ISSN 0206—418

# Казан утлары

6.1988



*КПСС өлкә комитеты бюросы*
*һәм Татарстан АССР*
*Министрлар Советы карары*

# 1988 ЕЛ ӨЧЕН ТАТАРСТАН АССРның Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯЛӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА



М. Хәсәнов



Ф. Әхмәтов

Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләре комитеты тәкъдимен караганнан соң, КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы карар бирәләр:

1988 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләрен бирергә:

1. **Хәсәнов** Мәхмүт Максудовичка — язучы, «Язгы аҗаган» романы өчен.

2. **Әхмәтов** Фасил Әхмәтгалиевичка — композитор, соңгы елларда иҗат иткән әсәрләре, симфониясе һәм «Мин гармун булыр идем» дигән җырлар җыентыгы өчен.

**КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре**
**Г. И. УСМАНОВ**

**Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе**
**М. Ш. ШӘЙМИЕВ**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АИЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

1988

6

(788)

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ

И. САЛАХОВ. **Тайгак кичү.** *Роман-хроника* . . 3

И. ЮЗЕЕВ. **Нихәл, күрше.** *Шигырьләр* . . . 53
К. СИБГАТУЛЛИН. **Еракларданн дәшеп...** *Шигырьләр* . . . 57
Г. МОРАТОВ. **Алма-риваять.** *Шигырьләр* . . 61

Җ. РӘХИМОВ. **Кыядагы чәчәкләр.** *Роман* . . 64

1 ИЮНЬ — БАЛАЛАРНЫ ХАЛЫКАРА ЯКЛАУ КӨНЕ

Р. ХАФИЗОВА. **Күңелле мизгел.** *Хикәяләр* . . 138
Р. ВӘЛИЕВ. **Улым хикәяләре.** *Парчалар* . . 139
Х. ХАЛИКОВ. **Куркактан курыккан.** *Шигырьләр* . . . 141
Р. БӘШӘР. **Картайган ат.** *Шигырьләр* . . . 142
Р. КОРБАНОВ. **Ташбака.** *Шигырьләр* . . . 142

ӘДӘБИ МИРАС

Ф. КӘРИМ. **Онытма.** *Шигырь* . . . . . . 144
Г. КАШШАФ. **Татар әдәбиятының якын дусты** . . . 145

ПУБЛИЦИСТИКА

Р. ФӘИЗОВ. **Яшәү мәгънәсе** . . . . . . . 148
Г. БАГДАЛОВ. **Табигатькә мәрхәмәт** . . . . 153

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

М. М. ХАСНУЛЛИН. **Еракларданн күренә** *(Менделеев районы)* . . . . . 156

БӘХӘС ДӘВАМ ИТӘ: «ЗАМАН ҺӘМ ШИГЫРЬ»

Р. ХИСМӘТУЛЛИН. **Сүзнең чәчәге, телнең бәлзәме** . . . . 159
Г. РӘХИМ. **Мактаулар, тәнкыйтьләүләр** . . . 165

БИБЛИОГРАФИЯ

Р. КУКУШКИН. **Шигъри телдә уйлану** . . . 171
Р. ЮНЫС. **Кыйгак-кыйгак җан кычкыра** . . 173

*Баш редактор*

**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**ӘХӘТ ГАФФАР**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**НУРИХАН ФӘТТАХ**
**РИЗВАН ХӘМИД**
**НИЛ ЮЗИЕВ**
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-65

*бүлекләр:*

проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

**УФАДА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ**

**Х. ГОБӘЙДУЛЛИН, Җ. МИҢНУЛЛИН. Якты йорт** *(А. Тимергалина рәсеме)*. . . . . 176

**КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА**

**М. МӘҺДИЕВ. Туган як авазы** . . . . . . 178

**СӘНГАТЬ**

**Д. ВӘЛИЕВА. Шәмаилләр** . . . . . . . 182

**БОРЫНГЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЛӘРЕ**

**Ф. ГАРИПОВА. Җүкәтау** . . . . . . . 185

**С. ХӘЙРЕТДИНОВ. Утлы еллар авазы** . . . 187

**ЮБИЛЕЙЛАР**

**И. НУРУЛЛИН. Каләмдәшем турында** *(Нур Гыйззәтуллинга 60 яшь)* . . . . . . 189

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . 190

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

Продолжение романа-хроники И. САЛАХОВА «Тернистый путь», роман Дж. РАХИМОВА «Цветы на скале», стихи И. ЮЗЕЕВА, К. СИБГАТУЛЛИНА, Г. МУРАТОВА.
1 июня — Международный день защиты детей: рассказы Р. ХАФИЗОВОЙ, Р. ВАЛИЕВА; стихи Х. ХАЛИКОВА, Р. БАШАРА, Р. КУРБАНОВА.
«Литературное наследие»: стихотворение Ф. КАРИМА; воспоминание Г. КАШШАФА о А. Фадееве.
«Публицистика». Очерки Р. ФАИЗОВА «Смысл жизни» и У. БОГДАЛОВА «С любовью к природе».
«Татарстан — родной мой край»: выступление первого секретаря Менделеевского райкома КПСС М. ХАСНУЛЛИНА.
«Литературная критика». Продолжение дискуссии «Время и поэзия: статьи Р. ХИСМАТУЛЛИНА и Г. РАХИМА.
В рубрике «Библиография» рецензируются книги Н. Юзиева, Ф. Яруллина.
«Памятники татарской культуры в Уфе» — Кумысолечебница Б. Максутова.
«К истории татарской культуры»: статьи М. МАГДЕЕВА «Голоса родины» и С. ХАЙРУТДИНОВА «Отзвук пламенных лет».
«Искусство»: искусствовед Д. ВАЛИЕВА знакомит читателей с одним из видов прикладного искусства татарского народа — шамаилями.
«Города древней Булгарии»: статья Ф. ГАРИПОВОЙ «Джукетау».
В номере отмечается 60-летие литературоведа Н. Гиззатуллина.
Дневник культурной жизни.
На наших обложках: «Золотое шитье» — женский головной убор — калфак;
Выставочный зал Союза художников Татарии.

Җаваплы секретарь *Флүс ЛАТЫЙПОВ*
Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова.*

Производствога бирелде 25.03.1988 ел. Басарга кул куелды 16.05.1988 ел. ПФ 05237. Офсет ысулы белән басылд
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 67049. Заказ А-129. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1988 ел.

## ПРОЗА

**Ибраһим Салахов**

# ТАЙГАК КИЧҮ

РОМАН-ХРОНИКА

## Ике очрашу



Ике мичне дә тоткыннар, сукыр чебен төсле, өереләп-сырып алган. Кайсысы күшеккән, өшегән бармакларын тырпайтып, пешә язып мичкә урелә. Кайсысы пимасын, чолгауларын киптерә. Кайберәүләре, шыр ялангач калып, күлмәк-ыштанын кыздыра — «куйларын» коя. Алар мич өстендә шытыр-шытыр килеп шартлый, көек исе тарала. Шунда ук эреле-ваклы консерв банкалары бокырдый — чәй кайный. Берсе куя, икенчесе ала. Берсе кулын пешерә — түгә. Бу оча, сүгенү, шау-шу тарала.

— Яле, контрлар, юл бирегез!

Ванька-Козгын! Колга буй. Тузган кара бөдрә чәч. Карчыга күзләр. Баракның старостасы. Чегән. Яшь. Бәлки теге Корольның улыдыр? Ул мичкә якынлашканда юл бирергә өлгермәгәннәрне шундук тибеп очырды. Корбан, гөнаһ шомлыгы, мич янында күлмәген кыздырып торган ап-ак сакаллы картка — рус әдәбияты профессоры Переверзевка бәрелеп, болай да дерелдәп кенә торган гәүдәне аударды. Көйгән ит исе аңкыды. Ярый әле профессорны шундук тартып алдылар... Мескен карт кычкыра да алмый — ыңгыраша гына. Сәкегә сузып салып, көйгән түшенә боз сиптеләр.

Ванька-Козгын мич өстендәге барлык банкаларны арлы-бирле этеп төшерде дә үзенең өч литрлы кастрюлен куйды. Өстәмә баланда, ботка! Аңа ашханәдән махсус рәвештә җибәрәләр — түрә!

Чатырның аргы очындагы түбән сәкедә (теге, тамчы тама торган сәндерәдә — политиклар) бер төркем блатной, өсләренә одеал ябынып, карта суга — паекка, баландага, тоткын «мундир»ына. Уен — изге. Отылучы вәгъдәләшкән вакытта бурычын түләргә тиеш. Юкса!

Кичә әнә теге карта уйнаучылар рәтендәге түбән сәкегә кыйшайган идем. Мин баракта «штатный» әкиятче. Блатнойлар әкият тыңларга ярата. Шуның өчен миңа аеруча хөрмәт, өстәмә бер чүмеч баланда — әкият сөйләгән кичләрдә анда-санда түбән сәкедә йокларга да рөхсәт. Казан төрмәсендәге карцер онытылды — тамак тәмугка кертә. Бервакыт,

---

Ахыры. Башы 4, 5 саннарда.

кемдер бик каты төртеп-этеп җибәргәнгә уянып, җиргә барып төштем. Чатырда идән юк, тоткынга такта әрәм итәләрме соң, ул әле приискa кирәк-ярагына да җитми. Аңгы-миңге ятам. Шулай нәрсәдер шак итте. Гырылдый башладым. Көч-хәл аягүрә бастым. Карауга, чәчләрем үрә торды. Сулыш алудан туктадым. Сәкедә — киселгән баш! Муенынннан ургылып кан ага. Калай күзләр миңа кадалган. Гришка-Чыпчык бит бу!

Оттырган унбиш паегын вакытында китермәгән.

Ә Ванька-Козгын, бернәрсә дә булмаган сыман, кан тамып торган беләк озынлыгы пычагын Гришка-Чыпчыкның бушлатына сөртте-сөртте дә, итек кунычына кыстырып, нниндидер табор көен сызгыра-сызгыра, баракның икенче башына китте.

Бүген мин Гриша яткан җирдә ятам — урын киңәйде... Төшкә кермәсә ярар иде. Инде керсә дә, кермәсә дә — керфекләр йомыла, арылган, аяк-кулны җыеп алып булмый. Иртә караңгыдан кара кичкә хәтле забойда, чатнап торган суыкта-челләдә, алтын юу сезонына участоклар әзерлибез бит.

Көнозын туңган тән хәзер мич кызуында да җылына алмый. Бушлатны баштан ук уранып, калач булып бөкләндем.

Йокы аралаш ниндидер шау-шу колакка керде. Әүвәле колагымны яба төшеп икенче якка әйләндем — шау-шу тынмый. Тагын борылдым.

— Магаданнан этап килде!

Безнең Линкольн приискысы Магаданнан мең чакрым ераклыкта. Этап безнең өчен зур сөенеч — яңа тоткыннар өстәлә. Этап килгәндә нинди генә мәхбүс йоклап ята ала! Мин дә йокылы-уяулы күзләремне ачтым. Чатыр ишегеннән ишелеп суык керә. Томан. Шау-шу. Бернәрсә дә күренми — йокы баса, тагын күзләрне йомдым, яңа гына җылына башладым бит. «Ярар, иртәгә дә күрермен әле». Әмма тавышлары колакта. Сөйләшәләр. Кычкыралар. Әле өске, әле түбәнге сәкедән урын эзләп тыкшыналар — егылып төшәләр. Сүгенүләр. Кычкырулар. Димәк, контрлар өстәлгән, уголовниклар килсә, урын сорап тормый, үзләре «хуҗалар»ны өстерәп төшерә.

Минә минем яныма да берсе килеп тыкшынды. Озын коры сөяк — шалдыр-гөлдер. Үзе суык, әйтерсең лә, чатыр артындагы шыңлап каткан каен яргагын китереп салдылар. Аягым белән тибеп җибәрдем, чигенде, тавышланмады, кысылыбрак ятты. Мин йоклап киттем.

Тагы күзәтченең карлыккан тавышы:

— Этапныкылар, тышка чыгыгыз!

Тагын ыгы-зыгы. Эт өргән тавышлар. Сүгенү. Тагын ишелеп кергән суык! Каһәр генә төшсен, яңа гына җылынып, йоклап киткән идем, тагын бүлделәр.

Ә ишек төбендә инде конвой башлыгы бaрактан чыгар алдыннан этапчыларның «гамәл дәфтәрләрен» укый.

— Петров Иван Иванович — илле сигез, унынчы.

— Пятница Миколь Кузьмич — илле сигез, унҗиденче.

Димәк, аларны яңа конвой санап-тикшереп ала.

— Тизрәк кыймылдагыз, тизрәк!

— Петров!..

— Мутин Мохтар!..

Күршем ишетелер-ишетелмәс кенә җавап бирде:

— Мин!

— Тизрәк! Авызыңны фәлән итим, йокыңны ачармын, кутәрәм!

Янымдагы тоткын сикереп торды, ыңгырашты. Сәкедән шуып төште.

— Тизрәк! Формуляр!

— Мутин Мохтар, илле сигезенче статья, ... пункт, ун ел төрмә...

— Чык әйдә!

«Мохтар! Мутин!» Яшен суккандай, аңгы-миңге булып киттем. Ан-

нан сикереп торып ишеккә таба йөгердем.

— Син кая кузгалдың, үләксә!?

Кемдер яңагыма сугып җибәрде — йокым ачылды. Алдымда — конвой башлыгы, кулында бер кочак формуляр. Ул ачулы карады да чыгып китте.

Ишек ябылды. Йозак шалтырады.

...Мең тугыз йөз утызынчы еллар. Казан педагогия техникумында укып йөргән студент чагым: стипендия унбиш сум. Шуңа ашыйбыз, шуңа киенәбез, шуңа күңел ачабыз, газета-журналлар яздырабыз, комсомолга, мопрга, «Бетсен наданлык» җәмгыятенә һәм башкаларга взнослар түлибез. Дөресен әйткәндә, тамак хәле әллә ни артык түгел иде.

Ә кәеф һәрвакыт күтәренке!

Борынны төшермибез — көн дә уен, көн дә — туй. Кайсыдыр «булачак шагыйрь» үз шигырьләрен әле язарга өлгермәгәнлектән, Тукайныкын җайлаштырган, без, карын ачса, күмәкләшеп шуны җырлыйбыз:

Фәгыйләтен, фәгыйләтен, фәгыйләт,
Әй бу студент халкының күңле шат!

Лекцияләрне тыңлау җәфасыннан котылу белән, без — егет-җилкенчәк — кышын печән базарына, «Көфер почмагына» барабыз да утын кисәргә-ярыргаялланабыз, җәен пристаньга төшеп баржалар бушатабыз. Кавын-карбыз килгәндә бигрәк күңелле — корсак шартларга җитешә. Менә шул «өстәмә керем» походыннан арып-талып, өстерәлеп тулай торакка кайтып егылганда гына, сөенечле хәбәр:

— Академия театрында «Отелло»!

— Отелло ролендә Мохтар ага Мутин!

Әфсен өрделәрме — арулар, йокылар әллә кая кача. Икмәк алырга дип саклап йөргән соңгы тиеннәрне җыябыз да (кызлар-шефлар да безнең җилкәдә, ярлы булсак та — егет) галеркага билет алабыз. Әгәр инде бөтен курска җитәрлек акча җыелмаса да, кайгы юк, хәйләсен табабыз. Бер өлешебез, күбесенчә кызлар, алдан билет белән керең, беренче пәрдәләрне карый, аннары тәнәфестә контрмаркаларны көтеп торучыларга чыгарып бирәләр. Без инде соңгы пәрдәләрне карыйбыз. Теләк — Мохтар ага Мутинның Отеллоны уйнавын күрү. Без генәме? Бөтен Казан шулай ашкына. Мохтар ага исеме афишаларда күренү белән, театр кассасында билет калмый.

Залда ут сүнә. Авыр бәрхет чаршаулар акрын гына ачыла.

Замок. Йокы бүлмәсе. Көмеш шәмдәлләрдә бернична генә шәм яна. Ярым караңгылык. Түрдә атлас чыбылдыклар белән капланган караватАнда, күпереп торган мамык түшәк-мендәрләргә күмелеп, ак ефәк юрган ябынып гүзәл Дездемона йоклый.

Кинәт шәмнәр калтыранып кызгылт телләре сузылып-тибрәнеп китә. Бүлмә эче тагын да караңгылана төшә. Ишек ачыла. Бүлмәгә ашыгып Отелло — Мутин керә. Көч һәм гайрәт ташып торган мәһабәт гәүдә. Сокланырлык килеш-килбәт. Ул Флоренция дәүләтенең дан һәм шөһрәткә күмелгән атаклы генералы.

Иң авыр, куркыныч сугышларда да каушауны белмәгән менә шушы Кумандан хәзер үзенә-үзе урын таба алмый газаплана. Ул бөек һәм мескен хәзер үзенең мөкатдәс гыйшкы алдында. Генерал акыллы һәм кызу канлы мавр-хыянәтче Ягоның мәкерле хәйләсе белән агуланган. Ул яна! Анда — бөек саф мәхәббәт һәм дәһшәтле нәфрәт! Өермә! Давыл! Тайфун! Ә Дездемона сабыйлар гамьсезлеге белән рәхәтләнеп, һичбер хәвеф-хәтәр сизмичә, онытылып йоклый.

— Син нинди пакь һәм гүзәл... (Отелло иелеп Дездемонаны үбә) Әмма... өзелгән роза кебек суларга-шиңәргә тиешсең хәзер.

— Отелло, бу синме? — Нинди ышанулы, назлы тавыш.

Отелло сискәнеп китә, гүя аны кара елан чага.

— Әйе, кадерлем...— тавыш калтырана. Отелло иңрәп күтәрелә. Аның йөрәгендә хәзер ике ут — мәхәббәт һәм нәфрәт. Отелло үз-үзе белән көрәшә. Кем-кемне?!

Мәхәббәтме? Нәфрәтме?

— Минем бердәнбер гөнаһым — сиңа булган керсез мәхәббәтем...

— О, юк! Юк!

Мәкер белән агуланган, күзләре тонган Отелло, бу илаһи тавышка чыдый алмый тулып-ташып Дездемонага ташлана һәм үзенең саф изге мәхәббәтенә кул суза...

Зал сулыш алудан туктап тетрәнә.

Ә инде явыз хыянәтче Ягоның җинаяте фаш булгач, Дездемонаның илаһи мәхәббәте үзенең бар сафлыгы белән яңадан ачылгач, Отелло соңгы көчен югалтып егыла.

Ул әле исән. Әмма Дездемонаның самими мәхәббәтеннән башка яшәү аңа нигә? Нигә?!

Йөрәкләр тибүдән туктый... Һәм бары, озак вакыт үтеп акылын җыйгач кына тамашачылар шашынып, тыела алмыйча, Мохтар ага Мутинны алкышлыйлар...

Менә шушы бөек артист, гали җан, татар халкының даны һәм сөенече — бүген арестант. Колыманың җан тетрәткеч зәмһәрир суыгында этап белән куылып, бер прискыдан икенчесенә сөрелә. Ни өчен?

Мин үксеп елап урыныма килеп егылдым. Вахта алдында һаман әле шау-шу — конвоирларның ачулы әмерләре, сүгенүләре һәм өстерелгән этләрнең абалап өрүләре.

Ә мин һаман әле тыела алмыйм, үземне үзем тиргим, үкенеп өзгәләнәм. Ул бит минем янымда гына ятты. Нигә инде сикереп торып исәнләшмәдем, кулларын кысмадым? Кайдан килә? Кая бара? Авырмыймы? Ул, мөгаен, шушы араларда гына материктан килгәндер. Казанда нинди яңалык бар икән? Минем Казаннан китүемә-аерылуыма инде дүртенче ел бара бит,— их сорашасы, сөйләшәсе иде...

Урыннан-сәкедән сикереп торып йөгерәсе — Мохтар аганы куып җитеп кочаклыйсы килә. Мескен күңел, юкка гына талпынасың бит! Чатыр ишегендә ат башы хәтле йозак. Аннан ары чәнечкеле тимер чыбыклар, манаралар, мылтыклар, пулеметлар, этләр. Ә шулай да... Син кайда, Мохтар ага? Кайда син?

Бу очрашылмаган очрашудан соң ике елга якын вакыт үтте. Колыма һәм Индигирка елгалары инде ике тапкыр, аз гына вакытка булса да — июнь, июль, август айларында өсләрендәге калын боз катламнарын салып, ачылып, ниһаять, башка елгалар кебек тулып, ташып агып, улакларда алтын юдылар, «соргылт-кызыл тараканнар»— самородокларны чайкадылар. Ә тоткыннар һәр көн, һәр ай берсеннән-берсе өметлерәк хәбәрләр тыңлады. Тиздән моңа хәтле ишетелмәгән бик зур амнистия була икән, илле сигезләрнең барысын да азат итәләр икән...

Әмма һәр көн таң караңгысыннан вахта каршындагы өрлеккә эленгән чаңга сугалар:

— Даң-доң! Даң-доң!

Уяну. Вахта. Конвой. Тентү. Карцер һәм... Тагын этап. Өмет. Ышану. Көтү. Мәхбүс шулар белән яши дә, мескен.

Менә шулай михнәт чиккәндә, ниһаять, мин агач аякка калып, инвалидлар колоннасына килеп эләктем.

Инвалидлар колонна-лагере Магаданнан егерме өч километр чакрымда. Шуның өчен «Егерме өченче колонна» дип йөртәләр икән аны.

Бу лагерьда ике зона. Берсе — эшче зона, анда аз-маз кузгала, әлени дә булса майтара ала торган инвалидлар тупланган. Икенчесе — гарип-горабалар; сукырлар, аяк-кулсызлар.

Мине турыдан-туры беренче зонага керттеләр. Монысы да бәхет — эшләсәң, үлмисең. Мин кәрзин үрүчеләр бригадасында эшли башладым.

Бу зона зур, монда ширпотреб цехлары — мебель, савыт-саба, уенчык, караваt ясыйлар. Талчыбыктан кәнәфи, урындык, чемодан, тартмалар һәм кәрзиннәр үрәләр. Бу соңгысы миңа бигрәк тә ошады — төрле төстәге бизәкләр төшереп үрелгән кәрзиннәр — түгәрәк, озынча, капкачлы, капкачсыз,— уенчык диярсең, шундый матурлар.

Беренче бригада — уголовниклар, аллага шөкер, аларның аяк-куллары исән-сау, конвойсыз да зонадан чыгып йөри алалар. Аларга ышаныч зур — Колыма буеннан талчыбык кисеп, аркалап алып кайталар.

Без, бу талчыбыкның кабыгын сыдырабыз, каезлыйбыз. Аннан аны зур казаннарга салып кайнатабыз. Ул ныгый, үргәндә дә чатнамый, йомшый, сыгылмалы була. Талчыбыклар «пешеп» өлгергәч, алып бераз саркытабыз да төрле төстәге буяу изелгән казаннарга төшереп манабыз. Кайсы кызыл, кайсы яшел, кайсы күк төскә керә. Буялган талчыбыклар цехта бераз киптерелә. Менә шуннан соң гына алар эшкә файдаланыла — салават күпере төсләре белән балкыган нәфис кәрзиннәргә әверелә.

Мин килеп кушылган кәрзинчеләр бригадасында илле тоткын-инвалид. Барысы да «илле сигезләр». Бригадир Максим Максимович минем төсле үк агач аяк. Инде чәчләре агарган, түгәрәк йөзле, ягымлы кеше. Ачуланмый. Сүгенми. Сабыр. Лагерьда андый кеше бик сирәк очрый. Кулга алынганчы ул Киев хәрби округында дивизия комиссары булып хезмәт иткән, гражданнар сугышында Ковпак белән бергә сугышкан карт командир. Большевик диләр үзен.

— Кәрзин үрү төбеннән башлана. Без дә шуннан башлап өйрәник, яле, әнә теге нечкәрәк талчыбыкларны бир әле,— дип, Максим Максимович мине үз янына утыртып һөнәренә өйрәтә башлады.

Ниһаять, монда эшли башлауның беренче якшәмбесендә, Колымага килгәннән бирле өч елда беренче тапкыр ял иттем, төшке баландага хәтле йокладым. Үземә-үзем ышанмыйм, көпә-көндез сәкедә аунап ятам. Кызык.

Төшке аштан соң мин дә, башкалар кебек, палатка артына кояшка кызынырга чыктым.

Май. Кояш ярыйсы ук югары күтәрелгән, кыш көннәрендәге кебек, офык тирәсендә генә әйләнми. Дөрес, монда әле, материктагы кебек, агачлар яфрак ярып, сиреньнәр шау чәчәктә утырмый. Кар көртләре яңа гына челтәрләнә. Юл читләрендә, тау итәкләрендә әле беренче гөрләвекләр генә... Шулай да яз! Күңелдә — яз!

Зона ике кат чәнечкеле тимер чыбык белән уратылып алынган. Һәр почмакта — манара. Анда кулына мылтык тоткан солдат ялт-йолт каранып-күзәтеп тора. Әгәр инде алай-болай берәр тоткын тимер чыбыкка якынлаша башласа, хәзер затворын арлы-бирле йөртеп кычкыра:

— Якын килмә! Атам!

Сул якта эштән чыкканнар зонасы. Арада чәнечкеле тимер чыбык койма һәм манара. Арырак — вахта. Анда бер төркем конвойчылар капка төбендәге өстәлдә домино уйный.

— Әй, карагыз әле,— дип кычкырып җибәрде кемдер,— әнә кыр казлары килә.

Аптырап, тавыш килгән якка борылдым. Колымага нинди кыр казлары килсен ди. Зона аръягындагы үрдән, бер-бер артлы нәкъ кыр казлары төсле тезелешеп, бер төркем гарип-гораба төшеп килә: бөкрәйгәннәр, көчкә-көчкә атлыйлар, җилкәләрендә коры-сары каен ботаклары. Нишлисең, Колымада май аенда да мич ягарга кирәк!

Бу инде гарип-тоткыннарның әле бераз кыймылдый ала торганнары — зонаны утын белән тәэмин итүче бригада.

«Кыр казлары»ның алды инде зонага җитте. Вахтер озын шинель кигән колга буйлы уголовник кулындагы наряд кенәгәсенә карандаш

белән билге ясап кычкыра, вахта капкасыннан кертә:
— Иванов, уз!
— Базарбаев, уз!
— Пятница, уз!
Алпан-тилпән килеп, үз аякларына үзләре сөртенеп, утынчылар уза. Төркемнең иң соңында ава-түнә килгән бер озын, ябык инвалид, вахта капкасына да житә алмыйча, абынып егылды. Артта тартылып-уйнаклап килгән овчарка, бәе бушауга, бер генә сикереп, җирдә яткан теге утынчының өстенә ыргылды һәм талый башлады.
— Ха-ха! Ха-ха!
— Шайтан, әйдә каезла шул контрны.
— Ха-ха, хи-хи-хи!— арттан килгән конвойчылар туктап калып, бу тамашаны карап көлә башладылар.
Бушлаттан мамык оча, әйтерсең лә, кар ява.
Теге мескен бөгелеп башын яшерә. Овчарка, шуны сизгәндәй, утынчының башындагы иске бүреген йолкып алды. Овчарка бүрекне йолыккалап ертканда, бер конвойчы килеп теге мескенне тибә-тибә тарткалады:
— Тор, тор, контр! Зонага кергәч иркәләнерсең.
— Әй, Мутин,— бу яктан вахтер кычкыра-сүгенә башлады,— фәлән итим, тагын комедия башлыйсыңмы? Мин сиңа хәзер театрны күрсәтермен. Тиз йөгер, бригаданы көттермә!
«Мутин! Мохтар ага!» Мин чәчрәп урынымнан тордым — агач аяк төртелеп авып киттем. Тагын тордым. Җан тавышыма кычкыра башладым:
— Мутин! Мохтар ага!
Вахтага таба ашыга атладым (каһәр төшкере агач аяк атлаган саен сөртенә).
Мохтар ага инде үз зоналарының капкасыннан узган, утынын ташлаган иде.
— Мохтар ага!
Ул минем тавышны ишетте ахрысы, борылды, калтыраган зәгыйфь тавыш:
— Сез кем? Кайдан?— дип инәлде.
— Мин... Мин... Казаннан.
— Зона яныннан кит!
Мохтар ага зонага кергән иде инде, тагын теге овчарка аның өстенә ташланды. Манарада мылтык шартлады. Минем сул җилкәм көеп китте.

Ун көн карцерда утырганнан соң, мине, качарга хәзерләнүдә гаепләп, тикшерүгә хәтле, тулы гарипләр зонасына күчерделәр. Ә теге көнне манарадан атылган пуля җилкәмне тырнап кына үткән иде, ярам ун көндә төзәлде.
Зонага керүгә, вахтердан: «Мутин Мохтар кайда?», дип сорадым.
Ул кулын селтәде.
— Ишетмәдеңмени, ул артистка инде әллә кайчан «агач бушлат» кигезделәр ләбаса.

## Тапшырылмаган хат

Исәнме, кадерлем Нина!
Хатымны ничек башлап китәргә дә белмим. Гафу ит, гафу ит дустыңны. Инде әллә кайчаннан бирле сиңа хат язарга җыенам. Ләкин ничектер кул җитми — дөнья мәшәкатьләре.
Әнә ерак офыкта алсуланып таң беленә башлады... Өйдәгеләр барысы да — хатыным да, балаларым да тәмле йокыда. Ә минем керфек-

ләремә йокы кунмый. Синең белән сөйләшәсе, үткәннәрне искә төшерәсе, күңелне, зарыгып тулган күңелне бушатасым килә. Сагындым, өзелеп сагындым үзеңне, кадерлем.

Нигә болай вакытсыз хат язарга утырдың, дисеңме? Хәзер әйтәм, җаным. Сәбәбе бар.

Командировкада идем. Менә бүген үзебезнең Күкчәтау станциясенә таң беленә башлагач кына килеп төштем. Автобуслар туктаган. Алар бит иртәнге сәгать алтыдан гына йөри башлый. Ә мин Күкчәтаудан жидс километр ары, Кызыл Яр авылында торам ич. Нишләргә? Акрын барган куян артыннан житкән, ди. Тәвәккәл. Җәяүләп кенә китеп бардым.

Гаҗәп бер төн иде бүген. Әйтерсең лә, куе мамык шәл бөркәнгән шәһәр янып торган гәүһәрләр белән бизәлгән. Шуның өчен җылы, җил дә исми. Тып-тын. Биек таш йортлар куе караңгылыкка чумып йокымсырыйлар. Бары тик багана башларындагы ак шәмнәр генә тирәякка тыныч нур сибеп, урамны яктырта. Мин, әле кичен генә яңгыр белән юылган асфальт тротуардан атлыйм. Адым саен ул шыңлап, яңгырап китә. Бер машина узмый. Бер кеше күренми. Мин бер үзем. Гүя, бер ялгызым дөнья буйлап атлыйм — шап-шоп! Шап-шоп! Үз адымым тавышына үзем куанып, бөтен мәшәкатьләремне онытып, аруымны онытып, ниндидер эчке шатлыклы бер җилкенү белән атлыйм. Шап-шоп, шап-шоп! Кинәт сискәнеп туктап калдым. Нәкъ минем каршыдагы зур, якты бер йолдыз калтыранып торды да кинәт кузгалып, алтын ук булып офыкка атылды. Күк йөзе яктырып, нурланып китте. Ә теге алтын ук янып кара-куцкыл күкне икегә ярып, балкып җиргә ашыга. Нинди матур күренеш! Караңгы төндә шулай гел янып, нур сибеп торсын иде ул... Теләгемне теләп тә бетерә алмадым, алтын ук кара бәрхет күкне ярып үтеп, офыкка җитәм дигәндә генә юк булды, сүнде... Күк тагын караңгыланып калды. Менә шул мизгелдә йөрәгем авыртып китте. Сине күргәндәй булдым. Йолдызым, Нина, Нина Воскресенская (гафу ит, әтиең исемен онытканмын бит, хәерсез. Аннан, без ул вакытта зурлап эндәшергә артык яшь идек). Әйе, син дә, Нина, гомерем күгендә, аның иң караңгы, кара болытлар белән томаланган чагында, якты бер йолдыз булып балкыдың, яктырттың — өмет, дәрт, көч бирдең миңа һәм... юк, юк! Сүндең дип әйтә алмыйм... син бит күктән егылган метеорит түгел, якты бер нур, бәхет, янып торган өмет идең бит син, күз нурым...

Әле дә хәтеремдә, поездыбыз Тайшеттан иртә белән чыгып, Топорок разъездына икенче тәүлектә төн уртасында гына килеп җитте. Инде колоннага алып барырлар, баракка кереп җылынырбыз дип куанган идек, булмады. Вагонны ачмадылар, бары тик составтан гына ычкындырып калдырдылар.

Тышта буран. Җил, вагонны аударгандай булып, әле бер, әле икенче яктан өрә, улый, шыңшый. Бераз тынып тора. Инде басылды, ахрысы, дигәндә, буран тагын да катырак тавышланып вагонга ташлана — ярыклардан кереп биткә бәрелә. Без бер-беребезгә кысылабыз. Алай да җылынып булмый, дер-дер калтырыйбыз. Суык җелеккә, сөяккә үтә. Торып, вагон эчендә булса да бераз йөрсәң, кыймылдасаң, тән бераз җылыныр да иде. Ләкин... кырык баш тоткынга нибары унҗиде аяк (өчебез бөтенләй аяксыз, калганнарыбызда — берәрдән генә). Протезлар да юк. Менә, кәкре таякларга таянып йөреп кара. Шуңа да карамастан конвой безне лагерьга алып барырга базмый, мөгаен, качып китәрләр, дип курка. Без инде менә икенче тәүлек авызга бер валчык капмаган. Тайшетта исәптән төшерделәр, ә бу колоннага вакытында килеп җитә алмадык. Җитмәсә, юньле кием дә юк — таланып беткән бушлат, чытырдап каткан «ЧТЗ»лар. Ә вагон артында тайга ыңгыраша!

Син Тайшет — Абакан тимер юлын салу тарихын яхшы беләсең. Үзең анда катнаштың бит. Юл Тайшеттан Братскига килеп җиткәндә генә сугыш башланды. Эшне шунда туктатып, юл салучы тоткыннар-

ны Уралга — хәрби заводларга күчерделәр. Тайшеттан башланып Братскига кадәр сузылган тимер юл полотносының ике ягында тыгызланып баскан мәһабәт кедрлар, пихталар, карагайлар. Алар арасында сыерчык оясы кебек кенә булып манаралар күренә. Лагерьлар. Монда аларны колонна дип йөртәләр бит. Лагерьларны тимер юл салучы тоткыннар корган. Нык итеп, өч кат чәнечкеле тимерчыбык белән уратып, бер генә мәхбүс тә ычкынмаслык итеп салганнар. Мондагы тоткыннар Уралга күчерелгәч, бу лагерьлар бушап калган. Ләкин озакка түгел. Менә хәзер тагын шул лагерьларны тутыру бара. Безне, Колымадан кайтарылган бер партия инвалидларны, шушы лагерьларның берсенә — Топорок колоннасына билгеләделәр.

Безнең поезд бу якка кичә иртә белән үк кузгалган иде. Аз гына бардык та тукталдык. Буран күтәрелеп юлны кар баскан. Безне саклап алып баручы конвой, шул тирәдәге колонналарның берсенә барып, тоткыннар алып килде. Алар, өч-дүрт сәгать карны казып, юлны ачтылар. Ниһаять, гудок кычкырды. Шалдыр-шолдыр килеп, кагылып-сугылып поезд кузгалды. Монда барысы сигез вагон, җидесендә тоткыннар, сигезенчедә конвой. Бу — Тайшет-Братск трассасы буенча мәхбүсләр ташучы махсус поезд. Бераз баргач, поездыбыз тагын тукталды. Конвой тагын колоннага китеп тоткыннар алып килде. Менә шулай итеп Тайшет белән Топорок арасын безнең поезд тәүлек ярым йөреп килде. Суык, мөгаен, минем йөрәккә үтеп кергән. Бармакларым гына түгел, сау аягым да, гарибе дә хәрәкәтләнми. Үземне-үзем көчләп кузгалырга, мүкәләп булса да вагон эчендә арлы-бирле йөрергә теләп омтылган идем, утырган җиремнән авып киттем.

Сискәнеп уяндым. Юк, куркудан түгел, киресенчә, сөенүдән. Артык йомшак, артык шәфкатьле кул минем битемнән, маңгаемнан сыйпый. Нинди рәхәт! Җан эри. Бу өнме, әллә төшме, үкенечле төш кенәме? Кайда мин? Ашыгып керфекләремне күтәрергә, күзләремне ачарга — хакыйкатьне күрергә тырыштым,— булмый. Әйтерсең лә, кабакларыма ком өйгәннәр. Керфекләрем күтәрелми. Авызым кипкән, иреннәрем көя.

— Су...— дидем. Әллә димәдем дә, уйладым гынамы? Белмим. Ләкин, теге шәфкатьле кул минем иреннәргә тәмле су тамызды. Йотылып эчтем, гүя тере суын бирделәр. Күзләремне ача алмыйм. Ләкин... Күрәм. Гаҗәп! Әгәр кеше, маңгай күзләре белән күрә алмаса, күңел күзләре белән күрә икән. Нәкъ шул мизгелдә күңел күзләрем белән дөньядагы иң матур, иң шәфкатьле кеше итеп күрдем мин сине. Әмма әйтә алмадым. Башым әйләнде. Нindидер караңгы бер упкынга егылдым.

— Молодец, кризисны җиңеп чыктың. Хәзер инде куркыныч чигенде,— дидең син икенче тапкыр уянуымда. Аптырадым. Нинди кризис? Нинди куркыныч? Мин кайда? Вагон әле һаман Топорок разъездында туктап торамы? Ә буран? Нигә мин өшемим? Ә каршымдагы бу ак халатлы, сөйкемле сылу кыз? Ул кем? Кем ул? Әллә фәрештәме?

— Менә кайнар чәй эчеп җибәрегез.

Искиткеч йомшак, иркәләүче көмеш тавышың миңа нindидер илаһи көч бирде, күзләремне ачтым — синең белән очраштым. Һәм синең рәсемең-төсең мәңгегә күңелем түрендә калды.

Хатымның шушы юлларына килеп җиткәч кенә кулымнан каләмем төшеп китте. Нигә икән? Хәерлегә булсын, әйе бит?!

Әнә, ерак офыктан, Күкчәтау тауларының өркәчләре артыннан, кояш күтәрелә. Көнчыгыш алтын ялкыннар белән балкый. Алсуланып таң ата. Алсуланып кояш байый. Менә шулай көн үтә. Гомер үтә. Агымсу кебек туктамый ага, әллә кая, билгесез ярларга ашыга ул кеше гомере. Менә инде безнең аерылышуга да өч дистә ел гомер үтте. Ул вакытта син әле егерме ике яшьлек кенә сылу кыз идең. Ә хәзер? Юк, юк! Әле һаман да нәкъ шул без очрашкан вакыттагы кебек яшьлек, шатлык белән балкып торган, зифа һәм искиткеч шәфкатьле, гүзәл күңелле кеше бит син, Нина!

Менә хәзер күзләремне йомам да сине эзлим. Әгәр ике йөрәк бер-берсен бик-бик яратса, өзелеп сагынса, бер-берсенең тавышларын ишетәләр һәм... бер-берсен күрәләр, диләр. Чын микән? Тукта! Бу ни бу? Аз гына сагыш сөреме шәүләләнгән соргылт күзләр. Никадәр моң, никадәр мәхәббәт ул чак кына кысык, соргылт күзләрдә... Я, хода! Бу нинди могҗиза. Бу күзләр синең илаһи күзләр бит, Нина. Югалтмасам гына ярар иде. Күзләремне чытырдатып йомам. Күгелҗем томан эченнән син якынлашасың! Күрәм! Әйттем бит, син үзгәрмәгәнсең дип. Нәкъ теге вакыттагы кебек аз гына, аз гына алсуланып торган нәфис яңаклар. Матур гына борын. Аз гына ачылып, гадәттәгечә елмаеп торган юка иреннәр. Түгәрәк, чак кына алга бәреп торган ияк...

Кемдер матур итеп, көйләп сызгырды. Күзләремне ачтым. Кояш инде Күкчәтау таулары өстендә. Дала зөбәрҗәт диңгез булып балкый. Тәрәзәм каршындагы колгага куелган оясыннан башын чыгарган да, очынып-очынып сыерчык сайрый... Ә син кайда соң? Кайда соң мине үлемнән алып калучы изге җан? Чәчәкләр өстендәге чык тамчысы кебек балкып яндың да, кояш чыгуга юк булдың.

...Икенче тапкыр аңыма килеп, күзләремне ачкач, миңа шикәрле, кайнар чәй эчкездең дә: «Сездә бик куркыныч үпкә авыруы, кулдан килгән кадәр дәваларбыз»,— дип янымдагы тумбочкага порошоклар, таблеткалар куеп, барактан чыгып киттең.

— Бәхетең бар икән, егет, синең белән бергә алып килгәннәрнең өчесен инде моргка озаттылар. Менә бу яшь врач — Нина Воскресенская өч тәүлек яныңнан китмәде. Туган сеңлең дә болай карамас. Әллә чынлап та берәр туганыңмы ул?— диделәр минем янда яткан авырулар.

— Санбарак тоткын симертүче база түгел, эшкә чыксыннар,— дип, колонна башлыгы төзәлеп килгән авыруларны эшкә куганда, «Бу авыруда — плеврит. Аңа эшкә чыгарга ярамый», дип тагын мине саклап алып калдың.

Ахырында мин үзем эшкә чыгарырга рөхсәт бирүеңне сорап аптырата башладым. «Ашыкма! Вакыты килгәч әйтермен», дидең. Аннан бер көн үзең мине санчастькә чакыртып алып, сәламәтлегемне тагын бер кат тикшереп чыктың да:

— Кәрзин үрү цехына язам. Анда эш җиңел һәм күңел күтәрә торган. Бер вакыт шигырь үргәнсең, инде кәрзин үреп кара...— дип елмайдың һәм түрә килеп керүгә, житди кыяфәт алып, тавышыңны күтәреп: — иртәгәге көннән эшкә. Больница паегын тагын бер атна сакларга,— дидең.

— Эшләп ашаса да катмас,— дип түрә кашларын җыерды.

— Тагын кем бар?— дип кычкырып, син аның сүзен һәм ачуын бүлдең. Мин тиз генә киенеп чыгып киттем.

Яраттым мин ул эшне. Кеше, бигрәк тә тоткындагы кеше, табигатьне юксына, сагына. Ә менә безнең алда ямь-яшел болын, урман исе аңкытып торган талчыбыклар. Бала вакытлар, әти белән печән чабуга йөрүләр, кичен яңа чабылган дымлы, хуш ис аңкып торган печән өстенә ятып, бер гамьсез рәхәтләнеп йоклаулар искә төшә...

Бу цехта төрле-төрле кәрзиннәр (бер тоткалы, ике тоткалы, зуркечкенә, базар өчен — бизәкле, хуҗалык өчен — кабыгы белән), алардан тыш, өстәлгә ашамлыклар куя торган төрле табаклар, вазалар да үреләэ иде.

Хәтереңдәме, мин сиңа төрле төстәге чыбыклардан ридикюль шикелле ябылмалы кечкенә генә кәрзин үреп биргән идем. Син аны кулыңнан төшермәдең, зонага гел шул кәрзин-ридикюль белән йөрдең. Ә мин читтән карап, балалар төсле сөенеп тора идем: «Ошаткан, кулыннан да төшерми...» Бу әле соңыннан, мин цехта бригадир булып эшли башлагач. Читтән караганда, кәрзин үрүнең әллә ни кыенлыгы юк сыман. Башта нигез-төпне әзерлә. Аннан чыбыкларны берәмләп үрә бар. Юк, алай тиз генә булмый икән ул. Мин цехка килгәндә, мастер булып

Андрей Христианович Меркер — озын буйлы, ябык, шадра битле немец карты эшли иде. «Кайгырмагыз, берәүне дә сүкмәгез. Яхшылык та, яманлык та бер алла тәгаләдән, ул рәхимле. Безне үзенең шәфкатеннән аермас. Сез бары тырышыбрак эшләгез. Һөнәрдән жирәнмәгез. Өйрәнегез. Бер кеше дә оста булып тумый. Эшли-эшли, өйрәнә-өйрәнә остара»,— дип кәрзин үрергә өйрәтә иде. Мин бу һөнәрне тиз үзләштердем. Мөгаен, кече яшьтән үк верстак янында эти белән агач юынып, юкылап үсүем дә ярдәм итте. Ә кайберәүләр еллар буе утырып нормаларын тутыра алмый, ә кәрзиннәре күп вакыт брак булып чыга. Мин чыннан да яратып, күңел биреп эшләдем. Бу да үзенә күрә иҗат эше. Тырышсаң, уйласаң, әллә нинди матур әйберләр эшләргә, бизәргә була икән ул... Андрей Христианович беренче көннәрдән үк мине яратты. «Кулы ипле, эш чыгар», диде һәм үзе авырып цехтан китәргә булгач, алъяпкычын салып миңа бирде.

«Төсем итеп ки. Кара, бервакытта да ашыгып, булыр-булмас эшләмә. Кәрзиннәрең кешеләргә сөенеч китерсен», диде ул киткәндә. «Әле, алла кушса, күп ятмам, кайтырмын, бергәләп эшләрбез», дигән иде дә, кайта алмады остазым. Санбаракка барган көнне үк дөньядан күчкән, мескенем.

Кара әле, сөйли башлагач, әллә кайчан онытылган вакыйгалар искә төшә икән. Цехта бригадир булып эшләргә керешкәч, минем белән кызык бер хәл булып алды бит. Кызык дип, ул хәл мине яхшы ук шүрләтте. Шүрләмәслек тә түгел. Һич көтелмәгән хәл.

Бер көнне төшке аш вакытында, бер дә көтмәгәндә, барагыбызга колонна башлыгы Иван Иванович килеп керде. Староста, кулындагы баландалы банкасын төшереп җибәреп, аягүрә басарга әмер бирде. Бастык. Түрә гадәттә кичке тикшерү вакытында, яки юлга озату алдыннан гына килә иде. Шып булдык, тын да алмыйбыз. Иван Иванович тәбәнәк, юантык кеше, күзлек астыннан гына каранып йөрде дә минем янга җиткәч, туктап, озак кына миңа карап торды да:

— Алга чык! — диде.

Култык таякларымны арлы-бирле авыштырып барак уртасына чыгып бастым — я юлга, я карцерга.

Башлык, миңа игътибар да итмичә, ишеккә таба атлады һәм чыгып барганда гына борылып:

— Минем арттан бар! — диде.

Һичшиксез — карцер! Ни өчен? Егылып китә яздым — иптәшләр тотып калды. Бушлатның җиңен таба алмыйм. Бүрек әллә кая киткән. Көч-хәл киенеп ишеккә атладым. Әле үткән төндә генә көчле буран тузгыган иде. Зона уртасында биек-биек көртләр. Башлык шул көртләр өстеннән атлый. Култык таякларым көрткә батып-батып китә. Суырып ала алмыйм егылып китәм, көрт өстенә үрмәләп чыгам. Йөрәк дөп-дөп итә. Шабыр тиргә баттым. Ни өчен инде ул мине штраф зонасына алып бара? Бу салкын кыш уртасында анда эләксәң беттем диген. Ике-өч көртне үткәч, әлеге зона каршындагы баракка борылдык.

— Менә бу токкынны баштанаяк киендер — күлмәк-штан, гимнастерка, чалбар, яхшы ботинкалар. Иң кирәге — яхшы тун бир! — диде Иван Иванович келәтче картка.

— Гражданин начальник,— дип карт сикереп торды да арлы-бирле каранды,— гражданин начальник, бездә тун юк бит.

— Телеңә салынма! — Башлык кычкырып аның сүзен бүлде.— Булмаса, менә өстеңдәге тунны салып бир!

Бу ни бу? Аптырап калдым.

Баракка кайткач, иптәшләр үземне танымый. Исләре китте. Шакатырлык бит. Гел сәләмә, тишек-тошык белән йөргән кеше кинәт өр-яңадан киенсенче. Җитмәсә, келәтче өстеннән салдырып алынган кара тун.

— Бүрең үкерде. Киттең, малай, өеңә,— дип иптәшләр аркадан кага, куаналар. Көнләшәләр.

Ул арада бер вахтер протез китерде.

— Врач җибәрде! — дип.

Болай булгач инде барыбыз да, иптәшләр белән бергә үзем дә ышандым — иреккә!

...Рапортны укып бетерүгә, зал кул чаба башлады. Мин тагын берничә сүз әйттем, президиумдагы хәрби кешеләр кул чаптылар. Башым әйләнеп, күз алларым караңгыланып китте. Рапорт кәгазьләремне президиум өстәленә куйдым да тиз генә сәхнә артына атладым. Бу ни бу? Нәрсә булды? Һаман төшенә алмыйм. Бара торгач, сәхнә артындагы бүлмәләрнең берсенә килеп кердем. Арып урындыкка утырыйм дигәндә генә әллә кайдан син килеп чыктың да кочаклап үптең.

— Молодец! Бик шәп сөйләдең. Генерал үзе дә канәгать калды. «Молодец», ди. Син чыннан да молодец...

Үз гомеремдә беренче тапкыр, ахры, мин кайнар иреннәрнең, синең иреннәрнең көчен сиздем. Яндым! Сөендем!

Кайдан, кайдан килде миңа бу могҗизалы бәхет? Күзләремә яшь тулды. Җиде ел төрмәләрдә, лагерьларда кагылып, сугылып, кимсетелеп йөргәннән соң, беренче тапкыр үземне тагын кеше итеп тоеп, кайнар кочагыңда еладым мин.

Тайшетлаг ударниклары слетына бригадабыз исеменнән рапорт әзерләү, шул слетка мине делегат итеп сайлау, слетта рапорт бирүне миңа тапшыру, өр-яңа киемнәр, протез... Барысы да синең инициатива икән. Аны мин слеттан кайткач ишетеп таң калдым. Менә син нинди «астыртын», чая кыз икән, Нина!

Зона эчендәге кар көртләре әкренләп эреп бетте. Беренче яшь шытымнар күренде. Яз! Инде сигезенче язны мин төрмәләрнең тынчу камераларында яки менә мондагы кебек чәнечкеле тимерчыбыклар артында каршылыйм. Ә шулай да күңел ярсый, тулып ташый, еракка, күгәреп торган тайга урманнары артына, Күкчәтау далаларына омтыла.

— Бригадир! — яткан җиремнән сискәнеп сикереп тордым. Бүген якшәмбе, мин барак артында кояшта кызынып, уйланып ята идем. Күзәтче сүгенә башлады.— Шайтан алгыры! Бөтен зона буенча эзлим, ә син монда бот күтәреп ятасың.

— Нәрсә булган?

— Нәрсә булсын, вахтер килде, сине санбаракка чакыра.

Врач бүлмәсе. Ишеген ачып керүгә, аптырап туктап калдым. Син! Шундый шат, шундый балкып торасың. Исем китте. Күзләрең шундый зур, якты-якты, иреннәрең, бит алмаларың ап-ал булып янып тора.

— Ибраһим! — Син йөгереп килеп кулларымнан тоттың, каты итеп кыстың.— Беләсеңме, нинди сөенечле хәбәр әйтәм мин сиңа!

— Юк. Белмим,— дидем гаҗәпләнеп.

Син мине ике куллап кысып кочакладың. Үзең ут булып янасың. Йөрәгең дөп-дөп итә, миңа ишетелә. Кинәт күзләреңдә яшь тамчылары күренде. Битемә тамды.

— Беләсеңме, Җиңү! Сугыш беткән... Инде әтием дә кайтыр, әйе бит, дустым? — дип син минем иреннәремә үрелдең...

Шул мизгел ишек ачылып, бүлмәгә каравыл башлыгы Волков килеп керде, болай да салкын йөзе агарып китте.

— Бу ни?!

— Нигә ишекне шакымыйча керәсез? Бу сезгә вахта түгел! — дидең син кочагымнан чыгып, ачулы тавыш белән.

— Кирәк җирендә шакырмын! — диде дә Волков, ишекне шарт иттереп ябып чыгып китте.

Мине шул көнне үк ун тәүлеккә карцерга яптылар, аннан соң Марлагның штраф колоннасына җибәрделәр.

Ә син?

Берәүләр, Нина Воскресенскаяны башка лагерьга күчергәннәр,

диде. Ә кайберәүләр... Юк, юк, мин ул сүзләргә ышанмыйм. Син исән! Син яшәргә тиешсең!

Менә кояшның беренче нурлары тәрәзәмне яктырттылар. Менә шул нурлар кебек син дә минем күңелемне яктыртасың! Хәзер дә! Мөгаен, мәңге!..

Нина, кадерлем, җанкисәгем, ишетәсеңме, мин сине сагындым, өзелеп сагындым бит.

Син кайда, Нина, Нина Воскресенская? Син кайда?

## Сандугач

### I

Берәр җирдә Алябьевның «Сандугач» көен җырлауларын ишетсәм, һәрвакыт туктап уйга чумам. Бик еракта калган, әрәм үткән гомер һәм якын бер дустым искә төшә. Бу тылсымлы көйне ишеткәндә ничек аны сагынмаска! Мин бит аны тар юл, тайгак кичүдә — лагерьда очраткан идем. Киң күңелле, юмарт, кулыннан гөл түгелеп тора торган гаҗәп кеше иде ул. Ә тавышы? Үзе көр, үзе моңлы. Ул җырлаганда Федор Иванович Шаляпин җырлый диярсең.

Соңыннан, төрмәдән котылгач эзләп карадым. Ул ике елдан соң азат ителергә тиеш иде. Әйтүенә караганда, Новгород шәһәренә, карт анасы янына кайтырга тиеш иде. Шәһәр милиция бүлегенә яздым. «Андый кеше бездә исәптә юк», дигән җавап килде.

Аннары Мәскәү радио студиясенә: «Фәлән кеше Алябьевның «Сандугач» көен бик яратып җырлый иде. Менә шул дустыма музыкаль сәлам рәвешендә «Сандугач» көен берәр күренекле җырчы башкаруында тапшырсагыз иде», дип хат язган идем. Бүген эштән кайткач, радиоалгычны куюга, исем китте. Үтенечемә җавап рәвешендә «Сандугач» җыры. Бүлмәдә аның яраткан көе-җыры яңгырый!

...1945 елның октябрь ахыры иде. Трасса төзү колонналарындагы тоткыннарны, ашыгыч рәвештә каядыр күчерә, алып китә башладылар. Чират безгә — инвалидлар колоннасына да җитте. Җыен аяксыз-кулсызларны вагоннарга төяп, башта Тайшет шәһәренә, станциядә өч көн тотканнан соң, аннары Маршинск озату төрмәсенә китереп тутырдылар. Шуннан Марлаг бүлекләренә бүлеп-бүлеп җибәрү башланды. Мин бүтән «илле сигез»ләр белән «Антибес»ка барып эләктем.

Антибес! Кызык! Шайтаннарга, җеннәргә каршы дигән сүз буладыр инде.

Юкка гына гаҗәпләнмәгәнмен икән бу сәер исемгә. Дөресендә дә, бу исем җисеменә бик тә муафыйк икән. Моңа без Антибеска килеп кергән беренче төндә үк ышандык.

Маршинскидан иртә чыксак та, лагерьга кичкә таба гына килеп җиттек.

Беренче күбек кар — тездән батып атлыйбыз. Өстәвенә, лагерьга якынлаша башлагач, җил кузгалды. Буран. Көчкә килеп җиттек. Чәнечкеле тимер чыбык белән ике кат уратылган зур лагерь. Манаралар. Вахта, агачтан салынган кечкенә алачык. Тимер морҗадан төтен күтәрелә. Димәк, анда җылы. Без вахта янына килеп туктауга, куыштан лагерь түрәләре килеп чыкты:

— Беренче саф, алга! Киемнәрегезне салыгыз!

Суык. Җил. Ә монда чишенергә кирәк. Зонага куркыныч әйбер алып кермәсеннәр янәсе. Чишенү, киенү, формулярларны тикшерү, санау — бер генә түгел, берничә тапкыр. Чөнки тапшыручы конвой башлыгы да, алучы лагерь башлыгы да бер-берсенә ышанмыйлар. Һәрберсе үзе бармагы белән тоткыннарның күкрәгенә төртә-төртә саный.

Ниһаять, зонага, баракка кердек. Монда инде жылынырбыз дигән идек, кайда ул, зәмһәрир суыгы. Баракта бер генә бөтен тәрәзә юк. Барысын ватып-жимереп бетергәннәр. Аптырагач, тәрәзәне юк-бар белән томалап, кар белән кумдек.

Бу эш безне бераз жылытты. Шул жылыны югалтмыйк дип, баракка кергәч, барыбыз да түбәнге сәкеләргә, бер-беребезгә тыгызланып яттык. Арылган, йоклап та киткәнбез.

Кемдер иягемә сукты, сискәнеп уяндым.

— Акчаң кайда?

— Нинди акча?

— Менә нинди акча,— борын төбендә генә пычак ялтырады.— тизрәк!

Аңгы-миңге килеп башымны күтәрүем булды, сугып ектылар.

— Бушлатын ал!

— Полундра!

Барак ут кабынгандай дерт итеп кузгалды.

— Уголовниклар!

Ул арада ишектән кулларына таяк, төрле тимер кисәкләре, ясалма пычаклар, кистәннәр тоткан тагын бер төркем акырып килеп керде.

— Полундра!

— Контрларны из!

Ыгы-зыгы. Шау-шу. Сүгенү. Шатыр-шотыр сәке такталары куба-рыла башлады.

— Син нишләп торасың?! — Кемдер арттан килеп төртеп алды,— әйдә, мичне жимер!

Ул шундук иелеп мичнең капкачын суырып алды да, якынлашып килгән пычаклы бер уголовникның башына сукты. Теге акырып егылды. Мин мичне сүтә башладым, тузан, көл, корым. Кирпечләрне биреп торам, арттан килгәннәр аны алып, ишек төбенә өелгән уголовникларга ыргыталар. Беренче һөҗүм кире кагылды — барак уртасына үтә алмадылар, кире чигенделәр. Әмма безнең көч тә кими бара, мич сүтелеп, кирпечләре атылып бетте. Сәке такталары да житәрлек түгел. Күпләр буш кул белән калды. Ә тегеләр яшьләр, тазалар. Өстәвенә, алдан ук сугышырга әзерләнеп, коралланып кергәннәр.

Икенче һөҗүм башланды. Без сәке такталарыннан баррикада ясап, бер почмакка өелдек. Уголовниклар тагын да ныграк котырды, күзләрен кан баскан.

— Контрларны сыт!

Тагын пычаклар, кистәннәр ялтырады. Без ташлаган кирпечләр кире үзебезнең башка төшә башлады. Берничә уголовник инде баррикада өстенә үрмәләп, пычакларын янарга тотынды. Без хәлдән таябыз. Күпләр яраланган... Нишләргә? Әгәр алар өстенлек алса, барыбызны да суеп чыгачаклар. Нишләргә, көч-хәл белән такталарны тотабыз.

— Иптәшләр! — калын көчле бас, барлык шау-шуны, акыруны басып, баракны дер селкетте,— курыкмагыз, алга!

Баррикада алдына калын каен такта күтәргән берәү тезләнеп йөреп, килеп чыкты да, тактасы белән, чалгыоткандай, печән чапкандагы кебек, арлы-бирле селти-суга башлады. Никадәр гайрәт! Никадәр көч! Тактага туры килгән уголовникның берсе дә басып кала алмый, мәтәлеп, тәгәрәп китә. Ә теге тезе белән йөргән ике аяксыз кеше, бер куркусыз алга бара. Моны күреп, без дә күтәрелдек. Тагын акыру-бакыру, сүгенү, пычак, кистән, такта уйный башлады. Жәһәннәм!

## II

Сугыш иртәнгә хәтле барды. Әле без уголовникларны кудык, әле алар безне кысрыкладылар. Әгәр бу сугыш тагын беразга сузылса, без

инде жиңеләчәк һәм бандитлар башбаштаклыгына дучар булачак идек. Бәхеткә, уяту чаңы тынар-тынмас, баракка бер отделение солдат белән конвой башлыгы килеп керде.

Солдатлар, прикладлар белән сугып егып, ике якны аерып, унлап тоткынның кулларына богау салып, типкәләп, өстерәп алып чыгып киттеләр.

Барак тынды.

Безнең яктан дүрт мәхбүс үлгән икән, аларны санитарлар носилкага салып моргка алып китте. Җиңел яралылар үзләре медпунктка өстерәлде. Авыр яралылар калды, кайсы җирдә, кайсы сәкедә. Алар белән маташырга вакыт та юк, мөмкинлек тә юк иде. Мин, аллага шөкер, җиңел котылдым, сул күз күгәргән, уң кулда пычак ярасы. Күлмәк җиңен ертып кысып бәйләгән идем, сызлавы басылгандай булды.

Уголовникларның югалтуы ни хәтле булгандыр, билгесез. Алар үлекләрен дә, яралыларын да чыгарып, үз баракларына алып китәргә өлгергәннәр. Менә шулай итеп, без Антибес лагере белән таныштык.

Өч-дүрт көн баракны төзәтү, сәкеләрне җәю, тәрәзәләрне кую, ишекләрне рәтләү, тазарту, юу белән үтте. Баракка бераз торак төсе керде. Әмма, мичне яңадан сала алмадык, ичмасам бер бөтен кирпеч калсачы. Колосниклар, ишекләр, япкычлар берсе бер калмаган, ватылып, кыйралып беткән.

Вахтадан ике тимер мичкә бирделәр. Аларны алып килеп, баракның ике башына урынлаштырдык та морҗалар куйдык. Мичкәләрнең бер як төпләрен тиштек.

Мич әзер!

Утын да җитәрлек, теге сугышта кыйралып, эштән чыккан сәке такталарын, ишек яңакларын арлы-бирле ярып, кисеп, мичкә тутырдык. Мич дөрләп янып китте. Беренче тапкыр баракка җылы төште.

— Яле, яшьти, миңа да урын калдыр,— дип калын бас гөрелдәде.

Карасам, берәү мүкәләп сәкегә менеп маташа. Бер аягы балтырдан киселгән, икенчесенә иске тун җиңе кидерелгән, өстерәлеп килә. Башы иске бер чүпрәк белән уралган, кан сирпеп тора. Күзләр күмкүк. Авыз ерылган...

— Әй, кызык та булды соң сабан туе, ә?

Бу кем? Абайлабрак карасам, теге баррикадада такта белән селтәнеп уголовникларны пыр туздырган батыр.

Почмаккарак кысылып, урын бирдем.

— Әйдә, менә монда сузыл, кысылып ятсак, җылырак булыр.

## III

Яңа күршем миңа әллә ни кысынкылык күрсәтми, комачауламый, киресенчә, файдасы тия.

— Мин Маслов Валентин Валентинович. Илле сигезенче статья, ...пункт, ун ел төрмә,— дип таныштырды ул үзен.

— Ул унлыкны кайда эләктердең? — дим.

Авызы тагын ерыла... Әллә нинди җилбәзәк сыман. Әллә инде шөрепләре тулы түгел...

— Котелоктан,— ди.

Мин гаҗәпләнәм.

— Ничек котелоктан? Ул чумар түгел бит.

— Нәкъ менә өстенә бастың... Чумар эченнән килеп чыкты.

— Тукта әле, Валентин, сөйләсәң рәтләп сөйлә, башны катырма! Чумар белән ун ел арасында байтак аерма бар.

— Алайса тыңла,— ул койрыгы белән шуышып минем янга елыш-

ты,— Волхов юнәлешендә, бер һөҗүмдә мине яхшы ук теттеләр, дүрт ярчык берьюлы килеп утырды. Өчесе аякка, берсе кулга. Кулныкы зарарсыз, санбатта ук алып ташладылар. Ә менә аяктагылар яхшы к алама булды. Сул аякны чәлтердән кисәргә туры килде. Ә уң аяктагысы әллә кая эчкә кереп киткән, табанда, бастырмый.

— Син бит госпитальдә булырга тиеш.

— Ә мине кайдан дисең,— госпитальдән.

— Ә нигә монда?

— Әйттем бит.— Ул тагын авызын киң ерып елмайды.

Бу үзе эре бәдәнле адәм, баш зур, колаклар салынып тора. Утыргач, аның янында мин — бөкән янындагы түмгәк төсле генә. Әмма шундый баһадир гәүдәле булуына карамастан, сабый балалардай беркатлы, ачык. Ак күңелле, ачуланмый. Ә инде бер кузгалса, теге көндәге сыман, аны инде бер кеше тыя алмый.

— Озын сүзнең кыскасы, госпитальдә бик начар ашата башладылар. Иң ачу килгәне — санитарларның комсызлыгы... Дежурныйлар күрә бит... Безгә дигән ит-майны кухняда үзләре бүлеп ашыйлар. Ә безгә чумар урынына, коры су, баланда. Бер көнне иртәнге обходта госпиталь башлыгына әйтеп салмыйммы: «Лев Абрамович, безне әттән яман ашаталар. Санитарларыгыз урлый». Иптәш кара көеп китте, бер сүз әйтмәде. Икенче көнне мине трибунал хөкем итте, контрреволюцион үгет өчен ун ел төрмә. Ярар! — Ул койрыгы белән шуышып, сәкедән төшә дә башлады. Озын, табагач кулларына, култык таякларына таянган сыман таянып, бер күтәрелеп, бер төшеп, бaрактан чыгып та китте.

Һәркөн шулай, иртәнге тикшерүдән соң, кайвакытта баланданы да көтмичә шуып төшеп китә дә югала, суга баткандай. Аннан бары кичке тикшерү вакытында гына кайта.

Кая олага ул, ходай үзе белә.

Әллә урлашып йөри инде?

## IV

— Яле, күрше, колагың шешкән идеме, мә тот,— ул әле сәкегә менмәс борын ук бияләй хәтле зур күн янчыгын ыргытты,— рәхәтлән, кәгазе дә бар.

Янчыкның җебен тартып, авызын ачуга, төчкереп җибәрдем.

— Әп-течи...

— Менә-менә, андый-мондый гына махорка түгел, маржа чылатып үстергән, әче җимеш.— Мин «кәҗә сыйрагы» төреп өлгермәдем, янчык кулдан-кулга сәке, барак буенча китте. Валентин ике табагач кулларына таянды да сикереп сәкегә утырды.

— Ничек, тәмлеме маржа җиләге?

— Тфү...— Мин чәчәлим, күзләрдән яшь ага. Янчык кире кайтты. Буп-буш, күзгә кырып салырлык бөртеге дә калмаган тәмәкенең...

Тәмәке белән генә түгел, ара-тирә икмәк паеклары алып кайтып та сыйлый Валентин. Ә бүген сәкегә утыруга, куеныннан бер пар менә дигән өр-яңа хром итекләр чыгарды.

— Ничек, ошыймы?

Шаккаттым, телем бәйләнде.

Һичшиксез, карак. Лагерьда мондый итекне кайдан алмак кирәк. Тентү килеп, мине дә алып китмәсәләр ярый, «кәҗә сыйракларын», паекларны борыныңнан чыгарырлар.

Ул итекләрен киредән куенына салды да, бөгәрләнеп ятып, гырлап та китте. Ә мин әле бер, әле икенче якка әйләнәм, һич йокы керми күзгә. Хәтәр кеше булып чыкты бит әле бу күрше, юкка үзенә урын бирдем.

## V

— Менә шулай, безнең ыру гомер-гомергә Гатчинада тора. «Алтын аяклар» дип йөртәләр безнең нәсел кешеләрен.

— Ха-ха! Менәябыштырдың, Валя, уйлап та тормыйсың... Синең аякларны да алтынга манганнармы?

— Тукта, нәрсә авызыңны ерасың! Мин дөресеннән барам. Россиянең барлык патшалары безнең башмакларны киеп йөргән.

— Ха-ха! Алтын башмак аркасында Антибеска килдең, ә?

— Җитәр, бүлдермәгез! Сөйләсен, эчеңне тишәме. Валя, әйт әле, мондый курчак шикелле итекләрне тегәргә материалны, хромны кайдан аласың?

— Җүләр, лагерьда әйбер беткәнме? Иске тун, иске бүрек, ташланган куныч. Менә шуларны җыям, тазартам, кыркам, буйыйм.

— Тукта, тукта, каты киттең. Буяу кайдан? Шурум-бурум түгел, әнә нинди лак. Ялтырап тора.

Безнең сәкегә җыелган халык, Валентин теккән шыгырдап торган хром итекләрне кызыксынып, сокланып карый. Кунычларын әйләндерәләр, олтаннарына, үкчәләренә чиртеп-чиртеп карыйлар.

— Фабричный...

— Тукта әле, әйтсен, лак кайдан, ә?

— Кайдан булсын, морҗадан. Анда сине лакларга да җитәрлек корым бар.

— Әйе, бу булыр-булмас башмакчының эше түгел. Патша киярлек башмак тегү дим.

— Ә-ә, Антибеска ничек эләккәнеңне яңа төшендем. Романовлар династиясе белән бәйләнештә булган өчен!

— Юләр, итекче белән патша арасында нинди бәйләнеш?

— Даң-доң! Даң-доң!

— Барлау!

## VI

Валентин лагерьның итек тегү цехында эшли. Антибестагы барлык түрәләр, бигрәк тә аларның хатыннары, кызлары аны сырып алып, чиратлы-чиратсыз итек, боты, туфля тектерә башладылар. Хәтта Маршинск түрәләре дә Валентинны белеп алганнар.

— Заказ ун елга җитәрлек! — ди ул, кичен кайтып сәкегә күтәрелгәч. Әле һаман шаяра. Әмма элекке кебек озак-озак әңгәмәләр корып, патша итекләре турында хикәяләр сөйләми.— Мә, күрше, йөрәк ялга,— дип, миңа үзенең паегын, анда-санда колбаса кисәген төртә дә, бушлатын ябынып гырлый башлый. Арый, бик арый башмакчы.

Ничек кенә булмасын, ул миңа зур терәк. Югыйсә, эшләрем көннән-көн хөртиләнә башлаган иде. Валентин аркасында гына бераз хәл алдым.

Бу арада лагерь түрәләре безгә дә эш тапты — ике цех ачты. Берсе эрләү, икенчесе туку-бәйләү цехы. Беренче цехта сыңар аяклылар. Алар шул аяклары белән орчык әйләндерә, мамыктан җеп эрли. Икенче цехта, бөтенләй аяксызлар, койрыкларына утырып, ыргак белән мамык җептән оек, бияләй бәйлиләр.

Мин беренче цехка эләктем. Башта орчыкны әйләндерү тансыккызык булса да, иртәдән кичкә кадәр ялгыз аяк белән бөрөзлексез эшләү ярыйсы ук арыта башлады. Өстәвенә, эрләвемнең юне юк, я юан, төерле була, я нечкә — өзелеп теңкәгә тия. Кичен эшне тапшырганда йомгагымны бракка чыгардылар. Нәтиҗәдә паегым өч йөз граммга төште, төшке ашта баландадан соң бирелә торган ярты чүмеч чумардан да колак кактым.

— Иртәгә дә брак бирсәң — карцер! — диде цех башлыгы, минем йомгакны сул яктагы кәрзингә ташлап. Сүзендә торды, икенче кичне мин үз сәкемә кайта алмадым, карцерда йокладым. Валентин цех башлыгына итек тегеп биреп, мине бәладән коткармаса, белмим, карцерда ничә көн булыр идем. Алай гына түгел, фырт эшкә күчерде.

— Син цехта мич ягып утырырсың,— диде цех башлыгы, мине эрләүдән алып. Көнозын жылыда, житмәсә, ашханәдән бәрәңге урлап китерәләр. Пешереп бирәм, «өресе» үземә дә кала.

## VII

Бервакыт төнозын кар яуды. Иртә белән жил чыкты, күз ачкысыз буран күтәрелде. Ул көнне безне эшкә чыгармадылар, ишеккә йозак салдылар. Зонага тимер чыбык сузып, берничә эт жибәрделәр.

Һич көтмәгәндә — бәйрәм. Бөтен барак дерт итеп кузгалды, төрле ярыкларга, тишекләргә, идән асларына яшерелгән карталар, шашкалар, шахматлар, ашыклар калкып чыкты. Ыгы-зыгы. Шау-шу! Уен. Сәке өстендә, сәке астында, идәндә өер-өер булып утырган, яткан, аягүрә баскан, азарт белән шашкан төркемнәр.

— Буби валет!

— Банкада унбиш паек.

— Яп туз белән!

— Тукта, чү, хәрәмләшмә!

— Менә сиңа мат!

Төтен, пар. Сүгенү. Кычкырышу, сугышу. Тагын валетлар, корольләр шапылдый. Барак артында жил, давыл. Тәрәзәләрне кар баскан. Упкын-упкын жил сукканда, стеналар дерт-дерт итеп китә. Ә баракта бәйрәм. Кем ничек булдыра ала — шулай күңел ача, көлә, кычкыра, сикерә. Гажәп, һәрвакыт шат күңелле, кайгыра белми торган күршем Валентин гына күңелсез, бот башларын бушлат белән төргән дә түшәмгә текәлгән. Әүвәле куркып киттем, әллә инде жан тәслим кылган. Үрелеп карыйм — авыр-авыр итеп сулый. Озын сары керфекләре йомылып-йомылып куя.

— Валентин, әллә авырыйсыңмы?

Жавап юк. Жавап бирми.

— Валентин...

— Эч поша, күрше... Эч поша,— сулъяк бите тартылып, сикереп-сикереп китә.— Контузиядән... Борчылсам, һәрвакыт бит алмаларым сикерә башлый. Үземнең сөйләшәсе дә килә. Әмма, тагын сүз катарга базмыйм, нигә комачауларга, ичмасам, бер көн тынычланып сагынсын...

Ә сагынырлыгы, пошынырлыгы бар аның.

1941 елның беренче маенда өйләнә ул, туе була. Ә егерме икенче июньдә сугыш башлана. Валентин фронтта. Разведчик. Кыю һәм батыр хәрәкәт итеп, «кирәкле тел»не алып килгән өчен, аны «Кызыл байрак» ордены белән бүләклиләр. Аннан соң һөжүм, контузия, ике аяктан аерылу. Госпиталь. Инде өйгә кайтам дигәндә (дөресен әйткәндә, өй юк. Гатчина немецлар кулында. Кая да булса тылга китү мөмкинлеге генә бар...) кинәт хәрби трибунал. Ун ел төрмә. Антибес.

Менә бит кеше язмышы нинди чокыр-чакырлы. Сагына ул. Сары сагыш.

— Со-ло-вей...

Кинәт барак калтырып, яңгырап китте. Мин торып утырдым. Бу ни? Бу нинди көчле, моңлы, яңгырау тавыш? Барактагы барлык шау-шу, сүгенү, кычкыру тынды.

Жыр үсте, көчәйде, сандугач булып өзгәләнде. Тышта буран, өермә, жыл сызгыра, ыңгыраша. Жил саташып баракка ташлана, аны дер селкетә. Ә монда, барак эчендә, моңа кадәр һич күренмәгән тын-

лык, изге тынлык. Карталар, паеклар, сүгенүләр, якага-яка килешүләр — барысы да онытылган. Бөтен барак сихерләнгән, тылсымлы җырны тыңлый. Монда — җәй. Монда иртәнге кояшлы, җофар исле урман. Монда өзелеп-өзелеп, очынып-очынып сандугач сайрый.

Соловей, мой соловей,
Голосистый соловей!
Ты куда, куда летишь,
Где всю ночку пропоешь?

Валентин урынынннан торып тезләнгән, башын артка ташлаган. Ярты гәүдәсе белән дә ул башкалардан биек булып, мәһабәт булып күренә. Ул бар күкрәгенә, бар мәһабәт тавышына ирек биреп, йөрәген бушата.

Йөрәк! Кеше йөрәге, син нинди бөек һәм илаһи. Ул минә хәзер җыр булып, өмет булып, ерактагы якты азат көн булып ташый:

Соловей мой, соловей,
Голосистый соловей!..

Валентин Маслов безнең баракның гына түгел, барлык колонна-ның — Антибесның юанычы, сөенече булды. Кичләрен эшкә чыкмаган яңгырлы, буранлы көннәрдә аның җырлавын үтенәләр. Ул кыстатмый, дөресрәге, үзе теләп җырлый, моңая. «Вниз по Волге матушке-реке», «Вдоль по Питерской»...

Нинди ген җыр җырламасын, ахырында ул, нигәдер, Алябьевның «Сандугач»ын кабатлый... Гаҗәп бер көй, моңлы тавыш белән сандугач булып өзгәләнә ул.

— Бу көйне Дусям ярата иде... Гел шушы җырны җырла әле дип үтенә иде,— диде Валентин миңа бервакыт, ачылып китеп.

Теге беренче төн сугышыннан соң, каршыдагы баракта торучы уголовниклар белән пычакка-пычак яши идек. Хәтта безне баланда алырга, паек алырга ашханәгә үткәрмиләр, талыйлар, кыйныйлар иде. Бары тик конвой белән генә йөрибез. Бигрәк тә алар Валентинга үчле, аны үтерергә җыеналар иде. Гаҗәп.

«Сандугач»ны ишеткәч, алар бөтенләй үзгәрде.

— Валюша, безнең баракка да килеп бер җырла әле,— дип, үтенә, чакыра башладылар.

Ике барак арасында дуслык урнашты. Ул гынамы?

Валентин җырлый башласа, аны тыңларга вахтадагы түрәләр килә. Манарада сакта торган солдатлар, автоматларын куеп, таң калып тыңлыйлар иде. Ул җырлаганда бөтен лагерь дерелди. Көчле, көр, музыкаль иде аның тавышы.

Ә куллары?

Куллары, чыннан да, алтын булып чыкты. Валентин теккән итекләр, туфлялар, иң соңгы фасон, модага әверелеп, лагерь түрәләре хатыннары арасында көнчелек-ызгыш тудырды. Һәрберсе Маслов теккән туфляны гына киярга тели. Ул хәзер күпме тырышмасын, тегеп өлгертә алмый. Ә түрәләр көтәргә яратмый. Ахырында шушы чибәр осталык — алтын куллар аның башына җитте.

Бу вакыйга менә ничек була. Бер көнне конвой командирының хатыны, Валентинга итек тегәргә заказ бирә һәм тиз тегеп бетерергә куша — кунакка барырга кирәк. Ә икенче көнне колонна башлыгы Валентинны кабинетына чакыра да:

— Берсекөнгә кызыма туфля тегеп өлгерт. Туй,— ди.

— Гражданин начальник, миндә әле конвой командирының ашыгыч заказы бар бит,— ди Валентин аптырап.

— Әмерне үтә! — дип, түрә аны куып чыгара.

Валентин, бу ике көнне, йокларга да кайтмады,囧эштә булды.

— Уф алла! — дип, икенче көнне кичкә кайтып егылды,— бер убыр-

дан котылдым. Туфля кызга ошады. Менә бүләк итеп, бер пачка «Казбек» та бирде. Без папиросны тартып та өлгермәдек, вахтер йөгереп килде, мышнаган.

— Командир чакыра.

— Капут! — диде күршем, миңа карап, рәнжүле елмаеп.

— Ярар, теләнә салынма, тиз!

Валентин зур бияләй кулы белән минем кулны кысты да, койрыгы белән шуып, сәкедән төшеп китте.

Әйтерсең лә, суга батты. Шул китүдән без Валентинны күрмәдек. Вахтерларның әйтүенә караганда, конвой командиры Валентин Масловны, лагерь режимын бозуда гаепләп (мастерскойда кунган өчен) әүвәле карцерга япкан, аннан штраф зонасына җибәргән.

...Бүлмәмдә Алябьевның «Сандугач» җыры яңгырый. Нинди дер җырчы, фамилиясен ишетә алмый калдым, көчле бас белән җырлый, тавыш бер үсә, күтәрелә — очына, бер кинәт төшеп китә.

Йөрәк өзгәләнә.

Дустым Валентин да ишетәме икән хәзер бу җырны — бу бит минем аңа сәламем, сагыну тавышым.

## Юлның соңы

### I

...Ниһаять, ирек!

Вахта ишегеннән чыгып, әле яңа гына явып үткән күбек кар өстеннән агач аяк белән бата-чума бер-ике адым атладым да, туктап калдым. Өнемме, төшемме? Мин хәзер, чыннан да, иректәме? Хәвефләнеп, шикләнеп кенә артыма әйләнеп карадым. Бу ни хәл? Күләгә булып артымнан калмый «тиз-тиз!» дип әтәрмәләп, сүгеп йөргән автоматлы сакчылар да, «һау-һау» килеп өскә ыргылып торган овчарка этләр дә күренми. Сәер! Чыннан да, алар инде юкмы? Әллә теге тар ишекле рәшәткә тәрәзәле вахтада яшеренеп, бу нишләр икән, дип сагалап кына торалармы, юкса? Ун ел буе канга, тәнгә, сөяккә сеңеп калган бу явыз иярченнәр-тагылмаларның кинәт юк булуына күңел дә, күз дә ышанып бетә алмый. Аптырап, сагаеп, куркып-дерелдәп тирә-якка карыйм. Ат башы хәтле йозак белән бикләнгән тимер капка. Ике кат чәнечкеле тимерчыбык белән уратылып алынган зона.

Тырпайган чәнечкеле тимерчыбыклар артындагы тәбәнәк баракларга карыйм — күзләремне ала алмыйм... «Әх! Син бәхетле... Ә без? Без ул көнне, азатлыкны күрә алырбызмы, әллә монда «такта бушлат» киярбезме... Ирекка сәлам!» — дип анда калган дусларның көрсенеп, еламсырап әйткән сүзләре, тавышлары колагымда чыңлый.

— Нәрсә катып калдың, аксак! Әллә лагерьдан китәсең килмиме, контр!

Вышкадагы сакчының кычкыруына сискәнеп-каушап, ашыгып кузгалган идем, агач аяк таеп китте, мәтәлеп барып юл читендәге кертка егылдым.

— Ха-ха! Ха-ха! Әй, ни таптың, аксак! Яртысын миңа да бир... Ха-ха! — Тик торудан ирекән яшь кенә егет эче катып көлә. — Әй, контр кисәге, ирек тәмлеме? Нәрсә, аллаңа сәҗдә кыласыңмы? Ха-ха!

Көч-хәл агач аякны шудырып барып, кертка терәп күтәрелдем. Тәнем — шабыр тир. Җилкәдәге капчык әйләнеп килеп күкрәккә төшкән, муенны кысып буып тора. «Биштәрне» аркага этеп ташлап, юлга чыктым.

Нинди матур тирә-як! Ап-ак! Җем-җем итә, гүя, энҗе сипкәннәр. Хуш ис, беренче кар исе! Беренче яңгыр — ләйсән яңгыры! Шифалы яңгыр. Бала чакта «үсәбез, үсәбез!» дип шул яңгырда коена идек ич. Ә беренче карны ничек атыйлар соң? Минемчә, ул да ләйсән — пакь, йомшак, җирне ничек итеп агарткан — ак җәймә җәеп чыккан. Мөгаен, минем бүген ирекккә — азатлыкка чыгуымны хөрмәтләп, табигать дөньяны алмаз кыйпылчыклар сибеп бизәгәндер. Яңа күтәрелеп килгән кояш нурларында алар күзләремне чагылдыра, салават күпере төсләре белән балкыйлар.

Хуш ис! Беренче кар исе нинди рәхәт, сулап туя алмыйм! Үзем ашыгам — Мариинск вокзалына җитеп, Күкчәтауга билет алырга кирәк! Әле һаман болай конвойсыз баруыма, тимер юл поездына үзбаш билет алырга ашыгуыма ышанып җитә алмыйм. Бу ашкынулар барысы да төш кенәдер, дип куркам, үземне-үзем чеметеп карыйм. Үч иткәндәй, ашыккан саен агач аяк таеп-таеп китә яки юл читендәге көртләргә төртелә. Аякны күтәреп алып, урап атларга туры килә. Әле һаман агач аякка күнегә алмыйм. Их, бу бүкән башы урынына үз аягым булса, ничек йөгереп китәр идем мин...

Моннан ун ел элек — 1937 елның егерме бишенче октябре иртәсендә нәкъ менә бүгенге кебек ашыгып атлый идем түгелме? Юк! Юк, кызганыч ки, бүгенгедәй түгел шул.

...Казан. Көз. Томанлы иртә. Урам буендагы агачларның яфраклары әле яңа гына саргая башлаган. Алтын көз. Мин, егерме алты яшьлек таза, типсәм тимер өзәрлек егет,— Казан педагогия институтының дүртенче курсы студенты. Әмма читтән караганда, мин әле хәрби. Өстә хаки төсендәге постау гимнастерка, күгелҗем галифе. Башта өр-яңа фуражка — йолдызы гына алынган. Аякларда — куныч-лары ялт-йолт итеп торган хром итекләр. Һәрхәлдә, өч еллык хезмәттә полк мәктәбен бетереп, кече командир дәрәҗәсенә күтәрелгән егет идем ич мин! Институтка килгәч тә мин бу хәрби киемнәрнең кайберсен гади пиджак, чалбарга алыштырмадым. Ошый иде миңа хәрби кием, килешә дә иде. Курсташ кызлар да: «Ибраһим, хәрби кием бик килешә сиңа»,— диләр иде...

Биек, киң ишектән кереп, инде менә бу иләмсез тәбәнәк вахтаның тар капкасыннан кысылып чыкканчы бары тик ун ел гомер узган. Ун ел! Егерме алты белән утыз алты арасындагы алтын еллар!

Яшьлегемнең иң гүзәл, иң шаулы, иң мөкатдәс көннәре! Алар шушы ике ишек арасында калды... Нигә?

Юлдан атылып килгән бер «Москвич» чак кына үземне таптап китмәде, көч-хәл көрткә авып калдым.

— Ачыгавыз! Йолкыш! Юньсез аксак! Нәрсә комачаулап йөрисең! Читтән барырга ярамыймы әллә? Синең аркада яхшы кешеләр бәлагә юлыгыр! — Машина эчендәге адәм, тәрәзәсеннән башын сузып, әнә шулай тиргәп-сүгеп китте.

Ә мин көрткә бата-чума көчкә күтәрелдем.

Тукта, нигә рәнҗедем соң әле мин — дөресен әйтте ич. Сул аяк урынына чыпта белән бәйләнгән бүкән башы. Өстә ертылып-таланып беткән торкын бушлаты, һәм шул ук сорттагы ертык балаклы чалбар. Ялгыз аякта ямалыр урыны калмаган «ЧТЗ». Башта — бер колагы йолкынган бүрек кисәге. Ирекккә чыгасымны ишеткәч, барактагы иптәшләрнең берсе посылка белән алган чалбарын, икенчесе өстендәге яңа бушлатын салып биргән иде. «Безгә ярар, ә син инде ирекккә! Артык мескен күренмә»,— дип сөендергәннәр иде. Бүген вахтадан узганда сакчы: «Лагерьдан яңа кием белән чыгарырга рөхсәт юк! Яле, хәзер үк сал»,— дип шундук чишендерде дә, яңаларны үзенә алып, почмакта яткан ертык-портыкны миңа ташлады. «Мә, йолкыш, мыштырдамый тизрәк эл дә сыздыр. Юкса хәзер, лагерь милкен урлаган өчен, икенче срок бирдерермен».

Мондый алардан булыр да, каушавымнан киенер-киенмәс, вахтадан атылып чыктым.

Ә шулай да нигә соң мин аксак? Нигә мин йолкыш? Ун ел элек мин аксак та, йолкыш та түгел идем ич. Нигә?

— Әй, бабай, Мариинскигамы? — Бер йөк машинасы шып итеп минем янга туктады. — Әйдә, утыр. Ирекка ашыгасыңмы, батя?

Кабина ачылды. Мин агач аякны этә-төртә көчкә күтәрелдем.

## II

Тык-тык.

Тык-тык.

Вагон бер туктаусыз тыкылдый, чайкала, буферлар сугылып зыңлап китә. Поезд Себер урманнары, Себер сопкалары аша көнбатышка ашыга.

Инде, мөгаен, төн уртасы. Вагон уртасындагы «буржуйка» каршында карта «суккан» бер төркем фыртлар да, югары сәкегә менеп, калачланып уралганнар. «Буржуйка» инде сүнгән. Мариинскига, минем кебек лагерьдан азат ителгән байтак тоткын җыелган икән, күбесе уголовниклар. Барыбызны бергә җыеп, җимерелеп беткән бер товар вагонына тутырдылар да аллага тапшырдылар.

Лагерьда вакытта: «Ни булыр, азат итәрләрме, юкмы?» дип тәшвишләнеп өч-дүрт төн йоклый алмаган идем. «Инде вагонга эләксәм, аю йокысы белән йокларммын», дип уйлаган идем. Менә хәзер мин вагон эчендә, күзләргә йокы гына кунмый. Күңел ашыга, ул инде әллә кайчан Күкчәтауда...

Кем каршы алыр икән? Билгеле инде, әти, үги булса да әни, сеңелем Разия. Әй куаныршар. Ул арада тирә-күрше, дус-иш килеп житәр. Иптәшләр күп иде дә күбен, сугыштан кемнәр генә исән-сау кайта алды икән? Бардыр, бардыр әле бергә ат-ат уйнап үскән малайлар. Их, сагындым үзләрен!

Тик менә өс-баш бик хөрти. Җитмәсә, бет сырып алган. Әле монда, вагонда, суыкта да я бер, я икенче җирне тешләп, кычыттырып теңкәгә тияләр, каһәр төшкерләре. Әй, онытa да язганмын, әти: «Хәзер без Сафаларда торабыз. Аңа өй салып бирергә сөйләштем. Кайтсаң, туптуры шуларга төш», — диган иде бит бер хатында. Ә Сафа җизнәләрдә борын-борыннан мунча бар. Әни, һичшиксез, мин кайтуга, мунча ягып җибәрер. Күлмәк-ыштанны шартлаганчы бер кыздырырмын инде, барып җитсәм.

Их, рәхәтләнеп бер чабынырга! Юк, бер чабыну белән генә ун ел каешланган арка бирешмәс. Аны өч-дүрт тапкыр каезларга туры килер, һичшиксез.

Әти өс-башка берәр кием алып куйса ярар иде, хатымда язган идем язуын. Хәзер сугыштан соң кием-салымы да юктыр, солдат искемоскысы булмаса. Булса, анысы да ярап торыр иде. Нәләт, теге вахтадагы сакчы өр-яңа бушлат белән чалбарны тартып алып калды бит... Аны инде бер «ярты»га әллә кайчан шуыткандыр.

Әгәр аз-маз рәтле кием табылса, шунда ук эш эзләргә китәм, алтмышка җиткән атаның җилкәсен кимереп ятып булмас. Нинди эш булыр икән? Билгеле инде, мәктәпкә укытучы итеп алмаслар алуын. Илле сигезенче статьядан соң биш ел мәхрүмлек тә бар ич әле. Бәлкем, редакциягә урынлашырмын, хәбәрче кебек йөремсәк эш уңайсыз булыр булуын. Тик нишләтәсең, кайда да йөрергә кирәк. Әй, ярар, нәрсәгә монда, бүрәнә аша бүре куып ятам. Кайткач күз күрер. Туган җиргә кайтам бит. Туганнар да, дус-ишләр дә җитәрлек ич анда.

— Ту-у-уу!

Паровоз бөтен тирә-якны шыңлатып кычкырды. Мөгаен, берәр станциягә якынлашабыз булыр. Ашыйсы да килә... өч көнгә бирелгән коры

паекны вокзалда ук ашап бетердем бит. Яхшы эшләгәнмен. Булмаса, мондагы уголовниклар хәзер талап алырлар иде. Әнә теге аскы сәкедә яткан картның сумкасын күз алдында «шуыттылар». Мескен акырыпакырып елады: «Соңгы паегым иде. Тагын дүрт көн кайтырга кирәк», — ди.

— Ту-уу...

Паровоз тагын кычкыртып, ухылдап, станциягә туктамыйча гына алга омтылды. Әйдә, әйдә, корыч атым, ашык, тизрәк йөгер! Алда минем туган Күкчәтавым...

## III

Йөрәк дөп-дөп итә. Бу ни — каушаумы, әллә куанумы?

Ай болытлар арасыннан йөзеп килеп чыкты: тирә-як яктырып китте. Менә каршымда инде җиргә сеңеп барган, кыйшайган кәс түбәле өй — Сафа җизниләрнең йорты. Безнең өй әнә теге каршыдагы мәчетнең аръягында, почмакта иде. Утызынчы елларда, калада тормыш авырайгач, әти, ул өйне сатып, алтын приискаларына киткән булган. Хәзер тагын Күкчәтауга күчеп кайткан да, әнә, вакытлыча, үзенә яңаны салып алганчы, Сафа җизниләрдә тора икән.

Бу ике бүлмәле иске өй миңа кечкенәдән таныш. Мин бит ялгыз гына бала идем, уйнарга абыем да, энем дә булмады. Ә монда, җизниләрдә (әтинең бертуганы Әшрәф апаларда) бер көтү бала-чага. Җизни Күкчәтау-Акмулла-Кызылъяр арасында йөк ташый, ә апа — йомшак табигатьле, безне орышмый. Тирә-күрше балалары белән бергә өйне ду китереп уйныйбыз. Төннәрен апаның өлкән улы Хәсән, без сыер астын, ат абзарын тазарткан, көрәгән өчен, «Алтынчәч»не сөйли. Һәр төнне шул бер үк әкият, әмма кызык!..

— Сөйлә, сөйлә инде, Хәсән абый.

— Иртәгә өлкән кураны тазартып, тиресне түгәсезме?

— Түгәбез.

Мондый кызык әкиятне тынлар өчен тирес түгү түгел, утын ярырсың.

Ләкин бу йорт миңа кызыклы әкиятләр белән генә түгел, ә фаҗигале бер хәл белән дә истә. Бу йортның бусагасы төбендә минем кадерле әнием Маһиҗамал фаҗигале рәвештә вафат булды бит.

Безнең әти белән әни Татарстанның Балтач ягыннан, әүвәле бабай, аның артыннан әти Себергә эш эзләп килгәннәр дә Күкчәтауда төпләнеп калганнар. Әти солдатка каралырга кайткан вакытында өйләнеп, әнине дә Күкчәтауга алып килә. Башта алар үзләренә оя табу нияте белән көне-төне эшлиләр, авылга кунакка кайту турында уйларга вакыт та булмый. Инде өйне салып бетереп, «уф алла» дип тынычланганда гына, Герман сугышы башлана. Әти фронтка китә. Аннан революция. Аннан Колчак, атаман Анненков баскыннары, кулаклар фетнәсе һәм, ниһаять, дәһшәтле ачлык. 21 нче елда ваба авыруы белән бергә Идел буе халыкларын кырып салган коточкыч ачлык.

Менә шулай итеп, әнием килен булып төшкәннән бирле ун елга якын туган бусагасына атлап керә алмый, ата-ана, туганнарын күрә алмый.

Ниһаять, 1922 елда дөнья бераз тынычлангандай була, игеннәр уңа. Безнең күршедәге Бану әби (ул Түнтәрдән икән) авылына кунакка кайтырга җыена. Моны ишетеп, әнием дә җилкенә — «Сиңа әйтәм, әти-әнине бик сагындым. Бану әбигә ияреп барып кайтыймчы. Улымны да алып барыйм», ди. «Сала башлаган өем бар, эшне ташлап китә алмыйм, алайса, Ибрай белән үзең генә барып кил. Өйнең акчасын алданрак сорарлар, юллык сәмән генә бирермен», — дип, әти бу сәфәргә каршылык күрсәтми. Әни юлга әзерләнә башлый. Күчтәнәчләр ала, аш-су пешерергә тотына. Ә мин инде урамда, дусларым Галәү,

Фәйзи, Гомәрханнарга мактанам:

— Беләсезме, мин Казанга китәм бит.

— Шартлатасың, андый еракка сине кем алып барсын?

— Валлаһи,— дим.

— Борчак сибәсең,— диләр.

— Барам дигәч барам, әни белән барам.

Бу хәбәргә безнең урамдагы барлык балалар шаккатты.

Чыннан да, ышанырлык хәбәрмени, балтачы Низаминың улы Казанга барсын, имеш.

Ә әни инде авылдашларга күчтәнәчкә дип: чәк-чәк, кош теле, тукач, бавырсак, тагын әллә ниләр, әллә ниләр пешерә. Үзе: «Аш-суым бик уңа, юлыбыз, иншалла, уң булыр!» — дип сөенә, очып-кунып йөри. Арууталуны белми, көтү куганнан алып караңгы төнгә хәтле йөгерә, һаман юлга әзерләнә. Бану әби кереп:

— Ходай боерса, җомга көн Кызыл Ярга кузгалырбыз, килен, иншалла,— дип юлга кузгалу көнен дә билгеләп чыкты.

Нәкъ шул көнне эти эштән, гадәттәгегә караганда, күп соңга калып кайтты. Әни аны капка төбендә үк каршылап:

— Сиңа әйтәм, нигә болай озакладың? Самавырымны өч тапкыр яңарттым,— диде.

— Яман хәбәр ишетелеп тора әле,— диде эти салкын гына, капка төбендәге бүрәнә өстенә утыра калып, балтасын бүкәнгә чапты.— Ревкомга барган идем.

— И... раббым,— әнием коелып төште,— әллә тагын сугышмы?

— Казаклар тагын фетнә күтәргәннәр. Күкчәтаудан пропускысыз берәүне дә чыгармыйлар,— ди.

Ул төнне әни йокламады, намазлыгын җәйде дә бик озак намаз укыды, елады, пышылдап ниндидер догалар укыды.

Ул вакытта әле Күкчәтауга тимер юл килеп җитмәгән иде. Казанга барыр өчен әүвәле йөз сиксән чакрымдагы Кызыл Яр каласына барырга, шунда поездга утырырга кирәк иде. Ә менә хәзер анда барыр өчен, ВЧКдан пропуск кирәк. Аны ничек алырга? Менә бит, инде кузгалам дигәндә генә...

Бер төндә әнием танымаслык булып суырылды, ап-ак булып калды. Күзләре эчкә баткан, иреннәре күгәргән.

Мин дә аптырадым. Әгәр алай-болай Казанга бара алмый калсак, малайлар күзне ачырмаслар, «буш куык», дип кенә йөртерләр.

Эти иртәнге чәйдән соң, гадәттәгечә, алъяпкычын киеп, пычкыбалтасын алмады.

— Булмаса, Сафага барыйм әле. Ул түрәләр белән таныш. Может пропуск алып бирер.

— Эти, мин дә барам.

Өчебез дә Сафа җизниләргә киттек.

Әни нигәдер бик акрын, туктап-туктап кына барды. Җизниләргә килеп җиткәч тә: «Тыным кыса. Менә шушында гына утырыйм әле»,— дип ул баскыч төбенә утырып калды. Эти белән мин эчкә өйгә кердек. Пропуск турында әйткәч үк, җизни торып җиләнен киде: «Әйдә, түрә анда-монда киткәнче, барыйк. Фетнә булгач, алар өйдә утырмаслар»,— дип кабаланып чыгып та китте. Олы кызы Рабига: «Мин дә барам»,— дип, этисенә ияреп. Мин урамда бер малайны очратып, кичен далага ат багарга бару турында сөйләшә, киңәшә калдым.

Мин инде этиләр турында онытып да идем. Рабига йөгереп килә, бөтен урамны яңгыратып кычкыра:

— Сөенче! Сө-ен-че!

— Нинди сөенче?

Ул арада Рабига баскыч төбендә утырган әни янына килеп тә житте, баягыдан да катырак кычкырып, тезеп китте:

— Апа, апа, сөенче! Начальник: «Пропуск бирәм»,— диде!

— Ә... ә.— Әни сискәнеп күтәрелеп карады, пышылдап кына тагын: — Ә... ә,— диде дә, ике кулы белән күкрәген кысып, авып китте...

Икенче көнне, җомгадан соң, безнең урамнан күл якка ике олау кузгалды, алда әни, аның артында — Бану апа. Ул — Казанга, әни — зиратка. Зират күл буенда, Кызыл Ярга бара торган олы юл каршында иде.

Әле менә хәзер дә әнием бу өйнең баскычы төбендә хәл җыеп утыра кебек...

Чымырдап өшеп киттем, вокзалдан җәяү килеп тирләгән идем, инде кузгалмый басып торгач, тир каткан. Күкчәтауда әле кар төшмәгән икән, шулай да суык, күзге кара суык.

Болыт арасына кереп качкан ай тагын күренде, тузган, кыйшайган, иске өй кинәт яктырып: «Нихәл, исән-сау кайттыңмы? Сине күрмәгәнгә байтак булды бит...»— дип, минем белән исәнләшкәндәй булды.

Кайттым, кайттым, ага-йорт! Үзем дә сизмичә, калын, карт бүрәнәләрне капшый-сыйпый башладым, сагынып кайттым сезне, сабый чак бишегем.

Йорт кинәт юк булды. Дөм-караңгыда калдым. Әллә куркынып, әллә инде туңып дерелди башладым. Нишләп торам соң, шакырга, уятырга кирәк. Тәрәзәгә якынлаштым. Йөрәгем ярсып китте, кулымны күтәрәм дә дерелдәп, шакый алмыйча, кире төшерәм. Кемнәр тора икән хәзер бу өйдә? Танырлар микән? Ашыгып, каушап тәрәзәне шакырга үрелгән идем, агач аяк нигездән таеп китте дә тәрәзә яңагына барып сугылдым.

— Әй, кем анда?

Әти тавышы.

— Мин... бер мосафир... куныл чыгарга рөхсәт булмасмы?

Өй эче яктырып китте, кысып куйган лампаның филтәсен күтәрделәр. Өстәл янында озын чандыр бер кеше, ак күлмәк-ыштаннан. Әти! Сәкегә иелде, мөгаен, өстенә киярга эзли. Йөрәк дөп-дөп итә. Чыннан да, бу минем туган әтиемме?

— Хуҗа...

— Ибрай! — Әти кычкырып, тәрәзәдән атылып чыгардай булып, йөгерә-аксый мин торган тәрәзә ягына килде:— Ибрай... син кайттыңмы?..

Ул үксеп елап җибәрде.

## IV

Ирек ул иркенлек-тиңлек түгел икән әле. Минем өметләр, язгы гөрләвекләр өстендәге иртәнге юка боз кебек, атлаган саен чатный, челпәрәмә килеп ватыла бара.

Күкчәтауда рус телендә өлкә газетасы чыга икән. Бер көнне редакторга кердем, үземнең Казанда республика газеталары редакциясендә эшләвемне, шигырьләр язуымны, инде басылып чыккан өч китабым булуын сөйләдем. Редактор урта яшьләрдәге күзлекле кеше, өстәленә иелеп, минем сүзләрне «алай икән» дип җөпләп, дикъкать белән тыңлады да, мин сөйләп беткәч, кинәт тураеп, кашларын җыерды:

— Гафу итегез, бездә сезгә лаеклы эш табылмас,— диде һәм телефон трубкасын алып кемгәдер шалтырата башлады. Бу инде — сүз бетте, китәргә мөмкин дигән ишарә.

Шәһәр мәгариф бүлегенә барып, үземнең педтехникум тәмамлавымны, пединститутның дүртенче курсыннан китүемне әйтеп, башлангыч мәктәптә урын табылмасмы, дигән идем. Сап-сары бөдрә чәчле, мөлаем ханым, сөрмәле кашларын җыерып:

— Балаларыбыз язмышын без халык дошманнары кулына тапшыра алмыйбыз,— диде.

Бала вакытта бергә ат-ат уйнап, аннан мәктәптә бергә укып үскән Нигъмәтулла исемле иптәшем бар иде. Ул хәзер Күкчәтауда Заготскотның өлкә конторасында директор булып эшли икән. Бу хәбәрне ишетүгә күңелем яктырып китте, менә кем миңа бер эш табып бирер. Тизрәк барып күрешергә, сөйләшергә кирәк. Ул әле минем кайтканымны ишетмәгәндер, югыйсә әллә кайчан йөгереп килеп җиткән булыр иде бит.

Иркенләбрәк сөйләшеп утырырбыз, дип конторасына бармадым, кичне көттем. Аның атасы Фәсхетдин абый да (мин читтә йөргәндә үпкә авыруыннан вафат булган икән) балтачы иде, әти белән бергә эшли иде. Өйләрен дә бергә салганнар иде. Шуның өчен мин аларның өйләрен беләм, Кызыл урамында, чат башында ике бүлмәле, алтыпочмаклы өй.

Бала вакытта Нигъмәтулланы «черки» дип атый идек, тәбәнәк, ябык, авырудан чыкмый иде. Хәзер өйләрендә каршыма килеп баскач, иманеп киттем: миннән калку, таза, хәтта аз гына корсагы да бүлтәеп тора. Әллә ул, әллә башка...

— Ә, кайттыңмы? Яхшы булган,— диде ул салкын гына, теләр-теләмәс кенә кулын биреп. Күрештек! Утырдык. Ул нигәдер, тиз генә аш бүлмәсенә чыгып керде. Мөгаен, хатынына самавыр куеп җибәрергә кушкандыр. Тәмәке тарттык. Инде йомышым турында сүз башлыйм гына дигән идем, аш бүлмәсеннән хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Әй, Нигъмәт, без инде киногә соңга калабыз ич.

Нигъмәт сул кулын күтәрде, карады — алтын сәгате ялтырап китте.

— Әйе, әйе, Бибиҗан,— ул торып шифоньердан костюмын алып кия башлады.— Ибраһим, син инде гафу ит, без билет алып куйган идек. Бик кызык картина ди бүген.

Капка алдына чыктык. Нигъмәтулла нигәдер ялт-йолт тирә-якка карады, миңа тиз генә кулын сузды, хушлашты һәм пышылдап кына эндәште:

— Син инде, Ибраһим, безгә килеп йөрмә, күршеләр бик алама. Мин, наверное, вакыт булса, үзем сезгә барып чыгармын. Сафа абзыйларда торасызмы? Ярый, хуш.

Ул ашыгып кире өенә кереп китте.

Үги әнинең йөзе көннән-көн караңгылана башлады. Үземә турыдан-туры әйтмәсә дә, күршеләргә кереп: «Кайтканына инде өченче ай китте. Эш турында уйламый да, һаман атасының җилкәсен кимерә»,— дип зарлануын ишетә башладым.

Нишләргә? Кая, кемгә барырга? Аптыраган. Яңа ел, 1948 ел якынлаша, ә мин һаман эшсез.

Кая гына барып гозеремне әйтмим, паспортымны карыйлар да йөзләрен чыталар.

Нигъмәтулланы көтеп өметләнгән идем, ул да күренми. Бүтән иптәшләр дә бар иде, берсе-бер килеп хәлне белсәче.

Әтинең йөзенә карарга оялам. Әни болай да күтәрелеп карамый, кабаклары төшкән. Без җизниләрнең мунчасында торабыз.

Тик Әшрәф апа гына анда-санда чәйгә чакыра, иске-москыны рәтләп миңе киендерә — чалбар, пиджак рәтләп бирде, иске тунны кыскартып, «москвичка» ясады, рәхмәт төшкере.

Ә мин һаман әле иртә торам да, кай вакытта чәй дә эчмичә, әтидән оялып, урамга чыгам. Буран. Суык. Кая барырга икән бүген?

Аяклар сау булса, берәр складка йөк ташырга-бушатырга керер идем. Бүкән башы белән үз-үземне дә әле көчкә йөртәм — атлаган саен көрткә батып, чыгып китә алмыйча җәфаланам бит, коргыры. Кайвакытта бер ишектән икенче ишеккә кагылып, «Сезгә лаеклы эш юк!» җавабыннан җан өшегәч, өйгә ничек тә соңрак кайтыйм дип, Күкчәтауны урап алган, бала вакытта уйнап йөргән калкулыклар артына чыгам, берәр таш куышына ышыкланам, уйланам... Нигәдер, Тукайның һаман бер шигырен кабатлыйм:

Үксеп елыйм. Туйганчы елыйм. Монда, таш куышында, суык булса да, аулак — берәү дә күрми.

Кай көннәрдә зиратка барып, әнием кабере янына утырам да күңелемне бушатам.

Бар күңелләрдән дә жылы, йомшак синең кабрең ташы,—
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

Шулай яңа ел алдыннан беркөнне әти, кичке чәйдән соң: «Әйдә, тәмәке тартып керик»,— дип мине ишегалдына алып чыкты. Анда Сафа җизниләрнең үрәчәле чанасы тора иде, шунда утырдык. Әти янчыгын чыгарып тәмәке төрә башлады. Сизәм, нидер әйтергә тели. Күрәсең, яшь хатыны алдында күңел серен ачасы килми.

Әти яшь вакытында бик таза булган, көрәшләрдә дә, кабак сугышларында да бирешмәгән. Үзе мәчет салышып йөрсә дә, мәчет ишегеннән елына ике тапкыр, корбан гаете белән ураза гаетендә генә ачкан. Шуңа, ахры, аны кыерсытып «Урыс Низамый» дип атаганнар. Әмма Күкчәтауда аннан оста балтачы-столяр булмаган. Күкчәтаудагы иң матур, челтәр кәрнизле, өлге тәрәзә капкачлы өйләр — аның эше... Менә шул атаклы оста хәзер тәмәке кабыза. Тәрәзәдән төшкән җиделе лампа яктысында ул бигрәк тә мескен күренә,ябык, арка бөкресе чыккан. Заманында аның мыеклары, нәкъ маршал Буденныйныкы сыман, кабарып, колакларына уралып, йөзенә ниндидер бер мәһабәтлек сирпеп торалар иде. Хәзер инде әнә ул мыеклар да сәлперәйгәннәр, юкарып, сыланып тора.

— Улым! — диде әти нигәдер авыр сулап.— Мин менә гомер буена балта чаптым. Әле менә үземә дигән өй дә юк. Син минем ялгыз улым. Сине укытып, балтадан котылырмын дигән идем, булмады,— ул сүнеп барган «кәҗә сыйрагын» чытырдатып суырды. Очкыннар чәчрәде.— Булмады! — Тагын көрсенү.— Ходай шулай язгандыр инде. Син дә кулыңа балта алмасаң, булмас. Мин бүген Сафа белән килештем. Без аңа яңа өй салабыз, ә ул безгә өеннән артып калган бүрәнәләрне, такталарны бирә. Шулай тырышып үзебезгә бер куыш рәтләмәсәк, булмас.

Әти сүнгән төпчеген кар өстенә ташлап таптады. Яшь кар шыгыр-шыгыр килде.

Якында гына эт өрде.

## V

Калын карагай бүрәнәләр. Көч-хәл күтәрәбез, үзләре сөяк сыман каты, карандаш очлый торган үткер балта, чапкан саен сикереп-сикереп китә, бигрәк тә туң вакытта. Менә шушы бүрәнәләрне әүвәле тап-таза итеп каезларга, тигезләргә, аннан өч ягын такта кебек итеп тигезләп чабып чыгарга һәм шоп-шома итеп ышкыларга кирәк.

Шуннан соң гына бура бурый башлыйбыз. Почмакларны «француз йозагына» бикләп, әти үзе чаба, кисә. Ул кадәресенә әле минем кул ятмый. Мин күбрәк иртәдән кичкә хәтле бүрәнә чабам, уем алам, тырнак куяр өчен тишекләр бораулыйм.

Бура үскән саен бүрәнәләрне югарырак күтәреп салырга туры килә, бер генә тапкыр түгел — берничә тапкыр.

— Шулай-шулай! — ди әти, әле яңа гына куйган бүрәнәнең ятышын, уемның дөрес булуын карап бер алга, бер артка атлый, күзләрен кысып, аннан яткан бүрәнәне тимер сызгычы белән сызып чыга.— Әйдә әле!

Әле генә көчкә-көчкә күтәреп куйган бүрәнәне тагын көч-хәл күтәреп җиргә салабыз. Әти бүрәнәнең сызылган җиреннән тагын балтасын ялатып, кәгазь калынлыгы юнып ала...

Агач аяк кирәк җирдә бөгелми, кирәкмәгән җирдә таеп китә, авыр күтәргәндә җирне тишеп керә, суырып та ала алмыйсың.

Кичен чәй эчәр-эчмәс егылам, ә иртән... Иртән кузгала алмыйм, бөтен тәнем ватылган, чулак аягымның тезе кажалып, чи яра булып кансылый. Торырга кирәк.

Ниһаять, яз башына өйне салып бетердек. Сафа җизниләр дүрт бүлмәле матур өйгә күчтеләр. Безгә — иске өй һәм артып калган бераз бүрәнә, такталар. Әтинең әле моңа хәтле дә җыеп килгән матчалыклары, ишек-тәрәзә яңаклары бар икән. Менә шуларның барысын караштырып, инде үзебезгә өй салырга җыенабыз.

— Өйгә тотынсак, ашарга юк,— диде бер көнне әти, такта ышкылаганда.— Мин торгта эшләүче Хафизга өй салырга килештем. Көндез анда эшләрбез, ә иртә-кичен үзебезнең өйне сипләрбез.

Менә шулай итә-итә, ниһаять, үзебезнеке диган куыш та булды. Казах әйтмешли, үз башыбызга түтен чыгара башладык. Минем чулак аяк та өстерәлә торгач, барыбер бүтәнчә булмас инде, дип ахрысы, сөялләнеп тупасланды, элеккечә үк атлаган саен кырылып чиләнми. Куллар да балтага ятышланды. Әти инде миңа бура почмакларын «француз йозакка» бикләүне, ишек-тәрәзә яңакларын утыртуны да тапшыра башлады. Билгеле инде, үзе һәрвакыт күзәтеп-өйрәтеп тора.

Ә менә үги ана белән ара һаман да җылына алмый. Ул җае килгән саен «үтмәс товар» дип кадап ала, «кырыкка җиткән сакаллы сабыйның ыштырларын юар хәлем юк»,— дип керләремне атып бәрә башлады. Ахырында, әти белән киңәшеп, өйләнергә булдым, Маһинур исемле бер тол хатынны алып кайттым.

Менә шунда исем китте. Тагын чәпчер инде дисәм, әни һич тә шау-шу күтәрмәде, хәтта коймак коеп, никах урынына бер мәҗлес ясап, күрше хатыннарын чәйгә дә чакырды.

Мин дә куандым. «Әллә кайчан өйләнәсем калган икән, әни май булды»,— дип мактанып та алдым.

Маһинур беренче көннән үк өйдәге бар эшне: кер уу, идән юу, сыер саву, сыер куу, аш-су пешерүне үз кулына алды һәм житез-пөхтә булуын күрсәтте.

Сүзгә саран әти дә бер көнне аштан соң:

— Ярады, киленнән уңдык,— диде.

Минем дә күңел күтәрелеп китте. Ниһаять, сукмак юлга алып бара. Эш тә җитәрлек. Сугыш вакытында кыйралган дөньяны халык төзәтергә ашыга. Шуның өчен бер эш бетәр-бетмәс икенчесенә димләп килаләр.

Менә шулай яхшы гына эшләп, торып ятканда, бер көнне сеңелем Разия яшь баласы белән иреннән аерылып кайтты. Башта мин аның кайтуына сөенгән дә идем. Билгеле инде, иреннән аерылуга түгел, үзебезнең гаиләгә кушылуына. Ничек кенә әйтмә, үги анадан туган булса да, бердәнбер кардәш, сөйләшсәң дә, киңәшсәң дә дигәндәй. Ул бит инде акылга утырган, унъеллыкны тәмамлап, өлкә судында секретарь булып эшли.

Әмма бу юравым белән ашыкканмын икән...

Гаҗәп, Разия бусагадан атлап керүгә, әтинең миңа булган карашы үзгәрде — суынды. Ул инде элеккедәй минем белән ачылып сөйләшми, киңәшми. Кашлары салынган, йөзе һәрвакыт чытык. Ә бер көнне эштән кайтканда турыдан-туры әйтә салды, йөрәккә хәнҗәр кадады:

— Син инде үзеңә лаеклы эш тап та үзеңә куыш эзлә. Өй тыгызланды,— диде ул ачулы тавыш белән, кырыс кына.

Коелып төштем. Мондый сүзне ишетермен дип уйламаган идем. Әти бит кечкенәдән мине ярата — аркасына асып йөри иде. Ә инде Казанга китеп, кулга алынуымны ишеткәч, ул көне-төне елаган, хәтта асылына башлаган. Кайткач, күкрәгенә кысып, балалар төсле үкереп елады, «күрә алмам диган идем... өнме, төшме...»,— дип кочаклап йоклады ул мине беренче төндә. Ә хәзер? Ни булды аңа? Нигә кырысланды?

Әтинең бу көтелмәгән сүзләрен мин, билгеле инде, Маһинурга әйтмәдем, әмма үзем тонозын керфек какмадым, борчылып чыктым. Нишләргә? Кая барырга? Хәзер бит мин ялгыз башым гына түгел, икәү, бәлкем өчәү дә...

Әтинең бу кырыс сүзләренең серен күршеләр чишеп бирделәр. Әни инде әллә кайчан аларга әйтеп йөри икән.

— Үзенә генә түгел, кешегә дә кәсафәте тия. Менә шул ристан аркасында кызым югарырак эшкә күчә алмый. «Агаң халык дошманы»,— дип юлын кисәләр мескеннең, көн дә елый. Кайчан гына күздән югалыр җан көеге.

Ә икенче көнне Разия әти алдында әйтә салды.

— Син миңа туган түгел, син — халык дошманы! Синең аркаңда мине эштә күтәрмиләр. Кит бездән!

Шул кичне мин өйдән чыгып киттем. Кая? Үзем дә белмим...

## VI

...Вокзалдан бераз читкәрәк китеп, чирәм өстенә пальтомны җәйдем дә яттым. Көн болытлы. Гарип аяк очым сикереп-сикереп китә. Һава бозылыр алдыннан шулай кылана ул, хәерсез. Кая барырга? Кемгә таянырга? Нишләргә? Баш чатный. Җавап таба алмыйм...

Кесәдә нибары унбиш сум акча. Аның белән кая билет аласың? Бер пролетка да җитми бит ул. Нишләргә соң?

Менә сиңа ирек! Менә сиңа туган ата! Менә сине көткәннәр! Йоклап киткәнмен икән, паровозның сузып кычкыруына сискәнеп уяндым. Күкчәтау ягыннан ниндидер бер поезд килеп туктады, пассажир поезды. Берәүләр төшә. Берәүләр менә. Кочакланышалар. Үбешәләр. Көлешәләр. Нинди бәхетле җаннар! Әнә каршыдагы вагон тәрәзәсеннән өстәлгә тезеп куйган сөтле, кефирлы шешәләр, бер бөтен күмәч күренә. Авызыма сулар килеп китте.

— Ибраһим, бу синме! — Егылып китә яздым, кемдер култыгымнан тотып калды.— Нишләп торасың?

Алдымда — Галәү Маннапов, үзем белән бергә уйнап үскән малай. Хәзер инде өлкән абый булган, озын, тулы, өстендә яхшы костюм. Аптырап калдым, ни әйтергә дә белмим.

— Болай... Исәнме? Кая барасың? — дим.

— Алма-Атага, киңәшмәгә. Төсең юк, әллә авырыйсыңмы?

— Әйе, башым чатный. Кара әле, Галәү, мин кесәмнән акчамны алдырдым, инде билетка да юк.

— Доң-доң!

Вокзал ишегалдында эленеп торган өлкән җиз кыңгырау ике тапкыр сукты.

— Менә кесәдә бер утыз сум бар.

Галәү костюм кесәсеннән бер уч акча чыгарып миңа тоттырды да поездга таба йөгерде.

Кесәгә акча кергәч, хәтерем дә яктырды. «Тукта, Акмулада әле минем Алтай дигән бер дус бар бит. Антибеста да бергә яттык. Ул уголовник, вакыты да тулырга якын иде. «Әгәр Күкчәтауда рәтле эш табылмаса, үземә кил, урнаштырам»,— дигән иде бит. Кассага йөгердем.

Озакламый Күкчәтау ягыннан «Максим» килде.

Мин Акмулага киттем.

## VII

Төнлә аз гына яңгыр явып узган иде, ә монда, Акмула урамнарында, аяк атлагысыз саз, бигрәк тә минем кебек агач аякларга. Атлаган

саен тездән батып китәм, агач аякны ике куллап суырам. Көч-хәл аны тартып икенче адым ясыйммы, тагын батам. Кай җәһәннәмдә тора бу Алтай? Кайда соң аның Шанхай дигәне? Шәһәрнең көньягындагы иске бараклар, саман өйләр белән тыгызланган «нахалкалар» бистәсен Шанхай дип атыйлар икән. Әйтүенә караганда, Алтай шул Шанхайның урта бер җирендә, базарга каршы чат башындагы өйдә торырга тиеш.

Ниһаять, җан тиргә төшеп, былчыракка батып, сораша-сораша Алтай торган өйгә килеп җиттем. Эчем җу итеп китте, яртылаш җиргә сеңгән саман йорт, түбәсе кыйшайган, ишек каерылган. Түшәме җимерелеп төшкән бер бүлмәне үтеп, икенчесенә кердем. Кап-караңгы, бер нәрсә дә күренми. Бары тик колак тондыргыч чебен мыжлавы.

— Өйдә кеше бармы?!

Нәрсәдер кыштырдады, каршыдагы сәкедән мияулап песи сикереп төште, карлыккан тавыш гырылдады:

— И... коргыры, тагын кем җөри, җокы бирмәй?

— Чичәй, Алтай дигән адәм шушында торамы?

Әйтерсең, камчы белән сукты:

— Китче, Алтай-балтаеңды белмәймен, ни дигән каңгырган жансың!

— Мин, чичәй, Күкчәтаудан.

— И... әнә бакзал башында Торсын кассапчы торады. Алтай-балтаеңды шуннан сора!

Тагын саз ерып, кирегә, вокзал якка, итче Торсынны эзләп киттем.

Капка төбендә мине, көрәк белән су ерып, кура тазалап йөргән бер карт каршылады, озын, чандыр, чөй сакал. Өстендә иске чапан, башында кыркылып беткән бүрек.

— Әссәламегаләйкем, ага?

Әллә саңгырау, сәламемне алмады, шикле бер караш белән озак карап торды, аннан кырыс кына эндәште.

— И... көннең кашы каралганда ни кылып җөрисең?

— Ата, сез Алтай дигән адәмне белмисезме?

Карт сискәнеп артка чигенде:

— Ул кем, жулдасыңмы?

Мин куанып киттем: төпченеп сораша,— мөгаен, монда тора.

— Ие... якын юлдашым иде.

— И... жаксы адәм икәнсең... жулдасың төрмәдә утыра. Талаган кичә төндә.

Бусында инде башыма чукмар белән суктылар, аңгы-миңге килдем.

— И жаксы килдең,— чал ачулы тавыш белән мыгырдады,— милиция ул сукбайның жулдасларын эзләп җөри иде... Искәртү кирәк.

Бу чал сакаллы дорфа карт яныннан ничек ычкынганымны да белми, алдыма-артыма карамый йөгерәм. Кая? Үзем дә белмим. Ниндидер бер тыкрыкка килеп кысылдым. Әллә кайдан бер кәрлә эт чыгып, абалап өрә башлады.

Артта кемнәрнеңдер ашыгып килүләре, сөйләшүләре ишетелде. Бар көчемә йөгерә-атлый тыкрыкның очына чыктым. Күмер өеме. Вагоннар. Ниндидер тупик. Мин күмер өеме янына барып егылдым. Якыннан гына уф-уф килеп паровоз үтте.

Төн буенча яңгыр яуды.

Мин тупиктагы бер товар вагоны астында утырып чыктым. Арыган, алҗыган булуыма карамастан, күзләремә йокы кунмады. Бердән, вагон басарга йөргән карак, дип тотып ябалармы дип хәвефләнсәм, икенчедән, эч бокыр-бокыр килеп һич тынычлык бирми. Бичара нишләсен, инде икенче тәүлек авызга бер валчык төшкән юк. Алтайга житкәч тамагымны бер туйдырырмын дигән идем, ярый әле үземне эләктермәделәр. Теге дорфа картның карашы яман иде, вакытында ычкындым...

Алсу нур бөркеп кояш күтәрелә башлады. Тирә-як яктырып, матураеп китте. Яңгырдан соң монда күмер өемнәре, тотен сеңгән иске, җимерек

вагоннар арасында да иртәнге тәмле хуш ис!

Ә шулай да ашыйсы килә.

Вокзал артындагы базарда, озыннан-озынга сузылып киткән өстәлләрдә сөт, эремчек, катык, ара-тирә бөтен табикмәкләр дә күренә. Нинди тәмле ис.

Вокзалдагы пассажирлар килеп әле бер, әле икенче өстәлгә туктыйлар, сөт белән, катык белән табикмәк ашыйлар. Аларга карап авызыма су килә.

Читкәрәк китеп өстемдәге күлмәгемне салдым, төрмәдән кайткач, әти үзе: «Мә, улым, үзең киеп туздыр», дип бүләк иткән иде бит...

Вокзалдан читтә аулак бер җиргә — ташландык шпаллар өстенә килеп утырдым да ике табикмәкне бер шешә сөт белән ашадым да бетердем... Сизми дә калдым. Үз гомеремдә, хәтта, Колымада да мондый тәмле ризык ашаганым юк иде.

Корсак тулгач, тынычланып, шпал өстенә сузылып яттым.

Күзем эленеп киткән.

— Ту-ту-ту!

Сискәнеп уяндым.

Каршыдагы биек өелгән тимер юлдан поезд килә. Алтын билбаулы яшел вагоннар. Алда кызыл түшле мәһабәт тепловоз. Поезд якынлаша. Вагоннарның тәрәзәләре ачык. Аннан пассажирлар карый. Менә вагон-ресторан. Өстәлләрдә шешәләр. Әнә ике пассажир кулларындагы стаканнарны чәкештерә. Ишеге ачык тамбурда хәрби киемдәге бер егет белән күк күлмәкле бер кыз басып тора. Алар бер-берсенең кулларыннан тотышып, далага карап көлешә-көлешә ни турындадыр сөйләшәләр. Поезд шпаллар өеменә якынлашты. Аларның күзләре миңа төште. Кыз елмаеп миңа кул болгады «Хушыгыз!» Аңа ияреп теге хәрби егет тә кул болгады.

Кара, дөнья нинди матур! Кара, дөньяда әле нинди әйбәт кешеләр яши. Түзмәдем, сикереп торып үзем дә теге кыз белән егеткә яулыгымны болгадым.

— Хушыгыз! Хушыгыз!

— Ту-ту-ту!

Поезд китте. Ерактагы чәчәкле Алма-Атага, карлы түбәләре күкләргә үрелгән Алатау ягына китте. Бүгенге беренче һәм соңгы сөенечем дә шул поезд белән офыкка китеп югалды. Мин тагын үземнең авыр чәнечкеле уйларым белән калдым.

Кара, кояш инде баеп бара. Әле яңа гына ул күтәрелеп килә иде түгелме? Тагын төн якынлаша. Кайда йокларга? Нигә йокларга? Аннан кая барырга — уңгамы, сулгамы? Юл юк! Өстемдәге соңгы күлмәкне сатып ашадым. Кесәдә бер тиен акча юк.

Нигә соң болай?

Әнә берәүләр нинди пөхтә, матур итеп киенәләр, нәфселәре ни тели, шуны ашыйлар, кая барасылары килсә, шунда китәләр. Ә мин? Мин — бүре! Мине куалар, эзәрлеклиләр. Кешеләр минем белән сөйләшергә курка. Мин алардан куркам. Нигә?! Мин дә бит алар төсле үк кеше. Миңа бит әле утыз сигез генә яшь. Мин хәзер бөтен яктан камилләшкән, дөньяда үз урынын тапкан ир булырга тиеш бит! Ә хәзергә — сәләмә киемнәргә төренгән агач аяклы гарип. Нигә мин гарип? Анадан шулай гарип булып тудыммы? Сугыш мәйданында илемне саклап гарипләндемме?

Ни өчен мине тере гарип ясадылар һәм хәзер чиркانып яннарыннан куалар? Җир тетрәнеп китте. Сискәнеп аягүрә бастым. Поезд килә. Кызыл вагоннар! Әйтерсең лә берәү җилкәмнән тертеп торгызды. Кызыл вагоннарга таба атладым. Тизрәк! Тизрәк! Ашыккан саен агач аяк тәртелә, сөртенә. Әнә инде вагоннар гөрелтесе. Якынлаша! Якынлаша! Тизрәк! Пальто чабуы аякка уралып, йөгерергә бирми. Аны салып ыргытып, өемгә йөгердем. Җир дер-дер итә. Менә уф-уф итеп, пар бөркеп, тирә-якка төтен таратып килүче паровоз күренде. Тизрәк! Соңгы

көчемне җыеп, тырмашып, өемгә үрмәлим. Төнге яңгырдан соң балчык йомшарган, шуа, бата. Нәрсәдер дерт-дерт итә. Әллә җир, әллә минем йөрәк. Житә алсам гына ярар иде... Әмма... мин инде рельска ятам дигәндә генә, соңгы чуен тәгәрмәч дыңгырдап, тәгәрәп узды. Мин хәлсезләнеп, ачынып шпаллар өстенә аудым.

— Булмады...

## VIII

Нәрсә соң ул фактура?

Нәрсә соң ул нетто? Брутто? Тара?

Унлы үлчәүдә ничек үлчиләр? Контора счетында ничек исәплиләр? Ходай белсен, төшкә дә кермәгән нәрсәләр. Ә шулай да мин менә Кызыл Яр авылындагы кооперация ашханәсендә буфетчы — товар алам, товар сатам, хисап бирәм.

Мондый җаваплы эшкә ничек алдылар дисезме? Билгеле инде, кызганып түгел, чыгырыннан чыккан мохтаҗлыктан гына. Бу ашханәдә буфетчы, гадәттә, биш-алты айдан артык эшләми, судланып төрмәгә китә икән. Шуның өчен авылда инде бу буфетка керүче табылмаган. Ә ашханә-буфет эшләргә тиеш. Мин, ходайга тапшырып, тәвәккәл кылдым. Нишлисең, аптыраган үрдәк арты белән күлгә чума, диләр бит...

Вакыты җитмәсә, үләм дисәң дә үлә алмыйсың икән. Бу талпыну да барып чыкмагач, бераз суындым. Икенче көнне өстәге пальтомны саттым да Күкчәтауга кайтып киттем. Төн уртасында ишекне шакыдым. Йоклыйлар. Бераз икеләнеп, кыймыйча торгач, тагын тәвәккәлләдем.

— Кем анда җиде төн уртасында?

— Мин, әни.

— Ә, үтмәс товар, тагын кайттыңмы!

Үги әни өйалды ишеген ачты, әмма үзе уртага басты — тәбәнәк, юан, ак күлмәк-ыштаннан. Ачулы. Кулында җиделе лампа.

— Маһинур өйдәме?

— Булыр өйдә,— әни нигәдер җилкәләрен сикертте, лампа пылт-пылт итеп китте,— уйнаштан бала тапты. Әле менә кичә Разиянең итәген урлап качып киткән.

— Кайда инде ул хәзер?

— Чертым беләме? Милиция белән эзләп таба алмадык. Бик кирәк булса, табарсың әле. Ярар, әтиеңә иртәгә эшкә барырга кирәк.

Ишек шап итеп ябылды. Лампа сүнде.

Дөньяда әле мәрхәмәтле кешеләр дә бар икән. Бер иптәшем паспортымны алыштырып бирде. Икенче иптәшем «ун ел хисапчы булып эшләде» дигән язуга кул куеп, мөһер сугарга җөрьәт итте. Нәкъ менә шул документларны юллап йөргәндә, Кызыл Яр авылындагы ашханәгә буфетчы кирәк дигән хәбәрне ишеттем.

Сельпо председателе урта буйлы, аз гына шадра битле казах документларны күргәч, көлеп җибәрде:

— Уйбай, нәкъ үзе, ун җыл хисапчы булып эшләгән,— дип документларны бухгалтер кызга сузды.

Тәрҗемән халне хезмәт кенәгәсенә ятыштырып язып бирдем. Председатель Мостафин миңа бер ташландык йортны күрсәтте.

— Шушында катын-балаңны алып кил. Алда күз күрер.

Шул көнне үк келәттән аракы, шәрап, конфет, шикәр кебек товар алып, фактурага кул куеп, буфетны ачып җибәрдем.

Икенче көнне Күкчәтауга барып, Маһинур белән улым Шамилне алып килдем. Маһинур өйнең эчен-тышын сылап, агарта, юа башлады.

Кызыл Ярдагы беренче көн үзе бик кызыклы башланып китте. Ул кичне безгә Хөзер килде. Чын, һич ялганы юк, ышанмасагыз, менә үзегез хөкем йөртегез.

Кич белән, ашханә ябылгач, мин буфеттан бер бөтен икмәк, ярты кило шикәр, бер әчмуха чәй алып кайттым. Ә Маһинур, башындагы дебет шәлен сатып, чиләк, чәйнек, табак-савыт, кашык һәм бер кило ит алган булган. Мин кайтканда өй ялт иткән, анда тәмле аш исе аңкый иде.

Ниһаять, беренче тапкыр, Маһинур белән үз куышыбызда, күршедәге казах карчыгы бүләк иткән тәбәнәк, түгәрәк өстәлебездә үзебез пешергән ашны ашарга утырдык. Күптәннән инде итле аш ашаган юк иде, хуш исе борынны кытыклый.

— Я, карчык,— дидем мин көлеп,— өстәл байларча, музыкасы гына юк!— Сүземне очлый да алмадым, ишек ачылды.

— Әссәламегаләйкем!

Аптырап калдым. Ишек төбендә ап-ак сакаллы бер казах карты басып тора, култык астында ак яулыкка төрелгән зур гына төргәк.

— Вәгаләйкемәссәлам, ата, югары чыгыгыз,— дидем, әле һаман гаҗәпләнеп.

Карт кыстатып тормады, төенчеген тәрәзә төбенә куйды да, кулын юып, өстәл янына утырды.

Аштан соң чәй эчтек!

— Хәерле булсын,— дип карт бер аять укып, дога кылды да, тагын миңа карап:— Инде бер сорнай тартсам, ничек булыр?

Шаккаттык! Бу ни дигән сүз! Ап-ак сакаллы карт! Дога. Инде...

Ул арада карт урыныннан җитез генә торып, тәрәзә төбендәге төенчекне чиште һәм тальян гармун чыгарды.

Бармаклары бик җитез генә әле өскә, әле аска йөгерә, гармун телләре ашыгып аваз чыгара. Менә Себер татарларының иң яраткан көйләре «Биш күл». Карт яхшы ук яңгырау тавыш белән җырлап та җибәрде.

Бишкүл көе, Бишкүл көе, Бишкүл көен яратам.
Бишкүл көенә җырласам, хәсрәтемне таратам...

Бераздан гармунга Маһинур да кушылды.

## IX

Бу ашханә Кызыл Яр авылының кырыенда — Чагалы елгасы борылышында «Г» хәрефе шәкелендә салынган иске бер өйдә урнашкан иде. Иске булганда да шундый иске — исең китәрлек. Ул әле тумышында ук беләк юанлыгы карагай сайгаклардан гына әштер-өштер әмәлләнгән булган, нигезсез, җиргә түшәп кенә. Тора-тора ул тузган, утырган, нәкъ тавык тәпиендәге өйгә әверелгән.

Әнә тәрәзә тәпләре астында, почмакларында баш сыярлык тишекләр. Алар иске-москы капчык, чүбек-чабык белән генә томаланган. Түбәдәге шиферларның күбесен җил куптарып алып ташлаган.

Эчке яктан ашханәнең стеналары, кайчандыр фанер белән тышланып, ак буяу белән буялган да булган. Әмма хәзер инде ул фанерлар җыерчыкланып күпергәннәр, калкып чыкканнар. Буявы кубып, саргаеп, шадраланган. «Г» хәрефенең ыргагында — аш пешерү бүлмәсе һәм кечерәк кенә буфет кисәге. Ә инде «Г»ның «ботында»— зал. Анда дүртәр кешегә исәпләнгән җиде-сигез өстәл һәм җимерек урындыклар. Уртада калай белән тышланган зур мич.

Кухняда — ике кеше. Баш повар, ул ук ашханә мөдире. Аның ярдәмчесе, ул ук — официантка. Мин — буфетчы. Менә бар штат.

Баш повар — тәбәнәк, ябык, мескен генә бер ир. Ә исеме, мыскыллап куйган сыман,— Великанов Иван Иванович. Авызында һәрвакыт какланып беткән трубка пыскып тора. Иван Иванович сөйләшергә яратмый, әмма һәрвакыт ниндидер бер көй шыңшып йөри.

Ярдәмчесе Вера Петровна шефның нәкъ киресе — мәһабәт гәүдәле, балтырлар, беләкләр сылык-сылык итеп торалар. Әгәр ул ачуланып бер кизәнсә, Великановның көле күккә очачак. Гөнаһларына керер хәлем юк — тавышланганнарын ишеткәнем булмады — һәр икесе үз эшендә: Вера Петровна бертуктаусыз сөйли, авылның иң соңгы яңалыкларын фаш итә, ә Иван Иванович, трубкасын пыскытып, бетмәс-төкәнмәс көен шыңшый.

Алар икесе дә мине яхшы каршы алды. Иван Иванович зур гына жамаякны түбәсеннән тотырып, уртасына көнбагыш мае салып, тары боткасы бирде. Вера Петровна (ул вакытлыча буфетчы хезмәтен дә башкара икән) бер тутәрәм ипи дә китереп куйды һәм ашханәгә кемнәр килүен, нәрсә ашауларын сөйләп китте.

— Монда күбрәк авылныкылар килә бит, кайсы банктан акча ала, кайсы ревкомга, кайсы исполкомга... кайсы комендатурага... немецлар, поляклар, төрмәдән кайтканнар...

Эчем жу итеп китте. Әйтерсең лә, минем төрмәдән кайтканны, ялган язулар белән йөргәнне белеп, сынап әйтә... Әмма Вера Петровна миңа игътибар да итми. Инде дөньядагы бүтән хәлләрне тезә башлады.

— Карагыз, сез бурычка бирмәгез. Бурычка эчеп теңкәгә тияләр. Әле миңа гына да дүрт-биш кеше бурычлы. Ала алсам ярар иде...

Дөресен әйткәндә, мин такылдавык хатынның бу сүзләренә әллә ни игътибар да итмәгән идем. Әмма озакламый бу сүзләрнең алтын булуына шигем калмады. Инде кар төшкән иде. Буфетта җил уйнап тора. Аракы тезелгән киштәләрдә ап-ак кар чачаклары асылынып тора. Ашханәдә кунаклар юк. Мин өстәл-буфет артында утырдым, утырдым да, тәмам дерелди башлагач, кухняга Иван Иваныч янына, тәмәке тартырга кердем — плитә янында җылырак. Вера Петровна утын ярырга чыгып киткән иде. Папиросымны тартып бетерергә дә өлгермәдем:

— Начальник килә!— дип атылып-бәрелеп Вера Петровна керде. Кочагындагы ярты олау утынын плитә янына ташлады, мич селкенеп китте. Үзе һаман такылдый:— Менә бәла... Ә син, буфетчы, нәрсә шаккаттың, чык тизрәк. Уф алла, алъяпкычым кайда?!— Ул әле бер, әле икенче почмакка йөгереп мәш килде.— Кайда гына куйдым?

— Вера Петровна,— диде Великанов артык ашыкмыйча, трубкасын плитә кырыена суга-суга,— алъяпкычың биленңдә иң.

Мин чатанлап буфетыма чыктым.

— Өч кешегә заказ.— Вера Петровна залга чыгып, килүчеләрдән заказ ала. Мин талон язам. Повар шул талоннар белән үзенең аш-суын җибәрә. Кичен повар белән талоннарны барлап, исәпләп, кухня ризыгының ничә сумлык сатылуын исәплибез.— Бер литр аракы, өч гуляш.

— Өч кешегә бер литрмы?

— Тиз дим. Ул көттергәнне яратмый.

Ике шешә аракы, стаканнар бирдем. Тагын яздым. Ул арада тагын бернечә кеше килеп, тәмәке, шырпы сорады, талон яздырды. Мин бу котны алган башлыкның кем булуын да сораша алмый калдым. Бары заказ кәгазенә «Начальник!» дип сырлап счетта сумманы исәпләп төшерә башладым.

— Тагын бер бөтен, ике гуляш,— дип Вера Петровна исәбемне ялгыштырды.

Аракыны бирдем. Гуляшка талон яздым. Сумманы исәпләп, заказга өстәдем.

Залда халык күбәйгәннән-күбәя бара, өстәлне өстәлгә кушалар, кухняга кереп, кыйшык аяклы эскәмияне дә алып чыктылар. Кунакларның барысы да диярлек кып-кызыллар, чиртсәң битләреннән кан сирпер. Әллә суыктан, әллә аракыдан.

Озакламый залда күкле-яшелле тавыш белән җыр да күтәрелде, русча, казахча. Заказны язып биреп, исәпләп өлгерә алмыйм. Иван Ивановичның инде өч көн сатылмый туңып яткан гуляшлары да, җылыты-

лып, «худка» китте. Туп-туры бер ящик аракы бар иде, бушады. Ахырда шампан шәрабына күчтеләр.

— Минем инде аякларым йөрми,— дип Вера Петровна еларга житешеп зарлана башлады.

Бары тик төнге сәгать өчне сугып киткәч кенә көч-хәл белән өйләребезгә таралдык. Иртәгесен тагын буфетка. Буран, көрт. Култык таяклар көрткә бата да мин мәтәлеп барып төшәм.

Торам, тагын егылам. Ә буран котырганнан котыра бара. Көчкә генә ашханәгә килеп житеп егылдым. Буфет шкафын ачып, үлчәүне өстәлгә куеп, шешәләрне тезәргә өлгермәдем, бер хатын килеп керде. Лампочка кызарып кына тора, караңгы. Өстәлгә килеп житәр, житмәс, сорап түгел, боерып:

— Бер литр аракы,— диде теге хатын.— Мин фәлән начальникның әйеле (хатыны).

Куанып киттем. Менә әйбәт булды, дип тиз генә кесәмнән, кичәге түләнми калган заказ кәгазен чыгардым.

— Кичә ирегез бездә утырган иде... Заказны түләмәде... Тугыз йөз житмеш сигез сум егерме өч тиен.

— Жала жапмагыз,— дип хатын кырт кисте,— менә бер литрга.— Ул ачу белән миңа илле сумлыкны ыргытты:— Минем жулдасым акча түләмәй заказ бирмәйде.

Аптырап, ни әйтергә белми торганда, хатын ике шешәне сумкасына салды да ишеккә атлады һәм ачулы рәвештә:

— Жарайды, мин жулдасыма сезнең жалагызны айтаен,— дип ысылдады.

Ишек шап итеп ябылды.

Мин, сылк итеп урындыгыма ишелдем. «Менә сиңа кирәк булса! Нинди яла?»

Төш авышкач, түрә абзый хәрби киемдәге бер кеше белән залга үтте. Бераздан Вера Петровна йөгереп килде:

— Начальник сине чакыра.

«Мөгаен, исәпләшергәдер...», дип, заказ кәгазен кесәмә салып, счетны култык таякка кыстырып йөгердем.

— Сәламәтсезме?

— Рәхмәт. Яхшы.

Мөлаем гена кеше икән бу начальник. Йөзе түгәрәк. Матур. Елмаеп кына сөйләшә.

— Син жаңа буфетчымы?

— Әйе.

— Жаксы, жаксы,— ул тагын елмайды. Папирос кабызды, суырды. Иптәше — озын, таза гәүдәле кеше, нигәдер торып чыгып китте. Начальник авызыннан зәңгәр божралар чыгарып өрде дә миңа карады.— Бурычка товар бирергә ярыймы?

Аптырап калдым. Счетым кулымнан төшеп китә язды.

— Юк, ярамый, иптәш начальник.

— Алай булгач, нигә минем әйелемә «бурычыгыз бар» диден?

— Мин бит... заказ буенча.

— Яле, яле... монда бир әле ул кәгазеңне.

«Уф алла. Ичмасам хәтерләр...»

Мин халат кесәсеннән заказ кәгазен алып начальникка суздым.

— Рәхим итегез. Тикшерегез.

Кашлар жыерылды. Тавыш кинәт сикереп ачулы тонга күчте:

— Бир, күп сөйләмә!— Ул минем тугыз йөз житмеш сигез сумлык заказ кәгаземне кулымнан тартып алды да ертып-ертып идәнгә ташлады, үзе шунда ук сикереп торып ишеккә таба атлады.— Хөкүмәт малын тагын бурычка таратасы булсаң, мин сиңа урын табармын!

Култык таякларым төшеп китте. Мин мичкә сөялеп калдым.

Ишек шап итеп ябылды.

# X

Буфеттан катып-туңып, соң гына кайтып йокларга гына яткан идем, кемдер тәрәзәне шакый башлады. Җимереп керәмени, бөтен өй селкенә. Бу дөбердәүгә бишектә йоклап яткан улым куркып уянды да елый башлады. Үзем дә сискәнеп кычкырып җибәрдем.

— Кем анда? Ни кирәк?

— Милиция! Ач!

Мингерәүләнеп киттем — «килделәр!»

Маһинур бишектән баланы ала башлаган иде, бу тавышка ул баланы төшереп җибәрде. Мин чалбар урынына гимнастерканың җиңен кия башлаганмын. Аны атып бәрдем. Чалбар юк, таба алмыйм гына үзен.

— Әй, үлеп калдыңмы, ач җылдам!

Тагы да катырак суга башладылар, әллә тәрәзәдән керәләр инде! Бала акыра. Маһинур елый. Мин нәрсә эшләргә белми, чалбарсыз урын өстендә әйләнәм, үзем дер-дер киләм, әллә туңам, әллә куркудан.

Мөгаен, ялган язулар белән йөрүемне сизгәннәр. Их, нигә шул түрә белән бәйләндем.

Мин әле күптән түгел генә Казанга, Кави агага хат язып, «Акколак һәм Сакколак» исемле кечкенә поэмамны җибәреп, берәр редакциягә тәкъдим итүен үтенгән идем. Җавап тиз килде, әмма вафасыз. «Поэмаң балалар теле белән матур язылган, сюжеты да мавыктыргыч. Әмма бер редакциягә дә тәкъдим итә алмыйм. Сәбәбен үзең беләсең. Әле күптән түгел генә, ун ел срогын тутырып, тәнкыйтьче-журналист Гомәр Гали кайткан иде. Өч-дүрт ай эш таба алмый аптырап йөрде. Кичә тагын кулга алганнар үзен. Шулай булгач, Казанга килергә җилкенмә!»— дигән иде Кави ага хатында. Менә, чират миңа да житте.

— Ач, дим, җылдам!

— Үлеп калдыңмы, мур кыргыры...

Маһинур абына-сөртенә барып ишекне ачты, өйгә ажгырып буран керде. Аның эченнән өсләрен ап-ак кар сырган ике милиционер күренде:

— Җыен, милиция башлыгы чакырды!

Күз ачкысыз буран. Алдан кар ерып ике милиционер бара. Алар артыннан, култык таякларым белән көрткә бата-сөртенә мин тырмашам. Артта бала күтәргән Маһинур мине озата бара. Милиция конторасы авылның аргы башында. Үч иткәндәй, нәкъ шул яктан буран бурый.

Мин инде шабыр тиргә баттым, ә алда әллә никадәр барасы. Без әле ашханәгә генә якынлашабыз. Ул буран эченнән карачкы булып күренеп-күренеп кенә кала. Мөгаен, инде аны да, авылны да соңгы күрүем.

— Әй, буфетчы,— диде алда барган милиционерларның берсе, яшь казах егете туктап: — Башлыкка Күкчәтаудан кунаклар килде, ике литр аракы сорады.

Әйтерсең лә, өстемнән мең пот йөк төште, бушап, җиңеләеп киттем:

— Мә, Маһинур, ачкычларны, күпме сорасалар, шул хәтле аракы бир үзләренә.

Маһинур ачкычны алды да куана-куана ашханәгә йөгерде.

Мин буран эчендә күмелеп калдым.

— Уф, алла, өнемме, төшемме?

Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга диләр бит, мин дә, әтләшә торгач, үлчәргә дә, санарга да, счет тартырга да өйрәнә башладым. Әмма ничек итеп бурычка бирмәскә — акыл җитми. Кунакларым берсеннән-берсе өлкәнрәк түрә бит. Аларны кире кагып кара, бигрәк тә үзең «юеш»кә утыргач. Ә менә бер ай сәүдәдән соң алыш-биремне исәпләп карасам: ике мең җиде йөз сиксән алты сум унҗиде тиен акча җитми! Нишләргә?..

Күкчәтауга барып, туган-тумача, дус-иштән бурычка акча сорап

карадык. Юк! Барысы да йөз дүндерде. Менә шунда гына миннән алда буфетта эшләгән бәндәләрнең ни өчен судланып китүләрен төшендем.

Әмму бу төшенүдән ни файда? Акча юк. Тагын — төрмә дигән сүз.

— Булмаса ашханәне ремонтларга алыныйк. Агач эшен син эшләрсең, буявын, агартуын мин,— диде Маһинур.

Мин сельпо председателе Мостафин белән сөйләшеп, өч мең сумга килешү төзедем дә Маһинур белән ашханәне төзәтергә керештек. Эштән соң кичләрен, ял-йокы исәбенә. Улыбызны аракы әрҗәсе өстенә яткызып торып. Ремонтны бетергәч, килешү буенча акчаны алып, «тишекне» ямадык. Уф алла! Ләкин озаккамы?!

## XI

Кызыл Яр авылы янынннан кечкенә генә бер елга ага. Казахлар аны Чагала үзәне диләр. Чагала — Акчарлак дигәнне аңлата. Авылга җитәр алдыннан елга ермакланып-тармакланып китә,ерактан, үрдән карaганда, ул очарга әзерләнеп канатларын җәеп җибәргән акчарлакка охшый. Бәлкем, аның исемен дә әнә шул күренеш тудыргандыр.

Эштән бушаган араларда, бигрәк тә кичкырын мин шушы елга буена килеп уйланып утырырга яратам. Чагала үзе тар, үзе сай, ярлары да текә түгел, сөзәк! Анда вак-төяк куаклыклар. Ә мин утыра торган төштә шомырт агачлары. Яз башында алар шау чәчәктә була. Әчкелтем хуш ис борынны кытыклый.

Әйткәнемчә, мин утыра торган җирдә дә үзән сай — үтәли күренә. Кызгылт, сары, саргылт, ак ком бөртекләре, ногыт борчагы кебек, чекерәеп яталар. Ара-тирә аларны күләгәләп, вак чабаклар ялт-йолт үтә.

Мин утырган җирдән аз гына алда су эчендә зур гына бер чуер таш ята. Чагала агып барышлый шул ташка сугылып, чупылдап ала.

— Чупылт-чупылт. Чупылт-чупылт.

Яратам мин шушы тонык пышылдаган тавышны тыңларга. Агып барышлый, теге таш янында бик аз гына тукталып, елга аңа үзенең ниндидер бик яшерен серен пышылдап кына әйтеп уза сыман.

— Чупылт-чупылт. Чупылт-чупылт.

Нинди сер, нинди әкият сөйли икән бу көмеш канатлы акчарлак? Әнә ишетәсезме, тагын.

— Чупылт-чупылт.

Чагала менә шулай, артык тавышланмыйча гына, сагышлы бер җыр көйләп оча-оча да, кылганлы далага чыккач, кинәт юк була. Җиргә сеңеп югала. Акчарлакның көмеш канатлары салына, җыры әйтелеп бетмәгән сер булып өзелә.

Гомер! Кеше гомере дә, елгалар кебек ага бит. Берәүләрнең гомере Агыйдел төсле тулып ташый. Ул иксез-чиксез дәрьяларга барып чыга — зөбәрҗәт дулкыннарын чайкалдыра. Ә кайбер гомерләр, менә шушы Чагала үзәне төсле, акрын гына, чупылт-чупылт итеп кенә ага да иркен киңлеккә чыктым дигәндә генә эзсез югала.

Менә минем гомер дә, нәкъ менә шушы Чагала үзәне төсле саркып тәшвишләнеп кенә ага. Кайчандыр мин тау елгасы сыман таштан ташка сикереп, тавышланып, чәчрәп ага идем бит. Нигә соң әле болай тып-тын шыпырт булып калдым?

Күңелемдә әле һаман да яңа җырлар яңгырый. Мин һаман әле яңа шигырьләр, хикәяләр, романнар язу уты белән ялкынланам.

«Син инде яңа әсәрләр язып азапланма. Бер редакция дә аларны кабул итмәс»,— дигән Кави ага миңа җибәргән соңгы хатында.

— Чупылт-чупылт...

Сискәнеп башымны күтәрәм. Уйлар очына җитә алмыйча өзелә. Мин, култык таякларымны алып, көчкә-көчкә генә аягүрә басам.

Акчарлак канатларында — шәфәкъ яна. Әйтерсең лә, канатлары

жәйгән кызылказ кичке күккә күтәрелергә жыена.
— Чупылт-чупылт.
Сагышлы жыр, зарлы пышылдау...
Ерак офыкта соңгы учаклар сүнә. Ел артыннан ел уза. Башлыклар алмашына. Үзгәрәләр. Бары тик аларның гадәтләре генә үзгәрми. Элеккеләре дә, соңгылары да бер калыпка коелгандай бурычка — бушка эчәргә, ашарга ярата. Ә мин, ике ревизия арасында ут йотып, әнә көям, менә янам дип, кызган табага баскандай сикергәлим. Ашау-эчүне кысам. Маһинур анда-монда кәнсәләргә йөреп идән юа, мич яга. Аның хезмәт хакын да бурычлар түләү исәбенә җыеп куям.

Менә 1953 нче ел. Март. Радио: «Сталин вафат!».
Берәүләр елады. Берәүләр ләгънәт укыды. Берәүләр өметләнде. Әмма минем тормышка бернинди дә үзгәреш килмәде. Буфет. Башлыклар. Әҗәткә сораулар һәм тетрәнеп ревизия көтү.
Ниһаять, партиянең XX съезды. Ул шәхес культы җинаятьләрен каплап торган кара шомлы пәрдәне күтәрде. Дөнья чиркanып тетрәнде.
Күңел иләс-миләс. «Халык дошманы» дигән тамгадан, хурлыктан, җәбердән котылу өметләрем тагын кабынды...
Әмма минем гомер Акчарлак үзәне төсле һаман бер үзгәрешсез чупылт-чупылт килә.

Көтеп-көтеп аптырагач, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Климент Ефремович Ворошилов исеменә үземнең 1937 елда нахак гаепләнүем турында язып, бу кара таптан арындыруны үтендем.
Нинди генә җавап килер икән?
Ярсып, икеләнеп, өметләнеп, хәвефләнеп көтәм.
Көн дә көтәм.
Айлар үтте. Мәскәүдән җавап хаты әле һаман юк. Нинди озын, авыр, газаплы бу көннәр. Нинди генә җавап килер икән?
Этләнә торгач, кырык гариза биреп, авырыйм, дип буфеттан котылдым. Котылуын котылдым, әмма ике меңгә якын акчамны, чакырылмаган «кунак»ларымның түләнмәгән бурычларын түләп.
Кызыл Яр (Петропавловск) каласында алты айлык бухгалтерлар курсы ачыла икән, шунда укырга юнәлтмә алдым.

Көз җитте. Кар аралаш суык яңгырлар башланды. Мин инде, курсларны тәмамлап, райпотребсоюзда бухгалтер булып эшли башлаган идем. Бер көнне шулай лычма су булып, өшеп өйгә кайтып керүем булды:
— Менә сиңа хат,— дип, Маһинур конверт тоттырды. Суыктан өйгә керүгә күзлек парланган, бернәрсә дә күрмим. Конвертны алам дигәндә култык таякларым төшеп китте. Ярый әле сәкегә аудым.
Күзлекне алай-болай сөртеп, күшеккән-тырпайган бармаклар белән көч-хәл конвертны ачтым.
«Күкчәтау өлкә НКВД идарәсе сезгә фәлән көнне, фәлән сәгатьтә фәлән кабинетка килергә куша.»
Утырып тәмәке тарттым. Теге кәгазьне тагын иҗекләп укып чыктым.
Я хода, ни өчен чакыралар мине тагын ул шомлы йортка? Хәерлегәме? Хәерсезгәме?
— Дөп, дөп! Дөп, дөп!
Нинди тавыш?
Чү, бу минем йөрәгем шулай ярсып, сызланып суга, тыпырчына түгелме? Я, раббым, нишлим соң!!!

# Сагыну

Альбомымда күп вакыт узудан инде тоныклана да башлаган бер фоторәсем бар. Ул минем өчен аеруча кадерле. Эчем пошканда, күңелсезләнгәндә альбомны алам, озак карыйм. Уйланам. Сагынам, өзелеп сагынам мин бу рәсемдәге җан дусларны.

Без анда өчәү. Өчәү... Хәзер мин берүзем генә. Япа-ялгыз. Икебез инде дөнья куйды — «дарелфанидан дәрелбакыйга рәхләт әйләде.» Тирән хәсрәт. Ул инде минем күңелдә мәңге бөтәшмәс, кансырап торганчи җәрәхәт.

1956 ел. Көз. Казан. Кар аралаш яңгыр ява. Шыксыз көннәр. Әмма нәкъ менә шушы шыксыз, күңелсез вакыт безнең язмышта иң шатлыклы, якты көннәрнең берсе булды.



*Сулдан уңга: Сөбух Рафиков, Хәсән Туфан, Ибраһим Салахов. Казан. 1956 елның көзе (рәсем беренче тапкыр басыла).*

Без — өчәү. Ләкин без әле бер-беребезне күрмәгән, күрешмәгән. Алай гына да түгел, без әле бер-беребезнең ни хәлдә икәнен дә белмибез — исәнме? Әллә озын юлның ахырына хәтле барып җитә алмыйча, берәр борылышта егылып калганмы? Белми идек әле ул вакытта, белми идек.

Без — өчәү.

Беребез — Котластан, беребез — Норильскидан, беребез — Колымадан.

Унтугыз елдан соң! Бер гомер бит үзе без аерылышканга! Кем уйлаган мондый бәхетле очрашу булыр дип.

Бауман урамы. Матбугат йорты. Якшәмбе саен өмәләр оештырып, унар-унбишәр кирпечне аркалап, һаман югарыга-югарыга ташып салган бина бит бу! Култык таякларыма абына-абына, ашыгып баскычлардан күтәреләм, икенче катка. Язучылар союзы идарәсенә кереп күрешер-күрешмәс, миңа чакыру билеты бирделәр. «Хөрмәтле иптәш, Сезне Татар опера һәм балет театры бинасы ачылу тантанасына чакырабыз». Имәнеп киттем.

Бусы да һич уйланмаган сөенечле очрак лабаса. Мин бит әле ул бинаның нигезен әзерләү өмәсенә катнашкан идем ич. Унтугыз ел элек...

Яз. Пединститут паркындагы мәһабәт юкәләр балга манылган нәни

яфракларын әле яңа гына җәеп җибәргәннәр. Һавада сулап туя алмаслык хуш ис. Бал исе. Без әнә шул зифа юкә агачлары тирәсендәге ямь-яшел хәтфә түшәккә сузылып ятып, соңгы имтиханнарга әзерләнәбез. Шулай беркөн дөньяны онытып, китап-конспектларга мөкиббән китеп, гыйлем эстәгәндә, институт комсомол комитеты секретаре Бәдигов, йөгерә-атлый, мышнап килеп чыкты.

— Кай җәһәннәмгә таралдыгыз, үзегезне эзли-эзли арып беттем,— ди.

— Ни яна?

— Янмый.— Бәдигов юкә агачына терәлде, чыннан да, арыган икән.— Райкомолдан шалтыраттылар, иртәгә сезнең факультет «Бакыр бабай» бакчасына өмәгә барырга тиеш.

— Иртәгә? Иртәгә якшәмбе, аннан үзең беләсең, зачетлар.

— Барысын да беләм. Бу бик ашыгыч эш икән. «Бакыр бабай» бакчасында зур бер бина салачаклар, ди. Менә шуның өчен андагы агачларны казып алып, каядыр күчерергә, ди.

Аптырап калдым. Ничек инде Казанның нәкъ үзәгендәге гөлбакчаны туздырырга? Алай да икенче көнне бөтен факультет белән көрәкләр, ломнар күтәреп, җырлый-җырлый «бакыр бабай» бакчасына киттек.

Унтугыз елдан соң хәйраннар калдым — әкият. Кайчандыр «бакыр бабай» утырган бакча урынында мәһабәт, искиткеч гүзәл сарай. Бинаны әйләнәм — сокланып туялмыйм. Бинаның ике ягындагы куышта ике бөек шагыйрь басып тора. Аларга тәгъзим белән баш иеп сәлам бирдем.

Нәкышләп бизәлгән биек түшәмнәрдә бәллүр чәчәкләр булып кәндилләр балкый. Аларның һәрберсендә күптән-күп шәмнәр яна — мәрмәр баскычларга, залларга, фойеларга нур түгелә. Бәйрәмчә матур, пөхтә киенгән хатын-кызлар, ирләр көлешә-сөйләшә өске катка ашыгалар. Мин дә шул агымда. Әмма мин, үземнең бу күркәм кавемгә ят булуымны күреп-тоеп гарьләнәм һәм каушыйм. Гарьләнәм, чөнки өстемдә таушалган иске кием-салым. Каушыйм, чөнки култык таякларым мәрмәр басмаларда шуып-шуып китә. Гүя алар: «Кара әле, хуҗа, без монда ялгыш килеп чыктык, ахры, бу без йөри торган төш түгел ич!» дип мине шелтәли һәм атлаган саен чайкалып кире чигенә.

Ниһаять, тирләп-пешеп, мең газап белән фойеның бихисап биек ачык ишеге янына килеп терәлдем.

Зур, якты, матур зал. Сап-сары балавыз белән ялтыратылган паркет идән. Стена буйларында кызыл бәрхет белән тышланган аркасыз йомшак озынча урындыклар. Уртада шатлык белән балкыган халык чайкала — биек үкчәле нәфис туфлиләр, ялт-йолт итәкләр, ботиклар паркетка тияртимәс кенә шуа.

Мин ишек кырыендагы йомшак урындыкларның берсенә елышып кыяр-кыймас кына чүктем — култык таякларын аска яшердем. Үзем сокланып фойеда арлы-бирле йөргән шат, пөхтә кешеләргә карыйм. Казанлылар. Мин бит ун ел алар белән бергә кайнадым. Ә хәзер аларның берсен дә танымыйм, алар мине... Кем танысын, ди. Казаннан киткәнемә инде егерменче ел. Ә шулай да, кем белә, бәлки бу күңелле төркемдә мине танучылар да бардыр. Ләкин алар мине шәйләмәгән төсле, мөгаен, читкәрәк авышалардыр. «Халык дошманы» ярлыгы тагылган арестант белән кемнең күрешәсе килсен, ди, бигрәк тә мондый тантанада, халык алдында. Гәрчә нәкъ менә кичә Казанда Союз Верховный судының минем эшне кередән карап, гаепсез дип табып, реабилитацияләнүем турында рәсми карарын алган булсам да... Нәкъ менә шул кәгазь мине бу гүзәл сарайның ачылу тантанасына китерде бит. Әмма хәзер менә Штраус вальсы дулкыннарында рәхәт йөзүче шат казанлыларның миндә ни эше бар? Киресенчә, мин монда ак козгын ич. Сискәнеп киттем, кемдер артымнан килеп кочты.

— Таны, кем бу?

Каушап калдым, бик таныш тавыш шикелле. Үз гомеремдә ишеткән барлык дус-иш, таныш-белешләрнең тавыш төсмерләре колагымнан

зыңлап узды. Ләкин бу йомшак, аз гына моңсу тавышның кемнеке булуын һич тәгаенли алмыйм.

— Я инде, тизрәк әйт!

— Сөббух,— дип кычкырып җибәрдем.— Сөббух Рафиков!

Без кочаклаштык. Күзләргә кайнар яшь тыгылды.

Ниһаять, бу шатлыклы күрешүнең беренче давыллы хисләре акрынлап чигенде — без бер-беребезгә карап тын калдык.

Галимҗан Ибраһимовны тәбрикләү хатына кул куйганы өчен кулга алынып, Норильскига сөрелгәндә ул әле яшь-яшь, коңгырт кара чәчле, зур соргылт күзле, аксыл йөзле, һаман елмаеп тора торган дәртле егет иде. Хәзер инде ир уртасы. Киң маңгаенда — җыерчыклар, күзләрдә — тирән моң, чәчләр сирәгәя төшкән. Әмма аның йөзендә чытыклык, ачу яки ачыну ярсулыгы сизелми. Һаман әле аның иреннәрендә самими елмаю.

— Ибраһим!— Кинәт аның иреннәре тетрәнеп китте, йөзенә күләгә төште, күрәсең, минем артык текәлеп каравым аны борчыды, ул бу караштан котылырга ашыкты. Кулын иңемә салды һәм кычкырып, аз гына шаярткан сыман, сүзгә чакырды.

— Я, Колыма аюы, сөйлә, нинди приискаларда булдың, күпме алтын казып алып кайттың?

— Җитәрлек.— Яртылаш бөкләнеп, бил каешыма эләнгән чалбар балагыма ишарә ясадым.— Тик бер аякны...

Сүземне очлый алмадым, кемдер бүлдерде.

— Менә алар кайда посканнар, ә мин эзли-эзли арып беттем.

Күтәрелеп карадык та сөенечтән сикерешеп тордык. Мин бер аягым юклыгын да онытып җибәргәнмен, күтәрелүгә авып киттем. Хәсән ага Туфан мине кочып алды. Ул арада Сөббух та озын куллары белән безне урады — өчебез бер кочакка сыйдык, бер-беребезнең йөрәк тибешен тыңлап сүзсез калдык.

Җиз кыңгыраулар чыңлады.

Халык тамаша залына агыла башлады. Без дә аңыбызга килдек. Туфан ага иелеп урындык астыннан култык таякларымны алып бирде, бер үземә, бер култык таякларыма карады да нигәдер башын чайкады һәм рәнҗүле елмайды.

— Мөкафәт...

Хәтерем ялгышмаса, 1926 елның кышы иде. Күкчәтау татар мәктәбенең кыйраатханәсенә Казаннан чираттагы татар газета-журналлары килде. Арада «Безнең юл» да бар иде. Зур тәнәфестә кыйраатханә бүлмәсенә кереп, «Безнең юл»ны алып актара башладым. Аннары шатлыкны бүлешергә йөгердем, коридор уртасында малайлар белән көрәшеп яткан Нурины (булачак шагыйрь Нури Арслановны) җилтерәтеп алып килеп, журналның битләрен ачтым.

— Карале, монда менә кемнәрнең шигырьләре, рәсемнәре.

Без арткы партада утыра идек. Дәрес барганда журналны алмаш-тилмәш укый башладык.

Журнал Һади Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы белән ачылган иде. Ике шигъри багана уртасында — шагыйрьнең рәсеме. Ул башын аз гына түбән иеп, уйланып басып тора. Калын кашлар астында зур күзләр, иңнәренә тузып төшкән «тынгысыз» чәчләр. Өстендә — килешле костюм-чалбар, галстук.

Тагын берничә биттән —«Урал эскизлары». Хәсән Туфан шигырьләре. Аның да бөтен буйга төшкән рәсеме шигъри баганалар арасында. Ул да башын аз гына кыңгыр салган. Моңсу күзләр, кабарып торган чәч. Костюм, ак күлмәк.

Такташның шигырьләрен без элек тә газета-журналларда очрата һәм яратып укый идек. Ә менә Хәсән Туфан беренче тапкыр күренә. Шигырьләре дә ят. Рифма, ритмнар башка. Без күнеккән шигъри вәзеннәргә сыймый. Ә шулай да, беренче укудан ук, ул шигырьләр безнең

күңелне үзенә җәлеп итте, хәтта ятланып калды.

...Әллә инде минем уйлар авыргамы,
Әкрендегез инде вагоннар.

Күкчәтау җидееллык мәктәбен тәмамлагач, без Нури белән Казанга киттек. Ул художество, мин педагогия техникумына.

Татар мәдәнияте йортында атна саен әдәби кичәләр уздырыла. Без шул кичәләрнең берсен дә калдырмаска тырышабыз. Алгы сафка утырып, мин менә шунда йотлыгып Һади Такташны, Хәсән Туфанны тыңладым. Тыңлаган саен аларның тылсымлы шигырьләре белән сихерләндем.

«Кызыл яшьләр», «Яшь ленинчы» газеталары һәм «Авыл яшьләре» журналы редакцияләрендә иртәдән кичкә хәтле ыгы-зыгы: укучылар, пионерлар, яшь язучылар килә иде. Ә кичкырын олы язучылар да кереп гәпләшеп, шигырь укып утыралар. Аеруча көтелгәннәре Һади Такташ, Хәсән Туфан, Гадел Кутуй, Кави Нәҗми. Анда-санда Мәскәүдән Муса Җәлил дә килеп төшә. Менә шунда инде мин алар белән якыннан танышып-аралашып киттем. Күкчәтауда вакыттагы өметем — олы шагыйрьләр, язучылар белән танышу, үзем «Яшь ленинчы»да эшли башлагач, әнә шулай тормышка ашты.

Юк, дуслар турында, «күрмиләр» дип көфер уйлар уйлаганмын икән. Бу әкиятләрдәге кебек гүзәл бинаны ачу тантанасы вакытында таныш-белешләр килеп кочып, хәтта үбеп күрештеләр — сөенделәр. Ә радиостудиядәге дуслар: Зәкия Садыйкова, Гайшә Бикмөхәммәтова, Суфия Гыйззәтуллина безне өйләренә кунакка да чакырдылар.

Иртәгәсен кичкырын без трамвайга утырып Яңа бистәгә төшеп киттек.

— Әйдүк-әйдүк, хуш килдегез, хөрмәтле кунаклар,— дип Зәкиянең әтисе белән әнисе ишекне үзләре ачып, куанып, якты йөз белән каршы алдылар.

Без хәл-әхвәл сорашкан-танышкан арада, өстәлдәге күп нигъмәтләр уртасына таҗ булып, әле генә майлы табада чыж-пыж килеп сикергәләгән милли ашыбыз — пәрәмәчләр килеп утырды. Ул да түгел, бу бөркеп, җырлап торган самавыр да үз урынына менеп кунаклады.

— Әйдүк, җитешегез, кунаклар, пәрәмәч ул кайнарында ләззәтле,— дип хуҗалар сыйлый да башладылар.

Баллап-майлап, пәрәмәчләп-коймаклап, каймак салган һинд чәен эчеп, тирләп, хуш булып, рәхмәт әйтеп, өстәл янынан кузгалуга, пианино тавышы яңгырады. Зәкиянең пианиносы да бар икән. Кирә-керешкә абайламаганбыз. Бу музыка тагын кәефне хозурландырды. Милли моң. Анда ниндидер тылсымлы бер могҗиза бар. Ул үзенең беренче яңгырашыннан ук сине әсир итә, канатландыра, биекләргә күтәрә, яки тирән сагыш дәрьясына батыра. Ә безгә, унтугыз ел буе бу моңнан мәхрүм булганнарга, хәзерге яңгыраш күктән иңгән илаһи аваз иде. Зәкия уйный, Гайшә белән Суфия җырлыйлар.

Күңелем йомшак, еларммын, дип
Бирмәдем куллармыны...

— Уф!— Кинәт Хәсән абый тавышлап, авыр итеп сулады. Аннан йөзен ике кулы белән каплады да, ашыгып торып, өй алдына чыгып китте. Клавишлар чәчрәп тындылар. Җыр өзелде.

Мин аптырап, ни әйтергә белми, Хәсән абый артыннан чыктым. Ул ишек яңагына сөялгән дә үксеп-үксеп елый иде...

Еласак та, көлсәк тә, бездән бәхетле кеше юк иде бу көннәрдә. Һәрберебезнең кулында ничә еллар буе зарыгып көткән бәхет ярлыгы — «җинаять дәлилләре табылмаганлыктан, сез гаепсез»...

Без Сөббух белән икебез Казанга вакытлы гына, Союз Верховный судының карарын алыр өчен генә килгән идек. Ә Туфан ага — казанлы,

монда аның үз оясы. Әмма, кызганыч, ул оя аны өнсез, караңгы каршылый. Шуңа күрә Туфан ага фатирына ашыкмый, гел безнең белән.

Нәкъ без Казанга килгән көннәрдә Язучылар союзында татар шигърияте антологиясен татар-рус телләрендә чыгару мәшәкате купкан иде. Аның редколлегия әгъзасы Хатип Госман:

— Сез, егетләр, өмәнең нәкъ өстенә килеп төштегез, афәрин!— диде.— Инде җиң сызганып эшкә тотынырсыз. Әүвәле үзегезгә аеруча хуш килгән шигырьләрегезне сайлап, антологиянең татар һәм рус редакцияләренә тапшырырсыз. Аннан, русчага тәрҗемә итәләчәк шигырьләрегезгә подстрочниклар әзерләгез. Тиз башкарыгыз. Болай да инде соңлыйбыз, кульъязмаларны үткән айда ук нәшриятка тапшырырга кирәк иде. Хәерле сәгатьтә, фатиха!

Билгеле инде, без бу тәкъдимне бәхет санап, сөенеч белән эшкә тотындык. Язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубы көндезләрен буш-тыныч. Без өч аглый-таглый, шунда күтәреләбез дә, өчебез өч өстәлгә утырып, шигырьләребезне сүзгә сүз, юлга юл русчага тәрҗемә итә башлыйбыз. Башта аерым-аерым утырсак та, тора-бара бер өстәлгә — Хәсән абый янына җыелабыз. Ул, үз шигырьләрен ташлап, безнекеләрне рәтләргә керешә.

Төшке аш дип, матбугат йорты буфетында гына капкалап алабыз да тагын бишенче катка күтәреләбез.

Без инде нәкъ теге борынгы әкиятләрдә күңелләргә курку сала торган «барса-кайтмас» юлларыннан, ниндидер могҗиза белән генә исән калып, кире урала алган «бәхетле тазлар». Безнең ул мәхшәрдә күргәнкичергәннәр, һичшиксез, зур бер кәрванга авыр йөк була алыр иде булуын, ләкин нигәдер беребез дә ул «йөкне» бушатырга ашыкмыйбыз. Бары зур өстәл артына тезелешеп утырып, бер-беребезгә комачауламыйча, уйга талабыз.

Сөббух, ябык кулларын өстәлгә җәеп салып, маңгай сырларын челпәрәмә китереп ватып, күзләрен еракка юнәлткән. Хәсән ага нәрсә турында уйлана — минем өчен сер.

Беренче тапкыр укудан ук күңелемә уелып калган «Урал эскизлары»нда:

Эдисонга тиңдәш булыр башын
Нигә инде шагыйрь ясаган?—

дигән гади, тирән мәгънәле юллар бар. Һич ризасызлык белдермим, безнең Хәсән ага үз өлкәсендә һичшиксез Эдисонга тиң була ала. Әмма килеш-килбәте, акыл, уй-фикерләре белән күбрәк борынгы юнан философы Сократка тартым, дияр идем. Киң маңгай, тирән сырлар, чал чәч, яңак сөякләре калкып торган ябык озынча йөз һәм тирән-уйчан күзләр.

— Егетләр!— Кинәт ул сискәнеп, ниндидер авыр уйлардан арынырга теләгәндәй, башын күтәреп, чайкап җибәрде. Чал чәчләр тузышып маңгайга төштеләр.— Бер шигырь укыйм әле сезгә, рөхсәтме?

Һәр икебезгә аерым-аерым карап елмайды, бары тик аңа гына хас ихлас, самими елмаю. Тавыш гадәттәгедән дә йомшаграк, йөрәк авазы:

Тәрәзәңә «җилләр» бәрелгәннәр,
«Сагынма!» дип, янап киткәннәр...

. . . . . . . . . . . .

Алдарсың дип уйлый идемме соң?
Ә син мине алдагансың ич,
Өзелер хәлгә житкән гомеремне син
Каның белән ялгагансың ич!
Соңгы таның беленеп килгәндә дә
Күрешү көнен көткәнсеңдер дә,
Ләкин ирек,
Бераз кичегеп килеп,
Эзләп тапты мине Себердә...

Әйе, ул көннәрдә без өчәү идек, өч дус бергә идек бит. Ә хәзер — ялгыз. Әйтерсең лә, кара урман уртасындагы ялгыз кәккүк. Сагынам, бик сагынам мин ул дусларны һәм өзелеп моңланам.

## Өрәңгеләр яфрак койганда

I

Мәскәүдән ерак түгел, электричка белән ярты сәгатьлек юлда, урман эчендә язучыларның иҗат йорты урнашкан. Һәр ел саен диярлек мин монда ял итәргә, язарга киләм. Языла. Илһамлы, шифалы почмак бу.

Язып, укып арысаң, әйдә, ял итәргә рәхим ит, каршында — кара урманга тиң парк. Мин аллеялар буенча йөреп, түтәлләр каршындагы урындыкларга утырып ял итәм. Табигатьнең гүзәллегенә, камиллегенә карап хәйран калам, сокланам һәм табынам. Менә быел да мин көзен бу иҗат йортына килдем.

Көзнең беренче сулышы сизелә. Һава салкынча, күктә авыр, соры болытлар өерелә, мөгаен, тиздән яңгыр да сибәли башлар. Күпчелек агачлар инде яфракларын коя. Сукмакка алтын тәңкәләр түшәлгән, матур да, йомшак та. Тик ылыслы агачлар гына кара-кучкыл чыклы таҗларын биек күтәреп, шәрәләнә башлаган агачлар арасында масаеп, горур тынганнар.

Чуар келәм өстеннән акрын гына атлап дымлы, бераз төчкелтрәк көзге урман һавасын сулыйм. Рәхәт. Бара торгач, кызыксынып, өрәңге агачы каршындагы бер урындыкка утырдым. Өрәңге инде шәрәләнә язган. Озын, кара ботакларда берәм-сәрәм генә, «әнә өзеләм, менә өзеләм», дип тилмереп җилфердәгән соңгы яфраклар. Мин аларга сокланып карыйм. Бердән, өрәңге агачы Күкчәтау далаларында үсми, икенчедән, нинди гүзәл бу көзге өрәңге яфраклары.

Җил исеп китте, агачлар чайкалды, шаулаштылар. Каеннардагы соңгы яфраклар, кинәт нәрсәдәндер куркышып кузгалган саргылт күбәләкләр кебек, көтүләре белән күтәрелделәр дә ашыгып җиргә кундылар.

Ә икенче агачтагы яфраклар тиз бирешмәде, боргаланды, ботакларыннан аерылмаска тырышты. Ә шулай да, әнә, берсе өзелде, әмма җиргә ашыкмады, очты, хәтта туган өрәңгесеннән дә биегрәк күтәрелде һәм әле бер ягын, әле икенче ягын күрсәтеп чайкалды: әйтерсең лә, канатларын ал, кызыл, алтын төсләргә манган тылсымлы ярканат. Җәйге төсеннән чагыштырмаслык дәрәҗәдә матур, сокландыргыч бу яфраклар — карт өрәңгенең көзге яфраклары.

Ниһаять, шул гүзәл «ярканат» минем алдымдагы урындыкка кунды. Түзмәдем, алыйм дип, кулымны суздым... Һәм туктап калдым.

Нәкъ шул урындык артындагы сукмактан кемдер ашыгып, аксаклап миңа якынлаша иде. Кечерәк чандыр гәүдәле, дала халыкларына хас, кысык күзле, яңак сөякләре аз гына калку. Узып китәр дигән идем, киресенчә, миңа таба омтылды һәм, урындыкны атлап чыгып, мине кочаклады:

— Я алла, кемне күрәм, син теремени...

— Санже!!— Мин дә ашыгып аны кочтым.— Чыннан да, синме бу, дустым Санже?— Күзләремә кайнар яшь тыгылды.

Санже Кәләев белән мин беренче тапкыр моннан кырык еллар элек Топорок колониясендә очрашкан идем. Кырык ел узса да күңелдән китмәслек хәлләрдә...

II

Иртәнге барлауны уздыргач, вахтерларның берсе, яшьрәге, тагын атылып-бәрелеп баракка килеп керде. Бар тавышына акырды:

— Староста, барактагыларның барысын да вахтага! Тиз!

Югары сәкеләрдән барак уртасына идәнгә култык таяклары шалдыр-

гөлдер коелды, гадәттәге сүгенү, кычкыру, ыгы-зыгы башланды.

Вахта алдындагы мәйданга дүртәр саф булып тезелдек. Алда койрыкларына утырган ике аяксызлар, алар артында агач аяклар, аннан сукырлар, саңгыраулар.

Тирә-якта ап-ак кар. Зона аръягында күгелҗемләнеп урман күренә. Тайга. Шул урман артыннан хәзер кан-кызыл булып кояш күтәрелә. Офык та, урман да, янгын кабынган кебек, кызарганнан-кызара бара. Җил юк, коры суык. Тайга «янган» саен суык көчәя бара — «тешли».

Вахтерлар колонна буенча арлы-бирле йөгерә, суганлап, борычлап сүгенә. Җирдә утырганнарны аяклары белән тибеп, басканнарны этеп-төртеп сафларны тигезләргә, колоннаны «тантаналы парадка»— түрәне каршылар өчен әзерләргә тырышалар. Әмма инде күптәннән басып торганга, иске-москыларга гына уранган токтыннар туңа, калтырыйлар. Шуның өчен булдыра алганнары тыпырдарга тырыша, сафны бозалар. Бу хәл вахтерларны бигрәк тә үчектерә.

Ниһаять, вахта будкасының ишеге ачылып, колонна башлыгы чыкты. Ак тун, ак бәрән бүрек, соры киез итекләр кигән озын буйлы, чандыр гәүдәле, чытык чырайлы, урта яшьләрдәге кеше. Ул ашыкмыйча, гәүдәсен төз тотып, хәрби адымнар белән атлап, безгә өтеп карап, колоннаның бер башыннан икенче башына үтте. Ялт борылды һәм кире килеп, урта бер төштә колоннага карап туктады:

— Контрлар, әрәм тамаклар!— Кинәт ул, берәү җилкәсенә сугып җибәргәндәй, аваз салды, без сискәнеп киттек. Әллә инде акылдан шаша? Юк, акылында икән, бер-ике адым алга атлады да сүгенде. Кемнедер эзләгәндәй, алдагыларны сөзеп үтте. Куркып киттек: әллә инде берәребезне карцерга ябарга җыена? Аллага шөкер, тукталмады, тагын эре-эре атлап колоннаның аргы башына үтте, тагын борылды һәм вахта янында команда көтеп басып торган вахтерлар янына килде. Шул ук ачулы тавыш белән боерды:

— Хәзер үк барысын да утын хәзерләргә куарга! Мин аларны бушка ашатып яткырмам.

— Ә... ә... аяксызларны,— диде алдарак торган бер вахтер, тотлыгып.— Аларны кайда, иптәш начальник?

— Кайда?— Тагын гасаби тавыш, ачулы караш.— Кайда, зонада утын киссеннәр. Аяклары булмаса, телләре озын, барыбер халык дошманнары, аналарын... барысын да Мария-Магдалинага олактырырга!— Түрә, тагын ике катлап сүгенеп, безгә карап төкерде дә ашыгып атлап вахтага кереп югалды.

Вахта капкасы ачылды.

Ыгы-зыгы башланды. Вахтерлар аяклыларны бер якка, аяксызларны икенчегә кудылар, тезделәр һәм утын командасын капкага таба алып киттеләр. Ул арада вахтадан автоматларын кулларына алып, этләрен җитәкләп конвой чыкты. Саңгыраулар сукырларны култыклады, алар артыннан үз-үзләрен көчкә йөртүче күтәрәмнәр атлады.

Алдагылар койрыкларында шуышып, без таякларга таянып, вахтер артыннан иярдек, тау-тау итеп өелгән юан-юан нарат агачлары янына барып туктадык.

Һәр дүрт мәхбүскә бер пычкы, тукталмыйча алмаш-тилмәш кисәргә. Балта юк. Зона эченә балта керту — хәтәр. Утынны зонадан чыгарып яралар, өяләр. Озакламый бөтен зонада пычкы тавышы яңгырады, чинады, чырлады. Безне эштән караңгы төшкәч, урманга утын хәзерләргә киткән команда кайткач кына, туктаттылар. Ике токтын анда үлгән. Аларны чана белән тартып алып кайттылар.

Катып, туңып, арып чайкала башлаган идек — баракка кергәч рәхәтләнеп киттек. Кизүләр ике мичкә дә яккан, җылы. Озакламый кечке баланданы китерделәр. Баракта бердәнбер лампа ишек төбендәге баганага эленгән. Аның да куыгы чатнаган, корымланган, булыр-булмас

кына яктырта. Чират зур, ыгы-зыгы. Һәрберсе алдан алырга тырыша.

Ниһаять, минә дә чират житте, инде Колымадан бирле саклап килгән консерв савытыма бер чүмеч баланда аударгач, ава-түнә сәкемә ашыктым. Култык таяклары белән савытны тотып баруы читен бит.

Савыт бушады, корсак жылынды, эч богырдаудан туктады. Ләкин туймады. Тагын шуның чаклы ике-өч чүмеч өстәлсә дә ярар иде.

Әле генә умарта оясы кебек мыжлаган барак тынычлана башлады. Бүлә торган бернәрсә дә юк, мичкәне, чүмечне әллә кайчан алып чыгып киттеләр.

Мин итекне баш очына мендәр урынына салдым да йокларга әзерләндем. Итекне мич янына куеп киптерсәң нинди әйбәт булыр иде дә, ярамый. Хәзер урлап китәләр, аннан яланаяк каласың.

— Иптәшләр!— Тагын ни булган? Торып утырдым, староста эндәшә икән:— Иптәшләр, тыңларга әзерләнегез, тавышланмагыз. Хәзер Конан Дойльның Шерлок Холмс мажаралары турында хикәяләр укуны башлыйбыз.

— Әйдә, әйдә, башла.

— Көтәбез.

— Әй, агач аяк, акрынрак йөр, шыгырдыйсың.

Мин сәкенең кырыена ук шуышып килеп, ишек якка карадым. Лампа һаман үз урынында — баганада кызарып кына тора. Мондый яктыда ничек укыр? Мин уйлап та бетмәдем, түбәндә, өстәл янында утырган староста тамагын кырды.

— Эһем, эһем, йә, башладык. Кичә без «Көмеш кашка»ны башлаган идек, юлга чыкканда өзәргә туры килде. Хәтерегездәдер, полковник Кассның «Көмеш кашка»сы бөтен Англиядә бәйге бирмәс толпар була. Менә бер төнне нәкъ бәйге алдыннан, шул атаклы «Көмеш»не урлыйлар һәм ничә еллар аны хыянәтсез тәрбияләүче, бәйгеләргә хәзерләүче Джон Стрэкерны үтерәләр. Полиция бу четерекле хәлне ачыклый алмагач, телеграмма белән Шерлок Холмсны чакыра. Шерлок Холмс ахирәт дусты доктор Уотсон белән шул сәфәргә чыга.

— Әйе, әйе, хәтерлибез, тизрәк дәвам ит. Кызык, ни булып бетәр икән?— дип аскы сәкедән аны кемдер ашыктырып та куйды.

Мин бу кызыклы хикәяне бала вакытта да, аннан соң да берничә тапкыр укыган идем. Хәзер тыңламасам да ярар иде. Житмәсә күзләрне йокы баса. Тик мине бер мәсьәлә бик кызыксындыра: шундый булыр-булмас яктыда староста ничек укый алыр икән — мәче күзләре түгелдер бит аңарда?

Әмма староста һаман укый бирә — аның тигез, ярыйсы ук яңгырау тавышы безнең почмакка хәтле килеп житә. Шерлок Холмс инде фажиганең ничек чуалуын жентекләп тикшерә башлады... Шул урында күзләрем йомылып, мин йоклап киткәнмен.

...Колонна башлыгы әйткән сүзендә торды, безгә — «халык дошманнары»на тынычлык бирмәде, көн дә эшкә куды.

Мәхбүсләргә бердәнбер юаныч китергән, аларның монда, чәнечкеле тимер киртәү эчендә, жәфалануларын оныттырган нәрсә — староста-ның кичке укулары гына иде. Артур Конан Дойль хикәяләре — алардагы исәпсез күп серле, четерекле вакыйгалар һәм аларны фаш итүче атаклы Шерлок Холмс һәм доктор Уотсон безнең хыялыбызны биләде. Староста гажәеп мавыктыргыч һәм искиткеч катлаулы «Сары йөз», «Бөкре», «Буш йорт», «Алты Наполеон» кебек хикәяләрне укыды. Күбесен мин дә бик кызыксынып тыңладым. Тик әле мин һаман аның бу зәгыйфь янган лампа яктысында ничек укуын төшенә алмый идем. Ниһаять, бер буранлы, без эшкә чыкмаган көнне, мин староста Палатай Николай Исидорович янына кердем. Баракның такта белән бүлеп алынган кечкенә бүлмәсендә тумбочка, озын бер эскәмия, тапчан (анда киез, одеал, мендәр — начальникларча тора!).

Мин кергәндә ул култык таякларын тапчанга терәп, мөгаен, чыгып

китәргә ашыгып, тумбочка өстендә бер исемлек язып утыра иде. Миңа борылды:

— Сезгә ни кирәк?— Киң маңгай, зур борын, ябык йөз һәм эчкә баткан зур күзләр. Болай да кансыз ак бите чытылып китте; күрәсең, минем керү ошамады — эшен бүлдем.

— Сез һәр кичне Конан Дойль хикәяләрен укыйсыз, бүген көндез шул китапны миңа биреп тормассызмы?

Староста карандашын кәгазь өстенә ташлап, миңа гаҗәпләнеп карады.

— Аны мин каян алыйм?

Бу җавапка инде мин тагы да ныграк шаккаттым.

— Нигә, сез һәр кич аны укыйсыз бит?

— Ә-ә, менә нәрсә,— ул кычкырып көлеп җибәрде.— Мин бит аны бары тик күңелдән укыйм.

— Күңелдән?

— Әйе, күңелдән. Монда һичбер төрле китап бирмәгәннәрен белмисезмени?

— Беләм.

— Шулай булгач?

Ул борылып, карандашын алды да янә язарга тотынды. Мин, култык таякларымны рәтләп, чыгарга җыендым.

— Сезнең,— диде ул, кинәт тагын миңа карап,— иректәге һөнәрегез нинди иде соң?

Мин үземнең язу-сызу белән шөгыльләнгәнемне әйттем.

— Менә, шәп,— ул инде миңа таба шуышып килеп, кулымны кысты, елмайды.— Менә очрашу, утырыгыз. Мин дә язучы. Шагыйрь. Украинадан.

Без сөйләшеп киттек. Палатай миңа бу лагерьда бер казах, бер калмык язучысы булуын, анда-санда аларның янына килеп чыгуларын әйтте һәм үзләре белән таныштырырга вәгъдә бирде. Мин бу көтелмәгән очрашуга-танышуга куанып чыгып киттем. Николай:

— Буш вакытта кереп утыр, сөйләшербез, хәзер миңа исемлекне начальникка алып барырга кирәк,— дип култык таякларына үрелде.

Бу очрашудан соң озакламый мин тагын бер бәлагә очрадым: калган ялгыз аягымны да сындырдым. Утын кисеп утырганда, әрдәнәдәге бер юан бүрәнә тәгәрәп китте дә басты. Ул бүрәнәнең тәгәрәп өстемә килгәнен дә күрдем, ләкин торып өлгермәдем, култык таякларымны эзләп харап булдым. Ә биектән авып-тәгәрәп килгән бүрәнә, минем кымшанганны көтмәде. Әле ярый бөтенләй измәде, аяк өстендә тукталды. Тирә-яктагы тоткыннар җыелып, бүрәнәне көч-хәл белән күтәреп, мине тартып чыгардылар һәм санбаракка күтәреп алып бардылар.

Мин анда өч айдан артык яттым. Әгәр инде хәзер, кырык елга якын вакыт узгач, дөресен генә әйтсәм, мин ул чакта санбаракка эләгүемә артык хафаланмадым.

Бәхеткә, аягым бөтенләй үк сынмаган — чатнаган гына булган һәм ул тиз төзәлде. Әмма мин аннан, алда әйткәнемчә, чыгарга ашыкмадым.

Санбарак шул ук зонада, шул ук күп баракларның берсе. Ләкин монда өске сәкеләр юк. Аска төрле үлән-яфрак тутырылган «киез», одеал, мендәр бирәләр. Бу инде менә ничә еллар күрмәгән рәхәтлек — комфорт!

Мине дә шундый урыннарның берсенә китереп салдылар. Инде хәзер, врач килеп карап, аягымны гипска салырлар, дип көтәм. Чөнки аяк чатный, сызлый, үз-үземне кая куярга белмим. Ә врач юк та юк. Мин инде кычкыра, сүгенә башладым. Ул арада бер санитар килеп минем тавышны басты:

— Акырма, врач юк, аны Мариинскига җибәрделәр. Хәзер имче килә.

Баракта иллегә якын авыру мәхбүс ята иде. Күбрәге дизентерия —

эч авыруы белән. Ләкин алар арасында да ятарга була: урын йомшак, эшкә кумыйлар, жылы. Аякның сызлавы басыла төшкәч, йокы да килеп житте.

— Яле, күрсәт аягыңны, ни булган?— Кемдер одеалымны күтәрде.

Уянып киттем. Каршымда ак халат кигән берәү. Буйга яшүсмер егет кебек кенә. Ябык, йөзе ап-ак, ләкин чәче, кашлары чем-кара, күзләре кысык, бит сөякләре калкып чыккан дала халыкларыннан, әллә бурят, әллә якут. Имче диганнәре шул, ахры, одеалны алып ташлап, аягымны карарга жыенды. Аякта кырык тапкыр ямалган, төпләнгән киез итек, аны күргәч «врач» санитарга кычкырды.

— Иван, пычакны алып монда кил.

Санитар Иван — яшь кенә таза егет килеп пиманы кунычыннан башлап башына хәтле ярып жибәрде, чолгауларны сүтте.

— Кая, мондамы?

Әйтеп бетермәде, мин сикереп киттем. Гүя аягыма икенче тапкыр бүрәнә төште.

— Чыда, түз... Иван, тас белән су алып кил!

Мин, кычкырмас өчен, иреннәремне тешләп яттым. Имче аякны тотып, селкеп, капшап карады да янымa утырды.

— Сынып ук чыкмаган, чатнаган кебек. Кузгалмыйча ят, хәзер бинт салырбыз. Исем, фамилияң?

Ул блокнотына исем-фамилиямне язды да, кайдан икәнемне сорады. Анысын да әйттем. Кинәт аның йөзе яктырып китте:

— Кайсы шәһәрдән?

— Күкчәтаудан.

— Шулаймы?— Ул мине кочаклап ала язды, кулымны каты итеп кысты. Без шундук казахча сөйләшеп киттек. Менә бу, хәзер янымда утырган ак халатлы имче (лекпом) теге көнне безнең баракның старостасы Николай Исидорович Полатай әйткән казах язучысы Зәен Шашкин икән. Без ул көнне бик озак сөйләшеп утырдык.

— Туган жирне дә, туган телне дә үтә сагынып калган идем, сезнең белән очрашу көтелмәгән сөенеч булды,— диде ул, аякны юып, бинт белән бәйләп мендәргә салгач.

Моннан соң буш вакыты булган саен Зәен янымa килә башлады. Сөйләшеп туялмыйбыз. Сөйләшә торгач, уртак танышлар, язучыларның хәлләрен белештек. Ул атаклы шагыйрь — казахның Есенины Мәгъжан Жомабаевның шигырьләрен укыды. Үзе прозаик. Алма-Атада берничә китабы басылып чыккан. Язучылар Союзы әгъзасы. Мәскәүдә тарих, философия һәм әдәбият институтын тәмамлаган булган.

— Сиңа нинди гаеп тактылар соң?— дим, сүз арасында.

— Нинди булсын,— ди Зәен, калын кашларын жыерып, йөзен чытып.— Милләтчелек. Мин совет чорында пионерда, комсомолда тәрбияләнгән егет. Аннан мин ярлы казах баласы. Байларга мал багучы булу урынына, совет хөкүмәте аркасында, Мәскәүдә укыдым. Кайдан килсен миңа милләтчелек.

— Анысы алай, ул тамганы барыбызга да бастылар, ә менә син ничек врач булып киттең?— дим. Ярым житди, ярым шаярып.

— Каян врач булыйм мин,— ди Зәен башын чайкап.— Барысы да авырудан башланды. Үпкәм чирле. Өйдә вакытта кымыз эчеп, жылкы ите ашап, далада саф һавада йөреп, саклана идем. Төрмәгә эләккәч, кан төкерә башладым. Хөкем чыгарылгач, мине төрмә больницасына салдылар. Анда озак ятарга туры килде. Чыгарып жибәрмәс өчен, врачлар мине санитар итеп калдырды. Югары белемле булгач, латин хәрефләрен яхшы беләм, даруларны, аларның составын, рецептларын өйрәнә башладым. Булыштылар, үзем дә тырыштым, шуның белән врачлар арасына кереп киттем.

— Имче... монда кил... дару,— ди баракның аргы башында яткан бер авыру.— Зәен әңгәмәсен өзеп, шул авыруга таба китә.

Аяк тиз төзәлде. Әмма Зәен: «Аягы сынган, һаман берекми», дип, аны гел бинтта тотып, язга хәтле чыгармыйча үзендә саклады. Больницаны тикшерергә комиссия килә дигәч кенә, санбарактан чыгарырга мәҗбүр булды.

## III

Санбарактан чыккач, элекке иптәшләрем янына эләкмәдем. Монда да Зәен Шашкинның ярдәме тиде. Ул мине «савыгучылар барагы»на җибәргән. Анда чынлыкта савыкмаслар, инде тәмам бетерешкәннәр җыела. Алар, билгеле, бер төрле эш тә эшли алмыйлар. Әмма баландалары куерак, ятарга урын-җирләре дә бар.

Менә мин шул баракка урнаштым. Монда бер катлы сәкеләр. Алар шыгрым тулган. Күбрәге кузгалмаучылар. Мин зона врачы урынына калган Шашкинның күрсәтмәсе белән килсәм дә, «урын юк», дип озак кына барак төбендә тоттылар. Носилка белән бер мәетне алып киткәч кенә шуның урынына — баракның иң аргы почмагына барып яттым. Яхшы урын — тәрәзә янында.

Хәзер инде кояш күбрәк карый. Көндезләрен кар эри, түбәләрдән тамчы тама. Яз килә. Ичмасам тәрәзәдән табигатьнең алышынуын карап хозурланырга була.

Яттым. Миңа каршы сәкедә берәү ауный. Одеалга төренгән, бите генә ачык. Менә шул йөзне күрүгә, калтырап киттем. Әллә инде бусы да аяк сузганмы? Бит җәенке, үзе карындык төсле сап-сары, күзләр кысылган. Борын почык, иреннәр күм-күк. Хәрәкәтсез. Урынга утырып, култык таякларымны стенага терәп куйыйм дигән идем, алар шалтыр-шолтыр шуып төшеп китте. Бу тавышка теге күршем күзләрен ачты, кузгалып куйды. Юк, әле, тере икән, дип куйдым, күңелдән тынычлана төштем.

— Кайдан?— диде күршем, ярыйсы ук ачык тавыш белән.

— Санбарактан.

— Шашкин ничек анда?

Кара, аны да белә, әллә казах инде? Сынап карар өчен, казахчалап дәштем:

— Хәлегез калай?

— Ә?— ул ишетми калдым дип, ахры, башын суза төште.— Ни дидегез?

— Гафу итегез, мин сезне казах дип уйлап, казахча эндәшкән идем.

— Юк,— ул торып утырды. Шыр сөяк!— Юк, күрше, мин казах түгел, калмык.

Ничек авызымнан чыкканын да белми калдым:

— Санже Кәләев.

Күршемнең карындык бите яктырып киткәндәй булды, кысык күзләр зураеп, гаҗәпләнеп карады.

— Кайдан беләсез?

— Шашкин миңа сезнең турыда сөйләгән иде. Полатайдан да ишеттем исемегезне.

— Менә сөенеч... Әллә сез дә язучымы?

Ул арада ишек ачылып, берничә вахтер килеп керде, без дә сүзләребезне бүлеп, урыннарыбызга сузылдык.

## IV

Ниһаять, тайгага да яз килде.

Кар акрын гына эреп, җиргә сеңеп югалды, озакламый яшел үлән күтәрелде. Зона тышында гына түгел, хәтта зонада да, бигрәк тә, икенче кат чәнечкеле тимерчыбык киртәләре тирәсендә. Тыелган зонага барма-

сак та, читтән карап хозурланабыз. Зона артындагы урманнар да инде яшәрә-яктыра төшкәннәр.

Озак-озак шул урманнарга карап торабыз. Кайвакыт чәнечкеле тимерчыбык белән уратылган зона, манаралар да, анда корулы автомат тотып торган сакчы да югала — без табигать кочагында йөгерәбез, яшел чирәмдә ауныйбыз, кедр агачларына үрмәләп менеп, тәмле, майлы чикләвекләр ашыйбыз. Хыялда!

— Әй контрлар, нәрсә авызыгызны ачып катып торасыз, таралыгыз! Хәзер атам.

Тик торудан иреккән сакчы, автоматын шалтыр-шолтыр китереп, безгә төби башлый. «Кызык өчен» бер очередь бирүе дә мөмкин аның. Рәнжү һәм нәфрәт белән баракларга таба таралабыз. Мәлгуньнәр, табигатькә читтән карап күңелне тынычландырырга да бирмиләр.

Әмма безнең икенче бер юанычыбыз бар иде. Әдәби кичләр. Анда-санда без — Санже Кәләев, Зәен Шашкин, Николай Исидорович һәм мин — я Полатай, я Шашкин кабинасына җыелабыз — казах, калмык, татар, рус әдәбияты классикларын искә алабыз һәм үзебезнең шигырьләрне укыйбыз. Бу кичләр, ничектер күңелгә ял бирә, кайгыларны оныттыра, яшәү көчен өсти, сүнеп барган өметләрне кабыза иде. Кызганыч, бу сөенеч тә озакка бармады.

Беркөнне безнең дүртебезне дә ашыгыч рәвештә вахтага чакырдылар, аннары конвой белән станциягә алып бардылар. Монда инде поезд килеп туктаган икән, безне, вагонга утыртып, Тайшетка алып киттеләр. Анда карцерда йокысыз төн уздырдык. Нәрсәгә, нигә, яхшылыккамы? Яманлыккамы? Иртә белән безне берәмләп яшь кенә, әмма салкын йөзле, усал карашлы хәрби тикшерүчегә алып килделәр. Ул ниндидер бер папканы актарып, бер кәгазьне алды да коры гына итеп:

— Сез лагерьда контрреволюцион төркем оештыруда һәм совет дәүләтенә каршы агитация алып баруда гаепләнәсез. Менә гаепләү акты,— диде.

Мин аптырап, хәлсезләнеп киттем. Култык таякларым ычкынды, дык итеп урындыкка утырдым.

* * *

Әле генә парк өстендә куерып, тулганып, менә-менә салкын тамчылар белән коендырам, дип куркыткан, күзгә шыксыз кара болытлар кинәт таралды. Инде күптән зарыктырган кояш күренде. Шундый якты, шундый җылы, үзе дә безне күрүгә елмая кебек. Тирә-як балкып, матураеп китте.

Без Санже белән йомшак талир тәңкәләр түшәлгән сукмактан, наратлар, чыршылар арасыннан сөйләшеп барабыз, бер-беребезнең хәлләрен сорашып туя алмыйбыз.

Ул да аксый, мин дә, ул уң аякка, мин сулга. Лагерьда урман кискәндә агач төшеп, аның уң аягы сынган. Бик озак берекмәгән, аннан төзәлгән. Әмма ул аягы унбиш сантиметрга кыскарган.

Әнә теге, Тайшеттагы төрмә карцерыннан аерылганга инде бер кеше гомере диярлек була. Кырык елдан соң кеше, һичшиксез, картая. Ә мин менә Санжега карыйм да гаҗәпләнәм. Ул — яшәргән. Чын-чын, теге, лагерьдагы вакыттагыдан ул күп яшь һәм ярыйсы ук матур-күркәм аксакал. Юк, хәзер дә ул сакал-мыексыз, тик йөзе карындык төсле сары түгел, сөйкемле, соргылт күләгәле, кояшлы җирдә торган кешеләр шулай нәзакәтле яна бит. Күзләр элеккечә кысык булсалар да, зур ачылганнар, яктырганнар. Борын аз гына калыккан сыман, иреннәр сусыл, елмаерга гына торалар. Хәрәкәтләре житез. Өстендә корыч төсендәге менә дигән костюм, ак күлмәк, кара күбәләк.

Кинәт ул, нәрсәдер исенә төшкәндәй, капылт борылып миңа карады:

— Ә Зәен Шашкин кайда хәзер?

— О, ул Казахстанның атаклы романчысына әверелде, рус, казах телләрендә күп әсәрләре чыкты.

— Ә хәзер?

— Хәзер ул вафат шул инде.

Санҗе сискәнеп, борчылып туктады:

— Ничек?

— Шул, лагерьдагы чире — үпкәдән...

Без озак кына сүзсез атладык, тынып калып, уртак дустыбызны сагындык.

Асфальт сукмакка чыккач, Санҗе тагын сорау бирде:

— Николай Исидорович Полатайның да язмышын белмисеңме? Әйбәт мәсәлләр яза иде, чукынган.

— Ул инде күп еллар Ялтада тора. Сатирик шигырьләр яза. «Крокодил»ның төп терәге.

— Молодец! Мин шулай булыр дип уйлаган идем. Адресын бир әле, хат язармын.

— Санҗе,— корпус бакчасында торган бер язучы аны күреп калып кычкырды,— тизрәк, сине Элистадан телефонга чакыралар.

Санҗе ашыгып атлап, инде сизелерлек аксап, телефонга китте. Мөгаен, өеннән шалтыраталар. Ул хәзер Калмыкстанның башкаласы — Элистада тора. Бик күп шигырьләр җыентыгы һәм проза китаплары бастырып чыгарган. Калмык хөкүмәте аңа «халык шагыйре» дигән мактаулы исем биргән. Күкрәгендә Монголия хөкүмәте ордены балкый. Шигъри хезмәтен югары бәяләп, Улан-Батырга чакырып биргәннәр бүләкне.

Җил исте, агачлар чайкалып китте, җиргә сары яфраклар коелды. Менә минем каршыдагы өрәңгенең каралган ялангач ботакларының берсендә япа-ялгыз бер яфрак җилферди, чайкала. Җил аны йолкып алырга тырыша, ләкин ялгызак яфрак, үз оясыннан, туган анасыннан — карт өрәңгедән аерылырга теләми. Әле бер, әле икенче якка иелә...

Ләкин рәхимсез көзге җил ялгыз яфракка үчекте, карт өрәңгене арлы-бирле селкетте һәм, ниһаять, теге мескен яфракны ботактан йолкып алып ыргытты.

Алсу-кызыл төсләргә манылган йолдыз — өрәңге яфрагы өзелгәч тә җиргә сыенырга ашыкмады, агачлар арасына очты, калгынды. Ниһаять, хәлсезләнеп, каршымдагы куак арасына төшеп югалды.

Кеше гомере дә нәкъ шулай, өрәңге яфраклары төсле, сызланып, саргаеп, янып-көеп, теләмичә генә өзеләдер. Мөгаен, шулайдыр.

*1957—1981 еллар.*

## Илдар Юзеев

### Нихәл, күрше?

*(Телетамашачы белән сөйләшү)*

Мин дустың да, танышың да түгел,
Аргансыңдыр инде, кич җиткән.
Зәңгәр экраныңда күренермен,
Кермәсәм дә бикле ишектән.
Килдем сиңа бары ике сүзне:
«Нихәл, күрше?» — диеп әйтергә,
Шигърияттнең бер илчесе булып,
Сөенеп һәм көеп әйтергә.
Тынгысыз һәм җайсыз Җир йөзендә
Бергә яши торган кешеләр —
Телибезме, теләмибезме,—
Без һәммәбез якын күршеләр.
Хәлең ничек?
Сөенеч-шатлыкларың
Котлы булсын! Әйдә, күрешик!
Хәсрәт-бәлаләрең газапласа,
Уртаклашыйк, бергә бүлешик!
Ачык әле җанны бары икәү
Хәл белешкән чакта, бу мәлдә:
Әти-әниләрең, туганнарың,
Күрше-күләннәрең ни хәлдә?
Берәр күршең, тормышыннан бизгән,
Өметен өзгән, бәлки, кем белгән...
Иң-иң якындагы кешең синнән
Таш диварлар белән бүленгән.
Әллә инде күптән онытылганга,
Иштелмәгәнгә күрше ягыннан,
Авылдагы «Нихәл, күрше?» дигән
Җанга рәхәт сүзне сагынам.
Бер үк планетада диеп әйтмим,
Бер подъездда күпме яшибез,—
Күңел өчен генә булса да бер
«Нихәл, күрше?» диеп дәшмибез.
Нигә тансык хәзер күркәм гадәт:
Хәлгә керү, олы-кечелек?
Күрше белән күрше аңлашмагач,
Ничек аңлашсын, ди, Кешелек?

---

Илдар ЮЗЕЕВ *(1933) — шагыйрь, драматург, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән егермедән артык шигырь һәм пьесалар китабы авторы. ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт һәм М. Җәлил исемендәге комсомол премияләре лауреаты. Казанда яши.*

Туслардан да бигрәк, дошманнар күп,
Аерым-аерым яшәр чак түгел...
Һәр адымның кайгы-хәсрәте бар:
Берәүнең дә хәле шәп түгел...
«Күрше хакы — алла хакы!» дигән
Изге мәкаль бара искереп...
Һәлакәткә таба илтер үзен,
Күршелектән язса Кешелек,—
Кешелектән язса Күршелек!
...Сау бул, күрше...
Борчып китте, диеп,
Гаеп итмә...
Яшә сәламәт!
«Нихәл, күрше?» диеп дәшкәннәргә
Миннән сагынып-сөеп сәлам әйт!
Бәла-кайгы җир астына китсен,
Сөенечләр күккә ашсыннар,
Илләр, планеталар бер-берсенә
«Нихәл, күрше?» диеп дәшсеннәр!
Тыныч йокы, матур төшләр теләп,
Зәңгәр экраныңнан югалам...
Шигъриятнең бер илчесе булып,
Ят илләргә карап юл алам...

*

Соңгы егет китте авылдан...
«Бәхил бул, авыл!»
Бәхилләрме, юкмы?

Карт топольнең хәлсез яфрагында
күз яшеме, чыкмы?

Соңгы егет китте авылдан...
«Бәхил бул, авыл!»

Озатырга
таң нурында
тып-тын зират калкып чыкты...

Менә ул бәхилләрме, юкмы?

## Үзгәрүчеләргә

Юк, ышанмыйм сезгә, нык ышанмыйм,
Җыелыш саен сүз алучылар,
Өстән «Үзгәрергә!» дию белән,
Минутында «үзгәрүчеләр»...
Мин ышанам сезгә, нык ышанам,
Ялгыш өчен сызланучылар,
Йөрәкләрен янар эшкә биреп,
Беләкләрен сызганучылар,
Сызыла-сызыла, кайчак өзелә-өзелә,
Авыр-авыр үзгәрүчеләр!

## Аксакаллар мәҗлесендә булдым

Әлегә кадәр юкка мин үземне
Акыллы дип фараз иткәнмен,
Аксакаллар мәҗлесендә булдым:
Мин шактый ук надан икәнмен.
Әлегә кадәр юкка мин үземне
Хисле адәм диеп йөрткәнмен,
Аксакаллар мәҗлесендә булдым:
Мин хискә дә ярлы икәнмен...
Көчсезлегем калкып чыгар диеп,
Әйтә алмый калдым сүземне,

Әмма шуны аңлый алуым белән
Көчле итеп тойдым үземне.
Тарих бабай үзе карап тора
Зирәк аксакаллар аркылы,
Мөлдерәмә ялыләр булып тула
Халык хисе, халык акылы.
Бөек аксакаллар мәҗлесендә
Боек күңелем калды хуш булып...
«Без китәбез...»— диеп җырладылар...
«Без калабыз!»...— дидем, кушылып.

## «Татар бавы»

Кама буйларында бау ишәләр.
Бугазымда авыр төер бар:
Бик якында гына Маринабыз [1]
Соңгы сулыш алган бер өй бар.
Кемдер уйлый: «Элмәк киюенә
«Татар бавы», имеш, гаепле»...
Вакыт үзе әйтер хакыйкатьне!
Нахак сүзгә халык лаекмы?.
Нәселем минем өзелерлек түгел,
Тамырлары — ерак, алыстан:
Чулман буйларында иген иккән,
Суга юкә салган, бау ишкән...
Нинди ачы җилләр исмәгән дә,
Үрешләрен кемнәр кисмәгән,
Тарих бавын җигелеп бергә тарткан,
Әмма комнан аркан ишмәгән.
Упкын-чоңгыллардан үткән чакта,
Өзелсә дә камыт баулары,
Ат урынына тарткан үз язмышын,
Сызласа да йөрәк майлары...
Идел-Чулман кичкән, ишкәк ишкән,
Язмышы да баудай үрелгән...
Татар җайдаклары гомум яуда
Париж урамында күренгән.
Бабаларым озак еллар ишкән
Ул бау иш янына куш булган:
Октябрьдә бер көн «Аврора»ның
Арканына килеп кушылган.
Нәселем минем күп дәһшәтләр күргән,
Баулар белән бергә җыр үргән,
Аның нинди җырлар үргәнлеген
Сорагыз сез Муса Җәлилдән!
Төрле телдә җырлап яшь аналар
Өмет баглап бишек асканнар,
Илбасарлар, баудан элмәк ясап,
Зояларны дарга асканнар.
...Авыр бер чор, сугыш гарасаты
Маринаны монда китергән.

[1] Рус шагыйрәсе Марина Цветаева гомеренең соңгы айларында Алабуга шәһәрендә яши.

Хәзер кемне, кемне гаепләргә.
Сорыйк әнә Кама, Иделдән...
Кем ишсә дә, бауның милләте юк,
Сылтамагыз аны милләткә!
Һәрбер телдә бер сүз: *шәфкатьсезлек*
Шагыйрәне илткән элмәккә.
Кама буйларында бау ишәләр,
Өмет баглап ага сулар да,
Мин дә кушылам: бишек бавы үрәм
Шигъри җанлы нарасыйларга.
Бугазымда авыр бер төер бар:
Калды инде фәкать сызларга...
Өметсезгә ярдәм бавы бирик,
Бирмик аны шәфкатьсезләргә!

## Егерменче гасыр тәкбире

Тынычлык юк — бар Җиһанда,
Тынычлык юк — таңнарда,
Тынычлык юк — Җирдә, Күктә,
Аңнарда һәм җаннарда.
Һәлакәттән кешелекне,
Җирне тотып калырлык
Тик бер көч бар, илаһи көч:
Сабырлык...

Урамнан-урамга йөрим,
Тәкбир әйткән картлар күк:
Шигъри догам бу дөньяны
Һәлакәттән саклар күк:

И табигать, бир сабырлык
Тынычсыз улларыңа,
Улларыңның нәфрәт белән
Сузылган кулларына!
И табигать, бир мәрхәмәт
Җиргә, Суга, Галәмгә,
Ультиматумнар, ноталар
Яза торган каләмгә!

Иллләрдән-илләргә йөрим,
Тәкбир әйткән картлар күк,
Шигъри догам бу дөньяны
Юк булудан саклар күк:

Үз-үзеңне харап итмә,
И кешелек, кил аңга:
Бердәнбер аң икәнеңне
Онытма бу Җиһанда!

Калалмабыз, юк, күкләргә
Кулларны сузып кына...
Коткарыйк без үзебезне
Көрәшкә чыгып кына!

Картлар сабырлыгын алып,
Кул тотышыйк яшьләр күк:
Аңнар, җаннар аңлашсалар,
Яшәр Җир һәм яшәр Күк!

# Кадыйр Сибгатуллин

*

Еракларрдан дәшеп үзләренә
янып тормый ярда утлары:
пристаньнар бергә җыелганнар,
киткән инде пароходлары...

Үтте җәйләр.
Пароходлар белән
кавыштырыр кабат яз гына.
Тынды Кама...
Тынып калды ярлар...
Ял итсеннәр инде аз гына.

Кайсы ярдан килгән монда кайсы,—
исемнәре ачык язылган.

Яшәү гамен төяп килгәндер күк
һәр пристань үзенең ярыннан.

Сыенгандыр кеше язмышлары,
айлы төннәр белән бәйләнеп...
—Я киткәндер мәңге кайтмаска дип,
я кайткандыр бераү әйләнеп.

Кемнәрнедер алар аерганнар...
Кемдер тапкан...
Кемдер кавышкан...
...Пристаньнар чайкалышып тора
җәйләр буе җыйган сагыштан.

## Кеше

Ач та булыр.
Ялангач та булыр.
Ышыкланырга булмас урыны да.
Уйлар кеше,
хыялланыр кеше
патша сарайлары турында.

Авыру булып яшәр.
Тоткын булыр.
Гомере буе кеше кол булыр.
Котылырга аны чакырып торган
хыялында берәр юл булыр.

Яратмаган кеше белән торыр.
Туры килер начар хатынга.
Хыялында хур кызлары булыр —
мәхәббәтне чынлап татырга.

Түзәр кеше.
Чыдар гомере буе.
Гомере буе шулай яшәр дә.
Каршысында аның үлем торыр,
хыяллары булыр яшәүдә!

*

Мин икенче кабат яшим бугай:
Җире бүтән,
        һава,
                күн бүтән.
...Мондый түгел иде минем гомер,
бер яшәгән идем мин күптән.

Без үлчибез кеше гомерләрен
анасыннан туган көненнән.
Үлә, диләр, кеше бер мәртәбә,
ничә тапкыр туа?—
Кем белгән...

---

Кадыйр СИБГАТУЛЛИН *(1942)— шагыйрь, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән дистәгә якын шигырь китабы авторы. Чаллыда яши.*

Бер ялгышсыз гомер итеп була.
Бүген дә бар әле андыйлар.
Бу яшәүнең шартлы икәнлеген
андыйлар да бик шәп аңлыйлар.

Аңлыйлар да...
Ләкин ялгышмыйлар.
Ялгышларның хакы югары.
...Горур булып,
ихлас булып йөрдек,
ялгышлардан котылып булмады.

Кемгә ялгыш,
безгә дөрес иде.
Шуны сорыйм әле язмыштан:
башкалары инде кабатланмас,
тик аерма син бер ялгыштан.

«Бу дөньяның бөтен мәшәкате,
авыр йөге безнең җилкәдә»,
дип уйлыйк без,
уйлыйк соңга кадәр...
һәм ышанып китик киткәндә.

## Көчсезлегең белән...

*Көчле көчсезгә мохтаҗмыни?*

Канада шагыйрәсе Рина Ланье.

Көчлеме мин,
көчле түгелме мин —
бу турыда түгел уйларым.
Яратырга хакым булган чакта
булмас минем синнән туйганым.
Баштанаяк гашыйк сиңа, димим,
гашыйклардан инде көнләшмим.
Баш бирмичә чапкан хисләремне
тыярга дип тә мин көрәшмим.
Су буенда суга карап үскән,
моңга чумган ялгыз тирәк син.
Сагышларың белән,
моңың белән,
ялгызлыгың белән кирәк син.
Иреннәрне кыймылдатып кына
әйтеләсе гади сүзләргә
мохтаҗ бит син,
мохтаҗ — күңеленә
карап тора торган күзләргә.
Тиңнәремне табам, дигән кеше
гел югалта бара тиңнәрен.
Миңа кирәк зәгыйфь канатларың,
сиңа кирәк минем иңнәрем.
Уйларыңа кирәк минем уйлар.
җаннарыңа кирәк җаннарым.
Мин бит инде сине күргәнче үк
шундый итеп сине аңладым.
Күңелеңне гөрләвекләр итеп
эретергә килгән бер яз мин.
Көчледер мин,
шуны раслар өчен
синең көчсезлеккә мохтаҗ мин.

## Хәзергә исән[1]

*«Өегез җылымы, тормышыгыз аруммы?»*

Ф. Кәрим хатыннан.

Синең хатларны укыйм да кабат,
(бик таныш инде алар, танышын),
ерактан карап күргәндәй булам,
тойгандай булам гомер агышын.

Булгансыңдыр, дим, шундый ук Фатих,
шундый ук Кәрим — нинди хатыңда.
Хатлардан гына аңлавы кыен
бик күп нәрсәне кеше хакында.

Сорауларың күп өең-җиреңә,
бик аз язасың үзең турында.
Сораулар алар шундый ук, Фатих,
сезнең буынга, безнең буынга.

Өебез җылы, тормышлар ару.
Суыклар кайчак зәһәр, чатнама...
Сезнең хатларны кабат укыйбыз
өйләр суынып туңган чакларда.

...Син дә азагын күрмәдең аның,
сугышлар инде беттеме, дисәң,—
җавап бер генә: сугышлар бара,
үзебез, Фатих, хәзергә исән...

*

Бер күкләргә менеп төшсә кеше,
түзә алмас күксез аннары.
Җирдә үләр үзе,
җирдә калмас
андыйларның әмма җаннары.

## Хөкемдар

Исәпләми яшәп булмый икән
гомерләрнең үткән һәр көнен.
Мин бик озак көтеп тордым бугай
кешеләрнең гадел хөкемен.

Йөриләрдер мине уйлап дисәм,
берәүнең дә миндә эше юк.

[1] Ф. Кәрим фронттан җибәргән хатларында үзе турында һәрвакыт «үзем хәзергә исән-сау» дип яза.

Кайвакытта кирәк гаепләүче,
гаепләргә мине кеше юк.

Көтмәгәндә сине гаеплиләр.
яклаучы юк шундый чагында.
Гомер буе икесен дә бергә
тота алмыйм шул мин янымда.

Инде үземә алдым ул эшләрне,
барганым юк судья-казыйга.
Үзеңне үзең хөкем итеп кара —
ансат түгел андый вазифа.

Көне-төне язып кына тора
пәйгамбәрләр ике иңемдә:
гөнаһлар да табыла,
дөнья булгач,
савaплар да була минем дә.

Кем гаепләр мине,
кем яклар дип,
як-ягыма инде карамыйм.
Кирәк чакта яклыйм
һәм гаеплим,
карарын да чыгара барам мин.

Үзеңне үзең хөкем итү авыр...
Минем моңа тулы хакым бар.
Шунысы дөрес:
хөкем гадел булыр,
мин ышанам сиңа, хөкемдар!

❀

Көннәре Кояшлы түгел,
төннәре Айлы түгел.
Гомернең шундый вакыты —
күңелләр җайлы түгел.

Сызланып ала, сыкрап,
суынып китә кинәт.
Йөрәккә җылы кирәк бит,
йөрәккә җылы кирәк.

Учакларда яна утлар.
Ник суык ялкыннары?
...Безгә кирәкләре — ерак,
җылытмый — якыннары.

*1986—1987.*

# Газинур Моратов

## Алма-риваять

триптих

I

Юк, ышануым түгел бу
Ырымга, я аллага —
Җир-әнкәбез дә, мөгаен,
Яралгандыр алмадан.

Ул чакта да Җир-алмага
Ят куллар үрелгәндер.
Ә ул карышкандыр...
Шуңа
Оҗмахтан сөрелгәндер.

Утлы тәмуг газабына
Ничек түзгәндер җаны?!
Оҗмах кануннарын бозган
Адәм белән Хаваны —
Гүя эмигрантларны —

Үзенә сыендырган ул,
Бәйсез бер дәүләт сыман.

...Һәм чәчкәгә узгандыр Җир
Гашыйклар карашыннан.

Ышануым түгел һич тә
Ырымга, я аллага —
Җир-әнкәбез дә, мөгаен,
Яралгандыр алмадан.

Фал ачуым да түгел бу —
Болай да һәрни анык —
Бер алманы юкка гына
Бишкә бүлмәгән халык.

2

«Бер алманы бишкә, әй, бүләек»...
Заманага сабак-гыйбрәт булсын —
Трояны[1] барып күрәек.

Трояны барып күрәек бер,
Барам дисәң, җае табылыр.
Антик чорның шәһре Болгарына
Сәҗдә кылып кайтыйк, табынып.

Чал хәрабә каршысына басып,
Йөз гасырга, әйдә, тын калыйк,
Һәм сөңгегә җан-калканны элеп,
Тутык кылыч белән чаң кагыйк.

Тапталудан ташка әверелгән
Йөрәкләрне тыңлыйк...
И күңел,
ни диярсең?—

Һәр хәрабә — музей,
Һәр җинаять — экспонат бүген.

Ә без — турист: иңдә фотоаппарат —
Гүя хәтер!
(Шундый гасыры!)
Җирдә, бәлки, һәр хәрабә — зират,
Һәр җинаять — кабер ташыдыр.

...Ә алма — сау: орлыкларын тиран
Нейтрон үлем итеп чәчәдер.
Вәхши өчен һәр хәрабә — һәйкәл,
Һәр җинаять, бәлки, чәчкәдер.

Бу кешелек гамьсез балачагын
(Ут-күз белән шаярган чагын!)
Хәтерендә гүя шулай саклый:
Троя... Сталинград... Нагасаки...

---

[1] *Риваятьләр буенча, Троя һәлакәтенә алма «сәбәпче булган». Автор.*

---

ГАЗИНУР МОРАТОВ *(1959) — яшь шагыйрь. «Җир хәтере», «Мин дөньяны тыңлыйм» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Бурзайларга ташлап кына
Үтереп булмый аны —
Материалист Акылны,
Материалист Аңны:
Җирдә даһи туып ята —
Тулгак тота җиһанны.

Җирдә даһи туып ята —
Әйтерсең күктән иңә,—
Пешкән алма күк, чеменнән
Өзелеп төшә җиргә.

Төн уртасында атылган
Йолдыз шикелле янып.
Күктән «иңеп» пәйда була
Төп законы дөньяның.

Алмага алма тартыла,—
Даһилык — гадилеккә.
Алмага алма тартыла,—
Гадилек — камиллеккә.

Алмага алма тартыла —
Чебеннәр — тирес-ашка.
Алмага алма тартыла —
Икар җаннар — Кояшка.

Шундый гади! Әйтерсең лә,
Камиллек күктән иңә —
Пешкән алма күк, чеменнән
Өзелеп төшә Җиргә.

## Түбә

*Төзүче Марат Бибишевка*

Өйләр сала халык, өйләр сала —
Агачтан да сала, таштан да...
Чулман аккошыдай ап-ак калам
Җырга әверелгән, дастанга.

Өйләр сала халык,
өйләр сала,
Чулман гына, никтер, моңая,
Өйле булсын һәркем,
көйле торсын —
Заманасы көйсез болай да.

Өйле булсын һәркем...
Хыялыбыз
Аккош булып күккә ашканда,
Җисеменә лаек исем тиеш
Һәр калага, һәрбер дастанга.

Кемнәр анда «төзәтмәләр» кертә
Халык язмышына, тарихка?!
Патшаларын алла итеп чөйгән
Заманнардан гыйбрәт алыйк та,

Җисеменә лаек исем кушыйк —
Лаек исем — җырга, кешегә.
Хакимен дә, хәкимен дә заман
Бәяләсен карап эшенә.

Ни кылсак та, әнә, Чулман шаһит,
Идел шаһит...—
Алар күп күргән...
Баш очында түбәң булу кирәк,
Түбәң булу кирәк —
Үз түбәң.

Баш очында түбәң булу кирәк.—
Катмарлы да, яшәү, гади дә...
Йортсыз-җирсез тома сукбайлыкта
Гомер иткән азмы галиләр?!

Ә без бүген килеп баш иябез
Алар мирас иткән байлыкка.
Фатирлы да, хатынлы да килеш
Мөмкин әле яшәү
Сукбайлыкта.

Ни кылсак та, әнә, Чулман шаһит,
Идел шаһит...—
Алар күп күргән.
Бу дөньяда түбәң булу кирәк,
Лаек түбәң булу —
Үз түбәң!

## Игъланнар

...Муенчагын өзеп этләр кача —
Этләүдәнме тели котылырга?..
Ә мин игълан укыйм «Атналык»тан:
— Эт югалды! —
Колли токымыннан.

Эт югалды! —
Гибрид шәҗәрәле!
Холкы күндәм иде, нәсле — затлы!
Эт югалды! — табышыгыз, зинһар?!
Эт югалды! — «Платон» кушаматлы!

...Платон белән бәхәсләшми генә
Мин игъланнар укыйм «Атналык»тан:
— Гражданнар, табышыгыз, зинһар —
Гаип булды акчам... алтын алкам!

Дөнья белән бәхәсләшми генә
Мин игъланнар укыйм «кырын ятып»:
— Чын ир белән телим танышырга —
Бирнәм — фатир булыр, юрган-ястык...

Аңламассың...
Соңгы мода кебек
Бу дөньяның холык-фигыльләре.
Хатыннарын ташлап ирләр китә,
Шагыйрьләрне ташлап — шигырьләре.

Аңламассың...
Сальери күк иске
Бу дөньяның гайбәт-доноспары...
Зынҗырларын өзеп җырлар кайта —
Сынмас Муса кебек намуслары.

Җырларның да, әйе, намусы бар —
Себер киткән башы җырларның да.
Чылбырларын өзеп чорлар кайта —
Тыелганы була чорларның да.

Табу салсаң әгәр чын тарихка
(Чынлык та, һай, кайчак хәтәр әле),
Дастаннардан алыплары качар,
Кешеләрдән качар хәтерләре.

...Ә сезгә мин, ханым, бәхет телим —
Танышыгыз, сөеп кавышыгыз...
Җирдә бәлки шундый игъланнар бар:
— Вөҗданымны җуйдым —
Табышыгыз?!

# ПРОЗА

## Җәмит Рәхимов

# КЫЯДАГЫ ЧӘЧӘКЛӘР

РОМАН

### 1



Аитов кайтып кергәндә идарәдә берәү дә юк иде. Яңа тупланып килгән коллективта болай да бармак белән генә санарлык хезмәткәрләрнең кичке биш тулуга кайтып китүләре көндез үк сөмсере коелган Әсфәндиярның кәефен тәмам кырды: соры күзләренең карашы кургашын белән өртелгәндәй авырайды, ике як яңагындагы орылары бүртеп кызарды. Коридорга чыгып, аның ике ягы буйлап тезелгән дерматин тышлы ишекләрне тартып-тартып караса да, усал сүз әйтеп ачуын басар кеше тапмады. Шунда гына бүген шимбә көн икәнен искәреп алды, сүрелә төшеп, янә бүлмәсенә кайтты. Куныччына кадәр мәте каткан күн итекләренә карап-карап торды да, аларны салып, ишек артындагы аулак почмакка томырды, диван астыннан киез чүәкләр алып киде. Аннан, инде тагын нишләргә дигәндәй, идән уртасында басып калды. Аның каланчадай калку, эре сөякле гәүдәсе, әйтерсең, бөтен бүлмәне тутырды. Шул рәвешле бераз басып торды да, кинәт исенә килеп, бүлмәдәге бөтен лампочкаларны кабызды — эшләсә-эшләмәсә дә, кабинетның якты булуын ярата иде Әсфәндияр Аитов.

Кабинеты гөлт итеп яктыргач, күңеле тынычлангандай булды. Өстәле янына килеп, аның тартмасын ачты, ачык кызыл бизәкле калай савытны алды да селкеп карады — эчендә таныш тавыш чыгарып, чәй бөртекләре кыштырдады. Монысына тагын күңеле булды. Гадәте — вакыты барында, куе итеп, зәгъфран сарысы булып чынаякка сыланырлык кара чәй эчү. Астагы киштәдән ялтырап торган электр чәйнеге чыгарды, аңа графиннан су салды да утка тоташтырды.

Аяклары аны ирексездән бөтен стенаны тутырып торган СССР картасы янына алып килде. Аитов — илебез киңлекләрен буйга да, аркылыга да кат-кат йөреп чыккан кеше. Карашын төрле төсләргә буялган өлкә-республикаларның, картага кызыл түгәрәк итеп кенә төшерелгән олы-олы калаларның кайсына гына төбәмәсен, искә төшереп юанырлык хатирәләре, төрле мәзәк хәлләргә дә, аяныч вакыйгаларга да бай истә-

Җәмит РӘХИМОВ *(1935) — прозаик. «Өлешемә тигән көмешем», «Тәвәккәл таш яра» һ. б. китаплар авторы. Татарстан АССРның атказанган культура работнигы. Лениногорск шәһәрендә яши.*

лекләре житәрлек. Шулай да бу көннәрдә үткәннәргә сәяхәт ясап торыр вакыты юк, карта янына бастымы, күзләре гел бер төбәкне колачлый. Аны һәр кичтә карта янына тартып китергән, бөтен уй-исәбен, игътибарын җәлеп иткән нәрсә — Себер түреннән Иделгә кадәр сузылган кызыл сызык. Берәүләргә кәгазьгә төшерелгән каләм эзе генә булып тоелган шушы билге — Әсфәндиярга, ул җитәкли торган меңләгән төзүчеләргә олы бер мәшәкать. Юк, гади мәшәкать кенә түгел, моңа кадәр дөньяның бер генә почмагында да күренмәгән гигант төзелеш, партия, халык, туган ил ышанып тапшырган зур әманәт. Менә шуңа да, кабинетында ялгызы калдымы, ниндидер бер кодрәт аны шушы карта янына тартып китерә. Дөрес, нефть яки газ кудыра торган торба юлларының үз гомерендә озыннарын да, кыскаларын да салды Аитов. Әмма бу кадәр дә юанын, меңнәрчә чакрымнарга сузылганын, континентларны кавыштырган колачлысын күргәне юк иде. Әнә бит эченнән шук малайлар йөгереп йөрешле торба юлы, Обь елгасының урта агымыннан башланып, Идел ярына барып җитәргә тиеш. Турыга гына сузылса, бер хәл иде, бормаланып-бормаланып, дистәләрчә дәрьяларны, гомердә кеше аяк басмаган сазлык-баткакларны, кара урманнарны, таучокырларны, тимер юлларны, тагы әллә нинди киртәләрне кисеп үтәчәк ул.

Әсфәндияр күрсенде, карта өстенә төшкән шәүләсенә күз салды. Шул тонык шәүләгә карaганда, баһадир гәүдәсе мескенләнеп калган иде бу минутта. Күрсенерсең дә, мескенләнерсең дә. Әнә шул коточкыч зур нефть үткәргечен төзү мәшәкате йөкләнде аңа. Моңа кадәр дә эше ансаттан түгел иде түгелен — Уфадагы иң эре төзү тресты белән җитәкчелек итте. Шулай да анда өйрәнелгән коллектив, күнеккән кешеләр, масштаб бөтенләй башка — үз трестыңа билгеләнгән участок өчен генә җавап бирәсең. Монда исә трасса буйлап җиңел машинада үтсәң генә дә әллә ничә көн кирәк булачак. Аннан төзүчеләр илнең бөтен почмакларыннан җыелачак ич. Хәер, нигә зарланырга? Идарә начальнигы камытын көчләп кидермәделәр лә. Алты дистәне тутырырга калган дүрт-биш айны Уфада утырып та уздырган булыр иде. Партия чакыргач, ил кушкач, чыгымчылап торыр ара юк: трест мәшәкатьләрен калдырды да Төмәнгә килде менә, эшләрне оештырып яткан көне.

Ә бит Себер җире — бөтенләй башка. Алтмыш градуска җиткән кышкы чилләләрен, мул сулы елгаларын күздә тотуы түгел, котны алганы — сазлыклар. Җитмәсә, алар кеше яшәми торган тайга чытырманлыклары буйлап сузылган. Җәяүле дә уза алмаслык баткаклыкларның барын бергә кушып санасаң, кот очарлык сан килеп чыга — ул кырыс чакрымнар саны меңгә җыела. Әйе, авыр юл бу, мәшәкатьле, зур чыгымлы юл!

Бүген ул Төмән белән Курган арасындагы мөһим бер участокта булып кайтты. Вак-төяк сазлыкларны, кибеп җитмәгән урыннарны исәпкә алмаганда, трасса юлы инде коры диярлек. Басуларда уҗым калыккан, бодай, борчак ише сабан ашлыклары күтәрелеп килә. Урманарәмәләр зиннәтле киемнәренә төренгән, дөнья чәчәккә күмелгән. Җиң сызганып эшләр өчен иң кулай чак җитте. Ләкин эш акрын бара — бригадалар оешу чорының кыенлыгыннан котылып бетә алмыйлар. Алай да Зәйсудан килгән бер колоннаның эше ошады идарә начальнигына. Башлыгының фамилиясе кем соң әле? Усанов? Юк, татар егете... Хисамов бугай. Трассага чыкканнан бирле норманы үтәп бара. Юк шул, һәркайда да алай түгел. Бер урында җир казучылар тоткарлаca, икенчесендә монтажчылар... Туктале, оешу чоры чире генәме соң бу? Һәрвакыт шулай бит: бригадалар арасында килешеп эшләү, фикер уртаклыгы житенкерәми. Шулай булмыйни, җир казучылар бер трестка буйсынса, монтажчылар — икенчесенә. Изоляцияләүчеләр исә бөтенләй башка идарәнеке. Шул таркаулыктан чыгу максаты белән төзелде дә бит инде яңа идарә! Оешуын оешты, тик хәзергә кәгазьдә генә дияр-

лек, ә эшләр һаман да искечә бара. Болай ярамый, ни дә булса уйларга, оештыру эшләрен ныклы бер кулга алырга кирәк. Ләкин ничек?

## 2

«Картаеп акылга туймаган дивана»,— дип тиргәде ул үз-үзен. Ял сәгатьләрендә эш турында уйламаска, дип күпме сүз биргәне бар. Хәер, бөтен тормышың, бөтен барлыгың хезмәткә бәйле булгач, гаҗәпмени? Хаклы, мең хаклы Сөембикәсе. Дәшмәс кенә көндәм хатын югыйсә. Ул булып ул түзмәгәч инде. Тукта, ничек дигән иде әле? «Мин дә ир белән яшәдем, имеш»... Йөрәгенә төшмәсә, шулай диmi бит инде ул. Чыннан да, бөтен гомере өй саклап, балалар үстереп үтте хатынның. Гаиләсе янына кунакка кайтып-китеп кенә яшәде Аитов. Бирсә дә бирә икән сабырлыкны табигать — ничә елга бер зарланганын ишетермәде Сөембикә, оя баскан каз кебек еллар буе өйдә утырды. Алай да ахырга кадәр түзмәде, бу китүендә үпкәсен сиздерде бит тәки. Әмма сер бирәсе итмәде: «Бар, Әсфәндияр, егәрең барда эшлә»,— дип озатып калды. Шул аерылу кичендә, Сөембикәсенең сары суккан йөзенә карап, беренче тапкыр Әсфәндияр гаилә фәлсәфәсенә бирелде. Үзебезне җантән белән казна эшенә биреп, табигатьнең шушы назлы җаннарына хыянәт итмибез микән. Әнә бит үпкәсен сиздерә. Сиздерер дә шул, соңгы елларда бигрәк биреште Сөембикәсе. Чире көчлеме, әллә балалар хафасыннанмы. Әтиләре кебек үк бигрәк дуамал, бигрәк тынгысыз шул малайлар да...

Тамагы кибеп киткәндәй булды, ашыгып чынаягына чәй койды. Әмма бер кайнарлап, бер суынып беткән чәйдә тәм калмаган иде инде. Бер тын белән чынаягын каплап куйды да, диван ятагын күтәрде, астан ак капламага ураган мендәр белән юрган чыгарды — кабаланмый гына урын көйли башлады.

Кунакханәдәге бүлмәсенә кайтып тормыйча, кабинетында гына куна калуы бүгенге сәфәренә бәйле иде. Дөньяның бөтен мәшәкатьләре, уйисәпләре нәкъ менә яткач килә аның башына. Шуларны сүтә-сүтә гаҗизләнеп бетә, шуларга җавап эзли-эзли таңны каршылаган чаклары да байтак. Бүген дә шулай булыр микәнни? Юк, моңа юл куярга ярамый. Әсфәндияр сикереп торды да яңадан ут яндырды — бөтен бүлмәгә мул булып яктылык төште. Аитов бүгенге почтаны эзләп тапты, ятагына утырып газеталар караштыра башлады. Шулчак өстәлендәге телефоннарның берсе, бүлмә хуҗасын сискәндереп, таләпчән зыңларга тотынды.

Аитов сабырлыгын җуйды, шулай да трубканы алгач, орды-бәрде сөйләшмәде, бар тынычлыгын җыеп:

— Тыңлыйм,— диде.

— Төзелеш идарәсеме? — диде саф татарча тавыш.— Миңа иптәш Аитов кирәк иде.

Каушабрак, аптырабрак калды Әсфәндияр. Соңгы айларда ана теле ят булып тоела башлаган иде аңа. Биредә, Идел-Кама буеннан меңләгән чакрым җирдә, нәкъ өендәгечә итеп дәшүләренә сәерсенде.

— Телефонда Аитов,— диде ул, шул ук басынкы тавыш белән һәм түземсезләнеп теге кешенең ни әйтәсен көтте.

— Бу Сунарчин әле.— Малайларча тыйнак тавыш кисәк тынып калды.

Трубканы колагыннан алып, уйланып торды Әсфәндияр, әлеге кешене исенә төшерергә тырышты, тик «Сунарчин» дигән фамилия аңа берни дә аңлатмый иде. Аптырагач, кабат микрофонга иелде:

— Сөйләгез, тыңлыйм.

— Зәйсудан мин, колонна начальнигы,— дип дәвам итте билгесез кеше.— Сезнең карамакка...

Эшнең нәрсәдә икәнен шундук төшенеп алды Аитов, йөзенә канәгатьләнү билгеләре ташып чыкты, гәүдәсе тураеп, арганнары бетеп киткәндәй булды. Сунарчинны тыңлап та бетермәде хәтта:

— Кайдан шалтыратасыз?

— Бирердән, станциядән.

— Хәзер үк идарәгә килегез, мин сезне көтәм.

Шулай диде дә трубкасын куйды. Бу минутта, киеренке эш вакытындагы кебек, аның бөтен тәненә куәт-егәр, яңалык белән очрашу тойгысы йөгергән иде.

Себергә эшкә килүчеләрнең барысы да баһадир булмаса да, һәрхәлдә, яшьрәкләрне, физик яктан сау-сәламәт кешеләрне очратырга гадәтләнгән Аитов, кабинетына чал чәчле, шактый олы чырайлы, тулы гәүдәле ир-ат килеп кергәч, сәерсенеп калды. «Бу карт нишләп йөри инде тагы?» — диган уй үтте башыннан. Шулай да шик-шөбһәсен йөзенә чыгармады, ашыгып Сунарчин каршына килде, картларча итеп аңа ике кулын сузды.

— Танышыйк булмаса...

— Ә мин сезне таныйм, Әсфәндияр Газарович,— дип, күрешергә кулын сузды кунак.— Сез генә онытып җибәргәнсез бугай. Хәер, гаебе дә юк, меңнәрчә кеше белән эш итәсез бит.

Аитов арткарак чигенде, Сунарчинның йөз чалымнарына карап-карап торды. Кунакның сәеррәк күренгән ямьшек борыны гына кемнедер хәтерләтә иде кебек.

— Тукта, тукта. Сез бит... Сез бит...

— Әйе, әйе, төрмәдән кайтып, озак каңгырап йөргәннән соң, сезгә килеп егылган кеше.— Сунарчинның күкрәге кысып алды, «төрмә» сүзеннән йөрәгенә утлы хәнҗәр кадалгандай булды. Халәтен начальнигына белдерәсе килмичә, тәрәзәгә таба борылды. «Шөкер, сизмәде бугай».

— Менә, менә. Үзем дә әйтергә уңайсызланып тора идем.— Аитов кунагын өстәл янына алып килде, аңа йомшак утыргычларның берсеннән урын тәкъдим итте, үзе аягүрә басып калды.— Шуннан бирле трассада алайса?!

— Кая барасың инде? Алда — дәрья, артта — сазлык,— Сунарчин моны уфтангандай әйтеп куйды.— Кайда да бер кояш, кайда да эшләргә кирәк. Башта шул җир казучы булып йөрдем. Бара-тора, үзегез беләсез, трассада көрәкнең кирәге калмады — изоляция эшенә күчерделәр. Аннары машинистлыкка укып кайттым, бригадир булып эшләдем. Инде менә ничәнче ел колонна башлыгы. Сезгә рәхмәт укып, алтынчы дистәне түгәрәкләп яткан көн.

Аитов аның соңгы сүзен ишетмәмешкә салынды. Шулай да хәтер сандыгының аулак бер почмагында әллә кайчангы күренеш калыкты: тәмәке төтененнән, стеналарга сарышкан сөремнән караңгыланып калган кечкенә будкада тимер мич гүли, Аитов каршында дүрт дистәсен дә тутырмый чәче агарган, дөньядан өметен өзә башлаган кеше каравылчы итеп булса да эшкә алуларын үтенә... Ләкин үткәннәрне шәрехләп торасы килмәде Әсфәндиярның.

Сүзсез тору икесенә дә кыен иде. Ризван Сунарчин — кунак, вазифасы буенча да кечкенә кеше, аңа сорау биреп, сүз башлап утыру килешми. Өзелгән әңгәмәне тагын Әсфәндияр ялгап китте:

— Хатының ни ди инде? Гомер буе читтә, трассаларда йөрүеңә үпкәли, рәнҗи торгандыр. Картаеп акылга туймаган дивана, дип тә әйтәдер әле.

— Шөкер, бу хатыннан уңдым, Әсфәндияр Газарович.— Ризван үз хәлен, кайда икәнен белеп кенә әйтте бу сүзләрне. Артыгын чишеләп, үзе турында: «Куштанлана бу, начальнигына ярарга тырыша»,— дигән фикер калдырасы килми иде. Шулай да теле бер язылгач, күңелендәгеләрен әйтми кала алмады: — Хәтерләмисездер инде, минем бит

беренче хатын «утырма»дан кайтуымны көтмәде, ниндидер спекулянтка ияреп Ташкент ягына чыгып киткән иде. Байтак гомер бүйдак яшәдем. Аннан дөнья үзем кебек үк күпне күргән бер ханым белән очраштырды. Мәхәббәт-фәлән дип чәпәшләнеп яшәмәсәк тә, йорт-җирне җыеп тота, тапканның кадерен белә. Балаларны ул үстерде инде. Минем эш мәсьәләсендә дә орды-бәрде килгәне юк.

— Түзгәнче түзә инде алар,— дип әлеп алып китте Аитов, һәм, үзе дә сизмәстән, урындык алып Ризван каршына утырды. Аның сүз сөреше дә, кыяфәте дә дөнья мәшәкатьләре хакында гәп корып утыручы авыл агаен хәтерләтә иде.— Минем дә шулай тел-теш күрсәтми яшәде, ана бөркет кебек оя җыеп торды. Шулай да сабыры төкәнде, монда киткәндә авызын турсайтып калды.

— Да-а-а,— дип сузып әйтеп куйды Сунарчин. Аңа ияреп, Аитов та көрсенде.

— Тукта. Нәрсә без хатыннар сыман юк-барны куертып утырабыз әле? Йә әйт: колоннаң белән килдеңме?

— Егетләр КамАЗда әле, миннән телеграмма көтәләр.

— Димәк, үзем монда, күзем тегендә.— Аитов, сүзнең житдигә күчүенә басым ясагандай, өстәле артына утырды, пыяла өстендәге кәгазьләрне алгалап, өлкә картасын ачты.— Кайда төпләнергә уйлыйсың?

Сунарчин, сүзнең зурдан кубуын чамалап, карта янына елышты.

— Хуҗа нинди чырай күрсәтә бит әле?

Аитов, хәрби киңәшмә алып баручы генерал сыман, карта өстенә иелде, кулындагы калын кызыл карандашын шартлы билгеләр өстендә биетә башлады.

— Бүгенгә без шушында кунакладык. Төмән белән Курган арасында. Ничек кенә булмасын, бу участокны көзгә файдалануга тапшырырга кирәк. Сезнең егетләр, кем әле, Хисамов колоннасы бугай, алар да шунда. Барысы тугыз-ун бригадага җыела. Аларны бераз тыгызласак, синең чебиләргә дә урын табып булыр сыман. Тик...

— Тагын күченергә кала, дисез инде,— дип бүлдерде аны Ризван.— Яратмыйм шул асынып-бүсенеп йөрүләрне.

Идарә начальнигы, авыр карашы белән Сунарчинны кадаклап куярга теләгәндәй аңа туры карап куйды. Күрер күзгә юаш кына шушы кешенең әрсезләнергә чамалап утыруы сәерсендерде аны. Берни аңламый торган түмәрме, әллә соң калҗаның иң майлысын эләктерергә маташучы хәйләкәрме бу? Син аңа кулай урыннан эш биреп үзеңчә ярдәм итәргә тырышасың, ә ул сатулашмакчы, тагы да җайлырак участокны эләктермәкче. Андыйларның син беренчесе түгел, иптәш Сунарчин, беләбез тел төбегезне: коры участок, ул да булса тимер юл буенда, Төмән кырыенда булсын. Тукта, аппетитыңны бозыйк әле бераз.

— Әйе, күчәргә! Тик анда саз, баткак, кара урманнар көтә сезне,— Аитов карандашын Төмән белән Обь арасында йөртеп алды, аннары акрын-акрын гына төньякка таба хәрәкәтләндерде.— Менә биредән башлап Тубылга, хәтта менә монда Сазанак станциясенә кадәр коры җир диярлек әле. Басым ясап әйтәм: Себер өчен генә коры җир санала ул. Баксаң, шул ук баткак, сазлык, урыны-урыны белән диюем. Сазанактан соң исә тоташ упкын-баткаклар башлана — кышсыз якын килермен димә.

— Димәк, Төмән белән Сазанак арасына кул тимәгән әле?

— Ничек дип әйтергә? Бригадалар төньяк иңсәдә дә эшли. Нигездә, Төмән белән Тубыл арасында. Иртыш янында, ниһаять, Сазанак янында да һөҗүмгә күчтек. Тик әле анда монтажчылар һәм җир казучылар гына. Бик ирәеп китмә, Сунарчин, изоляцияләүчеләр җитешми. Сүз уңаеннан, синең колоннага ничә километр каралган анда? — Аитов кесәсеннән куен дәфтәрен чыгарды.

— Эзләп азапланмагыз.— диде Ризван коры гына.— Сиксән чакрым.

— Сиксәннең йөз сиксәнгә әйләнүе дә ихтимал.

Ризван әле Зәйсуда ук трассаның схемасы белән танышкан иде. Юлда килгәндә дә вакытын бушка уздырмады, нефть үткәргече салыначак җир өстен өйрәнде. Тик кәгазь кәгазь инде ул, үз күзләрең белән күрү түгел. Шулай да эшлисе җирләрен бераз күзаллау мөмкин булды. Сунарчин тагын бер хакыйкатьне яхшы белә иде: алдан килгән — урын өчен, диләр. Себер җиренә башлап аяк баскан колонналар, яз сылтавы белән, корырак урыннарны эләктереп калдылар, әлбәттә. Алар арасына барып тыкшыну җае бар икән әле барын — хуҗа үзе үк әйтеп тора әнә...

Аитов аның тынып калуын үзенчә аңлады бугай, кырыс кына әйтеп куйды:

— Йә, ник дәшмисең? — идарә начальнигының йөзендә мәсхәрәле елмаю чалынып үтте.— Шүрләп калдың алайса?!

— Балыкны су белән куркытмыйлар, Әсфәндияр Газарович!

Шулай диде дә картага төбәлде Сунарчин. Билгеләрнең типографиядә басылганнары да, Аитов кулы белән төшерелгәннәре дә байтак иде монда. Барыннан битәр тигезлек билгесенә охшаш сызыкларның күп булуы хәйран калдырды Ризванны. Сазлык-баткак дигәннәре шул бит инде.

Аитовны озак көттерде Сунарчин. Аның каравы, ул уйламаган сүзне әйтте:

— Ярый, без менә монда, Сазанак тирәсенә төпләнәбез. Йөкләрне яңа тимер юл буенча үткәрергә ярдәм итәрсез бит?!

— Анысында эш тормас,— Аитов кунакка сынаулы караш ташлады.— Тик уйлап бетердегезме? Сазанактан соң тоташ сазлыклар башлана, дидем ич.

— Әнә шуны күздә тотам да инде мин, Әсфәндияр Газарович. Җәен Иртеш буйлап көньякка барып эшләргә исәп. Кышка исә әлеге Салым сазлыклары. Өстәмә чакрымнар да булыр дисез бит әле.

— Планга өстәмә буласы шөбһәсез. Чөнки торба юлы Обьның теге ягына, Черек күлгә кадәр озайтылды. Шулай да исәплән бетердегезме? Җәй башында коры җирдә эшләү әйбәтрәк булмасмы?

— Юк инде, без күченеп йөрмибез!

Аитов бу тискәре бәндәгә сәерсенеп карап-карап торды да, әңгәмә бетүен аңлатып, урыныннан кузгалды... Сунарчин да урыныннан кузгалды.— Үткәргечнең төньягын да без саласы ич. Сайланып торасыбыз юк. Төзелеш ныклы бер кулга тапшырылгандыр, шәт.

— Рәхмәт. Шундый сүз көткән идем дә мин сездән.

— Күтәргә түгел, таләп итәргә кирәк, Әсфәндияр Газарович,— Сунарчин да урыныннан кузгалды.— Үткәргечнең төньягын да без саласы ич. Сайланып торасыбыз юк. Төзелеш ныклы бер кулга тапшырылгандыр, шәт.

Аитов бүлмә уртасында туктап калды.

— Ярый, монысын бүтән чакта сөйләшербез. Ә хәзер йоклап алырга кирәк. Бер диванга икәү сыярбыз бит?!

## 3

Ата-бабадан калган гадәт буенча, төрле хорафатларга ышана иде Нурлы. Сынаганы да бар: сул кашы тарттымы — һич кенә дә хәерлегә түгел, бер-бер күңелсезлек чыгасын, елап аласыңны көт тә тор. Ходаем, нигә бу кадәр тыпырчына соң ул? Эше көйле, тормышы, әнисе әйтмешли, аллага шөкер, башкаларныкыннан ким түгел. Ире Шаяз белән дә бозылышканнары юк. Ул әле кичә, төштән соң гына, бригадасы белән КамАЗдан кайтып төште, бер төндә ызгышу түгел, сөешеп тә туймадылар.

Эшендә дә ул-бу килеп чыкканы юк. Заводның конструкторлык бүлегенә күчкәненә тулар-тулмас бер ай. Хәер, бүлекнең дә яңа

оешып килгән чагы, әлегә рәтле-башлы эш башкарганнары да юк.

Нурлы, үзе дә сизмәстән өстәле тартмасын ачты, ниндидер кәгазьләр астыннан көмеш берлек кадәр генә көзге чыгарды, кабаланып аны чәченә юнәлтте. Юк, ак бөртекләр күренми, шәһәр шаукымы тияргә өлгермәгән табигый озын чәчләре элеккечә чем-кара, саллы гына толым аларны артка тартып, җыеп тора. Шуңа күңеле булып, көзгене йөзенә күчерде. Юк-ла, җыерчык-буразналар ул кадәр сизелерлек түгел, күзләре дә, шөкер, элеккечә дәрт белән балкый, битләре алсуланып янып тора. Тупырдатып бала таба торган чагы да бит...

Кинәт йөрәге чатнап, хәле китте Нурлының. Кулы, чамасыз йөк тоткандай авыраеп, ачык тартма өстенә салынып төште. Әле генә шатлык балкыган күзләрендә өметсезлек билгеләре чагылып үтте. Соңгы елларда төннәр буе, еш кына көндезләрен дә күңеле тәрәзәсен шакыган шик-шөбһәнең кабат баш калкытуы иде бу. Юк инде, булмады. Җир йөзендәге күпчелек хатын-кызга, хәтта киек-җәнлекләргә һәм хайваннарга да биргән бәхетне — ана булу бәхетен кызганды аңардан табигать!

Әнисе һәм сердәшләре сөйләве буенча, үзенә инде бик таныш булып тоелган тибүне — йөрәге астында судагы балык йөзүедәй талгын хәрәкәтне Шаяз белән тора башлавының икенче-өченче аеннан ук көтте Нурлы. Яңа бер тормышның хәбәрен менә бүген, менә иртәгә дип ымсынып көтте. Көтү-зарыгу, шик-шөбһә эчендә ике ел үтеп китте. Башта аны-моны абайламаган Шаяз да еш кына «бәләкәч» хакында сүз кузгата башлады. Иренә берни җавап кайтармады Нурлы, ә көенече артты гына. Инде өмете киселә башлагач, иренә һәм күрше-күләнгә сиздерми генә, врачка күренде.

Барасы калмаган икән шифаханә дигәннәренә! Шул көнгә хәтле татлы өмет чаткысын сүндермичә яши иде ичмасам. Табип, мәрхәмәтсез, шул юанычын да кисте: «Болай гына бала китерә алмассың, дәваланып кара»,— диделәр. Бу хакта башкаларга әйтмәсә дә, хәлне иреннән яшерү мөмкин түгел иде инде. Шаяз белән киңәшкәч, курорт-санаторий юлын таптый башлады.

Йөреп-йөреп тә рәт чыкмагач, ничарадан бичара дигәндәй, хатын-кызлар арасында исеме чыккан карчык-корчык янына да барып карады Нурлы. Алар ясап биргән әллә ниткән әче сулар эчте, күңеле ышанып җитмәсә дә, муенына догалы бөти тагып карады, мендәре астына иренең чалбарын салып йоклады. Аннан, ачуы чыгып, боларның барына да кул селтәде. Шулай да бала китерү өмете бөтенләй сүнмәгән иде әле аның.

Пыяла бүлмә артында сузып-сузып телефон шалтырады. Менә мөдир Святослав кем беләндер әдәпле генә сөйләшә башлады. Мөдир телендә үз фамилиясен ишеткәч, Нурлы сагаеп калды. Кемгә кирәге чыгар аның? Святослав ишеген ачканда, ул инде аягына торып баскан иде.

— Сезне сорыйлар,— диде мөдир, ничектер уңайсызланып һәм, гадәтенчә, галстугының төенен рәтләп куйды. Аннан Нурлыны эчкә үткәреп җибәрде дә үзе зур якта торып калды. Шундый тәрбияле, итагатьле кеше инде ул Святослав.

Трубкада ят хатын-кыз тавышы ишетелгәч, тагы да сәерсенеп калды Нурлы, үзен сәламләгән кешегә дәшәргә ашыкмады.

— Алло, алло, сез мине ишетәсезме? — дип үрсәләнде таныш түгел ханым.

Нурлының тавышы ярым пышылдап чыкты:

— Ишетәм, яхшы ишетәм.

— Нурлы Рамаевадыр ич телефонда?

— Әйе, мин,— диде Нурлы тагын да каушабрак.

— Ниятегездән кире кайтмагансыздыр ич сез?!

Нурлы бөтенләй аптырап калды. Кем бу? Нинди ният турында сөйли? Әллә соң аны ялгыш сорыйлармы?

— Карагыз әле,— тавыш йомшый төште, бастырып, аңлатып сөйли башлады: — Бала табу йортының баш врачы Астафьева бу. Гаризагыз буенча шалтыратуым.

Калганын тыңлап тормады Нурлы, тартып алуларыннан курыккандай, трубканы чытырдатып кысты, бите бурлаттай янып чыкты, бар күңеленә ялкын капкандай булды.

— Нәрсә?.. Әллә...

— Менә инде. Шуңа шалтыратам да ич.— Доктор аның дулкынлануын сиздe бугай, тавышы тәмам ягымлыланды, сабыйны назлагандай, иркәләп кенә сөйләвендә: — Мин инде сезне атнадан бирле эзлим. Беләсезме нәрсә, баланы бездә асрауның вакыты чыгып килә. Ниятегездән кайтмаган булсагыз, бүген үк хәл итәргә кирәк мәсьәләне.

Телефон трубкасын куйгач, кызышкан битен сыпыргалап, мөдир өстәле артында шактый басып торды Нурлы. Менә бит син, әй, һич көтмәгәндә! Дөресрәге, көтә-көтә көтек булып, өмет киселгәндә...

Уллыкка иясә кызлыкка бала алу нияте аның йөрәгендә моннан байтак еллар элек бөреләнгән иде инде. Әмма аны тормышка ашыру ансат булмады. Башта һаман да үзем буйга узмаммы дип юанды, аннан теләген иренә әйтергә тартынып яшәде. Үзе кебек бәхетсез хатыннардан ишеткәне бар Нурлының: уллыкка яки кызлыкка бала алу хакында сүз кузгаттыңмы, имеш, җен ачулары чыга ирләрнең. Тик юкка гына курыккан, юкка шөбһәләнгән икән. Шул хакта сүз кузгаткач, ачуланмады да, битәрләмәде дә Шаязы. «Алып кайт соң»,— дип сикереп тә төшмәде. Мендәренә чалкан яткан килеш бик озак дәшми торды да:

— Ни генә дисәң дә, үзеңнеке булмый инде ул,— дип әйтеп куйды.

Бала алуны өнәп бетермәсә дә, каршы килми, димәк. Нурлы шул кадәресенә дә шатланды. Боз кинәт кенә кузгалмый инде ул. Шул хакыйкатьне исендә тотып, Шаяз ялга кайткан саен, төннәрен иренең колагына пышылдый торган булды:

— Юк бит инде, Шаязым. Нишлим? Бер сары башлысын алып кайтыйк булмаса.

— Соң алып кайт, алай бик мәшәкать тансыкласаң,— диде Шаяз беркөнне, уенын-чынын бергә кушып.

Шушы сүз генә кирәк иде дә Нурлыга. Икенче көнне, ирен читтагы командировкага озатуга, шәһәр мәгариф бүлегенә йөгерде. Күкрәгенә җып-җылы нарасый кысып кайтасы минутлары белән хыялланып яши башлады...

Туктале, ни дип терәлеп катты соң әле ул? Нурлы каударланып ишеккә таба атлады, бусагага җитүгә, алдагы якта тавышлар ишетеп, туктап калды.

— Айга менгән заманда бит! — дип кайнарлана иде кемдер, шактый кызып.— Кешеләр, җирдә утырган хәлдә, галәм киңлегендә корабларны йөртә, айдагы механизмнарны хәрәкәткә китерә. Ә без? Ә без торба салгычтан ун-унбиш метр читтәге агрегат белән идарә итә алмыйбыз. Тфү! Көлке бит бу.

Идән уртасында урта буйлы, төзек гәүдәле кеше йөренә. Ул ялан баш, кыска гына сары чәчләре, сөзешергә җыенгандай, усал тырпаеп тора. Малайларныкыдай сакал-мыексыз йөзе кызарып чыккан. Нурлы аны шунда ук танып алды, бу — Шаяз бригадасында изоляцияләү машинасында эшләүче Анатолий Синицын иде.

Гомерендә кеше белән ызгышмаган Святослав исә тәрәзә буена барып елышкан да, еларга җыенган малайдай бөрешеп, иренен тешләп тора. Ниһаять, ул телгә килде:

— Безнең бюро оешып кына килә бит әле, Толик. Шуңа карамастан, кызыклы гына эксперимент ясарга дип торабыз... Берәз башкүз алыйк, синең тәкъдим турында да уйларбыз.

— Баш-күз алыйк, уйлашырбыз, имеш,— дип тагы алып китте Анатолий.— Колонна начальнигына әйтсәң — сабыр ит, участок начальнигына сөйләсәң — юк белән баш катырма, баш инженерга керсәң — конкретрак әйт, сызып күрсәт. Я инде, сызып күрсәтерлек булсам, сезгә ялынып йөрер идемме мин?!

Толик, ярсуына чыдый алмый, бүлмәне тагын бер урады, пинжәге чабуына эләктереп, сызым тактасын аударды, аннан ишекне аягы белән тибеп ачты да, җилләнеп чыгып китте.

Бүлмәне авыр тынлык басты. Бер-беренә күтәрелеп карарга кыймый шактый озак тордылар.

— Нәрсә, күңелсез хәбәр бар мәллә? — дип телгә килде Святослав, тәрәзә буенда торган хәлдә.

— Юк ла...— Нурлы тотлыгып калды.— Шулай да китәргә кирәк миңа, Святослав Михайлович. Бәлки, бүген бүтәнчә килеп тә булмас...

— Барыгыз, бар,— мөдирнең йөзенә елмаю чыкты. Начар хәбәр булмавына шатлануы иде бугай.— Иркенләп калыгыз хәзергә, тиздән безгә дә урак өсте җитә.

Завод белән өе арасын әллә йөгереп, әллә очып үтте Нурлы. Зәйсуның һәрчак кайнап торган урамнары аңа бүген җансыз булып тоелды. Кала шау-шуын ишетмәде, тротуардагы кешеләрне күрмәде. Төшендә сыман гына булып тоелган ниндидер җанлы курчакларны узып китте, кемнәргәдер килеп бәрелде. Тынына каплана-каплана йөгерүеннән биш катлы кирпеч йортның ишегалдына килеп кергәч кенә туктады. Әмма монда да тоткарланмады, ниндидер сихри көч аны әйдәкләп икенче катка алып менеп китте. Ишек төбенә җиткәч кенә уң аягының баш бармагы сызлавын тоеп алды. «Тиле,— дип битәрләде Нурлы үзенүзе,— нигә дип кидем шул биек үкчәле туфлиләрне!» Кисәк кенә күңеле сүрәнәеп китте, ишекне теләр-теләмәс кенә ачып, эчкә узды. Ялтырап торган кара туфлиләрен салып атты да өске өлеше гел пыяладан торган зал ишеген төртеп җибәрде. Бүлмә һәрвакыттагыча чиста, пөхтә, шулай ук һәрвакыттагыча буш иде. Йөрәге чәнчеп алды Нурлының. Их, менә шулай җыйнак, кырт итеп тормасын иде шул өең! Кайтып керүеңә бүлмәнең асты-өскә килгән булсын иде, шуклыклары күзләренә чыккан, үзләре юешләнеп, буялып беткән өч-дүрт малай каршыласын иде. Малайлар бер хәл, өй тулы кыз бала чырыйласа да шатлыгы эченә сыймас иде Нурлының. Юк шул, юк. Шушы өйдәге йөз квартираның туксан тугызына кагылган бәхет нишләп соң алар бусагасын гына читләтеп үтә? Ни яме булсын инде бала-чагасыз йортның? Балалы өй — базар, баласызы — мазар, дип белми әйтмәгән инде борынгылар. Шаязның оясыннан качкан каз кебек йөрүен генә кара син. Әлеге дә баягы, бала булмаганга, өйдән ямь тапмаганга бит инде ул. Трассадан мең ел күрешмәгәндәй сагынып, ашкынып кайта да, икенче көнне үк ямансулый башлый: анда барып төртелә, монда килеп орына — эш-шөгыль таба алмый, аптырагач, чыгып китә. Әнә ич бүген дә каядыр китеп олаккан. Җитте, бүген үк алам да кайтам баланы! Ник әллә нәрсә дими...

Үзен-үзе кая куярга белмичә, атылып тышка чыкты, җан атып урам буйлап китте.

## 4

Шаязның звонок төймәсенә үрелгән кулы хәрәкәтсез калды. Эчтә, ишек артында, сулкылдап-сулкылдап сабый бала елый иде. Ләкин әрнеп түгел, ничектер тәмле итеп, көйләп-көйләп елый нарасый. Ирнең башыннан минут эчендә мең төрле уй үтте. Ниткән бала бу? Тугантумачалардан кем дә булса килгәнме, әллә тирә-күршеләрдән берәрсе сабыен күтәреп биләмгә кергәнме? Төймәгә басты — эчтә электр кыңгы-

равының шырлаганы ишетелде. Ләкин киез чәпәләйләрен лаштор-лоштыр сөйрәп, ишек ачарга килүче Нурлының аяк тавышы юк иде. Баягыча тәмләп, көйләп-көйләп бала гына елый. Юк, аңа кушылып, кемдер кычкырып сөйләшә бугай.

Шаязның эчендәниндидер шайтан кузгалгандай булды, ачуыннан төймәгә кат-кат басты. Әмма ишек ачылмады. Бу хәл Шаязны шактый ярсытты, ул гайрәтләнеп кесәсеннән моңа кадәр кирәге чыкмаган ачкычын эзли башлады. Ярый әле аны һәрчак үзе белән акча янчыгында йөртә иде.

Ишекне ачып, эчкә узгач, тагын да аптырап калды. Ничә еллар буе кырт итеп, туйга әзерләнгәндәй җыйнак торган залның иәдәнендә төрле чүпрәкләр, бала юрганы аунап ята иде. Бу хәлне нәрсәгә юрарга белми кызуланып, тавыш килгән якка — кухняга таба борылды. Аның ишеге ябык, пыяласыннан гөлт итеп яктылык төшеп тора. Үрелеп, кухняга күз салды. Пыяла тирләгән, аның теге ягында мунчадагы кебек җылы, парлы һава сизелеп тора. Юка күлмәктән генә калган Нурлы исә урындыкка куелган тирән таз эчендә ниндидер баланы юындырып маташа. Битендә, маңгаенда эре-эре тир бөртекләре, йөзе янып чыккан, үзе бөтенләй яшәреп киткән кебек. Бу хәлне күргәч, Шаяз әллә нишләп китте. Ул, үзен-үзе белештермичә, эчкә атлады. Нурлы аны, аяк тавышыннан бигрәк, килеп бәрелгән салкынча һавадан сизеп алды, ире ягына ачулы караш ташлады да, оясына куркыныч янавын сизгән ана коштай, кычкырып җибәрде:

— Яп, яп дим ишегеңне, дивана! Баланы харап итәсең бит! — дия-дия Шаязны сыңар кулы белән төрткәли башлады.— Теге яктан яп... Менә шулай.

Ыгы-зыгысыз, чыр-чусыз өйләренә ниндидер мәшәкатьле шатлык килеп керүен кабат залган чыккач кына тойды Шаяз. Бу әле мәсьәләне тәмам төшенеп, анык кына аңлау түгел иде. Алай да шушы стеналар эчендә беренче тапкыр бала елавы, хатынының ничектер яшәреп калуын күрү рәхәт, бик рәхәт иде аңа. Ул җинелчә исергәндәй очынып, авызын җыеп алалмыйча бүлмә буйлап бераз йөренде дә кабат кухня ишегенә килде, пыялага капланды. Бу минутта ул күп еллар элек, авыл клубының нигез ташына басып, кача-поса кино караучы малай чагына охшап калган иде.

Шаяз ишек пыяласының әле бер, әле икенче ягына чыгып, баланы, бигрәк тә аның йөзен карарга тырышты. Әмма нарасый юньләп күренми, аны Нурлының гәүдәсе каплаган иде. Теләсә-теләмәсә дә хатынының ванна тирәсендә биеп кенә әйләнгәләвен күзәтергә, ана күгәрчендәй нидер гөрләвен тыңларга калды. «Кара, кара син аны нишләгән,— дип сөйләнде Шаяз,— үзе бала тапса, ни кыланмас диген».

Нурлысы күреп алмаса, белмим, тагы күпме торган булыр иде. Хатыны исә күреп тә алды, «әпипә»гә биетә дә башлады:

— Нәрсә инде өч көнлектәй тасраеп торасың? Бала чүпрәкләрен җыяр иден ичмасам. Урын әзерли торсаң да харам булмас... Карале, Шаяз, Вера Васильевналарның чоланнарында Митядан калган коляскалары аунап ята бугай. Кереп чык булмаса. Иртәгә яңасын алырбыз.

Иренең бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты бу сүзләр. Ул әле һаман да кухняга керү, баланы кулына алып карау белән хыялланып тора иде. Нурлының бик озак сөйләвеннән шуны төшенде: хәзергә анда керергә ярамый. Шулай ук кухня янынннан китәсе килми Шаязның.

Нурлы аның халәтен аңлады булса кирәк, битенә ягымлы елмаю чыкты. Ул да түгел, ванналы урындыкны ишек төбенә тартып китерде, үзе тазның теге ягында торып, сабыйны йөзе белән ишеккә таба борды. Бала да нидер сизенгәндәй, елавыннан туктады, пыяла ишек артындагы чуртан борынлы кешегә чор итеп карап тора башлады. Шаяз аның җылы судан кызарган йөзенә, шулай да кара-тут иканлеге беле-

неп торган битенә, йөзем бөртеге генә булып тоелган борынына, телсез калып, байтак карап торды. Аннан, кисәк кенә исенә килеп, телен шартлатты, «ыгы-гы» дигән булды, авыз-борыннарын уйнатып-чалшайтып кыланырга маташты. Бала исә кара күзләрен зур ачып карап торуында. Сабый белән борчагы пешмәгәч, Шаяз хатынына эндәште:

— Карале, Нурлы, үзебезнекеме?

Тегесе, дөбер-шатыр китереп, урындыкны ягулы плитә буена алып китте, үзе уенын-чынын кушып сөйләнде:

— Кемнеке булыйк соң, әтием, диң, кызым. Шулаймы. Трассада катып йөри-йөри кызың туганны да белми калдыңмыни? Ә мин тудым, инде менә үсеп ятам,— дип сайрады ул бала булып. Аннан үз теленә күчте: — Җә, бар инде, Шаяз, уйнап сөйләмим лә.

Ләкин Шаяз китәргә ашыкмады. Пыялага терәгән борынын мышкылдатып бераз торды да:

— Карале, Нурлы исемен кем дип кушарбыз икән?— дип сорап куйды.

— Һай, җаным, тапты бит хәсрәтне. Исем беткән ди дөньяда: Фиалкы, Тамаркы, Катькы...

— Юк, алай бармый,— дип каршы төште Шаяз.— Күр чәчләре нинди бөдрә... «Бөдрә» дип кушабыз. Во!

— Ярый, ярый, кушарбыз. Бар инде, Шаяз.

Тукта, ни диде соң әле бу Нурлы? Коляска, диде түгелме? Ә нигә кеше иске-москысын эзләп йөрергә? Кирәк икән, арба гына түгел, чын автомобилен алып кайтабыз аның. Ул, күлмәге җиңсәсен кайтарып, сәгатенә карады. Кибетләр эшли иде әле. Сервант тартмасын актарып, бер төргәк акча алды һәм ишегеН бикләргә дә онытып, чыгып чапты.

Көн күрмәгән көн күрсә, көндез чыра яндырыр, ди. Балага салкын тиюдән коты алынган Нурлы зур йөнтәс сөлгене, чүпрәкләрне һәм бала юрганын кухняга кертеп үк куйган иде. Судан алуга, кызчыкны әлеге сөлгегә салды, аны елата-елата озаклап сөртте. Аннан, сөлгесен идәнгә шуытып төшереп җибәрде дә, сабыйны йомшак чүпрәккә төрде. Шуннан соң гына кухня ишеген ачып җибәрде.

Нарасыйның ашыйсы килүе җиткән иде бугай, шешәдәге азыкны мүкелт-мүкелт имеп, Нурлыга карап ятуында. Әмма алсу кабаклары аны тыңламый, вакыт-вакыт йомылып китәләр. Нурлы аңа карап кинәнеп басып тора: йөзендә җиңелчә елмаю, күзләреннән бәхет ага. Чыннан да, бәхетле, бик бәхетле иде ул бу минутта. Гүя менә әле генә экиятләрдәге кәүсәр чишмәсендә коенып чыккан да, җиңеләеп, сафланып тәмам чистарып калган. Гәүдәсе генә түгел, җаны да сафланган, дөньяның бөтен мәшәкать-кайгылары әлеге чишмәдән юылып калган иде. Бер гөнаһсыз нарасыйга карап, шундый илаһи халәттә озак, бик озак торды.

Шул мизгелдә дөбердәп ишек ачылды, кызчык сискәнеп куйды, авызыннан имезлеген төшереп җибәрде, ул да түгел чырыйлап еларга тотынды. Бүлмәгә, зур гына көймәле арба этеп, Шаяз кайтып керде. Нурлы башта кабаланып баланы кулына алды, аннан иренә борылып, әйтеп салды:

— Җә, тиле булсаң да булырсың икән, игезәкләргә дигәнен алып кайткансың лабаса. Болары нәмәрсә тагы?

Шаяз, зыян өстендә тотылган малайдай, күзләрен мелт-мелт китереп торды да, арбасы өстенә иелде.

— Мин яхшысы, кыйммәтлесе булсын, дидем, карчык.— Үзе ашыгып арбадан зур гына картон тартма алды, аны шатыр-шотыр китереп ачты. Тартмадан идәнгә артсыз урындык биеклеге уенчык экскаватор килеп төште.

— Уф, үләм!— Нурлы шаркылдап көлә-көлә диванга иелде, каударланып баланы көйли башлады.— Җә, җә, алтыным, җә, җә, сабыем...

Шаяз исә берни булмагандай арбасын бушатуында иде. Бернича



А. Тимерғәлина рәсеме

минут эчендә идәнгә берсеннән-берсе зуррак вертолет, бульдозер, электровоз, самолет ише нәрсәләр тезелде, «Нәни конструктор» тимерләре, тагы әллә нәрсәләр коелды.

— И, кызым, кызым, нишләрбез инде бу тиле әтиең белән,— дип сөйләнде Нурлы һәм идәндә тезләнеп торучы ире янына килде.— Мәле, тирбәткәлә, кулыңнан килә микән? Мин табын әзерлим булмаса.

Әти кеше кызчыкка кайсы кулын сузарга да белмичә катып калды. Уңы белән алса, сабыйны изәр, сулы белән тотса, имгәтер сыман тоелды. Аптырагач, малай чагында кисеп-ярган утынны ташыгандагы кебек, ике кулын да алга сузды. Нурлы сак кына баланы аның беләкләренә салды.

— Болары тагы нәрсә соң әле?— дип арба өстенә иелде Нурлы, кухняга узган җиреннән.— Әллә манный ярмасы инде. Ие шул. Монысы «Геркулес». И, җаным, менә бу әти ичмасам.

Ул шулай ярым чын, ярым шаярып сөйләнә-сөйләнә арбадан азык-төлек бушата башлады.

— Хәлвә, сыр, колбаса. Мармелад, шоколад... кәтермәч. Вәт монысы булган! Хәзер кәтермәч кимерерсең, кызым. Әтекәем, шул кадәр тозлы балык та алмасаң?! Берәр ярты да кыстырасың калган тагы...

— Ул заманнар үтте инде,— диде Шаяз, хатынының кинаясенә исе китмичәрәк кенә.— Элегрәк булса, бригада белән җыелып юган булыр идек, кәнишне.

— Шәп иттеләр, койрыгыгызны кыстылар!— Нурлы җиңүче кыяфәтендә кухняга кереп китте.

Бая, Шаяз кайтып кергәндә, куркып калганмы, бала йоклап китә алмыйча озак интекте. Шаяз аны кулында тирбәтеп, бүлмә буйлап озак йөренде. Баланы әле тегеләй, әле болай тотып карады, ләкин җаена төшә алмады. Арып беткәч, барып диванга утырды, кызчыкны итәгенә яткырды да аны селкергә-тирбәтергә тотынды:

Әлли итәр бу бала,
Бәлли итәр бу бала.
Бу баланы бага-бага
Башым булды дивана.

Җырның ахырын кабатлыйм дигәндә, шырыйлап кычкырып җибәрде:

— Уһу-һу! Кайнар, шау кайнар!

Куркытылган боландай атылып, Нурлы килеп чыкты.

— Нәрсә бар инде тагы?

— Мәле, тот тизрәк, кәчтүмне котлады бу.

— Котлыйсы калмаган инде, мазутка батып кайткансың,— диде Нурлы, баланы кулына алып,— Бар, чишен, юынып ал.

Ул өс-башын алыштырып, юынып кабат залга чыкканда бала изрәп йоклап киткән иде инде. Икәүләп аңа карап тордылар да, кухняга узып, ашарга утырдылар. Башка чакны шулай кара-каршы табынга утырганда, чүкердәшеп туймый торганнар иде. Шулай булмый ни, сирәк күрешәләр. Шаяз ялга кайткан саен сөйләшәсе сүзләре бетми кала. Бүген исә сүзләренең һич рәте булмады: берсе сүз башлауга, икенчесе бала ягына чыгып керә, тегесе сөйләргә тотынса, монысы залга таба борылып, нидер тыңлап тора. Шулай тырт-мырт утыра торгач, токмач куерды, чәй суынды. Табын яныннан башта берсе, аннан икенчесе торып китте. Сабый белән әвәрә килә торгач, төн уртасында гына арып-талып урынга аудылар.

Кинәт коридор стенасындагы звонок шырыйлап җибәрде. Шаяз, житез генә торып, караватыннан төште, кем икәнен дә сорап тормастан, ишекне ачып җибәрде. Бусагада идарә диспетчеры басып тора иде.

— Телеграмма... Себердән,— диде ул, гаепле кеше тавышы белән.

Яңа ачылган тимер юлдан пассажир поездлары юньләп йөрми иде әле. Шулай да Төмәннән төньякка әледән-әле авыр йөк төялгән составлар китеп тора. Ризван белән Сәетнафа шуларның берсенә эләктеләр дә инде.

Тепловоз тәрәзәсе янына басып, очсыз-кырыйсыз алыска төбәлгән Сунарчин алга барган саен җир өстенең сизелеп алмашынуына, чын мәгънәсендә Себер башлануына таң калган иде. Хәер, Уралны үтүгә үк тирә-юнь күзгә күренеп үзгәрде: таулар каядыр чигенеп, зәңгәр рәшә эченә кереп югалдылар, битләүләрен яп-якты каеннар, корыч торбадай төз наратлар, чәчәктә купшыланып утыручы миләшләр каплаган чагыллар ерак киңлектә эреп, юкка чыктылар — ерактан-еракка күчә барган офыкны тирбәлеп торган рәшә йотты. Әллә соң бөтенләй юкмы монда офык дигәнең? Әнә ич, уйдык-уйдык сирәк урманнар артында, күз күреме җирдә, бөтен түренә җирән таплар — сазлыклар «чәчрәгән» дала гына. Бу якларда «каен кулкасы» дип йөртелгән утрау-утрау каенлыкларның, чуп-чуар итеп коба ямау салынган даланың очы-кырые юк бугай — тәрәзә артында һаман да кысыр җирләр биешә. Иге-чиге булмаган Көнбатыш Себер тигезлегенең башлануы шушы икән.

Юлга чыкканнан бирле тепловозның тимер идәнендә, сырмасы өстендә аунаган Сәетнафа, тыштагы үзгәрешне сизгәндәй, янында яткан Буранны читкәрәк этәрде, кисәк кенә урыныннан кубып, Ризван кырыена килеп басты да, поезд барган җайга талгын гына чайкалып, табигатьнең шушы сихеренә карап бара башлады. Бераздан йокылы күзләрен күршесенә төбәде:

— Шушымы инде Себер дигәннәре?

Сунарчин кайтарып җавап бирмәде, бу минутта ул кешегә дәшәр хәлдә түгел иде. Ниндидер аңлашылмаучылык, мәкер аркасында әлегеп, гомеренең иң матур алты елын исраф иткән җиргә, дөньяның ачысын-төчесен, җәбер-золымын татыткан урыннарга унбиш елдан соң кабат аяк басу җанын тетрәткән иде. Инде хәтер патшалыгының ерак почмагына чигенеп, төсмерен югалта башлаган еллар, Себер җиренә килеп керүгә, әллә каян гына янартау булып ургып чыктылар да бөтен йөрәген биләп алдылар. Күңеле тулып, бугазына ниндидер төен калыкты.

— Һай, туган, Себер җире башлана гына әле!— диде ул бераздан, тәрәзәгә капланып өнсез калган Сәетнафаның җилкәсенә кулын салып.— Менә Иртешкә, Обь буена гына җитик, тынның ылыс исе, сумала исе капланыр, каеннарның таңдай яктылыгын карурманнарның каралыгы алыштырыр, каршыңа ак чыршы, карагайларның мәһабәт сыннары йөгереп чыгар, беренче кат эрбет агачларын күрерсең. Менә шунда инде чын-чынлап Себер җире белән очрашырбыз.

Юктан да күңеле була торган гадәте бар Сәетнафаның. Яше буенча да үзеннән өлкән кешенең дустанә сүзенә, ишарәсенә канәгать, тагы ятагына барып ауды, юкагачтан юнып ясалгандай сөякчел озын куллары башы астына куеп, күзләрен йомды. «Йокласа йоклый икән адәм баласы»,— дип уйлап алды Ризван, юлдашына борылып. Болай да буйчан, үтә ябык егет, майкадан килеш сузылып яткач, гел бастырыкка охшап калган иде. Кирәгеннән артык какча булганга, беренче карашка шөкәтсез булып тоелса да, болай ягымлы кеше үзе Сәетнафа. Әллә уяу чагында киезләнып торган шомырт кара күзләре, әллә гомер тарак күрмәгән, киезләнеп-тәпәрләнеп беткән чәче, әллә шул чем-кара көнҗәлә эчендә күренеп-күренеп киткән ак бөртекләр, әллә инде сабыр табигате — нәрсәдер аңа балаларча самимилек бирә. Хәер, төскә-биткә дә бөтенләй төшеп калганнардан түгел: эчкә батыбрак торган елтыр күзләре, карасу-сары йөзе, иягендәге чокыр тирәли борынгы бакыр биш тиен зурлыгындагы төк баскан урыны, туры борыны астындагы саргылт-кара мыегы —

барысы да бик килешле үзенә. Тик нишләптер һич кенә дә үзен-үзе карамый, шуңа гел сукбай кыяфәтендә йөри.

Шулай уйланып, Сунарчин бер мизгел генә юлдашына карап торды да, ялыгудан гаҗизләнеп, тепловоз идәненә беркетелгән утыргычка чүкте, янә тәрәзәгә капланды. Тышта бәрәкәтле Себер җире яз кояшы астында җәйрәп ята. Хәер, яз дисәң, инде яз түгел, җәй дисәң, әле җәй булып җитмәгән чак бу. Табигать үзен биш-алты ай буе богаулап тоткан кышкы челләләрдән, кар көртләреннән, төрле чүп-чардан арынып, шашып-тилереп тәрәккый итә. Урман-әрәмәләр, үзән-кырлар, чагылкашлаклар яшел япма ябынган. Шул бәрхет келәмдә, туй көткән кәләш күлмәгендәге асылташлар булып, чәчәкләр күзне иркәли.

Ризван карашын тимер юл буена күчерде. Тепловоз аңа акканат, мүк җиләге чәчәкләрен изеп, сазлык өстенә бара сыман тоелды. Чыннан да, рельс-шпаллар шундый түбән, чәй кебек саз суы өстендә йөзеп йөриләр төсле.

— Юкка тимер юл салып маташалар,— дип, ул машинистка һәм аның ярдәмчесенә борылды.— Обь буеның ул кадәр хәзинәсен кудыру өчен барыбер нефть үткәргеч төземи булмый иң... Ә безнең торбадан кудырылган җир мае сезнең тимер юлдан ташыганга караганда дүртбиш мәртәбә арзанга төшә, туганкайлар.

Форсаттан файдаланып, Сунарчин үзенең эше, һөнәре белән бераз гына мактанып алмакчы иде. Әмма тыңлаучылары колак салып, шаккатып торучылардан булмады.

— Менә! Менә!— дип кычкырып җибәрде тимер юлчы.— Бүгенге кешегә каян килгән бу купец психологиясе?! Безнекен — Себернекен алырга, ә аның үзенә берни дә бирмәскә алайса? Юу-ук, иптәш начальник, алай батмый. Күрәсезме, күпме яңа йорт бара төньякка!

Ул баш бармагын тырпайтып, кулын җилкәсе аша артка — вагоннардагы кырыкмаса кырык төрле бетон конструкцияләргә, терәк-колонналарга, кирпеч әрдәнәләренә таба селтәп алды да, кинәт сигнал биреп, идарә пульты өстендә үзе генә белгән хәрәкәтләр ясарга тотынды. Тепловоз йөрешен кисәк акрынайтты, дуга булып торган борылмага килеп керде.

— Сезнең белән бәхәсләшеп, юлның катлаулы участогына җиткәнне дә сизми калганмын,— дип сукранды егет.

Машинистның үзе дә сизмәстән тавышын күтәрүе, кулын бутап алуы Буранны борчыды. Сәетнафаның аяклары арасыннан торып, тимер юлчыга өреп алды. Сәетнафа, күзләрен угалап йокысын ачты, муенындагы бавыннан эләктереп этне үзенә таба тартты. Тегесе һаман да тынычлана алмагач, биштәрле капчыгын асты. Буранны житәкләде дә тепловозның ян мәйданчыгына чыгып китте. Шундый инде ул: йомышы төшмәсә, гомер кеше белән сөйләшмәс, зарлану-канәгатьсезләнүне белмәс, атна буе ач торса да, сабырсызланмас. Ризван аны кызганулы караш белән озатып калды. Чыннан да, ниткән кеше соң бу Сәетнафа? Ничә еллар бергә эшләп, трассаларда кунып-төнеп ятуларына карамастан, Сунарчинның шул сорауга җавап таба алганы юк. Колонна начальнигы буларак, Сәетнафаның күңел кылларын чиертеп карау нияте белән, әллә ничә тапкыр сүз башлап караганы бар. Әмма тегесе кайтарып ник кенә бер сүз әйтсен дә, йөзендә ник кенә бер билге пәйда булсын. Икәүдән-икәү юлга чыгасылары мәгълүм булгач, бу сәфәренә зур өмет баглаган иде Ризван. Тик кайда да телен чишә торган бәндә түгел икән. Кеше җаны кесә түгел шул — аны әйләндереп сала алмыйсың.

Поезд Иртешнең уң як ярына чыгып, тизлеген арттыргач, Сунарчинның да күңеле күтәрелеп китте. Нигә дисәң, елганың бу яры калкурак сыман. Сөргән җирләр дә күбрәк, чирәмлекләрдә дә бөтенләй башка чәчәкләр. Борынны ярып кергән әнис исе, кандала үләне һәм кылыч үләне исе, ниһаять, сирәк-мирәк күзгә чалынган такыр юллар, алар кырыенда

күтәрелеп килгән каты кура монда шактый коры икәнен сөйлиләр иде. «Анын» чакрымнары шушы тирәдән, Иртеш буеннан башлана да бит инде. «Шә-эп, эшләр пешә болай булса»,— дип пышылдады Ризван, кулларын угалап. Борчулы боек йөзендә елмаюга охшаш билгеләр барлыкка килде хәтта. Тик алар минут эчендә юкка чыктылар. Ул, дөньяның ачысын-төчесен татыган кеше, кара бәхеткә, очраклы уңышка ышанмый иде. Белә: тимер юл, әйләнечрәк булса да, калкурак җирләргә, ныклы туфракка салына. Ә торба салуның шартлары башка — мөмкин кадәр туры булсын, ара кыскарсын. Трассаны гел тимер юл буйлап бара дип уйлау малай-шалайлык булыр иде. Хәер, янәшәдә коры җир булганда, күрәләтә сазга барып кермәсләр. Ничек кенә булмасын, Себер—Себер инде ул: монда сазлыкка юлыгу гаҗәп түгел, коры җиргә тап булуың сәер. Әйбәт участок озакка куандырыр димә.

Шулай булып чыкты да: бераздан дымлы яткыллар, сулы чокырлар, күрәнле үзәннәр, өстенә кар яугандай ап-ак чәчәктә утыручы сазлыклар күренгәли башлады. Урманнар күзгә күренеп вагая: зифа карагайларны чирләшкә чыршы, нарат уйдыклары, куәтле ак чыршы, эрбет чытырманлыклары киртә юанлыгы агачлардан торган каенлыклар алыштыра барды. Шулай, Зәй, Шушма буйларында тау-чокыр һәм чагылкашлактан арынып булмаган кебек, монда сазлыктан котылырмын димә. Кыен булачак. Алай да эшләп булмаслык түгел. Тегеннән, Иртеш буеннан башларга туры килер, бу яткыллар җилли торсын.

Шуларны уйлап күрсенергә өлгермәде, поезд тагын калкурак урынга килеп менде, Иртеш буендагы сыман корырак җирләр, андагыдай калын урманнар башланды. Ул да түгел, иркен аланга килеп чыктылар. Тепловоз калтырый-дерелди акрынайды да туктап калды.

— Шушы инде ул Сазанак дигәннәре, иптәш начальник,— диде машинист, серле елмаеп.— Прошу любить и жаловать.

— Рәхмәт, рәхмәт, туганкай, китереп житкердегез бит,— дип, Ризван портфелен кулына алды һәм тышка атлады. Сәетнафа аны тепловоз баскычында көтеп тора иде инде.

Тепловоз моңлы итеп кычкыртты да урыныннан кузгалды, үз юлы белән арырак — төньякка китеп барды. Кинәт тыныч, бик тыныч булып калды.

Сазанакны станция дисәң, хәтере калыр. Каравылчы будкасына охшаш кечкенә генә таш корылма да нарат борыслардан салынган ике барак. Юлы да нибары икәү, каршы килгән поездларны уздыру өчен генә. Бар байлык шушы. Хәер, арыракниндидер корылма шәйләнә тагы.

Яхшылабрак карагач, аның тәгәрмәчле йөкләрне төяп-бушата торган эстакада икәнен абайлап алды. Дөньясын онытып, ашыга-кабалана Сунарчин шунда таба атлады. Сәетнафа белән Буран аңа иярделәр.

Чыннан да, торбалардан ясалган бер дигән эстакада иде бу. Калын калайдан җәйгән идәннең күперчегендәге торбаларның тырналып, җәрәхәтле урыннарының көмештәй ак-ак булып торуы аның файдалануы турында сөйли иде. Димәк, алардан да алда кемнәрдер килгән Сазанакка, төпләнергә дә өлгергәннәр. Ризванның өстеннән тау төшкәндәй булды, җиңел сулап куйды: баштагы мәлдә, үзләре хуҗалыкларын җайга салып җибәргәнче, сыенып урын бар дигән сүз. Аннан да битәр, нәүбәттәге беренче эштән — эстакада ясаудан асат кына котылалар икән. Ул, торба өрлеккә сөялеп, башындагы беретын салды, дымланган чәчләрен бармаклары белән тарады һәм шул чак аланның теге башында калын-калын торба әрдәнәләре күреп алды. Уңдарак, урман буенда, аларныкы кебек үк калай белән тышланган вагон-йортлар купшы карагайлар ябалдашы астына сыенган. Юлга чыкканнан бирле беренче кат бугай Сунарчинның йөзеннән чын мәгънәсендә елмаю бөркелде.

— Була болай булгач, Сәетнафа дус! Яшибез!— диде ул, арык юлдашының иңбашына сугып.

Төзек дүртпочмак булып саф-саф тезелгән күчмә шәһәрчектә шылт иткән тавыш юк, вагоннарга кереп-чыгып йөрүче дә күренми, хәтта участок конторкасы ишегенә дә йозак эленгән иде. Шәһәрчекнең ишегалдында, киң иркен мәйданда басып торучы Сунарчин үзен гасырлар тузаны астыннан казып алынган кала хәрабәләре арасында итеп тойды. Ул ярдәм эзләгәндәй артына борылды, өнсез генә басып торган Сәетнафа белән арт аякларына утырган Буранны күргәч, елмаеп куйды — үзләрен җил тегермәне белән көрәшергә килгән Дон-Кихот һәм аның юлдашларына тиңләде. Эт исә аның йөзенә чыккан мөлаемлыкны үзенә игътибар дип кабул итте бугай, урыныннан торды да койрыгын болгыйболгый, Ризван янына килде. Ул да түгел, башын күтәрде, борынын киереп нидер иснәргә тотынды. Аннан, кисәк ыргылып, вагон-йортларның берсенә таба юыртып китте. Сунарчин, авырсынып кына, Буран артыннан кузгалды, күләгә булып Сәетнафа да аңа иярде. Эт ялгышмаган — килеп кергән вагоннары ашханә булып чыкты.

Алар икешәр стакан чәй эчеп, ашханәдән чыкканда, Буран да үз өлешенә тигән колбасаны чәйнәп йоткан, тагы юкмы дигәндәй, иреннәрен ялмаштырып тора иде.

— Без болай итик,— диде Сунарчин юлдашына,— сез монда калып торыгыз, мин әйләнгәләп килим, нинди патшалык икән бу?

Ризван, торба өемнәрен урап үтә-үтә, алгарак узды. Алай да стеллажга якын ук килмәде, кояшта җылынган торба өстенә утырып, эш мәйданын күзәтә башлады.

«Шәп эшлиләр, каһәрләр!»— дип монтажчылар өчен сөенеп, канатланып утырды Ризван. Тик шулчак колак төбендә генә яңгырап киткән иләмсез аваз аны уеннан аерды:

— Әй, нәрсә оеп каттың?! Әҗәлең артыннан килдеңме? А-ну, ычкын әле моннан!

Сунарчин сискәнеп китте, ялт итеп тавыш килгән якка борылды. Артында, аның җилкәсенә атланырдай булып, тупас йөзле, бөтен битен ясмык-ясмык шадра баскан, зур җәйпәк борынлы, усал күзле кеше басып тора иде. Ул аны шунда ук танып алды, бу — җинаятьчеләр дөньясында атаклы Шадра иде. Йөнтәс ак каш өстендәге кып-кызыл тирән яра тагы кемдә булсын. Сунарчин теше арасыннан гына сыкрап куйды — йөрәк тибеше үзгәргән иде аның.

Шадра танып алды һәм каз ысылдагандай көлеп җибәрде.

— Ә-ә-ә? Кызыл?!— диде Шадра, зәһәр елмаеп.— Куян тиреләре базарда очраша, ызначыт.

Ризван кайтарып дәшмәде, астына салкын су агып кергәндәй, кисәк кенә сикереп торды, читкә тайчанды.

— Ашыкма, Кызыл,— диде Шадра һәм пычтырдатып төкереп җибәрде.— Никадәр генә кызарып йөрсәң дә, безнең юллар бер уңайга бит. Менә мин дә һаман Себер сазы изәм, йөкләр төяшәм. Күрәм, син дә шуннан узмагансың бугай.

— Ялгышасың, Шадра!— диде Ризван, үз уңаена атлаган хәлдә.— Безнең юллар бер якка булмады һәм булмас та... Хәер, үзең минем чанага утырсаң әллә...

— Ә менә моны татып карыйсың килмиме?— дип кычкырып калды аңа Шадра, ермачланып беткән пычрак кулы белән кукиш күрсәтеп.

Көтелмәгән бу очрашу Сунарчинның кәефен бозды, әле генә гөберле бакага юлыккан кешедәй, чыраен сытып, күкрәгендәге бума җибәргәнне көтеп бераз басып торды. Аннан кая һәм нигә баруын абайламастан, торба өемнәре арасында урала башлады. Кинәт кенә Томск тирәсендәге лагерь, шунда үткәргән беренче атнасы күз алдына килеп басты. Барып урнашуга, аларны каядыр төньякка, тайга чытырманлыклары арасына урман кисәргә алып киттеләр. Бу вакытта инде Ризван,

кулга алынган көннәрендәге ярсу-саташуларыннан арынып, аек фикер йөртер хәлгә килгән иде. «Хаклык барыбер ачыкланыр, бу аңлашылмаучылыкка чик куелыр, тиздән азат итәрләр,— дип уйланды ул үзалдына.— Хәзергә исә әйбәт кенә эшләргә, монда да намусны югалтмаска». Кулалмаш иптәше үзе кебек үк басынкы, сабыр авыл егете булып чыкты. Эшкә тотындылар. Ботакларын җәеп утырган калын гына ак чыршының яртысын кисәргә өлгермәделәр, яннарына шушы Шадра килеп житте.

— Тукта, хәзер үк туктатыгыз:— дип җикеренде ул, ачуыннан бүртенеп.— Дәһшәтләнең әмерен белмисезмени, ишәкләр?! Белмәсәгез, тиз төшендерермен мин сезгә! Бер генә агач та кисмәскә, балта чапмаска! Аңлашылдымы?

Беравык уйланып торгач, Ризван кабат пычкысына үрелде, аның икенче башын кулалмашына сузды. Пычкы тартка́н саен мул булып тирә-юньгә сумала исе таралды.

Менә йөз яшәгән ак чыршы чайкалып китте, салмак кына бер якка ава башлады, киселми калган җире сынып, иләмсез шатырдады. Менә-менә ул гөрселдәп төшәчәк. Ләкин аның ауганын күрергә дә, ишетергә дә туры килмәде Ризванга: кисәк кенә башы миңрәп китте, күз аллары караңгыланды, бер мизгелгә аңын югалтты. Аннан исенә килеп, чайкала-чайкала, артына борылды. Анда кулына күсәк тоткан Шадра басып тора иде.

Аларның икесен дә эт итеп кыйнап ташладылар.

Сакчылар килеп җитмәсә, бәлки инде Ризван бу якты дөньяда йөрмәгән дә булыр иде. Гомере бетмәгән икән. Больницада ятып чыкты, терелде. Тик баш түбәсендә, чәчсез ак тап булып, җәрәхәт урыны гына калды.

Үткәндәге шул газаплы көннәре исенә төштеме, вөҗданы аның алдына бер сорау китереп куя:

«Йә, минем сафлыгымны исбатлап ни кырдың?»

Анык кына җавап бирә алмый Ризван. Шул юлда башкарган эшләрен санап чыга, партия-совет оешмаларына язган үтенеч хатла́рын хәтеренә китерә. Шулар белән баш вата торгач, вөҗданын юатырлык сүзләр тапкандай була: «Вөҗданым, унбиш ел элеккеге кебек, син инде кагылган-сугылган түгел. Кешеләр Ризван Сунарчинның намуслы бер хезмәтче икәненә ышандылар, аңа ышанып җаваплы эш тапшырдылар. Хуҗаң хөрмәтле, абруйлы»,— ди.

Ләкин вөҗданның үз туксаны туксан, ул һаман:

«Алай булгач, нишләп соң син, элеккеге кебек, кесәңдә партия билеты йөртмисең?»— дип тенкәгә тия.

Монысы инде бәгырьне иң телгәләгәне. Ризванның тәмле йокыларын алганы. Ул хакта эш йөртмәде түгел, инде күзгә күренерлек нәтиҗәләре дә бар. Себергә китәр алдыннан гына партия шәһәр комитетының беренче секретаре янында кабат булып чыкты.

— Вөҗданыгыз саф булуына́ шикләнмибез,— диде секретарь,— ул инде өлешчә документлар белән дә расланды. Әйдәгез, болай итик: партиягә яңадан керегез сез.

«Партиягә кат-кат кереп була микәнни?»— дип шөбһә сала Ризванның вөҗданы.

Сунарчин шул авазга кушыла. Юк, сүзнең яңадан керү хакында баруы мөмкин түгел. Аның партия әгъзалыгы стажы белән торгызылырга, намусының пакьлеге расланырга тиеш.

— Алайса комиссия эшен бетергәнне көтегез,— диде секретарь.

«Бәс шулай икән, көтик әле без,— диде Ризванның вөҗданы,— сабыр төбе — сары алтын, дигәннәр».

Күзләре ачык килеш саташып торуына үртәлеп, тагы урыныннан кузгалды. Битенә көчле җил китереп бәрде — бер уч чәче йөзенә килеп сыланды. Көзгедә яисә пыялада үзенең чал чәчле сурәтен күрүгә Ризван

инде күнегеп беткән. Бу юлы да аңа әллә ни исе китмәде. Әчен пошырганы — икенче нәрсә. Нишләптер бик тулыланып китте соңгы вакытта, битләре шешенгән кешенеке төсле. Уйчан зәңгәр күзләре кысылып калган хәтта. Ботинка бәйләгән саен, корсагы кысылып, эче күкрәгенә килүе, озаграк иелеп торганнан соң, ашказаны бимазалап, саруы кайный башлавы исенә төште. «Тазарганмын, тәмам аристократка әйләнгәнмен»,— дигән уй үтте башыннан. Йөзенең көл кебек ак булуы шул уен куәтләде генә. Нилектән бу? Их, Ризван, Ризван, олыгаясың бугай. Күбрәк конторкада утыруыңны сизмисең дәдер... Ә бит нинди чакларың бар иде. Арыслан-киектәй егет чакларың. Бар да узды. Ни генә күрми ир-егетләр башы...

— Актуганович?! Димәк, тагы бергә! Менә монысы шә-әп.

Ризван тавышка башын күтәрде, каршында сизелер-сизелмәс кенә елмаеп торган каланчадай биек кешенең тупас йөзенә, тоныкзәңгәр күзенә текәлде.

— Давыд Захарыч?! — диде Ризван, гадәтенчә, тыныч итеп,— Менә бу очрашу ичмасам. Ялгышмасам, «Бохара—Урал»дан бирле күрешкән юк иде.

— Әйтмә дә, очрашмаганга мең ел бугай инде,— дип тегесе, көрәктәй зур кулын сузды.

Даны Татарстанга гына сыешмыйча, бөтен илгә таралган бригадир Давыд Захарович Клименковны күптән белә Ризван. Аның белән, дөресрәге, аның егетләре белән янәшә күп трассаларны иңгә-иң үттеләр. Клименков болай карап торуга ук чын рус баһадиры: буе сажиннан артык, җилкәләре киң, күкрәге тепловоз буферы кебек. Тазалыкны, көч-гайрәтне кызганмаган аңардан табигать. Шуңа да бригадасында «Гренадер» дип йөртәләр аны.

— Син нәрсә, чирлисең мәллә Актуганыч? Бөтенләй төсең киткән.

— Болай гына ул, Давыд Захарыч, эшсезлектән,— дип сүзне уенга борырга маташты Ризван.— Менә сезнең үкчәгә баса башлагач, агару-күгәрүләр бетәр әле.

— Тагы да артмасмы,— дип гөрләде Клименков, Ризванны култыклап.— Киттек безнең замокка. Татарча итеп чәй эчерми торып, җибәрдем юк.

— Ә мин китәргә җыенмыйм да, Давыд Захарыч. Вагоннарыңның берсендә урын биреп торырсың бит? Үзебезнекеләр килеп җиткәнче дию ем...

— Сөйләп торасың тагы,— диде Клименков, гөрләп торган күкрәк тавышы белән.— Телисең икән, әйдә, үз яныма! Күңел киң, урын иркен. Инде егетләремнән аерылмыйм дисең икән, рәхим ит, аллы-гөлле комачлар белән бизәлгән кызыл почмак синеке.

Сөйләшә-сөйләшә күчмә шәһәрчеккә килеп җиттеләр. Капканы керүгә, Клименков уң яктагы беренче вагон ишеген киереп ачты да үзенең көр тавышы белән эчкә кычкырды:

— Оксана, колонналы залны ач! Кунакларга җәймә караватның тирбәлеп торганнарын куй!

## 7

Юк, Ризванны йокы алмады бу төндә. Урын-җиренең җылы, ипле булуына карамастан, әйләнде-тулганды, кат-кат мендәрен кабарткалап, аны әйләндереп салды, һаман да күзенә йокы эленмәгәч, меңгә кадәр санап карады, тик берсенең дә файдасы тимәде — мие гадәттәгедән аек, фикерләве тәгәл ачык, тәнендә аз гына да арыганлык сизелми.

Клименков сөйләвенчә, участокның өчтән бере сазлык, яртысыннан күбесе урман чытырманлыклары аша уза. Елгалар күп түгел түгелен, нибары бер инеш — Уратма. Тик ул, башына йөгән кимәгән кырыкмыш

кебек, уйнаклап-бормаланып, трассаны дүрт-биш мәртәбә кисеп үтә икән. Җитмәсә, тар гына булуына карамастан, чагыштырмача тирән, мул сулы, ди. Явым-төшемнәр күп булган язгы-көзге айларда, ярларыннан чыгып, холкын күрсәтеп ала торган гадәте дә бар, имеш. Шуңа да бу яктагы татарлар арасында «Яман елга» дип атала икән.

Анысын, эшнең җиңелдән булмавын, Ризван монда килгәнче үк чамалады инде. Ул ягы әллә ни борчымый аны. Күңелен бимазалаган нәрсә — әлеге трассаның шактый тын булуы. Махсус бригадалар урманнарны кисеп, трассаны чистартмаса, сазлыкларга түшәүлекләр салынмаса, җир казучылар белән монтажчылар эш фронты ачмаса, нәрсә кыра ала изоляцияләү колоннасы?!.. Хәзергә Ризванның бөтен өмете Иртеш буенда. Давыд Захарович сөйләвенә караганда, анда Уфадан килгән монтажчылар байтактан эшләп маташалар икән. Акрынрак булса да, җир казучы һәм трасса чистартучы бригадалар да кыймылдый, имеш. Бераз эш фронты ачканнардыр, бәлки? Клименков вездеход бирсә, трассаны урап кайтып булыр, шәт. Юк, анысына өлгерер, бригаданы каршылау хәстәрен күрергә, шәһәрчек өчен урын эзләргә кирәк башта. Давыд Захарыч вагоннарны монтажчылар шәһәрчегенә терәп куярга тәкъдим итә дә бит... Булмас. Аерым шәһәрчек, үз-үзенә хуҗа булуга ни җитә!

Инде йоклый алмасына тәмам инанып, күзләрен ачты. Тәрәзәләр генә түгел, кызыл почмакның шәрә стеналарына хәтле яп-якты, теге як тәрәзә буендагы раскладушкада яткан Сәетнафаның сирәк мыегына кадәр аермачык күренеп тора. Яктырды да микәнни? Ул иренеп кенә сәгатенә карады — уклар уникене тулып китүен күрсәтteләр. Тукта, сәгатен җирле вакыт белән дөресләп куйган иде бит ул. Алайса нишләп якты? Һай, ахмак та инде син, Ризван! Караңгыланганы да булмады ич. Бу бит сиңа Зәй тугае түгел, Иртеш буе — ак төннәр сиздерә үзләрен. Табигатьнең төньякка тартканын көндез үк чамалаган иде югыйсә. Кояш кыздырып торганда жылы, хәтта тирләтә дә кебек. Аз гына болыт күрендеме, кинәт салкынайта, чиркандыра үк башлый.

Ул урыныннан кубып тәрәзә янына килде, тышка күз салды. Шәһәрчектән кырык-илле метрлар тирәсендә эрбет агачлары зәңгәрләнеп, күксел яктылыкта коенып утыралар иде. Ризван, эшенә соңаргандай өтәләнеп, чалбарын, зәңгәрсу-кара күлмәген, якалары шактый ялтырарга өлгергән пинжәген киде, брезент плащы белән беретын кулына алды, чыгу ишегенә балчык каткан күнитекләрен элэктерде.

Бераздан ул шәһәрчектән читтә, пакьлекнең үзенә төренгәндәй ак төн кочагына сыенган кара урманга карап тора иде. Карашын өскәрәк күчергән иде, иманеп китте — эрбет агачларының калын ботакларын ут алгандай тоелды. Офыкка сыенып, аз гына черем итәргә дә өлгермәгән кояш ябалдашларны алтынсу нурга манган.

Сунарчин, тагы да канатланып, кичә Клименков күрсәткән тарафка — трасса ягына китеп барды. Торба әрдәнәләрен, бульдозерлар айкап ташлаган торф өемнәрен урап атлый торгач, урман буена ук килеп чыкты, табигатьнең шушы серле, мәһабәт бөеклеге каршында туктап калды. Җилләр дә изрәп йоклаган бу гаҗәеп иртәдә агачлар гына түгел, дөнья үзе оеп калган төсле. Шулай да эчтә, ылыслар куелыгында, нидер кыштырдый, кемдер пышылдап сөйләшә, шыпыртлап көлә сыман — һәрхәлдә, нәрсәдер күңелгә шик сала иде.

Кошларның гөнаһсыз авазлары Ризванның шөбһәсен юкка чыгарды, ул урман кырыена ук килеп басты һәм, һич уйламаганда, тикшеренүчеләр утыртып калдырган баганага тап булды. Димәк, трасса кайдадыр якында гына! Ризван сакланып кына тагын берничә адым ясады һәм сизелер-сизелмәс кенә булып торган урман юлын шәйләп алды.

Аяк асты йомшак. Себер урманнарына хас булганча, сыгылып тирбәлеп тора — мул булып коелган ылыс энәсе затлы келәм сыман түшәлгән иде. Һава, әйтерсең, ылыс белән төнәтелгән, чәер исе белән

тулы. Исертердәй булып, каяндыр сазанак үләне исе килә. Тын алуы иркен, рәхәт иде.

Кинәт нидер шатырдады, дөпелдәгәндәй булды, Ризван, шикләнеп, артына борылып карады. Урман юлыннан аңа таба арт аякларына баскан ниндидер карачкы килә иде... Аю! Шомлы уй, ток суккандай, бөтен гәүдәсен тетрәтеп узды. Исенә килергә өлгермәде, сукмак буйлап томырылып килгән җан иясен күреп алды.

— Буран! — дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды Ризван. Эт килеп тә җитте, Сунарчинның күкрәгенә сикереп, җинелчә чинарга, сырпаланырга тотынды. Гүя ул үзен ташлап китүчегә үпкәсен белдерә иде. Бераздан Сәетнафа да аларга якынлашты.

— Син нәрсә, Ризван абый, дөньядан туйдың мәллә?! — диде ул, сулышына кабып. Шуның белән Сәетнафаның сүзе бетте дә.

Бергә-бергә күңелле булып китте. Шактый юл алгач, зур гына ачыклыкка килеп чыктылар. Басу дияр идең — сөрелмәгән, урман аланы дияр идең — артык зур. Билдән юешләнеп күпме үткәннәрдер, аяк астында су чыптырдый башлады, уйдык-уйдык булып җикән камышлар очрады. Менә алар инде тоташ стена булып баскан. Җикәннәрне кулы белән аралап, Ризван тагы берничә адым ясады, аннан сихерләнгәндәй туктап калды. Алда — күз күреме җиргә җәелгән, көзгедәй яп-якты су өслеге назланып, иренеп кенә изрәп ята иде. Аякларының ләмгә бата башлавын тоеп, Сунарчин янәшәдәге түмгәккә таба кузгалды. Кинәт, сулы табага куырган борчак сиптеләрмени, күл өсте кайнап хәрәкәткә килде — моңа хәтле оеп, йокымсырап торган кыр үрдәкләре «ду» килеп камышлыкка ташланды. Табигатьнең мондый иркен, хөр чагын байтактан күргәне юк иде, арык йөзенә елмаю чыкты, камышлар арасыннан сикерә-сикерә үрдәкләр качкан якка чабып баручы Буранга карап, көлеп үк җибәрде.

Трассадан читкә тайпылуга инде шик калмады. Тикшеренүчеләр күрәләтә күлгә барып кермәгәннәрдер ич: йә уңга, йә сулга алган булырга тиешләр. Ризван бая үрдәкләр качкан уң якка карады — су өслеге шактый еракка сузылып, моннан зәңгәрләнеп күренгән урман арасына кереп югала иде. Сулга борылды. Монда яр якын, өстәвенә, Себер як табигате өчен шактый биек. Яр кырыеннан ук өсте агачлар белән капланган калкулык башланып китә. «Әлбәттә, шуннан, түбәдән узганнар».— дигән уй үтте башыннан.

Күл буйлап бераз баргач, аяк асты ныгыды, калкулыкка күтәрелә башладылар. Биек булмаган кышлакка менүгә, Ризван туктады, балаларча кычкырып җибәрде:

— Күр әле, Сәетнафа!

Чыннан да, алларында гаҗәеп манзара иде. Бөтен түбә, сайлап утыртылгандай, таң кебек якты каеннар белән капланган иде. Араларында ичмасам ялгыш кына да башка агач юк. Каенлыктан гаҗәеп бер яктылык бөркелә, күңелгә күптән таныш әчкелтем ис килә. Әйтерсең, кемдер, юлчыларга бүләк итеп, туган якның бер почмагын монда күчереп куйган! Шәһәрчек өчен моннан да кулай урынны көндез шәм яндырып эзләсәң дә тапмассың»,— дип уйлап куйды Ризван.

Каенлык зур түгел, агачлар сирәк, аралары чиста, куаклар, чыбык-чабык өемнәре юк. Урта бер җирендә иркен генә алан да күренә. Шунда таба атладылар. Ләкин ачыклыкка чыгып җитмәделәр, андагы сәер бер корылманы һәм аның янындагы җанияләрен күреп, туктап калдылар.

Корылма дигәне башы урыс капканыкы сыман итеп ябылган ике баганадан гына гыйбарәт бер нәрсә иде. Җирдән ярты метр чамасы биеклектә булыр, баганаларны тоташтырып, әллә такта, әллә утлык куелган. Шуның тирәсендә башына колакчынын төшереп йөнтәс бүрек кигән бер агай урала, аңа тагылып диярлек сыермы, бозаумы бутала иде. Бераз карап торгач кына Ризван әлеге нәрсәнең мөгезе юклыкка игътибар итте, башы да ничектер озынчарак, юка. Поши позавы ич бу!

Моны нәрсәгә юрарга белми беравык тордылар да аланга чыктылар.

Әлеге кеше, шактый олы яшьтә булуына карамастан, төп кебек таза, киң җилкәле иде. Өстендә арзанлы тупас плащ, ачык изүеннән җиңсез туны күренә. Аның Азия халыкларына хас кысык кара күзе, озынча сары йөзе мондагы кеше икәнен кычкырып тора. Тик кем ул: хантмы, мансимы, себер татарымы? Казах-кыргызга да тартым. Агайның кем икәнен тәгаен белмәгәнгә, Ризван русча сәлам бирде.

Тегесе дәшмәде, килүчеләргә күтәрелеп карап кына алды да утлык эченә иелде. Бураннан шикләнеп калган поши бозавы аңа сыенды. Әмма кунакларның усал ният белән йөрмәүләрен сизеп алды бугай, батыраеп Ризван янына килде, аның плащы кесәсенә борынын төртте: ипи соравы, тәмлерәк берәр нәрсә өмет итүе иде бугай.

— Юк бит, наныем, берни алмаганбыз,— дип сөйләнде Сунарчин, пошиның муен астын кашып.

Тавышка агай да башын күтәрде, кулларын каккалап, кунаклар янына килде.

— Песнең кеше игәнсең гуй,— диде ул, карлыккан тонык тавыш белән.— Калай парып торасыз, нимә кылып йөрисез?

«Безнең кеше» дисә дә, аның татарчасы мәзәгрәк иде — казахчагамы, себер татарлары теленәме якын. Алай да аңларлык.

Нишләп йөрүләрен кыскача гына аңлату мөмкин түгел иде. Җавапсыз калып та булмый, бу төксе карт белән сүзне дәвам итәргә кирәк иде. Шуңа да:

— Без төзелеш кешеләре,— дип куйды Ризван.

— Алай пулгац, агацларны кисеп петерәсес икән.

— Шулай кирәк, агай.

Шуның белән сүзләре бетте. Төксе агай, кабат борылып, җирдәге биштәрен алды, анда калган тозны утлыкка салды. Капчыгын каккалады да аны төрә башлады.

— Кац мыннан, кац,— дип һаман да янында уралган поши бозавын читкәрәк этәрде. Шулай да тавышында усаллык сизелми иде. Аннары карт кунакларга таба борылды.— Инәсенә берәй нимә пулганты, йә перәйсе атып киткәнте, пелмәем. Усган көсне куе цыбыклар эценнән тавып апкайтым. Күрәләтә үлтереп пулмайты гуй. Хәсер каусаң та китмәйте.

— Сез аучымы?

— Әвәл егерь итем.— Карт ачыла төште, баштагы төкселеге юкка чыкты.— Инте пенсиягә цыкканыма унпер йыл пулыпты. Әй, гомер тигәнең!

— Авыл ерак түгел алайса? — дип уендагын кычкырып әйтеп салганын сизми дә калды Сунарчин.

— Авылга пывойта гына,— карт капчыгын төреп, аны култыгы астына кыстырды.— Пырас катырак атласак, кеше-кара эшгә цыкканцы иртәнге цәйгә кайтып етәпес.

— Шулаймы? Киттек алайса. Син, Сәетнафа, станциягә кайт, килеп төшүләре бар.

Карт белән Ризван басуга таба, Сәетнафа белән Буран икенче якка китеп бардылар.

8

Менә ул тагын ялгызы. Малайлар туп тибеп уйнарлык өч бүлмәле фатирда бер башы. Шушы таш стеналар эчендә тиле күке сыман уза инде Сөембикәнең гомере. Элегрәк, балалар яшь чакта, рәхәт иде ичмасам. Көннәре шулар мәшәкате белән үтте: юды-үтүкләде, текте-ямады, пешерде-кыздырды. Сырхавыннан арынып, башын күтәргән көннәрендә, улларының мәктәпләренә дә барып кайткалый, кибетләргә дә чыккалый иде. Шушы ук кварталдагы мәктәп белән кибетне урап кайту — алай

зурдан кубып сөйләрлек нәрсә түгел, шулай да ярый иде: кеше күреп, һава сулап кайта, көннәре сизелми үтә торган иде. Анысы хәзер дә йорт эшләрен аның җилкәсеннән алган кеше юк, барына да һаман үзе. Шулай да балалар бәләкәй вакыттагы мәшәкать юк инде. Алар икесе дә көнозын институтта, шундагы ашханәдә ашыйлар, лекцияләреннән соң да кайтмыйча, кичләрен я спорт залында, я китапханәдә уздыралар. Һәрхәлдә, үзләре шулай ди. Яшьләрнекен кем белсен инде, әллә кайларда да йөриләрдер, бәлки? Бозык юлда булмасалар, шунысына шөкер. Ял көннәрендә исә йорт эшен әниләренең кулларына да тидермиләр: идәнен дә, савыт-сабасын да юалар, азык-төлеген дә алып кайталар. Шулай, алар институтка кергәч, узган ике ел эчендә өйдә байтак нәрсә үзгәрде. Тик бер нәрсә — Сөембикәнең гомерлек ялгызлыгы калды. Әсфәндияр һаман да шул трассасында, алтмышы тулганда да басылу белмәс икән кеше. Аның кебекләр шушы Уфада сабыр гына утыралар югыйсә, вакытында барып, вакытында кайта торган урыннарында эшлиләр,— берсе дә ачтан үлми. Һәрчак җылы өйләрендә, хатыннары, балалары янында. Яллары — ял, йокылары — йокы. Моның ни үзенә гаилә җылысы юк, ни хатынына тынгылык тими. Әй, үтте гомер таш стеналар саклап! Бераз һава алу нияте белән балконга чыкты, йомшак урындыкка утырып, кулларын култыксага куйды.

Шәһәр урамы үзенә бер моң белән гөрли иде. Уртадан тегеләйгә дә, болайга да машиналар чаба, тротуарларда халык кайный. Ләкин аларына игътибар итмәде Сөембикә, урамның як-ягындагы купшы юкәләргә, алар артындагы зур-зур ак ташпулатларга карап, онытылып торды. Һаман матурлана, яшәрә аның Уфасы. Тик алар гына... Тукта, әнә тегендә, зәңгәр рәшә тирбәлеп торган турда, Агыйдел түгелме соң? Елга моннан үзе күренмәсә дә, йөрәге белән тойды Сөембикә. Шул, Агыйдел! Һай, ни хозурлыктыр хәзер аның буйларында! Яр кырыйларында бөдрә таллар көязләнеп утырадыр, су өстендә вак дулкыннар чабышадыр. Агыйделнең алкынлыгын, мәһабәтлеген мактап күке кычкырадыр, сандугач, тургай сайрыйдыр. Кинәт аның йөрәге алгысып куйды, хәзер, шушы минутта ук, Агыйдел буена төшәсе, әллә кайларга китәсе килде. Һай, шунда бер генә тапкыр парлап төшсәң икән!

Әсфәндиярга да рәнҗеп булмый. Ул да бит эшем эш булсын, ил алдында, халык алдында йөзем ак булсын, дип йөрде трассаларда. Сөембикә исә тыймады аны, киресенчә, һәр адымын хуплап, хезмәтенә рухландырып торды, бер генә тапкыр да үпкә-рәнҗү сиздермәде. Хатынының хисләрен, ялгызлыктан интегүен белеп, аңлап торды Әсфәндияр, шуңа да яшерен газап чигүе һәрчак чыраенда булды. Иртәгә Себергә китәсе дигән кичне дә шушы балконда, шушы урында, Сөембикәнең арык кулларын күкрәгенә кысып, ачыргаланып әйтте:

«Тагын ярты ел чамасы түз инде, Сөембикә. Беләм: сиңа җиңел түгел — чирең дә каты, аннан килеп, ялгызлык үзе бер хасталык инде ул»,— диде.

«Мин ни... Мин түздем инде, Әсфәндияр, түзәрмен дә,— дип җавап кайтарды ул иренә.— Тик башкалар, бигрәк тә яшьләр, чыдарлар микән болай аерым-суырым яшәүгә».

«Син әле кайчаннан бирле башкалар өчен хәсрәтләнә башладың?»— дип шукланырга маташты Әсфәндияр.

«Бу хакта гомерем буе уйландым мин, Әсфәндияр. Борчылмасын, шөбһәләнмәсен дип, сиңа гына әйтмәдем. Бит син ялгызың түгел, трассада, меңнәр анда. Алар язмышы сине дә уйландырмыймы? Әнә ич, кичәге газетта да язганнар: хәзер яңа өйләнешүчеләрнең өчтән бер өлеше аерылыша, дигәннәр. Әнә шуннан бит инде ул, Әсфәндияр, ирләрнең айлар буе читтә кунып-төнеп ятуларыннан».

«Аерылышуның сәбәпләре күп инде аның, Сөембикә. Шулай да синең сүзләрдә хаклык бар. Тик хатын дип, семья дип, гомере буе өй саклап ята алмый бит инде ир кеше. Ир-егетнең мәхәббәттән дә

өстенрәк, изгерәк хафасы, бурычы булырга тиеш, минемчә. Ил язмышын җилкәсендә йөртсен ул, халык мәнфәгатен кайгыртсын».

«Ә гаилә бәхете?»

«Анысын да кайгыртырга тиеш чын ир. Алай да җәмгыять интереслары алдарак тора. Әнә ич, ил өстенә дошман килгәч, күпме ир-егетләр күтәрелде яуга. Берәү дә хатынын, сөйгәнен саклап ятмады».

«Сугыш чоры — башка, Әсфәндияр. Хәзер бит тыныч замана».

«Имин дип, өендә хатынын кочаклап ятарга тиешме азаматлар?»

«Бәлки, син дә хаклыдыр. Шулай да трассачыларның гаиләләрен ныгыту турында нык уйлыйсы бар, Әсфәндияр».

«Уйлыйбыз да, кайбер нәрсәләр эшлибез дә... Үзең хәтерлисең ич, трассада бар идеме шушындый менә дигән күчмә йортлар, бар идеме кибет-ашханәләр? Хәзер бит, зур каладагы кебек: уты, телевизоры, киносы, кызыл почмагы, мунчасы, душы дигәндәй — бар да бар. Шуңа да күпләр гаиләләре белән яшиләр трассада, бергәләп эшлиләр. Без моны хуплыйбыз, аларга кулдан килгәнчә ярдәм итәбез. Ялгызакларга да өйләренә еш кайтып йөрү өчен шартлар бар: бер дигән машиналар, вертолет яки самолет дисеңме...»

«Алар гына җитми, күрәсең, Әсфәндияр».

«Җитми шул. Ә синеңчә нәрсә эшләргә мөмкин тагын? Трассаларны калага күчереп куеп булмый бит инде. Торба юллары исә бик кирәк халык хуҗалыгына».

«Себергә очып тау токымнары бораулаучылар сыман, вахта ысулына күчәргәдер, бәлки. Белмим, белмим. Сез күбрәк ич, уйлагыз, эзләнегез, җае табылмый калмас».

Тукта, ни дип аек килеш төшләнеп утыра але? Кичкә Әсфәндияры кайта бит аның. Юкка гына алдан ук шалтыратып әйтеп куймый бит инде ул: үзе яраткан төче коймак ашыйсы килгәндер. Сөембикә, тәненең тагын да җиңеләеп китүен тоеп, ашыга-ашыга кухняга узды. Баягы фәлсәфә дөньясын онытып, пилмәнлек ит тартты. Аннан шул ук җиңеллек белән өеннән чыгып китте: кибеткә кереп йомшак конфетлар сайлады. Бала-чага сыман, тәмлене ярата Әсфәндияры. Әйдә, сыйлансын, каты-котыдан туеп беткәндер тегендә... Кайтышлый үзләре янындагы скверда, агач эскәмиягә утырып, озак кына балаларның уйнавын карап торды, чыр-чуларын тыңлады. Шуннан кинәт кенә арганын, хәлсезләнеп киткәнен тойды. Туктап тын ала-ала, өйләренә кайтты, култыксага тотынатотына өскә менде, ишеген ачып керде дә чишенми генә диванга ятты.

Ул ишектәге звонок тавышына уянып киткәндә, кояш инде көнбатыш яктагы тәрәзәдән карый, нурлары тәмам сүрелгән иде. Сөембикә, ярыйсы гына хәлләнгәнен тоеп, җай гына атлап ишеккә килде. Коридорда олы яшьләрдәге ханым — өстендәге киемнәренә караганда, элемтә бүлеге хезмәткәре басып тора иде.

— Телеграмма... Кул куеп алыгыз.

Әлеге ханым сузган кәгазьгә имзасын төшергәнче үк, Сөембикә телеграмманы укып чыкты: «КАЙТА АЛМЫЙМ АШЫГЫЧ МӘСКӘҮГӘ ОЧАМ ОЧРАШКАНГА КАДӘР ӘСФӘНДИЯР». Ул тагын хәлсезләнеп калды, почта хезмәткәренә сер бирмәскә тырышып, кәгазьгә кул куйды да ишеген япты. «Менә син, әй,— дип уйланды Сөембикә, кухняга узып, һәм куәс белән камырын алды.— Аныкы гел шулай инде, кайта башласа да менә бүген, менә иртәгә. Ярый әле исәнлеген хәбәр итте. Мәскәвенә барып җиткәч, тагын шалтыратыр, кабат Себергә узышлый кереп тә чыгар, шәт».

Үзен-үзе шулай юатып, камыры белән маташканда, залда телефон зыңлады. Сөембикә кызуланып аппарат янына килде.

— Аитовлар квартирасымы? Әсфәндияр ага кирәк иде.

— Ул өйдә юк шул, Себердә. Йомышыгыз бар идеме?

— Йомыш дип... Сез аның бичәседер ич... Менә нәрсә, тимер юлчы-

лар больницасыннан врач Кинҗәголов бу... Тик сез борчылмагыз, зинһар. Безгә сезнең улыгызны китерделәр...

Сөембикә коелып төште, хәлсезләнеп янәшәдәге урындыкка чүкте.

— Нәрсә булган? Тереме? Үлеме?

— Куркыныч нәрсә юк. Иптәшләре белән бәхәсләшеп, Агыйдел күпереннән сикергән. Алай да унбиш-егерме көннәр ятар бездә.

Сөембикә телсез калды. «Олысымы, кечесеме?» — дип тә сорый алмады хәтта. Күңеле белән хәзер үк больницага чыгып чабар төсле булды. Әмма аның бөтен тәнен нидер баса-изә иде. Трубканы урынына куйды да, көч-хәл белән барып, караватына ауды.

## 9

«Пывойта гына — монда гына»ның себерчә мәгънәсен Ризван юлда төшенде. Инде сәгать ярымлап атлыйлар, авыл исә күренми дә күренми. Башта машиналар салган комлы басу юлыннан бардылар, аннан караңгыланып торган ылыслы урманга килеп керделәр, тагын берничә сазлыкны үттеләр дә кабат кырга килеп чыктылар. Шунда җиткәч, Ташбулат карт туктады, бүреге белән җиңсез тунын салып, капчыгына тыкты да, әле генә ял итеп торган кешедәй, җиңел кузгалып китте.

— Кайда соң әле синең «пывойтаң»? — дип сорап куйды Ризван, картның яңа көч белән атлавын күздә тотып.

— Сасанак мынта йовыкта гына,— дип кулы белән алга, кояшта җәйрәп яткан басулар ягына ишарәләде Ташбулат.

Ризван дәшмәде. «Тегендә генә» булгач, әле барасы да барасы икән, дип уйлады ул эченнән һәм Ташбулаттан калышмау өчен адымын кызулатты. Шулай да Сунарчин үз хәлен үзе генә белә иде: ул инде тәмам талчыкты, күн итекләре сизелеп авырайды. Аннан да бигрәк ачыкты, эче эчкә ябышты. Ләкин хәлен Ташбулатка сиздермәде. Күңелсез уйларыннан арыныр өчен сүзен башка якка борырга ашыкты.

— Болары да сезнекеме? — дип сорады ул, бер очы офыкка барып тоташкан чәчүлекләргә ымлап.

— Песнеке пулмаен, кемнеке пулсын.— Ташбулат мәгърур бер кыяфәт белән тирә-юньгә карап алды.— Пы пуйларта пашка оуыл юг, Сасанак кына. Цацулыклар та, пецәнлекләр тә, саслыклар та, урманнарның пер кисәге тә песнеңке. Унике мең гектар ере пар «Азат Себер»нең!

Ташбулат карт ярыйсы ук сүзчән, шат күңелле кеше булып чыкты. Өстәвенә, җиде дистәне тутыруына карамастан, җен кебек таза, аруталуны белми — юлга чыкканнан бирле Ризванга туктап тын алырга бирми, бераз гына бөкересен чыгарып атлый да атлый. Шул арада теле дә тик тормый, гомер сөргән авылы тарихыннан берсеннән-берсе гыйбрәтле вакыйгалар сөйли.

...Татарларның монда ничек һәм кайчан килеп утыруларын берәү дә хәтерләми икән авылда. Борынгыларның сөйләвенә караганда, Сазанак шушында мәңге булган, имеш. Җирләр иркен, урман күп, тайгада киек-җәнлекләр җитәрлек — рәхәтләнеп яшәгән Ташбулатның бабалары. Авыл тарихында телгә алып сөйләрлек әллә ни булмаган. Ләкин бервакыт... Бервакыт авылның иң зур бае — Ситдыйк бай Яман елганың теге ягындагы җирләрен бу якларга күчеп килгән урыс Курингa сатып җибәргән. Шуннан ни күрсеннәр, бер-ике ел дигәндә, аръякта өр-яңа авыл — рус авылы калкып чыккан. Менә шуннан соң инде авыл Сазанак-Багульникка әйләнгән. Ул гына да түгел, элек атлы арба белән аркылы чыгып йөри торган Яман елга төпсез дәрьяга әверелгән. Куринга бил бөккән рус мужикларының хәле дә татар ярлыларыныкыннан әйбәтрәк түгел ди түгелен. Шулай да авыл белән авыл аралашмый, һәр икесе үз-үзенә йомылып яши. Ике халыкның бер-берен өнәмәвен поплар һәм муллалар бик оста файдалана, алар русларны һәм татарларны бер-

сен икенчесенә каршы котырталар. Патша чиновникларына исә шул гына кирәк тә, җае туры килгән саен утка май өстәп торалар. Дөрес, җәен басуда, тайгада эш күп вакытта дошманлык онытылып torгандай була, хәтта, кирәк булганда, бер-беренә ярдәм итү дә гадәткә кереп китә. Аның каравы, көз җитеп, Яман елгада боз катуга, һәр ике авылның яше-карты, кайсы кусәк, кайсы балта күтәреп боз өстенә төшә. Китә шуннан бер юкка кан кою: кайсының башы ярыла, кайсының авызы, маңгае җимерелә, кайсының күзе агып чыга — гарип калучылар да була. Шулай да акылга килүче юк, кул сугышы кышын да күп тапкырлар кабатлана.

Бер елны, Ташбулат инде тәмам буй җиткереп, боз өстендә беренче тапкыр тешен сындырып менгән елны, авылга әтисе Әбүбәкер кайтып төшә. Аның инде дүрт-биш ел күренгәне булмый Сазанакта: җәйләрен Иртештә һәм Обьта, бурлаклар белән җигелеп, баржа тарта, кышларын каядыр шахтага эшкә китеп бара. Әбүбәкернең кайтуы Сазанакка губернатор килеп төшкәннән ким булмый. Нигә дисәң, иртәгә Яман елга өстендә бу кышның соңгы сугышы. Әбүбәкер исә авылда иң көчлеләрдән — боз сугышына һәрвакыт бастырык тотып төшә торган була. Шуңа да аңа вәкилләр килеп җитә, Әбүбәкерне боз өстенә чыгарга димли башлыйлар.

— Ярар,— ди Әбүбәкер.— Чыгам, әлбәт чыгам!

Тик икенче көнне Яман елга ярына коры кул белән килгән Әбүбәкерне күргәч кенә шикләнеп кала агайлар. Нәрсә, бу урысларга каршы йодрык белән бармакчымы? Ул арада теге як ярда руслар да җыелып җитә.

— Эй, гололобый, выходи на лед!

Шулчак кемдер Әбүбәкергә тимер кендек китереп тоттыра. Тегесе исә карап-карап тора да, кендекне кар өстенә томыра, кусәк һәм балта белән коралланган русларга каршы ялгызы китеп бара. Әнә ул инде аларга якынлашып та килә. Төркем алдында торган кара сакаллы яшь кенә рус егете, учына төкереп ала да, билбавыннан кистән тартып чыгара. Әбүбәкер туктап кала, ул да түгел, бөтен Яман елга өстенә аның куәтле тавышы яңгырый:

— Хөрмәтле күршеләр! Кемне кыйнарга дип килдегез сез?! Үзегез кебек үк ач-ялангач мужикнымы? Әйдәгез уйлап карыйк әле: нәрсә бүләбез, нигә дип сугышабыз, кем өчен кан түгәбез?!

Шунда руслар төркеменнән берәү әче тавыш белән:

— Чево уши развесили? Бей его! — дип кычкырып җибәрде.

Ләкин берәү дә кузгалмый, киресенчә, кайберәүләр балта-кендекләрен билбауларына кыстырып куя.

— Күзе ачылмаган эт баласы кебек күпме яшәрбез без, дуслар?— дип дәвам итә Әбүбәкер. Аның русчасы да әйбәт яңгырый икән.— Җитәр инде, җитәр! Күзләрне ачарга, тирә-юньгә, бигрәк тә калада яши торган туганнарыбызга карарга вакыт. Анда завод-фабрикаларда, рудникларда эшләүче урысы һәм татары, башкорты һәм украины бер булып, ярлы халыкны изеп яшәүче байгуралар, завод хуҗаларына, патша этләренә каршы күтәрелә — үзләренә азатлык даулый. Ә без монда, Хисаметдин мулла белән отец Герасим сүзенә карап, бер-беребезнең канны коябыз, бер дә юкка дошманлашабыз. Җитәр! Сезгә дә, безгә дә коралны чын дошманга, патша җәлладларына каршы күтәрергә вакыт.

Бу вакыт инде руслар да, татарлар да аны урап алып, ихлас күңел белән тыңлыйлар. Ара-тирә арадан сабырсызланып кычкыручылар ишетелә:

— А ведь верно говорит.

— И впрямь, чего нам делить, зачем драться?!

— Молодец, Абубакир!

Ул сөйләп бетерүгә, төркем уртасына, яралы уң аягын сөйрәп, солдат Иван Коростылев килеп керә.

— Туганнар!— дип кычкыра Коростылев авылдашларына. Шинеленең изүен ычкындырып җибәрә, апрель кояшында күкрәгендәге Георгий тәреләре җемелдәп куя.— Әбүбәкер дөрес әйтте, чын хакыйкатьне әйтте. Безгә бер-беребезнең канын кою турында түгел, үзара дуслыкны ныгыту хакында уйларга кирәк.

Ул көнне сугышмый таралалар.

Инде бүген ызгыш, низаг булмый калды дигәндә, боз өстеннән менеп килүчеләрне Хисаметдин мулла каршылый.

— Җәмәгать, ни дип тыңлыйсыз шул имансыз Әбүбәкерне,— дип чыелдый ул, төркем каршына чыгып.— Ул бит динен урысларга саткан, кяфер бит ул! Кит, югал моннан, имансыз!— Мулла саллы гына артыш таягын күтәреп, Әбүбәкер өстенә килә башлый.

— Сук, яле сук!— ди Әбүбәкер, тунының изүен ычкындырып.— Халыкны җитәрлек алдадың инде син, карт ябалак! Менә тиздән авылга большевиклар килер, шунда барысы өчен дә җавап бирерсең!

— Ниткән большевиклар ул тагы? Әй, мөселманнар, аны тыңламагыз, акылына зәгыйфьлек килгән аның!— дип бөтен су буена сөрән сала мулла.

— Боргаланма, эт!— дип аның каршына баса Әбүбәкер.— Большевикларны яхшы беләсең син. Авылда гәҗит алдыручы син генә. Тик халыктан яшереп ятасың.

Мондый хәлне беренче күрә, мондый сүзләрне беренче ишетә Сазанак халкы. Һәркем куркуга кала, кичен шыпыртлап кына һәр йортта шул хакта сөйләшәләр. Әбүбәкерләр өендә дә сүз булмый калмый.

— Нигә генә алай эшләдең инде,— дип өзгәләнә Әбүбәкернең хатыны Сәгыйдә.— Хисаметдин болай гына калдырмас, приставка җиткерер, төрмәгә утыртыр инде, ходаем.

— Томана син,— дип кычкыра Әбүбәкер хатынына һәм киндер күлмәген ярып төшерә.— Менә ул төрмә, һәрчак үзем белән...

Аның үтә ябык тәнендәге буйга һәм аркылыга сузылган карасукызыл бурлак арканы эзләрен шунда беренче кат күрә Ташбулат.

Бөтен авыл куркышып торса да, Әбүбәкергә ул-бу булмый. Байлар һәм муллалар нишләптер бик юашланып, мескенләнеп калалар. Шул көздә Сазанакка патшаның бәреп төшерелүе турында хәбәр килеп ирешә. Әмма ел да үтми, Хисаметдин яклыларның тавышлары бөереннән чыга башлый. Ә инде авылга Колчакның бер адашкан отряды килеп төшкәч, алар ничә ай дәшми торганнарын чыгаралар. Әбүбәкер кулга алына, шул ук төндә аның янына Иван Коростылевны да китереп ябалар.

Иртәгәсен Яман елга бозы өстенә русларны да, татарларны да — бөтен Сазанак-Багульникны куып төшерәләр. Иван белән Әбүбәкер дә шунда китерелә. Аллы-артлы ике залп яңгырый. Бер-беренә таянып-сыенып торган ике ир боз өстенә авып төшә. Ике кан бергә кушылып, бозны эретә һәм, халыкның чын дошманнары кемнәр икәнен исбатлап, язга кадәр шунда кала.

Утыз беренче елда Сазанакта — «Якты юл», Багульникта «Восход» колхозлары төзелә. Күмәк хуҗалыклар оештырылып, алар аякка басуга, ике колхоз членнары киңәшеп, Яман елга аша күпер салалар. Нәкъ Иван белән Әбүбәкер атылган җирдә, гасырлар буе бер дә юкка ике халык каны коелган урында калкып чыга күпер!

Ләкин кечкенә генә агач күпер озын гомерле булмый. Яман елга аны икенче язда ук ташкыны белән алып китә. Җәен анда тагын күпер корыла, әмма холыксыз елганың ташуы монысын да ялмап кына ала. Шуннан инде бу хәл ел да кабатлана: җәй саен яңа күпер салына, яз җиткән саен ул юкка чыга. Тик ике колхоз берләшеп, тәмам ныгып алгач кына, елгага зуррак агач күпер салына һәм ул байтак еллар халыкка бик шәп хезмәт итә. Ләкин узган елның мул сулы ташуы монысын да урталай өзеп ташлый.

## 10

Алар Сазанакка килеп кергәндә, авыл инде иртәнге ыгы-зыгыдан арынган, урамда берән-сәрән мәктәпкә баручы балалар гына күренгәли иде. Ләкин аларга игътибар итмәде Ризван, аның бөтен дикъкате — колхозчы хуҗалыкларында. Авылга кереп, биш-алты йорт турын үтүгә, үзенчә нәтиҗә ясап куйды: әйе, борынгы авыл булырга охшаган. Өйләрнең күбесе, татарларга хас булганча, алты почмаклы итеп, эчкәрәк тартып салынган. Тәрәзәләре урамга карый, каршыларында янбакча. Тәрәзә кашагалары, кәрнизләр бу якка гына хас бизәкләр белән сырланган, күбесе буяулы. Кыекларда исә такта белән дранча хакимлек итә. Каралып, ярылып беткән калын-калын нарат бүрәнәләр бу өйләрнең инде бик күпне күрүләре, ихтимал, Әбүбәкер үлеменең шаһитлары да булуны сөйлиләр. Дөрес, арада яңалары, заманча — алты почмакка ян-яктан терәп салынган кухнялылары да байтак. Аларының башында калай да шифер. Искесе, яңасы булмасын, өйләр барысы да имән яисә карагай бүкәннәр өстендә утыра. Анысына гаҗәпләнмәде Ризван, бу якларда таш кытлыгы икәнен, хәтта мунча ташы урынына да тимертомыр кулланууларын белә иде. Шунысы күңеленә хуш килде: авылда йорт-җир нык, хуҗаларча салынган, койма-киртәләр төзек, абзар-кура көлеп тора. Күбесендә урыс капка, шулай да арада заманча, машина-трактор кереп йөрерлек итеп эшләнгәннәре дә күп.

Үзе йорт-җир белән яшәүче буларак, Ризван барын күреп, барын хәтерләп барды. Алай да бер нәрсәне абайламый килгән икән. Тәрәзә капкачлары ачык зәңгәргә буялган бер йорт янына җиткәч, туктап ук калды, хуҗаның җиләк-җимеш бакчасына тезеп куелган егерме-утыз баш умартаны күреп хәйран калды. Әмма бу Сазанак өчен гадәти күренеш икән. Башка бакчаларда да шулай ук ишле умарталар күргәч, һаман да егетләрчә җитез атлаган Ташбулаттан сорамый түзмәде:

— Сездә әллә барысы да умартачы инде?

— Урманта торгаң, бал кортларын та асырыйпыс,— дип җавап кайтарды тегесе.

Авыл уртасына якынлаштылар. Урамның сул ягында йортлар бетеп, тигез булып бәпкә үләне үскән бушлык башланды. Шунда, ялгызы сураеп, ташландык иске мәчет утыра. Аның инде тәрәзәләре ватылып, башындагы калайлары кубып беткән, картайган манарасы исә ниндидер бер могҗиза белән генә исән калган иде.

Шул турыга җиткәч, Ташбулат карт юлдан читкә тайпылды. Аның артыннан борылуга, Ризван каршындагы бушлыкның авыл уртасына ук килеп кергән Яман елга яры икәнен төшенеп алды. Сөзәк кенә яр башына килеп баскач, Ташбулат карт туктады, үләләр зиярәт итәргә килгән кешедәй, тынып калды. Дәшми-тынмый шактый торгач кына:

— Әткәм пелән Иванны әнәү пывойта аттылар инде,— дип куйды.

Әйтерсең мәетләр шунда ята — Ризван алга омтылып алды, ләкин елга өстендә тырпаеп торган берничә агач субайдан башка нәрсәне күрмәде. «Күпернең урынын дөрес сайламаганнар икән шул,— дип уйлап алды,— әнә тегендә өскәрәк салырга иде». Аннан күзе аръякка, мондагылар кебек үк сураеп торган таза стеналы йортларга төште. Анда өйләрнең күбесе кәрнизсез, башлары дүрт яклап та кыеклап ябылган иде. Сирәк-мирәк булса да татарча итеп, кәрнизләп эшләнгәннәре дә күренә. Шунысы гаҗәп, тәрәзә кашагаларындагы бизәкләр ике авылда да бер үк алым белән эшләнгәннәр. Багульникның урта бер җирендә, бу яктагы мәчет кебек үк, ташландык агач чиркәү моңаеп утыра.

Урам буйлап, күп тә бармадылар, Ташбулат карт яңача ясалган зәңгәр буяулы капкаларның берсенә борылды. Киң иркен ишегалдына килеп керделәр. Иң түрдә юан гына мәһабәт нарат үсеп утыра, аның күләгәсендә чия кызыл төстәге «Москвич» машинасы. Сул якта махсус проект белән салынган берничә бүлмәле агач йорт, аның почмагыннан

өч дюймлы торбаларны ялгап ясалган озын антенна күтәрелгән. Каршы якта, бизәкләп-бизәкләп эшләнгән рәшәткә артында, җиләк-җимеш бакчасы җәелеп киткән, ул якта бал кортларының дәррәү безелдәгәннәре ишетелә. Ә абзар-кура кайдадыр бакча артында иде.

— Менә гуй кайтып та еттек,— дип сөйләнә-сөйләнә Ташбулат карт капчыгын болдырга ташлады һәм шунда каплап куелган чиләкне алып бакчага таба китеп барды.

Ризванның хәле кыстатып, ялындырып торудан узган иде, күн итекләрен салып, тирләүдән юешләнгән чолгауларын итекләре өстенә җәеп куйды да аягына ишек төбендәге тирән калошларны элеп, хуҗа артыннан атлады. Ул бакчага кергәндә, Ташбулат карт коедан су алып маташа иде.

— Бирегез әле, үзем,— дип Ризван кое бавына үрелде.

Карт гүя аның сүзен ишетмәде дә, картларга хас булмаган житезлек белән су тулы чиләкне күтәрде, җилтерәтеп рәшәткәгә эленгән юынгыч янына китеп барды.

— Пер бидрә су күтәрмәеммә әллә,— дип сөйләнде ул үзалдына.

Салкын су рәхәт, арыганны, йокы килүне юкка чыгарды. Бөтен тәнендә гаҗәеп бер җиңеллек тоеп, Ризван ишегалдына чыкты. Өйдә кеше бары сизелми, шулай да ишек бикләнмәгән иде.

— Пылар пөтенесе китеп калганнар икән,— дип сөйләнә-сөйләнә, Ташбулат карт ишекне ачты, кунакны эчкә уздырды.

Өендә ул тагын да яшәреп киткәндәй булды. Ризванны ай-ваена карамый зур якка алып керде, болай да йомшак утыргычка җәймә салып, кунакны урталыктагы өстәл артына утыртты, үзе кухня белән ике арада чабулап йөри башлады.

— Килен пешереп китте гуй,— дип сөйләнә-сөйләнә, иң элек яшел эмаль тышлы миски белән итле токмач күтәреп керде, аннан тегермән ташы кадәр бодай күмәче, кашыклар китереп куйды. Инде үзе дә утыра дип торганда, тагы да дәртләнеп чоланга чыгып китте. Шуннан тотынды ташырга. Зур гына фарфор савыт белән кәрәзле бал китереп утыртты, маен, эремчеген, бавырсагын алып керде, шикәр-конфет ише тәм-том ташыды. Алары гына җитмәс дип уйладымы, хәлвә, берничә төрле варенье өстәде. Инде өстәлдә урын да калмады. Ләкин Ташбулат әле чоланга чыгып, әле кар базына төшеп, сөтен-катыгын, каймагын ташый да ташый. Аның шулай, озак еллар күрмәгән туганын каршылагандай, йөгергәләвен карап утырган Ризванны кинәт йокы басты. Тынгысыз төн һәм җаяү үтелгән чакрымнар сиздерә иде. Репродуктордан агылган җиңелчә музыканы тыңлый-тыңлый, оеп киткәнен сизмәгән дә.

— Оһо, кунак бар икән,— дигән тавышка сискәнеп, уянып китте Ризван һәм, үзенең йомшаклыгыннан кызарып, тавыш иясен карады. Өстәл янында урта буйлы, таза гәүдәле, бераз гына корсагы беленә башлаган шактый яшь чырайлы ир-ат басып тора иде.

— Гафу итегез, арылган,— дип сөйләнде Ризван, күрешергә кулын сузып. Торып басты һәм әлеге кешенең чиста итеп кырынган йөзенә, болыт булып торган көрән чәченә күз төшереп алды. Егет нәрсәсе беләндер Ташбулат картны хәтерләтә иде.

Алар танышырга өлгермәделәр, җыйнак кына ак самавыр күтәреп, бүлмәгә Ташбулат килеп керде. Әлеге кеше самавырны карт кулыннан алды да җилтерәтеп өстәлгә куйды.

— Әй, эти, үземә әйтсәң соң инде,— дип Ташбулатны битәрләп алды.

— Син мине цуттан цыгарырга ашыкма гуй, Зиннур улым,— дип гөрләде Ташбулат һәм ул, иpләп-җайлап кына, тәлинкәләргә токмач бүлә башлады.

— Мин ашаган-эчкән, эти,— диде Зиннур, өстәл янына урнашып.— Шулай да кунак булгач, табынга утырмый ярамас. Карале, эти, шунда буфетта теге нәрсә дә бар иде бугай.

Ташбулат өстәлгә ярты шешә коньяк китереп куйды.

— Сез ачуланмагыз тагы,— диде яшь хуҗа Ризванга,— көндез, эш сәгатьләрендә бу нәрсәне каба торган гадәтем юк. Колхоз председателенә килешми. Җитмәсә районга китеп барышым.

Сунарчин кайтарып дәшмәде. Ачыгуы житкән иде, токмачка ябырылды:

— Тагы перәй эшең килеп цыктымы?— дип сорады Ташбулат.

— Әй, эти, һаман да шул төзү материаллары артыннан йөрү инде. Үзең беләсең, мал-туар ишәйгәннән-ишәя, урын житешми. Шул ферманы көзгә кадәр житкерәсе иде. Агачтан салмагыз, диләр дә бит. Кая соң әле аның ташы, кирпече? Агачы житешми әле монда. Тагы теләнергә барам...

Ата белән улның үзара сүзенә әллә ни әһәмият бирми ашау белән булышып утырган Ризван председательнең бу сүзеннән сәерсенеп калды. Агач житми диме? Кызык, Себердә агач кытлыгы булсын, имеш. Күнелендәгеп кычкырып әйткәнне сизми дә калды:

— Алтын чыккан жирендә кыйммәт икән.

— Себердә дә исәпсез байлык юк шул,— дип уфтанып куйды Зиннур.— Бирсеннәр иде әле тагын ун-унбиш гектар урман. Ул чагында без кышны бер кайгысыз каршылар идек. Ярый, сандугачны жыр белән сыйламыйлар. Тотыгыз әле.

— Житте, рәхмәт. Без дә эш кешеләре бит.— Ризван эчемлекне читкәрәк алып куйды, башында исә һаман да шул агач турындагы уйлар бөтерелә иде. Һы, кешеләр аны жан атып эзләп йөриләр икән, ә без трассадагы урманнан ничек котылырга белмибез, аны ничек кирәк шулай аударабыз, ватабыз-сындырабыз, бульдозерлар белән таптатып бетерәбез... Тукта, кызык кына алыш-биреш ясарга мөмкин түгелме соң монда? Без аларга агач бирәбез, алар исә трассаны чистарта. Барыбер нәрсә дә булса вәгъдә итәргә туры килә ич аларга. Колхоз председательләрен белә инде Ризван: карты, яше булмасын, синнән ни дә булса йолыкмый торып, асат кына ачылып китмиләр, шәһәрчеккә урын бирми йөдәтәләр. Ул күтәрелеп Зиннурга карады.— Агач мәсьәләсендә без ярдәм итә алыр идек.

Председатель сагаеп калды, зур көрән күзләрен кунакка төбәде.

— Кем инде ул «без»?

— Бәй, без бит әле танышмадык та,— Ризван кызарып куйды.— Механикалаштырылган колонна начальнигы Сунарчин булам мин. Сезнең жирләр аша торба юлы сузабыз.

— Менә хәзер аңлашылды,— диде Зиннур көлеп. Ул бөтенләй үзгәреп, жиңеләеп китте, урыныннан күчеп, диванга утырды.— Болай булгач, сезнең белән иркенләп, на высшем уровне сөйләшәбез инде... Ләкин сездә бик кыйммәттер бит ул төзү материалы?

— Агачны без бушлай бирәбез,— диде Ризван, чәй тулы чынаякка үрелеп.— Тик...

Зиннур дәшмәде, кысыграк күзләрен кунакка төбәп, аның әйтер сүзен көтте. Председательнең хәйләле күзләрендә: «Беләбез без бушлайның нәрсә икәнен, бер бүрәнә алырга өлгермәссең, итен, балын сорап теңкәгә тиярсез, фатир даулап баш катырырсыз»,— дигәнне укырга мөмкин иде. Сунарчин исә, сүзен оныткандай, тәмләп чәй эчә башлады. Зиннур сүзен дә, эшен дә ярты юлда калдыра торганнардан түгел. Ризванны ашыктырырга тотынды:

— «Тик» дигәне нәрсә инде?

— Агачны үзегезгә кисеп алырга туры килә,— диде Сунарчин, буш чынаягын Ташбулатка сузып.— Шарты шул: эшне тиз тотарга, иртәгәдән кисә башларга кирәк.

«Әһә, аңлашыла,— дип уйлап алды Зиннур, күзләрен очкынландырып,— үз кирәгеңә йөрисең икән әле син, туганкай. Болай булгач, кибәккә алданырга ярамый, боларда машина ягы да иркендер әле»

— Анысын булдырабыз аның,— диде ул Ризван каршына килеп,— тик безнең транспорт ягы аламарак бит, туганкай.

Ризван аның хәйләсен шунда ук аңлап алды, йөзенә елмаю чыкты, председательнең нәфесен кыскартырга ашыкты:

— Бездә дә буш түгел инде ул машиналар, шулай да трассадан читкә алырга ярдәм иткәләрбез.

— Бер төягәч, фермага ук илтеп бушатабыз инде аны.— Зиннур көлеп җибәрде, аннан кисәк туктап өстәп куйды:— Без сезгә нәрсә бирергә тиеш инде?

— Күчмә шәһәрчек өчен күл буендагы каенлыгыгызны бирсәгез, шул җиткән.

Моңа кадәр сүзгә кушылмый утырган Ташбулат та телгә килде, анда пошилар яшәп ятканын аңлатырга кереште.

— Сезгә барыбер күчәргә туры киләчәк, әти.

Зиннурның әңгәмәдән канәгать икәне һәр сүзендә, һәр хәрәкәтендә күренеп тора иде. Ул, йөзенә чыккан шатлыгын яшермичә, балаларча кулларын угалап, идән буйлап йөренде.

— Районга бармыйбыз болай булгач,— дип сөйләнде ул, нәтиҗә ясагандай.— Безгә дә бу көннәр килер икән, әй! Беләсезме, студент чагымда практиканы Татарстанда үттем мин. Андагы колхоз председательләреннән көнләшеп үлә яздым. Нәрсә генә кирәкмәсен, нефтьчеләргә баралар. Тегеләре дә каршы килми тагын, торбасын, цементын, тимербетон әйберләрен биреп кенә торалар.

— Сез Татарстанда укыдыгызмыни?

— Әйе, Казан авыл хуҗалыгы институтында.

— Әйтәм аны гел Казан татары кебек сөйләшәсез.

...Председательнең җитез газигы авыл урамын бик тиз йөгереп үтте, Яман елганы кичте, Багульникны бер якта калдырып, тип-тигез болын юлына чыкты.

Юлның ике ягында да сөрелмәгән җирләр, күз күреме арада, асылташлар тезгән бәрхет сыман, чәчәкле ямь-яшел иркенлек җәелеп ята. Кинәт кенә борынга баш әйләндерерлек хуш ис килеп бәрелде. Шуңа сәерсенеп, Ризван пыяласы алып куелган тәрәзәдән башын тыкты һәм телсез калды. Алда — бөтен болынга сирень чәчәге төшәлгән иде. Бераз юл алгач кына төшенеп алды, сирень түгел, саз үләне сазанак, Себер татарларынча әйткәндә, йоушыр иде бу. Ул шулай дәррәү чәчәк атып, тирә-юньне гаҗәеп бер могҗиза белән күмгән иде. Зиннур кунакның ни уйлаганын сизеп алды бугай, карашын юлдан алмый гына:

— Сазанак дип юкка гына аталмаган шул инде безнең авыл,— дип куйды.

Ризван шулай табигать белән хозурланып барган арада, председательнең башында үз уе, үз мәшәкатьләре иде. «Бик тиз ризалашмадым микән?— дип уйлады ул, Сунарчин белән сөйләшүе хакында.— Ялындырырга, бераз гына тартышырга иде. Бәлки тагын нәрсә дә булса алып булыр иде үзләреннән». Шул ук вакытта икенче бер эчке тавыш аны юатып куя иде: «Ярар, беренче күрешү өчен бер дә начар түгел, күктән төшкән агач бит, кис тә ал. Аннан тагын кылын чиртеп карарга булыр».

Машинада бару җәяү атлау түгел шул — станциягә килеп тә җиттеләр.

— Сезгә шәһәрчеккәдер бит?— дип сорады Зиннур, машинаны вагон-йортлар ягына борып.

— Трассага сугылмыйбызмыни?— дип, сорауга сорау белән җавап кайтарды Ризван.

— Нигә? Йомышыгыз бармы?

— Нигә дип... Иртәгә кисә башлыйбыз, дидегез ич. Урынын күрсәтергә уйлаган идем.

— Һай, туган, минем эти аны сездән башка да яхшырак белә. Теге кемнәр әле, топографлармы? Шуларда ат белән эшләп йөрде ул. Чамасын әйтсәгез...

— Иң элек безгә күл белән станция арасын чистартырга кирәк.

— Булды, аңлашылды,— диде Зиннур, машинасын кучмә шәһәрчек капкасы төбенә туктатып.— Ярый, хәзергә. Карагыз аны, килгәләп йөрегез. Бәлки, безнең дә ярдәм тиеп куяр.

— Килербез,— диде Ризван, машинадан төшә-төшә.— Башка председательләр белән дус яши идек шулай... Бездән әллә ни ярдәм юк инде югын. Шулай да кулдан килгәнчә булышырбыз.

Машина борылып киткәч, Ризван шәһәрчеккә карап беравык басып торды. Шулчак станция ягында ниндидер тавыш, ыгы-зыгы ишетелгәндәй булды. Йөрәге кагып куйды, кисәк кенә урыныннан кузгалып, тимер юлга таба атлады. Торба әрдәнәләрен урап, ачыклыкка килеп чыкты һәм, кинәт туктап өнсез калды: әлеге торбалардан ясалган эстакада янында ак калай тышлы йортлар, торба салгычлар һәм башка җиһаз төялгән платформалар тезелеп тора иде. «Нужали килеп тә життеләр,— дигән уй үтте башыннан.— Тимер юлчыларның да йокылырын ачты Мәскәү. Тикмәгә түгел бу, кайнар булачак трассада».

Станция ягыннан ишетелгән дәртле җыр аның уйларын бүлдерде:

Адресыбыз булмаса да,
Хат килә шәһәрчеккә.
Сагынсагыз, сөйгән ярлар,
Кайтырбыз берәр кичкә.

Якташларының моң тулы иркен тавышын шунда ук танып алды Ризван. Егетләр үзләре дә килеп җиткән! Ниндидер бер тыелгысыз ярсу аны җилтерәтеп җыр каршына алып китте...

## II

Төннең серле яктылыгыннан сихерләнеп, назланып кына тайга җәйрәп ята, калкулыктагы каен кулкасыннан шул ук аклык, сафлык бөркелә. Агачларның кәүсәләрендә, әйтерсең, чык түгел, ә яктылык тамчылары саркып чыккан. Каеннар, күл өстенә төшкән шәүләләренең зифалыгына хәйран булып, яшел чукларын салындырганнар да оеп калганнар. Каядыр әчтәрәк шашып-шашып сайраган сандугачлар да, су өстендә калгып киткән үрдәкләрнең, саташып, вакыт-вакыт бакылдап алулары да, камышлар буендагы пар аккошның, мәхәббәттән исереп, назлануларында да эшләре юк аларның, үз буй-сыннарының гүзәллегенә шаккатканнар, тамырларыннан күтәрелгән шифалы суның сихәтеннән исергәннәр.

Шулай да элеккеге каенлык түгел иде инде бу. Әнә, агач араларын трактор чылбыры яргалаган, тегендә дә, монда да үләннәр тапталган, ә арырак, аланлыкта, тулы бер шәһәрчек пәйда булган. Андагы тынгысыз кешеләр исә, төн белән көн тартышкан бу мизгелдә, изрәп йоклыйлар иде әле.

Менә каенлык тагын да яктырды, бераздан бирегә, тирә-юньдәге бердәнбер калку урынга, кояш нурлары үтеп керде. Агачларның кәүсәләре алсуланып китте, ачык яшел төс белән кызыллык бергә уйнаудан, ябалдашлары сихри бер буяуга манчылды. Гүя монда гадәти каеннар түгел, сихерче тарафыннан барлыкка китерелгән алтын фонтаннар чөелеп утыра иде.

Шушы илаһи мизгелдә аланлыкка поши бозавы килеп чыкты: мондагы үзгәрешләргә, ят исләргә сәерсенеп, озак иснәнде, күзенә ятышсыз әллә ниткән иләмсез нәрсәләргә карап торды. Тозлыкның икенче бар тарафка күчерелүе исенә төште бугай, күркәм адымнар белән карт каен

төбенә килде һәм тәмле ипи исен сизеп алды. Утлыкка иелде, аның бер почмагыннан ипи телеме табып, ләззәтләнеп кенә чәйнәде. Шуннан ул шәһәрчеккә таба борылды, курку-өркүсез генә ачык капкадан үтте дә ишегалды уртасындагы улак сыман нәрсә янына килде. Маташа торгач, юеш борынын әлеге улактан чыгып торган имчәк сыман нәрсәгә төртте — каяндыр чәптереп су агып чыкты. Шулчак кинәт нидер дөбердәде — мәйданның дүрт ягына да стена булып калыккан вагон ишекләренең берсе ачылып китте. Поши бозавы ыргылып куйды, аннан бер мизгелгә генә тукталып, башын күтәрде, колакларын шомартты, борын тишекләрен киереп еш-еш сулады. Инде капкага таба томырылырга дигәндә генә таныш тавыш ишетеп алды.

— Иркә! Килдеңме, Иркә?!

Поши бозавының киерелгән мускуллары йомшады, телен ялмыйялмый Сәетнафаны көтеп алды. Тегесе исә, килеп җитүгә, Иркәнең башын кочагына алды да иплэп-назлап кына сөйли башлады:

— Килдеңме, Иркә? Ялгызыңа ямансумыни соң урманда? Шулай шул инде, син хәзер кешеләрдән башка яши алмыйсың. Үзең алардан куркасың да... Минем кебек...

Тагын дөпелдәп ишек ачылды, аннан керпе энәседәй чәчләрен тырпайткан Толик килеп чыкты, вагон астына иелеп, баш-башына авыравыр карагай кисәкләре бәйләп куелган лом тартып алды, аны штанга итеп бер күтәрә, бер төшерә: иртәнге күнегүләренә тотынды. Бераздан аның янында Кавказ күренде.

— Тукта, мин дә менеп утырам,— дип сөйләнде ул, мышныймышный кисәкләр күтәреп маташкан Толикка һәм шулчак вагоннан килеп чыккан Шаяз ягына ымлады:— Икенче башына әнә бригадирны атландырабыз!

Шәһәрчек тәмам җанланды: вагон ишекләре бер ачылып, бер ябылып торды, кулларына сабын-сөлге тоткан ярым ялангач ир-атлар, эчке күлмәкләре өстеннән бизәкле халат кигән хатын-кызлар юынгыч янына җыелдылар. Толик, кызның үзенә сиздерми генә, Таңчулпанның җилкәсенә бер уч су салды, тегесе бөтен тавышына чырыйлап җибәрде. Шуннан китте чыркылдашу, ыгы-зыгы. Яңа трассага беренче тапкыр эшкә чыгасы көннәре булгангамы, кәефләре яхшы: юктан да кызык табып көлешәләр, гөр итеп шаулашалар.

Бригаданың җыелып беткәнен генә көткәндәй, янәшәдәге вагон ишекләренең берсендә Дания күренде. Карап торуга ярыйсы гына, урта яшьләрдәге хатын ул. Озын керфекле зур кара күзләре, килешле генә җыйнак авызы, янып торган сусыл иреннәре хәтта матур итеп күрсәтә үзен. Ләкин бөтен эшне ирләрнекедәй дәү карчыга борын харап итеп ташлый. Шуңа да бригада да аны «Ямьсез борынлы чибәр» дип йөртәләр. Аның җыйнаклык, пөхтәлек кебек дөнья ваклыкларына игътибар итәргә вакыты юк: авыз тутырып, тартынмый-нитми бер сөйләшергә булсын да, тамагы кытыкланганчы шаркылдап көләргә булсын.

— Егетләр, имеш,— дип башлады ул чираттагы тупас шаяртуын,— берәрсе кереп, хәлемне белмәсме диеп, юри ишекнең келәсен элмичә яткан идем. Кая ул! Яттылар да үлделәр, суерлармыни.

— Бәй, чакырмадың ич, Даниякәй,— дип шуклануны куертып җибәрде Кавказ.

— Чакырып эт кенә йөри.

— Ә-әй, юк инде чибәркәем, шаяртма!— Кавказ сабын белән сөлгесен юынгыч өстенә куеп, иркенләп сөйләргә әзерләнде.— Әле дәшеп китергәндә дә әллә нинди хәлләргә юлыгасың кызлар янында. Бервакыт шулай, Шөгер ягында буровойда эшләгәндә, чибәр генә кыз белән танышып киттек. Күргәч тә крах булып акылдан язарлык асыл зат. Ну, мин, кәнишне, егылып китмәдем, андыйларны беренче күрүем түгел... Кичләрен йөрибез моның белән урам буйлап туди да сюди. Берзаман түйдырды бит болай бушка чабата туздыру. Сүз каттым бит тегеңә:

«Кайда йоклыйсың?»— мәйтәм. «Кайда булсын, караватта инде»,— ди бу. «Һә-әй,— мәйтәм,— җәйге кичләрнең, саф һаваның кадерен белмисең икән» һәм башкалар, һәм башкалар. Печәнлектә кунарга күндердем бит моны.

Кавказ туктап калды, болай да кысык күзләрен йома төшеп, янындагыларга карап алды: тыңлыйлармы, мәзәкнең кадерен беләләрме? Әмма тегеләрнең аңарда эшләре юк: кайсы пош-пораш килеп юына, кайсы тәне буйлап сөлге йөгертә, кайсы чәчен тарап маташа. Бер Дания генә, авызына җыелган суны еш-еш йотып, аңа текәлгән, печәнлектә булачак хәлләрнең куеруыннан эреп киткән иде.

— Икенче көнне,— дип дәвам итте Кавказ,— авыл тынып, тәрәзәләрдә утлар сүнгәч, шикләнә-шөбһәләнә генә Сәлимәкәем янына киттем. Печәнлеккә менә торган баскыч янына җитсәм... йөрәгем тирес арасына төшеп китте дип торам, баскыч төбендә һәркайсы көймә кадәр ике галош тора. Уф, монда икән, җанкисәгем! Дөм-караңгы печәнлеккә менүгә, кулым паласка төртелде, шикләнүләрем тәмам юкка чыкты. Менә ич аяклары алтынымның... Бармакларын тотып карадым, балтырына күчтем. Уянмый, бәгырь, көн буе эшләп арган, күрәсең. Кулларым белән һаман өскә таба үрмәлим, инде күкрәге тирәсенә дә килеп җиттем, тик бер дә кулга ятышлы йомшак әйбер туры килми, бары да каты-коты. Тагы да өскәрәк үрелгән идем — учыма бер көлтә сакал килеп кермәсенме! Ул да түгел, сакал иясе йөрәк яргыч аваз белән акырып җибәрде:

— Ка-ка-каравыл! Үтерәләр!

Төзүчеләр шәһәрчекне тутырып көлеп җибәрделәр.

— Ну, шыңкытасың да инде, Кавказ дус.

— Өрдерә, кибәге күзгә керә.

— Яле, я, сөйләп бетерсен кеше.

Кавказ инде хикәятенең ахырына җитәргә ашыкмый иде. Хәзер кусаң да, тыңлап бетерми торып, китмиячәкләр. Ул кесәсеннән бөкләнеп, суерланып беткән сигарет пачкасын чыгарды, тәмәке кабызып, ләззәтләнеп төтен йоткач та байтак тын торды әле.

— Әллә үзем сикергәнмен, әллә яшен сугып өлгерде,— дип сөйләп китте Кавказ, тавышын акрынайтып,— «ә» дигәнче җиргә тәгәрәп төшкәнмен. Карт исә, борып куйган патефон кебек, акыра да акыра: «Ра-разбой, үтерәләр!»— дип сөрән сала бу. Дәшәм тегенә: «Шәйхаттар агай, тукта,— дим,— кызың янына гына килгән идем»,— дим. Кая ул туктау, аның саен ярсып кычкыра, сакау тәре. Бераздан басылды бу. Тик ул чакта тирә-күрше җыелып өлгергән иде.

— Соң, кабырганны санадыlaрмы?

— Санавын санамадылар. Алай да буровойдан китәргә туры килде — көлеп теңкәгә тиделәр. Менә шулай да була, Даниякәй, кызлар куены.

Дания ерылып киткән авызын көчкә генә җыеп алды, уенын-чынын кушып әйтеп салды:

— Юктан куркасың, Кавказ...

Тагын чыркылдашып алдылар.

— Юк инде, җитәр! Сезнең брат авызны күп пешерде минем,— дия-дия, Кавказ буй-буй ак төшә башлаган чәчләрен юынгыч астына тыкты.

Бу кешеләр инде үз гомерләрендә күпме генә яңа трасса кормәгән дә нинди генә юллар үтмәгән! Шулай да һәр яңа трасса — бәйрәм алар өчен. Ни генә димә, һәр трасса — көндәлдә яңа бер сәхифә, укылмаган китап, башланмаган тормыш. Шушы тантаналы, бераз гына шөбһәле минутларның ләззәтен турыдан-туры трассада эшләүчеләр генә түгел, шәһәрчектә калучылар да тоя. Аш пешерүчеләр иренмәгәннәр бүген, төннән торып, пилмән ясаганнар, мае тамып торган пылау әзерләгәннәр. Зур гаиләдәй дәррәү ашарга утырдылар. Әмма тыелгысыз уен-көлке,

мәзәк өстәл янында да басылып тормады. Андый чакта шаярырга сәбәбе дә чыгып тора бит аның. Әнә, үрдәктәй чайкалып, ашханәгә Дания килеп керде, пилмән салып куелган тәлинкәне алды да, күзләре белән урын эзләп, урталыкта басып калды. Аннан өстәл янындагыларны этә-төртә, Сәетнафа кырыена кереп утырды.

— Йәле, хет син ир бул, Сәетнафа, иңнәрне иңгә куеп, парлап кына ашыйк бер.

Тегесе шөпшә тешләгәндәй сикереп торды, пылаулы тәлинкәсен эләктерде дә, үләттән качкандай, ашханәнең ары башына китеп барды.

— Һайт, Дания тота бит!— дип кычкырып калды кемдер.

Сәетнафаны шулай ирештерүләре беренче тапкыр түгел. Комендант нишләптер хатын-кыздан уттан курыккандай курка, алар белән ялгыз калмау яисә яннарына утырмау өчен теләсә нинди җәберне, көлкене күтәрергә әзер.

Бераздан игътибар Кавказга күчте.

— Россиядә син булмаган төбәк калдымы әле, Кавказ?— дип сорап куйды Гөлзәминә.

Сүз башларга җай гына булсын инде Кавказга, элеп алып та китте:

— Һай, туган, безнең ил зур, бик зур бит ул. Абзаң аяк басмаган урыннары да бар әле аның. Пример, Сочины күргән юк минем, бер генә курортка барганымны да хәтерләмим.

— Ә ял йортына?— дип төрттереп куйды Шәхсәнәм.

— Анысында булмадым дисәм, гөнаһка батуым бар. «Васильево»-да өч төн кундым бер...

— Анда бит унике көн ял итәләр,— дип утка ялкын өстәп куйды Сыртлан.

— Түзәрсең анда унике көн,— дип сөйләнде Кавказ, икенче порция пылау белән булашып.— Өч көнендә дә эшсезлектән үлә яздым. Тегендә барам — таяк белән шар төртәләр, монда киләм — ятьмә аша туп ыргыталар. Берәүләр тик йөри, икенчеләре кеше хатыннары артыннан чаба...

— Ә син нишләдең?— дип сөйләүчене кыздырып җибәрде Толик.

— Ул яктан махы бирмәдем бирүен, икенче көнне үк тоттым бер нечкәбилне. Казанныкы булып чыкты, хәерсез. Якын җир бит, ире килгән. Урманнан чыгуыбыз булды, ире сугып екты тегене.

— Ну-у-у? Шуннан?— диеште тезүчеләр.

— Иртән иртүк җыендым да тайдым мин моннан. Казанга киттем, оргсинтез төзелешенә. Вәт анда булды хәлләр. Өченче хатыныма шунда...

Моңа кадәр сүзгә кушылмый гына ашап утырган Шаяз, өстәлне дөбердәтеп, урыныннан кузгалды:

— Әйдәгез! Кавказның әкияте бетмәс аның...

## 12

Әрҗәсе брезент белән томаланган машинага менеп утыргач, сабырланып тынып калдылар. Кабинаны Гөлзәминә белән Шәхсәнәмгә биреп, Сунарчин үзе өскә, эшчеләр янына урнашкан иде. Аңардан тартынулары микәнни? Юктыр. Бер чыр-чу килә башласалар, яннарында Ризван түгел, министр үзе басып торса да, уен-көлкене ташламаячаклар. Болай үзләре басылып калганнардыр. Ни әйтсәң дә, гомер күрмәгән-ишетмәгән җиргә аяк басулары бит.

Чыннан да, тезүчеләрнең трассаны үз күзләре белән күргәннәре юк әле. Торба салгычларны, машина-җиһазларны илткәндә тимер юл буендагы шоссеదан йөрделәр. Трасса хакында бар белгәннәре — участокның аргы башы гына. Кыенлыкларны күз алдына да китермиләр. Ярый, вакыты җитми торып белмәүләре яхшы, күңелләрен төшермәсен-

нәр. Ә хәл ярыйсы ук җитди. Сунарчин, машина барган җайга тирбәлеп, күзләрен йомды...

Төзүчеләрнең, брезентны ертырлык итеп, дәррәү көлеп җибәрүләреннән айнып китте Ризван һәм сораулы карашын егетләргә төбәде. Нәрсәдән көләләр болар шул хәтле? Әй, Кавказ теленә салынадыр ла. Юк, бригадага яңа килгән Дамирны ирештерүләре икән. Тегесе трассага ак күлмәк киеп, муенына галстук тагып чыккан.

— Син, Дамир, кояштан саклана торган ефәк зонтик та аласың калган,— дип егеткә ябырылуында Кавказ.— Аннан да главные — эшләпә киярга иде, траншея буенда күренгәннәргә эшләпә болгап кына барасың.

Дамирның кызларныкыдай ак йөзе алсуланып янып чыккан, пыяламамык кебек аксыл чәче, һәр бөртеге үзенә бер якка карап тырпайган ак кашларына кадәр ояла сыман. Егетләрдән бигрәк янәшәсендә утырган Таңчулпаннан уңайсызланып, күзләрен әрҗә идәнендәге ярыкка төбәгән дә акланырга маташа:

— Кешенең һәр җире матур булырга тиеш, дигән Чехов: йөзе дә, киеме дә, җаны да, уйлары да...

— Чәче, чәче, дигән ул,— дип сүзгә кушылды Сыртлан,— иң мөһиме чәч кешедә. Чәч матурны тагын да гүзәл итә, шөкәтсезне тагын да ямьсезли.

— Ул яктан сынатмый безнең Дамир,— дип эләп алып китте Кавказ.— Әнә бит, чәч кенәме, прәме арыслан ялы, калак сөягенә төшеп тора. Дамир түгел, Дамирә.

Тагы гөр итеп көлешеп алдылар. Бу инде трассачыларның егетне шушы минуттан башлап «Дамирә» дип йөртәчәкләрен раслау иде.

Бер Таңчулпан кызганып барды Дамирны. Трассачыларны белә ул: бер кабып алдылармы, чәйнәп өзми туктамыйлар. Йә елап, йә үзең үк сүзне уенга борып котылсаң гына. Дамир исә ул хәтлесен белми әле, кыз аңа ярдәмгә ашыкты — сүзне икенчегә борырга булды:

— Кавказ абый, синең чын исемең ничек? Паспортыңда да шулаймы?

— Һе, исемнең юрие дә була микәнни?

— Кушаматтыр, бәлки?

— Юк, законные шулай — Кавказ.

— Кит инде, шундый исем буламы? Мулла кушамы инде шундый пучтәк атны?!

— Мулла кушмаса, әтәй кушкан.

— Сөйлә, ә, Кавказ абый?

— Сөйләсәң, озак инде ул,— дип, гадәтенчә, бераз ялындыру чамасын сиздереп куйды Кавказ.

— Әйдә яр, юл ерак бит,— диеште трассачылар.

Кавказ, барының да дикъкате үзендә икәнне тоеп, тынып калды, күкрәкләрен, янбызларын каккалап, тартырга эзләгән булды, аннан янәшәсендәге Толикның тышкы түш кесәсеннән күренеп торган фильтрлы сигаретын тартып чыгарды.

— Беләсез бит инде, утыз беренче елда районнар оештырыла,— дип тәмләп кенә башлап җибәрде ул сүзен.— Язмыга-таем дигәндәй, район үзәген безнең авылдан өч чакрымдагы Юкалегә куялар. Район оеша, төрле-төрле оешмалар барлыкка килә. Тик аларда эшләргә кешеләре дә кирәк бит әле, аларын да Казаннан төяп килмәссең. Шуннан тотыналар авыллардагы язу-сызу белгән активистларны, минем кебек телгә беткәннәрне җыярга. Минем әтәй, болай бик актив булмаса да, төшеп калганнардан түгел икән. Җитмәсә, дүрт-биш ел мәдрәсәдә укыган, аннан ликбездә, өяз каласына барып ике айлык курс та бетереп кайткан. Авылдагы мал-туарның сырты кортласа, койрык асларына карболка сөртеп йөри, кыскасы, ат духтыры. Аны да чакыртып алалар район үзәгенә — ветпунктка дезинфектор кирәк икән.

Кинәт машинаның сул яктагы тәгәрмәче ниндидер чокырга туры

килде, уң якта утыручылар, чырыйлап, каршылары итәгенә капланды. Сүз киселде, Кавказ тынып калды, тәзүчеләрнең тынычлануын, кыстаганын көтте. Ләкин аны ашыктыручы күренми иде. Көтеп-көтеп тә йөдәтүче булмагач, бүленгән хикәятен дәвам итте:

— Район үзәге әнә шундый төрле-төрле халык белән тула бервакыт. Кичәге крәстияннар культурный интеллигентка әйләнде бит инде. Тик бу культурныйлыкны башкаларга ничек күрсәтергә? Баш вата торгач, әмәле табыла бит моның. Әүвәл, иң культурный кеше буларак, район газетасы редакторы күрсәтә кемлеген — яңа туган улына «Авангард» дип исем куша. Атна да үтми, милиция начальнигының малаен «Наган» дип атавы мәгълүм була. Шуннан башлана бу кизү, авылда бала тудымы, Эдуард та Альберт, Урал да Памир. Аннан дөньяга бер-бер артлы Спартаклар, Икарлар килә. Бераздан, бик популяр исемнәр кушылып беткәч, Альянус, Академия, Гатуф, Рафинад ишеләре хутка китә.

Минем әтәй, культурный кешеләрнең берсе буларак, бу хәлгә бик көнләшеп йөри. Барысын шаккатырырлык бер исем кушар иде, бала тумаган, нишләптер инәй ашыкмый икән — нәкъ тугыз ай корсагында йөрткән мине. Бик аптырагач, культура кертүне үзеннән башларга була бу. Хыялетдиннең «этдин»ен алып ата да «Хыял» булып кына йөри башлый. Тик һаман да эчен бер нәрсә тырнап тора икән, телдән әйтү белән генә түгел, кәгазьләрдә һаман «Хыялетдин» бит. Шуннан документларын алыштырырга була. Бер уңайдан фамилиясен дә культурныйлаштырып куя — Виноградов. Әмма моңа берәү дә шаккатмый. Нигә дисәң, аның кебекләр күп була Юкәледә: кайсы фамилиясен «Чапаев» дип үзгәртә, кайсы исемен «Завгар» дип төзәттерә. Әтәйнең тагы эче поша башлый. Шулчак акырып, елап, разбой салып мин дөньяга килгәнмен. Малай булгач, түбәсе күккә тигән әтәйнең. Чөнки шул көннәрдә генә кызыл почмактагы радиодан бик матур бер сүз ишетеп кайткан була — Кавказ. Мондый исем әле берәүдә дә булмый Юкәледә, бары миңа насыйп икән...

Моңа хәтле менә ерылам, менә көләм дип, мимылдап торган ирен-нәр, кинәт җәелеп, кайсы хахылдый, кайсы хихылдый башлады. Юлдашлары көлеп аргач кына, Кавказ сүзенә йомгак ясап куйды:

— Дөрес, миннән соң да Юкәледә унлап малайга «Кавказ» дип кушканнар кушуын. Ну ләкин беренчелек минем әтәйдә калган тәки. Менә шул. Юкка исегез китә, мин үскәндә бер безнең урамда гына да дистәдән артык «Марсельеза», биш-алты «Академия», берничә «Институт», тагы әллә кемнәр бар иде.

Машина тагын бер бик каты чайкап алды, шоссědан төшеп, сулга, тәгәрмәч эзләре белән яргаланган чирәмлеккә борылды.

Трассага якынлашуларын сизеп, тынып калдылар.

## 13

Шаяз Рамаев бригаданың тезгенен кулларында нык тота, берәүгә дә чыгымчыларга юл калдырмый. Шунысы кызык, Сунарчин шунда булуга карамастан, һәркем киңәш сорап Шаязга килә, кечкенә генә куанычын да, шик-шөбһәсен дә аның белән уртаклаша. Рамаевның абруе каты куллы булуында гына түгел иде бугай. Хикмәт — аның, бригадирлыкка ташлама көтми генә, йөкне башкалар белән бергә төпкә җигелеп тартуында булса кирәк.

Бригадир бүген дә үз урынында иде. Вахта машинасыннан төшеп, тигез рәткә тезелгән торба салгычлар янына килүгә, ул инициативаны кулына алды. Ризван аңа комачауламады. Киресенчә, үзен иркенрәк тотсын дип, читкәрәк китеп басты һәм әле генә килгән юлларын күзәтә башлады. Көткәне — кайнар битум төягән машиналар күренми иде әле.

Ашыгып үзенә таба килүче Шаязны күргәч, башыннан битум хәсрәте китте, күңелен шом биләп алды. Ни булган? Бригадирның килеп җитүен дә көтми, аңа каршы кузгалды.

— Нишлибез, Ризван абый, кичә сөйләшкәнчә, дүрт агрегат белән башлыйбызмы? Әллә...

— «Әллә»гә урын калмаган иде бугай бит, Шаяз,— дип тыныч кына җавап бирде Ризван.— Нәрсә, Бәкер килгәнче башламый торыйк дисеңме?

Шаяз нидәндер курыккан сыман, чалт аяз күк йөзенә, кояш җылысы астында изрәп яткан урман-әрәмәләргә, бихисап чәчәкләр исенә чумган болынга карап алды.

— Андый сүзне ничек телең барып әйтәсең, Ризван абый? Шушындый көнне әрәм итәләр димени? Өлкә газетасына күз салгансыңдыр: күршеләр чакрымнар саныйлар анда. Мәскәүдән килгән Цветков колоннасы атнага биш чакрым үткән; ди әнә. Ә без?! Бәкернең торба салгычын да «җигик» мәллә дим?

— Син, Шаяз, әллә шаярасың, әллә ялгызың ике агрегатта эшләргә уйлыйсыңмы?

— Шәхсәнәм апаны утыртабыз. Тракторчы бит ул.

— Моннан утыз ел элек кәҗә тракторында эшләгән хатын белән ишәрсең ишәк чумарын. Тагын да аламарак хәлгә калуыбыз бар.

— Калмабыз! Өченче көн Бәкер машинасын ул алып килде бит. Сыртлан абый өйрәткәләп тә маташты үзен... Дүртәү эшләр идек анысы, торба салгычны монда калдырып китеп булмый бит инде. Аннан безгә запас машинист турында да уйларга кирәк, Ризван абый. Ни әйтсәң дә Себер бит.

— Ай, Шаяз, бер дә күңел тартмаган эш кузгатасың әле син.— Ризван тынып калды, беретын салып, учы белән тәмам сирәкләнеп калган баш түбәсен сөртеп алды.— Ярый, сынап карыйк, тик, зинһар, күз уңыннан җибәрмә инде син аны.

Кешеләр бөтен күңелләрен биреп, янып-көеп эшләгәндә, алар янында буталып йөрергә, күп белгән булып, алар үзләре аңлап торган нәрсәләр хакында акыл сатарга яратмый иде Ризван. «Урал» машинасы янына барып, аның канатына сөялде дә аптырап калды. Бүгенгә ниятләгән эшләре күп иде күбен: сварщиклар янына барырга, түшәүлек салучыларны эзләп табарга, җир казучыларны күрергә, ташлап калдырылган сазлыкларда чокыр казу һәм торбаларны ялгау турында сөйләшергә иде исәбе. Кая инде, колонна беренче адымнарын ясарга торганда, ничек ташлап китәсең, ди. Баштагы адым ныклы, ышанычлы, бердәм икән, эш майлагандай барачак, бригада бернинди кыенлык каршында да туктап калмас. Инде кузгалып киткәндә үк аяклар бутала, көй бозыла икән — күпне өмет итмә.

Дөрес, егетләрнең эшне әйбәт башлап җибәрәчәкләренә ышана ул. Аларның утка дисәң — утка, суга дисәң суга керәчәкләренә иманы камил. Шулай да өч кешегә ышанып җитми Ризван. Аларның берсе — торба салгыч машинисты Мәүлетбай, озын буйлы, какча гәүдәле шыксыз кеше. Юк, Мәүлетбай эчкече дә, юкка-барга ызгыш-талаш кузгатучы җәнҗалчы да түгел. Саран — бары шул гына. Хәер, саранлыкка гына сыймый аның комсызлыгы. Мәүлетбайның иманы да, алласы да — акча. Бөкрене кабер генә төзәтә, диючеләр хак икән. Мәүлетбай трассачыларның әче теленнән куркып, көннәр буе дәшми йөри. Аз гына буш ара килеп чыктымы, берәр аулак почмакка посып, куен дәфтәрен чыгара, нидер саный, яза, сыза. Бервакыт, үзе йоклагач, егетләр аның әлеге кенәгәсен алып актаралар һәм шаккаталар. Куен дәфтәренең бите саен тиеннәр, сумнар... Бер урында ул алган акчасын язып барса, икенче җирдә контора тарафыннан төрле басып калулар, профсоюз взнослары суммасы, кемнең дә булса туган көненә алынган бүләк өчен чыгымнар, хәтта әнисенең җеназасы өстендә таратылган хәер акчасына

хәтле тиене тиенгә теркәлгән. Берничә бит өч процентлы дәүләт заемына багышланган. Аннан да ары квартира, газ, су һәм электр энергиясе өчен түләнгән акчалар. Шуларны санап кына юанса ярар иде дә бит, юк, башкаларга тынгы бирми. Сүз башладымы, акчасы юклыктан, хезмәт хакы азлыктан, товар бәяләренең кыйммәтлегеннән зарланырга тотына. Аннары, арзаны була торып та, кыйммәтле күлмәк алган хатынын сүгеп ташлый, ыштан ертып кайткан улын атналар буе каргап йөри. Һич тә булмаса, син берни уйламаганда: «Безнең министр күпме ала икән?»— дип баш катыра.

Эшчеләрне шулай җәфаласа, Ризванның җанын башкача кыйный Мәүлетбай. Кичен, шәһәрчеккә кайту белән, ул конторкага килеп керә, һәм Сунарчиннан нарядларны күрсәтүне таләп итә башлый. Наряд турында булмаса, спецовка сорап йөдәтә. Ризван эш киемнәре алу тәртибен аңлата-аңлата да арды. Мәүлетбайга аны сөйләп торасы да юк югын. Әмма тегесе кайчан һәм ничек өстәмә киемнәр алу юлларын белә. Берәр алама сырма табып, шуны айлар буе күтәреп йөри, акт яздырып, гамәлдән чыгармый торып туктамый. Чөнки эшкә булмасын, рәешкә булмасын, кибеттән кием алып кию гадәте юк аның.

Кавказга да таянып бетә алмый Ризван. Ул җилкуарның теләсә кайчан бригаданы ташлап китүе бар. Аның илгизәрлеген белгәнгә, бервакыт үзеннән дә сорады:

— Сер булмаса, әйт әле, Кавказ, нәрсә куып йөртә сине болай ил буйлап?

Кавказ көрсенеп, беравык дәшми торды.

— Үзем дә белмим,— дип куйды аннары,— бер урында озаграк эшли башласам, пошынудан эчем күбә минем. Яңа җиргә күчсәм, кызык булып китә: башка табигать, башка кешеләр...

— Башка хатын,— дип өстәде шуңа Шаяз.

— Яңасын яңа, тик алар тормыйлар минем белән. Миңа ияреп, ике-өч тапкыр күченеп карыйлар да, зимагур дип, кул селтиләр.

Әмма аңардан да бигрәк Дамирдан шикләнә Сунарчин. Дөрес, ул әле аны юньләп белми. Карап торуга әйбәт кенә, таза, төскә-биткә дә килмәгән җире юк. Ләкин артык күпшы, көяз. Дамирның менә шул ягы шөбһәләндерә дә колонна начальнигын. Җитмәсә, егет бик мәгълүматлы, кирәксә-кирәкмәсә дә үзенең гыйлемлеген, күп белгәнлеген күрсәтеп алырга ярата. Мондыйлар, гадәттә, я ялкау, я җәнҗалчы — һәрхәлдә, бригадада төпләнеп кала торганнардан түгелләр.

Кинәт болынның сихри тынлыгын куәтле мотор тавышы ярып керде, һавага кайнар гудрон исе таралды. Төзүчеләр телендә «Луноход» дип йөртелә торган битум ташу машинасы, аңа хас булмаган житезлек белән, изоляцияләү машинасы янына килеп туктады. Шуны гына көткәннәр икән, аллы-артлы пускачлар пытырдый башлады, авыр ухылдап дизельләр кабынды. Дистәгә якын машинаның берьюлы үкерүенә күнекмәгән кошлар, янәшәдәге әрәмәлекне ташлап, каядыр очып киттеләр. Тик ялгыз шөлди генә, үз сазлыгын ташлап китә алмыйча тирәкләр өстендә әйләнә иде.

Бригада тормышында сирәк була торган тантаналы вакыйга — яңа трассада беренче адым ясау минуты җитте. Инде изоляцияләү машинасы сыек битум белән тутырылды, инде моторлар ярсып эшли, инде машинистлар бар да урыннарында. Ләкин никтер кузгалмыйлар, Сунарчинның фатихасын, хәерле юл теләвен көтәләр бугай. Ризван ашкына-җилкенә колонна алдына килде, корыч гәүдәләренә коточкыч зур көч туплаган машиналарга, аларны тезгенләгән хуҗаларга карап бер мизгел генә торды да, кулын селтәп, Шәхсәнәм утырган торба салгыч янына китеп барды. Юк, бу кечкенә хатынның тау кадәр машинаны идарә итүенә ышанып бетми иде ул.

Шәхсәнәм белән янәшә утыруга, алдагы агрегатка — Шаязга кул болгады:

— Кузгал!

Колоннаның беренче ыргымыннан кәефе күтәрелеп китте Ризванның, хәтта йөзенә елмаю чыкты. Шушы бәхетле мизгел рәхәтеннән айный алмыйча, йөз метр ара узганын сизми дә калды. Бераздан исенә килеп, башына уй төште. Дөресен әйткәндә, монда инде аңа эш юк иде. Шулай да агрегатта Шәхсәнәмнең ялгызын калдырасы килмәде. Үзенең һаман да Шәхсәнәм кырыенда бер эшсез утырып баруын күңеленнән шулай аклаcа да, вакыты бушка узуга эче поша башлады. Ул, урыныннан кузгалып, җиргә сикерде, һәр агрегатны йотардай булып карый-карый, колоннаны яныннан үткәрде дә төбендә биләүле торба яткан траншеяга төште. Беравык торба өслегенә карап торды, күзләренә генә ышанмыйча, чорналган тасманы капшап-капшап карады. Маташкан саен, йөзе бозылды, күзләре кысылды — эшнең сыйфатыннан канәгать түгел иде ул. Тасма нишләптер тигез ятмый, өслек җыерчыкланып-дулкынланып тора.

Ул колонна алдына басып кулын күтәрде — моторлар гөрелтесе сүрелеп, дөнья тынып калгандай булды. Шаяз машинасыннан төшеп җиткән иде инде.

— Ни бар, Ризван абый?

— Чорнау ошамый миңа,— диде Сунарчин, колонна ахырына таба атлап.

Терсәкләреннән мазутка, гудронга батып, җыйнаулап маташсалар да, эш сузылды, машина, киресенчә, көйсезләнгәннән көйсезләнде. Алар шулай дөньяларын онытып маташкан арада, төш ауды, һаваны салкын тартты. Инде ашыйсылары килеп бетте, инде Дамирның чал «арыслан ялы» карага манчылды, инде кояш та каядыр казах далалары өстенә күчеп, ничектер төссезләнде, кечерәеп калгандай булды, саран җылыта башлады. Кичке дүртләрдә генә агрегатның җаен таптылар. Барысы да җиңел сулап куйды, телләре ачылды, бөтенесе берьюлы сөйли-сөйли, якындагы тирәк төбенә атладылар. Алай да ашаганда бер-беренә сүз катучы булмады, авызлар чәпелдәде дә борыннар мышкылдап торды.

— Менә хәзер ашханәгә кадәр түзәргә дә була,— дип куйды Мәүлетбай, ашап туйгач, һәм ялгызы бер читтә черкиләр белән сугышып утырган шоферга борылды.— Әйдә, туган, арбаңны бор, кайтабыз!

— Ничек инде «кайтабыз»?— диде Шаяз коры гына.

Кавказ исә сүзне уен-көлке белән бетермәкче булды:

— Шәһәрчектә дә Хупҗамалың мунча ягып көтми лә...

Мәүлетбай бу сүзне башларга күптән әзерләнгән бугай, куеныннан җәһәт кенә «Профсоюз хезмәткәре белешмәсе» тартып чыгарды.

— Менә монда, туганкаем, совет эшчесе көнгә җиде сәгатьтән артык эшләргә тиеш түгел, диелгән.— Ул кулындагы белешмәне Кавказның борыны төбендә уйнатып алды.— Инде алай-болай артыгын эшләргә туры килә икән, икеләтә түләргә диелгән.

Ризван, аның сүзләрен ишетмәгәнгә салышып, дәшмәде. Башкалар да, Мәүлетбай белән бәхәсләшәселәре килмичә, тынып калдылар. Бер Шаяз гына иреннәрен чәйнәп-чәйнәп торды да:

— Менә нәрсә, Мәүлетбай, эшлисең килмәсә, кит син,— диде.

— Житкәндер инде сиңа безнең җанны таларга,— Толик, чәчрәп аягына басты.— Һаман бер балык башы туйдырды бит инде. Гарык!

— Вәт ахмаклар,— дип куйды Мәүлетбай, тыныч кына,— мин бит сезнең интересны яклап сүз кузгаттым. Әйттем исә кайттым.

— Синең кайгыртуың өч тиенгә дә кирәкми безгә,— Шаяз урыныннан кузгалды.— Ризван абый, колоннадан чыгарып атам мин аның агрегатын!

Шаяз ярсуын тыя алмый ашкынып, агрегатлар янына китеп барды. Башкалар аның артыннан кузгалдылар. Мәүлетбай, белешмәсен куенына яшереп, баскан урынында бераз таптанды да тегеләр артыннан йөгерде.

— Мин бит болай гына, шаярып кына,— дип мыгырданды ул үзал-

дына һәм барысыннан элек торба салгычына менеп утырды.

Якә дәррәү моторлар үкерде, янә тирә-юнь куәтле гөрелтедән калтырангандай булды, тирәкләренә әйләнеп кайткан кошлар кабат канәгатьсезләнеп һавага күтәрелде. Кояш офыктагы чыршы-сөңгеләрнең үткер очларына төшеп тәртелгәч кенә тукталдылар. Ризван янына кулына пикет казыгы тоткан Таңчулпан килде.

— Дүрт йөз метр, Ризван абый.

Коры, тигез җир өчен аз, бик аз иде бу. Мондый темп белән барганда, бригаданың хурлыкка каласы көн кебек ачык...

## 14

Колоннаның исә яңа начальникта да, алда торган сазлыкларда да гаме юк, ул ашыкмый-кабаланмый гына, бер җай белән алга бара да бара. Шулай ук бик көчәнми генә торба салгычлар гүли, чистарту машинасы чиный, изоляцияләү агрегаты тырылдый. Менә куәтле машиналар гаскәре туктап калды — бераз гына артта калып траншея буйлап килгән бульдозерны көтәләр. Тегесе колонна белән тигезләнүгә, чанадан Гөлзәминә белән Дания сикереп төштеләр дә, кулларына пыяла-мамык төргәкләре тотып, изоляцияләү машинасына таба атладылар.

Урта яшьләрдәге бу ике хатынны якынайткан уртак сыйфат — икесенең дә эшкә комагай, физик яктан таза, чыдам булулары дыр, мөгаен. Шулай да алар бер-береннән ала карга белән тутый кош кебек аерылалар иде. Гөлзәминә табигате белән басынкы, сабыр, күндәм. Төскә-биткә дә күркәм генә: болай да битум кисәге сыман кара күзләре озын керфекләре күләгәләүдән тагы да кара, зур булып тоела. Килешле генә туры борын, өлгереп җиткән әнис алма төсле җиңелчә кызарган бит, иягенә якынрак урында — елмайган саен беленеп-беленеп киткән нәни чокыр һәм ниндидер бер самими сөйкемлелек аны кызлардай яшь күрсәтә. Тик тыгыз кара чәченә үткер күзгә генә күренерлек булып йогып калган еллар тузаны — зәгыйфь кенә аксыллык аның инде дөньяның ачысын-төчесен татыганын сөйләп тора. Озак еллар буе авыр эштә, һәрвакыт кола-яланда, кояш, җил-яңгыр астында йөрүенә карамастан, гәүдәсе җыйнак, зифа, хәтта күкрәкләре дә кыз-кыркынныкы сыман тыйнак кына калыккан. Гөлзәминәнең бөтен килеш-килбәтеннән, үзен-үзе тотышыннан нәзакатьлелек, нәфислек, мөлаемлык бөркелә. Моңа аның үтә җыйнак, пөхтә булуы ярдәм итә бугай. Бизәнү-ясану өчен бернинди шартлары килмәгән кыр уртасында, эш арасында, тузан-сөрем эчендә дә ничектер чиста йөрү, эш киемнәрен пөхтә итеп кию җаен таба ул. Тавышы ягымлы, сүзе төпле булса да, Гөлзәминә артыгын сөйләмәс, тупас уен-көлкегә кушылып китмәс, тора салып теләсә кайсы ир-аттан үзенә кул салдырмас. Бригададагылар аңа аерым бер ихтирам белән карыйлар иде. Дания исә бик җыйнаклардан түгел. Гәүдәсе авыр эштәге ирләрнекедәй таза, мускуллары тыгыз, нык. Мул күкрәге аның әзмәверлеген куәтли генә. Атлап йөрүе дә, хәрәкәтләре дә, эшләве дә ирләрчә Даниянең. Кулындагы пыяла-мамык төргәкләрен дә, зур чүкечне дә, ломны да уйнатып кына йөртә. Әйтәсен күп вакыт тупас итеп, аты-юлы белән әйтә. Ә эштә аның ачуы килмәгән, кәефе кырылмаган чак сирәк була. Әнә хәзер дә Толикка теленә килгәнне кычкырды:

— Тотсаң юньләп тот,— дип җикеренде ул, машинистка пыяла-мамык төргәген сузып,— хатынныңны сыпыргалаган кебек маташма.

Башка вакыттагы кебек, Даниянең тупас шаяруын күтәреп алучы булмады. Кәтүкләргә яңа төргәкләр куюга, колонна кабат алга китте. Азактан чанасын сөйрәгән бульдозер кузгалды. Дания өтәләнеп чанага менде, пыяла-мамык төргәкләре өстенә ауды.

Гөлзәминә исә никтер туктап калды, артына борылып, бүген үзләре узган юлга күз салды. Анда — ерак-еракка сузылган траншея да, аның

төбендә биләүләнеп, назланып яткан торба гына. Ул инде бөтен буена ялганып, изоляцияләнеп беткәндер, икенче очы белән аның Зәйсуына барып төртелгәндер сыман булып тоелды Гөлзәминәгә. Әгәр шушы торбага тимер белән суксаң, тавышы, гитара кылы кебек чыңлап, Зәйсуга барып җитәр, улларына ишетелер төсле. «Их, торба өсләп йөгереп кенә кайтасы иде дә балаларның хәлен белеп киләсе иде»,— дигән уй бөреләнде аның миендә. Куныр-нитеп тормыйча, тәрәзәдән генә карап яисә күршеләреннән генә сорашып килсә дә, күңеле булыр иде. Нишләп яталар икән инде, бахырлар? Аның күз алдына берсеннән-берсе сөйкемле, тере, ире Сәйран кебек үк кап-кара чәчле, киң күе кашлы, әтиләре кебек үк кара-кучкыл уллары килеп басты. Бер мизгел эчендә әллә ниләр уйлап бетерде Гөлзәминә. Менә алар, ясап куйган пилмәнне дә пешерергә иренеп, икесе дә ач йөриләр, имеш. Җитмәсә, юып, үтүкләп куйган күлмәкләрен алып кимичә, мәктәпләренә каткан өс-баш белән барганнар. Ул гына да түгел, азып-тузып йөргәннәр дә хәзер әнә башларын иеп, милициядә утыралар, имеш...

Гөлзәминә ямьсез уйларыннан сискәнеп китте, аңардан котылырга теләп, як-ягына төкеренеп алды. «Кин-кит, булмаганны»,— дип сөйләнде. Хәзер инде, шөкер, зурлар: әниләрен оятка калдырмаслар. Элегрәк кыен иде менә: Айзаты — уникедә, Айгизе — ун яшьтә, өстәл биеклеге ике малай әниләрен озатып кала торган иде. Гөлзәминә трассага ут йотып китә, көйрәп торган күмер өстенә басып кайта торган иде. Хәзер бөтенләй башка: зурысы унынчы класста, бәләкәе сигезенчедә укый. Гел тукып тору йөрәкләренә җиттеме, үзләре тәүфыйклы булдымы, әллә инде тормыш йөгенең беразын җилкәләренә салуның файдасы тидеме — әйтмәгәне булсын, әлегә инсафлы малайлары: укулары да әйбәт, аның өстенә берсе спорт мәктәбенә йөри, икенчесе баянга өйрәнә. Өйне дә олылардан ким тотмыйлар. Тузан инде анысы, Гөлзәминә кайтуга мебель-әйберләр өстенә кәгазь юкалыгы утырган була булуын. Һи, анысына инде кем сүз әйтсен! Исән-имин торсыннар да, азып-тузып кына йөрмәсеннәр... Торырлар, боерган булса. Квартира әйбәт: мичкә ягасы юк, суы өйдә, газы бар. Һай, алай да яннарында булып, гел күреп тормагач, тыныч яшисең әллә? Акыллы, басынкылар дисәң дә, бала-чагалар шул әле, ни генә килмәс аларның йөгәнсез башларына!

Дуслары, туган-тумачалары еш кына: «Ташла торбаңны, балаларыңны кара, сиңа Зәйсуда эш беткәнмени соң?»— диләр. Шундый ук сорауны кайчак үзенә-үзе дә куя Гөлзәминә. Аек акылы җавап бирә шунда: эш җитәрлек, тик бу яшькә җиткәч, ничек инде яңа һөнәргә өйрәнәсең. Аннан, ничектер, күңелен шушы трасса биләгән, инедер тарта шуның. Нәрсәсе бик газиз икән соң бу чегән тормышының? Шул юлларда уздырылган чирек гасыр гомере, аркылыга-буйга узган далалар, тугайлар, әрәмәләрме, туган-тумачалардан да якынрак булып беткән шушы кешеләрме, сабыйларны биләүләгән шушы куллар белән кадерләп, чистартылып, кат-кат төрелеп траншеяларга салынган меңнәрчә чакрым торбаларммы? Әллә ире Сәйран истәлегеме?.. Мөгаен, шулар барысы бергә тарта торгандыр Гөлзәминәнең күңелен, шулар барысы бергә серле, могҗизалы көч булып алгысыта, яңадан-яңа трассаларга алып чыгып китә торгандыр.

Ул шулай аягүрә саташып, хыялланып торган арада, колонна шактый юл алырга өлгергән иде. Гөлзәминә, сагыш-хәсрәтләрен онытып, кыз чагындагыча җиңел генә йөгереп китте. Чанага утырырга дип ыргылган иде, траншея кырыенда бер пар иске күн итек күреп, туктап калды. Шушы чүп-чар тагы әллә нишләтеп җибәрде күңелен. Аяк астында, әйтерсең, тузып, эштән чыккан аяк киемнәре түгел, кемнеңдер язмышы ауный иде. Шунда кинәт күптән ишетеп тә, инде онытылган бер хикмәтле сүз исенә төште: «Иске чабатаның да пары була». Тукта, кем, кайчан әйткән иде соң бу сүзләрне? Юк, хәтерләми...

Гөлзәминә тагын чананы куып җитте, ансат кына менеп, пыяла-

мамык өстенә утырды. Дания әллә йоклый, әллә уйланып бара: күзләре йомык, зур борыны күккә төбәлгән. Йокласа йокласын, аның белән чыркылдашасы килми әле Гөлзәминәнең. Нишләптер баягы сүз башыннан китми. «Иске чабатаның да пары була». Ә менә анықы юк. Инде ничә ел ялгызы йолкына, дөнья мәшәкатьләрен ялгызы ярып бара. «Ялгыз яшәмәссең бит, иске чабатаның да пары була». Тукта-тукта, моны бит күптән, бик күптән, кан-яшьле авыр елларда әнисе әйткән иде. И әни, әни, мәрхүмкәем минем, булган парлар да юкка чыга икән ич бу мәшәкатьле дөньяда. Уйлары Гөлзәминәне ерак-ерак кө̄ннәргә алып китте-ләр...

...Үз гомерендә беренче тапкыр гашыйк булды Гөлзәминә. Сәйранның да аңа булган мәхәббәте саф иде, керсез иде. Туй ясамыйча, шау-шу кубармыйча гына бергә яши башладылар. Нур өстенә нур дигәндәй, идарә авыл өе кебек аерым йорттан квартира бирде. Тавык-чебеш үрчетеп җибәрделәр, кәҗә сатып алдылар, ишегалдын гөлгә күмделәр.

Шул тулып ташыган бәхетенә үзе күз тидерде Гөлзәминә. Беркөнне кич Сәйраны аны иркәләп-назлап утырды да, хатынының шактый зураеп килгән корсагына ишарәләп:

— Әллә трассаны ташлыйсыңмы, Гөлзәминә?!— дип куйды.

Ул исә иренең сүзен үзенчә аңлады. «Мине өйгә, шул сыңар мөгезле кәҗәгә бәйләп куймакчы бугай»,— дип шикләнде яшь хатын, үпкәсен Сәйранга белдерде.

— Туачак бәбиебез өчен куркам мин,— диде Сәйран.

Ире бу хакта башка сүз кузгатмады. Әмма ул хаклы, мең хаклы булган икән. Бала туып, бу якты дөньяга күзләрен ачып кына карады, менә мин дә тудым, дип аваз бирде дә үлеп тә китте.

— Балагызга карында чагында ук салкын тигән,— диде бәбине караган врач.— Тирләп эшлисез, аннан салкын су эчәсез, шулаймы?!

Гөлзәминә дәшмәде. Врач, күзгегә карагандай, белеп сөйли иде. Докторның соңгы сүзе кискен, мәрхәмәтсез булды:

— Бәби үстерәсегез килсә, бу эшегезне ташлагыз!

Янып торган яшь хатынның бала табасы, аларны карап үстерәсе килә иде, билгеле. Күңеле трассада калса да, дүрт ел өйдә утырды. Чәчәкләр үстерде, кәҗә сауды, һәм шул арада иренә тупырдап торган ике малай бүләк итте. Дөньялар тәмам иминләнеп, кешеләр айга менү, айда йөрү турында хыяллана башлаган вакыт иде бу. Малайларның олысына — Айзат, кечесенә — Айгиз куштылар.

Гөлзәминә бала табып, аларны тәпиләренә бастырып маташкан арада, трассада эшләр нык җиңеләйгән иде инде. Сәйран машинасына утырып, җыйнаулап сахрага чыккач, төзүчеләрнең эшен күреп, шаккатып кайтты ул. Күр инде, бөтенләй оҗмахка кергәннәр ич болар! Торбаны машина чистарта, машина төрә, алар ук күтәреп траншеяга сала. Эш түгел, уен ич бу хәзер. Өстәвенә, хан сарае кебек вагоннарда яшиләр. Трассада эшләргә дә, тупырдап торган бала табарга да була хәзер.

Башкача бәби китермәде китерүен Гөлзәминә, әмма трассада эшләүнең үкенечен калдырмады. Эшләү генә түгел, бөтен гаиләләре белән шунда яшәделәр, күчмә халыклар кебек йорт-җирләре, бала-чагалары белән күчеп йөрделәр. Татарстан белән Башкортстанда алар аяк басмаган төбәк бар микән? Калмады Уралы, Урта Азия, Пенза, Рязань яклары, калмады казах далалары. Фатир алып Зәйсуда төпләнгәч тә шул трассада кунып-төнеп ятуларыннан туктамадылар. Сүз дә юк, эшләре тынгысыз, мәшәкатьле иде. Шулай да бәхетле иде Гөлзәминә. Гашыйкларга куышта да оҗмах дигәндәй, бер-берен сөеп, санлап яшәгәч, күчмә вагонда торганда да кыенлык тоймадылар, ызгыш-талашны белмәделәр.

— Гөлзәминә дим, Гөлзәминә!— Аны Дания селкеткәли иде.— Бу трассадан да ирсез кайтсам, исемем Дания булмасын! Инде берсе-

нең дә башын әйләндерә алмыйм икән, башкача чыкмыйм командировкага. Зәйсуда да бетмәс әле берәр имгәге... Әй, Гөлзәминә, син дә йөрисең инде дуадак каз кебек. Синең матурлыгың миндә булсамы?!

Гөлзәминә аны тыңламый, үткәннәренә чумганнан-чума бара иде.

...Ул көнне иртәдән үк дөньяның яме булмады. Чалт аяз торса да, көн ничектер караңгы, ямьсез, шомлы иде. Һәм бу шом юкка булмаган икән. Бригада әле трассага чыгып китәргә өлгермәгән иде, кинәт көнә вагон-шәһәрчеккә дуамал җил килеп бәрелде, каядыр чылтырап пыяла төште, дапы-дөпе килеп вагон ишекләре ябылды. Ул да түгел, өермә тагы да пырдымсыз гайрәт белән ябырылды, куәтле машина белән сиптергәндәй, тәрәзәләргә ком ташкыны бәрде, җил, күчмә йортларны әйләндереп капларга җыенгандай, аларны каерды, йолыкты, чайкап-чайкап алды. Бер минут эчендә чүлдә генә түгел, шәһәрчек ишегалдында да берни күренми иде инде. Бөтен җирдә ком бураны уйный, кайный, бөтерелә, бихисап зур багана булып һавага суырыла, әйтерсең, меңнәрчә җеннәр бии, туй итә, кыргый тантанадан шашып котыра. Гөлзәминә куркынып тизрәк вагон ишеген япты. Шулчак эче чатнап киткәндәй булды: шоферлар, шул исәптән аның Сәйраны да, трассага чыгып китәргә өлгергәннәр иде.

Ком бураны кичен дә басылмады. Мондый мәхшәрдә шоферларның кайтуын көтәсе дә юк, әлбәттә. Берәр җирдә ышыкланып төн уздырырлар, бергә-бергә әмәлен табарлар, дип юанды шәһәрчектәгеләр. Мондый афәтләр булмады түгел, шуңа да Бохара-Урал трассасында шоферларга юлга ялгыз чыгу катгый тыела иде. Шулай дип тынычланырга тырышса да, төнен керфек какмады Гөлзәминә, җил үкергәнен тыңлап, түшәмгә карап таңны аттырды.

Чүлдәге мәхшәр иртәнге якта гына тынды. Сәгать уннарда шоферлар да кайтып төштеләр. Әмма алар арасында Сәйран юк иде. Аның кайдалыгын сорагач, юлдашлары Гөлзәминәдән күзләрен яшерделәр. Сәйран колоннадан аерылып калган икән. Кичкә таба аның машинасын алып кайттылар. Кабинада буш термостан башка нәрсә табылмады.

Сәйранны ике тәүлек рәттән эзләделәр. Өченче көнне генә юлдан читтә, ком астында калган торба эченнән табып алдылар аның гәүдәсен. Колоннадан аерылып калгач, юлны югалткан, эзгә төшү нияте белән кабинасыннан чыккан һәм машинасыннан да язган бугай Сәйран. Торба эченә кереп, дәһшәтле төнне уздырмакчы булган, мәрхүмкәй...

— Гөлзәминә дим, әллә йоклый инде чукынган!

Даниянең шөкәтсез тавыш белән кычкыруы бүгенге көненә кайтарды Гөлзәминәне. Кәтүкләр бушап калган, колонна тукталган иде. Ул, кулына беренче эләккән пыяла-мамык төргәген алып, җиргә сикерде, изоляцияләү машинасына таба ашыкты.

Кабат кузгалып, яңадан чанага менеп утыргач та, сагыштан, авыр исталекләрдән арына алмады бүген Гөлзәминә. Күптән болай хәтер сандыгын айкап ташлаганы юк иде аның. Траншея буенда аунаган иске көн итекләр тәмам иләсләндерде бит кешене. Сәйран үлгәннән бирле, тормышның бөтен ямен трассадан гына табарга, үзенең парсыз яшәвенә күнгән иде бит инде ул. «Пар» дигән сүзне башына да китергәне булмады. Баксаң, уйларга кирәк икән ләбаса. Балалар үсеп җителәр әнә, озакламый тарала да башларлар, үзләренә гаилә корырлар. Аналарын бөтенләй ташламаслар анысы ташлавын, шулай да үз тормышларына, үз мәшәкатьләренә ябыша төшәрләр. Менә шунда инде дуадак каз сыман япа-ялгыз калырсың. Юк, ир булганы өчен генә түгел, олыгайган көндә иптәшкә булса да кемдер кирәк барыбер. «Иске чабатаның да пары була». Тик кемгә сыенсын соң ул? Калада аның юньләп торганы да юк, анда берәүне дә белми диярлек. Монда кемгә өметләнсен инде? Йөгәнсез Кавказгамы? Юк, андый җиңел холыклы кеше белән яши алмас иде Гөлзәминә. Сәетнафа менә бөтенләй башка: аз сүзле, сабыр, кешелекле. Ләкин нишләп алай өркетелгән киек сыман яшь ул, нәрсә

газаплый аны? Бик нык хәтерен калдырганнармы, рәхимсез алдаганнармы үзен? Кешеләрдән, бигрәк тә хатын-кызлардан читләшә. Фәкать кайчак аулактарак Гөлзәминәгә йотлыгып, онытылып карап торгалый. Карашында сагыш, моң, гаҗизләнү. Менә шуңа да еш кына жәлләп куя аны Гөлзәминә. Шул сакаллы сабыйны аркасыннан сөеп юатасы, иркәлисе-назлыйсы килгәнен тоеп ала. Туктале, кызгану хисе генәме соң бу? Әллә якын итә инде шул мәхлукны? Кит, кит, булмаганны...

## 15

Кичтән уйлап куелганча, Аитов идарәгә сугылып тормаска, туп-туры очу кырына китәргә тиеш иде. Шулай да түзмәде, шоферына ике катлы таныш бинага борылырга кушты.

Диспетчер бүлмәсендә генә рация шатырдаганы, вакыт-вакыт телефон зыңгылдавы ишетелгәләп куйгалый. Әсфәндияр, җиңелчә атлап, шунда узды, иртәнге тәмле йокыга бирешмәскә тырышып, оеп утырган диспетчер белән баш кагып кына исәнләште дә сводкалар язып алына торган ашъяулык кадәрле кәгазьгә үрелде. Диспетчер кулы белән чуарланып беткән шушы кәгазьдә дистәләрчә бригадаларның, участокларның узган тәүлектә башкарган эшләре, уңышлары яисә уңышсызлыклары уч төбендәгедәй ярылып ята иде. Саннар өстенә иелеп, шактый утырды. Кайберләрен караганда бите яктырып-яктырып китә, кайсыларыннан исә йөзенә кара шәүлә төшә. Чирек сәгать тә үтмәде, ул инде зур магистральнең кайсы төбәгендә нәрсә һәм күпме эш эшләнгәнлеге турында хәбәрдар иде. Шулай да кузгалырга ашыкмады. Карашы белән кайтып-кайтып изоляцияләү колонналарының исемлеген карады, һаман бер ноктага — Рамаев фамилиясенә туктады. Бу коллектив инде атна буе көн саен мең метр торба салып бара. Моңа партком секретаре да игътибар иткән бугай, бригадир фамилиясе турына нәни генә «чәүкә» билгесе төшереп куйган. «Рамаев, Рамаев,— дип кабатлады Аитов үзалдына,— бу бит теге Сунарчин колоннасы бригадиры бугай, молодец!»

Аитовның моңа игътибар итүе очраклы түгел иде. Атнага җиде километр бит! Әлегә кадәр Идел-Обь трассасында мондый күрсәткечкә ирешкән бригада булмады. «Кичекмәстән барлык бригадаларга җиткерергә кирәк»,— дип уйлап алды Әсфәндияр,— егетләр үзләре мөрәҗәгать белән чыксалар да начар булмас». Ул, сводканы кулына тоткан килеш, кабаланып урыныннан торды, йөгерә-атлый икенче катка күтәрелә башлады. Тик менеп җитмәде, ярты юлда туктап калды — партком секретареның өченче көн Обь буена очканы исенә төште. Шулай ук кызулап, кире диспетчерлыкка кайтты һәм инде йокысыннан тәмам айныган диспетчерга Обь буен — Герасимов бригадасын чакырырга, партком секретаре Рябининны эзләп табуларын үтенергә кушты.

Анда да иртәнге ыгы-зыгы иде бугай, рация байтак вакыт узгач кына телгә килде.

— Рациядә Рябинин,— диде партком секретаре яшь, яңгыравык тавыш белән.

— Хәерле иртә, Дмитрий Ильич,— диде Аитов, микрофонга иелеп.— Мин әле бу. Карале, Дмитрий Ильич, үзем бүген Агыйдел ярына очам. Син кайчан кайтырга чыгасың? Прием...

— Төш тирәсенә кайтып җитәрмен дип торам.

— Дмитрий Ильич, кадерлем,— диде Әсфәндияр дулкынланып,— зинһар, Сунарчин колоннасына кагылып чык. Ул Сазанак станциясеннән көньяктарак, Елан сазлыгы тирәсендә... Эшләре бик күркәм егетләрнең, бәлки, барлык трассачыларга мөрәҗәгать белән чыгарлар...

— Мин ул хакта беләм... Тукталам...— Рация кинәт шатырдарга тотынды, аннан тынып калды.

Бу хәтлесенә күңеле булды Аитовның. Шулай да нидер тота иде әле аны монда. Нидер онытыла бугай. Әһә! Ул телефон өстенә иелеп,

номер җыярга тотынды, әмма трубкада «түт-түт» дигән сигналдан башка нәрсә ишетелмәде. Әсфәндияр сәгатенә карап алды — редакциядә эш көне башланырга иртәрәк иде шул әле. Трубканы куеп, өстәлдәге кәгазьләр арасыннан чиста бит эзләп тапты һәм ашыга-ашыга язарга тотынды.

— Менә шуны өлкә газетасына хәбәр итәрсең,— диде ул диспетчерга һәм кабаланып идарәдән чыгып китте.

Көн бүген, аның кәефенә яраклашырга тырышкандай, ничектер мәһабәт-тантаналы иде. «Очу кыры» дип аталган кечкенә мәйданчык кояш нурына коенып утыра. Вертолет тәгәрмәче измәгән, кеше аягы таптамаган урыннарда тыгыз булып кылган күтәрелгән, аның арасына вак кына шәмәхә чәчәкләр сибелгән. Ахрысы, шулардан мул булып хуш ис бөркелә, үзләре күзгә күренмәгән бал кортларының дәррәү безелдәгәне ишетелә. Вакыт-вакыт шул нәни җан ияләренең тавышларын күмеп, станция ягыннан тимер чыңы, моторлар гөрелтесе ишетелеп куя. Мәһабәт эрбет агачлары арасыннан ниндидер кошларның, чукырларның бугай, «кләклә» дип үзара сөйләшүләре яңгырап тора.

Тукта, нишләп болай вертолетка беренче кат утырган малайдай очына әле ул? Юк ла, вертолетның ни катнашы булсын ди монда. Үз гомерендә аз очтымыни Аитов аңарда... Соңгы көннәрдә трассада эшләр күзгә күренеп җанланды, атна-ун көн эчендә илебезнең әллә кайсы төбәкләреннән бригада арты бригада, эшелон-эшелон техника килеп торды. Шуңа шатлануы, шуңа очынуы микәнни соң йөрәкнең? Юк ла инде, болай үзенә үзе сер бирмәү өчен генә сәбәпләр эзләп маташа Әсфәндияр. Татар җырларыдай моңлы, башкорт далаларыдай иркен Агыйдел буена кайтуны, ягымлы Сөембикәсе янына кагылып чыгу ихтималын тоеп талпына иде аның күңеле.

Алай да барлык сәбәпләр бөтенесе бергә ашкындырган икән. Вертолет җирдән аз гына күтәрелеп, трассага таба очып киткәч тә, Агыйделен дә, Сөембикәсен дә онытты, тәрәзәгә капланып, офыктан офыкка сузылган магистральне күзәтә башлады. Трасса үлән арасындагы кырмыска юлы кебек кайный иде. Аның буйлап иләмсез озын буыннар тарткан машиналар чабыша, экскаваторлар, бульдозерлар үрмәли, әле анда, әле монда сварка утлары җемелди. Әнә, ниндидер авыл кырыенда көмеш тартмачыклардан торган шәһәрчек. «Рязань егетләре»,— дип куйды Әсфәндияр үзалдына һәм алга таба очкан саен күчена барган офыкка карады. Алда, торба өемнәре янында, тагы бер шәһәрчекне шәйләп алды. «Болары Мәскәү монтажчылары бугай».

Механикалаштырылган колонналар, төзек дүртпочмак булып утырган күчмә шәһәрчекләр өстеннән очканда, Аитов үзалдына аларның исемнәрен атый барды: Саратов, Омск, Ташкент, Төмән. Әйе, бишьеллыкның иң зур төзелешләреннән саналган Идел-Обь нефть үткәргечен салуга бөтен ил күтәрелде.

Ә бит уйлап баксаң, сөйләп кеше ышанмаслык эшләр тора алда.
Юанлыгы метр ярымга якын торбаны ике мең чакрымнан артыграк
арага сузасы бар. Дөньяда тиңе булмаган бу континентара нефть үткәр-
гече Обь буеның мәшһүр промыселларыннан башланып, тоташ сазлык-
лар аша, Түбыл шәһәренә килә, шуннан кисәк кенә көнбатышка — Тө-
мәнгә таба борыла һәм Курган, Чиләбе, Свердловск өлкәләре буйлап
сузыла. Аннары, үзенең корыч гәүдәсен Урал сырты аша ташлап, Баш-
кортстанга, ниһаять, Татарстанга килеп җитә.

Безнең дә бар иде көчсез чаклар, хәерче вакытлар. Кайчандыр,
китаптан укыган юлларны хәтерли Әсфәндияр. Имеш, революциягә ка-
дәр Россиядәге берданбер нефть үткәргечен салуда нибары бер сварщик
эшләгән. Әлеге алыштыргысыз һөнәр иясе трассага яхшы атлар җигел-
гән фаэтонда гына килеп, көненә бер ялгау ясый торган булган. Аның
да әйбәт көннәрдә генә. Менә шуннан инде Бакудан Батумига уза торган
киртә юанлыгы нефть үткәргеченең ничә ел салынуын күз алдына ките-
рүе кыен түгел.

Кем белә, бәлки хәл башкарачак та торгандыр. Тик шунысы хак: революциягә кадәрге Россиядә нибары мең километр чамасы торба юллары бар иде.

Вертолет ерак араларга очу өчен җайланмаган. Свердловскида туктап, аңа ягулык салдылар, үзләре тамак ялгап алдылар. Шулай байтак юангач кына һавага күтәрелделәр. Бераздан таулар башланды. Аста — Уралның берсеннән-берсе мәгърур өч сырты, алар арасындагы кылганлы үзәннәр, кара урманнар каплаган кыя-таулар, дәһшәтле тарлавыклар, сикереп-ярсып аккан елгалар. Җентекләп карамаса да, белеп тора Әсфәндияр: монда, кайчандыр патша ялчылары йөрәгенә шом салып Салават батыр һәм аның сугышчан дуслары йөргән җирләрдә, трасса әлегә тын. Көч җитмәүдән генә түгел, хәзер, Себердә елгалар ачык чакта, булган бөтен торба шунда озатыла. Җәен, баржалар ярдәмендә, иң сазлы һәм аулак урыннарга да кирәк кадәр йөкне ташып калдырырга мөмкин. Елгаларда боз каттымы, бетте диген, бөтен нәрсәне самолет-вертолетлар белән генә китерергә кала. Уралда исә тимер юллары җитәрлек, йөкләрне елның теләсә кайсы фасылында ташырга була.

Бераздан еракта якты тасма булып Агыйдел күренде. Әсфәндиярның йөрәге тагы ярсый-алгысый башлады. Алда — Уфа. Анда аны тын, басынкы, ире өчен җанын ярып бирергә дә әзер Сөембикәсе көтә...

## 16

Аитовның конторкага кереп тормыйча, турыдан-туры Агыйдел буендагы дюкер янына китүе участок начальнигы Тифунляны бераз шиккә салган бугай, аның болай да кызыл бите янып чыккан, ул бер йөгереп, бер атлап, идарә начальнигына каршы бара иде. Килә-килешкә хәрбиләрчә кисеп сәлам бирде, кунакның кулын кысты. Аның дала җиле дә, җәй кояшы да каралта алмаган кызыл йөзендә бераз гына һавалану чалымнары, хуплау, мактау көтү сизелеп тора. Моңа хакы бар иде Тифунляның. Трассадагы иң четерекле эшләрне башкаруга карамастан, аның участогы хезмәтне әйбәт оештыруы, тәртибе белән аерылып тора, үзенә тапшырылган бурычны һәрчак төгәл һәм сыйфатлы итеп үтәп чыга. Эшләре үзенчәлекле һәм бик югары сыйфат таләп иткәнгә бугай, монда сварщикларның да, механизаторларның да, водолазларның һәм башка эшчеләрнең дә иң осталары тупланган. Ахры шуңа, үзләрен башкалардан өстенрәк хис итәләр, сөйләшүләрендә үк горурлык сизелеп тора. Тифунляда исә участокның шушы бөтен сыйфатлары бергә тупланган сыман. Аның шул гадәтен белгәнгә, участок эшеннән канәгатьсезлек сиздерәсе килмәде Аитовның, тик нишләптер теленә мактау сүзләре дә килмәде.

— Агыйдел буйлары ошап китте бугай сезгә, Ким Васильевич,— диде ул, сүзне гөнаһсызрак итеп башларга тырышып.

Әмма Тифунля аның тел төбен шунда ук аңлап алды, бите тагы да ныграк янып чыкты, беравык дәшми торды.

— Бөтен эш график буенча бара, Әсфәндияр Газарович,— дип аклангандай әйтеп куйды аннары.

— Бәхәсләшмим, сез сынатмассыз анысы,— Аитов участок начальнигын култыклап алды. Акрын гына дюкер буйлап атладылар.— Шулай да эшләрне ашыктыра төшәсе иде, Ким Васильевич.

— Әсфәндияр Газарович! — Тифунля туктап калды, йөзендә әлеге дә баягы тәкәбберлеген саклаган хәлдә сүзен дәвам итте: — Безнең эшнең үзенчәлеген беләсез бит. Дюкер елга төбенә бер салып, бер алып маташа торган нәрсә түгел, ул анда мәңгелеккә ята. Тизлек түгел, сыйфат бездә беренче планда. Аннан елганы штурмлау көне югарыда раслан-

ган бит. Аны мин генә үзгәртә алмыйм.

— Анысы шулай, Тик алда Обь барын онытырга ярамый. Бәлки, эшчеләрнең беразын анда күчерергә, дюкер әзерли башларга мөмкиндер, ә?!

— Ул хакта уйлап карарга ярый.

— Менә шул турыда сөйләшергә дип килдем дә инде мин.

Кинәшмә ниятләгәннән шактый сузылды. Аның каравы, эшчеләр бик мөһим тәкъдимнәр белән чыктылар. Шунысы кызык, аларның да күбесен Аитовны борчыган нәрсә — Обьны кичү борчый икән. Дюкерны Агыйдел төбенә салганчы ук бригадаларның яртысын Обь ярына күчерергә! Күпчелекнең фикере әнә шундый иде.

Эш кешеләренең хуҗаларча, һәм дәүләт масштабы биеклегеннән торып фикер йөртүләреннән әсәрләнгән Әсфәндияр өенә шалтыратырга да онытkan иде... Машинага утыргач, исенә төште төшүен, шулай да кире конторкага керәсе итмәде. Әллә соң өйгә сугылып та тормаскамы? Сөембикәгә аны-моны сиздерми генә кире китәргәдер, бәлки? Тулыр-тулмас бер төн икеңне дә үртәү генә... Юк инде, Агыйдел буена килеп, янына кермичә, хәлен белмичә китсәң, аяз көнне яшен сугар. Трасса дип, эш дип, сөекле хатыныңнан ваз кичеп булмый ич инде. Болай да үз гомерендә ир назы күрмәде, аның киң җилкәсенә ышыкланмады Сөембикә, ирле тол булып, зарланмый-сукранмый гына ялгызы тартты гаилә йөген. Чыннан да, без, ирләр, гаҗәеп эгоистлар. Үзебезнең мәнсезлекне, мәгънәсезлекне эшкә, вакыт җитмәүгә сылтап, гомерләрен гаиләгә, аның иминлегенә багышлаган сылуларның сулуына күз йомабыз. Ул гына да түгел, аларның гомер буе безнең өчен янып-көеп йөрүләрен шулай тиеш дип кабул итәбез. Ә алар... алар исә шуның өчен берни таләп итмичә, ир дип, семья дип, тормышыбыз башкаларныкыннан ким булмасын дип, нинди генә кыенлыклар күрмиләр дә, нинди генә йөк тартмыйлар. Кимендә ике-өч кешегә тормыш бүләк итү өстенә, шул нарасыйларны карап үстерәләр, гаиләнең бөтен мәшәкатен җилкәләрендә сөйрәп баралар. Һаман да ир көйләп, аның җырын җырлап яшиләр. Үзләре сүнә баруга карамастан, гел безнең өчен өзгәләнәләр. Моның чыннан да шулай икәнен Әсфәндиярдан сорасыннар әнә.

Сугыштан ул әзмәвердәй гәүдәсенә дүрт җөй өстәп кайтып төште. Хәер, болай дип әйтү бик үк дөрес булмас иде, станциядән кабык чанада толыпка төреп алып кайттылар аны, өйгә носилкада кертеп салдылар. Үз йомышына чыгарлыгы да юк иде Әсфәндиярның — дошман пулясы умыртка сөяген зарарлады.

Зур-зур госпитальләрнең дә ярдәме тимәгәч, караңгы бер авыл больницасында ятуның файдасы була әллә? Сөембикә үзе медсестра булып эшли торган больницага бер салдылар, бер барып алдылар, тагы салдылар. Алай да булмагач, халык арасында таралган им-томнарны сынап карамакчы булды хатыны. Кичен мунча ягып, төн уртасында ирен күтәреп бара, аны тозлы чүбеккә, кызыл балчыкка, ат тизәгенә урап, парда тота. Янә җилкәсендә алып кайта, таң атканчы әллә нинди үлән төнәтмәләре әзерләп эчерә, тәнозын тәненә массаж ясый торган иде. Җитмәсә, боларның барын да төнлә, кеше аягы тынгач эшләргә туры килә. Тирә-күршеләр сизсә: «Үзе медик, үзе карчыклар име белән дәвалый»,— дип сүз таратулары бар. Сүзе бер хәл, эштә күзне ачырмаслар, больницадан ук куарлар. Халык медицинасы — шарлатанлык, дип санала иде ул елларда.

Ничек итсә итте, тәки Әсфәндиярны аякка бастырды бит. Бастырды гына түгел, трассада эшләрлек итеп савыктырды. Шуннан инде өенә юньләп кайтып кермәде Аитов. Әйе, Сөембикәсен өйдә тотып нык ялгышты ул. Ял иттерә, бурычын кайтара, янәсе. Баксаң, хатыны дәшмитынмый гына бөтен тормышны сөйрәгән, бернинди дәгъвалар куймый гына балаларны үстергән икән. Шул игелекләрен ни белән кайтарырсың да, ничек бәхилләтерсең аны?

Таныш йорт янына килеп туктауга, һич көтелмәгән житезлек белән машинадан төште, шоферы белән саубуллашып та тормастан, подъездга ыргылды, малайлар өлгерлеге белән текә баскычтан өскә атылды. Кабалана-каушый ясалма күн белән тышланган ишекне ачты да, күн итеген дә салып тормастан, залга ыргылды.

— Сөембикә?!

Йомшак диванда йон оекбаш бәйләп утырган Сөембикә, эшеннән туктап, өнсез калды. Әсфәндияр аның сары суккан йөзенә, куркынган күзләренә беравык карап торды да, хатыны алдына чүгәләп, аның башын кочагына алды.

— Тагы чирлисеңме, алтыным?

Сөембикә иплән кенә иренең кочагыннан арынды, бәйләвен бер читкә куйды.

— Үтте инде. Чишен.

— Балалар ни хәлдә, балалар? — дип каударланды Әсфәндияр, хатыны янына утырып.

— Әнис студентлар отряды белән колхозга эшкә китте,— диде Сөембикә, зәгыйфь тавыш белән.— Фәнисе... Шул башсыз аяктан екты да инде мине... Иптәшләре белән бәхәсләшеп, Агыйдел күпереннән суга сикергән.

Әсфәндияр, өстенә салкын су койгандай, сикереп торды, зур булып ачылган күзләрен хатынына төбәде.

— Исән ул. Утыр! — Сөембикә, күзләрен йомып тынып калды.

— Бәлки, миңа барып кайтыргадыр,— Әсфәндияр урыныннан купты,— сиңа да дарулар кирәк.

— Соң инде, бүгенгә йөрмә. Барыбер янына кертмәсләр.

Әсфәндияр сәгатенә карап алды.

— Дөрес әйтәсең, алтын. Ярый, иртәгә барып кайтырмын... Иртәгә дә, берсекөнгә дә.

Сөембикә, күзен тутырып, иренә карады.

— Ничек инде берсекөнгә дә, ди?

— Житте. Берничә көн ял итәм, Сөембикә. Сезне бу хәлегездә ташлап китә алмыйм.

Хатыны торып ук басты, хәлсез куллары белән иренең беләгенә тотынды, күзләренә текәлде.

— Ни сөйлисең син, Әсфәндияр?! Үтенәм, ир булып кал. Эшеңдә элкен-салкын йөрмә!

— Болай булмый бит инде, Сөембикә. Мин болай да бурычлы, бик зур бурычлы синең алда.

— Юк, юк,— дип Аитовның кулына ябышты Сөембикә.— Булдыра алсаң, иртән больницага барып кил дә трассага кит. Синең эшең кешеләргә кирәк, Әсфәндияр!

## 17

Нурлы бала арбасын ишек төбендәге эскәмия янына чыгарып куйды да, томырылып, тагын баскычтан өскә менеп китте. Әгәр дә ул бу минутта үзенә читтән күз сала алса, буй-сынының шактый суырылып, ыспайланып китүен абайламый калмас иде. Хәер, гәүдәсенең ничектер җиңеләеп калуын тоя ул тоюын. Әмма моны бала үстерү дәрте белән барлыкка килгән бер җиңеләю дип кабул итә, үзенең шактый яшәреп, матурланып китүен белми иде әле.

Кыз-кыркын житезлеге белән өйләренә килеп керде, зур-зур тимер уенчыклар белән мавыгып диванда яткан Бөдрәне күтәреп алды.

— Киттек, кызым!

Нәниен кочагына кысып, түбәнгә төшеп китте. «Нигә чакыртыр икән? — дип уйлады ул үзенең башлыгы Святослав турында, баланы

арбага сала-сала.— Чакыртмыйча соң, үзең этәнләп йөргәч ни. Тагы берәр сызым күчермәсе эшләргәдер инде»

Өйдә яшь бала булгач, элеккечә ялгызлыктан интекмәм, мәшәкатькә, чүпрәк-чапракка батып, кинәнеп яшәрмен, дип уйлаган иде. Ялгышты. Шаяз китүгә, өйдә тагы ямь калмады. Бүлмәләр җимеше җыеп алынган бакча сыман моңсуланды. Элеккечә үк һәр почмакка сагыш, моң, эч пошу оялады. Шулардан котылу уе белән, беркөнне сабыйны арбасына яткырды да урамга чыгып китте. Тик болай бер максатсыз буталып йөрүнең дә кызыгын тапмады, үзе эшли торган заводка таба борылды.

Святослав аны шатланып каршылады. Гадәтенчә, тартынып кына исәнлек-саулык сорашты, кызчыкны кулына алып, аны утын агачы йөрткәндәй итеп ипсез генә тотты да бүлмәне әйләнеп килде. Бәдрә ятсынып, авызын очлайта-очлайта еларга җыенгач, баланы әнисенә бирде, өстәле артына утырды.

— Менә шулай, Нурлы, начальник та, эшне башкаручы да үзем хәзер,— дип сораганны да көтмичә мондагы хәлләрне сөйләп китте.

Ә яңалыклар шактый икән. Фәнни-тикшеренү институты галимнәре, Шаяз белән Сыртлан тәкъдиме нигезендә, яңа машина эшләгәннәр. Барып чыкса торбаны чистартуны да, изоляцияләүне дә шушы бер комбайн башкарачак икән. Инде соавторга әйләнеп калган авторлар монда яшәгәнлектән, сызымнарын алып Зәйсуга килеп төшкәннәр. Әмма эш барышында байтак кына нәрсәләрне үзгәртеп ясарга туры килгән. Ыгы-зыгы арасында аннан-моннан гына әзерләнгән сызымнарны чистага төшерергә кирәк. Менә шуңа ялгызы баш күтәрми эшләп ята икән Святослав.

Шушы оялчан егетне кызганып куйды Нурлы. Үзенең киенеп-ясанып тик йөрүе җинаять булып тоелды аңа, авызыннан сүзе чыгып киткәнне тоймый да калды:

— Соң, берәр гадирәген бир миңа, өйдә эшләрмен.

Шул сөйләшүдән соң һәр көнне сызымнар белән утыра башлады Нурлы. Болай вакыт уздырырга дип кенә тотынган эше шактый мавыктыргыч булып чыкты. Ни генә димә, Шаяз тәкъдимен тормышка ашыруда катнаша бит. Беренче көнне, коляска белән өстәл арасында йөгерә-йөгерә, сызымын көчкә сызып бетерде. Иртәгәсен Бәдрәне Гыйлминур әбисенә илтеп куйды да көнозын маташты. Аннан конструкторлык бюросына ук барып утырды. Соңгы көннәрдә сызымнар тәмамланып, Святослав вак-төяк эшләр генә җибәргәләп тора иде. Бүген үзе чакырткан менә. Ни булды икән тагы?

Святославны ул завод ишегалдындагы бушлыкта, әле узган атнада гына кәгазь битләрендә сызым рәвешендә йөргән комбайнның машинага әверелгән адашы янында, майга, сөремгә батып беткән бер төркем инженерлар арасында эзләп тапты. Бюро начальнигы үзе дә мазутка буялып беткән, шулай да күзләре шатлыклы ялтырый. Нурлыны күргәч, көлеп үк җибәрде.

— Күрдеңме безнең машинаны?! — диде ул горурлык катыш канәгатьләнү белән.— Чын-чынлап комбайн бит. Үзе ура, үзе суга дигәндәй, чистарта да, чорный да.

Яңа машинадан бер якты пыяла-мамык белән пөхтә итеп биләүләгән йөз метр чамасы буйны шунда гына күреп алды Нурлы, шунда гына Святослав сүзләренең чынлыгына ышанды.

— Мин сине эш белән чакырдым бит, Нурлы,— диде Святослав, колясканы контора ягына таба этеп.— Киңәш бир, нишләргә дә белмим... Яңа комбайн соавторлар, ягъни Шаяз бригадасында үзләштерелергә тиеш. Тагы берничә көннән машинаны Себергә озатабыз. Аның белән бергә институт вәкилләре дә бара. Производство шартларында сынауда бездән дә кем дә булса катнашырга тиеш. Мин янсә баш механик булу планлаштырылган иде.

Контора янына җиткәч, Святослав чәчәк түтәле янында туктап кал-

ды. Нурлыга шундагы эскәмиядән урын тәкъдим итте, янәшәгә үзе дә утырды.

— Ләкин безнең ниятләр чәлпәрәмә килде,— дип дәвам итте ул, кулъяулыгы белән битендәге мазут тапларын сөрткәләп.— Баш механикны кичә кич больницага алып киттеләр. Аппендицит... Үземә исә ашыгыч эш бирделәр: көзге салкыннарга кадәр битум ташу машиналарының тәгәрмәчләрен чылбырга алыштырырга, цистерналарын җылытырга. Шул Себердә эшләү өчен инде...

— Туктале, боларны ни дип миңа сөйлисең соң? — дип бүлдерде аны Нурлы.— Мин конструктор түгел, барыбер ярдәм итә алмам. Әллә Себергә барырга димлисеңме?

— Ялдагы кешегә кушарга хакым юк анысы. Ә менә киңәш сорый алам. Нишләргә соң? Эше дә катлаулы түгел югыйсә. Яңа машинаның эш параметрларын язып барырга кирәк. Шул гына.

— Озаккамы?

— Атна-ун көн чамасы торырга туры килер.

— Үзем барсам әллә?

— Ә бу? — дип, Святослав коляскага таба ымлады.

— Балага урын бар анысы.

Святослав Нурлының кулыннан тотып алды.

— Ай, рәхмәт сиңа, Нурлы!

— Тукта, барам дип кисеп әйтмәдем ич әле. Уйларга, Гыйлминур апа белән сөйләшергә кирәк.

Себер хакында сүз чыкканнан бирле эчендә ниндидер бер хис — пошынумы, сагышмы барлыкка килеп, аның һаман да үсүен тоеп торды Нурлы һәм менә хәзер, шушы мизгелдә, аның нәрсә икәнен аермачык сизеп алды. Күр инде, Шаязны бик сагынган икән ич ул! Әллә соң шуны чамалап, юри аны җибәрмәкчеме Святослав? Ничек кенә булмасын, моннан файдаланып калырга кирәк...

## 18

Иртәнге ак буак, изрәп йоклаган кешеләрне сак кына уятырга теләгәндәй, күчмә йорт стеналарына сарылып-сырпаланып йөрде, инде яфраклары тәмам ныгып, ябалдашлары куерырга өлгергән каен-шәмнәр арасында уралды да, аларны дымыктырып, күл өстенә чигенде, чыршыларның үткер очларына менеп кунаклаган кояштан оялып, тарала башлады. Томан күтәрелүен генә көткән кебек, аланга поши бозавы килеп чыкты, гадәттәге урынга — тозлык улагына куелган ипи сыныкларын чәйнәп йоткач, ашыкмый-пошмый гына шәһәрчек ишегалдына кереп китте. Ул, эшлекле бер кыяфәт белән, ишегалдын урап чыкты, Сәетнафа яши торган вагон янына туктап, тыңлагандай итте. Гаҗәп хәл: аны сыйлаучы үзе түгел, йөнтәс эте дә күренми иде. Ә бит, кояшка караганда, бу шау-шулы бәндәләргә кузгалырга вакыт, бик вакыт иде югыйсә.

Чыннан да, бик сәер тынлык иде бу шәһәрчектә. Көн саен иртән мондагы ыгы-зыгының шаһиты булып торган каеннар да гаҗәпкә калдылар. Ни булган бу тынгысыз бәндәләргә? Башта алар, әйдә йокласыннар инде дигәндәй, үзләре дә яшел чукларын салындырып, оеп кына утырдылар, бераздан инде, ай-һай, гамьсезләр болар, дип, башларын чайкый башладылар. Аннан инде, эшкә соңга калалар бит дип, борчыльрга, яшел шәлләренең чуклары белән тәгәрмәчләр өстендәге йортларның стеналарына, тәрәзә пыялаларына шап-шоп суккаларга тотындылар.

Әмма шәһәрчек уянмады, хәтта һәрвакыт бөтен кешедән иртә торып баса торган Ризван да урынында ауный иде әле. Дөрес, ул инде күптән йокламый, каеннар шаулавын, аларның ботак очлары белән тәрәзәгә сугып-сугып алуларын тыңлап ята. «Көннәр бозылырга, күрәсең»,— дип уйлап алды ул, җилнең агачлар очын ботарлавына карап. Хәер, якында-

гы ике көндә яуды ни дә, яумады ни. Егетләр барыбер ялда. Аязда ял итү ниятләнмәгән иде дә бит. Нишлисең, нужа калач ашата дигәндәй, теләсәң-теләмәсәң дә күләгәдә назланып ятарга туры килә.

Кичә төштән соң колонна, әлеге акмыек үскән сазлыкка житеп, туктап калды. Аны үтәрлек вакытлары бар иде югыйсә. Әмма алда ни торба ялганмаган, ни траншея әзер түгел, аннан да битәр баткакка түшәүлек салынмаган. Узган ике атнада Сунарчин агым начальнигына көн саен диярлек шуны тукып торды. Казанбаев исә барлык подразделениеләргә баш булып алгач та, әллә үҗәтлектән, әллә инде алдан ук максат итеп куйганча, баштагы айларда чакрымнар алуны күздә тотып, һаман үзенекен итә килде.

Бугазга-бугаз килеп ызгышырга маһир булмаса да, моңа кадәр үз сүзен аяк астында калдырганы бик сирәк иде әле Сунарчинның. Ул — табигате белән сабыр, басынкы кеше, боерганына еш кына хәйлә белән ирешә торган иде. Идарәдә аның турында: «Аны әле бер генә чегәннең дә алдаганы юк»,— дип сөйлиләр. Башлыкларны «ярар» белән юмалап, гадәттә, эшне үзенчә башкарып чыга торган иде. Бу юлы исә «ярар» белән генә котылып калырмын димә. Я акмыеклы сазлыкны ташлап китәргә, я мәсьәләне Аитов каршына куеп, үзенекен итәргә. Өченче юл юк бугай. Шул хакта озак баш ватты Ризван һәм ниһаять, башка юл тапмагандай булды — бригадага ял игълан итте.

Беренче карашка мондый карар бик табигый иде. Әзерлек эшләрен кертеп исәпләсәң, егетләрнең инде егерме көннән бирле ял иткәннәре юк. Алар шактый арыдылар, талчыктылар. Бер-ике көн эчендә үзләрен тәртипкә китерсеннәр, хәл җыйсыннар. Икенче яктан исә трассаның атна уртасында тынып калуы Казанбаевны сагайтырга, сагайтырга гына түгел, тиз арада түшәүлек салдырып, торбаны ялгарга, траншея казырга мәҗбүр итәргә тиеш иде.

Ризван ялгышмады, кичә кич шәһәрчеккә Казанбаев килеп чыкты. Аның сөмсере коелган, йөзе кара янып чыккан — трассада булуы, тынып калган агрегатларны күрүе сизелеп тора. Ул, конторка ишеген ачуга, Сунарчинга ябырылды:

— Колонна нишләп сазлыкның аръягында? Бүген бу якка күчеп куярлык вакыт бар иде ич,— диде ул кера-керешкә. Дөбердәтеп урындыкны тартып алды, Ризван каршына утырды. Сунарчин исә дәшми торды, аның тынычланганын көтте. Әмма Казанбаев тәкатьсез иде: — Син нервыга тими генә эшләргә уйлыйсыңмы, юкмы, Сунарчин?!

— Бригада эш фронты булганчы урынында кала,— диде Ризван тыныч кына.

Казанбаев, урындыгын этеп, аягына басты, өстәл аша Ризван өстенә иелде. Күзләре акаеп чыккан иде.

— Нәрсә?! Син... син бунтовать итмәкче буласыңмы?! Бу кыланышыңнан нәрсә исе килгәнне беләсеңме син?! Саботажник!

— Бик яхшы беләм,— диде Ризван, баягыча басынкы гына.— Син дә беләсең. Шулай булгач, әйдә, иплән кенә сөйләшик. Иртәгәдән түшәүлек салучыларны да, җир казучыларны да, сварщикларны да сазлыкка куярга кирәк.

Сунарчинның күтәрелеп бәрелмәве, үзенең бәһасен белеп кенә сөйләшүе Казанбаевны уйланырга мәҗбүр итте бугай, ул тәрәзә буена килеп, кесәсеннән папирос чыгарды.

— Син чистый бала-чага, Ризван Актуганович. Сазлык өчен агач каралмаганны беләсең бит. Ул хакта мин докладной яздым, өстә хәл итәрләр мәсьәләне.

— Агач бар, трасса тулы. Кешеләрне генә оештырырга кирәк.

Казанбаев тагын чыгырыннан чыга башлады, кабат өстәл янына килде, лыркылдап урындыкка утырды.

— Анысын инде үзең начальник булгач оештырырсың, иптәш Сунарчин. Хәзергә исә агымга мин хуҗа һәм сазлыкка чыбык-чабык түшәп,

машиналарны батыра алмыйм. Иртәгәдән бу якка күчәсез, минә шул,— диде дә, шапылдатып кулын өстәлгә куйды.

Ризван дәшмәде. Аның тын торуын ризалык билгесе дип кабул иткән Казанбаев, урыныннан кузгалып, чыгып китәргә җыенгач кына телгә килде Сунарчин:

— Минә нәрсә, Айрат, түшәүлек булмый торып, колонна урыныннан кузгалмаячак. Ә тик торган өчен җавапны икәүләп бирербез.

Казанбаев бу хәтлесен көтмәгән иде. Ул түргә атлады, йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты, иске өстәл сыкрап-ыңгырашып куйды.

— Ни сөйләгәнеңне беләсеңме син, юкмы?! Эт каешы булсаң да булырсың икән... Болайга киткәч, соңгы чара кала: иртәгәдән докладной язачакмын.

— Теләсәң нишлә. Әмма колонна урынында калачак!

Агым начальнигы, чабуына ут капкандай, торды, атылып ишеккә килде, аягы белән аны тибеп җибәрде.

— Эшеңне әнә Рамаевка тапшыр! — дип кычкырды ул баскычтан.

Ике арада булып узган шул низагны хәтеренә төшереп, Ризван елмаеп куйды. Аларның әле вакытлары бар. Изоляцияләү эшенә тотынганнан бирле колонна унбиш көндә унбиш чакрымнан артык юл үтте. Мондый күрсәткечкә әле, Себер шартларында, бер генә бригаданың да ирешкәне юк. Аларның рекордлары турында өлкә газетасы беренче биткә иң эре хәрефләр белән язып чыкты. Монысы бер булса, якшәмбеләрне генә санасаң да, башы булса, Ризванның хаклы икәнен төшенер. Инде болай да максатка ирешеп булмаса, сазлыкның бу ягына ялдан соң да күчәргә мөмкин бит.

Тик менә өч көн ял итү үзе бер бәла инде. Озакка сузылган эшсезлекне трассачылар ялсыз уздырган атналардан авыррак кичерәләр. Шәһәрчектә шахмат-шашка ише өстәл уеннары, телевизор, футбол һәм волейбол туплары бар барын, китаплар да җитәрлек. Әмма һәркайсы елга тиң җәйге көннәрне уен белән генә үткәрәсең әллә? Юк, болай батмый, берәр шөгыль табарга кирәк егетләргә. Җыйнаулап балыкка китәргәме? Әллә мунчаны ремонтлап алыргамы? Юк, Сазанакка, Зиннур янына барып кайтырга кирәктер. Колхозда беркайчан да эш бетеп тормый, безгә кулае да табылыр. Хәер, эшне эзләп торасы да юк лабаса! Ул бит Зиннурга Яман елгага күпер салып бирергә вәгъдә иткән иде. Ял көннәрендә дә эшләмәсәң, кайчан төзисең ди аны. Тик күпер хәтле күпер салырга тотынганчы, аның проектын эшләргә кирәк. Моның өчен исә елганың киңлеге, ярның, ниһаять, суның иң күп вакыттагы биеклеге һәм башка кайбер мәгълүматлар булуы шарт. Булды. Чәй эчеп алгач та, Сазанакка китәчәк, кирәкле үлчәүләрне алачак...

## 19

Шәһәрчектән ераклашканнан-ераклашты Сәетнафа. Күңеле аның ялгызлык тели иде. Шактый юл алып, колагына андагы тавышлар ишетелми башлагач кына тукталды, каршысындагы өмет кебек якты каенны кочаклап алды, кайнар башын нәфис ак тузга терәп, уйга калды...

Бер Гөлзәминә генә бөтенләй башкадыр, мөгаен, бу дөньяда. Ул ничектер үтә ягымлы, йомшак күңелле, артыгын сөйләмәс, алдашмас, тупасланмас. Үзенең самимилеге, ихласлыгы, кешелеклелеге белән күңелне тартып тора. Шуңа да бик якын итә аны Сәетнафа, үз күрә. Әмма әллә ничә еллардан бирле йөрәген буып торган ачу-үпкә аңа якынаерга ирек бирми Сәетнафага. Әлеге рәнҗүе онытылып киткән минутларда Гөлзәминәгә читтән генә сөеп, яратып карап тору белән канәгатьләнә... Ә бит аның да кешечә яшәгән чаклары, яратам дип, сөям дип янып йөргән мизгелләре, Мәхтүмә исемле бер кызны алиһә урынына күреп, шашып чапкан вакытлары бар иде. Ул чакта әле Сәетнафа бу кадәр үк

телсез дә, сәер дә түгел, аз сүзле гадәти бер егет иде.

Ташлы тау авылы янындагы разведка скважинасын бораулаганда танышты Сәетнафа аның белән. Хәер, танышты дию зурдан кубу булыр иде, Мәхтүмәне шунда беренче кат күрде.

Иртәнге якта ашханәгә бармый, электр плитәсендә чәй кайнатып, коры-сары белән генә хитлана иде Сәетнафа. Ул иртәдә исә егетнең тумбочкасы буш булып чыкты: ни ипи, ни балык-колбаса, ни шикәр-конфет калмаган. Вахтадан кайтуына, киемнәрен дә алыштырып тормыйча, кабат чыгып китте һәм күрше барак почмагындагы кибеткә юнәлде. Килеп керсә, хайран калды Сәетнафа: элеккеге тулып ташыган апа урынында, прилавка артында, яшь кенә чибәр кыз басып тора, кибеттә башка кеше-кара юк. Сатучы кыз тал чыбыгы кебек нәзек, үзе ябык, борыныннан кыссаң, җаны чыгар төсле. Буй-сынына ир-ат егылып китәрлек булмаса, да, төскә-биткә ярыйсы иде кызый.

Шул көннән башлап кибеткә ешлады Сәетнафа. Килеп кергәч, «Сине күрер өчен килдем»,— дип әйтеп булмый бит инде, ни дә булса алырга кирәк. Тик кайсы почмакка кем төкергәнне дә белеп торган поселокта чын ниятеңне моның белән генә каплап каласыңмы соң, сизде бит егетләр, аның сатучы кызга үлеп гашыйк булганын беләләр. Андый хәл дөньяга чыктымы, бетте диген, бораулаучылар күзеңне ачырмыйлар, җае чыккан саен синнән көләргә, теш ыржайтырга гына торалар. Әмма моңа әллә ни исе китми иде егетнең, киресенчә, Мәхтүмә турында сөйләгәннәрен яратып тыңлый, аның белән икесе хакында юкны бар итеп лыгырдасалар, чыннан да шулай бугай дип, ышана иде. Тик гел матурдан, гел тәмледән түгел иде шул сүзләр.

Бик алама бер гадәте бар бит ир-ат халкының: бер-бер хатын-кызны үзенә каратса, өстәвенә, аның ышанычын яулап, янында куныпнитеп тә калса, икенче көнне үк бу хакта, аю өнендә булып кайткандай мактанып йөри башлый. Андыйлар поселокта да бар иде, бораулаучыларның икесе Мәхтүмә куенында назланулары белән масаерга тотындылар. Моның кара гайбәт, коры шапырыну икәненә иманы камил иде Сәетнафаның. Әмма тора-бара Мәхтүмә исеме белән авыз чайкаучылар ишәйде. Юк, андый сүзләргә ышанмады Сәетнафа, үзенә фәрештә булып тоелган бу кызның начар юлга басуын күз алдына да китерми иде. Тик шунысы аяныч, кибет юлын күпме генә таптаса да, кызга йөрәген ачып сала алмады, эчтән янып-көеп йөри бирде. Аның күңелен киткән, эчен пошырган нәрсә — Мәхтүмә хакында сүзләрнең куеруы иде.

Ут-ялкын, газап эчендә байтак вакыт узды. Бер заман әлеге гаярь егетләрнең Мәхтүмәдән сүрелүен сизеп алды Сәетнафа. Сүрелүен сүрелделәр, әмма сатучыдан башка яши дә алмыйлар. Нигә дисәң, акчалы көннәрдән акчасызы күбрәк була. Мондый кара көннәрдә Мәхтүмә үзе бер хәзинә инде. Хәзинәсен хәзинә, тик ул да тиле түгел. Егетләрнең ниятләрен сизүгә, аларга бурычка бирни дә бирми башлый. Шуннан Сәетнафага сарышты егетләр. Ул, беркатлы бәндә ни, берәүгә дә каршы сүз әйтми, карусыз, кем нәрсә сораса, шуны үтәргә әзер. Кибеткә барырга җай чыкканга шатланып, тегеләргә бурычка азык-төлек ташыды. Иптәшләре дә бер дә рәхмәтсез түгел иделәр, Сәетнафаны дус иттеләр, хәтта Мәхтүмәнең фатирына алып барырга вәгъдә бирделәр. Сүзләрендә тордылар да.

Мәхтүмә, әйтерсең, кунакларны көтеп алдан әзерләнгән: аш-су мулдан, эчемлек җитәрлек иде. Гомер булмаганны, кыз үзе гел Сәетнафа янында урала, «Сәет җаным»,— дип җенә тора. Хәмердән дә бигрәк аның шул сүзеннән, игътибарыннан исерде Сәетнафа. Бермәлне аңына килеп, шушы бәхет ташырга торган бүлмәгә күз салса, хуҗа белән икәүдән-икәү генә калганнар. Бүгенге гаҗәеп кич хөрмәтенә тагы бер рюмка күтәргәч, егет бөтенләй мәлҗеде, акылын югалтмаса да, торып кайтып китәрлек түгел иде. Мәхтүмә аны, тартынып-нитеп тормый, чишендерде, караватка ятарга булышты...

Иртән ул гөр итеп сөйләшкән, көлешкән тавышларга уянып китте. Күзен ачса, кичәге шешәдәшләре өстәл янында «баш төзәтеп» утыралар. Мәхтүмә исә, йөз ел күрмәгән туганнары килгәнмени, тыз-быз кунакларны сыйлый. Сәетнафа торып утыруга, аның кулына да стакан китереп тоттырдылар.

— Ну, туган, закунлы никах белән үзеңне!

Сәетнафа, күзләрен мелт-мелт йомып, ни дияргә белми торганда, янына йөгереп Мәхтүмә килде, аны кочагына алып, битеннән үпте.

Шулай итеп, ул һич көтмәгәндә Мәхтүмәнең ире булып куйды.

Гаилә тормышы ничек кенә очраклы башланмасын, ул язмышыннан канәгать иде. Зәйсуга күчкәч, Мәхтүмә зиннәтле кафеларның берсендә кассир булып эшли башлады. Чаялыгы, кыюлыгы бар, шуңа да дус-иш күп, малны таба иде. Сәетнафа үзе дә хәзер торба салгычта эшли, акчаны яхшы төшерә. Тормышлары мул, бөтен. Дөрес, ул каладан еракка, промыселларга йөри. Бер атна кырда куныл-төнеп ята да аннан рәхәтләнеп ял итә. Аның каравы, кайтуына Мәхтүмәсе елмаеп каршылый, өстәл тутырып кунак ашы әзерли, дөресрәге, аларны ашханәдән ташып куя, ире утырган өстәл янында биеп кенә йөри. Башка хатыннар ирләрен бер чәкүшкә аракы алдырмау өчен чукынып китәргә әзер булганда, Мәхтүмә үзе модный сумкасына төяп эчемлекнең агын да, кызылын да алып кайта, «Эч, Сәет җаным, эч! Үз күкрәк көчең»,— дип ире кырыенда бөтерелә. Сөйгәне белән чәкештереп бер рюмка тоткач, Сәетнафа өстәлдәге нигъмәтләрнең тәмледән тәмлесен генә сайлап ашый, аннан йомшак кәнәфигә чумып, башмак тана биеклеге телевизор каршына утыра. Анда да игътибарсыз калдырмый аны Мәхтүмәсе, эчемлекнең затлыдан затлысын китереп кенә тора, күпләрнең төшенә дә кермәгән кара икра яисә кызыл балык каптыра, шул арада иренең битеннән «пәп» иттереп үбеп алырга да өлгерә. Башы авырая башлагач, киң агач караватка, сөттәй ак урын-җиргә барып ава Сәетнафа, беравык түшәмгә карап уйланып ята. Уйлары, тук бурзайныкы кебек, тиранннән түгел түгелен. Миендә ваемсыз тынычлык, канәгатьләнү. Шулай булмыйни, тагы кемгә тия мондый тормыш, яшәсә министр гына яшидер мондый рәхәттә!

Эх, ул чаклар! Матур иде дөнья, ямьле иде. Тирә-юньдәге барлык җанлы һәм җансыз нәрсә гүзәл, хатын-кыз исә фәрештә иде. Мәхтүмәне инде әйткән дә юк — матурлык алиһәсе! Һай, җир өстендәге җәннәттә яши иде шул Сәетнафа. Ләкин бу рәхәт озакка бармады, шомлы, аяусыз бер төн бөтен тормышын челпәрәмә китереп ташлады, җанын аяк астына салып таптады.

Чираттагы ялына калага кайткан иде Сәетнафа. Мәхтүмәсе аны шулай ук елмаеп каршылады, өстәл сыгылырлык итеп табын әзерләде. Сәетнафа, гадәтенчә, ашыкмый-кабаланмый гына сыйланды, исе китми генә телевизор карады. Аннан ак мамык мендәргә чалкан ятып, дөнья матурлыгы, тормыш бөтенлеге турында уйланды, шундый ипле һәм булган хатын белән кавыштырган язмышына рәхмәт укый-укый, Мәхтүмәсен көтте. Тегесе дә озак зарыктырмады, «Сәет җаным»,— дип гөрлигөрли килеп тә җитте. Сәетнафа аның шактый түгәрәкләнергә өлгергән кулбашына яңагын куеп, байтак иркәләнде, аннан ваемсыз гына йоклап китте.

Башка чакны шулай бер борчусыз, хәтта төш тә күрмичә, иртәнге җиделәргә кадәр йоклый иде. Хатынының: «Мин киттем, Сәет җаным»,— дигәненә генә уянып, аның эшкә ашыгуын тәрәзәдән карап кала торган иде. Бу юлы ни гаҗәп, төн уртасында уянып китте. Аңгы-миңге килеш өстәл янына барды, кулы белән кармаланып «Шифалы су» шешәсен эзләп тапты, аның бөкесен теше белән генә каерып ачты да стаканга салып тормый гына эчеп җибәрде, кабат ятагы янына килде. Ни хикмәт, Мәхтүмә караватта юк иде. Күзенә, кулларына гына ышанмыйча, салкын урынга эндәште:

— Мәхтүмә!

Җавап бирүче булмады. Кая китәр бу? Эшенә олаккан дияр иден, әле таң атмаган. Сәетнафа кызуланып кухняга узды, анда кеше-кара булмагач, ванна бүлмәсенең ишеген ачып карады, туалетка күз салды. Аннан бөтен җирдә ут яндырып куйды да бүлмә уртасына басып катып калды. Шулай беравык торды да бөтен өйне ярып кычкырып җибәрде:

— Мәх-тү-мә!!

Әмма стеналар өнсез иде. Тик келт итеп зур стена сәгате йөри дә, күрше квартираларның берсендә радиодан җиңелчә музыка ишетелә. Сәетнафа бөтенләй айнып китте, җанын шик-шөбһә басты. Җилләнеп тышкы ишеккә килде, анысы бикле булып чыкты. Шул кайнарлыгы белән кием шкафы астыннан бәләкәй балта, өтерге коралар чыгарды, каера-кыймылдата торгач, бикнең тимерен шуытуга ирешә. Аннан ашык-пошык киендә дә урамга чыгып китте.

Чыгуын чыкты, тик җиде төн уртасында кайдан эзлисең кешене? Милициягә барсаң әллә? Ярамый, сүзе бөтен шәһәргә таралыр, янында яткан хатынын югалткан дип, күзеңне ачырмаслар. Аптырап-йөдәп беравык чатта басып торды да Мәхтүмә эшли торган кафега таба китте. Эшендә ул-бу килеп чыгып, чакыртып алмадылар микән? Тып-тын калган урамны аяк тавышы белән күмеп, шунда ашыкты. Тик кафе бинасы караңгы һәм тын иде.

Йөгереп өенә кайтты. Анда аны шул ук өнсез стеналар, буш урын каршылады. Тагы чыкты, янә керде Сәетнафа, кабат урамга атылып ярты шәһәрне урады.

Үзләре яши торган йортның киң ишегалдына килеп кергәч, колагына ниндидер шау-шу чалынды. Сискәнеп, тавыш килгән якка карады. Квартал уртасындагы гаражлар янында халык төркеме шаулаша иде. Йөрәге «жу-у-у» итеп китте, шунда атылды. Әмма барысы да башын сузган якка — төркем уртасына үтеп керерлек түгел, бар да берьюлы сөйләгәнлектән, сүзләреннән берни аңлап булмый. Сәетнафа, йөрәк ярсуын басып, аерым сүзләрне тотып алырга, монда ни булганын аңларга тырышты.

— Маташмагыз да, җан керерлек түгел.

— Икесе дә суынып беткәннәр иң.

— Менә нәрсәгә икән ул ирләргә машина!

— Тегесен әйт син, әзмәвердәй ире бар көенә.

Өзек-төтек сүзләрдән бередә коточкыч бер хәл булуын абайлап алды Сәетнафа. Ул, терсәкләре белән халыкны аралап, ерып-ешып, төркем уртасына узды. Ә колагы төбендә иләмсез сүзләр һаман ишетелеп торды:

— Газга тончыгып үлгәннәр, бәдбәхетләр!

— Газ исен сизәргә ни, эшләре тыгыз булган бит.

Мәхтүмәне ул исемсез бармагындагы зөбәрҗәт кашлы алтын балдагыннан танып алды. Ничектер җайсыз итеп сузып салган ир-атның йөзенә карап та тормады, кисәк борылып, кешеләргә бәрелә-сугыла, читкә атылды.

Өенә әллә керде, әллә кермәде Сәетнафа. Берни ишетми-күрми бик озак чапты. Аннан тыны бетеп, арып-талып каядыр егылды һәм һушыннан язды. Аңына килгәндә аның өстенә битен кап-кара сакал-мыек баскан ир-ат иелгән иде. Ул аны, бала көйләгәндәй, нидер сөйли-сөйли җитәкләп, машинасы янына алып килде, күтәреп диярлек кабинага утыртты.

Кая таба һәм күпме барганнарын хәтерләми Сәетнафа. Машина ниндидер вагоннар янына килеп туктагач кына, үзенең исән икәнен искәрде. Бераздан аны шул вагоннарның берсенә алып керделәр. Ак халатлы кыз аңа укол кадады, ниндидер дарулар эчерде. Баш астына мендәр салып, шунда ук яткырдылар... Трассачыларның күчмә шәһәрчегенә әнә шулай килеп эләкте Сәетнафа. Шуннан инде калага бүтән кайтмады, гомерен трассада үткәрә торган булды...

Нидер кыштырдауга сискәнеп, Сәетнафа шыксыз уйларыннан айның китте, шикләнеп кенә борылып карады. Артында, аның пинжәк кесәсенә борынын төртеп, Иркә басып тора иде. Ул пошиның муеныннан кочып алды да сулкылдап елап җибәрде.

## 20

Ризван исә шәһәрчеккә бик соң һәм арып кайтты. Ярты көне Сазанакта Зиннурны эзләп үтте. Эше тыгыз булса да, төгәл кеше икән председатель, нәкъ уникенче яртыда төшке ашка кайтып җитте. Төп сүзен чәй янында башлады Сунарчин, исәбе — яңа күперне искесе урыныннан өскәрәк, кулай җирдә салуга күндерү иде. Кая ул, якын да килмиләр. Ул безнең өчен күпер генә түгел, ата-бабаларыбыз рухына, ике халыкның үткән тарихына һәйкәл дә булсын дип, аны гомерлек урынында төзүне якладылар.

— Ярый, сез дигәнчә булыр, дуслык күпере булыр ул,— диде Ризван урыныннан кузгалып.

Аннан соң ул, елга аша бер тегеләйгә, бер болайга йөри-йөри, елганың киңлеген, ярларның биеклеген үлчәп алды, авыл картларыннан ташу вакытында суның күпмегә күтәрелүен сорашты.

Инде шәһәрчеккә кайтырга, тынычлап ял итәргә була иде. Күлгә җиттек дигәндә, башына исәп төшеп, шоферга трассага борылырга кушты. Казанбаев белән бәхәсләште бәхәсләшүен дә, ә чынында ул ауган, тапталган агачлар гамәлгә яраклымы, бүрәнәләрне бульдозер чәрдәкләп бетермәгәнме?

Чишенеп ятуы булды, Зиннур белән көндезге сөйләшүләре хәтеренә төште. Менә сиңа, әй, авыртмаган башка тимер тарак! Сүзне сөйләгәч, эшен дә эшләргә кирәк бит аның. Алай ук зурдан кубар өчен тимербетон конструкцияләре, плитәләре, ташы, цементы кая соң әле аның? Андый мөмкинлеге юк Ризванның. Телисеңме-теләмисеңме, тимердән, дөресрәге, торбадан ясарга кала. Торба исенә төшкәч, урыныннан сикереп торганын сизмәде дә. Булды! Күперне ул Клименков базасында аунап ята торган яраксызга чыккан торбалардан салачак. Қискәләргә генә өлгермәсеннәр.

Үткән көне мәшәкатьле, төне борчулы булса да, гадәтенчә, иртә уянды Сунарчин. Кирәк була калса дип, рацияне кабызып куйды да кәгазьләренә чумды.

Сирәк-мирәк шытырдап, җиңелчә гүләп утырган рация турында ул инде бөтенләй оныткан иде. Кинәт эфирда кемнәрдер сөйләшә башлады. Ризван сәгатенә карап алды — җиде тулып киткән, димәк, идарәдәгеләр дә эшкә килгән. Чыннан да, рациядә Аитов тавышы иде. Әмма ул күп сөйләми, үзе кирәк дип тапкан агым яисә колонна начальникларын, бригадирларны берәм-берәм рация янына чакыра, нидер сорый, үтенә, таләп итә, кемгә нәрсә кирәк икәнен төпченә. Рация аша үткәрелә торган мондый летучкаларда, гадәт буларак, эше уңай барган коллективларга кагылмыйлар. Шуңа да рациядәге авазларга артык игътибар итми, нарядлар белән мәж килеп утыруында Сунарчин.

— Эрбет! Эрбет!

Эфирда үз колоннасының чакыру сигналын ишеткәч, Ризван сагаеп калды, сәерсенеп аппаратның яшел күзенә карап торды, аннан микрофон өстенә иелде.

— Тыңлыйм, Әсфәндияр Газарович.

— Нихәл, картаеп буламы?— диде рация Аитов тавышы белән.

— Бирешергә исәп юк югын.

— Шаяртасың, Ризван Актуганович. Сизелә, сизелә бит. Склероз якыная үзеңә — сводка бирергә онытkансың ич.

Ризван эшнең бик кечкенәдән икәнен чамалап, җиңел сулап куйды,

жавап бирергә ашыкты:

— Кичә без ял иттек, Әсфәндияр Газарович.

— Анысы яхшы. Тик башкалар белән бергә, якшәмбе ял итәргә кирәк.— Аитовның тавышында канәгатьсезлек билгеләре чалынып китте.— Бүген күпме узарсыз икән? Гадәттәгечә, бер чакрым инде, ә?!

Мондый сорауны көтмәгән иде Ризван, җавап бирергә кыенсынып калды. Бераз дәшми торгач кына:

— Без бүген дә ял итәбез, иптәш Аитов,— дип куйды.

— Менә нәрсә,— диде Аитов, кырыс кына,— ял итәсе көннәр алда бик күп әле безнең. Һавалар бозылып, көннәр яңгырга китсә, атналар буе йокларсыз. Хәзергә исә эшләп калырга кирәк.

Ризван дәшмәде. Ни дисен инде ул? Сүзен әллә никадәр кеше тыңлап торганда, Казанбаев белән икесе арасындагы низаг турында әйтеп салсынмы? Башкалар ни уйлар аның хакында? Әләкче, ялагай, диярләр...

— Я, ник дәшмисең, Сунарчин?!

Ризван киеренкелектән тирләп чыкты, рация өстенә иелгән хәлдә, катып калды. Шул мизгелдә рация яңадан телгә килде:

— Сунарчин ул артык акыллы, иптәш Аитов, агым начальнигы күрсәтмәләрен үтәүдән баш тарта.— Монысы Казанбаев тавышы иде, рация янында тыңлап утырган, күрәсең.

— Ал-лай... Эш нәрсәдә, Ризван Актуганович?— дип аңа мөрәҗәгать итте Аитов.

Инде мондагы хәлне яшереп торудан мәгънә калмаган иде.

— Эш фронты юк, Әсфәндияр Газарович.

— Монысын ничек аңларга, Казанбаев? Дөресме бу?

— Ялган!— дип кычкырды эфирга Казанбаев. Ул да түгел, кызып киткәнен сизеп алды бугай, ярарга тырышып кына сүзен дәвам итте:— Эш фронты бар, иптәш Аитов. Тик Сунарчин агым начальнигына баш бирми. Мин аны эшеннән читләштердем.

— Да-а-а, хәлләр,— дип көрсенде Аитов.— Тымызык күлдә корт уйный, димәк. Менә нәрсә, Казанбаев, көндезге сәгать уникегә барыгыз да Сунарчин колоннасы янына җыелыгыз... Үзем барып җитәм. Што-ты сезнең хәлләр ошамый әле миңа...

Күпер дә, аның нигезенә дигән торбалар да онытылды. Билгеләнгән сәгатьтән күп элек бригада саз буенда ямансулап яткан машиналар янында иде инде. Бераздан агымның башка бригадалары да җыела башлады. Берүзенә бер «Урал» куып, Казанбаев та килеп җитте. Җиргә аяк басу белән Сунарчинга ябырылды:

— Синең аркада бөтен Себергә адәм рисвае булабыз бит, понимаешь!

Ризван кайтарып сүз әйтмәде, торба салгычлар янында кайнашкан егетләр янына китеп барды. Колоннадан ерак түгел чирәмгә урнашкан башка инженер-техник работникларның да сүзләре ябышмады, дәшмитынмый гына тәмәке көйрәтәләр. Алар инде кайсы рациядән ишетеп, кайсы башкалар аша, булып үткән сөйләшүне ишеткәннәр һәм, идарә начальнигы килгәч, бирелә ни буласын якынча күз алдына китерәләр иде. Очрашу эзсез калмаячак: Ризванга да, Казанбаевка да эләгәчәк бүген. Башкалар да өлешсез калмас, билгеле. Менә шуңа да һәркайсының борыны салынган иде. Ярый әле озак көтәргә туры килмәде. Иртеш ягындагы урман өстендә вертолет күренде.

Очкыч иләмсез пытырдап килеп тә җитте. Ләкин аны көтеп аягүрә баскан кешеләр турында тукталмады, трасса буйлап ары китте. Идарә начальнигының мондагы хәлне үз күзләре белән күрергә теләве ачык иде. Чирек сәгать тә узмады, вертолет кабат мондагыларның баш өстендә йөзә иде инде. Түбәләрендә бераз асылынып торды да, җиргә төшә башлады. Тәзүчеләр, аңа урын биреп, як-якка сибелделәр.

Канатлар әйләнүдән туктауга, үлән чикерткәседәй яшел машинаның ишеге ачылып китте, Аитов чирәмгә сикерде. Яңак мускулларының

калкып чыгуы, зур соры күзләрендәге очкыннар киңәшмәнең гаугалы буласын әйтеп тора иде. Шулай булып чыкты да.

— Казанбаев!— дип кычкырды ул, төркем янына килә килешкә. Хәтта исәнләшеп тә тормады, әллә онытты, әллә инде ярсуы шул кадәр көчле иде.— Нишләп сазлыкка түшәүлек салынмаган?!

Айрат бу сорауны көткән иде, билгеле, үзе белән участокның техник документларын да алып килгән. Кулындагы күн тышлы папкасын ачып, бер төргәк кәгазь чыгарды, үзенә кирәклесен эзләп тапты.

— Ни сәбәпледер, бу сазлык проектта күрсәтелмәгән, иптәш Аитов,— дип башлады ул сүзен, үтә акыллы һәм дәрәҗәле булырга тырышып.— Шулай булгач, мәгълүм ки, аңа түшәү өчен агач та каралмаган.

— Ә нишләп мин бу хакта белмим?— дип бүлдерде аны Аитов.

— Мин докладной яздым, баш инженерга тапшырдым. Мәсьәлә хәл ителә булырга кирәк.

— Ителәме, әллә ителәдер генәме?

Казанбаев дәшмәде, җиңелчә кызарып, башын плащ якасы эченә җыйды.

— Нишләргә уйлыйсыз?— дип барына берьюлы ябырылды идарә башлыгы.

Казанбаев, кабат үзенең дәрәҗәле хәленә кайтырга тырышып, башын калкытты.

— Мин колоннага сазлыкны калдырып китәргә куштым. Ә ул,— Айрат Сунарчинга таба баш кагып алды,— күрәсез, мине күрмәмешкә салына...

Аитов Ризванга таба борылды:

— Син нәрсә, Ризван Актуганович?!

— Тиз арада түшәүлек салырга, траншея казырга, торбаларны ялгарга кирәк.

— Әлегә кайда икәне дә билгеле булмаган бүрәнәләр беләнме?

— Агач трасса тулы.

— Кызык, кызык фикер,— дип куйды Аитов, үзалдына сөйләнгәндәй, һәм кисәк кенә Казанбаевка таба борылды.— Шулай булгач, эш нәрсәдә соң?

— Сунарчин тузга язмаган белән хыяллана,— дип акланырга тотынды Айрат.— Монда агач вак, чыбык-чабык кына. Аңа ышанып, сазга техника кертә алмыйм, иптәш Аитов.

Идарә начальнигы, кинәт урыныннан кубып, трасса буйлап китеп барды, башкалар аңа иярде. Бераз атлагач, Аитов читкә борылды, бульдозер өеп-өеп куйган чүп-чар, агач өемнәре өстенә күтәрелде. Аннан, бүрәнәдән бүрәнәгә сикерә-атлый, аларны барлый башлады. Усаклар монда, чыннан да, нәзек һәм кыска иде. Шулай да арада өй бүрәнәсенә ярардайлары байтак күренде. Аитовның дәшми-тынмый гына атлавыннан аның ни уйлавын чамалап алды Сунарчин, үзенең хаклы икәнен исбатларга теләгәндәй, әйтеп куйды:

— Тегендә,— ул сазлыкның аръягына төртеп күрсәтте,— эре нарат-чыршы җитәрлек, кичә үзем карап уздым.

— Синеңчә эшләгәндә, сазны кичәргә ничә көн кирәгер?

— Агымда булган көч белән ябырылсак, түшәүлек салуны ике көндә төгәлләргә мөмкин,— диде Ризван ныклы итеп.

— М-да,— дип куйды Аитов, әллә килешеп, әллә икеләнеп. Егетләрчә җитезлек белән аркылы-торкылы яткан агачлар, тамырлары белән кубарып ташланган төпләр арасыннан үтте, чистартылган мәйданга сикереп төште. Юлга таба берничә адым ясады да, туктап, башкаларны көтеп алды.— Менә нәрсә, иптәш Казанбаев,— диде ул, барысы да җыелып беткәч,— бүгеннән, менә шушы минуттан технологик агым белән җитәкчелекне Сунарчинга тапшырыгыз. Ә син, Ризван Актуганович, кичекмәстән, халыкны күтәр. Үзегезнең генә көчегез җитәр бит?

Сунарчин мондый хәлне көтмәгән иде, ни дияргә белми аптырап калды. Башкалар да, миңгерәгән балык кебек, исләренә килә алмый торалар. Бер Казанбаев кына берни булмагандай сорап куйды:

— Мин... Миңа нәрсә? Колоннаны кабул итәргәме?

— Юк,— диде Аитов, шактый кырыс итеп.— Без Төмәнгә кайтып китәбез, иптәш Казанбаев. Турыдан-туры эшне оештыра белмисез икән, кәгазьләр белән утырырсыз.

Зираттан кайтучылар сыман дәшми-тынмый гына вертолет янына килделәр, шулай ук сүзсез генә Аитовны озаттылар, бер-беренә күтәрелеп карамый гына тәмәке кабыздылар. Һәркайсы гаепле эш эшләгән сыман тартынып, сүзсез калган иде. Казанбаев, исә, барына да үпкәләп, бер читтә төкеренеп торды-торды да машинасына утырып китеп барды.

— Болай торып сазлыкны кичеп булмас, җәмагать,— Ризван кесәсеннән кулъяулык чыгарып, битен һәм муен тирәләрен сөртеп алды, чал чәчен сыпырып куйды.— Болай итик булмаса...

Бригада җитәкчеләре машиналарына таба кузгалдылар.

— Давыд Захарыч, бер генә минутка!— дип кычкырды Ризван, инде кабинага кереп утырган Клименковка.— Син теге ярык торбаларыңны туратмадыңмы әле?

— Кая инде, Ризван Актуганыч, аязда шулар белән маташасың инде. Яңгырлы көннәрдә инде, насыйп булса...

— Кистерми тор, кирәге бар.

Клименков баш какты, ашыгып кабина ишеген япты.

Шундый чакта күпер турында уйлануына ачуы чыгып, үз-үзен шелтәләп тә алды Сунарчин, шулай да баскан урыныннан кузгалырга ашыкмады. Күпер булыр анысы. Тик менә сазлыкны ничек кенә тизрәк үтәргә? Аитовка ике көн диде диюен дә... Ай-һай. Бүгенгесе узып бара әнә, кичкә кадәр әллә ни кыра алмассың. Иртәгә дә бик алдырып булмас. Сварщиклар белән җир казучыларның үз эшләре. Бөтен өмет трасса чистартучыларда, Шаяз егетләрендә. Аз, бик аз шул көч. Сазлыкны үтү атнага сузылмагае... Зиннурга сугылып карасаң әллә? Нүжәли бер-ике көнгә бирмәс урман кисүчеләрен?

Бераздан инде ул утырган «Урал» Сазанак юлында иде.

## 21

Сунарчин агым начальнигы итеп билгеләнгәннән бирле, колоннаның бөтен мәшәкате Шаяз җилкәсенә төште. Трассадагы бригадирның эше болай да нык аерылып тора анысы. Башка тармактагылар хезмәтне оештыру, техниканың төзеклеген тәэмин итү, тәртип белән генә шөгыльләнсәләр, монда аңа, болардан тыш, күчмә шәһәрчекне ягулык һәм су белән тәэмин итү, ашханә, кибет, медпунктларның эшен күздә тоту, элемтәне җайга салу, мунчаны рәтләп эшләтү, тагын-тагын әллә нәрсәләр йөкләтелгән. Кызыл почмакта телевизор сүнсә дә, мичләр начар җылытылса да, душ эшләмәсә дә, яңгыр үтеп, урын-җирне юешләтсә дә, төзүчеләр туп-туры бригадир янына килаләр. Тап, төзәт, кара!

Күтәрү механизмы белән җиһазландырылган агрегатларны трассада «трубач» дип йөртәләр. Чыннан да, алар, укларын югары күтәргән хәлдә бер сафка тезелгәч, марш уйнап җибәрергә торган оркестрантларны хәтерләтәләр. Менә хәзер оркестрның куәтле авазы яңгырар да колонна алга кузгалыр...

Юк, фанфараларның тантаналы тавышы ишетелмәде, моторлар бердәм гүләде дә чистарту машинасының тимерчыбыктан ясалган щеткалары торбага ышкылып иләмсез чинады һәм куәтле машиналар алга ашкынды. Агрегатлар салмак кына уңга-сулга тирбәлә. Тигез баралар, изоляцияләү машинасы торбаны пәхтә һәм шома биләүли. Инде күп тә калмады, тагы берничә метр... һәм коры җир!

Торба салгыч яр буена түшәлгән агачлар өстенә менде бугай, торбаның бөтен авырлыгы үз машинасына гына төшүен тоеп, Шаяз сискәнеп китте. Тик чарасын күрергә өлгермәде, кирәгеннән артыграк тартылган корыч аркан, кинәт өзелеп, аңа таба ыргылды! Ул, сукканда тидерми калдырмагаем дигәндәй боргаланып, нәкъ Шаяз өстенә омтыла. Бригадирның аркасында салкын кырмыскалар йөгереште, кулы үзеннән-үзе рычагка үрелде. Аны кичекмәстән тартырга, укны кисәк кенә җиргә ташларга кирәк иде. Болай иткәндә, трос укка уралып җиргә төшәчәк һәм Шаяз бәладән котылып калачак. Ул үз уеннан үзе куркып китте. Нигә дисәң, Шаяз укны ташлауга, торбаның бөтен авырлыгы янәшәдәге машиналарга гына төшә һәм аларны мәтәлдерәчәк иде.

Аркан баш өстеннән генә еландай сызгырып узды, алтмыш тонналы агрегат чайкалып куйды. Бер уңга, бер сулга чалшайды. Хәзер авачак. Кичекмәстән сикерергә кирәк иде. Тик кайсы якка? Уңгамы, сулгамы, алгамы, арткамы? Кая таба мәтәлә бит әле? Төрле хәлләр булып тора трассада, шуңа да торба салгычларга кабина куймыйлар.

Әйе, теге чакны Галиаскәр укны ташлады, үзе имгәнүдән дә, авудан да котылып калды. Аның куркаклыгы аркасында башкалар мәтәлде. Дөрес, аны битәрләүче булмады. Куркаклык хакында сөйләмиләр, шулай ук беркайчан онытмыйлар да. Галиаскәр гарьлегеннән башка колоннага күчте. Әмма төзүчеләрнең кинаяле карашын күтәрә алмады — трассадан ук китеп барды. Шулай, монда үзеңне генә кайгыртмыйлар. Иң элек башкалар хакында уйларга, аннан соң гына үзең турында хафаланырга кирәк. Трассаның язылмаган законы шундый.

Калганы яшен тизлегендә булып узды. Күз ачып йомган арада машина ауган, Шаяз үзе берничә метр читтә, лычпырдап торган мәте өстендә ята иде. Егетләр, агрегатларын туктатып, колонна алдына йөгерделәр, Шаязны күтәреп аягына бастырдылар.

— Ярар... Мин үзем,— дип мыгырданды бригадир.

Нәкъ шул мизгелдә сазлык кырыена «Урал» килеп туктады. Ризван кабинаны ачып, түшәүлек өстенә сикерде.

— Нәрсә бу? Ничек болай килеп чыкты?— дип ябырылды Сунарчин. Аның үзенең дә йөзе агарынган иде. Резин итегенең башы белән корыч арканның өзелгән урынында каты мыек кебек тырпаешкан тимерчыбыкларга баскалап карады, аннан тагын кычкырынырга тотынды:— Мондый аркан белән эшләргә ярыймыни?! Бригадир башың белән ни карыйсың?! Бригадир күзсез, мин сукыр икән, черт побери!

Барысы да тынып калдылар. Ни дисең инде монда?

Юк, акыра-җикерә белми иде Сунарчин, үзе хаксыз булганда бигрәк тә. Минут үтүгә суынды, һәрвакыттагы басынкы кешегә әйләнеп калды.

— Нәрсә, егетләр, саз суырганчы машинаны күтәрергә кирәктер бит?!

Шаяз алга карап алды — коры җиргә, ныклы балчыкка чыгып җитәргә ун метр чамасы ара калган. «Караңгы төшкәнче узасы иде бит,— дигән уй үтте башыннан,— колоннаны төнгә саз өстендә калдырмассың ич. Түшәүлек иңә, тирә-юньдә агач та калмады».

— Гаеп миндә,— диде ул, бу хәлдән тизрәк котылу өчен.

— Син молодец! — Бәкер аны мактап алды.

— Егет икәнсең,— монысын Сыртлан әйтеп куйды.

«Нигә мактыйлар? — дип өзгәләнде Шаяз.— Тиргәргә кирәк. Ризван абый хаклы, яңа тросны кызганмаска иде».

— Ничава, бригадир, андый хәлләр булгалый ул,— ниһаять, Кавказ телгә килде,— шөкер, диген, хатының янына исән-имин кайтасың.

Зәйсуга кайтырга иртәрәк шул әле. Ә менә бәла аяк астында гына. Торба салгычны күтәреп куярга да колоннаны сазлыктан чыгарып калдырырга кирәк. Ә кешеләр арган, булып узган хәл, нервлар киеренкелеге аларны бөтенләй изеп ташлаган иде.

Шулай да эшкә тотынгач, арганлыклары онытылды. Торба салгычны «аягына» бастырып куйдылар да тагын алга таба кузгалдылар.

## 22

Ятагында кемдер бераүнең башыннан ук бөркәнеп ятуын һәм гамьсез генә йоклавын күргәч, Шаязның жене кузгалды. Кайсы исәре ауный монда? Шул гына житмәгән иде? Ул ачу белән теге бәндәнең аягына ябышты.

— Жүләр! Акылыңнан яздың мәллә?

Шаяз колакларына ышанырга да, ышанмаска да белмичә, ак жаймә ябынып яткан хатынының ак кулбашларына карап торды, тырпайган кашларын сыпыргалап, телсез калды.

— Син?.. Син нишләп йөрисең монда? — диде ниһаять, тотлыгып.— Бала кайда? Кыз нишли? Әллә...

Тагын нидер әйтмәкче иде, теле әйләнмәде, урыныннан торырга маташкан хатынына карап катып калды.

— Гомергә котың булмады,— дип зарланды Нурлы. Күтәрелеп аягына басты, урындык артына ташлаган халатын алып киде.— Борчылма, кызның урыны әйбәт анын — Гыйлминур әбисендә. Бик яхшы итеп ашый, эчә. Үсеп китте, күз генә тия күрмәсен.

— Соң нишләп аны ташлап йөрисең?

— Кунакка килдем менә.

Юксына иде хатынын Шаяз. Соңгы көннәрдә янына кайтып килү хакында да еш уйлана башлаган иде. Бүген менә һич көтмәгәндә очрашудан дөньясы шатлык белән тулды. Шулай да күңелендәген хатынына сиздерәсе итмәде.

— Һы, эшең беткән икән,— дип кенә куйды.

— Эш бетми шул, Шаяз, эш,— дип зарланган булды Нурлы.— монда килүем дә шул эш аркасында... Бар, юын ичмасам, таба сөрткече кебек торма каршымда.

Хатыны килүдән очынган Шаяз шуннан соң гына майлы киемнәрен салып атты, спортчылар чалбары киеп алды да, кулына сөлгесабын тотып, ишегалдына чыгып китте.

Ялан кырда яисә бирedәге кебек аулак урман аланында бар дөньядан аерылып яшәгән шәһәрчек шундый инде ул: бер-бер нәрсә «шылт» иттеме, тиздән ул хакта ишетмәгән кеше калмый. Нурлының һәм аның белән бер үк вакытта таныш булмаган тагын ике кешенең килеп төшүе барына да таралган иде инде. Алай да ниндидер институт вәкилләренең буталып йөрүләренә исләре китмәде. Ә менә үзләренен кендекләре береккән каладан тере кеше килүе — мондагылар өчен бер бәйрәм! Эштән кайтып төшүгә, күбесе Нурлыны күрү нияте белән пытпылдап йөри башлады. Әмма бер-берен күрергә зар-интизар булып беткән ир белән хатын янына капылт кына барып керергә берәү дә кыймый иде. Гөлзәминәнең генә сабырлыгы житми, һаман Шаяз яши торган вагон тирәсендә урала. Ашыгып юынгычка таба баручы бригадирны күреп алуга, Гөлзәминә ишеккә ыргылды.

— Минекеләрне күргәнең бармы, Нурлы? — диде ул керә-керешкә, хәтта күрешү йоласын да онытып. Йөрәге аның шашып тибә, күзләрендә куркыну иде. Менә хәзер Нурлы уллары хакында коточкыч бер хәбәр әйтер дә, йөрәге өзелеп идәнгә төшәр, тәгәрәп китәр төсле. Ул кунакның сүзен авызыннан тартып алырлык булып аңа текәлде.

— Исән-сау гынамы, Гөлзәминә? — Нурлы күрешергә дип кулын сузды. — Ару гына эшләп ятасыңмы?

— Нидер булган,— диган шомлы уй яшен ташыдай яндырып узды Гөлзәминәне,— югыйсә сүзмас, туры сорауга туры җавап бирер иде. Сагышлы ананың күзләренә илерү бәреп чыкты.

— Сузма, әйт: исән-саулармы бәгырь кисәкләрем?
— И-и-и, Гөлзәминә, булса да булыр икән балаларың! Кызлар кебек инсафлылар. Узган-барганда туктап исәнләшми калмыйлар.
— Соң, соң, күргәлисеңме үзләрен? — дип ялварды Гөлзәминә, бераз тынычланып.
— Күрмәгән кая... Монда китәсе булгач, беркөнне кич яннарына үзем кереп чыктым. Өйләрен гөл иттереп җыйганнар. Айзаты аш пешерә, Айгизе оекбашын чайкап маташа... И-и, онытып торам икән, күчтәнәчләре бар бит әле.
Нурлы вагон почмагында яткан чемоданын ачты, аннан бавырсак тулы полиэтилен капчык чыгарды. Гөлзәминә төенчекне алып күкрәгенә кысты, тып-тып итеп ике бөртек яшь үтәкүренмәле янчыкка тамды: «Сабыйларым минем!»

Чәчен-башын туздырып Шаяз килеп керде, бүлмәнең астын-өскә китереп чиста киемнәрен эзли башлады. Рәешкә диген, моңа кадәр кирәге чыкмаган күлмәк тә, чалбар белән пинжәк тә кайсы кая аунап яталар иде. Күз төпләренә яшь аралаш шатлык кунган Гөлзәминә исә шыпырт кына чыгып та китте. Сагынышканнардыр, гөрләшсеннәр әйдә.
Әмма аларга гөрләшү насыйп булмаган икән. Гөлзәминә китүгә ишектә Таңчулпан күренде. Килеп тә керде, яшь болан кебек атылып, апасының муенына асылынды.

— Кит, ләтчә, кытыклыйсың бит,— дип куйды Нурлы, назлап кына.
Бераздан Сыртлан белән Шәхсәнәм керделәр. Озаклап, тәмле итеп күрештеләр, тәфсилләп исәнлек-саулык сораштылар. Аннан соң гына сүз Гыйлминур әбигә, Зәйсу хәлләренә күчте. Бераздан инде вагонга дистәгә якын төзүче кереп тулган иде.
Дания исә хәл белергә ашыкмады. Тутырган тавыктай шул кысыр хатынны яратмый иде ул. Өрлектәй ирне авызына каратып, гомерен заяга уздырып тора бит әле шул. Даниягә эләксәме андый ир! Өч бүлмәсенең өчесен тутырыр иде бала белән...
— Менә бит, ирләре янына ятмыйча бер генә ай да чыдый алмыйлар,— дип сөйләнде Дания, токмач кабарганны көтеп ашханә ишеге төбендә таптанучыларга.— Тол хатыннарның гайбәтен сатарга дисәң, аларга куш. Торып карасыннар ие, безнең сыман еллар буе ир назы күрмичә. Менә шунда сөйләшер ием мин алар белән.
Шулчак ашханәдән Клавдия түтинең ягымлы тавышы яңгырады:
— Әй, хезмәт халкы, ашарга!
Шау-гөр итеп ашханәгә җыелдылар. Көндәгечә уен-көлке, мәзәк башланды. Бүген ул куерак та түгел иде микән әле? Нигә дисәң, Шаязның, кечке ашка килмичә, хатыны куенында назланып ятуы көн дә бер балык башын чәйнәүчеләргә әйбәт азык иде. Башта, һәрвакыттагыча, һәркайсы күчәр башын Сәетнафа арбасына орындырырга маташты:
— Сиңа эш артты бит әле, комендант, бригадир сараена сак куярга туры килер бүген.
Ашауларыннан туктап, бер гаңгылдашып алдылар. Сәетнафа шуннан файдаланып, тәлинкәсен күтәреп тышка чыгып китте. Эчтә исә мәзәккә генә сыеп бетми торган сүзләр дәвам итте.
— Күршедә генә кияү егете белән кәләш ятканда синең дә йокың йокы булмас бүген, Бәкер.
— Анысы да моңысы, Кавказ төшләнер инде, саташып бетәр. Шүтке мени, өч-дүрт хатынның берсе дә килмәсен әле янына! Әалимент акчасын ай саен сыпырып торалар.
Кавказ кызарынды-бүртенде, ләкин башка чакны теленә үзләре килеп торган җор сүзләрне таба алмады. Аның өчен Дания җавап биреп өлгерде:
— Хафаланмагыз, саташмас! Нурлы кебек кенә асыл затлар үзе-

бездә дә бетмәгән. Ие бит, Кавказ?!

— Шулай диген, Дания. Без үзебез дә төшеп калганнардан түгел!

Күчмә шәһәрчекнең бертөслерәк тормышына килеп кергән шушы кечкенә генә яңалык барын да үзгәртеп җибәргән, дәртләндергән, канатландырган иде. Ашавын онытып, үз вагонында утырган Сунарчинны гына шатландырмаган бу вакыйга. Дөресрәге, көтмәгәндә килеп төшкән институт вәкилләре эчен пошырды аның. Яңа машина сынап карамакчылар, имеш. Тапканнар бит урынын, тапканнар бит вакытын.



## 23

Кичәге күңел күтәренкелегенең шаукымы иртән дә басылмаган иде әле. Төзүчеләр эшкә китәр алдыннан уен-көлке, төртмә сүзгә тагын ирек бирделәр.

— Сиңа, бригадир, трассага чыкмаганда да ярый иде инде. Барыбер эшеңнең рәте-чираты булмас.

— Әйтмә дә, гөнаһлы кешегә ничу.

— Ну, малай, үзең дә тартылып киттең бит, әй. Бер төндә авызың гына утырып калган.

Шаяз башта бу мәгънәсез сүзләрне ишетмәгәндәй барды. Башкалар сыман юкка тел кашырга кәефе юк иде аның. Нурлы килү уңае белән күңелен биләгән шатлык бүген иртән ниндидер канәгатьсезлек белән алышынды. Төзүчеләр белән бергә машинага утырган институт вәкилләрен күргәч исә сөмсере тәмам коелды. Шуңа да авызларын ерып һаман юк-барны лыгырдап барган Кавказ белән Бәкер ягына ачулы караш ташлады.

— Җитте сезгә! Ничек телегез армый юк-барны сөйләп.

Тегеләр дә, тирәнгәрәк кереп китүләрен аңлап, телләрен тешләделәр.

Яңа агрегатка күңелләре тартмаса да, дәррәү эшкә тотындылар. Хәтта институт вәкилләре үзләре дә, җиңнәрен сызганып, төзүчеләр белән бергә мәж килә иде. Бигрәк тә аларның өлкәне, пеләш башлысы бөтен күңелен биреп тырышып йөри. Икенчесе — пыяла чәшке хәтле зур һәм калын күзлек кигәне («Фара» дигән кушамат алып өлгергән!) төскә-биткә чибәр, яшь күренә, тазалыгы-исәнлеге ташып чыккан. Шулай да эш дигәндә дөрләп китми, бигрәк тә кара эштән чиркана, башкалар җан талашып тир түккәндә читтәрәк торырга ярата.

Кояш күтәрелеп җиткәндә яңа комбайн, чут төймәсе кебек, торбага кидереп куелган иде инде.

Шикләнүләре юкка икән. Кузгалып китүгә, машина әйбәт кенә эшли башлады. Аның торба өслеген чистартуы хәзергә әллә ни мактарлык түгел түгелен, уралган кәгазь белән пыяла-мамык та элеккечә шома, тигез ятмый. Андамыни соң хикмәт, иң мөһиме — комбайн эшли, димәк, максатка ярашлы! Йөзләренә шатлык билгесе чыгармасалар да, эшчеләрнең күбесе шулайрак уйлый иде бу минутта. Комбайнның кечкенә басмасына менеп баскан Толик кына, дулкынлануын яшерә алмый, ыгы-зыгы килә. Башта ул басмасында биеп алды, аннан, елгыр тиен сыман, агрегатның әле бер, әле икенче ягына чыкты, институт вәкиленә баш бармагын күрсәтте. Дөрес, ул яңа машинага әле яралгы чагында — сызымда хәлендә үк кул селтәгән иде. Исең киткән икән, ике агрегатны бер иткәннәр, имеш. Ә эш шартларында нәрсә генә үзгәрә соң? Юк бит, юк. Аңа — машинистка һаман да шушы күперчектә басып торырга, ут борчасы булып, комбайнның әле бер, әле икенче ягына чыгарга, элекке сыман әледән-әле егылып төшәргә кала. Шулай да ул бу нәрсәнең эшләп китүеннән канәгать иде. Нигәнтә, быел аңа да күптәнге уен тормышка ашыру — техникумга керү өчен имтиханнарга бару җае чыкты бит. Югыйсә елның елында: «Тагы бераз

түз инде, Толик?! — дип теңкәсенә тияләр. Уйларыннан аны колоннаның кисәк кенә туктап калуы аерды. Машина белән мавыгып, яннарына Сунарчин килеп туктавын сизмәгәннәр дә. Моторлар гөрелтесе юашланып калуга, барысы да комбайн янына җыелдылар.

Сунарчин машинаны капшаштырган җиреннән туктап, кулларын каккалап алды, үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

— Чыннан да, тумаган тай.— Бераз тын торды да, вәкилләргә таба борылып сүзен дәвам итте: — Болай булмый, егетләр. Чистартылмаган торбаны битум белән чорнауда ни мәгънә? Җитмәсә, уравының да рәте-башы юк. Көйләрлек булса, көйләргә кирәк.

Трассачылар, суд хөкемен тыңлаганнан соң таралган халык сыман, акрын-акрын агрегат яныннан читләштеләр. Комбайн янында авторлар белән соавторлар һәм агым начальнигы гына басып калды. Алар берберен бүлә-бүлә тамаклары карлыкканчы бәхәсләштеләр, машинаның әллә кай җирләрен актардылар, узелларын сүтеп җыйдылар. Ниһаять, аны эшләтеп карадылар. Тагын туктаттылар, тагын җибәрделәр...

Инде кояш төшлеккә җитте, инде машина янындагылар баштанаяк майга батып бетте. Әмма эшләренең нәтиҗәсе күренмәде. Агрегат торбаны һаман да өстән-өстән генә чистарта, изоляцияләве дә шулай ук аннан-моннан гына. Пеләш башлы вәкил, комбайнга карап-карап торды да, күкрәгеннән соңгы сүзен сыгып чыгарды:

— Кайбер узелларны үзгәртеп ясарга кала, Ризван Актуганович.

Агым начальнигы дәшмәде, «Фара» исә чыелдап кычкырып җибәрде:

— Шушында, кыр шартларындамы?

— Аз-маз үзгәртү өчен Зәйсуга кайтырга оят,— диде иптәше.— Шулай да кыру станогы, сварка һәм алачыктан башка ерып чыгып булмас. Нишлибез, Ризван Актуганович?

Сунарчин дәшмәде, үпкәләгән баладай турсаеп, читкә борылды.

— Сүтегез! — диде бераздан, берәүгә дә төбәп әйтми генә.

Вату — төзәтү түгел, чирек сәгать дигәндә, агрегатның чатын чатка аерып ташладылар, торба өстендә аның кысасы гына сураеп калды.

— Утырыгыз! — диде Ризван конструкторларга, үзгәртеп ясыйсы узелларны машинага төягәч, аннан, Шаязга борылды: — Вакыт барында машиналарны карап, майлыйсы булыр. Без Сазанакка киттек, Зиннур ярдәменнән ташламас.

Трасса буйлап китеп барган «Урал»га карап, тын калдылар. Барысының да сөмсере коелган, әйтерсең, әле генә якын бер кешеләрен күмеп кайтканнар да, авыр югалтудан өнсез калганнар. Авыр тынлыкны Анатолий бозды:

— Әйттем бит пүчтәк дип.

— Иписез калабыз, егетләр, болай булса,— дип сүзгә кушылды Мәүлетбай елак тавыш белән.— Үләксәләрен институтларында сынасыннар әнә. Ничу кешене ач калдырып йөрергә.

— Эшли идек бит әле, ярый иде,— дип куйды Гөлзәминә тыныч кына.

— Сөйләмә дә,— дип күтәреп алды Дания,— кулдан урасак та, ике-өч йөз метр үткән булыр идек инде. Йөриләр шунда эч пошырып.

— Йә, ни дип сытылдыгыз әле. Сөртегез күз яшьләрегезне,— дип җикерде Кавказ, елмаюлы йөзендә җитдилек сакларга тырышып.— Кайсыгыз соң срогыннан элек туган? Машина да шулай. Вакыты җитми, чәчәк атмый бакчадагы гөлләр дә...

Ах, янды, кычкырып янды көн!

Шул рәвешле беравык өзгәләнеп торды да, кискен бер карарга килде бригадир.

— Алып атыгыз бу нәмәрсәне! — дип кычкырды ул, зарланышып торган трассачыларга. Үзе ачуыннан бүртенеп, беренче башлап торба өстендә сураеп торган агрегат кысасына таба атлады.

Башка чакны изоляция машинасын һәм чистарту агрегатын тор-

бага кидерү байтак вакытны ала иде. Бу юлы әллә артык ярсып эшләделәр, әллә мавыгып китеп күпме маташканнарын сизмәделәр, һәрхәлдә, эш сәгате тәмамлануга, колонна тулы хәзерлектә иде инде.

Тамак ялгап вакыт үткәрәсе итмәделәр, исәпләре — бүген югалтканның яртысын булса да кайтарып алу иде. Иләмсез машиналар кәрваны ухылдап-гүләп, чинап-чыелдап алга кузгалды.

Кояш баеп, Иртеш буе киңлекләренә ак төн иңгәч кенә торба салгычын туктатты Шаяз. Машинасын сүндерергә өлгермәде, арттан Мәүлетбайның тузанга буталып юталли-юталли кычкырганы ишетелде.

— Нигә туктадың, бригадир?! Ках-ках... Куала давай!

Аңа Кавказның карлыккан тавышы кушылды:

— Перекур юк, җәмәгать, крах, норманы үтәмичә туктамыйбыз! Төн уртасы җитсә дә...

* * *

Шәһәрчек кырыендагы чирәмлектә тын гына утырган яшел вертолетны күргәч, Ризванның эченә пошаман төште. Башлыклар! Антовмы, әллә партком секретаремы? Теге чакны, нефть үткәргечен төзүче барлык эшчеләргә, инженер-техник работникларга мөрәҗәгать белән чыкканнан бирле, участокта тынгылык бетте. Җитәкчеләрнең әле берсе, әле икенчесе килеп чыга, әрсез корреспондентлар теңкәгә тия, башка агымнардан тәҗрибә уртаклашырга килеп йөдәтәләр. Болары нишләп йөри икән тагын? Кем генә булмасын, сиңа файдага йөрмиләр инде. Эш калдыручылар.

Конторка түрендә утыручы Антовны күргәч, фикере үзгәрде Сунарчинның. Каралып, кырысланып киткән йөзенә елмаю чыкты. Тик тәрәзә буендагы могтәбәр кыяфәтле кешеләргә күзе төшкәч, тагын чырае сытылды. Шулай да аны-моны сиздермәде, гөрләтеп сәлам бирде.

— Менә агым начальнигы үзе,— дип куйды Антов, юлдашларына карамый гына һәм йөнтәс зур кулын Ризванга сузды.— Исәнме?! Сирәт күперен кичүчеләр алып килдем менә. Кабул ит.

Аның тел төбеннән берни аңламаса да, Сунарчин шикләнеп-шөбһәләнеп калды.

— Янә эксперимент алайса?

— Ниндие генә әле! Сынау узганнан соң, гомерең буе миңа рәхмәт укыячаксың.

— Һәй, экспериментлар болай да бөердәге таш кебек утыралар минем.— Ризван, үпкәле малайдай, аскы иренен салындырды.— Гарык мин алардан!

— Менә нәрсә, Ризван Актуганович,— дип, идарә начальнигы русчага күчте,— институт вәкилләрен мин сине яратканга янсә яратмаганга алып килмәдем. Хикмәт шунда, сезнең участок иң катлаулылардан: алда — берничә чакрымга сузылган Елан сазлыгы. Эксперимент өчен трассаның нәкъ менә шундый урыны кирәк тә. Барып чыксамы! Беләсеңме ни була, барып чыкса? Нефть һәм газ үткәргечләре салуда тулы бер революция!

Юк, дөресен сөйләми иде Антов. Сазлыклар өчен генә түгел, нәкъ менә Ризванны якын иткәнгә алып килде ул монда институт вәкилләрен. Югыйсә, Себер хәтле Себердә азмы сазлык-баткак! Дөресен әйткәндә, кайсы гына технологик агымга барып төшмә, булачак сынаулар өчен полигон әзер. Әйе, нәрсәсендер ярата ул шушы басынкы кешенең. Сабырлыгынмы? Күпме йөк салсаң да, бер җайга гына тарткан алаша сыман күндәмлегенме, әллә начальство күрсәтмаләренә «ярар» дип тә, һаман үз җаена эшләп, әйбәт кенә җитәкчелек итүенме? Бу юлы да алда торган гаҗәеп сынауның монда узуын ул теләде, техсовет утырышында ихтыярын башкаларга ул такты. Дөрес, участок ерактан да, һәртөрле фәнни-тикшеренү институтларыннан да еракта,

юлы дисәң юлы, зур шәһәрләрдәге башка уңайлыклары юк. Аның каравы, биредә үз эшләренә башы-аяклары белән бирелгән осталар, энтузиастлар бар. Менә шулар тәэмин итәчәк тә инде экспериментның уңышын!

Идарә башлыгының күтәренке рух белән дәртләнеп сөйләве Сунарчинга да тәэсир итми калмады. Ул, хәтер калуларын онытып, Аитовның дулкынланудан бераз кызарып киткән йөзенә текәлде:

— Нәрсә соң ул шул хәтле революция ясарлык?

— Торбаларны йөздереп салу. Нечкәлекләрен әнә белгеч иптәшләр сөйләрләр.

Кунакларның берсе — кылган чәчлесе, чандыры, группаның җитәкчесе булса кирәк, аяк очындагы бозау чаклы портфелен күтәреп алды, аны ачып, бер төргәк кәгазь тартып чыгарды да аларны өстәлгә чәчеп ташлады.

— Кыскача гына аңлатканда, менә болай,— дип башлады ул, килешкилбәтенә ябышмаган калын тавыш белән.

Җыйнаулап кәгазьләр өстенә иелделәр. Әлеге сызым-проектның кайчандыр Зәйсу янындагы Урсал сазлыгында үзе торбалар салган тәҗрибә һәм кайчандыр институтка үзе язган хат нигезендә эшләүләрен дә, ул хатның күптән чүплеккә ташланып, анда язылган фикернең аерым галимнәр башына күчүен дә белми иде әле Ризван...

## 24

Кичләр сизелеп сүрелде, ак төннәр каядыр Обьның түбән агымына — тайгага чигенеп, эңгер-меңгердән соң ук Иртеш буена караңгылык иңә башлады. Җәй буе бер кат ак җәймә генә бөркәнеп йоклаган төзүчеләр мамык юрганнарын эзләп алдылар, иртә-кич сырма киючеләр күренгәли. Төннәр салкын һәм коры иде. Соңгы бер-ике көндә тагын да җиләсләтеп җибәрде: Салым сазлыкларыннан салкынча җил исте, шул яктан ямьсез булып аксыл-сары болытлар күтәрелде — мәһабәт Боз океанының сулышы сизелә иде.

Шулай да җәй үз куәтендә әле. Агачларның яфраклары кара-кучкылланып, купшыланып, яшәреп утыра, ә тирә-юньдә, колхозчыларның кулы җитми калган җирләрдә, кеше күмәрлек булып, каерылып сусыл үлән үскән.

Тик барыбер күз үзенең еракта түгеллеген сиздерә. Моңа кадәр талгын гына искән төньяк җиле кинәт көчәеп, болытларның зурларын, карараларын алып килде, яшькелт-зәңгәр күк гөмбәзен яссылатып томалап куйды.

Көчәйгәннән-көчәя барган җил тавышына сискәнеп, алдында өстәл тутырып яткан нарядларын бер читкә этеп куйды Сунарчин, тәрәзәне ачып, тышка үрелде, йөзенә китереп бәргән җилнең чиркандыруына игътибар бирмичә, күккә төбәлде. Их-ма, көннәрнең бозылуы микәнни? Әх, китмәде бит, тагын китмәде бераз. Янә атна чамасы гына сабыр итсә дә, колонна баткак урман арасыннан чыгып, инде бодае җыеп алынган иркен басуга килеп керәчәк иде. Нишлисең, вакыт сине көтми шул. Башта вак-төяк баткаклар, аларга вакытында түшәүлек салынмавы кулны тотты; Елан сазлыгы, аны моңа кадәр күренмәгән ысул белән үтү айдан артык вакытны алды. Теге яңа комбайн ике-өч көнне йотты... Анысы ярый инде, чистарту агрегаты машинистына хаҗәт калмады. Югыйсә имтиханнар бирергә дип китеп барган Дамирны кем белән алыштырыр идең? Болай исә барына да бер Анатолий өлгерә.

Шулай уйланып, Ризван вагонның тимер баскычына чыгып басты, һәм авыр тимер стена булып төшкән караңгылыкка килеп бәрелгәндәй, туктап калды, башында һәрчак прожектор янып торган багана ягына ихтыярсыздан карап алды. Әмма анда да шушындый ук дәһшәтле

караңгылык иде — лампочкасы янып чыккан, күрәсең. Житмәсә, күчмә йортларда да утлар сүнеп беткән. Шәһәрчек ишегалды дөм караңгы һәм шомлы иде. Йөрәген шөбһәле күңелсезлек биләп алды. Агач башларында җил ыжылдый, тайга, үзенең яшел толымнарын ботарлауларына ачуы килеп, ыңгыраша, ухылдап-ухылдап куя, ярсып шаулый. Әллә саташып, әллә язмышыннан зарланып, камышлар арасында тәкърарлек кычкырып алды — тагын да күңелсез, шыксыз булып китте. Кинәт якында гына эт уларга тотынды. Ризванның кәефе тәмам кырылды, боегып кына вагонга узды, чишенеп утын сүндерде, караватына ауды.

Калгып китәргә өлгермәде, ишегалдында ярсып-ярсып эт өрергә тотынды, ул да түгел, ачыргаланып чиный-чиный, каядыр читкә китеп барды. Якында гына аяк тавышлары дөпелдәгәндәй булды. Әллә соң әлеге авазлар колагына гына ишетеләме? Юк, кемдер йөри, әнә баскычка ук килеп менде. Тавышсыз гына ишекне ачып, бүлмәгә үк килеп керде. Сәлам бирмәде, ут яндырмады.

— Кем ул? Ни йомыш?

Кайтарып җавап бирүче булмагач, үрелеп ут яндырды, әчке күлмәкыштаннан килеш, чакырылмаган кунак каршында басып калды. Өстендәге сырмасы пычранып, чыланып беткән, чәчләре тузгыган бәндәне башта танымый торды. Күзе яктыга күнгәч кенә, аның Клименков бригадасындагы Шадра икәнен белеп алды.

— Ни йомыш? — дип кабатлады ул, тегенең исемен һәм атасының исемен хәтеренә китерергә тырышып. Тик исенә төшерә алмады, бригадада аны бар да «Шадра» дип кенә йөртәләр иде.

— Килдек әле, начальник,— диде теге, баскан урынында чайкалып. Ишек катында, ул баскан урында кап-кара күлдәвек хасил булган иде.

— Күрәм. Тик ни өчен җиде төн уртасында?

— Хатын үлгән, начальник... Кайтырга кирәк. Төмәнгә илттереп куй... Һич югы Тубылга.

«Нүжәли хатыны булды икән моның? — дип уйланды Ризван,— адәм рәтләп иректә яшәгәне дә юк бугай лабаса».

— Поездлар йөреп тора бит,— диде ул, Шадрадан котылырга җае табылуга шатланып.— Клименковка әйт: утыртып җибәрсен.

— Юк инде, начальник, ике-өч тәүлеккә бер узган поездны көтәр әмәлем калмады. Машина бир син миңа!

— Машиналар юк... Төн уртасында бигрәк тә.

— Табарсың! — диде Шадра, тавышын күтәрә төшеп.

Ризван аның янавына игътибар итмәде, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып әйтте:

— Менә нәрсә, сез хәзер кызыл почмакка барып, иркенләп ял итегез. Ишеге ачык, раскладушкалар һәм урын-җир шунда. Иртән иртүк Тубылга илтеп куярлар.

— Йокы — башлыклар эше, үзең йокла. Әзгә китәргә кирәк, начальник. Әйдә, җик атыңны! — Шадра, идәнгә җәелгән линолеумда пычрак эз калдырып, өстәл янына үтте, лыркылдап урындыкка утырды.— Без көтәбез, начальник!

Ишек яңагына сөялгән үсмернең җебеп төшкән чандыр гәүдәсен Ризван шунда гына күреп алды. Егетнең башы салынган, авызыннан селәгәе агып төшкән иде. «Малайны эчергән»,— дигән уй үтте Сунарчинның башыннан. Тукта, монысы кем соң әле тагын? Монда күптән түгел генә килеп, монтажчылар янына стропальщик булып урнашкан Альберт түгелме соң? Шул. Ай, начар кулга эләккән егет. Ничек ычкындырдың соң син аны, Давыд Захарыч?!

Шадраның исә үз туксаны туксан иде.

— Бер сүзне күпме сөйләргә була, начальник?!

— Мин әйттем: барыгыз йоклагыз! Иртәгә... Ә малайны синең

белән җибәрмим мин.— Ризванның тавышында кырыслык, катылык чалынып китте.— Ягез, мин китәм!

Шадра тешләрен шыгырдатып куйды, зур йонтәс йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты.

— У-у-у, падла! Начальник булган, имеш. Минем кебек үк зыка бит син, сволота. А-ну, уят шоферыңны!

— Мин аңларлык итеп әйттем бугай: төнлә бернинди дә машина булмаячак.

— Ах, шулаймы?..— Шадра чайкала-чайкала аягына басты, Ризванга таба ыргылды. Аның уң кулында күгәрми торган корычтан ясалган хәнҗәр ялтырап китте.— Табарсың! Таптырырбыз!!

Сунарчин, үзе дә сизмәстән, янындагы урындыкны эләктереп алды...

* * *

Кавказ дөпелдәп идәнгә төшүеннән уянып китте. Һу-у-у, нинди генә яман төшләр керми адәм башына, ниләр белән генә саташмый кеше! Тукта, һәр саташуның реаль чыганагы булырга тиеш бит. Әһә, капы дөпелдәп тәрәз капкачы ябылган икән. Ул эченнән генә сүгенеп алды да кабат урынына менеп ятты. Тик эреп йоклап китә алмады, теге хәерсез тәрәзә капкачы бер ачылып, бер ябылып эчен пошырды, пыялага энә коелгандай итеп сибәләүче вак яңгыр йөрәгенә шом салды. Әллә соң капкачны ябып керергәме? Шулай итсә, берьюлы ике куян ата инде атуын: дөпелдәүдән дә, пыялага яңгыр сибәләүдән дә котыла. Шулай да иренүе җиңде, юрганын башыннан ук томалады. Шулчак вагон кырыенда ук ачыргаланып эт чинап җибәрде, колакка ниндидер тавышлар килгән төсле тоелды...

Чыкты да төнге шәһәрчеккә колак салды. Тын, бар да искечә. Бары тик салкын җил шашына, күчмә йортларның калай түбәләрендә тамчылар биешә. Ашыкмый гына вагон артына чыкты, тәрәзәне ябып, капкачын кадактагы тимерчыбык белән тарттырып куйды. Шулчак конторканың начальник яши торган ягында ут кабынганга игътибар итте, колагына ниндидер тавышлар чалынгандай булды. Теләр-теләмәс кенә ишегалды уртасына узды, туктап тыңлады. Чыннан да, вагонда кемнәрдер сөйләшә иде. «Башлык янына кем килмәс тә кем китмәс»,— дип уйлады Кавказ һәм торагына таба атлады. Шул мәлдә колагына: «У-у-у, падла»,— дип сүгенүләре килеп ишетелде. Тукта, ниндидер хәвеф бар монда! Ул, янә борылып, конторкага таба китте. Эчтә тавышлар көчәйгәч, алга ыргылды, ике сикерүдә вагонның тимер баскычына барып менде.

Ул килеп кергәндә, башын-чәчен туздырган карачкы, баш өстендә пычак тотып, урталыкта басып тора, ә Сунарчин урындык аякларын штык итеп, үзен яклый-яклый, стенага барып терәлгән иде...

— Тукта! Нишлисең? — ул Шадраның кулыннан тотмакчы булып аңа ташланды.

Тегесе һич көтмәгәндә житез булып чыкты, кисәк борылып, пычагы белән кизәнде. Кавказның уң кулбашын утлы кисәү яндырып алгандай булды, беләге буйлап кайнар кан китте...

* * *

Яктырып килгәндә шәһәрчек корт иледәй кайный иде инде. Төзүчеләрнең төрле яңалыкларга, мәзәк яисә аяныч хәлләргә ярлы тормышы бүген берсеннән-берсе хәйран вакыйгалар белән тулы. Ыгы-зыгының уртасында Кавказ иде, әлбәттә. Аның уң кулы ак бүз белән әйбәтләп урап, элмәкләп муенына асылган, авызында папиросның затлысы. Үзенең шактый бай хыялына һәм фантазиясенә төреп, төнге вакыйганы инде дүртенче кат сөйләве...

Аны тыңлап бетермәделәр, каяндыр вагоннар арасыннан үлгән эт күтәреп Сәетнафа килеп чыкты. Баштанаяк канга буялып беткән, үзе еламый гына. Хатын-кызлар әллә этне, әллә Сәетнафаны җәлләп: «Әбәү җаным, харап иткәннәр»,— диешеп, болай да күңелсез ишегалдын кызганыч авазлар белән тутырдылар. Сәетнафа, кулына кирәк алып, этнең гәүдәсен җирләргә киткәч кенә еламсыраган тавышлар басылды, төзүчеләр иркенләп тын алды.

Ләкин бу иртәнең хәерсез яңалыклары болар белән генә бетмәгән икән. Бераздан капкадан колхозның җиңел машинасы килеп керде, тәркем янына килеп туктады. Аннан Зиннур белән участок милиционеры килеп чыкты. Төнлә белән Сазанакның кибетен басканнар икән. Эзләр шәһәрчеккә китергән, имеш. Хәзинәдә булганнан нибары аракы белән тәмәке генә югалуы бу эштә эчкечеләр кулы уйнавын әйтеп тора, ди.

— Алайса, бар да аңлашылды,— диде кунакларны каршы алырга чыккан Ризван.— Җинаятьчеләр минем бүлмәдә әнә...

Милиционер торакка кереп китте, куллары сөлге белән бәйләнгән Шадраны алып чыкты. Аның юлдашын исә берничек тә уята алмадылар. Светлана китереп биргән нашатырь спиртының да файдасы тимәде — егет үлгән кебек йоклый иде.

Шадраны машинага утыртып, милиционер белән Зиннур китеп баргач та халык ишегалдыннан таралмады. Барысының да чырайлары сытык, зиһеннәре таркау иде. Клава түтинең кат-кат ашка дәшүенә дә колак салучы юк, боегъып, оеп калганнар.

Светлана ишегалдына чыгып Кавказга бәйләнә башлады:

— Авыру Виноградов, палатага кереп ятыгыз!

— Менәтерәк, нишләп мин авыру булыйм, ди. Яралы диген.

— Барыбер авыру. Әйдәгез, ятыгыз.

— Юк инде, һәр тырналган өчен крах булып караватта ауный башласаң, кая китә ул? Сөйләмә дә, кермим.

— Керерсең! Бригадир! Мин авыру Виноградовны эштән читләштерәм, аңа покой кирәк.

— Я инде, Света, акыллым, бәйләнмә, тырналды гына ич.

— Авыру язмышы өчен мин җавап бирәм, иптәш Виноградов.

— Ярый, ярый, бетте. Алайса мин, Светлана, үзебезнең вагонда гына ятармын. Бик сагынсаң, пунктыңа үзем килеп китәрмен.

Тагын, бераз тарткалашкач, Кавказ файдасына килештеләр. Ләкин төзүчеләр трассага китәргә җыенганда тагын тавыш купты — Светлана гудронатор кабинасына кереп поскан Кавказны күреп алган иде.

— Монысы ни тагын!.. Ризван Актуганович! — дип кычкырды Света конторкадан чыгып килүче Сунарчинга.— Бу Виноградовыгыз өстеннән докладной язачакмын мин, һич кенә дә тәртипкә буйсынмый.

Ыгы-зыгы басылып, инде кузгалабыз гына дигәндә, тагын бер мәрәкә килеп чыкты — Дания чирләп киткән, имеш. Светлана һич авырсынмый гына ул яшәп торган вагонга йөгерде.

Төзүчеләр трассага чыгып китүгә, шәһәрчек тынып калды. Кавказ исә вагон баскычында моңаеп утырды-утырды да, кереп ятагына ауды. Кулбашы шактый үк сызлауга карамастан, төнге төше башыннан китми иде...

Дыңгырдап ишек ачылды, бүлмәгә Дания килеп керде. Йөзендә елмаю, иреннәре дымлы иде аның.

— И-и, җаным, бик сызлыймы кулың? — диде ул, авызына килгән суны йотып. Караватъ янына батыр гына узды, урындык алып, Кавказ кырыена ук утырды.— Каяле, рәтләп бәйләмәгәндер дә әле чикерткә.

Кавказ дәшмәде, хатынның очкын чәчеп торган дәртле күзләренә карап-карап торды да, кисәк кузгалып, сул кулы белән аның муеныннан кысып алды. «Чү, нишләвең бу?»— дигән булды Дания, үзе тыгыз күкрәкләре белән Кавказның кочагына капланды.

— Тилекәй, ишегеңне бикләр идең ичмасам...

Теге чактагы салкын яңгырдан соң табигать ничектер сүрәнәеп, боегыбрак калды. Инде кая карама, күз галәмәтен сизәргә була: аяк астындагы үләннәр тамырда килеш кибә, корый башлады, хәтта ямь-яшел күрән кылычларының да очлары, утта көйдереп алгандай, көрәнләнде. Әледән-әле явып торган яңгырлар җирне, агачларны, хәтта һаваны дымыктырып шөкатьсезлек арттырды. Болытлар көн саен килеп өсти торгач, ешлыклардагы дымык җирләр генә түгел, басу юллары да үтеп йөргесез пычракка әйләнде. Төзүчеләр инде трассага агач ташый торган тракторларда гына баралар.

Трассаның үзәгендә дә хәлләр мөшкел иде. Траншея су белән тулды, аның як-яклары ишелеп, түшәүлек өстендә эшләүләр хәвефкә әйләнде, һич көтелмәгән туксан тугыз мәшәкать килеп туды, кышкы чордагы кебек хәтта мичне худка җибәрергә туры килде — киптерми, җылытмый гына тимергә битум ябышмый иде. Трассада уен-көлке онытылды, кешеләр тешләкләнде, егетләрнең сакал-мыек баскан йөзләре сулып, күзләре эчкә батты. Шулай да эш тукталмады, аз гына яңгыр сүрелүгә, колонна гайрәтле үкереп алга кузгала. Бата-чума ярты сәгать эшләргә өлгермиләр, тагын яңгыр килеп баса, янә будкага кереп бөялергә, көн буе ягудан өсте бурлат булып чыккан тимер мич янында киемнәрне киптерергә, боегуны белмәүче бердәнбер кеше — Кавказның чираттагы хикәятен тыңларга кала. Болыт ертыклары арасында кояш күренүгә, төзүчеләр кабат машиналарына ташланалар.

Шулай изалана торгач, баткаклы урман да артта калды, инде саламы җыелып, туңга сөрелгән басу буйлап та шактый юл үттеләр. Бүген колонна Яман елгага килеп төртелде. Аны гадәттәгечә генә үтеп булмый. Торба салгычларны «туарырга», елганың теге ягына чыккач янә «җигәргә», ә торбаның ике яр арасында асылынып калган өлешен кулдан биләүләргә кала. Табигать исә, әйтерсең, аларның шушы Яман елгага җитүләрен генә көткән, бүген тагын күк йөзен болыт тартты, яңгыр утырып, үзенә бер күңелсез көй белән яварга тотынды. Тукта басылмасмы, тукта ачылып китмәсме дип, будкада утырдылар-утырдылар да, эш сәгате тәмамланганчы ук, тракторга төялеп кайтырга чыктылар.

Җылы өйдә, өсләренә коры киемнәр киеп алгач, кәефләре ярыйсы гына үзгәрде. Алай да шәһәрчектә җәйге матур көннәрдәге җанлылык: чыркылдау, ыгы-зыгы, көлешү ишетелми иде. Көзге чебешләр сыман ашханәдә тамакларын сүлпән генә туйдырып кайттылар да һәркайсы җаны теләгән шөгыленә ябышты.

Беркетовлар торагында, кич җиттеме, җәен-кышын бер үк күренеш: Шәхсәнәм тегү машинасы янына утыра, ситсылар белән әвәрә килә башлый. Сыртлан, караватына ятып, чираттагы китапның вакыйгаларына, андагы язмышлар эчендә эри. Алай да кич саен булып ала торган сүзләрен онытмыйлар. Шәхсәнәм, энә-җепләре белән мавыгып утыра-утыра да, тәмам ялыккач, эшеннән туктап, әллә инде мең дә беренче кат:

— Сиңа әйтәм, шушы трассаны гына бетерик тә ташлыйк инде бу чегән тормышын,— дип куя.

— Ярый, ташларбыз,— ди Сыртлан, китабыннан аерылмый гына.

Шуннан да күңеле була Шәхсәнәмнең, капка төбенә туе төшкән кыз сыман, ярсып-ярсып машинасын әйләндерергә тотына.

Кавказ нишләптер кич саен баянын кычкырткаларга тотынды. Шуны шыгырт-быгырт китереп бераз юана да, кеше аягы тынуга, Дания янына кереп югала. Хәер, бер-беренә булган мөнәсәбәтләрен, араларындагы якынлыкны трассачылардан яшерми дә алар. Рәсми рәвештә бергә яши башлау өчен туй буласын көтәләр. Туйны исә эттем-төрттем генә үткәрергә түгел исәпләре. «Эшне бетереп, Зәйсуга кайткач, бөтен Татарстанга яңгырарлык итеп ясыйбыз аны»,— дип мактана Дания.

Шаяз, кәефе ярыйсы булганда, кызыл почмакка барып телевизор каршына утыра. Тапшырулар тәртибен белешеп, аның белән кызыксынып тормый, ни күрсәтсәләр, шуны йотлыгып, ихлас күңелдән карый. Һәрхәлдә, «Вакыт» программасын, илебездәге яңалыкларны, дөнья хәлләрен ишетми торып, урыныннан кузгалмый. Инде эшеннән арыбрак кайтса, кәефе кырылганрак чак булса, ятагына авып, транзисторлы радиоалгычын кабызып җибәрә. Аны боргалый-боргалый эфирдан таныш тавышны — Казан дикторы тавышын эзли, инде татарча концертка да тап булса, дөньясын оныта иде.

Бүген дә ул, ашханәдән кайтуга, радиоалгычын тотып караватына ятты, маташа торгач «Маяк»ны тотты. Анда төрле милләт җырларыннан төзелгән концерт бара иде. Тик бүген аңа гадәтенчә хозурланып тыңларга туры килмәде, бүлмәгә атылып Светлана керде.

— Шаяз Рамаевич, сезгә хат,— диде ул, һәм ятып торган ялгыз ир-ат янында тералеп торасы килмәде бугай, бригадирның кулына почмаклары яньчелеп беткән конверт тоттырды да чыгып китте. Җәмәгать эше тәртибендә хат ташучы вазифасын да үти иде Светлана.

Сәерсенеп кенә конверттагы адреска күз төшерде. Һич көтелмәгән бу хат Зәйсудан, Нурлыдан иде. «Вәт, картайганда — тыртайган»,— дип куйды Шаяз үзалдына. Чөнки әлегә кадәр алар арасында, гомумән трассачылар арасында хат язышу гадәте юк иде. Күпме трассаларда йөреп, үзе язганны да, Нурлыдан хат алганны да хәтерләми. Шәһәрчеккә әледән-әле идарәдән килеп-китеп торалар, кирәк кеше йомышын я телдән әйтеп җибәрә, я язмача шулар аша житкерә иде. Менә шуңа да хат алуына шатланмады Шаяз, каударланып конвертны ертты да, эченә бөкләп-бөкләп салган дәфтәр битләрен тартып чыгарды.

«Шаяз!

Теге чакны байлар утырып йөри торган фәйтүн чаклы бәби арбасы күтәреп кайтуыңа бик ачуым килгән ие. Аннан соң да, Бәдрә белән урамга чыккан саен, сине тиргәдем, үзең ишетмәсәң дә, сине сүктем. Юкка тузынганмын, юкка чәпчегәнмен икән, жаным. Би-и-ик кирәк булыр ахры ул чыдам, иркен коляска. Себер жирена, Себер һавасына рәхмәт инде... Кыскасы, мин буйга узганмын...»

Менә сиңа мә — иске авыздан яңа сүз! Шаяз укуыннан туктап торып аягына басканын сизми дә калды. Тукта, нәрсә яза бу җүләр баш? Бала дип йөри-йөри, акылына җиңеллек килгән мәллә моның? Хыялындагын язып ятамы? Әллә инде ирен шаяртырга, көнләштерергә уйлыймы? Каян килеп буйга узсын ди ул? Булмаган курорты, күренмәгән врачы калмады, профессорга кадәр житте, әллә ниткән дарулар эчте, Шаязга әйтми генә карчыкларга да күренде бугай. Шуннан соң да бала тапмый йөрсен дә — мә сиңа, буйга узган, имеш. Юк, ниндидер хата бар монда. Тукта, тагын ни яза икән?..

«Чын менә. Башта үзем дә ышанмаган идем. Булмас, дип врачка да күренми йөрдем. Ә ул көннән-көн ныграк сиздерә үзен. «Мин бар, мине сизәсеңме»,— дип тибенә-тыпырчына сыман. Иң беренче тапкырында, гажәп тә, сәер дә булды, Шаяз. Бер сәбәпсез төн уртасында уянып киттем. Тыңлап ятам, шылт иткән тавыш юк. Бәдрә тынычсызланмый, авырткан-чәнечкән җирем дә сизелми. Кинәт йөрәгем астында гына, суда йөзеп киткән балыктай, нидер хәрәкәтләнгәндәй булды. Шатлыгымнан кычкырып җибәрә яздым. Тик шуннан бар да тынды. Кабатланмасмы дип, көтеп яттым-яттым да, башкача сизелмәгәч, юрган почмагын тешләп бик озак еладым. Ике-өч көннән әлеге хәл тагын кабатланды. Куанычымнан күләргә дә, еларга да белми байтак йөргәч, үзебезнең акушерка янына бардым... Себер җирена рәхмәт инде — аның бүләге бу, Шаяз!

Ә Бәдрә шундый үсте, кайткач танымассың да әле. Ул инде бөтен дөньяны бетереп үрмәли. Шундый ташбаш, теге син алып кайткан уенчыкларны ватып, тимер тавы итеп өеп куйды. Инде ике тәрилкәне, дүрт чәшкене бәреп төшерде. Курчаклар алып биргән идем, һич иплап

тотмый, чәчләреннән сөйри. Җыйган урын тормый, бөтен өйнең астын өскә китереп бетерә. Шундый кызык. Кайт, бергәләп тагын да күңеллерәк булыр».

Укып бетергәч, Шаяз бер мәл авызын җыеп алалмый торды, кинәт кенә Нурлысы бик якын булып китте аңа. Курчакларын чәчләреннән сөйрәп, бөтен өйне бетереп үрмәләгән кызы күз алдына килеп басты, кайтасы килеп, йөрәге сулкылдап куйды. Аннан кисәк кенә Бөдрә дә, өе дә онытылды, миенә хатынының башта язган сүзләре хуҗа булды. Чырае сытылды, үпкәләгән баланыкыдай, ирене салынды. «Менә сиңа номер!»— дип уфтанды ул, һаман да хатыны турында уйлап. Нәрсә була инде бу? Чынлап та авырлымы, әллә шаярта гынамы? Туктале, озак еллар ир белән торып та бала китермәгән хатынның тугыз-ун елдан соң авырга калу очраклары бар микән? Әллә соң Светланадан сораргамы? Кит, тиле, хәбәре иртәгә үк бөтен бригадага таралып, күзеңне ачырмаслар. Болай да ишетәселәре бар әле бу башкайларның!

Ул, майкасы өстеннән генә сырма киеп, аягына җәйге ботинкаларын элде дә Анатолийларга китте. Яшьләр, кызларын йоклатып, икесе өстәлнең ике башында китап укып утыралар иде.

— Аз гына консультация кирәк иде, Светлана,— дип башлады ул сүзен.— Бер китап укып ятам... Тугыз ел ир белән яшәп тә бала тапмаган бер хатын кисәк кенә авырга кала...

— Нигә? Андый хәлләр була,— диде Светлана, табын әзерли башлап,— хәтта өметсез дип саналган хатыннарның бала табу очраклары да билгеле медицинада. Әйдә, утырышыгыз әле.

Өметсез дип саналганнар да тапкан диме? Шаязның күңеле күтәрелде, ирен читенә елмаю чыкты. Өс-башын алыштырып, телевизор карарга барыйм булмаса дип, өенә керсә, анда аны Сунарчин көтеп утыра иде.

— Эшләр шәп түгел бит, бригадир,— дип каршылады аны агым начальнигы, гадәтенчә йомшак эндәшеп.— Нишлибез?

— Нишлибез дип... Шулай җәфаланабыз инде. Беренчесе дә, соңгысы да түгел лә. Гел коеп тормас әле, туктар.

— Яңгырны әйтмим лә мин.— Ризван кесәсеннән бер төргәк кәгазь чыгарды.— Иртәгә теге Шадра белән Альбертка суд — барыбызны да диярлек чакыралар менә. Дөрес, безнең үтенеч буенча Сазанакка килеп, авыл клубында ясаячаклар. Барырга якын да анысы. Барыбер көн узачак бит.

— Нихәл итмәк кирәк. Бармый ярамый. Бригадага ял игълан итәрбез.

— Анысы ярый. Тик мин икенче нәрсә уйлап торам әле. Суд барган арада күпернең өрлекләрен куйсак, ә?

— Белмим шул. Кешеләр бик талчыкты. Артык бөгеп, сындырып җибәрмәгәек.

— Анысы да бар...

Беравык сүзсез утырдылар. Шаяз каш астыннан гына Ризванның тартылып, каралып киткән йөзенә, уйчан күзләренә карап алды. Бу тыныч һәм юаш кешенең фаҗигасен белә иде ул. «Акланырга йөриме, әллә йөрәге шундый кылбырдыкмы?»— дигән уй үтте аның башыннан. «Хәер, ничек кенә булса да, барыбер түгелмени? Кеше изге эш хакында борчыла икән, аны битәрләргә түгел, кулыңнан килгәнчә ярдәм итәргә кирәк».

— Алай да егетләр белән сөйләшеп карыйм әле мин...

Иртән шәһәрчек уянганда да яңгыр ява иде әле. Бераздан Сунарчин янына Шаяз килеп керде. Аның тупас брезент плащы чыланырга өлгергән, идәнгә тияр-тимәс торган чабуларыннан тамчы тама иде.

— Нәрсә, кузгалабызмы, Ризван абый?! Егетләр каршы түгел алай,

бер Мәүлетбай гына дөньясын, алласын селкеп ташлады.

— Үзенә әйт: бармасын Мәүлетбай. Хатын-кызлар да судка чакырылмаган. Теләге булмаганнарның кирәге юк. Тик һаман ява бит әле, Шаяз. Әллә соң башка чакка калдырыйкмы?

— Һәй, яуганда да селкенмәсәң, кайчан эшлисең ди ул күперне? Самый көне инде: жыры да, көе дә килгән моның.

— Шулай дисеңме? Алайса, менә болай итик без, Шаяз. Үзебез Клименков янына барып, кирәк нәрсәләрне төйик, Сыртлан белән Кавказ торба салгычларны Сазанакка куа торсыннар.

...Алар авылга килеп житкәндә, торба салгычлар анда иде инде. Судьялар әле күренми, бу яуганда судның булуы да икеле иде. Вакытны сузмаска, шунда ук эшкә тотынырга булдылар. Хәзергә бар да хәерлегә сыман, көн ачылыбрак китте. Шулай да яңгыр сибәли иде әле. Әмма бу инде тоташтан коеп тору түгел, чамалап кына эшләргә, һич югы күпернең кысасын жыярга мөмкин иде.

Һәр нәрсәне алдан ук үлчәп, әзерләп куюның файдасы тиде — ике сәгать тә узмагандыр, бульдозер ике як ярны да кисеп, нигез ясады, анда тимер-бетон плитәләр менеп ятты. Тик бар да син дигәнчә генә бармый шул. Сварщик өрлекләрне бер-беренә беркетеп маташкан арада, авылга хәбәр килеп төште. Судьялар белән гаепләнүчеләр станциягә поезд белән килгәннәр икән. Аларны каршы алырга машина чыгып китте.

Ул арада булачак күпер янында сазанаклылар күренгәли башлады. Әүвәл, тынына каплана-каплана, Ташбулат карт килеп житте. Торбаларны үзе күтәреп куярдай булып, бер тегеләйгә, бер болайга чабулап йөрде.

Бераздан авылга машиналар кайтып төште. Алар, суы шактый күтәрелергә өлгергән Яман елганы кичтеләр дә, клуб янына килеп туктадылар. Халык шунда авышты, күпер янында аз калдылар. Әмма эш тукталмады, агрегатлар туры торбаларны күтәрә башлады.

Ризван белән Зиннур сөйләшеп куйганнар, күрәсең: шаһитларга судта даими утырырга туры килмәде. Алар, бушаган араларында, күпердә эшли тордылар, бер кереп, бер чыгып, клубка пычрак ташыдылар. Судья гына:

— Суд түгел, проходной двор бу,— дип зарлангалап алды.

Шулай икегә бүленсәләр бүленделәр, әмма елга өстендә эшне туктатмадылар. Суд та үз жаена барды. Председатель боерык биреп өлгергән бугай, төш житкәндә ферма ягыннан бүрәнәләр тарткан ике трактор килеп туктады, шуны гына көткән кебек, кулларына балта-пычкы тоткан колхозчылар жыела башлады. Алар килә-килешкә агач каезларга тотындылар.

Клуб залында исә кеше язмышы өчен көрәш бара иде. Дөрес, Шадраның инде жыры жырланган, аны юньләп яклаучы да күренми. Сүз күбрәк үсмер Альберт тирәсендә бара. Төзүчеләр коллективыннан жәмәгать яклаучысы булып килгән Клименков, эш кешесенә хас булганча, бастырып кына, нык лы дәлилләр белән сөйли иде.

Суд кичке эңгер-меңгергә кадәр сузылды. Карарны укыганда клубта ут алынган иде инде.

*Ахыры бар*

*1 июнь — Балаларны халыкара яклау көне*

**Роза Хафизова**

## КҮҢЕЛЛЕ МИЗГЕЛ

Кинәт нидер булды. Таудай «КамАЗ» машинасы җир селкетеп барган җиреннән шып туктап калды. Аның уң ягына көяз «Жигули», саллы «Волга» килеп терәлде. Асфальт юлдан җилдәй йөгерүче башка машиналар да, «ни булды тагын», дигән кебек, тормоз-тешләрен шыгырдатып туктый торды. Урамда хәрәкәт тынды. Арткы рәттәге шоферлар, тукталышның сәбәбен ачыкларга теләп, кабинадан башларын сузып, үрелеп-үрелеп алга карады. Аларның кырыс йөзләрен шундук елмаю балкытты: урам аша сабыйлар төркеме уза иде. Төркемнең алдында кызыл бантиклы нәни генә кызчык, кулындагы флагчыгын селкеп, машиналарга туктарга боера. Флагчыкның, әйтерсең лә, теле бар: «Туктагыз, туктагыз, без киләбез, балалар килә»,— дип җилферди кебек.

Сабыйлар исә урамга сибелгән күбәләкләргә охшап тора: чибәртазалар, гөл кебек киенгәннәр. Саф янәшәсеннән ак халатлы тәрбияче кыз атлый. Ул машиналар ягына әледән-әле борылып карап ала һәм, колачын җәеп, балаларны ашыктыра. Кулга-кул тотынышкан малайлар, кызлар шау-гөр килеп урам аша уза. Якында гына курчак театры. Спектакль карарга баралар булыр. Ләкин бу минутта малайларны алдына болан сурәте беркетелгән «КамАЗ» машинасы күбрәк кызыксындыра. Озаграк тукталып күзәтергә дә риза алар. Җитәкләшеп килгән кызчыклар гына ирек бирми, ашыктыралар, кулларыннан тарталар. Кызчыкларга машиналар әллә бар, әллә юк — исләре китми. Аларны урамның каршы ягындагы түтәлдә үскән чәчәкләр ымсындыра.

Күктә кояш елмая. Урамда гөлләр чәчәк ата. Тормышыбызның гадәти бер мизгеле. Туктагыз, тын калыгыз: урамнан сабыйлар уза.

## БАТЫРЛЫК

Көн уртасы. Күрше авылга барган җиремнән арып, юлдан читкәрәк чыктым да киң ябалдашлы каен төбенә ял итәргә утырдым. Урман эчендәге тынлыкка, аллы-гөлле чәчәкләргә, яшеллеккә сокланып тирә-ягыма карарга өлгермәдем, кинәт баш очымда бер кошчык чыркылдап җибәрде. Шәүлегән! Түше сап-сары, канатлары кап-кара. Ата кош. Ана шәүлегәннең каурыйларында аксыл-яшькелт төсләр дә була. Ул нәкъ минем баш өстендә бер юан ботакка кунган да йоннарын кабартып, канатларын җилпи-җилпи түбән карап, ачулы чыркылдый. Миңа карап чыркылдый. Син нәрсә, кошчык, ник миңа ачуланасың, сиңа тимим ич, әз генә ял итәм дә китәм,— дигән булам. Кошчык исә ялт кына түбәнрәк ботакка төшеп кунды да, баягыдан битәр чыркылдап, ачыктан-ачык тиргәргә тотынды.

Агач төбеннән куа иде ул мине. Хәтерем калды. Ярый, мин әйтәм, урманга сыймыйсың икән, читкәрәк китим соң. Янәшәдәге агач төбенә күчеп утыруым булды, кошчыгым шуны гына көткән икән, томырылып

каядыр очты. Бераздан ул томшыгына җим кыстырып әйләнеп тә кайтты. Әнә, аңлашылды, каен ботагында ояң бар, күрәсең, әнкә кошың йомырка баскандыр. Батыр кошчык икәнсең, кешe хәтле кешене оян янынннан куарга көч таптың. Батырлыгың өстенә түземлек, сабырлык телим. Нәниләрегезне парлап үстерегез, табигать сезне хәвеф-хәтәрдән сакласын!

## Равил Вәлиев

# УЛЫМ ХИКӘЯЛӘРЕ

### Табадан качкан май

Ял көнне Раушан белән качышлы уйнадык. Күзгә озын сөлгe бәйләдек тә, кулларны сукыр кеше сыман алга суза-суза, бер-беребезне тотып алырга тырышабыз.

Шулай байтак куышып аргач, тамак ялгарга теләп, тәмле ис килгән кухняга кердек. Менә әнисе кайнар табага Раушанның йодрыгы кадәрле ак май кисәге салды да, ниндидер ашыгыч йомыш табып, бүтән бүлмәгә чыгып китте.

Раушан табада эрегән майга озак кына текәлеп карап торды. Һәм бераздан, исе китеп, кычкырып җибәрде:

— Әти, дим, әти!

— Әү, улым?

— Табадан май качты!

### Хикмәтле ипи

Көтмәгәндә Раушанның температурасы күтәрелеп китте. Әбисе биргән сәдәф даруны эчәр иде — тәмсез!

Авыру оныгына дару эчертеп булмагач, әбисе хәйләгә кереште. Ак сәдәфне ул яшереп кенә, ипи йомшагына батырды да, өстенә балмай ягып, Раушанга бирде.

Ләкин әбисенең хәйләсе тиз ачылды.

— Икенче ипи бирче, дәү әни!— диде Раушан, дару сәдәфе авырттырган тешләрен тотып.

— Нигә, бәбкәм?

— Бусының сөяге бар!

### Хәрби бәрәңге

Әбисенең төрле белешмәләр салынган букчасын карап утыра идек. Шундагы кәгазьләр арасыннан кайчандыр мин хәрби хезмәттән җибәргән бер фото килеп чыкты. Раушан аңа озак кына карап торды да:

— Әти, син мәллә бу?— дип куйды.

— Әйе, солдат әтиең, улым! Әнә күрдеңме мундирын?

— Аны кемнәр кия, әти?

— Хәрбиләр.

— Кайчан?

— Парадка чыкканда, кунакка кайтканда...

Бераздан әбисе безнең алга мичтә тәгәрәтеп пешерелгән бәрәңге китереп куйды:

— Ашагыз — мундирлы бәрәңге! Читтә яшәгәч, авыл бәрәңгесен бик сагынгансыздыр.

Сагынмаган кая инде ул!

Хәтта Раушан булып Раушан да, соклануын белдереп:

— Аһ, дәү әни хәрби бәрәңге пешергән!— дип куйды.

## Паганини һәм әни

Әнисенең туган көне иде. Бүген ул ял гына итәргә тиеш!

Раушан белән икәү, иртүк торып, идән юдык. Аннары, тәмле коймак пешерү өчен, кухняга кереп киттек.

Хәер, киттек үк дисәк, бик дөрес булып бетмәс! Раушан зал ягында тыныч кына телевизор карап утырган әнисе белән кухня арасында йөреп торды:

— Әни, коймакка майны күпме салыйк?

— Әни, коймакны табадан кайчан алыйк?..

Өчебезнең дә кәеф шәп! Өй чиста! Табада, тәмле исе белән борыннарны кытыклап, коймак пешә!

Менә мин кухня стенасындагы радионы борып җибәрдем. Бөек итальян композиторы Никколо Паганини музыкасын тапшыралар иде. Дикторның телендә гел Паганини да Паганини! Бүген аның да туган көне икән.

Моны ишетеп җиткермичә, Раушан әйтеп куйды:

— Нигә минем әнием турында да сөйләмиләр? Аның да туган көне ич, әти?

## Арадашчы

Тормыш булгач, савыт-саба шалтырамый тормый икән!

Беркөнне әнисе белән юктан гына үпкәләштек тә Раушан аша «сөйләшергә» тотындык. Әйтик, иртән ул малайны кочагына алып сөя дә:

— Улым, бүген әниеңнең профком җыелышы!— дип, тыныч күңел белән эшкә чыгып китә.

«Профком»ның нәрсә икәнлеген, әлбәттә, кечкенә Раушан белми. Димәк, бүген кич аны бакчадан тагын әтисенә алырга туры киләчәк!

Икенче көнне инде мин:

— Улым, бүген әтиең дружинада йөриячәк!— дип эшкә чыгып китәм.

Дружинаның нәрсә икәнлеген бәләкәй Раушан әле кайдан белсен! Димәк, бүген кич малайны бакчадан әнисе алып кайтачак!

Мондый аңлашулар еш кабатлана башлагач, «күз бәйләш» уенына Раушан да ияләшеп житте. Башта аңа «телсез» әти-әнисе арасында йөрү шактый кызыклы булды. Ләкин бераздан ул да әлеге «уен»нан туеп өлгерде.

Ял көнне Раушан минем бүлмәгә керде дә:

— Әти дим... Борыным кычыта, бар, шуны әнигә әйтеп кил әле!— диде.

— Борының кычыткач, бәлки, үзеңә әйтергәдер?— дип котылмакчы булдым мин.— Күчтәнәчләр төяп, дәү әниең киләседер, улым!

Ләкин бу юлы Раушанга «күчтәнәч» сүзе дә тәэсир итмәде:

— Әйем... Мин инде күптән әйттем — хәзер син әйт!— диде ул, күзләрен мөлдерәтеп.

Бу мизгелдә аның юеш керфекләренә ике көмеш тамчы кунган иде.

# Хәкимҗан Халиков

## Куркактан курыккан

Курка шул бер курыккан.
Куркак куян бер дә юктан,
Каптырыр дип колактан,
Курыккан, ди, куактан.
Коты очып шул куяннан,
Суга чумган да бака,
«Котылдым!» — дип куанган.

## Колак каккан

Бер куянның төпчек улы
Йөри торгач кызык тапкан:
Йоклап яткан карт бүренең
Колагыннан тешләп тарткан.
Һәм шул чакта... үзенең ул
Колагыннан колак каккан.

## Кем кемне ничек таный

Бүре — бүрене
Улаудан таный.
Елак — елакны
Елаудан таный.

Маэмай — маэмайны
Өрүдән таный.
Ялкау — ялкауны
Йөрүдән таный.

Чәчәк — чәчәкне
Исеннән таный...
Кеше — кешене
Эшеннән таный!

## Азагына җиткерә

Әни гел тукып тора:
— Ничек итсәң иттер,— ди.—
Бер башлаган эшеңне
Азагына җиткер,— ди.

— Мин,— ди энем,— эшемне
Азагына җиткерәм:
Җиләк җыйсам бакчада...
Шундук ашап бетерәм.

# Рәшит Бәшәр

## Картайган ат

Тешләре булмаса да
Ул солы ашый иде,
Мичкә белән елгадан
Суын да ташый иде.

Кояш астында бераз
Утласын димәделәр,
Машинага «утыртып»,
Каядыр җибәрделәр...

Болынга чаба Акбай,
Иптәшсез нишләр инде?
(Сагынудан арба да
Ат булып кешнәр инде.)

Өзелеп карый юлга,
Берүзенә күңелсез.
Атны эзләп офыкка
Чабып китәр, күрерсез.

## Яшисе килә

Ракета очып төшсә,
Җирнең йөрәген тишсә?!

Су буенда чапкан колынның
Зур ат булып кешнисе килә.

Кабара болыт. Болытның да
Яшен булып яшьнисе килә.

Безнең дә һич үләсе килми,
Бик оза-ак яшисе килә.

Гөлдер-гөлдер кошлар сөйләшә...
Ә ракета яши янәшә.

Сугышның да үләсе килми!

# Рафис Корбанов

## Ташбака

Ташбаканы кызганам мин,
Ярдәм итәр идем дә...
Үз өен һаман күтәреп
Йөртә мескен иңендә.

Бер явызы алып китә
Күрмәсен тагын диеп,
Күтәреп кенә йөртәдер
Шулай, мөгаен, өен.

Ташын кемгәдер бик кирәк
Диеп беләдер инде?
Һәркемгә өй кадерле шул,—
Шуңа күрәдер инде...

Ташбаканың хәлен белдем,
Башкалар да аңлыйдыр,—
Өен күтәреп йөргәнгә
Кызу йөри алмыйдыр.

## Күргәнем бар...

Керпе таякка таянып
Йөри гел мультфильмдә,
Урманда чып-чын керпене
Күргәнем бар минем дә.

Таяксыз да бик шәп йөри,
Кәрзинен дә күрмәссең...
Ләкин менә җилкәсенә
Кем салгандыр гөмбәсен?..

## Пумала

Нәрсә булган пумалага,
Чәче тузган, битендә —
Буяу табы. Аунап ята
Идәннең бер читендә.

Нәрсә булсын, аны кичә,
Ясаганнан соң рәсем,
Юындырып та тормыйча
Ташлаган шунда Рәсим.

Бик кызганыч булды миңа...
Пумала түгел, Рәсим.
Беркайчан да яхшы рәссам
Чыкмас аннан, күрәсең.



*Без бу санда шагыйрь Фатих Кәримнең матбугатта чыкмаган шигырен тәкъдим итәбез.*

*Ф. Кәрим, шәхес культы чорында, 1937—1941 елларда төрмәдә утыра һәм Бөек Ватан сугышына да шуннан китә. Тәкъдим ителә торган шигырьдә сүз, күрәсең, Ф. Кәримнең төрмәдә Хәсән Туфан белән очрашуы турында бара.*

*Шигырьне редакциягә өлкән шагыйребез Салих ага Баттал китерде; ул аны сугыштан соң, Миславский урамындагы 8 йорт, 28 квартирада авторның куен дәфтәреннән күчереп алган.*

# Фатих Кәрим

## Онытма!

Яшь ягыннан абый син булсаң да,
ристанлыкта абый мин идем,
шуңар ахры, моң-зар, нәфрәт уты
һәм әрсезлек миндә күп иде.

Иске-москы салган капчык асып,
төрмәләрдә байтак сөйрәлдек.
Катлы-катлы вә тәшдитле итеп
сүгенергә яхшук өйрәндек.

Ристанлыкта телгә йоккан сүзләр
ихтыярсыз җырда чагыла.
Укучы да гаеп итмәс моны,
тик елмаер дусларча гына.

Үткәннәрнең авыр шәүләләре
сиңа һич тә тансык түгелдер.
Ләкин алар кыргый бер көч белән
кузгаттылар минем күңелне.

Ничек онытыйм кремль буендагы
Пугачевлар яткан төрмәне!
Юк, онытмыйм тынчу камерада
сулар һава тапмый йөргәнне.

Хәтреңдәме, чакырып алдың мине
ишек тупсасына таянып? —
Ишек ярыгыннан томаланып кергән
бәдрәф исе катыш һаваны,

балык кебек, авызларны ачып,
алмаш-тилмәш икәү суладык,
хәлгә килгәч, ак болытлар йөзгән
күккә карап, төшләр юрадык...

Сәламәне салындырып йөреп
куандырмадык без дошманны;
балык кылчыгыннан инә ясап
ямый идек күлмәк-ыштанны...

Күпме — илле грамм килер-килмәс
күксеп беткән ипи кисәген
хыянәтсез кап-урталай бүлеп
ашаганнар синең истәме?

Исеңдәме көзге кабер кебек
карцерларда бергә утыру;
хаксызлыкка нәфрәт игълан итеп,
ун-унбиш көн буе ач тору?

Белүчеләр әле дә сагынып сөйли
ул чактагы безнең дуслыкны,
дуслык белән чөнки тутыра идек
тормыштагы бөтен бушлыкны.

Бүген менә ялгыз кремль буйлап
үткән чакта башны күтәрсәм,—
сөремләнеп тора таныш төрмә...
Кабынып китте бөтен үткәннәр...

Үткәннәрнең авыр шәүләләре
сиңа бүген тансык түгелдер,
ләкин алар кыргый бер көч белән
кузгаттылар минем күңелне...

Гази Кашшаф

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ ЯКЫН ДУСТЫ

Бөек кеше! Совет әдәбиятының күренекле вәкиле, гадәттән тыш акыллы һәм тыйнак, олы җанлы Александр Фадеевны нәкъ әнә шундый сүзләр белән атыйсым килә.

Барлык китап укучылар шикелле үк, мин дә аның белән иң элек «Тар-мар» романы аша таныштым. Әсәр үзенең кырыс хакыйкате белән җанымны тетрәтте, Ерак Көнчыгыштагы партизаннар каһарманлыгына яңача карый башларга мәҗбүр итте. Шуннан соң Фадеев каләменнән чыккан бер генә юлны да калдырмый укый башладым. Һәм шулай итеп, башка яшь язучылар шикелле, үзем дә сизмәстән аның иҗатына баш иючеләрнең берсенә әйләндем.

Студент елларыннан ук аның белән мавыга башлавымның тагын бер сере бар: Гадел Кутуй һәм Муса Җәлил Фадеев турында тирән бер мәхәббәт белән сөйлиләр иде. РАПП оештырылган елларда Муса Җәлил РАППта һәм МАППта Фадеев белән бергә, секретарь буларак эшләгән кеше иде. Соңрак мин Фадеевның яшьләргә генә түгел, өлкән буын кешеләренә дә якын һәм кадерле булуын белдем. Галимҗан Ибраһимов, мәсәлән, рус язучылары арасыннан аны аеруча якын күргән, хөрмәт иткән. Фадеев белән берничә тапкыр татар әдәбияты хакында сөйләшкән, фикер алышкан Кави Нәҗми дә аның турында сокланып сөйли иде. 1941 елның дәһшәтле айларында олуг язучы янында берничә тапкыр кунакта булган Таҗи Гыйззәт аның гадилеге, эчкерсезлеге турында таң калып искә алды. Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир һәм башка язучыларыбыз да Фадеев турында күңелләрендә иң җылы хатирәләр саклыйлар.

Озын, төз буйлы, зәңгәр күзле бу мәһабәт кеше белән очрашулар һәм әңгәмәләр миндә дә онытылмаслык, рухландыргыч тәэсир калдырды. Үз гомеремдә әдип белән эш һәм иҗат мәсьәләләре буенча да күп тапкырлар очрашырга туры килде. Төрле киңәшмәләр турында әйтеп тә тормыйм. Аларда һәрвакыт диярлек Фадеевның акыллы, эчтәлекле чыгышлары яңгырый иде. Миндә шул вакытларда «Горькийдан кала Фадеев иң олы шәхес» дигән тирән ышану туып өлгерде. Дәрәҗәле язучы, киң колачлы эшлекле булу белән бергә, ул һәркем белән уртак тел таба торган гади кеше дә булып кала белде, шуңа күрә дә абруе чиксез зур иде.

Фадеев — күпмилләтле совет әдәбиятының юл башында торучыларыннан берсе. Ул Советлар Союзы халыклары әдәбиятларының барлык классикларын һәм танылган язучыларын анкета мәгълүматлары буенча гына түгел, ә аларның китаплары буенча белә иде.

1939 ел иде. Муса Җәлил һәм кайбер башка иптәшләр миңа Фадеев янына керергә һәм Татарстандагы, нәшрияттагы һәм газеталардагы хәл турында сөйләшергә киңәш иттеләр. Язучылар союзының кабул итү бүлмәсенә килеп кергәндә, анда утызлап кеше көтеп утыра иде инде. Аларның һәркайсы үзе турында хәбәр итүне, Александр Александровичка иң беренче чиратта аның белән сөйләшергә кирәклеге турында әйтә. Секретарь боларның барысын да житкерәчәген әйтеп кабинетка кереп китте һәм аннан чыгуга Фадеевның иң элек ерактан килгән кешене кабул итәчәген белдерде.

Әнә шулай, көтмәгәндә мин Фадеев янына килеп кердем, тормышымда бик күп нәрсәләрне үзгәртәчәк әңгәмәбез башланып китте.

1939 елның октябрендә Әрмәнстанда әрмән халык эпосы «Давид Сасунский»ның 1000 еллыгы билгеләп үтелде. Татарстаннан бу бәйрәмгә Хәсән Туфан белән икәү бардык. Фадеев инде Ереванда иде. Кунакханә вестибюлендә керүгә беренче очраган кеше Фадеев булды, ул мине иске танышын очраткандай, ягымлы елмаеп каршы алды һәм:

— Ә, Кашшаф иптәш килгән,— дип кулын сузды.

Безнең беренче очрашуыбыз май аенда булган иде. Аннан бирле инде берничә ай вакыт узган, тагын ничәмә-ничә кешене кабул иткән булуына карамастан, ул мине һәм фамилиямне дә яхшы хәтерли иде. Тантана көннәрендә безгә берничә тапкыр күрешергә туры килде. Үтенечем буенча ул мине кунакханәдәге бүлмәсендә дә кабул итте һәм мин аннан матур әдәбият бастырып чыгару өчен Татарстанга кәгазь фонды бирүдә ярдәм итүне үтендем.

* Татар телендә беренче тапкыр басыла.

Бөек Ватан сугышы елларында, 1941 елның октябрендә, илебез башкаласы Мәскәү дәһшәтле көннәр кичергәндә рус һәм чит илләрнең антифашист язучылары Казанга эвакуацияләнде. Алар вакытлыча Тукай клубында, Язучылар союзы һәм журнал редакциясе бүлмәләрендә урнаштырылды. Татар язучылары алар белән соңгы кыерчык икмәккә кадәр бүлеште, болай да әллә ни иркен булмаган квартираларында тыгызланып, аларны фатирга алды. Ләкин болар гына җитми иде...

Ниһаять, Мәскәүдән Фадеев килеп төште. Ноябрьләр тирәсе иде бугай. Александр Александрович хәрби формадан, яшел петлицаларында эмаль ромбиклары ялтырап тора. Ул вакытта мин парторг идем, шунлыктан, Фадеев миңа мөрәҗәгать итеп:

— Бөтенесен дә җентекләп сөйләгез,— дип сүз башлады.— «Безнекеләр» һәм «сезнекеләр» ничек яши?

Бик озак сөйләшеп утырдык. Ул эвакуацияләнгән һәрбер язучы, фронтларда сугышучы һәрбер татар язучысы турында мөмкин кадәр тулырак сөйләвемне үтенде, ул чакта больницада яткан Лебедев-Кумач турында аеруча кайгыртучанлык күрсәтте.

Килгәненең икенчеме, өченчеме көнендә Александр Александрович театрга барырга теләк белдерде.

— Рус драма театрынамы? — дидек без.

— Юк, үз театрыгызны — милли театр күрсәтсәгез, яхшырак булыр,— диде ул.

Шулай итеп, аны Г. Камал исемендәге Татар академия театрына алып киттек. Нәкый Исәнбәт трагедиясе бара иде. Без беренче рәткә утырдык һәм спектакль барышын мин сүзгә-сүз тәрҗемә итеп бардым. Постановка аңа ошады. Ш. Шамильский, Х. Әбҗәлилов, Ф. Ильскаяларның уены хакында аеруча яратып сөйләде. Тәнәфесләр вакытында Александр Александровичка татар театры традицияләре турында сөйләдем һәм аның «Татар сәхнә культурасы Мәскәүдәге Малый театр стилен хәтерләтә», дигән югары бәясен ишетү аеруча күңелле булды.

Фадеев белән икенче зур әңгәмәбез 1943 елның октябрь ахырларында булды. Мәскәү язучыларының зур төркеме Казанда һәм Чистайда яшәгәнлектән, Фадеев алар янына еш барып йөри иде һәм аның Татарстан Язучылар союзындагы хәлләр турында яхшы белүе гаҗәп түгел. Моннан тыш ул Союз җитәкчесе Таҗи Гыйззәт белән хат алышып тора. Бервакытта да ул татар әдәбияты язмышы, язучы кадрлар турында кайгыртуын ташламады. СССР Язучылар союзы президиумының эш планына хәтта татар әдәбиятының торышы турында отчет кертелде.

Шулай итеп, Бөек Ватан сугышы чорында Татарстан язучылар оешмасының эше турындагы мәсьәлә СССР Язучылар союзында тикшерелде. Мәскәүгә Таҗи Гыйззәт, Нәкый Исәнбәт, Кави Нәҗми һәм мин бардык. Фронт эшләре белән Мәскәүгә Гадел Кутуй, Әхмәт Ерикәй һәм Мөхәммәт Садри да килгән икән. Алар да минем докладны тикшерүдә катнашты. (Мәскәүгә барыр алдыннан гына булып узган җыелышта мине Татарстан Язучылар оешмасы председателе итеп сайлап куйганнар иде).

А. Фадеев язучыларыбызның сугыш чорындагы эшчәнлегенә югары бәя бирде, татар әдәбиятының бай традицияләрен гаҗәеп яхшы белүен күрсәтеп кенә калмады, хәзерге заман язучыларын һәм аларның әсәрләрен атап-атап сөйләде, шулай ук рус язучыларының татар язучылары алдында бурычлы булуы турында әйтеп үтте.

— Казан ерак түгел, кул сузымында гына,— диде ул.— Татар язучылары белән элемтәбез нык булырга тиеш.

Президиум киң колачлы карар кабул итте. Ләкин Фадеев моның белән генә тынычланып калмады. Ул рус язучыларының ярдәме тагын да сизелерлек булуын тели иде. Утырыштан соң безнең белән партия Үзәк Комитетына барырга теләвен белдерде. Анда татар язучыларын тыңларга тиешләр иде. ВКП(б) Үзәк Комитетының пропаганда һәм агитация бүлегендә минем докладны игътибар белән тыңладылар. Барлык фронтлардан «Совет әдәбияты» журналын җибәрүне сорап хатлар килүен, шундый ук үтенечләр белән башка күп өлкәләр һәм республикалардан да мөрәҗәгать итүләрен сөйләдем. Чөнки журналның тиражы лимитлы, ул өч мең данә генә чыга иде.

— Ничек, сездә журнал чыгамыни?

— Ә сез, Александр Александрович, бу турыда беләсезме?

Мин тынып калдым. Ялгыш ычкындырдым дип, эчем жу итеп китте. Чөнки сугыш кыенлыклары аркасында кайбер рус журналларының да чыгудан туктаганын яхшы белә идем. Шул вакыт Фадеевның ягымлы тавышы ишетелде:

— Әлбәттә, без җитәкчелек итәбез...

Фадеев, чыннан да, хәлебезне яхшы белә иде һәм шуңа күрә безнең белән Үзәк Комитетка килде дә. Авыр сугыш елларында татар телендәге журналны саклап ка-

луны Үзәк Комитетта хуплап кына калмадылар, ә балки бик югары бәяләделәр:

— Бу сезнең батырлыгыгыз!

Үзәк Комитет безгә тиражны өч мәртәбә арттырырга, аны ун мең данәгә җиткерергә рөхсәт бирде һәм кәгазь белән ярдәм итте. Без канатланып, яңа эшләргә рухланып кайттык.

Ләкин Фадеевның безнең турыда кайгыртуы моның белән генә тәмамланмады. Язучылар союзына кергән идем, техник секретарь миңа Александр Александровичның запискасын тапшырды. Ул үзенең квартирасына кереп чыгуны сораган иде. Бераз дулкынлана төшеп, шунда юналдем. Фадеев безнең язучылар өчен, Союз өчен, журнал өчен шулкадәр яхшылыклар эшләде ки, инде эшләнердәе барысы да эшләнгән кебек тоела башлаган иде. Сөйләшә башлауга ук, эчкерсезлеккә чакыргандай ачык елмаеп, ул киңәшләрен бирә башлады. Язучылар союзы президиумы карарын тормышка ашыру өчен нәрсәләр эшләргә кирәклеген, үзенең бу мәсьәлә буенча өлкә комитеты беренче секретарена хат язачагын яки шалтыратачагын әйтте.

Тагын бер мәртәбә күзгә-күз очрашуыбыз 1948 елның кышында булды. Партия өлкә комитеты заданиесе белән аның янына Муса Җәлил турында сөйләшү өчен махсус бардым. Моннан соң Александр Фадеев герой-шагыйрьнең язмышын ачыклау эшендә турыдан-туры катнашты. Ул шагыйрьнең талантын бик югары бәяли иде. М. Җәлилнең хатыны Әминә ханымга җибәргән хаты да шул турыда, әле сугыш башында ук аның Мусага ярдәм итәргә омтылуы турында сөйли. Сугыштан соң, Язучылар союзының 1953 елда үткәрелгән пленумында Фадеев: «Инде арабызда булмаганнарның истәлеген кадерләп сакларга, алар урнәгендә яшь язучыларны тәрбияләргә кирәк»леге турында сөйләде. М. Горький, В. Маяковский, А. Толстой, Д. Бедный, А. Серафимович һәм башкалар белән бергә ул Һ. Такташ, М. Җәлил һәм М. Гафури исемнәрен дә атады һәм залда яңгыраган көчле кул чабулар астында: «Алар совет әдәбиятының җанлы һәм матур мирасы»,— дип тәмамлады.

Сугыштан соң А. Фадеев Верховный Совет депутаты буларак та язучыларга мөрәҗәгать итә иде.

Көтмәгәндә килеп чыккан бер хәл татар әдәбиятының чын дусты булган бу кеше белән безне тагын да якынайтып, араларны җылытып җибәрде. 1951 елның 3 декабре иде. Кичен Язучылар союзында телефон шылтырады. Аптырашта калдык... Фадеев безне «Казан» гостиницасына чакыра иде.

— Каян килеп чыктыгыз? Әллә күктән төштегезме?

— Әйе шул, нәкъ менә күктән... Уралга очыш иде дә, менә монда төшәргә туры килде әле.

Һава шартлары бозылу сәбәпле самолет Казанга төшеп утырган булып чыкты. Иртән ул очышын дәвам иттерәчәк, ә Фадеев вакытны әрәм үткәрмәс өчен безне әңгәмәгә чакырган икән. Ул үзенең Днепропетровск заводларында булуын, ә хәзер Урал металлурглары тормышын өйрәнүен, яңа роман өчен материал туплавын сөйләде. «Яшь гвардия» романының төзәтелгән вариантын тәмамлавын әйтте.

Татар прозасы, поэзиясе, драматургиясенең торышы, нәшрият, китап сәүдәсе һәм башка мәсьәләләр белән кызыксынды. Сүз агышында әдәби тәнкыйтьнең артта калып килүе мәсьәләсе дә күтәрелде. Мин яшь язучылар тәрбияләү һәм бу эштә фән кешеләренең ярдәме булмау турында сөйләдем.

Фадеев яшьләрнең әдәби иҗатка зәгыйфь килүен мәктәпләрдә әдәбиятның сәнгатьчә үзенчәлекләре, нечкәлекләре өйрәнелмәү, укытуның иллюстратив булуы белән аңлатты. Үзенең гимназия елларындагы әдәбият укытучысын тирән хөрмәт белән сагынып искә алды.

А. Фадеев Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романын югары бәяләде, Гомәр Бәшировның «Намус» романын яхшы яктан телгә алды һәм аларга Дәүләт премиясе бирү турындагы фикерне комиссиядә барлык членнарның бердәм яклавын билгеләп үтте.

А. А. Фадеевның илле еллыгында мин дә катнаштым. Татар язучылары исеменнән аңа китаплар бүләк иттем, ә Казанга авторның кулы куелган, төзәтелгән һәм өсталгән «Яшь гвардия»не алып кайттым...

# ПУБЛИЦИСТИКА

**Радик Фәизов**

# ЯШӘҮ МӘГЪНӘСЕ

Сизәсезме: дөньяда яшәү күңеллерәк, мәгънәлерәк була бара. Үзгәреш, тизләнеш, яңарыш! Без әлегә бу төшенчәләрне, аларның бөтен колачы,тирәнлеге белән, күңелгә сыйдырып та, аңлап та җиткерә алмыйбыздыр, бәлки. Әмма алар соңгы елларда күңелләргә утырган битарафлык, ышанычсызлык юшкынын үзгәртеп өлгерделәр инде. Бездә хәзер — уйлану, эзләнү, үзлегеңнән ни дә булса майтарып карарга омтылу. Без хәзер илнең һәр уңышлы адымына куану, һәр күңелсез хәлгә борчылу сизәбез. Бу үзе генә дә инде — зур нәрсә.

Дөресен әйтик, яңалык яшәешкә шактый акрын, авырлык белән керә. Үз кабыгыңнан чыгып, тирә-юнеңә киңрәк караш ташласаң, инде шифалы җилләрнең ничек искәнен тоеп аласың.

Менә безнең Арча районы. Берничә генә мисал. «Яңа Кенәр» совхозы терлек симертеп, аны дәүләткә сату белән кәсеп итә. Ирле-хатынлы Язгөлем һәм Мөдәррис Үтәгәновлар гаилә подряды белән эшләп, йөз баш мөгезле эре терлек симерттеләр. Кышлату чорының бер кварталында алар һәр терлектән тәүлек саен 830 грамм үсеш алдылар. Әлбәттә, алай ук ис китәрлек сан түгел. Әмма бу үткән елгыдан бермә-бер артык. Менә нәрсәсе белән мөһим ул гаилә подряды! Шул ук совхоздан Равилә һәм Гыйльфан Хәкимовлар, Фирая һәм Люция Шакирҗановалар да яңача эшләп, артым алуны ике тапкыр үстерделәр. Сүз ике тапкыр хакында бара икән, моны чын мәгънәсендә яңарыш дими ни диясең?

Вахитов исемендәге колхоз — үсеш юлындагы хуҗалык. Шундагы комбайнчы Олег Шалканов — урак батыры — комбайнын бик хасиятләп чистартып, кышкы саклауга куйды да, эш сорап фермага килде. Элекке елларда ул төрле вак-төяк эшләрдә генә йөреп көн үткәрә иде, бу юлы маңгай тирен чыгара торган даими эш сорады. Мөдир Миңсур Гайнуллин моңа бик шат булды, Олегны азык цехына су җылытырга куйды. Олегка әле бу да җитмәде, ул буш вакытларында хатыны Лизага булышты: сыерлар астын чистартышты, саву аппаратын сүтте, юды, яңадан җыеп куйды. Ә көннәрдән бер көнне, кешекара юк вакытны туры китереп сыерларны аппарат белән савып карады. Шайтан алгыры, була икән бит! Ул арада авылда грипп таралды, Лиза да эшкә чыга алмады.

— Лиза үзе булмаса, аның урынбасары бар! — дип белдерде Олег, башын кашып торган мөдир янына килеп, һәм сыерларны савып күрсәтте. Тегеләйболай гына түгел, ә менә дигән итеп. Хәзер комбайнчы Олег Шалканов, фермада су җылытучы һәм резервта һәрвакыт әзер торган савымчы да. Нәкъ менә кеше кадеренең артуы түгелме бу?!

Үзен төрле формада сиздерә яңарыш. Менә «Заря» колхозының Күлтәс фермасы. Шушы бригада, кай яктан алсаң да, күп еллар буена бер урында таптанды. Ни түнеп китми, ни ныклап аягына баса алмый. Түзеп-түзеп торды да, бригада халкы бригадирны үзе сайлап куярга булды. Бюллетеньгә механизатор Нәҗип Сибгатуллин, бригадир Рифат Сабиров, агроном Мәгъфүр Салихов исемнәрен теркәделәр. Иң күп тавышны Мәгъфүр җыйнады. Чын демократия булды бу җыелышта.

Без дә алга атлыйбыз!

Шифалы җилләр җирле буйсынудагы предприятиеләрнең нык һәм биек коймалары аша эшчеләр янына да үтеп керде. Менә «Татмелиоводстрой» трестының механикалаштырылган 16 нчы күчмә колоннасы. Бик күп еллар инде аның начальнигы булып Алексей Захарович Токранов эшләде. Җитәкче кеше кырыс холыклы, күпмедер дәрәҗәдә, чиновник та булырга тиеш, диләр. Алексей Захарович моның капма-каршысы: гади, хәлгә керүчән, киң күңелле кеше. Колонна үз тармагында, Бөтенроссия күләмендә, иң алдынгылар рәтендә бара. Шунысын әйтик, хезмәтне оештыруның бригада системасына алар инде моннан ун ел элек күчкәннәр иде. Шул еллар эчендә хезмәт җитештерүчәнлеге 115 процентка, ә хезмәт хакы 81 процентка артты. Аңлаган кеше белә: бик зур саннар бу. Ә 1986 елның августыннан колонна тулысы белән коллектив подрядка күчте. Бу исә тулы хуҗалык исәбенә керtү, үз-үзеңне финанслау, чыгымнарны капларлык итеп эшләү мөмкинлеге бирә. Мелиораторларның 1987 елда ук үз-үзен финанслауга 200 мең сумнан артык акчасы кала, ә уникенче бишьеллык ахырына ул 800 мең сумга җитәчәк. Моңа 140 урынлы балалар бакчасы, торак йорт, эш өчен кирәкле яңа биналар салыначак.

Тулаем район буенча алга китеш сизелә.

Әйткән дә юк, тормыш кызыклырак, эчтәлеклерәк була бара һәм һәр шәхес ... һәр шәхес... Менә шушында инде тукталып уйланмыйча, фикер тупламыйча һич тә ярамый. Безнең һәркайсыбызның шәхсән рухи үсеше, хакыйкатьне таныйк, фән-техника прогрессыннан, социаль-көнкүреш өлкәсендә килеп туган мөмкинлекләрдән, гомумән, көн таләпләреннән, кызганычка каршы, калыша килә. Һәм дә шактый ук. Чөнки үз-үзеңне, гадәт-фигыльләреңне үзгәртү кыен, ай-һай кыен. Чабудан тарткан көчләр җитәрлек. Һәркайсыбызның итәгеннән чорнап тотып, аяк терәп артка тартучы көчләр...

Сүзне эчкечелектән, инде миллионнарча тапкыр каргалган, каһәр төшкере эчкечелектән башлыйк. Безнең Арча районында аракының бөтенләй сатылмый башлавына инде ике ел тулып узды. Халык җыенында шулай хәл иткәннәр иде. Ләкин эчкечелек кими төшсә дә нәтиҗәләре һаман сизелерлек булып калды. 1986 елда поселокта 267 тәртип бозуның 125 е — эчүчелек аркасында булган. Эчкечеләр урамда буталып йөрмәсә дә, өендә эчә. Кибеттә аракы сатылмый икән, ачы бал коя, үтә «киткәннәр» спиртлы чүп-чар таба. Хәзер эчкечелек легаль түгел, ул «идән астына» күчте. Шунда яши, рәхәтләнеп чәчәк ата.

Димәк, нәтиҗә нинди? Без бу афәтне күз алдыннан, җәмәгать урыннарыннан куып чыгара алдык. Ягъни инде урамнарда, клуб янсә кибет тирәләрендә салып йөрүдән тыелабыз, өйгә кайттык исә, дилбегә кулдан ычкына. Кешеләр янында үзгәрү турында сөйләнсәк тә, өйдә, ягъни үз алдыбызда үзебез, әле үзгәрмәдек, элек басып торган урыныбыздан бер карыш та алга китмәгәнбез. Үзе яшерми-нитми алырга ярата торган бер танышым әйткәнчә, бу инде — икейөзлелек!

Идән асты эчкечелегенең сәламәтлеккә зарарыннан тыш тагын да зур бер зыяны бар. Аны җәмәгатьчелектән азмы-күпме яшерәсең, әмма балаларыңнан берничек тә яшерә алмыйсың. Алар бу икейөзлелекне күреп, эшнең нидә икәнен бик тә аңлап, үзләренә нәтиҗәсен ясап тора. Димәк, болай итеп икеләтә җинаять эшлибез: җәмгыять алдында һәм балаларыбыз алдында.

Хөрмәтле хатын-кызларыбыз! Күңелегезгә авыр килмәсен, монда таякның юан башы нәкъ менә сезнең тарафка төшә. Чөнки өйдә ясалган исерткечләрне, башлыча, хатын-кызлар булдыра. Һәм еш кына очракларда алардан авыз итеп тә җибәрә. Эчкечелек хатын-кызлар арасында да дәвам итә. Җыеннарда эчкечелекне тиргәп зур аваз салган, аракы сатуны тыюны аяк терәп таләп иткән хатын-кызлар арасында!

Ә мондый идән асты эчкечелеге белән көрәшкә килсәк, ул юк дәрәҗәсендә. Исерткеч ясаган өчен кешене әллә ни җәзалап та булмый икән. Мондый очракта штраф салу гына каралган. Тик, тиешле органнар тарафыннан бу җәза да әллә нигә бер кулланыла. Безнең унөч меңле Арчада, мәсәлән, ачы бал ясаган өчен, унлап кешегә штраф салынган. Монда инде аңлатмалар кирәкми, «ха-ха!» — дип көләргә генә кала.

Урыннарда аеклык өчен көрәш җәмгыятьләре оештырылды һәм әлегә аларның бар эшләре ... взнос җыюдан һәм значок сатудан үткәне юк.

Эчкечелеккә каршы көрәш тулы көченә алып барылырга тиеш, һәм аның яңа, һәр гаиләгә үтеп керә алырдай алымнарын табарга кирәк! Чөнки эчкечелек безне әхлакый яктан гарипләндереп, гаиләләрне таркатып, балаларны җәберләп кенә калмый, ул безнең кайберләребезнең гомерен кисә, турыдан-туры һәлак итә. Мин монда аракы эчү аркасында якты дөньядан вакытсыз киткән

уннарча танышларым, дусларым турында сөйләп бирә алыр идем. Әрвахларны кабердән күтәрәсем генә килми. Араларында нинди асыл егетләр бар иде! Алар барысы да ир уртасы, аннан да яшьрәк кешеләр иде. Инде мәктәпләрдә, институтларда белем алган, тормыш тәҗрибәсе туплаган, тулы әзерлектәге кешеләр иде. Аларның җәмгыятькә файданы иң мул китерә торган вакытлары, алар илнең төп капиталы иде. Аларны югалту — җәмгыятькә коточкыч зур зыян. Шуларны күз алдыма китерсәм, йөрәгемне хәсрәт кыса. «Һи, аракы нәрсә ул? Берәр йөз грамм салып җибәрсәң, кәефләр күтәрелеп китә!» — дип, әле бүгенге көндә дә эчүчелекне яклап маташучыларга карата нәфрәтем арта.

Мондый фаҗигаларның сәбәбе нидә? Алдарак без һәркайсыбызның рухи үсеше көн таләпләреннән, социаль мөмкинлекләребездән артта кала, дигән фикерне әйткән идек. Чыннан да, тормышыбыз яхшырды, керемнәр артты, димәк, һәрьяклап гармоник үсешкә мөмкинлекләребез дә күбәйде. Нәкъ менә шул чиксез мөмкинлекләр алдында без югалып калдык. Асылда без аларны матди ихтыяҗларыбызны канәгатьләндерү өчен генә файдаланабыз, культура ягыннан үсешебез гел генә буталчыклыкта кала килә. Тирән эчтәлекле, мәгънәле итеп яши белмибез. Турысын гына әйткәндә, җәмәгать, гомуми культура дәрәҗәбез бик шәптән тормый безнең!

Мин тел белгече түгел. Шулай да нык ышанам ки, борынгылар «Мәҗлес» дигән сүзнең асылына күп кешеләр бергә җыйналып бик күп итеп ашапэчү дигән мәгънәне генә салмагандыр. Булмас. Безнең борынгы бабайлар ашау өчен генә түгел, ә бәлки яңалыклар уртаклашу, мәгънәле итеп сөйләшеп утыру, бәхәсләшү, интеллектуаль ярышлар үткәрү өчен бергә җыйнала торган булганнар. Мондый һәр мәҗлес аларга рухи үсешнең бер баскычы булып хезмәт иткән. Кешеләр андый урыннарда бер-берсенә яңа җырлар, шигырьләр, тапкыр сүз, сәнгать әсәрләре бүләк иткән. Ә хәзерге туган көн, юбилей, башка төр мәҗлесләрдә бергә җыйналабыз икән, без элгәре бер-беребезгә кыйммәтле әйберләр бүләк итәбез, мул итеп ашыйбыз, аңнарыбыз томалана башлаганчы хәмер чөмерәбез. Мин бер генә мәҗлестә дә кемнең дә булса китап яисә рәсем, альбом кебек әйбер бүләк иткәнен хәтерләмим. Чөнки алар арзанлы, игътибарга лаексыз әйберләрдән санала башлады. Хәзер кешегә матди байлык кирәк. Кайда соң безнең рухи үсеш баскычлары?!.

Мондый мәҗлесләргә тукталуым шуңа, гәрчә алар хәзер сирәк үткәрелсәләр дә, тәэсире, тәрбияви йогынтысы зур. Чөнки монда бер-береңне күрәсең, кешеләрнең үз-үзләрен ничек тотуын күзәтәсең. Ә җәмгыятьтә кеше үрнәкне һәрвакыт үз ишләреннән ала. Аннары социологлар индивидуумда хәмергә тартылуның нәкъ менә шундый мәҗлесләрдә сыйланудан башлануы турында да кисәтәләр. Димәк, мәсьәләнең бу ягын истән һич тә чыгарырга ярамый.

Без чит илләрдәге төрле клубларга бернинди илтифат салмыйча, шактый зур киная белән карый килдек. Акыллы эш микән бу? Сүз дә юк, әйтик, озын буйлылар яисә сипкеллеләр өчен ачылган клуб эшендә әллә ни зур мәгънә табу кыендыр. Тик, әйбәтләп уйланганда, һичшиксез, безнең социалистик җәмгыятьтә дә хезмәт ияләре үз теләкләре буенча төрле клубларга берләшә алырлар иде. Социалистик эчтәлекле, файдалы һәм шул ук вакытта кызыклы, мавыктыргыч итеп эшли торган клубларга. Максатсызлыкны, эч пошуны, эчкечелекне тәмам онытырырга сәләтле клубларга нигә берләшмәскә?!

Хәзер мин үз җирлегемнән, ягъни унөч мең халкы булган Арча эшчеләр поселогыннан торып күзәтү ясап карыйм әле. Инде гаиләсе, яраткан эше булган, тормышы эзгә салынган 30-60 яшьлек кешеләр өчен нинди үзешчән клублар бар бездә? Татарстан АССРның атказанган культура работнигы, Арча педагогия училищесы укытучысы Фирая Батыршина җитәкләгән һәм бары тик пенсиядәге әбиләрдән генә торган (күп булса утыз кеше) җыр һәм бию ансамблен исәпләмәсәң, андый клублар бөтенләй юк бездә. Бер генә клуб та. Арча кебегрәк кайсы поселокта бардыр инде ул, ишетелгәне юк.

Ә бит күп төрле клубларга берләшеп булыр иде. Шахмат, шашка сөюче, йөгерүче, автомобильче, мотоциклчы, велосипедчы, һәвәскәр рәссамнар, төрле коллекцияләр белән мавыгучы, балыкчы клублары! Моның өчен безнең хәзер социаль мөмкинлекләребез җитәрлек. Мәсәлән, безнең Арчада менә дигән, иркен һәм заманча иттереп салынган ике Культура йорты бар. Кайбер көннәрдә аларның күпсанлы бүлмәләре, хәтта заллары да буш тора. Димәк, бергә җыелыйм дисәң, рәхим ит, урын җитәрлек!

Безгә хәзер үзебезнең ялыбызны оештыру, буш вакытыбызны мәгънәле үткәрү хакында нык уйланыр вакыт җитте. Ни өчен әле «хобби» кебек бик кирәкле сүзләр безгә чит телләрдән генә керергә тиеш?!

Оештыру дигәч, билгеле инде, дилбегә җитәкчеләр кулына бирелә. Бу

уңайдан аларга әйтер сүзләр дә бар. Хәзер ачыктан-ачык сөйләшергә мөмкин: КПСС райкомы һәм район Советы башкарма комитеты әле авыл һәм поселок халкының ялын оештыру турында һич кенә дә житәрлек кайгыртмыйлар. Аларның эшчәнлеге, башлыча, авыл хуҗалыгы продуктларын мулрак житештерү һәм дәүләткә сатуны тәэмин итүгә юнәлгән. Сүз дә юк, монысы аның иң мөһиме. Әмма хәзерге шартларда хезмәт ияләренә эшче көч буларак кына карау һич тә кысага сыя торган нәрсә түгел. Ялны оештыру партия һәм совет органнарының, продукция житештерүне тәэмин итүгә караганда да, житдирәк бурычы. Чөнки бу бит — кешеләрнең рухи тәрбиясе, әхлакый бөтенлеге хакында, ниһаять, киләчәк турында кайгырту дигән сүз.

Без алга омтылганда чабудан тартып торган нәрсәләрнең тагын берсе — хезмәткә булган мөнәсәбәтебез. Яңарышка этәргеч булырдай мөмкинлекләр нәкъ шуңа килеп тоташа. Моннан берничә еллар элек мин «Ракета» колхозында булдым. Барлык игеннәр әйбәт, тик бер басудагы арпа гына зәгыйфь, анысын да чүп баскан. Гаҗәп! Яхшылар белән янәшәдә генә бит.

— Тракторчының булдыксызлыгыннан гына бу,— диде шул вакыттагы председатель ачынып.— Ни әйтелде, ни кисәтелде, барыбер үзенчә итте. Сай сукалады, вакытында тырмаламады, күңел бирмәде. Кеше үзе күңелен салмаса, син хет ярыл, барыбер берни чыкмый...

«Кеше күңелен салмаса»... Бер тракторчының эшкә күңел бирмәвеннән колхоз 50-60 гектарлы мәйданның һәр гектарыннан уңышны җиде, сигез, хәтта ун центнер кимрәк ала! Бер кешенең эшкә җиңел каравыннан. Мондый хәл безнең басуларда тулып ята бит! Бәрәңге алгандагы югалтулар 5-10 процентка житә. Күзләр яңгырлы килеп, бәрәңге алу сузылса, югалтуларны процент белән күрсәтү уңайсыз була башлый.

Үзенең шәхси хуҗалыгында исә кеше аны берәмтекләп җыйный. Юк әле! Җәмәгать милкенә үзебезнең шәхси милкебезгә карагандай сак карау юк бездә. Моңа мисалларны һәркем үзеннән дә дистәләп таба.

Бер үк колхозның бер үк фермасында кайбер савымчылар һәр сыердан ел буена 2500 килограмм, ә икенчеләре исә 4000 килограмм сөт савып ала. Нәрсә бу? Әлбәттә, монда савым сыерларының нинди леге дә роль уйный. Әмма бу тикле зур аерманың төп сәбәбе һаман да шул — хезмәткә төрле мөнәсәбәт. Ирене аркасында кем генә күпме бәхетләрдән колак какмаган? Кумәк хуҗалыкта- гы ирену исә бөтен җәмгыятькә зыян сала.

Соңгы елларда безнең тормыш дәрәҗәбез үсте һәм шушы күренешнең бик очлы гына терсәкләре дә килеп чыкты. Без хәзер үзебезне беркемнең дә ярдәменә, киңәшенә, хәлгә керүенә мохтаҗ түгел дип саныйбыз. Менә шушы тойгы безне акрынлап үз кабыгыбызга төрә бара. Байлыкларыбызга, зиннәтле һәм кыйммәтле әйберләребезгә сокланып, тар караш белән яши бирәбез. Кыскасы, без акрынлап, мещаннарга әйләндек. Бу — берниндн искелек калдыгы да түгел, үзебезнең табыш. Һәм ул, кызганычка каршы, тормышыбызның күп тармакларында чагыла. Шуларның күңелгә иң зур борчу салганы — үсеп килгән яшь буынга, ягъни балаларыбызга, карашыбыз.

Мәгълүм ки, мещаннарда романтика, хыял, батырлыкка, үз-үзеңне аямауга омтылыш юк. Мещан мондый хисләргә төкерми дә. Ничек итеп акчаны башкалардан мулрак алырга, ничек итеп башкалардан тәмлерәк ашарга, матуррак киенергә, гомумән, өстен булырга? Менә нинди уйлар чәчәк ата аның күңел кырында? Кызганычка каршы, ул әлеге омтылышын балалары күңеленә дә сала. Бик тырышып, эзлекле рәвештә сала. Чөнки никадәр генә гаҗәп тоелмасын, ул балаларына да шәхси милке итеп карый. Аларның киләчәгенә, язмышына үзен тулы хуҗа дип саный. Аның җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә бер тиенлек тә эше юк.

Хәзерге яшьләр аеруча күркәм, таза! Минем таныш-белешләрем нинди генә егетләр үстермәде! Мин бик яхшы сизеп, белеп йөрдем: ул егетләр балачактан очучы, һава десантчысы, диңгезче, машинист, танкист булырга хыялланды. Шул турыда китаплар укыдылар, мәктәпләрдә иншалар яздылар. Үсеп житкәч берсе генә дә балачакта хыялланган һөнәре иясе булмады. Барысы да җылы, тыныч урыннарга урнашып бетте. Мин шунысын да яхшы беләм: аларның хыялын, йөрәкләрендәге ялкынны бары тик әти-әниләре генә сүндерде. Ул әти-әниләр балаларын еллар буе үгетләделәр, аларга «акыллы киңәшләр» бирделәр, янадылар, ялындылар. Яшь күңелләрне төрле кыйммәтле һәм матур әйберләр алып бирү белән кызыктырдылар, җылы урыннарга кертеп куйдылар. Һәм, күрәбез ки, максатларына ирештеләр. Романтиклар урынына менә дигән мещаннар үсте.

Мещанлыкка кереп китсәң, җәмәгать, бу журналның калган бөтен битләрен язып тутырырга була. Тамырларын җибәрде, канат җәйде ул безнең хәзер. Ул безнең көтеп алган яңарышыбызга да, тизләнеш һәм үзгәреш процессына да яраклашырга омтылачак, яши бирергә өмет тота. Безгә тиз арада аның белән нәтиҗәле көрәшү юлларын эзләргә, табарга кирәк!

Авыл җирендә тизләнешне, үзгәртеп коруны тоткарлый торган тагын бер нәрсә бар — безнең юлсызлыгыбыз. Авыл шоферы өчен кыш әйбәт. Чөнки суык бабай юлларны асфальттан да болайрак итеп катыра, чокыр-чакырларны тигезли. Ямьле җәйләр шоферларның бу рәхәтенә чик куя. Язгы һәм көзге юлларны телгә дә аласы килми. Юл юклыгы — гаять зур күләмдәге өстәмә чыгымнар гына түгел, ул — әледән-әле кабатланып торучы фаҗига, вакытсыз өзелгән гомерләр дә.

Безнең җитәкче агайлар һаман да шуны аңлый алмыйлар: юллар салуга акчаны аз-азлап тоту — аны җилгә очыру гына. Безнең районда, мәсәлән, Арчадан Яңа Кенәргә юл сала башласалар, Кенәргә барып җиткәнче, аның Арча башын яңадан төзәтергә туры килә. Юллар ташбака адымы кебек акрын һәм гаять начар итеп салына. Сәбәп нидә? Шунда ки, юл төзү һәм төзәтү идарәсе райондагы иң кечкенә, иң зәгыйфь оешмаларның берсе. Юк, бу бездә генә түгел, бүтән районнарда да шулай. Бу оешмалар үзләренә җиткерелгән планнарны намус белән үтәп һәм арттырып үтәп барган суратта дә, авылларыбыз йөз еллар дәвамында да юньле юл күрмәячәк. Яхшы юллар булдырыйм, дисең икән, ул идарәләргә куәтле, киң колач бирергә кирәк! Аларны, башка кайбер оешмаларны чикләп тору бәрабәренә булса да, заман техникасы, яңа машиналар белән коралландырасы иде. Юл төзү инженерлары әзерли торган институтларга авыл яшьләрен җибәрәсе иде. Чөнки яхшы юллар салу — махсус белем дә таләп итә торган җитди эш. Хәзерге шартларда бу мәсьәләне һәр район җитәкчелеге үзе генә дә хәл итә ала дип уйлыйм.

Юллар! Киң итеп асфальт түшәлгән табадай тигез юллар — авыл кешесенең күптәнге хыялы. Алар бит тиз арада үз бәясен чыгарачак. Монысы — мәсьәләнең матди ягы. Юлларның рухи кыйммәтен чамалап бетереп тә булмый.

Рухи яктан, дигәч, кайберәүләрнең елмаеп куюы мөмкин. Моннан берничә еллар элек Сеҗе урта мәктәбен тәмамлаучылар арасында, аларның шәһәргә омтылуы сәбәпләрен ачыклап анкеталар таратылды. Һәм байтак кына укучылар әлеге сәбәпләрнең берсе итеп нәкъ менә авыл җирендә юньле юллар булмавын күрсәтте. Менә сиңа мәсьәләнең рухи ягы!

Ни генә булмасын, дөньяда яшәү күңеллерәк тә, мәгънәлерәк тә хәзер. Үзгәреш, тизләнеш, яңарыш! Безгә, һәркайсыбызга аерым-аерым, менә шушы төшенчәләрне тиз арада күңелләребезгә сеңдерү зарур. Без, һәркайсыбыз, аерым-аерым, үзгәрергә, яңарырга бурычлы. Яшәүнең төп мәгънәсе шунда.

**Гомәр Багдалов**

# ТАБИГАТЬКӘ МӘРХӘМӘТ

Заманында Стахеев дигән сәүдәгәр, елга флотында үз мәнфәгатенә зыян килмәсен өчен, Алабуга тирәләрендә тимер юл салдырмау чараларын күреп торган. Патша чиновникларына бирелгән зур-зур ришвәтләр үз эшен эшләгән — шәһәр дистәләрчә еллар буе тимер юл зыңын, паровоз үкерүләрен ишетмичә, тып-тын яшәгән дә яшәгән. Юлга бәйле бөтен хаҗәтләр Кама суына бәйле булып кала биргән. Тын калада коелган чиркәү чаңнары, монда эшләнгән тегермән һәм май язу җайланмалары да, дирбия, арба-чана, кәрзин-сандык кебек нәрсәләр — барысы да Стахеев флоты карамагындагы пароходларга төяп озатылган.

Әле Бөек Октябрь революциясеннән соң да бу тынычлык озак еллар дәвам иткән. Мондый хәл, бер яктан, төбәкнең зур дөньядан аерылыбрак торуына китерсә дә, икенче яктан, табигатьнең һич борчылмыйча, хәр яшәвен яхшы тәэмин иткән.

Алабуга кешеләре хәзер дә үз якларының нәкъ менә шул сыйфаты — бай табигате, саф суы, калын урманнары белән горурланалар. Дөрес, моннан берничә дистә еллар элек Алабугага да зур промышленность шавы бәреп керде. Нефтьчеләр алып килде аны. Соңгы елларда исә монда тагын да киңрәк колачлы Кама трактор заводы төзелешләре башланып китте. Шәһәр кешеләре сагаеп калдылар. Хәтеремдә: Алабуганың өлкән яшьтәге бер укытучысы ихлас күңелдән сөйләп торган иде.

— Акылым бу бик әһәмиятле заводның илгә кирәклеген яхшы аңлый,— ди.— Әмма ифрат бай табигатебезнең бөтенлеге сакланырмы, дип, күңел каушап калды. Кайдан килеп чыкты безгә мондый гаугалы кешеләр? Үзләре бихисап күп, үзләре ашыгалар, кычкыралар,— без бит андый шау-шуга өйрәнмәгән. Борын-борыннан килгән кадерле тынлыгыбызны, табигатебезнең матурлыгын харап итмәсәләр генә ярар иде!..

Агайның хафалануы бөтенләй үк урынсыз да түгел. Алабуга халкы нефтьчеләрнең дә шактый саксыз адымнарын күрде. Берсендә район газетасы да язып чыккан иде: «...бораулаучылар дәүләтнең җирне саклау турындагы законын бозалар. 1983 елның язында «Кама» колхозы басуларында, яңа кое казыган чакта, ике километр әйләнәсендәге җирнең өске катламын кырып алмыйча эшкә тотынганнар. Моннан тыш ике гектар көтүлек мазутланган. Яңгыр суы белән буталып, мазут Камага да агып төшкән...»

Кыскасы, алабугалылар туган җирләренең табигый кыйммәтен һәм матурлыгын мөмкин кадәр сакларга тырышалар. Башкача була да алмый. Монда хәтта йортлар да, көнкүреш кирәк-яраклары да, табигатьтәге мөкәммәл нәфислеккә охшатырга тырышып, матур итеп ясала кебек. Ул капка-болдырларның бизәкләре, ул тәрәзә яңакларының челтәрләре, ул морҗа читләрендәге катлаулы үрнәкләр — барысы да Алабуга төбәгенең кабатланмас гүзәллеге. Бөек рәссам Иван Иванович Шишкинның зур сәнгать дөньясына бу яклардан юл алуы тикмәгә генә түгел, әлбәттә. Табигатьнең тугрылыклы яклаучысы һәм аңа мәдхия җырлаучы Пришвинның таланты да Алабуганың кабатланмас матурлыгы җирлегендә ачылган.

Алабуганың табигатькә гашыйк җаннары еш кына Шишкин музеена җыелалар, шәһәрнең үткәне, киләчәгенә бәйле киң колачлы үзгәрешләр турында сөйләшеп утырырга яраталар. Музейның директоры Светлана Васильевна Бобкова шәһәрнең тарихына кагылышлы бик күп мәгълүматларны биш бармагы кебек белә. Шуңадыр, аның җитәкчелегендәге музей шәһәрнең рухи тормышында кадерле бер урынга әйләнгән. Тарихчылар да, архитекторлар да, төзүчеләр дә Светлана Васильевнадан файдалы киңәшләр ишетәләр, монда алар борынгы фотографияләр, рәсемнәр, кыйммәтле язмалар табалар.

Трактор заводы төзелешенә бәйле Алабугага яңа агым килеп керде. Бу корылышның мәнфәгатьләре шәһәр һәм район тирәлегенең гүзәллеген саклау белән генә чикләнми. Масштаблар зур, максатлар ерак-еракларга юнәлгән. Моны һәркем аңлый. Шунлыктан, бу яңарыш шәһәрнең төп халкында борчу-

лы, сак караш та уята. Җыйнак, тын шәһәрнең дистә еллар буе дәвам иткән гадәти тормышы пыран-заран килмәсме? Якын киләчәктә үк Алабугада яшәүчеләр саны да ун тапкырга артачак икән, моны ничек кабул итмәк кирәк? Гигант завод тын каланы тәмам «йотып» бетермәсме?

Бәхеткә, гайрәтле төзүчеләрнең беренче адымнары кайбер борчуларны юкка чыгарды. Завод корпуслары борынгы шәһәр аллеяларыннан шактый читтә салына. Ул биналар шәһәрдән күренмәячәк тә хәтта. Икенчедән, төзелешнең җитәкчеләре Алабуга төбәгендәге гүзәл табигатькә, каладагы кадерле истәлекләргә шәһәрнең үз кешеләре кебек үк тирән ихтирам белән карыйлар. Салынып ята торган заводның генераль директоры Николай Иванович Бех беренче эшен шәһәр аксакаллары, тарихчылар һәм туган төбәкне өйрәнүчеләр белән киңәшүдән башлап җибәрде. Аның теләге изгелектә: Шишкинның мәшһүр әсәрләренә таяныч булган Кама урманнары төзелеш тарафыннан кыерсытылмаска тиеш. Ул хәтта беренче чагышын да: «Мине, иң беренче чиратта, завод та, аның продукциясе дә түгел, шәһәр кешеләре ял итәргә тиешле тын аланнар, табигатьнең күркәм якларыннан файдаланып төзелгән профилакторийлар җәлеп итә,— дип башлады.— Эштә сынатмабыз, әмма бездән хәзер табигать белән уртак тел табу таләп ителергә тиеш...»

Николай Ивановичның ихласлыгына ышанмаслык түгел. Аның хезмәт юлына күз салсаң, җитәкченең һәрвакыт иң әүвәл кешеләргә яхшылык эшләргә тырышканлыгын күрергә мөмкин. Моңарчы ул КамАЗның кою заводы директоры булган. Анда да эшчеләрнең көнкүрешен, хезмәт шартларын яхшырту өчен күп көч куйган. Хәзер Николай Бех, КамТЗ тирә-юньгә зарар салмасын, анда эшләүчеләргә рәхәт булсын өчен, алдан ук бөтен чараларны күрергә тырыша.

Проектлау идарәсенең төзелеш архитектурасы бүлеге, мәсәлән, бөтен көчне заводның тирә-юньгә яраклашуын тәэмин итүгә юнәлдерә. Алабугада элек-электән ике парк бар иде. Проектлаучылар бу паркларны да тәртипкә китерүне күздә тоталар. Аларда физик күнегүләр ясарга, йөгерергә теләгән кешеләр өчен аерым урыннар булдырылачак. Ачык һавада чыгыш ясаучы артистлар өчен сәхнә дә планлаштырыла.

Алабугага бер баруымда мин директор Николай Ивановичны Светлана Бобкова белән сөйләшеп утырган чакта очраттым. Алар Алабуга кызы Надежда Дуровага багышлап иҗат ителгән һәйкәлне кайсы мәйданга кую турында киңәшләшәләр икән. Шәһәр аксакаллары төрле фикерләр әйткәннәр, ә бу җитәкчеләр шуларның иң отышлысын табарга тырышалар.

— Алабуга төбәге тора-бара бу якта яшәүчеләрне генә түгел, Чаллы, Менделеевск, Түбән Кама кешеләрен дә үзенә тартачак,— ди Николай Иванович.— Монда бит күп катлы ташпулатлар гына салынмаячак. Алабуга үзенең тарихи истәлекләре, табигатенең байлыгы белән дә кешеләрне сокландыра. Шуңа күрә шәһәрнең яңа өлешен дә җанны рәхәтләндерерлек итеп салырга кирәк...

Шәһәрне яңартуның генераль планы борынгы истәлекләрне тулысынча саклауны бурыч итеп куйган. Архитектура ягыннан һичнинди кыйммәте булмаган җимерек хәлдәге йортлар гына алып ташланачак. Алар урынына ике-өч катлы җыйнак кына яңа өйләр салу күздә тотыла. Матур биналар исә, искергән булса, яңадан төзекләндереләчәк. Үзәктән ераклашкан саен йортлар биегәя бара. Күп катлы ташпулатлар алдан салыначак, чөнки төзүчеләргә дә, машина ясаучыларга да торак кирәк. Унберенче микрорайонда өй туйлары уздыда инде. Дөрес, башта һәр бүлмәгә бер гаилә урнаштырыла. Гаиләле кешеләрнең тулай торагына охшый бу өй. Әмма бу — шәһәр читенә эреле-ваклы вагоннар, такта бараклар салу кебек ямьсез күренештән котылу өчен кирәк. Вакытлы чара. Бераздан бу йортлардагы тормыш та иркенәеп калачак.

Алабуганың киләчәге тагын да матур һәм шул ук вакытта элеккесенә дә охшаш булсын өчен җан аямаучы белгечләр күп. Элек Казан төзүче инженерлар институтында укыткан Фирдәвес Мансурованы гына алыйк. Ул шәһәрне беренче күрүдә үк ярата, үз итә. Шәһәрнең архитектурасы, аның тарихы белән мавыгып, Фирдәвес бик күп мәгълүмат туплый, үз тирәсенә теләктәшләр җыя. Хәзер аңа шәһәрнең һәр ташы таныш кебек. Алабуганың элекке матурлыгын саклау буенча берәр мәсьәлә килеп чыктымы, Фирдәвес җыйган белешмәләрдән файдаланалар.

Мансурова, Бобкова кебек фидакарьләр барында шәһәрнең киләчәге, тирә-юньдәге табигатьнең иминлеге өчен җан тыныч. Дөрес, андыйларга җиңел түгел, күп җиңүләр йокысыз төннәр, кискен бәхәсләр нәтиҗәсендә килә. Әмма

бүгенге көн шартлары мондый көрәшүчеләргә зур мөмкинлекләр бирә һәм өметләрне тагын да яктырта төшә. Безнең кечкенә Алабуга шәһәренә кагылышлы һәр мәсьәлә Мәскәүнең үзендә иң җитди төстә хәл ителеп бара. Бигрәк тә сүз җирне, урман-суларны саклауга карасa, һичкем вакытын да, белгәннәрен дә кызганмый.

Заводны салу проектында да табигатьне, бигрәк тә урман һәм суларны, саклау чаралары каралган. Каманың сафлыгын саклау аерым игътибар үзәгендә тора. Төзүчеләр эш көненнән, эш атнасыннан соң тирән саф сулы елга буенда ял итүнең нинди шифа булачагын тирәннән аңлыйлар. Алабуга төзүчеләренең бу омтылышында Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрендәге су чистарткыч җайланмалар ышанычлы үрнәк була ала. Әлеге шәһәрләрдә Кама суының сафлыгын, балык үрчетү өчен яраклы булуын тәэмин итәрдәй чистарткычлар бар. Чаллы һәм Түбән Кама предприятиеләре өчен Камадан алынган су елгага кире җибәрелгәндә нәкъ элекке хәлендәгедәй сафландырыла. Мондый чараларга акчаны кызганып тормыйлар. Аңлаганнар, димәк: җирне, суны кадерләүдән туктыйсың икән, аны агулыйсың икән, бу хәл кешегә төзәтеп бетерә алмаслык афәт булып әйләнеп төшә. Әгәр, киресенчә, табигатьне кадерләп саклыйсың икән, ул сиңа мең белән, яхшылык булып кайта. Әйтик, без Чаллыда, акчаны янга калдыру максатыннан, Каманы пычрата башласак, күптән инде елгадагы тереклекнең башына җиткән булыр идек. Бүген исә без бу суның сафлыгы, аның балыкка байлыгы белән горурлана алабыз. Түбән Кама ГЭСы сусаклагычында балык шул кадәр күп үрчегән ки, 1987 елны Балык хуҗалыгы министрлыгы монда, тәҗрибә төсендә балык сөзүне рөхсәт итте. Ун бер тонна корбан балыгы сөзделәр. Күп түгел, әлбәттә. Белгечләр бу эштә отыш алу юлын эзлиләр. Әмма бер нәрсә куанычлы: Кама суы саф! Заман өчен шунысы бик мөһим. Һәм без киләчәктә дә бу горурлыгыбызны югалтмау чараларын булдырырга тиешбез.

Һава сафлыгын саклау тагын да катлаулырак. КамАЗның җылылык һәм энергия үзәкләре, Түбән Кама нефть-химия гиганты атмосферага моңарчы да тирә-юньдәге урманнарга, үсемлекләр дөньясына дәһшәт сала иде. Шул көчләргә КамТЗга куәт бирүче «мич»ләрнең «төтене» дә кушылса, Менделеевск янында салына торган ашламалар заводы да «сулый» башласа, атмосферабыздан ни генә калыр? Аның сафлыгы тулысынча урманнарның имиилегенә бәйле. Әмма урманнарга чын-чынлап ярдәм итәргә өйрәнмәгән шул әле без. Киресенчә, хәтта гөмбә җыярга да машинага яки мотоциклга утырып йөрү ягын карыйбыз. Предприятиеләрдән чыккан яман газга машина төтене өстәлә. Юллар, аланнар, агач аралары таптала, безнең ял көннәреннән соң урман тәмам хәлсезләнеп кала.

Хәзергәчә Алабуга тирәсенең гүзәллеге саклана килде. Иван Шишкин рәсемнәренә күчергеч ролен үтәгән күренешләрнең дә дистәләбен әлегә шул хәлендә үк очратырга мөмкин. Әмма саклануның зарары юк һәм бу турыда борчылулар тикмәгә генә дә тумаган. Берсендә, Шишкинның атаклы «Изге чишмә»се язылган урында, экскаватор белән сосып, торф ала башлыйлар. Моны күреп өлгергән тарихчылар тиз арада чаң кагарга тотыналар һәм кадерле урын харап булудан котылып кала. Мондый мисаллар табигатькә зыян салмау чараларын һәр даим күреп торырга кирәклегенә ишарәли.

Төзүчеләр Алабуга урманнарын тулаем саклап калу өчен бу тирәләрне тоташы белән ял урыны дип игълан итү ягында торалар. Бу очракта урман хуҗалык ихтыяҗлары өчен файдаланылмаячак. Шул рәвешчә зур-зур заводлар тезмәсе генә түгел, иксез-чиксез урман киңлекләре дә төбәкнең уртак байлыгына, күз карасыдай кадерләп саклана торган милкенә әйләнәчәк.

Бу уңайдан КамТЗ эшчеләрен азык-төлек белән тәэмин итәчәк хуҗалыкны да күздә тотарга кирәк. Җитәкчелек бу юнәлештә хәзер үк киң тармаклы эш алып бара. Заводның цехлары кайчан ачылыр әле, анысын белгән кеше юк, ә менә ярдәмче хуҗалыкның уңышлары күз алдында: балыкны да үзләре үрчетә, «Нектар» цехында ике йөздән артык умарта бал җыя. Иген игәргә, яшелчә үстерергә, терлек-туар асрарга дип, төзүчеләргә өч мең гектардан күбрәк җир дә бүлеп бирелгән...

Аяз көннәрне Кама ярына чыгып бассаң, Алабугадан КамТЗ моржаларын, Түбән Кама ташпулатларын күрергә була. Чаллы, Түбән Кама, Менделеевск, Алабуга шәһәрләре көчле бер бөтенлек хасил итә. Аларның табигать белән дуслыгы исә бу көчне гаҗәеп матурлыкка төрә.



*Татарстан — туган төбәгем*

**М. М. Хаснуллин,**
КПССның Менделеев райкомы
беренче секретаре.

# ЕРАКЛАРДАН КҮРЕНӘ

Безнең район, «Еракладан күренә!» — дип җырларда җырланса да, яшь әле ул, нибары 1985 елның августында гына оештырылды. Әмма, миңа калса, хикмәт еллар озынлыгында гына түгел. Халык ниләр булдыра ала, район башкалардан кай ягы белән аерыла — мин әнә шулар турында сөйләмәкче булам. Төбәгебезнең, хәтта район итеп оештырылган көненнән башлап кына карасаң да, башкарган эшләре шактый. Хәтта борынгы шәһәребезнең дә, авылларның да йөзе үк үзгәреп-яктырып китте кебек. Моңа, әлбәттә, районның КПСС Үзәк Комитетының апрель Пленумыннан (1985) соң оештырылуы нык тәэсир итте. Райондагы партия, совет, комсомол, профсоюз оешмаларын төзегәндә үк без кеше кадерен алга куеп тотындык, кадрларны булдыклылыклары буенча бәяләп урнаштырдык.

Безнең район халкында революцион көрәш рухы дөрли, илгә һәм үзенә тапшырылган вазифаларга тугрылык көчле. Хезмәт дәртенең яңача кабынып китүенә элекке химия заводыбызга иш итеп яңа завод салыну да этәргеч булып тора. Аңарда илнең авыл хуҗалыгына бик кирәкле минераль ашламалар җитештереләчәк. Дөрес, бу яңа заводның нәкъ менә безнең якларда салынуы хакында төрле фикерләр йөрде. Хуплаучылар да, каршы төшүчеләр дә булды. Әмма, безнең уебызча, мәсьәлә дөрес хәл ителде. Яңа заводны бездә салу, беренче чиратта, Менделеевскиның тәҗрибәле химикларына бәйле. Безнең Л. Я. Карпов исемендәге химия заводы тарихы үзе генә дә ни тора?! Бу заводны 1868 елны Вятка губернасына караган Алабуга өязендәге Кураков волосте Бондюг авылы крестьяны К. Я. Ушков ача. Завод Кама елгасының Тихие Горы пристаненнан ике чакрым ераклыктагы Тойма суы буена салынган. Баржалар-пароходлар йөзеп торган су юлы булуы, арзанлы эшче көчләрнең күплеге, ташландык җирләр, унсигез-егерме чакрымда гына Кокшан заводының эшләп утыруы — барысы да тәвәккәл, уңган крестьянга яңа тармакны шактый киң җәелдереп җибәрергә мөмкинлек бирә. 1870 елда ук инде завод 238 пот химик продукция чыгара. Ушковның улы үзеннән дә эшчәнрәк була. Ул башлап йөргән чорда, ягъни 1898 елга кадәр завод тагын да киңрәк колач ала. Әмма шуннан соң, бигрәк тә беренче империалистик сугыш башлангач, заводның көймәсе комга терәлә.

Шунлыктан, завод идарәсе, эшләрне җайга салу ниятеннән, Бондюгка талантлы химикны, инженер Лев Яковлевич Карповны чакырып ала. Ул вакытта Лев Яковлевичның ялкынлы революционер икәнлеген берәү дә белми әле. Заводның өлкән коммунисты Ш. Саттаров истәлекләрендә мондый юллар бар: «...алты-җиде ай үтүгә заводтагы хәл нык үзгәрде. Лев Яковлевич, үзенә генә мәгълүм ысулларга таянып, эш көнен сигез генә сәгатькә калдырды, эшчеләргә махсус киемнәр бирдертте, хәтта мастерларның безгә мөнәсәбәте яхшырды».

Акыллы һәм уңган инженер, акрынлап, завод эшчәнлегенә революцион рух иңдерә башлый. Бөтен тирә-юньдә беренче буларак, хезмәт кешесе сигез сәгатьлек эш көненең рәхәтен татый. Предприятиедә эшчеләр контроле кертелә. Мондый яңалыклар торган саен тирәнгәрәк китә: профсоюзлар, эшче депутатларының Советлары, милициянең һәм Кызыл гвардиянең эшче отрядлары төзелә. Мондый әзерлек Каманың түбән төбәкләрендә Совет власте урнаштыру өчен барган көрәштә хәлиткеч роль уйный. Завод яшьләре арасында, тирә-юньдә беренчеләрдән булып, комсомол оешмасы төзелә. Ленинчыл коммунистик союзга берләшүчеләрнең яртысыннан артыграгы — татар яшьләре. Алар башка волость комсомолларыннан революцион көрәшкә әзерлекле булу-

лары ягыннан аерылып торалар: Р. Бәһаветдинов, Ш. Саттаров, А. Алимбеков, Р. Хәмитов, А. Шәймәрдәнов...

Заводның партия оешмасы шулай ук өяздәге башка оешмаларга үрнәк бирә. Бондюг эшчеләренең Совет хөкүмәте тарафыннан белдерелгән беренче декретларны иң алдан хуплап чыгуын нәкъ менә шуның белән аңлатырга кирәк тә инде.

Л. Я. Карпов исемендәге химия заводы — безнең районның әйдәп баручы коллективы ул. Кайсы тарафка нинди генә ярдәм кирәксә дә, беренче башлап, шушы заводыбыз алына. Районның башка оешмаларын кадрлар белән тәэмин итүдә дә, яңалыкларга юл ярүда да заводның роле зур. Бу данлы коллективта тәрбияләнгән кайбер коммунистлар Татарстанкүләм җитәкче постларга да тартылдылар: Ш. У. Усманов, Т. Ф. Фәсхетдинов, А. Ш. Шаһиморатов һәм башкалар.

1920 елның 1 Май өмәсендә эшчеләр завод белән елга порты арасына тимер юл суза башлыйлар. Ушковлар, дистә еллар буена хыялланып та, башкарып чыга алмаган бу зур эш 1921 елны уңышлы тәмамлана.

Поселокның яңача төзелә башлавы да шул чорга туры килә. Аның иң беренче урамына — бөек Ленин исемен, икенчесенә үк Л. Карпов исемен бирәләр. Дөрес, алга бару монда да канкойгыч көрәшләр белән өзелеп-өзелеп тора. Завод эшчеләреннән төзелгән революцион отрядлар легендар В. М. Азин дивизиясенә кушыла. Совет властен урнаштыруда һәм ныгытуда кызылгвардиячы А. Алимбеков, М. Лотфуллин, С. Сәетгәрәев кебек патриотлар башлап йөри. Алар промышленностьны үстерүдә дә, наданлыкка каршы көрәштә дә халыклар арасында интернационализм рухы тәрбияләүдә дә нык тырышалар.

Надежда Константиновна Крупская, 1919 елны Бондюгка килгәч: «...Эшчеләр безне бик җылы каршыладылар,— дип яза.— Үз хәлләре белән таныштырдылар. Аларның көрәшчән рухы шатландырды. Алар тормышны яхшыртырга тырышалар... Коммунистик клуб булуы яхшы. Клубларында шактый бай китапханә бар. Коммуна театры оештырылган. Анда төрле җыелышлар да уздырыла. Хәреф танымаучылар юк диярлек. Укытучылары — коммунистлар һәм аларга теләктәшләр. Мөселман укытучылардан икесе бигрәк тә ошады. Агалы-энеле алар. Икесе дә — коммунистлар...»

Надежда Константиновна телгә алган татар укытучылары — Сәхәбетдиновлар. Алар Бондюг кешеләренең белемле, революцион зирәк акыллы булуы өчен зур көч куйганнар. 1920 елдан КПСС члены К. С. Сәхәбетдиновны халык аеруча зур хөрмәт белән искә ала. Заманында яшьләрнең иң ышанычлы киңәшчесе булган коммунист Б. Бәһаветдиновны исә соңрак Казан университетына ректор итеп алалар.

Бөек Ватан сугышы елларында да Менделеевск кешеләре ил белән бер ритмда яши. Заводка икеләтә тырышырга, дошман итеге астында калган предприятиеләрнең бурычын да өлешчә үз өстенә алырга туры килә. Ул елларда завод оборона өчен егермеләп төрдәге продукция җитештерә. 1944 елны, фидакарьлекләрен искә алып, күпсанлы эшчеләр орден-медальләр белән бүләкләнәләр.

Фронтка киткән кешеләребез дә һич сынатмый. Җиде егетебез — В. Белоусов, И. Бурмистров, В. Пискунов, П. Софронов, М. Суднишников, М. Фомин, П. Фролов Советлар Союзы Герое исемен алды. Батырларның алтысы — Менделеевскиның 1 нче мәктәбендә бергә укып йөргән егетләр. Бу героик дәрт, дошманга карата сугышчан рух бүгенге яшьләребездә дә тәрбияләнә. Районда интернационалист хәрбиләр курсы бар. Аның иң актив членнарыннан хәрби хезмәт елларын Әфганстанда батырларча үткәргән егетләрне — Р. Дәүләтшин, С. Поспелов, С. Плитман, Р. Гайфетдинов, Л. Куликовны мактап телгә аласы килә. Кыскасы, фидакарьлек һәм батырлык безнең як кешеләренә буыннан-буынга күчә килә.

Әле бүгенге көннәрдә дә районыбыз горурлыгыннан саналган химия заводы йөз еллыгын да үткәрде инде. Бу зур тантананы коллектив хезмәт уңышлары белән матур итеп каршы алды. Шуңа күрә аны Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләделәр. Коллектив даннары илгә таралган уңганнар тәрбияли. Андыйлардан КПССның XXII съезды делегаты, Ленин орденлы Р. Б. Хәлиуллинны, КПССның XXIV съезды делегаты Л. З. Закированы, Бөек Ватан сугышы каһарманы, Ленин орденлы М. С. Юсуповны, КПССның XXVI съезды делегаты В. П. Мөхәмматшинаны, КПССның XXVII съезды делегаты В. А. Кучинаны, «Кама» колхозының элекке председателе Б. В. Әхмәровны һәм шундыйлардан үрнәк алып, җиң сызганып эшләп йөрүче йөзләрчә уңганнарны күрсәтергә мөмкин булыр иде.

Мәгълүм ки, безнең халык, гомумән, җырлый-җырлый эшләргә ярата. Безнең районда да шулай. Әле Октябрь революциясенә кадәр үк химия заводында һәвәскәр җырчылар-уенчылар түгәрәге булган. Соңра аны «Коммуна» театрына әйләндергәннәр. Завод театры ай саен диярлек яңа спектакль күрсәткән, А. Островский, А. Чехов, М. Горький пьесаларын сәхнәләштергән. Хәтта Бөек Ватан сугышы елларында да халык сәнгатьтән аерылмаган.

Районның шундый җирлегендә Татарстанның һәм Каракалпакстанның халык артисткасы Вафирә Гыйззәтуллина, җырчы Рәмзия Зиннатуллина кебек талантлар үсеп чыгу

һич гаҗәп түгел. Егор Уткин, Дифгат Сирай кебек шигъри җаннарны да укучы яхшы хәтерлидер. Алар, кызганычка каршы, дөньядан яшьли киттеләр. Шагыйрь күңелле кешеләребез тагын да бар безнең. Мәсәлән, колхоз председателе булып эшләүче Марсель Гыймазетдиновның шигырьләре республика газеталарында шактый еш күренә. Тиздән аның шигырьләре аерым китап булып та басылыр дип торабыз. Марсель үзе җитәкли торган Г. Тукай исемендәге колхозда әдәби-музыкаль берләшмә дә оештырып җибәрде.

Районыбыздагы халыклар татары, русы, марие, барысы бер гаиләгә тупланып, дус булып, бик матур иттереп яшиләр. Ул бездәге үзешчән түгәрәкләрнең ярыш концертларын күрсәгез — сокланып туймаслык! Арада Тукай исемендәге колхозның татар хоры, «Азин» совхозының мари фольклор ансамбле аеруча уңышлы чыгышлар ясый.

Менделеев районын яшь диган идек. Әмма безнең хезмәт һәм сугыш ветераннарыбыз да җитәрлек. Алар яшьләрне патриотик рухта тәрбияләүгә зур өлеш кертәләр, районны яшелләндерү, урамнарны төзекләндерү кебек өмәләрдә актив катнашалар. Ветераннарга карата кайгыртучанлык күрсәтү махсус төзелгән программа нигезендә тормышка ашырыла. Алар үзләре дә бик актив: М. Зыятдинов, М. Некрасов, К. Вафин, М. Вәлишин, Г. Садыйков, П. Южмин һәм башкалар район партия оешмасының иң ышанычлы таянычлары булып санала.

Бүгенге көннәрдә районның бөтен көче уникенче бишьеллыкны уңышлы үтәүгә юнәлдерелгән. Ил күләмендә алга сөрелә торган үзгәртеп корулар бездән бик тәвәккәл һәм эшлекле адымнар ясауны сорый. Бигрәк тә авыл хуҗалыгы өлкәсендә нык тырышырга туры килә. Уңган коллективлардан «Октябрьнең 40 еллыгы», «Батыр кул», Ильич исемендәге колхозларны, «Тойма» җәнлек совхозын һәм «Агропромхимия» берләшмәсен күрсәтергә була. Тукай исемендәге колхозыбыз быел: «Бишьеллык планны дүрт елда үтибез!»— диган яңа өндәү белән чыкты. Мондый тәкъдимнәрне, әлбәттә, хупларга гына кала.

Промышленностебызның да шатландыра торган яклары бар: химия заводы эзлекле, ышанычлы адымнар белән алга атлый; төзүчеләребезнең эше дә канәгатьләнерлек, сәүдә тармагында да мактанырлык яңалыклар сизелә.

Әмма алда торган бурычлар тынычланырга урын калдырмый. Без ел саен уртача 48-50 мең тонна ашлык җитештерергә тиешбез. Дөрес, алдынгы хуҗалыклар үрнәген киңрәк җәелдерә алсаң, бу бурычны уңышлы үтәп чыгарга мөмкин. «Кама», «Октябрьнең 40 еллыгы» исемендәге колхозлар, «Бондюг» совхозы яхшы эшкәртелгән басуларында гектарыннан утызар-кырыгар центнер уңыш җыя.

Хәзер авыл хуҗалыгын кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсен хәл кыласы бар. Моның өчен авылларны төзекләндерү, яңа йортлар салу, зур авылларда урта мәктәпләр ачу, больницаларны арттыру кирәк. Бу юнәлештә башкарылган беренче эшләр үк уңай нәтиҗә бирә башлады.

Якын арада район үзәгендә сөт комбинаты һәм ипи заводы саласы бар. Ижевка авылында елына 30 миллион шешә минераль су чыгара торган яңа завод ачылды. Билгеле булганча, монда безнең бик шифалы «Ижминводы» курорты бар. Аңарда ел саен сигез мең кеше дәва алып китә.

Менделеев шәһәре генераль план нигезендә төзекләндерелә. Бу планга заводның кайбер цехларын яңарту да кертелгән. Яңарту, нигездә, тирә-ягыбыздагы табигый матурлыкны, урман-суларның сафлыгын саклауга юнәлдерелә. Якын елларда безгә килсәгез, районыбыз сезне үзенең мул табыннары, төзек йортлары, бакчалары һәм Тойма буендагы чиста комлыклары белән каршылаячак.

*Бәхәс дәвам итә: «Заман һәм шигырь»*

**Рахмай Хисмәтуллин**

# СҮЗНЕҢ ЧӘЧӘГЕ, ТЕЛНЕҢ БӘЛЗӘМЕ

Мин ул чагында Азнакай район газетасында эшли идем. Бервакыт редакциягә шундый хат алдык.

«Хөрмәтле редакция!

Мин сезгә бераз сәеррәк хат язам булыр, ахры. Мин колхозда сыер савучы булып эшлим. Болай соңгы вакытта мактаулы эш ул. Алдынгы булсаң, макталасың, артта булсаң, сине берәү дә күрми. Әмма көн дә кабатлана торган бер үк эш белән генә тормышны бизәп булмый. Инде миңа 24 яшь. Ирем бик каты эчте, без аерылыштык. Тормыштан кайткан кеше булуыма кармастан, һаман каядыр омтыласы, тормышны матурайтасы килә. Кайчак күңелем тулы сагыш-моң була. Шул вакытларда күңел шигырьгә тарта. Тукайны, Такташны, Җәлилне укыйм. Аларда әллә нинди җанны дәвалаучы дару тапкандай булам, уңышсыз яшьлегемне онытып торам. Әмма йөрәгемне иң әрнеткәне шул: бергә эшләүче иптәшләрем минем шигырьләр белән мавыгуымнан көләләр генә. Беркөнне кызлар: «Алай бик яраткач, мә, укы, рәхәтлән инде» дип, минем алдыма 1952 елда чыккан «Татар совет поэзиясе» дигән китапны китереп салдылар. Укыдым да, аптырашка калдым. Менә сезгә дә берничә куплетын күчереп җибәрәм.

*Яз килә! Яз җиңә, чөнки*
*Сталин аның дусы.*

*Яшәсен яз. Яшә, җиңү*
*Генералиссимусы!*

*Г. Хуҗи.*

*Юлбашчыбыз Сталин аның*
*Мактап кулларын кысты.*

*Гүзәл эшен бригаданың*
*Дәвам итәргә кушты.*

*М. Садри.*

Бу буш шапырыну поэзияне мәсхәрә итү түгел микән дим мин. Минем иптәш кызларыма да шуларны укытып, җаннарын гарипләндереп бетермәделәр микән дим мин. Газетагызда шул турыда сөйләшү ачып җибәреп булмыймы?

Сәлам белән Энисә Г.»

Ул чагында мин бу хатка җавап итеп, мондыйрак бер мәкалә яздым.

«Хөрмәтле сеңелем Энисә! Эш менә нидән гыйбарәт. Татар классик поэзиясенә нигез салучы бөек Тукаебыз революциягә кадәр үк безне ташлап китеп барды. Ул халыкның үз баласы, аның йөрәге, теле, аның моңы, шатлыгы һәм кайгысы иде. Революциядән соң татар совет поэзиясенә бик күп яшь көчләр килде. Алар арасыннан үзенең тирән хисләре һәм эчкерсезлеге белән бөек Такташ калкып чыкты. һәм 30 елларда татар поэзиясе матур гына уңышлар бирә башлады.

Әмма... ил өстендә кара яшен яшьнәде, кыргый күк күкрәде һәм барыгызга да таныш булган күңелсез утызынчы еллар килде. Иптәш Хрущевның соңгы съездлардагы докладларында күрсәтеп үтелгәнчә, бик күп гаепсез кешеләр кулга алынды, ил бакчасындагы шау чәчәкләргә кырау төште. Бу чорда зур әдипләр төрмәләргә ябылдылар. Эстафетаны яшьләргә тапшыра алмыйча, шунда үлеп калдылар. Бик күп китаплар дөнья күрә алмады. Кыю фикерләрне пуля екты. Хыяллар бөредә шиңделәр. Әдипләр һәм халык арасында бер-береңә ышанмаучылык обстановкасы

туды. Әдипләрнең баш очында балта тоткан кара шәүлә торды. Язучы, ни әйтсәм ярый алырмын микән дип, бөтен иҗатын яраклашуга, җитешсез якларны күрмәү, бар дөньяны алсу буяуга буяу тактикасына корды. Бу Сталинның рәхимсез шәхес культы заманасы башлану чоры иде. Илдә шундый хәл, шундый тәртип урнашты ки, шагыйрь һәм язучы үз шәхесен, үзенең йөрәк кичерешләрен, халыкның яшәү сулышын онытып, бер аллага табынгандай, бер шәхескә дан җырлый башларга мәҗбүр булды. Күпме көч, күпме яшьлек, күпме йокысыз төннәр гел дә бушка, гел дә заяга, гел дә үкенечкә әрәм булды. Ә бит алар арасында шедеврлар язарлык талантлылары да бар иде. Халык, әдәбиятның үлә барганын тоеп, аны укымас булды. Аңлырак кешеләр «идән астында» гына булса да, әдәбият юк инде хәзер, дигән кыю фикерләр әйттеләр. Яшерен әдәби оешмалар барлыкка килгәләде. Ләкин алар гына хәлне үзгәртерлек түгел иде инде. Кырыгынчы елларда поэзиягә килгән яңа буыннан утызлап шагыйрь Ватан сугышы кырларында ятып калды. Күп кенә яшь талантлар, кая барырга юл таба алмыйча, өметсезлеккә бирелеп, каләмнәрен ташладылар. 1952 елда чыккан «Татар совет поэзиясе» дигән зәңгәр тышлы китап менә шундый шартларда туган иде.

Ә бүген ил күгендә язгы кояш елмая. Язгы кояш ил өстендә генә түгел, татар поэзиясе бакчасында да мул нурлар сибеп елмая. Язучыларның сулышлары киңәйде, дөньялар иркенәйде. Партиябезнең егерме икенче съезды илебез алдына якты, яңа максатлар кую һәм коммунизм төзү программасын кабул итү белән беррәттән, Сталинның шәхес культын ахырынача тәнкыйтъ итте. (Кызганычка каршы, ул ахырынача хәтле булып чыкмады. 1988 ел. Р. Х.) Башта гаепләнеп йөртелгән, үлгән һәм онытылган бик күп язучыларның әсәрләре яңадан халыкка кайтарылды.

Хәзер әдәбиятта өр-яңа, иң кызыклы чор башлана. Бу чорда милли культуралар һәм поэзия дә күрелмәгән үсешкә ирешәчәк. Куәтле яшьләр төркеме калка. Әнисә сеңлем, әгәр сез бу яшьләр арасыннан Такташ кебек кызыклы, талантлы шагыйрь үсеп чыгуын һәм сезнең яшьлегегезне үзенең шигъри энҗеләре белән бизәвен телисез икән, аларның әсәрләре белән тагын да ныграк кызыксыныгыз. Язучылар һәм тәнкыйтьчеләр алар бер-берләрен кырыс, каты, туры итеп тәнкыйтьләүдән тартыналар. Шунлыктан онытмагыз: шагыйрьне сез, укучылар үстерәсез. Начар шигырьләрне тәнкыйтьләп, яхшыларын хуплап, язучылар союзына, редакциягә языгыз. Яхшы, кыю шигырьләрне чыгаруны таләп итегез.

Минем үземне поэзиядә кеше йөрәгенең иң тирән газаплары, яшәү һәм үлем темалары кызыксындыра. Кешелек моңарчы җирдә — бишектә генә яшәде. Хәзер аны бөек космик ачышлар көтә. Аны чиксез пространстволар ымсындыра. Әмма кешегә космоста да сирень букетлары, чәчәкләр кирәк булачак. Ә кайда чәчәкләр, анда поэзия дә мәңгелек.

Бу яңа чор бездән яңача язуны да таләп итә. Татар шигыре, яшьләрнең йөрәк тибеше, коммунизм төзелеше яңа форма сорый, бөек ашкынуларыбыз «кирпеч» строфаларга гына сыеша алмый. Язгы ташкын кебек куәтле, космос кебек серле һәм тирән поэзия киләчәкнең иң гүзәл казанышларыннан берсе булачак, һәм ул җир шарын атом сугышы һәлакәтеннән саклап калырга ярдәм итәчәк.

Сезгә уңышлар теләп, ихтирам белән...»

Мәкаләм газета өчен ул елларда әле һаман да кирәкле пафос белән бизәлгән булуына да карамастан, дөнья күрә алмый калды. Кая ди ул?! Җепшетү чоры башланса да, әле ул вакытларда район газеталары андый әңгәмәләр оештыру дәрәҗәсенә күтәрелә алмаганнар иде. Журналистлар кеше яшәеше өчен иң кирәкле булган поэзия турында кайгырта башлаудан ерак торалар иде. Газеталар һаман да тирес чыгару, көл җыю, туган җиребез каны — нефтебезне күбрәк суырту турындагы һәм шул рухтагы кыска гомерле мәкаләләр белән тулып чыга иде.

Заманалар... Айный да алмый калдык... Озак та үтмәде, җепшек чигенде, бар дөньяны торгынлык катырып ташлады... Шул елларда мин бер шагыйрьгә хат яздым. Ул хаттан бирегә берничә өзек китерәсем килә.

Беренче сүзем. Сезнең И. Нуруллин белән башлап җибәргән бәхәс берьяклырак булды ул. Нуруллин өлкән буын кешесе, ә сез яңа, яшь, энергиясе ташып торган ярсу буын вәкиле. Мин үзем Нуруллинны, «Тукай» романы авторы буларак, бик хөрмәт итәм. Ул бик зур эш башкарган кеше. Мин аның Питрәчкә килеп Тукайны күргән карчыкларны эзләп йөрүләрен әле дә хәтерлим. Ул бездә, татарда гына була торган бик тырыш, фидакарь кеше. Әмма поэзия дигән катлаулы дөньяны аңлауда без аның белән аерылышабыз. Безнең поэзия һаман да шул дөрес «шакмаклар» юлыннан китсә дә, болай да телебезнең инде ничәмә-ничә гасырлар буена диңгез җиле күрмәгән йомыкыйрак бер тел икәнлеген искә алсак, ул тончыгып, басылып, сүнәчәк, үләчәк. Аңа иреклелек кирәк. Аңа нәкъ менә Равил Фәйзуллиннар,

Ренат Харислар поэзиясе кирәк. Бик күп кирәк! Кеше күңелен, күзен бер төрле генә формалар туйдыра гына түгел, аны котырта, ярсыта, чирләтә дә башлый. Табигать-тә дә гармония белән бергә иреклелек, чәчелеп китү, формасызлыклар да бик күп бит. Табигатьнең чәчелеп китүе дә үзе бер гармония. Тел, моң дөньясы искиткеч киң, чиксез. Дөньяны татарча күрү генә җитми, аны русча күрү генә дә җитми. Булдыра алсаң, аны французча да, немецча да, японча да һәм башкаларча да күрәсе иде.

Икенче сүзем. Игътибар иткәнегез бармы? Әдәбиятыбыз, нигездә, филология факультетын тәмамлаган кешеләр тарафыннан тудырыла. Алар арасында математик, физик, техник, архитектор һәм башка профессияләрне үзләштергән адипләр юк дәрәҗәсендә. Ә бит борынгы шагыйрьләрнең күбесе галим булган. Мин, математик профессиясен үзләштергән кеше, шактый еллар буена шигырь яздым һәм хәзер дә язам. Әмма мин, әллә шул чит-ят профессия кешесе булганга да инде, поэзиядән читкәрәк тибәрелеп калдым. Бүгенге шагыйрьләр арасында теләктәшлек һәм мохит таба алмадым.

Һөнәрләшү тарайганнан-тарая барган бу заманда, әлбәттә, әдәбият барыбер төп филологлар тарафыннан тудырылыр. Әмма шулай да, ә бит яшәешнең-философиянең филологларга бик үк таныш булып бетмәгән әллә нинди серле яклары да булуы бик ихтимал.

Поэзия турында барган дискуссиядә филолог И. Нуруллинның математик-шагыйрь В. Хлебниковны гаепләп үтүе дә әнә шул галимнәр дөньясын аңлап бетермәвенең бер чагылышы булды. Ә юкса бит Хлебников башка бик күп филолог-шагыйрьләр онытылганда да тиз генә онытылмый торган шагыйрь. Ул яңа формалар, яңа тел, яңа төшенчәләр, яңа шигъри алымнар тудырырга, филология дөньясы алга сөргән гадәти тел кануннарыннан югарырак күтәрелергә тырышкан. Телнең дә үз Циолковскийлары, үз Королевлары булырга тиештер бит!

Өченче сүзем. Поэзиябез үсә, сугышчан, аның гаҗәп талантлары, биекләре бар дип мактанырга, шаулашырга яратабыз. Ә менә шулар бүгенге дөньяда, тормышта, төзелеш һәм колхоз авылы дөньясында кешене Кеше итү өчен ни дәрәҗәдә көрәшә соң? Кызганыч, менә бу өлкәдә чын тикшеренүләр алып баручы юк.

Миңа бер вакыт жюри составына кереп район үзәгеннән ерак бер татар авылында мәктәпләрнең үзешчән смотрын карарга туры килде. Клуб шыгрым тулы. «Кыш озату» бәйрәме дә иде бугай. Сәхнәдә нindидер шигърият, болгар моңнары матурлыгын вәгъдә иткән исемнәр йөртүче Тоба, Каенлы, Болгар, Үчкә, Чапчак, Чаллы, Симәнәй кебек авылларның мәктәп балалары чыгыш ясый. Бер-бер артлы 36 номер башкарылды. Шунда, ышанырсызмы-юкмы, ник кенә бер Тукай, Туфан, Такташ, Җәлил, Хәким шигыре яңгырасын! Нур Гайсиннең бер шигыре дә Зәлфәт белән Ф. Кәримнең берәр шигыре укылды. Ә кая уен-көлкеле, юморлы, лиризмлы, чәнечкеле Г. Афзаллар, Ш. Галиевләр? Кая балаларны дөрес юлдан юнәлтүче татар теле һәм әдәбияты укытучылары? Ә кая ул, укытучылар ялгышка да, аларны дөрес юлга юнәлтүче бүгенге көннең актив, фидакарь шагыйрьләре? Ник алар бу мескенлеккә каршы тавыш күтәрмиләр? Ә бит татар теле укытучыларының кайберләре хәтта «Казан утлары» журналын да укып бармыйлар, алдыртмыйлар. Мондый рухи фәкыйрь кешеләрдән нинди ялкын, нинди мәнфәгать көтәсең?

Коры-сарыдан торган концерт беткәннән соң клуб тирәсенә чыксам, саламнан ясалып куйган карачкыны яндырып яталар иде. Кыш озаталар... Әмма тирә-якта бер генә ачык, айнык, нурлы йөз дә күренмәде. Яшьләрнең барысы да диярлек исереkләр иде. Коточкыч күренеш иде бу. Алар стеналарга килеп бәрелалар, сүгенә-сүгенә бер-берләрен төртешеп егышалар. Кайсыдыр, сөләгәен агызып, җырлап та маташа:

*Аракы арыш мае,*
*Эч әле, карышма әле.*

*Әче түгел, төче түгел,*
*Эчмәсәң кеше түгел.*

Соңыннан биш-алты исерек егет, автобуска утырып, шәһәргә чаклы безнең белән кайтты. Техник училищеда укучылар иде бугай. Аларның сүгенеп, ямьсезләнеп, кыланып кайтулары бернинди итагатьлек нормаларына да сыярлык түгел иде. Бу егетләрнең шигырь китаплары кебек изге әйберләрне кулларына да тотып карамаулары әллә каян күренеп тора иде. Өч мең татарга бер китап туры килерлек итеп кенә «кадерләп» чыгарылган ул шигырь китаплары ничек итеп инде бу исерек егетләр кулына килеп эләксен ди! Ничек инде борчылмаска, мин беләм, ул яшьләр яшәгән тулай торакларда безнең Татарстан рухы бөтенләй юк. Кызыл почмаклары безнең телдә бизәлмәгән, татарча стена газеталары чыгарылмый, анда татар газеталары алдыртмыйлар. Училищеларында татар әдәбияты укытылмый. Мәктәбендә дә, инде училищесында да кешелеклелекнең нигезе туган тел, әдәп сүзеннән ясалган, милли тәрбиянең иң төп изге чыганагы булган әдәбият, халкыбыз тарихы яратып, зурлап

укытылмагач, каян килсен ди аларга әдәплелек?! Кая барабыз?! Озаккамы культурабызны энтузиастларның йөрәк мае гына алга этәрер?

Дүртенче сүзем. Шагыйрьләр ни карый? Халык үзе ни карый? Ни өчен соң үзләрен гаҗәеп гражданин-көрәшче санаган шагыйрьләребез менә шушы яшь исерек массаны яктыга чыгару өчен көрәшкә ташланмыйлар? Рух, яшәеш, көрәш, бәхет өчен искиткеч кирәк була торып та, пропаганда җитмәү аркасында гына кирәксезгә әверелеп, сатылмый яткан үз китапларын тарату эше белән алар ни өчен кызыксынмыйлар? Яшьләребез озаккамы шулай, аракыдан миңгерәеп, сарыккүзләнеп яшәр?

Ә бит язучының гражданлык йөзе турында сөйләнеп җитәрлек авыз суы корытабыз. И. Нуруллин үзенең чыгышында «шагыйрь, минемчә, барыннан да элек, үз даирәсен, үз төбәген, үз халкын энәсеннән-җебенә кадәр яхшы белергә тиеш», дип яза. Әлбәттә, шагыйрь халыкның этнографиясен дә, археологиясен дә, җырларын да, авыл тарихларын да, халыкның психологиясен дә бик әйбәт белергә тиеш. Ләкин, кызганычка каршы, безнең кайбер шагыйрьләр, туган якларын бик сагынабыз дип язсалар да, хәтта үз авылларын, үз якташларын, үз ягының тарихларын да яхшылап өйрәнмиләр. Аларның күпчелеге туган ягыннан йөз чакрымнан дәрвишләр төсле яши биреләр.

Авыл халкының үзенең дә житешсез яклары юк түгел. Моңарчы ул еш кына ниндидер анда җыр чыгарган үз шагыйренә түгел, ә читтән баеп кайткан шахтерына, тәзүчесенә хөрмәтне зурдан куярга яратты. Халык дигәнебезнең әллә нинди вәкилләре дә бар бит аның. Үз телен, үз тарихын, үз әдәбиятын сукыр бер тиенгә дә санамаган йортсыз-илсез, буш җанлы, бер имансыз зимагүрләре дә безнең арабызда яши. Алар өчен корсак хаҗәте, тормыш исәп-хисабы синең шигырь-әдәбиятыңнан мең мәртәбә өстен тора. Ә бит шулар аркасында хәзер «А кто такой Тукай?» дип оятсыз сорау бирүче бөтен бер мескен буын хасил булды.

Менә шундый чакларда ашкынулы, ярсулы, мәгънәле шагыйрьләр, яңачарак уйлый ала торган кыю, батыр шагыйрьләр, башка төрле профессияләрдән дә килгән шагыйрьләр бик-бик кирәктер!

Бишенче сүзем. Ни өчен соң без малга, вак-төяк данга, чит чакыруларга алданучан? Ә бит юкса, иң бөек дан, иң бөек мал — ул яшәү үзе! Күзле булу, дөньяны тою! Иң бөек бүләк, иң бөек дан — ул үзең булып калып, үз телеңдә, үз денеңдә яшәп үтү! Менә шушыларны аңлый алмыйча, бәһасез Күз, иң татлы Тойгы заманның ялгыш фикер кысаларында кысылып кала.

Моның өстенә техника прогрессы кешегә әллә нәрсәләр алып килде дип шаулаган булабыз. Әйе, ул күпмедер дәрәҗәдә буш вакыт алып килде. Әмма тутырыр рухың булмаса, буш вакыт коточкыч агрессив нәрсә ул. Күпчелек җинаятьләрне буш вакытларын кая куярга белмәгән кешеләр эшли. Поэзиядән, әдәбияттан ерак торган адәм баласын буш вакыт бигрәк тә нык җимерә, аны упкынга тәгәрәтә. Димәк, әдәпсез-әдәбиятсыз калсаң, буш вакыт та, техника прогрессы да сиңа хәсрәт арты хәсрәт кенә алып килергә мөмкин. Менә шундый чакта поэзия кешегә һавада йөзгән өрфия болытларның ямен күрсәтсә, ботактагы бөредә бөтен бер планета тойдырса, гомернең мизгелен дә чиксез байлык, илаһи бер әверелеш, галәми хәрәкәтнең бер дулкыны итеп ачып бирсә, адәм баласы чын бер рухи азатлыкка ирешер, төпсез, иксез-чиксез ерак галәмнәргә ашкыныр иде. Ә ашкыну ул — иң бөек бәхет!»

Күп еллар элек язылган әнә шул хаттагы фикерләр бүгенге поэзия өчен дә актуаль яңгырый бит.

...Шигырь китаплары бездә шактый күп чыгып килә. Мин үзем аларны башта урман-кырларга, елга-күл буйларына алып чыгып укырга тырышам. Ләкин табигать гүзәллеге эчендә, чын күк, чын болытлар, чын кош-корт авазлары арасында күпләрнең шигыре күмелеп кала. Анда күп шигырьләр бик үк укылмыйлар. Шунлыктан мин аларны кире бүлмәгә алып кайтып укырга мәҗбүр булам. Димәк, әле без табигать гармониясеннән өстен, яисә шуны ачып бирә торган әсәрләрне аз тудырабыз.

Әйе, безнең шагыйрьләр читләтеп тирән серләр, фикерләр әйтергә омтылалар. Кызыгып, көнләшеп тә куясың: туктаусыз янулар, тетрәнүләр, югалтулар бәрабәренә китап чыгару бәхетенә ирешкәннәр. Мин ул китаплардан халык алдына чыгып укырдай шигырьләрне «Җидегән чишмә» сценариена кертер өчен эзлим. Андый шигырьләрне, кызганычка каршы, бик үк күп табып булмый. Шулай да мин Сибгат Хәким, Равил Фәйзуллин, Харрас Әюпов, Роберт Миңнуллин шигырьләрен шактый еш файдаланам. С. Хәкимдә мәңгегә чаң кагып торган олы моң бар. Бигрәк тә «Кырыгынчы бүлмә» моңнары сценарийларга кертмәгәндә үзләре бәреп керә. Р. Фәйзуллин шигырьләре дә, «Җидегән чишмә» идеалларын куәтләп, һәрвакыт сакта тора. Ул шигырьләрдән сыекланган буыннар катып китә. Аның поэзиясеннән без мәңге

аңлап бетерә алмаячак бу дөньяда бик кирәкле булган иң фидаи җанлы сердәшләрне табасың. Ә халыкка бирелгәнлектә әчкерсезлек җаныңны тетрәтеп җибәрә. Аның шигырьләре — кеше җанының гуманлылык үлчәме. Аларда яшәү һәм үлем, мәхәббәт һәм нәфрәт, дуслык һәм дошманлык, яхшылык һәм яманлык турында ялкынын чәчеп торган фикерләр табасың. Җанны иң әүвәл бер хис били: мондый шигырьләр язган кешенең күңеле начар була алмый. Ул һәр шигырен язар алдыннан иң кайнар җан саунасында сафланып кына каләмгә тотына сыман. Нинди кодрәт ул шагыйрьдә: күкләргә, җирләргә үзгә бер төс керә, һәм син үзең дә бөек булган сыман яши башлыйсың. Кешелегең арта...

Тик менә тәнкыйтьче Мансур Вәлиев үзенең «Шигъри бушлык» мәкаләсендә («Казан утлары», 8 сан, 1987 ел) С. Муллагалиевнең бер шигырен Р. Фәйзуллинның «Ах, тау юклыклар» дигән шигыренә капма-каршы куя:

*Теләмәдем кыяларга*
*Бер кош булып ояларга...*

С. Муллагалиев үзәнлектә яшәүне хуп күрә. Шушы ук идеяне хөрмәтле тәнкыйтьчебез М. Вәлиев тә күтәреп ала. Аны халыкка якынлык, ди. Нигә ул кыя, янәсе, «ә кыялар алар — үле таш, торараташ!» ди.

Моңарчы классик әдәбият, минемчә, тау-кыяны, биеккә, яктыга омтылу символы буларак, аңа ирешүне чын поэзиягә саный иде бугай. Фәйзуллин шигырендә аңлаган кешегә аңларлык итеп язган ич:

*Биектән башкача*
*Тау да, чүл дә, ил дә.*
*Тау да, үзән дә бер*
*Тик җебегән иргә.*

*Бөркетләр түмгәктә*
*Канатларын җилпи.*
*Басар кыя җитми,*
*Менәр күге җитми.*

Ачып карасаң, шунысына да игътибар итәргә кирәк иде. Аның бу шигыре «Кошлар юлы» дигән китапта «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга» дигән мәгълүм шигыре белән янәшә дә урнашкан. Аңлашыладыр. Бодайны кибәк белән бутаулар кирәкмәс иде. Барысын да ачыктан-ачык әйтеп бетерергә мәҗбүр итмәскә иде. Шигырь хикмәте, күңел скальпеле буларак, сүзләрне «предчувствие мысли» итеп, сүзләр астына өстәмә мәгънә төреп, яшереп, ягъни ул мәгънәне тел очында менә-менә әйтелергә, менә-менә туарга торган фикер итеп өлгертеп, башка тупас сүз һич үтеп керә алмый торган күңел түренә нәфис кенә итеп элеп калдыра. Шигырьнең менә шушы сыйфаты тылсымлы да инде. Кеше бер укыган шигырен ятламаска да, кабат-кабат укымаска да мөмкин, ә менә шул төреп бирелгән мәгънәсе, сүз белән атамыйча гына әйтелгән эчке хикмәте кайдадыр безнең тирән күңел нейроннарыбызда сакланып кала да, кирәк чагында уянып, безнең иң кешелекле хисләребезне хәрәкәткә китерә.

Ирләрнең асыл сыйфатларын югалта барулары сәбәпләренең берсе — кыяларга, тауларга чакырасы урынга, үзәннәргә чакыруыбыздадыр, бәлки?

Бу шагыйрь турында инде шактый күп язылган. Ә менә Харрас Әюпов... Ул төнге йолдызлы күк астында йөрәген ачып, керсез хыялый егет булып басып тора.

*Кемнәрнең серен яшергән,*
*Кайларга дәшә тагын?*
*Агызып китәр шикелле*
*Мине бу төнге агым...*

Безнең тамашачыга Харрасның әчкерсезлеге, хыялыйлыгы романтикасы ошый булса кирәк. Аның иркен сулышына, киң якты карашына, киләчәк матурлыкларга ышанычына соклана ахры. Әйе, бүген әле җирдә дәүләтләр, чикләр бар. Әмма Харрас поэзиясендә җир шары һәм яшәеш өчен бернинди чикләр дә, дәүләтләр дә юк. Харрас Әюпов әнә шул биеклеккә менгән, әнә шул киңлеккә, бәйсезлеккә ирешкән шагыйрь булып тоела. Аның өчен ерак үткәннәр юк, алар барысы да бүгенгедә. Кайсыдыр бер автор аның шигырь китабына күзәтүендә «вакыт, моң, мәңгелек» сүзләренең күбрәк кабатлануы турында язган иде. Әмма дә ләкин менә ни хикмәттер: алар күпме кабатлансалар да туйдырмыйлар, киресенчә, һаман-һаман шул турыда укыйсы килә. Чөнки татар поэзиясе инде күп еллар буена нәкъ менә шул төшенчәләргә, шул бәйсез киңлекләргә сусап килә. Чөнки безнең бөтен тарихыбыз шул Вакытка, безнең бөтен үткәнебез Мәңгелек төшенчәсенә эреп кереп беткән. Аның поэзиясендә Үткән, Бүген, Киләчәк бер мизгелгә сыя, «сабый күзләреннән киләчәк карап тора». Аңарда бүгенгегә кайтып көчәйгән «Тәфтиләү» һәм «Әллүкиләр» моңы өстенлек итә, ягы зәңгәр күктәге ак болытларга үрелеп, менә-менә яфрак ярырга

торган ак каеннар моңы кайный, беренче мәхәббәттән канатланып, бәхет тавына менеп житеп килүчеләр жыры ымсындыра, шигырь белән музыка арасындагы моңы жанынны сафландыра.

Аның уй-фикерләре кемнәрдер тарафыннан кайчандыр әйтелгән сыман тоелсалар да, ул аларны нииндидер яңа бер фонда, ниндидер яңа гаммада, ниндидер башка бер нюанс белән үзенчә әйтә.

*И, әле бар бит безнең дә*
*Күбәләк буласылар!*

Бу юлларны укыгач, кемнәрнең генә бәгырьләре сызланып куймас икән!

Мине поэзиясе белән гашыйк иткән тагын бер исемгә тукталып китәсем килә. «Жидегән чишмә»нең Бакый Урманче кичәсенә сценарий язганда кулыма Асия Минһажеваның китабын тоттырдылар. Анда бөек рәссамыбыз турында шигырьләр бар икән. Укыдым да хәйран калдым. Кайнар дәрт, тирән фикер бәреп тора. Урманчега багышланган өч шигыре сценарийга кайнар сулыш өрде. Шигырьләрендә гел яңа хис, яңа алым, яну, дулкынлану, кайнау... Укыйм да билге куям: «бишле!»! Укыйм да «бишле» куям. Булдырган! Гадәттә китапта иң талантлы дигән шагыйрьнең дә «дүртле» яки «өчле» белән бәяләнгән шигырьләре була, ә мин Асиянең бер шигырендә дә андый билгеләр куя алмадым. Тәнкыйтьчеләр Саҗидә Сөләймpraнованың дәвамын эзлиләр түгелме соң? Ә соң бөтенләй башка бер планетадагы сыман ярсу, ашкын җанлы бу шагыйрәнең иҗаты шул алдагылар рухында һәм, әлбәттә, алардан алгарак бер адым түгелме соң? Әнә бит ул үзе турында нинди кыю белдерә:

*Мин, күрәсең,*
*гомер китабында*
*серлелектән торган*
*яңа тип...*

Бу кыз бала моңарчы булган бөтен шагыйрәләрне бер бакчага җыеп, аларның барлык тавышыннан үз тавышын ясаган сыман. Хисләр төенләнешенең исемнәрен генә кара син: «Максат», «Илһам», «Ант», «Юану», «Төшенү», «Биогамма»... Әйтерсең лә ул астрономнар, математиклар, физиклар бәхәсен тыңлаган, аларның йөрәк пульсын ишеткән, әйтерсең лә бөтен фәлсәфәләр илендә булган. Менә ул кыршаусыз илһам, менә ул шартлы юк-барларны танымаган яшь-яшь көчле буын! Һәр шигырьдә нинди рух биеклеге, рәнҗүләрдә никадәр гаҗизлек, хисләрдә никадәр сафлык, сер бүлешүләрдә никадәр самими эчкерсезлек! Башка телләргә тәрҗемә иткәндә дә бик көчле яңгыраячак иҗат бу!

Шагыйрә иҗатында шашкын җан, тетрәнеп давылларга каршы бара. Аңа кул сузасы, иңеннән сыйпап көч бирәсе, аңа хәерле юл телисе килә. Иркенлек һәм тантана яратучы бу шагыйрәнең җаны сүнмәсен, сүрелмәсен иде, кайнар давылларда канаты көймәсен иде!

Гомумән хәзер поэзиябезгә без илле яшьлекләр күргән кара шомнарны күрми, өрекми, курыкмый үскән, караңгы-карачкылардан гарипләнми-имгәнми өлгергән, мескенләнүдән өстен таза шәпле буын килә!

Мондый шагыйрьләр иҗаты бездә тагын да көчлерәк поэзия туачагына ышанычны арттыра. Әйе, тагын да көчлерәк! Моңарчы безнең дисталәгән шагыйрьләребезнең җаны, хисе, кыюлыгы өстеннән үткән гасырларның авыр канаты, хәтта яңа чорларның да күпмедер дәрәҗәдә утилитар фәлсәфәсе хакимлек итеп килде. Шагыйрьләр генә гаепле түгел иде. Күп еллар буена әдәбият-сәнгать битләрендә дә, журналларда да торгынлык хөкем сөрде. Шагыйрьнең язганнарын матбугатка үткәрүчеләр һәр шигырьдән «двойное дно»— ике катлы төп — янәсе, «алдавыч яшерен баз» эзләп утырдылар. Янәсе, артык милли була күрмәсен, артык кыю уйлатмасын! Һәм аның яшерен мәгънәсен, ягъни шигырьне шигырь иткән «төшне» актарып чыгарып, «ярамый» мөһере суктылар. Кешене иң кешелекле, матур, бөек иткән тойгы — мәхәббәт турындагылары да булса, «обком органында мәхәббәт турында шигырьләр бастыраламмыни?! Ышту син?!»— дия-дия барысын бергә архивларга сыпырып төшерделәр.

Ә инде без кешегә иң авыр минутларында якты нур булырлык шигырьләр, рухани сүзләрдән өстен булырлык тел ачкычлары, җан бәлзәмнәре тудыру турында уйларга да курыктык. Ә бит алар туган булса, туган телне яраткан йөзләрчә мең укучыларыбыз була торып, шигырь китапларын 1000—2000 данә тираж белән генә чыгармас идек, чыгарганнарының да әкрен таралуына зарланмас идек.

Түбән Кама

Гәрәй Рәхим

# МАКТАУЛАР... ТӘНКЫЙТЬЛӘҮЛӘР...

## «Обойма»лардан — әдәби анализга

Бүгенге көндә «торгынлык еллары» дип аталып йөртелә башлаган чорда
безнең әдәби хәрәкәткә, әдәби жанрларга, бигрәк тә аерым язучылар
иҗатына һәм әсәрләренә бәя бирүдә берьяклылык, стандарт бәһа өстен-
лек итте. Тәнкыйть мәкаләләрендә һәм җыелышлардагы чыгышларда
бер төркем язучыны төрле җитәкче урыннарда эшләвенә, зур бүләкләр һәм мактаулы
исемнәре булуга, тәнкыйть фикеренә түземсез холыгына карап, тәнкыйтьтән өстен
«катлау» вәкилләре ясау һәм аларны мактау гадәткә кереп китте. Бу хәл язучылар
җәмәгатьчелегендә рәсми булмаган исем белән «обоймалар» дип аталып йөртелә
башлады. Эш шуңа барып җитте ки, әлеге «обойма»га кергән язучыларның тән-
кыйтьтән өстен булулары табигый бер хәл итеп карала башлады. Нигезендә гайре
табигый булган бу хәл безнең тәнкыйтьчеләр җәмәгатьчелегенең иҗтимагый урынын
бөтенләй кирегә әйләндереп куйды — инде «обойма» категориясендәге язучылар тән-
кыйтьтән курыкмыйлар гына түгел, ә киресенчә, әдәби тәнкыйть һәм тәнкыйтьчеләр
үзләре алардан курка башлады.

Шик тә юк, «обойма»дагы язучыларның да тулаем иҗатында, яки аерым әсәр-
ләрендә, я булмаса аерым әсәрләренең аерым өлешләрендә тәнкыйть күзе белән карап
фикер йөртерлек, әсәрне камилләштерү юлында киңәш бирерлек урыннар булмады
түгел. Әмма торгынлык еллары китереп чыгарган сәбәпләр аркасында тәнкыйть алар-
ның иҗатларының бары тик уңай якларына гына игътибар итеп, ул уңай якларны
бераз күпертеп тә мактау юлыннан гына барды. Әсәрләрдәге тәнкыйтьләнәсе күре-
нешләргә тулысынча диярлек күз йомылды. Ә инде берәр тәнкыйтьче кыюлыгы
җитеп «обойма»дагы берәр әдип әсәрен тәнкыйтьләргә алынса, ул дәррәү субъектив-
лыкта, әдәби хәрәкәтнең магистраль юлларын аңламауда, әсәрне бозып аңлатырга
тырышуда гаепләнде. Әлбәттә, «чирен яшергән үлгән» дигән шикелле, мондый
хәл «обойма»дагы язучыларның иҗатлары стабиль рәвештә үсә баруга комачау итми
калмагандыр.

Реаль әдәби хәрәкәтне тәнкыйтьтә чагылдыру эшендә «обойма чире»нең тагын
бер зыянлы ягы шунда иде — тормышта үз-үзен тотышы, гадәти булмаган үзен-
чәлекле холыгы аркасында торгынлык чоры җәмәгатьчелекнең күңеленә хуш килеп
бетмәгән, ниндидер җитәкче постлары, мактаулы исемнәре һәм зур бүләкләре бул-
маган, әмма табигый талантлары аркасында әдәби хәрәкәтнең алгы сафында баручы
драматургларыбыз, прозаикларыбыз һәм шагыйрьләребезнең кайберләрен тәнкыйте-
без әлеге «обойма»га кертмәскә тырышты (янәсе «обойма»дагы исемнәр белән бу
исемнәрне янәшә кую килешми). Алар иҗаты турында гомумән сүз алып бармау,
алар турында дәшмәү юлына басты. Шигърияттә, мәсәлән, гаять кызыклы поэтик
әсәрләре булган Роберт Әхмәтҗанов, Рөстәм Мингалим, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов
иҗатлары зур, олы тәнкыйтебез өчен күбесенчә күләгәдә кала бирде. Ә инде тән-
кыйтебез тарафыннан «обойма»га кадәр үк үсеп җитмәгән дип саналучы яшь-
ләребездән бик тә үзенчәлекле шагыйрьләр Зиннур Мансуров, Ркаил Зәйдуллин,
Газинур Моратов, Нияз Акмалов, Ләис Зөлкарнәев, Асия Минһаҗева, Ләбиб Леро-
новларны җитди тәнкыйтебез сүз арасында фамилияләрен кыстырып китәргә кирәк
булганда гына искә ала. Анда да гел мактап кына. Ә бит бу шагыйрьләрнең иҗаты
инде объектив тирән анализга лаек һәм профессиональ әдәби тәнкыйтькә мохтаҗ.

Илебезнең социаль тормышына партиябезнең XXVII съезды һәм КПСС Үзәк
Комитетының соңгы еллардагы Пленумнары карарлары алып килгән үзгәртеп кору
хәрәкәте белән акны ак, караны кара дип күзгә карап әйтү мөмкинлекләре булды-
рылганнан соң инде әдәби тәнкыйтебезгә дә бер урында таптанып тору мөмкин
булмый башлады. Шуңа күрә ул мәҗбүри рәвештә диярлек үзенең төп вазифасы
булган тәнкыйть фикерен үстерү, әдәбиятыбызда дистәләгән еллар буе «өлгереп»
җитешкән негатив якларны тәнкыйтьләү ягына табан борыла башлады. Бу җәһәт-
тән әлеге «обойма» күренеше дә, социаль тигезсезлек күренеше буларак, чын,
объектив, партияле, сәнгати тәнкыйть сүзенә дучар булырга тиеш иде кебек. Әмма,
гаҗәпкә каршы, әдәби тәнкыйтебез бүгенге көнгә кадәр «обойма»дан өркүен дәвам

итә. Ләкин бүген инде тәнкыйть илдәге үзгәрешләр яктылыгында авызына су кабып та тора алмый, аңа әдәби хәрәкәтебездәге конкрет негатив күренешләрне тәнкыйтьләмичә мөмкин түгел. Менә шушы котылгысыз хәлгә куелган тәнкыйтебез, «обойма»дагы исемнәр иҗатына, яки гомумән, аерым язучыларның әсәрләренә тирән анализ ясаудан качу өчен әдәбиятыбызның аерым жанрларын тәнкыйтьләүгә күчте. Әдипләрнең һәм аларның конкрет әсәрләренең исемнәре әйтелмичә генә билгеле бер әдәби жанр гомумән тәнкыйтьләнә. Болай иткәндә тәнкыйтьчегә тәнкыйте өчен аерым язучыларның үпкәләүләре, аны төрле ярлыклар тагып битәрләүләре дә булмый, тәнкыйтьнең заманнан артка калмавы, тәнкыйть сүзе әйтүе иллюзиясе дә туа.

Соңгы өч-дүрт ел эчендә әдәби тәнкыйть тарафыннан аеруча бер мавыгу белән туздырып ташланган жанрыбыз поэзия булды. Әдәби тәнкыйтебез уйлап тапкан компромисс алым поэзия жанрының бүгенге көндәге ролен гомумән шик астына алып эш итә. Газета-журналларыбыз поэзия жанрының девальвацияләнүе, аның укучы арасында абруе төшүе, шигырь китапларының тиражы кимүе, гомумән бүгенге рухи тормышыбызда поэзия тоткан урынның тараюы турында язалар, поэзиянең көрәшүчәнлеге, сәнгати көче кимү турында сүз алып баралар. Дөрес, бу раслауларның байтагында ачы дөреслек булуы бәхәссез. Әмма бүгенге көндә поэзиянең абруе төшүгә поэзия жанры үзе генә гаепле дип раслау тамырдан дөрес булмаган караш икәне дә көн кебек ачык.

Поэзиянең торгынлык елларындагы торышы турында фикер йөрткәндә кайбер тәнкыйтьчеләребез икенче чиккә ташланып, бу елларда татар шагыйрьләре поэзияне үстерүдә гомумән катнашмадылар, ул чорда иҗат ителгән бөтен әсәр тәнкыйтьтән түбән булды дигән берьяклы бәягә кадәр барып җиттеләр. Тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин «Советская Татария» газетасында (1988 елның 10 нчы январь саны) басылган «Җәза» исемле мәкаләсендә татар поэзиясенең торгынлык елларындагы торышы турында фикер йөртеп болай ди: «Һәм әгәр шагыйрьләр күптән түгел булып үткән торгынлык вакытларында иң әһәмиятле, күңелгә иң якын булган нәрсәләр турында дәшмәгәннәр, гаделсезлекләр белән көрәшмәгәннәр, дәртләнеп ярымдөреслек турында язганнар икән, бу инде, әлбәттә, шигърият өчен эзсез генә уза алмагандыр» (татарчага тәрҗемә минеке — Г. Р.).

Поэзиябезнең узган 20-25 елдагы үткәне белән аз-маз танышып барган кеше мондый катгый, каты бәя белән килешә алмас иде. Чөнки нәкъ менә шул торгынлык еллары дип аталган ул чордагы иң негатив күренешләргә дә карамастан, поэзиянең көрәш коралы икәнен раслап Хәсән Туфанның шәхес культы башбаштаклыкларын ачыктан-ачык фаш иткән, яки ул чакта ачыктан-ачык әйтеп бирергә мөмкин булмаган фикерләрне югары поэтик һәм политик кинаяләр белән укучы күңеленә үткәргән шигырь һәм поэмалары, Сибгат Хәким иҗатының тулы бер үзенчәлекле өлеше, Нури Арсланның яңа бер яңарыш белән активлашкан иң камил һәм җитди шигырьләре, Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Әхсән Баян, Саҗидә Сөләйманова, Роберт Әхмәтҗановларның төп иҗади йөзләрен диярлек билгеләгән шигъри әсәрләре нәкъ әнә шул елларда туды. Шул елларда шигъриятебезгә бүгенге әдәбиятыбызның төп көченә әверелгән шагыйрьләребездән Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рәдиф Гатауллин, Рөстәм Мингалим, Рәшит Әхмәтҗанов, Роберт Миңнуллин, Кадыйр Сибгатуллин, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов кебек тулы бер плеяда килде. Әгәр әдәби хәрәкәтебездән бу исемнәрне алып ташласаң, яки аларның әсәрләрен ярымдөреслек дип кенә бәяләсәң, әлбәттә, инде поэзиябез тәмам бушап калыр һәм аның югары абруе турында сүз дә алып барырга мөмкин булмас иде.

Шулай итеп, бүгенге поэзиябездә тышкы яктан караганда бер-берсенә капма-каршы булып күренгән ике зарурилык күзәтелә — бер яктан шигъриятебез жанр буларак яклауга мохтаҗ, икенче яктан исемнәре «обойма»ларга кертелеп табу хәленә китереп җиткерелгән шагыйрьләребез иҗатларының уңышлары лаеклы бәяләнгән хәлдә, аларны тәнкыйди анализ аша үткәрү, алардагы поэзия үсешен тоткарлаучы күренешләрне ачып салу, һәр шагыйребезнең шигъриятгәге реаль урынын билгеләү кичектерелмәс бурыч булып тора.

## Шигъри уңышлар һәм механик күнегүләр

Исеме «обойма»ларда еш күренә торган шагыйрьләребезнең берсе Ренат Харис. Бер төркем кызыклы шагыйрь белән әлеге торгынлык елларында әдәбиятыбызга килеп кергән Ренат Харис инде бүгенге татар совет поэзиясендә иң актив, продуктив һәм сыйфатлы итеп эшләүчеләрдән, бүгенге поэзиябезне алга алып баруда иң күп көч куючылардан. Бездә шагыйрьләр күп, әмма югары сыйфатлы яңа әсәрләр иҗат итеп баручылар бармак белән генә санарлык. Бүгенге көндә аларны санаганда бер бармакны «Ренат Харис» дип бөгәргә тулысынча хакыбыз бар. Шагыйрь поэзия-

бездә үз юлыннан — тирән эзләнүләр юлыннан атлый. Аның бүгенге татар поэзиясен яңа метафоралар, яңа формалар, яңа сурәтләү чаралары белән баетудагы иҗади хезмәтен аеруча билгеләп үтәргә кирәк.

Дөньяда теләсә нинди профессиядә дә күп эшләгән кешенең эшендә уңай нәтиҗәләр бик күп булган кебек, андагы җитешсезлекләр, хәтта ялгышлар да бармакка-бармак та сукмаучы эшсезләрнекеннән күбрәк була. Актив һәм продуктив шагыйрь буларак, Р. Хариста да шулай бу. Икенчедән, Р. Харис шигърияттә, аның формасында һәм эчтәлегендә яңалыкка, оригинальлеккә, экспериментлар ясауга, башкаларга охшамаска омтылучан шагыйрь. Ә даими эзләнү ул һәрвакыт бөтен яктан да килешеп беткән нәтиҗәләр генә бирел тормый, эксперимент вакытында вариант буларак уңышсыз, теләгәннең киресе булган нәтиҗәләр дә килеп чыга. Бу урында борынгы гарәп филологы Әбү Мөхәммәднең «Шигырьнең яхшысы — дөреседер, иң ягымлысы — ялганыдыр» дигән сүзләре искә төшә. Зирәк әйтелгән бу афоризм күзлегеннән караганда, Р. Харис әсәрләре гел «иң ягымлысы» гына булып тормыйлар, киресенчә, алар тышкы яктан бик үк ягымлы булмасалар да, тормышның «дөресе»н чагылдырырга омтылалар. Шагыйрь мантыйки төгәллек белән артыграк мавыгып киткән очракларда тормыш дөреслегеннән читкә тайпылану да булып алмый түгел, әмма андый «ялган»нар автор тарафыннан эшләнгән ялган түгел, ә «шагыйранә ялган ул». Шулай да талантлы шагыйрь иҗатындагы хәтта «шагыйранә ялган»нар да, Әбү Мөхәммәд әйтмешли, «ягымлы» булып күренми. Шуңа күрә бу урында Р. Харис әсәрләренең әнә шул, тәнкыйтьчеләребез бүгенгәчә күрергә кыймаган якларына күз салып үтәсе килә.

Р. Харис иҗатында, аның эзләнүләрендә оригинальлеккә омтылып та оригиналь була алмаган, әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан инде бик күптәннән тәнкыйтьләнеп, поэзия стихиясенә хас булмаган күренешләр дә очрый. Шуларның берсе, әйтергә кирәк, Р. Харис иҗатында шактый урын тотканнарының берсе — прозаизм. Юк, мин тулысынча прозаизмга гына корылган шигырьне верлибр, ак һәм иркә шигырь белән бутамыйм, инде аларны аеруның нык сыналган юлы бар. Аларның аермасы шунда ки, тулысынча прозаизмга гына корылган шигырьне проза итеп таратып, ягъни чәчмә итеп язсаң, әсәр берни дә югалтмый. Әгәр инде ул әдәби табышларга бай булса, бары тик жанрын гына үзгәртә — шигырь дип түгел, ә парча, хикәя, эссе дип атала, я булмаса күләмлерәк проза әсәренең бер өлеше хәтерләтә. Ә инде верлибр, ак һәм иркә шигырьне берничек тә проза итеп таркатып язып булмый, алай итсәң, ул мәгънәне, логиканы югалта, грамматик һәм синтаксик кануннарга сыймый. Р. Харис иҗатында прозаизмнар белән верлибр, ак һәм иркә шигырьләрнең дә аралашып яшәве безгә шагыйрь иҗатыннан ачык мисалларга мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек бирә. Менә, мәсәлән, ике шигырь һәм икесе дә традицион формада түгел. Мин аларның икесен дә чәчмә итеп сүтеп күчерәм:

### КИТКӘННӘН СОҢ

*Яңгырдан соң бар табигать рәхәтләнеп, күкрәк киереп сулу ала. Агым су — киткән юлына ашлыкларга аш булырдай ләм сала.*

*Кешедән — оныгы онык күргәнче, матча башы күгәрмәслек өй кала.*

### БАСКЫЧЛАР

*Без нәрсә генә ясасак та, нәрсә генә эшләсәк тә, үзебезгә баскыч төзибез, басмалары буйлап йортлар, юллар сала-сала, хәнҗәр безенә баса-баса, күкрәк белән дотлар каплый-каплый, шахталарда шартлый-шартлый, космик корабларда яна-яна, ак кәгазьгә канлы шигырь булып тама-тама, әкрен генә өскә ашабыз, тырмашаак кәгазьгә канлы шигырь булып тама-тама, экрен генә өскә ашабыз, тырмаша-тырмаша хыялыбызга якынлашабыз. Без калдырган агач, таш, сүз, нур баскычлардан, безнең эзләргә баса-баса, безнең варисларга төшә табигатьнең ачылып киткән бәхеткә әверелгән сере. Без баскыч басмаларында гына бәхет белән очрашабыз! Баскыч басмаларында гына кеше тере!*

Күрәсез, «Киткәннән соң» дигән әсәрдән нәни генә, уңышлы һәм тәэсирле чәчмә парча килеп чыкты. Бу әсәрнең әдәбиятта прозаның иң кечкенә формасы, ягъни лирик парча буларак яшәргә тулысынча хакы бар. Ләкин аның формасында поэзия жанры белән берникди уртаклык та юк. Авторның матур проза җөмләләрен көчләп сындырып, 12 юлга бүлеп язуыннан гына әсәр поэзия жанрына керә алмый. Дөрес, монда шигырьгә хас рифма кулланырга тырышылган, «ала-сала-кала» сүзләре рифмалашкан. Ләкин бу фигыль рифмалары татар поэзиясендә шул кадәр күп кабатланган рифмалар ки, аларны Р. Харис кебек күренекле шагыйрьнеке итеп кабул итәсе килми.

Инде килик «Баскычлар» дигән шигырьгә. Ул шулай ук рифмасыз, тышкы яктан караганда нәкъ «Киткәннән соң» дигән шигырь кебек язылган.

Гади күзгә дә күренә ки, чәчмә итеп таратып язудан «Баскычлар» әсәре күп югалта, ул проза кысаларына сыймый. Беренче җөмләдәге образларның поэтик накал белән кабатлана-кабатлана барулары һәрберсе үзенә аерым шигъри юл сорый, җөмләләрдәге поэтик инверсияне чәчмәгә бүлеп язу шигырьнең әрәм итү, аңа миһербансыз караш булып яңгырый. Бу әсәрне нәкъ әнә шулар шигырь итә дә. Дөрес, бу шигырьдә дә зәгыйфь кенә рифма чаткылары бар (каплый — шартлый, яна — тама), ләкин шигырьне шигырь иткән төп чара ул түгел, ә шигырь юлларының һәрберсе мөстәкыйльлеккә омтылу. Ә инде Р. Харисның бары тик прозаизмга гына корылган әсәрләрендә ясалма рәвештә шигырь итеп сындырылган юллары, киресенчә, прозаик җөмлә тезелешенә омтылалар.

«Тула эшләпә», «Кайтты», «Вәлит сәгате» дигән күләмлерәк әсәрләрен автор «хикәятләр» дип атый. «Тула эшләпә» һәм «Кайтты»ны чәчмә итеп, проза белән язсаң, әсәрләр берни дә югалтмыйлар. Ә менә «Вәлит сәгате» үзенең стилистикасы буенча шигъри юллар, шигъри җөмлә тезелеше белән язылган һәм аны югарыдагы ике әсәр кебек чәчмә итеп сүтеп булмый, ул әйбәт иректә шигырь булып кала.

Р. Харис иҗатында бер төркем шигырь киң җәмәгатьчелеккә, шул исәптән авторның үзенә билгеле булган хакыйкатьне бозып аңлатуга корылган. Әйтик, «Яшим дисәң» («Замана эзләре», 163 бит) шигырендә лирик герой үз йөрәген алып, аның урынына Мәҗнүн йөрәген куя. Автор бу йөрәкне берьяклы гына — матурлыкны гына күрүче, хыялый, рәхәтлекне генә танучы итеп күрсәтә. Р. Харисның лирик герое тормышта зур авырлыклар килеп тугач бу йөрәкне ташлый, Мәҗнүн йөрәге авырлыкка түзмәс дип курка. Ләкин бу шигырь көнчыгыш поэзиясеннән бөтен дөньяга күчкән катлаулы, трагик Мәҗнүн образын берьяклы гына аңлата, гомер буе җирдә гармония, яхшылык, матурлык, мәхәббәт, хәтта идиллия булдыру турында хыялланган Мәҗнүннең шулар хакына күпме сагыш, күз яше, сыкрану кичергән гаять катлаулы, нечкәлеге белән көчле рухлы, трагик образ булуын һәм инде ничә мең еллар буе нәкъ әнә шулар белән кешелек дөньясын сокландыруын яшереп калдырырга тырыша. Менә ни өчен бу шигырь дөньяга билгеле хакыйкатьне бозып аңлата һәм шуның белән уңышсызлыкка очрый. Гәрчә тышкы язылышы белән шигырь оста кулдан үткәнлеген раслый.

«Кыска җил» шигырендә лирик герой үзен һәр нәрсәне алга этүче җил дип хис итә. Монысы әйбәт. Соңыннан ул мин вак нәрсәләрне түгел, ә зур әйберләрне алга этүче җил булсам иде ди һәм: «Көнне төн аша яктыга чыгарышкан бер җил булыйм»,— дигән теләк белдерә. Ләкин, билгеле булганча, көннең төн аша яктыга чыгуында җилнең бернинди катнашы юк, бу эш бары тик кояш һәм җирнең галәмдәге хәрәкәтләре нәтиҗәсендә генә эшләнә торган эш. Чыннан да, сыңар яфрак та селкенмәгән җилсез вакытта да көн туа ич. Бәс, шулай булгач, лирик геройның бу эштә җил булырга теләве Дон Кихотның тегермәннәр белән сугышуы шикелле бөтенләй буш эш, «җил куу» гына булып чыга. Күргәнебезчә, бу шигырьдә төннең көнгә алмашыну күренешендә җилнең катнашы булмавы кебек күптән билгеле булган хакыйкатьне бозып аңлату автор үзе үк теләмәгән нәтиҗәләр китереп чыгара.

«...Кандагы эрегән тимердән...» дип башланган шигырьдә лирик герой үз канындагы тимердән кыңгыраулар һәм корыч каләм ясауны тели. Кыңгыраулар кешене юл йөрергә чакырыр, каләм кешечә яшәүне зурлар, ди ул. Әмма, билгеле булганча, бер кешенең канынннан бик аз микъдарда гына тимер алып була, димәк, ул тимердән микроскопик каләм дә ясап булмый. Нәтиҗәдә лирик геройның теләге тормышка ашуга бернинди реаль җирлек тә була алмый һәм ул әдәби образ тудыруга комачаулый. Хакыйкатьне бозып күрсәтү аркасында бу образ җитди итеп кабул ителми.

«Бакчачыга» шигырендәге бакчачы алма бирмәячәк яки дөрес үсеп китмәгән ботакларны кисеп ташлый. Автор мондый нәтиҗә ясый: «дөресен, түгелен алмагачмы, бакчачымы шәбрәк белә?» Янәсе, бакчачы табигатьне боза, янәсе, табигатьтә бар да дөрес. Ләкин табигатьне саклау (яки алмагач образын яклау) теләге бу урында ялган раслауга корылган, чөнки чәчәк атмый торган кысыр ботаклар алмагачның сутын эчеп, аның алма бирәселәрен дә зәгыйфьләячәк. Димәк, бу ботакларны кисү алмагач өчен дә (алмалары күп булса, аңа нәсел калдыру мөмкинлеге киңәячәк, ә бу — алмагачның төп яшәү мәгънәсе), бакчачы өчен дә дөрес булачак. Менә шушы билгеле хакыйкатьне белү аркасында укучы бу шигырьнең фәлсәфәсенә ышанмый.

«Шигырь турында шигырь» дигән әсәр тәнкыйтебез тарафыннан һәрвакыт диярлек макталып килгән булуына карамастан, һәркемгә билгеле, ачык хакыйкатьне бозып күрсәтүгә аеруча ачык мисал булып тора. Бу шигырьдә автор: шигырь — күңел чәчәге генә түгел, чөнки чәчәк өчен җирдә «беркемне дә, беркайчан да

үтергәнне тарих белми!» — ди. Әмма бит автор санап киткән Рудакиның, Пушкинның, Тукайның, Гарсиа Лорканың, Назыйм Хикмәтнең шигырьләре — аларның күрәшүче, бөек дәреслекне аяусыз рәвештә даулаучы, җирдә матурлык һәм хаклыкны раслаучы күнел чәчәкләре! Өстен катлау вәкилләре бу шагыйрьләрне нәкъ әнә шундый курку белмәс, даһи күңел чәчәкләре һәм бары тик аларның гына күңел чәчәкләре булган шигырьләре өчен трагик язмышларга дучар иткәннәр. Автор бу шигырьдә әнә шул хакыйкатьне бозып, ягъни шигырьнең иң бөек күңел чәчәге икәнлеген шик астына салып эш итә. Шуңа күрә бик тә көчле, киң диапазонлы бу шигырьне укып чыкканнан соң күңелдә олы социаль-эстетик хис белән бергә, йөрәкне тырнап-тырнап бер канәгатьсезлек тойгысы да кала.

Р. Харисның шигъри алымнарында очрый торган тагын бер күренеш — уңай итеп кулланып та укучыда кире эмоция тудыра торган сурәтләр, образлар. Алыйк оста кул белән язылган «Пумала» шигырен. Авторның әйтүе буенча, рәссам үз әсәрләрендә мизгелне туктата, шуңа күрә рәсемдәге кизәнгән кул мәңге сукмый, каргарга ачылган авыздан аваз чыкмый, шул ук вакытта кочарга теләгән кочак та мәңге буш, үбәргә теләгән ирен дә мәңге ялгыз, йөкле хатын карынында ничә йөз яшьлек тумаган бала. Сәнгатьне, рәсем сәнгатен болай аңлату тарлыкка, бары механик, матди раслауларга, ә рухи бушлыкка алып барыр иде. Чөнки бит һәркем белә, моннан мең ел элек иҗат ителгән рәсемдәге кочак (әлбәттә, талантлы картина турында сүз бара) мәңге буп-буш түгел, ул Мәңгелек мәхәббәт белән туптулы, карында — йөз яшьлек тумаган бала түгел, ә кешелек дөньясының үрчемгә, дәвамлылыкка булган тыелгысыз омтылышы. Юк, оста рәссам мизгелне туктатмый, ә логик, эстетик, сәнгати яктан киләчәккә, мәңгелеккә табан дәвам итә. Автор уңай сурәтләү алымы дип башлаган образлар кинәт авторның үзенә каршы килә башлыйлар, автор теләмәгән нәтиҗәләргә китерәләр.

«Бер дустымны уң җилкәмә күтәрдем...» дигән шигырьдә дә шул ук хәл:

*Бер дустымны уң җилкәмә күтәрдем,*
*Бер дустымны менгердем сул җилкәмә.*
*Икесе ике иңемә бастылар,*
*Аяк тибеп әрләштеләр иң әүвәл,*
*Җиң сызганып алыштылар аннары,*
*Кылыч алып сугыштылар бик яман.*
*Кылычка кылыч чаптылар.*
*Чаткылар*
*Чәчрәде дә минем чәчне көйдерде.*
*Кизәнеп тә тогәл чапмаган чакта*
*Кылычлары кадалды минем башка.*

*Сугыштылар...*
*Арыдылар...*
*Тындылар...*
*Тотындылар, аумаска, минем башка —*
*Куллары минем каныма буялды.*
*Чиркандылар...*
*Төштеләр иңнәремнән.*
*Икесе бер ук инешкә киттеләр.*
*Кул юдылар, хәл алдылар бергәләп...*
*Ялгыз калдым яу үткәргән кыр кебек.*
*Күңелемә канлы-яшьле җыр тулды...*

Күрәсез, лирик герой ике дустын ике җилкәсенә бастырып сугыштыра. Һәм ике дусны дошманлатучы, котыртучы, сугыштыручы ролен үти, чөнки шигырьдә аларны килештерергә омтылыш юк. Әлбәттә бу котыртучының үзенә дә эләгә, теләр аның чәчләрен көйдерәләр, башына кылыч белән дә чапкалап алалар. Ләкин шунысы гаҗәп (хәтта бераз аптыраш та): автор шушы лирик геройны мактый, кызгана һәм хаклы саный, янәсе тегеләрнең бөтен ачуы моңа төшә. Ә нигә соң лирик герой аларны иңнәреннән алып болай сугышырга ярамаганлыгын аңлатмый икән?

«...Минут саен гашыйк булып...» шигыренең ахырындагы шагыйрь: «Ә йөрәк башны үз буем җитмәслек биек чөйгән»,— ди. Әлбәттә, автор лирик геройның бөек акыллы булуын расларга тырыша. Әмма образ төзү белән саксыз эш итү югарыдагы ике юлдан карикатура ясый, гәрчә бу шигырь һич кенә дә юмористик планда язылмаган.

Югарыда карап үтелгән прозаизм һәм билгеле хакыйкатьне бозып аңлатуга корылган шигырьләрнең туу сәбәпләре Р. Харисның эзләнүләрдә, экспериментларда бераз арттырып җибәрүендә, чаманы тоймау яки махсус тоймаска тырышуында, оригинальлеккә омтылудагы чикләрне билгеләп бетермәвендә түгел микән?..

Кайбер әсәрләрендә Р. Харис, киресенчә, бөтенләй эзләнмәгәндәй тәэсир калдыра, поэтик сурәтләү чаралары һәм поэтик гомумиләштерүләрдән башка гына эш итә. Мәсәлән, Мондый шигырьләр акны ак, караны кара дип раслауга гына корылган. Мәсәлән, «Даимилек» дигән шигырьдә автор, зәңгәр күзле кеше нинди генә халәттә дә зәңгәр күзле булып кала, ди:

*Йөрәгеңә наз тутырып бакканда да*
*Күзләр зәңгәр.*
*Моңлы күлдәй мөлдерәшеп ятканда да*
*Алар зәңгәр.*
*Янар таудай, нәфрәт уты атканда да*
*Алар зәңгәр.*

*Өметсезлек томанына батканда да*
*Алар зәңгәр.*
*Чишмә булып илһам куры акканда да*
*Алар зәңгәр.*
*Мәңге-мәңге ачылмаска ябканда да*
*Күзләр зәңгәр!..*

Шушы гап-гади раслауны укыганнан соң укучыда сорау туа — күзнең зәңгәр төсе ничек үзгәрә ала соң? Зәңгәр күз шатланганда — кызыл, кайгырганда — кара, сагышланганда сары төсләргә керә алмый бит инде. Бу шигырьдә автор күз төсенең даимилеге кешенең үз холкыннан, көрәшүеннән, принципиаль характерлы булуыннан түгел икәнлеген, күз төсенең гел зәңгәр булуында аның хуҗасының бер катнашы да юк икәнен искә алмый, яки махсус рәвештә искә алмаска тырыша. Шуңа күрә шигырь гомумиләштерү көченә ия була алмый, ул бары тик зәңгәр күзле кешене зәңгәр күзле кеше дигән раслауга гына кайтып кала. «Бура бураганда» дигән шигырь бүрәнәгә бүрәнәне куйсаң өй була дигән гап-гади хакыйкатьне шигырьсез, сәнгатьсез кабатлауга гына корылган:

*Тотынышса бүрәнәгә бүрәнә,*
*Бүрәнәләр сыенса бер-беренә,*
*Гаиләгә оя була — өй туа...*
*Яшә, кеше, үз бәхетең түрендә.*

*Гашыйкларның бармаклары тоташса ,*
*Бурадагы бүрәнә күк, бу чакта*
*Бәхет өчен оя була — өй туа...*
*Яшә, шатлык, гашыйкларны кочаклап.*

Р. Харисның чордаш шагыйрьләреннән аермалы буларак тагын бер уңышлы ягы — аның тематик яктан аерым төркемнәргә тупланган шигырь цикллары иҗат итүе. Бу өлкәдә авторның поэма остасы буларак бөтенлеккә, зуррак күләмнәргә омтылуы сизелә һәм ул бу юлда уңышка да ирешә. «Дәрдмәндкә назыйрәләр» циклы моның иң матур үрнәге. «Бизәк» циклы да әйбәт, традицион, кешечә, табигый. «Яралар» циклы бөтенлеге белән аеруча көчле.

Р. Харис соңгы елларда поэмалар өлкәсендә аеруча сизелерлек уңышларга иреште. Бу жанр шагыйрь иҗатының магистраль юлын билгели. Әле күптән түгел генә матбугатта басылып җәмәгатьчелек арасында уңай бәя алып өлгергән «Борылышта» поэмасы шагыйрьнең бу жанрда һаман алга баруы турында сөйли.

Авторның элегрәк иҗат иткән поэмаларына килсәк, «Сабантуй», «Ант суы», «Мулланур», «Рәссам», «Камил Якуб», «Җитмеш икенче ел икмәге» дигән поэмаларның Р. Харис иҗатының гомуми йөзен билгеләүче әйбәт әсәрләр икәнен билгеләп үтми мөмкин түгел. Аларның бүгенге татар совет поэзиясендә үз урыннары, ныклы урыннары бар.

«Ат иярләү» поэмасы шагыйрьләр җәмәгатьчелеге арасында җитди бәхәсләр тудырды. Чыннан да, поэма язылышы белән көчле, оста кулдан үткән әсәр. Әмма анда автор тормышта, фәлсәфәдә, фикер йөртүдә булган реальлекләр белән поэтик логика аша түгел, ә үзе теләгәнчә эш итә. Бу — әсәрдәге төп, үзәк күренеш булган сугышка җибәрелгән атның качып өйгә кайту вакыйгасына карый. Бу хәлне автор дезертирлык дип бәяли. Әмма бит, чынлыкта ат, ат буларак, сугышырга кирәк икәнне аңламый, аның кире кайтуы — абзарын, печәнен, хуҗасын, туган җирен сагынудан гына. Монда автор табигать тарафыннан атка бирелмәгән акыл таләп итеп дөрес эшләми. Бәлки, автор атны Кәрамның яшерен уйлары, эчке халәте символы итеп алырга телидер? Әмма безнең халыктагы традицион ат образы әдәби, фольклор, халык көнкүреше традицияләре ягыннан да, психологик яктан да бу символны, нәкъ менә дезертирлык символын, чагылдыра алмый, бездә ат, киресенчә, патриотлык, батырлык, сугышчанлык символы. Менә шуның аркасында, поэма шигъри техника ягыннан сүз тидермәслек язылуына да карамастан, тормыштагы чын реальлеккә каршы бара һәм күп укучыда канәгатьсезлек тойгысы калдыра. Кәрамның йөкле хатынны сугып егуы исә бик зур кансызлык булып яңгырый.

Эксперименталь эзләнүләр кайчакта Р. Харис иҗатын образ эзләүдәге механик күнегүләргә кадәр китереп җиткерә. Ә шигырьдә мондый аңлы рәвештә механик алымнарга күчү шигырьнең үтемлелегенә, аның сәнгатьлелегенә, поэзиягә генә хас булган тәэсирчәнлегенә зур зыян китерә. Бу урында келт итеп Рубик кубигы язмышы искә төшә. Бу кубик белән кыска гына вакыт эчендә бөтен дөнья мавыкты, бөтен дөнья халкы шул кубикны боргалады. Әмма уен дөньяны шундый ук кыска вакыт эчендә туйдырып та өлгерде, бүген инде бу кубикны бармак белән санарлык кешеләр генә боргалый.

Механик күнегүләргә генә нигезләнеп язылган шигырьләр дә тышкы яктан гына кызыклы, гайре табигый булып күренәләр. Шуңа күрә укучыда мондый әсәрләр белән кызыксыну ничек кинәт кабынып китсә, шулай кинәт сүнеп тә куя.

Әлбәттә, 25 еллык иҗат тәҗрибәсе булган шагыйрь Ренат Харис поэзиядә бу хакыйкатьне яхшы аңлаган хәлдә эш итә. Иң әһәмиятлесе шунда: ул иҗатта мондый алым стихиясе колы түгел, киресенчә, шагыйрьнең әдәби белеме, сәләте һәм тәҗрибәсе үзе бу стихия белән идарә итәрлек дәрәҗәдә. Шуңа күрә ул бу алымны бары тик әдәби һәм сәнгати яктан камил, заманга аваздаш һәм поэзиябезне алгы көннәргә лаеклы алып барырлык әсәрләр иҗат итүгә генә куллана ала.

Библио-графия

# ШИГЪРИ ТЕЛДӘ УЙЛАНУ

**Юзиев Н. Мир поэта. Казань, Татарское книжное издательство, 1987.**

Күптән түгел күренекле әдәбият галиме, филология фәннәре докторы Нил Юзиевнең «Мир поэта» исемле китабы басылып чыкты. Аны русчага Энгель Нигъмәтуллин тәрҗемә иткән.

Автор татар совет поэзиясенең иң күренекле вәкилләре Һади Такташ, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким иҗатларын анализлауны һәм аларның катлаулы, нечкә поэтик иҗат эволюциясен җанландырып күрсәтеп бирүне бурыч итеп куйган. Шунысын да билгеләп үтик, әлеге классикларыбыз хакында инде аз язылмаган. Шул исәптән Нил Юзиевнең үзенең дә бу әдипләребез иҗатын анализлауга яңа алынуы түгел. Китаптагы әлеге дүрт иҗат портреты — тикшеренүченең утыз елдан артыкка сузылган уйлануларын үз эченә ала. Әмма хикмәт, билгеле, өйрәнүнең озак еллар буена дәвам итүе һәм бай фәнни чыганакларга таянуында гына түгел. Китапның төп уңышы, миңа калса, авторның анализ методында, тикшеренүнең фәнни системасында.

Нәрсә ул анализ методы? Әдәбият белемендә шулай ук зур кыйммәткә ия мени соң ул? Аңа ничек ирешергә? Һәркем дә җиңел генә үзләштереп алырлык әзер бер күрсәтмәсе юкмыни аның?!

Тормышта без төрле чынбарлык күренешләре белән очрашабыз һәм аларны әйбәтрәк күзаллар өчен, тирәнрәк аңлар өчен, табигый ки, тиешле күзәтү ноктасы, билгеле бер өйрәнү аспекты сайлап алу мөһим. Әйтик, китаптагы рәсемнәрне карарга 30—40 см ара кирәксә, Идел буендагы Ослан тауларының бөтен матурлыгы исә бары дистә километрлардан гына ачылып китәргә мөмкин. Күзәтү коралларын да без һәрвакыт өйрәнү объекты хасиятләреннән чыгып сайларга тырышабыз: ауга чыксак, кулыбызда — бинокль, йолдызларны барлаганда, телескопка төбәләбез, күзәнәк, микроблар тормышын өйрәнгәндә, микроскоптан файдаланабыз.

Әдәбият белеменең дә өйрәнү аспектлары һәм күзәтү офыклары гаять дәрәҗәдә төрле. Әдәбият галиме материал белән эш иткәндә бик күп төрле анализ методларына мөрәҗәгать итә: текстология, тарихи һәм социаль аспектлар, язучының иҗат методын тикшерү, идея-тематика, психологик, эстетик анализлар һ. б. Шунысын да әйтеп үтик, әдәби әсәрләрнең специфик асылын аңлауда әлеге анализ методларының соңгы икесе аеруча зур роль уйный. Кызганычка каршы, әдәби тәнкыйтебездә иң аз мөрәҗәгать ителгән һәм файдаланылган аспектлар да нәкъ әнә шулар. Ни хикмәттер, безнең әдәбият фәнендә һаман әле әсәрләрнең социаль җирлеге, иҗат методы яисә идея-тематик яңгырашы белән генә мавыгу төп урынны алып тора. Зур классик язучыларыбызнең психологик нечкәлекләре дә, сәнгатьле фикерләү үзенчәлеге дә, шигъри осталыклары да бер читтәрәк торып кала. Менә шундый чакларда микроскоптан күрәсене телескоптан күзәтү, гади күз белән рәхәтләнеп карау урынында бинокль белән әвәрә килү кебек тәэсир туа да инде.

Нил Юзиевне бик күп әдәбият галимнәреннән аерып куйган сыйфат та, миңа калса, әнә шунда: ул иҗат психологиясенең четерекле лабиринтларыннан да, шигъриятнең тылсымлы шартлылыгыннан да курыкмый. Киресенчә, аларны төп игътибар үзәгенә алып, сизгер йөрәге, ачык фикере, фәнни сабырлыгы белән ныклап өйрәнә, эчтә яткан энҗе-асылташны эзләп таба, үзенең укучысына да шушы серле җәүһәрне күрергә ярдәм итәргә омтыла. Иң әһәмиятлесе шунда, әлеге психологик һәм эстетик күзәтүләрен ул башка анализ методлары белән табигый төстә бергә үреп җибәрә белә. Анализ методларыннан комплекслы бөтенлектә файдалану әдәби тәнкыйть практикасында тагын да сирәгрәк очрый торган күренеш. Нил Юзиев шушы күпкырлы осталыкка ирешкән әдәбият белгечләреннән берсе — катлаулы әдәби процессларның текстологик, тарихи-социаль, психологик һәм эстетик чагылыш бөтенлеген тирән тойган, аларның яшәеш закончалыкларын ачык күзаллаган теоретик галим. 1974 елда «Татар совет поэзиясенең поэтикасы» темасына докторлык диссертациясе яклавы да әнә шул хакта сөйли. Кыскасы, әлеге галим кулында әдәбият белеменең универсаль анализ алымнары бергә тупланган һәм ул

алардан әлеге китабында бик иркен файдалана. Төп тикшерү объекты итеп алынган классик шагыйрьләребез иҗаты укучы күз алдында күп яклы булып, тулы канлы булып, шигъри җанлылыгын югалтмаган көе яшь башлый.

Минемчә, татар совет әдәбият белемендә әдипләрнең эчке поэтик рухын тоемлауда мондый тирәнлеккә һәм бөтенлеккә әле беркемнең дә ирешкәне юк. Әлеге китапның төп кыйммәте шунда.

Кем ул шагыйрь? Үз чоры һәм киләчәк буыннар каршында аның бурычы нәрсәдән гыйбарәт? Автор үзенең укучысы алдына әнә шул сорауны куя һәм бер шагыйрьдән икенчесенә күчә-күчә, үзе тоемлаганча, үз логик фикерләвеннән чыгып, җавабын да бирергә омтыла. Иң элек безнең алдыбызда классик шагыйрьләребезнең гап-гади балачак тормышлары, ашкынулы үсмер һәм уку еллары, зур хыяллар белән әдәбият дөньясына килеп кергән беренче адымнары күздән кичә. Шунда ук без булачак әдипнең иҗатына нигез булып ятасы төп характер һәм шәхес үзенчәлекләрен дә төсмерләп алгандай булабыз. Бу субъектив башлангычлар, ниһаять, олы тормыш эчендә барган җитди көрәш агымнарына килеп кушыла. Шагыйрь иҗат иткән чор, заманның үзәк проблемалары, әдип яшәешендәге тормыш материаллары, аларның иҗатчы күңелендә сәнгатьле фикерләү закончалыкларына буйсынып үзенчәлекле чагылышы, иҗат лабораториясендә миллион йөрәкләрне кузгатырлык сәнгать көченә — шигъри сүзгә әверелүе, гомер юлындагы аерым проблемаларны бербөтен процесс иткән иҗат эволюциясе барлыкка килү, аның милли һәм дөнья әдәбияты үсешендәге урыны һәм әһәмияте — галимнең әлеге китаптагы төп өйрәнү аспектлары әнә шулар.

Гади бер тормыш авазыннан башланып, киңәя, тирәнәя, катлаулана, көчәя барган симфоник әсәр сыман, анализдагы поэтик фикер дә күз алдыбызда әнә шулай үсеп, олы чынбарлыкка килеп тоташа. Шунысы мөһим, биредә теге яки бу шагыйрьнең индивидуаль үзенчәлеге генә ачылып калмый. Бу төрле иҗатлар анализда үзара янәшә куелып, үзара керешеп, поэзиябезнең гомуми үсеш тенденцияләрен дә бик ачык чагылдыралар. Традиция һәм новаторлык кебек катлаулы диалектик бөтенлекне ачыклау, шул рәвешчә, китапның лейтмотивына әйләнә һәм «Кем ул шагыйрь?» дигән сорауга без бер үк вакытта конкрет һәм шунда ук фәлсәфи аспектта да төгәл җавап табып алгандай булабыз. Шулай итеп, Такташ, Җәлил, Туфан, Хәким иҗатлары халкыбыз рухының, халкыбыз намусының югары бер поэтик чагылышы булуына төшенәсең. Авторның анализда аларны еш кына Тукай иҗаты белән бәйләп, аның лаеклы дәвамнары итеп күрергә теләве дә, һичшиксез, бер дә юкка түгел. Наҗыйм Хикмәтнең «татар теле — бөек шагыйрьләр теле» дип әйткән мәгълүм сүзләре дә бу очракта аерым бер конкретлык алып, реаль мәгънә белән кабул ителә.

Һәр шагыйрьнең индивидуаль һәм гомуми иҗат йөзен билгеләгән үзлекләргә биредә махсус тукталып тормыйм — алар белән танышу укучыга зур сөенеч китерәчәген белгәнгә, алдан сөйләп аның ямен кимәтәсем килми. Шуңа да, шагыйрьләребезнең поэтик ачышлары дөньясында сәяхәт итүне укучыларның үзләренә калдырып, китапның гомум принципларын һәм әһәмиятен әйтеп китү белән чикләнергә уйлыйм. Әмма, шулай да, биредә китапның тагын бер үзенчәлеген — аның тәрҗемә хезмәт булуын тагын бер кат ассызыклап үтү сорала дыр мөгаен. Н. Юзиевнең әлеге чын мәгънәсендә комплекслы анализга таянып эшләнгән әдәби иҗат портретларын рус укучысына тәкъдим итүнең шулай ук, минемчә, зур әһәмияте бар. Ни әйтсәң дә бездә үз әдипләребезне пропагандалау — бигрәк тә шундый югары профессиональ дәрәҗәдә язылган фәнни хезмәтләр ярдәмендә пропагандалау — бик сирәк очрый торган хәл. Димәк, мәсьәләнең бу ягын да исәпкә алмыйча һич ярамый.

Тәрҗемә тулаем әйбәт тәэсир калдыра. Авторның төп фикерләре, эмоциясе-рухы рус укучысына да бөтен көе барып җитәр дип ышаныйк. Әмма тәрҗемәдәге кайбер төгәлсезлекләрне дә күз йомып үткәрү дөрес булмас. Алар бигрәк тә Такташ шигырьләрендә ачык күзгә ташлана.

Такташ шигырьләре, гомумән, русчага бик начар тәрҗемәдә чыгып килә. Кызганычка каршы, алар бу китапка да — сайланма үрнәкләр белән эш итә торган китапка да үтеп кергән:

*Эх!*
*Вьюга февральская выла на поле вчера еще,*
*Тонкий и стройный сегодня к нам март*
*пришел.*
*Слушаю мартовский ветер, снега*
*пожирающий.*
(Л. Мартынов тәрҗемәсе)

Такташның:
*Их!*
*Кичә генә әле февраль иде,*
*Бүген давыл кырга кар ташый;*
*Март аеның нечкә билле җиле,*
*Сузлып ятып җиргә, кар ашый...*

юлларын укучылар хәтерлиләр булыр. Күрәбез, «художестволы яктан эффектлы образ»га (56 бит) үрнәк итеп китерелгән бу мисал тәрҗемәсе бер дә Такташ файдасына сөйләми.

Китаптагы мондый житешсезлекләр, һичшиксез, аның төп әһәмиятен югалтмый. Хезмәтнең җитдилеге һәм нечкәлеге дә, тирәнлеге һәм ныклы фәнни системага тая-

нуы да, материалның җанлы, эмоциональ биреләше дә — барысы да күз алдында. Шагыйрьләрнең якты поэтик дөньяларына алып кереп, укучыны сокландырырга, сөенергә, уйландырырга этәрүе белән китап зур эш башкара. Күпмедер инде таныш та, ә кайбер яклары белән әле яңа ачылып киткән бу шигъри дөньяларга кереп, оныталып йөрисең. Чөнки сине алга чакырып, ышанычлы дус булып, галимнең шигъриятле логик фикере бара. Шагыйрьләр дөньясы белән шигъри телдә уйлана белгән галим монда, әйтерсең лә, бер бөтенгә әверелә һәм шигырь гармониясен генә түгел, рухи — акыл гармониясен дә якыннан тоярга ярдәм итә.

**Равил КУКУШКИН**

# КЫЙГАК-КЫЙГАК... ҖАН КЫЧКЫРА

**Яруллин Ф. «Җилкәннәр җилдә сынала». Татарстан китап нәшрияты. 1986.**

Бер әдәби мәҗлестә доклад ясаганда, язучы М. Галиев Ф. Яруллинның «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра» повестен уңышсызлар рәтенә кертте. Төп дәлиле болайрак яңгырады аның: хатын-кыз Сәхия кебек булырга тиеш түгел. Мин андый хатын-кызны яратмыйм (?).

Бу хәлгә исем китеп, повестьны кабат укып чыктым. Чынлап та, повестьта сурәтләнгән хәлләр һәм кешеләр романтик алсу күзлек кигәннәргә әчпошыргыч булып, алтын кысалы «эстет» күзлектән караучыларга тупас, примитив булып күренер...

Яки менә заманында кайбер үтә «уяу» тәнкыйтьчеләребез колактан төшермәгән җете социаль күзлек. Киеп карыйк әле.

Башта Яруллинның мактаулы «Җилкәннәр»енә («Җилкәннәр җилдә сынала» повесте) күз төшерәбез. Ярый, бата. Әсәр герое Фәнияр — Корчагин түгел анысы. Уяулыкны җуеп, егылуы да начар. Тик яхшымы-яманмы, көрәш сафына әйләнеп кайта.

Ә менә бу сәер әсәрдә — «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра»да — ни сурәтләнә? Шайтан белсен! Авылда бер гаилә яшәп ята. Эти кеше, ярый инде, Ватан сугышында үлеп кала. Анда да авырып әле. Әниләре суга бата. Шәхси милекләрен юганда. Ике кызның берсе бала арты бала табып (ирсез!), аларны бер-бер артлы ташлый да тора. Ә икенчесе (әсәрнең героинясы!) нинди-дер ирдәүкә имеш.

Шулай итеп, сыйнфый көрәш аспектыннан гына караганда повестьның куәте нольгә тигез. «Киләчәк бинасын кору» җәһәтеннән карасаң да бик сөендерми ул. Әсәр героинясы Сәхия эш дигәндә булдыра анысы. Тик аның аң дигәне ташка үлчим. Иҗтимагый активлык исә аннан бөтенләй читтә йөри.

Төп персонажлары хатын-кыз дип, хатын-кыз язмышы ягыннан күз салсак, тагын шаккаткыч хәл. Арада бердәнбер язмыкүпме бәхетлесе — теленнән алланы төшермәгән Зәйнәп әби.

«Кыйгак-кыйгак каз кычкыра»да игътибарны хатын-кыз язмышының авырлыгына юнәлтү — Фәнис Яруллинның язучы булларак кыюлыгы ул. Соңгы җөмләне язганда, берәүнең дугаланып күтәрелгән кашын күргәндәй, ачулы тавышын ишеткәндәй булдым: «Ничек була инде болай — совет хатын-кызларының авыр язмышы?!» Чынлап та, ничек?

*Мин, бәхетле бала булсам,*
*Ир бала булыр идем...*

— иске тормышка сугылган кара тамга булып, үткәндә калмадымыни бу җыр?

Балачактан кара айгырның колагын кисеп алган, соңрак куәтле тимер айгырларны авызлыклаган, пенсия яшендә дә «җен калтырчасы»на атланып дөнья айкаган Сәхиянең көчле-тәвәккәл кулларын бәхет байталы нигә санламый?

Әйе, нәфис зат хәзер ирләр белән тигез яки хәтта аны уздырып җиләү хокукы алды. Ә эштән соң? Бу тигезлек гаиләдә дә сакланырга тиешме? Саклана, нидән гыйбарәт булыр ул? Юган тәлинкәләр саны тигезләгеннәнме? Рәсми оешмалар бу мәсьәләгә катнашмады. Матбугатта ике якның ут чыгарып сугышуына әйләнгән «тикшерүләр» дә берни бирмәде. «Инструкция» көтеп арган ханымнар исә инициативаны үз кулларына алдылар: үлчәүнең ир-ат утырган тәлинкәсе бик тиз өскә чөелде, җиңеләйде. Нәтиҗәдә... хатын-кыз «проект»тан тагын да ераклашты. Ә өмет ителгән бәхет урынына менә болар килде: рак ашаган күзәнәкләр сыман тиз таркалган гаиләләр, хатыннарның ир-ат белән һәм гомумән тормыш белән мәңгелек сугыш халендә яшәве, дискомфорт...

Сәхияне әдип безгә гыйбрәт өчен биргән. Аң булыгыз, нәрсәне дә булса үзгәртмәсәк, киләчәктә янибызда әнә шундый «Сәхи», «Зөлфи», «Зөлхи»ләр генә булачак дип кисәтүе бу аның. Ләкин, юк, Сәхияне бармагыннан суырып чыгармаган ул! Тормышта аларның күпкә тупасрак вариантлары да булу сер түгел ләбаса. Хәтта Сәхиянең иң гайре табигый тоелган ягы — егетләр белән сугышып йөрүенә кадәр чынбарлыкка каршы килми. Казан урамнарында очраган бер ир-атны кыйнап йөргән кызлар турында үзәк матбугатта да язылды.

Повестьта тагын берничә хатын-кыз образы бар. Аларны мин Сәхия аша куелган сорауга җавап дип түгел, бәлки бу сорауны

беркадәр ачыклый төшү дип аңладым.

Өметләнгән-хыялланган, бәхетемә таба чабам дип уйлаган адәм балаларының тагын берничәсе. Хатын-кыз булып яшәү вариантлары. «Дөньяның әле бер ертыгын, әле икенче тишеген ямап, монысын булдырыйм, тегесен җиткерим дип» яшәгән, иртән берәрсенең морҗасыннан төтен алданрак чыкканны күрсә дә ашы аш булмаган, уракта берәрсе үз артыннан куып җитсә, йөрәге ярылачак Мәгъдәния... Аның турында бары бер-ике биттә генә сөйләнә. Бәеттән төшкән якын туганың булып күз алдына баса, җәрәхәт булып йөрәккә уелып кала ул. Уйга да сала. Үткән заманның уңган киленнәре «сериясенең» төгәлләнеше һәм бүгенге «диктатор» хатыннарның башы түгел микән бу апа?

Тормыш Мәгъдәния вариантын берьюлы ике тапкыр сызып ташлый. Дөнья көтәм дип кирәгеннән артык ашкыну аны язгы суга агызып алып китә. Ире Локман исә киндер сугу станын тураклап ташлый, җеп йомгакларын утка ата. «Тотынмагыз,— ди ул кызларына.— Дөньяның тишек-тошыгын барыбер ямап бетереп булмый. Әнә, үз гомерендә бер кием бияләй бәйләп кимәгән Мөгелсемнәр да ачка үлми».

Икенче чиккә ташлану бу. Миңа шулай тоела: көйләп-җырлап бәйләм бәйләү, чигү чигү я әбиләре-әниләреннән мирас булып калган башка хатын-кыз эше кызларның күңелләрендәге сагышлы бушлыкны тутыра төшәр, аларга беркадәр юаныч һәм таяныч булыр иде...

Авторның үз күңеленә якын вариант — Зәйнәп әби. Киң күңелле, шәфкатьле булу өстенә, зирәк тә ул... Баздан бәрәңге чыгарганда, Сәхия белән Сәкинә сүзгә киләләр дә, бәргәләшә үк башлыйлар. Шул вакыт Зәйнәп әби килеп керә. Дипломлы педагог бу очракта ни әйтер иде икән? Зәйнәп әби исә болай ди: «Менәтерәк минем уңганнарым нишләп ята икән! Әйбәт, әйбәт, балалар! Бик вакытлы тотынгансыз.» Бу аның эш турында әйтүе, ә тегесе турында ләммим. Шуннан, үпкә-сапкаларын онытып, бәрәңге беткәнче баш күтәрми эшли кызларың!

«Вак-төяк!» дип, кул гына селтәр замана киленнәре. Менә шундый вак-төякләргә өйрәнегез әле сез — ул чагында «гаилә бәхете» дигән эре «төяк» тә кулыгыздан ычкынмас.

Юк, автор һич тә туташлар һәм ханымнарны шәригать кушканча гына яши башларга өндәми. Бу аның Зәйнәп әбигә хас динилекне Сәкинәдә өнәмәвендә үк күренә (гөнаһтан курыккан Сәкинә гөнаһ арты гөнаһ эшләп тора). Үткән буыннар туплаган тәҗрибә һәм әхлак мирасыннан йөз чөермик: сандыкта бик-бик кыйммәтле энҗегәүһәрләр бар дип әйтүе бу аның.

Сәкинәне «табигать авазы», инстинкт харап итүен аңлаган Сәхия үзенең хатын-кыз киемнәрен утка томыра. Тагын икенче чиккә ташлану инде. Сукмак бу юлы да уртадан үтәргә тиеш. Тик... җиңел микән ул күкрәкләре тулышкан кызыйларга акыл белән дәрт арасыннан атлап барулары? Җиңел түгел!— Трактор бригадасы ашчысы Тәлиганың ак кофтасындагы майлы бармак эзләре әнә шулай дип кычкырып тора.

Сәхия бәхеткә юлны күкрәге белән ярмакчы, тормышта көч-ярсуына таянмакчы. Бу җәһәттән ирдәүкә дигән даны чыкмаган хатыннар арасында да тарафдарлары аз түгелдер аның.

Сәхиянең күргән төше кызык. Мәрхүмә әнисе аңа болай ди: «Яшәү берәүгә дә җиңел түгел. Авыр дип эчкә ачу җыйма. Ачулы кеше — көчсез кеше». Туктаусыз башыннан сыйпап торуы да кызына сабырлык, йомшаклык бирергә теләү кебек.

Мәгъдәниянең холык-фигыленә бик туры килеп бетмәгән әлеге төшне мин үземчә «юрадым». Бу — соңарып килгән татар акылы, кабер генә төзәткән үҗәтлек авазы. Бу — гомерләрен ирләре белән көрәшкә әйләндергән кайберәүләрнең, тел очында йөртеп тә, үзләре белән кабергә алып киткән сүзләре: «Балам, мин дөрес яшәмәдем, гел дуамалга бардым. Хаклы түгел икәнемне белә идем, тик дөньялыкта моны танырга горурым карышты. Син берүк андый була күрмә!..»

Яңгыравык сүзләргә, берсеннән берсе җитдирәк термин-атамаларга уралып, абстрактлашып беттек, төшенчәләрнең асыл мәгънәләрен җуйдык бугай. «Кеше» дигәндә дә үзебезне яки күрше Гыйльменисаны түгел, ниндидер «горур яңгырый торган» әдәби персонажны яки теле-кино кешене күз алдына китерәбез. «Матур тормыш төзү» хакына ямьсезләнеп-тәмсезләнеп бетәбез. Онытабыз: якты киләчәк геройларын күктән иңгән фәрештәләр түгел, акыл һәм дәрт арасында чәбәләнгән бүгенге кызыйлар тәрбияләп үстерәчәк бит. «Анадан башка шагыйрь дә, герой да юк»— дигән М. Горький.

Димәк, Фәнис Яруллин һич тә тормышның үткен мәсьәләләреннән качмый икән. Аның каләме, хирург скальпеле кебек, яшәешебезнең кан саркыган җәрәхәтенә төбәлгән икән.

Чын хирург кебек, әдип тә аяусыз: шешне ул төбенәчә яра. Югыйсә, әсәренә якты буяулар да өсти алган булыр иде ул. Әйтик, Сәхиянең антиподын — «Үрнәк вариант»ны да иҗат итеп. Яки, кайберәүләр киңәш иткәнчә, повестьның азагына Сәхияне «гүзәл аккошка» әйләндереп. Тик болай иткәндә, язучы сугасы чаң көмеш чыңлы кыңгырауга әйләнеп калыр иде шул. Өстәвенә бу әле тормыш чынлыгына хыянәт итү дә булыр иде. «Чын» хатын-кызның нинди булырга тиешлеген без үзебез дә

шәп беләбез. Һәркайсыбыз нәфислектән башлап, җиде-сигез сыйфатны санап чыга ала. Тик бүгенге тормыш шартлары яшәү рәвешебез «нәфисбикәләргә» безнең хыялдан чынбарлыкка күчәргә мөмкинлек бирми шул. Алар, киресенчә, аккошның соңгы каурыйларын да йолкымакчылар...

Без күпме гомерләр прозабызның дөньяны шаккатыра алмавына аптырыйбыз. Чыннан да, гаҗәп: көчле прозаиклар бар, көчле әсәрләр юк! Юк диярлек. Сәбәп шул түгел микән: күпчелек язучыларыбыз үзләренең талантларын тормыш инде исбатлаганны исбатлауга җигәләр. Инде алынган территорияне үзләштерүче тыл частьларын хәтерләтә алар.

«Кыйгак-кыйгак каз кычкыра» — киләчәк өчен борчылу хисе яздырган сирәк әсәрләрнең берсе.

Без «көрәш» сүзен бик яратабыз. Һәр әсәрдә көрәш эзлибез. Сәхия кем белән көрәшә соң? Конфликт кайда? Гадәти конфликт юк монда. Ул — Сәхия белән дөнья, тормыш арасында. Шушы хәл әдиптән нейрохирурглар кебек нечкә эш итүне сорый: вакыйгалардан бигрәк күңел тирбәлешләре алга әйди сюжетны.

Турысын әйтик, нейрохирургик операцияне Фәнис профессорларча ук ясый алмаган. Кызларның әтиләре сугышка киткән җирдән соң әсәрнең «нерв җепселләре» аратирә өзелгәләп куя. Мондый урыннар безнең нервыларны да тыныч калдыра.

Моның төп ике сәбәбен күрәм мин. Беренчедән, әсәрдә психологик чынлык югалгалый. Әйтик, апасының Рәмзидән алдануы һәм шул сәбәпле Сәкинәнең китеп баруы Сәхияне тетрәндерә, шуннан соң исеме ике хәрефкә кыскара да инде аның. Ә менә Рәмзигә (үзен «кайнеш» дип йөргән Рәмзигә!) мөнәсәбәте сабыр-тыныч. Бары «җизнәсе» үзе җиккән атны алып киткән дип уйлау гына чыгырдан чыгара аны. Икенчедән, кайчакта моңа әсәрдәге сөйләм көпшәклеге (артык җөмләләр, сүзу-шәрехләү) дә өстәлә. Кызларны ачлыкка дучар итәчәк бәрәңге урлану фаҗигасе менә болай тасвирлана: «Бәрәңге бакчасының шактый өлеше казылып бетеп килә иде инде, шул вакыт кызлар сәер һәм ачы бер ачыш ясадылар: келәткә чыгарып куелган бәрәңге көннән көн кими иде. Әсәр дәвам итә. Шул ук информация хәзер бүтәнчәрәк вариантта тагын җиткерелә: «Апа! — диде Сәхия кылдан үрелгән чыбыркысын шартлатып. — Бәрәңгене безнең әллә җеннәр ташыймы икән? Менә бу почмакка сатарга дип иң эре бәрәңгеләрне юри өеп куйган идем, өем бөтенләй беткән. Шыта торсын дип, идәнгә таратылганнарының да яртысыннан күбрәге кимегән.» Озынлык бер хәл, Сәхиянең шундый чакта тыныч кына чыбыркы шартлатып торуы да «шартламый» әле.

Алда әйткәнемчә, Фәнис үзе тәвәккәлләгән үтә катлаулы операцияне баштан-ахыргача зур нечкәлек белән башкарып чыга алмаган. Әмма әсәр «исән кала». Нәрсә шифалы тын өргән соң аңа? Иң әүвәл — тел. Рецензентлар 15 ел элек — Фәниснең беренче повесте чыккач ук игътибарга алган «бизәккә бай», «халыкчан» тел тагын да чарлана төшкән. Кайбер сүзгә күчереп булмас кебек күренешләрне дә җиңел-табигый гына сөйләп бирә белә Фәнис. Автор сөйләменнән персонаж сөйләменә, диалогка күчкәнен сизми дә каласың аның.

Шулай да беренче әсәрләреннән үк сузылып килгән «гөнаһлары» да бар әле. Әйтик, күплек формасына мәхәббәте көчле аның: «Гөлҗимешләр бик уңа», «Шигырьләр дәфтәре», «Йомычкалар җыярга».

Фәниснең ничек образлар хасил иткәнен аңлап җиткереп булмый. Әйтик, портрет-фәлән ясап тормый ул. Әмма персонажларының күбесе күз алдына баса. Сәкинә белән Сәхияне аерым-аерым да, икәү бергә дә кинодагы кебек аермачык күрәсең. Фантазиябез үзе портрет ясый алсын өчен мәгълүмат җитәрлек бирелә, димәк. Аннан, әлеге дә баягы, тел. Һәр персонажның «бу мин!» дип торган үз теле.

Авторның тормышны әйбәт белүенә таң каласың. Тагын — хатын-кызны белүенә. Тракторчы Имам хатынының Тәлига белән сөйләшүенә генә колак салып карагыз әле сез!

Малайларны кем генә сурәтләмәгән бездә! Ә менә «чебен тимәс чер итәр кызларны елатудан» туйган Сәхия аларны менә ничек күрә: «...Йодрыклары мунча ташыдай каты, башлары өлгергән кабактай шома...», «Чәче пәке белән кырып алынган җыпҗылы башка карлы бүрекне кидерәсең...» Күз алдына киләме? Ничек кенә әле!

Сагышлы аваз салып абына-сөртенә каядыр ашыккан каз үзе генә дә ни тора. Ни аңлата ул? Кем ул?

Иң элек — үзе өчен кайгысы бик зур булган, бәпкә чыгара алмаган каз... Ялгызак...

Тагын, бәлкем, көчле дә һәм мескен дә Сәхиядер... Сеңелесенә матур күлмәк, ак туфлиләр алып бирәсенә ышанып авылдан китеп барган һәм бүтән әйләнеп кайта алмаган Сәкинәдер балки?


Ә бәлкем, безнең күпләребездер?

Кемнәрдер пессимизм дияр. Тик моны — бу трагедияне — тоймаган, тоюны артык санаган оптимизм — безне бер күзәнәкләләр белән тигезли торган ваемсыз оптимизм ул...

Кыйгак-кыйгак җан кычкыра...

**Рәфикъ ЮНЫС.**

## Уфада культурабыз истәлекләре



**Б. Мәкъсутовның кымыз дачасы**

1914 елгы фоторәсем буенча

*А. Тимергалина рәсеме.*

# ЯКТЫ ЙОРТ

Ямьле Агыйделнең йөзек кашы Уфа каласыннан дүрт-биш чакрым ераклыкта гына Караидел янындагы тау башында «Кымыз дачасы» дип аталган бер агач бина булган. Ул йорт, ягъни дача хәзерге «Зеленая роща» санаторие территориясенә керә. Революциягә кадәр нигез салынган бу дачаның хуҗасы — Баһаветдин Мәкъсутов дигән кеше. Тарих раславынча, татар мәдәнияте учаклары булган Казан, Әстерхан, Уральск, Троицк һәм башка шәһәрләрдән килгән иҗат интеллигенциясе вәкилләре бу дачада еш тукталганнар. Йорт хуҗасы Б. Мәкъсутов язучыларны, артистларны, журналистларны һәм гомумән иҗат кешеләрен хөрмәт итүче, үзе дә көндәлек татар матбугатында катнашып килә торган эшлекле булган. Мәсәлән, 1906 елдан аның җитәкчелегендә Уфада татар телендә «Әл-галәм әл-ислам» исемле газета чыга башлый. Либераль буржуазия органы булса да, газетада җирле халыкларның хокуксызлыгы, җирсезлеге, милли мәктәпләр хакында да мәкаләләр дөнья күрә. Редакциянең ярым-йорты рәвештә булса да рәсми политикага ризасызлык күрсәтүе, хөр фикерлеккә омтылышы патша администрациясенең игътибарыннан читтә калмаган. Полиция донесениеләрендә «Әл-галәм әл-ислам» (гәрчә чынлыкта алай ук булмаса да) «яңа юнәлештәге газета» буларак бәяләнә. Шуңа күрә властьлар редактор Б. Мәкъсутовны газетада «фетнәчел материаллар бастыра» дигән сылтау белән ике айга кулга алалар һәм аңа штраф салалар. Күптәрле эзәрлекләүләрдән соң, 1907 ел башында газета чыгудан туктарга мәҗбүр була.

Эше-гамәле белән культура дөньясына якын торган Б. Мәкъсутовның кымыз дачасы үз заманында татар интеллигенциясенең очрашып фикер алышу урыны булуы гаҗәп түгел, әлбәттә. Әйтик, Б. Мәкъсутовның кызы Фатыйма ханым 1916 елның җәендә бу дачада Галимҗан Ибраһимов, Фатих Сәйфи-Казанлы, Абруй Сәйфи, шагыйрә Гыйффәт Туташ, журналист Исмәгыйль Рәмиләрнең ял итүләрен искә ала. Шул ук җәйдә алар янына Габдулла Кариев та килеп чыга. Бу вакытта ул Уфага гастрольгә килгән була. Г. Кариев катнашында спектакль куелу турында Уфада татар телендә чыга торган «Тормыш» газетасында (1916, 3 июнь) түбәндәге хәбәр дөнья күрә: «11 июньдә Новый клуб залында Уфа театр һәвәскәрләре катнашы һәм мәшһүр артистыбыз Габдулла Кариев иштирәге (катнашы) белән татарча театр булачак. Тамашага беренче мәртәбә буларак «Ямьсез тормыш» (Ф. Сәйфи-Казанлы әсәре) исемле пьеса белән Г. Камалның «Беренче театр» комедиясе куелачак».

Б. Мәкъсутовның кымыз дачасын, хәзергечә әйткәндә, «иҗат йорты» дип тә атарга мөмкин. Чөнки ул иҗат кешеләренең очрашып фикер алышу белән бергә, сәламәтлекләрен ныгыту урыны да була. Фатыйма ханым һәм Исмәгыйль Рәминең хатыны Камәр ханым истәлекләренә караганда, дачага кичләрен Шәехзадә Бабич та килгәләп йөри торган була. Ул мандолинада уйный, ә Абруй ханым үзенең матур меццо-сопрано тавышы белән моңлы татар көйләрен башкара. Бирегә С. Рәмиев белән М. Гафури еш килә лар. Бу дачада булачак күренекле татар композиторы Әхмәтсолтан Габәши, журналист Самат Шәрәфетдинов һәм башка яшь талантларның кайнар эзләре саклана.

Мәдәниятыбызның күп кенә күренекле шәхесләрен үзенә тарткан, рухи табынына җыйган әлеге йорт һәм аның хуҗасы Баһаветдин Мәкъсутов турында якты истәлек бүген дә күңелләрдә саклана.

*Х. Гобәйдуллин һәм Ж. Миңнуллин тексты.*

**Мөхәммәт Мәһдиев**

# ТУГАН ЯК АВАЗЫ

Казан арты авылларының исемнәре каян килеп чыгуын сорап, соңгы елларда миңа да хатлар язалар. Мин бу өлкәдә белгеч түгел, бу мәсьәлә белән махсус шөгыльләнгәнем юк. Фән-гыйлем өлкәсендә минем егерменче гасыр башы татар әдәбиятына һәм халык иҗатына караган азмы-күпме хезмәтләрем бар. Авыл исемнәренә килсәк, моңа инде мин туган як табигатендә, җирендә сакланып калган тарих авазларын интуиция белән генә сизә алам. Ә интуиция ул — фактлар белән дәлилләми, шуңа күрә минем бу өлкәдә бик нык ялгышуым да бар. Шулай да минем тәҗрибә-күзәтүләремне уртаклашып карыйсым килә.

Авыл исемнәренең тарихын өйрәнгәндә мин түбәндәге ике концепцияне нигез итеп алдым.

1. Авыл исемнәре шул тирәдәге урман, елга, басу, шунда үскән агач, шул тирәдәге рельефка һәм шунда тереклек иткән кыргый хайваннар, кошларга бәйле рәвештә ясалган.

2. Казан ханлыгы рус дәүләтенә кушылганнан соң кайбер авыллар рус түрәләре, землемерлар тарафыннан исәпкә алынган һәм кәгазьгә язылганда рус теленә якынайтып үзгәреш кичергән. Димәк, кайбер авылларның исемен русчадан татарчага таба чыгып эзләргә кирәк.

Менә шул ике концепциягә нигезләнгәннән соң мин мондый нәтиҗәләргә килдем.

Болгар заманында тау сүзе урынына «мар» сүзен кулланганнар. Бу турыда шагыйрь Н. Думави әйтә. «Бу чокырлар да бар да болгарлар уры, болгар мары» ди ул. («Юлда» шигыре.) Моннан ачыла: тау итәгенә урнашкан Кукмара — һич тә марича «ике (кук) мари» сүзеннән алынмаган, ә Күк Тау сүзеннән ясалган (Күкеле тау яки Куаклы тау булырга мөмкин). Идел өстендәге Морквашы — Мар (тау) куышы булып чыга. Урманлы текә тау астына урнашкан Поши тавы авылы (Балтач районы) «Поши мары» була, документларга ул Пижмара дип кереп киткән. Мөрәле авылы (Арча) да шулай: ул авыл ике яктан тау белән уратылган, үзәндә утыра. Ул — Мар иле. Урмары — Ор тавы, Каймары — (Дөбьяз ягы) — Каен тавы.

Күп кенә авылларның исеменә «ил» сүзе нигез булган (халык, төркем, бер көч мәгънәсендә). «Ил» сүзеннән чыгып без байтак авылның исемен ача алабыз. Ләкин шуңарчы бер әйберне искәртеп үтик: борынгы Казан арты (Арча-Әтнә-Дөбъяз, Балтач, Чепья-Кукмара-Саба төбәкләре) тоташ кара урманнан һәм тирән сулы елга, күлләрдән торган. Бик борынгы заманнарда, әлбәттә инде, бу якта исәпсез-хисапсыз киек кошлар, кыр хайваннары яшәгән. Монда кыр казлары, торналар, аккошлар яши торган аерым төбәкләр булган, табигатьнең кайбер сәерлекләренә очрап, бу кошлар вакыт-вакыт колония булып монда кышлауга да калганнар. Торналар бала чыгарган регион — Торна иле (хәзер Төрнәле, Олы һәм Кече Төрнәле авыллары) дип исемләнгән, ул якларда әле дә булса кайбер басу, елгаларны (Сикертән, Гөберчәк авыллары тирәсендә) Торна басуы, Торна елгасы дип йөртәләр. Киек кошлар бик консерватив: ата-бабаларының элек бала чыгарган урыннарын алар хәтерләрендә биш, ун мең еллар буе буыннан-буынга тапшырып, саклап киләләр. Бу бигрәк тә, аккошлар мисалында күзәтелә.

Аккошны бер төбәктә «акку», икенче төбәктә «ку» дип йөрткәннәр. Дәрдмәнд шигырьләрендә моңа мисаллар күп: «Тонык елгыр күлләрендә каңгылдый аккулары», яисә: «Гөрләсә су, чыңласа акку һаваларда очып...» Бәс, шулай икән, Дөбъяз, Питрәч якларындагы Ташлы Кавал, Кавали авылларының исемендә «Ку иле» дигән сүз ята. Землемер, яки түрәнең документка «Ковали» дип язмый хәле юк. Сөн буенда Аккүз авылы бар (Актаныш районы). Аның болынына һәр елны булмаса да, ара-тирә берәр пар аккош килеп җәйли икән. «Бабайлар каны тарта», күрәсең. Аккүз авылының да исеме

башта Акку булгандыр, аны документка гына шулай «Аккузево» дип язганнардыр. Тагын шунысы кызык: Дөбъяз төбәге Ку иле (Ташлы Кавал) янындагы Бикнарат авылы кешесе Хәбибулла Әхмәдуллин музыкабыз тарихында беренче буларак марш — Аккош маршын иҗат иткән. Әби-бабалары тапшыргандыр аңа бу моңнарны. Безнең халык җырларында аккош бик еш телгә алына. Димәк, ата-бабаларыбыз аккошлар белән бергә гомер сөргән безнең.

Инде «ор» сүзенә килик. Бу бик хикмәтле сүз. Бер урында ул калкулыкны, икенче урында чокырны, өченче урында коры елганы аңлата. Шулай да тарихка яңадан аккош килеп керә: Кесмәс суы буендагы тау битен бабайлар «Ку орысы» дип йөрткәннәр. Шуннан авыл исемнәре: Югары Ку орысы, Урта Ку орысы, Түбән Ку орысы, Ку орысы башы, Ку орысы почмагы... Рәсми документларга ул «Корса» дип кергән һәм соңгы заман халкы аны Курса, Курсабаш, Курса почмак дип йөртә башлаган. Габденнасыйр Курсави үзенең аккошлар илендә туып-үскәнен белдеме икән?

«Ор» дигәннән, бу сүз мәшһүр Арча исеменең нигезендә дә ята. Әйткәләп, язгалап карадылар: имеш, Арча авылының исеме «ар» сүзеннән, ягъни, шул якта яшәгән удмуртларны «ар» дип йөрткәннәр. Тагын бер гипотеза: имеш, аның тау битендә «арча» агачы үскән. Ничек инде Урта Азиядә үсә торган бу артыш агачы тик торганда гына Питрәчтә, Сабада, Теләчедә түгел, нәкъ менә Арча тау битенә генә килеп үскән? Алай булмый бит! Арчаны күргән кешеләр белә: ул Казан елгасы буенда борылмалы тау битенә урнашкан. Аны әле заманында бер елга урталай ярган булган, аны инде акрынлп күмеп бетерәләр бугай. Арча сүзе, әлбәттә инде «Орыча»дан алынган. Калку урын, яки, коры елга мәгънәсендә. «Ор» сүзеннән Орск шәһәренең дә исеме ясалган булуы ихтимал. Орыча — Арча астында түбәндә Чокырча авылы бар. Борынгы төрки-татар телендә «чок» сүзе — түбәнлекне аңлата. Кайбер төбәкләрдә начар, әдәпсез кешене әле дә: «чак кеше» дип йөртәләр. Димәк, Орыча-Арча калку урында булса, Чак-Орыча түбән урында. Ничек инде, бер үк сүз югары дигәнне дә, түбән дигәнне дә аңлата, дип каршы килүләре мөмкин. Ләкин бит фәндә энантиоморфизм, ягъни бер үк әйбернең капма-каршы мәгънәсендә үз эчендә яши алуы дигән күренеш бар. И. С. Тургенев әйтә: «Верхом называется в Орловской губернии овраг». (Записки охотника. Повести и рассказы. М., 1979, 156 б.)

Арча янындагы Күпербаш авылының да исеме һич тә «Күпер»гә бәйле түгел (кайсы авылда гына күпер юк соң?), ә төньякка таба Казан елгасының бассейнына эчкәрәк кергән саен күп «ор»лар булачагына ишарә: менә бу авыл күп орның башы. Күп ор башы. Землемер үзенең кенәгәсенә яза: Күпербаш. Землемер эчкәрәк керә: картлардан сорый. «Бусы тагын нинди авыл?»— «Күп орчык»,— диләр бабайлар. Чөнки бу авылның бөтен болыны түмгәктән, бөтен басуы коры елгадан тора. Дөрес, алар аны моңарчы елга исеме белән «Кече Му» авылы дип йөртәләр иде, ә монда инде тегәлрәк — «Күп орчык» — шуннан рәсми документта Губурчок, шуннан — Гөберчәк. Монысы минем туган авылым.

Казаннан мәгълүм сәбәпләр аркасында күчеп утырган кешеләр мари, удмурт якларына гел ышна арчып, ягъни урман кисеп, ышна төбен чыгарып, иген басуы ясап барганнар. «Ышна басуы» дигән сүз бу якта әле дә актив. Ләкин җир ала-ала бара торгач, бабайлар бер урында урман халкы мариларга барып төртелгәннәр: сугышып тормаганнар, шул чиктә туктап соңгы авылны салганнар. Ул авылны соңгы ышна арты дип йөртә башлаганнар. Русча документка ул «Ышна арты» дип түгел, «Ишнарат» дип теркәлгән. Әлеге авылның исемендә, шулай итеп «нарат» сүзенең бер генә дә катнашы юк.

Казан артының пошилы урманнары турында аерым сөйләргә кирәк. Поши аланнарындагы авыллар документларга «Пшалим» дип кереп киткән.

Пөшәңгәр авылының исеме дә «поши оры» дигән сүздән алынып, русчада «Пушингер» га әйләнгән булуы мөмкин. Аннан инде рәсми татарчалаштырып, «Пөшәңгәр» булып чыгуы бик табигый.

Инде Тукай биографиясенә бәйле Өчиле, Кушлавыч яклары турында берничә сүз. Өчиле исеме «бу авылда башта өч өй булганнан килеп чыккан» дигән версиягә минем ышанасы килми. Борынгы заманда, яңа җир үзләштергәндә кайсы авылга нигез салганда анда ничә өй салынуы турында документлар була алмый, һәм аны эзләргә дә кирәкми. Кара төн уртасында дөм караңгы бүлмәдә анда булмаган кара мәчене эзләп табуы бик кыен, ди гарәп мәкале. Өч өйле авылдан килми әлеге исем, ә «оч иле» дигән сүздән. Калын урман эченәрәк кера-кера, авыл салып, ил нигезләп килгән бабайлар аерым территорияләрне кысалап, очын-кырыен билгеләп барганнар. Әнә тегене кошларның «кышлау урыны» дип исемләгәннәр. Шуннан, Кышлау, Кышкы-ар (җир) исемнәре тугандыр, бәлки. Ә менә монда Иделгә — кешеләр яшәгән җиргә якынрак килгән урында кышлауның очы. Шуннан — Кышлау очы, бөек шагыйрь Тукай туачак урын, документларга Кушлавыч булып кереп киткән. Кышлауның тагын нинди очлары (чикләре) бар соң? Авылда шулай бит: югары оч, түбән оч, ягъни чик: Кышлауның исә Казан артында чикләре

билгеләнгән: уртада Кышлау, Кышкар авыллары. Казан елгасына — көнбатышка таба аның очы — Кушлавыч, Кышлау очы. Көнчыгышка таба бер очы — Оч иле (бу авыл хәзер бетерелде, кечкенә авылларны бетерү дигән зарарлы шаукымның корбаны булды. Ул авыл Казан елгасының яшел хәтфәле, артышлы тау битенә урнашып, гасырлар кичереп ята иде). Кышлауның икенче читендә тагын бер Оч иле, монысы Тукайның аяк эзләрен саклаган Өчиле авылы. Тукайның Казан артында йөргән, яшәгән бөтен авыллары бик борынгы заманнардагы киек кошлар, кыргый хайваннар тулып торган тарихка бәйле.

Гадәттә, мәктәп балалары «безнең авылның исеме каян килеп чыккан?» дип авыл картларына мөрәҗәгать итәләр. Кемнәр соң алар бүгенге авыл картлары? Аларның бик күбесе Октябрь революциясеннән соң туган буын. Бу буын авыр еллар кичкән, шахталар, метро салган, колхоз төзегән. Бөек Ватан сугышы узган. Элеккеге тарихи риваятьләр белән шөгыльләнергә вакыты булмаган аның. Шуңа күрә бүгенге музейларда авыл исемнәре турында бернинди фәнгә, тарихка туры килми торган җиңелчә хата мәгълүматлар тулып ята. Кызганычка каршы, авыл мәктәпләре укытучылары балаларны шуңа ышандырып тәрбиялиләр. Мин бервакыт  Арча районы, Сарай Чокырча авылында, узышлый гына агай-энедән сорадым:

— Бу авыл нигә алай дип исемләнгән?

Ике-өч механизатор, күзләрен дә йоммыйча, миңа болай диделәр:

— Монда элек зур чокыр булган, авыл уртасында сарай булган...

Мондый аңлатулар, әлбәттә, примитив, һәм музейлар, мәктәпләр андый хата юнәлештән ерак торырга тиешләр.

Бу темага радиодан чыгышларымның берсендә мин Курса авылының исемен алда әйтелгәнчә, кешеләр урнашканчы ук анда яшәгән аккошлар колониясе булуга бәйләп «Ку орысы» дип аңлатып караган идем. Ләкин примитив уйлаучы моңа риза түгел: аңа әнә теге ансат юл, наданнарча фикер йөртү юлы ошый. Ул яза: Курса мәктәбендәге музейда, ди, бу исемнең каян алынганлыгы мәгълүм. Элек ди, ул тирәдә куе урман булган, чыршы, усак, юкә үскән ди. Ярый, монысы шулай, урман калын булган. Әмма теге иптәш сүзне кая таба бора: «Безнең борынгы бабаларыбыз юкә кайрысыннан чабата һәм төрле башка әйберләр ясаганнар. Алар юкә каерысын «Курс» дип атаганнар. Менә шуннан авылга Курса исеме бирелгән булса кирәк».

Ә бит, беренчедән, «курс» түгел, «курыс»; яшь юкә кәүсәсеннән июнь аенда тоташ салдырып алына торган тышча. Икенчедән, тарихка бик тирәнгә китсәк, безнең болгар бабайлар чабатаның ни икәнен дә белмәгәннәр, алар күннән тегелгән аяк киеме кигәннәр.

Шундый ук примитив аңлату Казан артындагы авылларның берсе — Күәмгә карата да кулланыла. Имеш, «куам» сүзеннән Күәм барлыкка килгән, ди. Хатларның берсендә Балтач районындагы Шода авылының исемен дә шулай өстән генә примитив аңлаталар. Имеш, бу авылда элек марилар яшәгән, Казаннан куып килгән татарлар бу авылга бәреп кергәндә, имеш, марилар төнлә чыгып качканнар, үзара «Шуди, шуди» дигәннәр, ягъни «акрын, акрын». Шуннан Шода авылы исеме барлыкка килгән. Мондый аңлатулар — көлке. Әгәр мәктәпләрдә дә шулай аңлаталар икән, бу инде көлкә генә түгел, ә зарарлы да.

Беренчедән, Күәм авылыннан татарлар җирле халыкны куып чыгарганчы авылның исеме булмаганмыни? Марилар «шуди, шуди» дип чыгып киткәнче Шода авылының да исеме булмаганмы? Әгәр мәктәп музейларында шундый материалар бар икән — болар тарихны бозу, болар интернациональ тәрбиягә хезмәт итми.

Авыл исемнәре тарихын тикшергәндә өстән-өстән фикер йөртүгә, примитивлыкка, ә дөресрәге наданлыкка юл куярга тиеш түгелбез. Әйтик, Көтек авылының исемен ниндидер бер мәзәккә нигезләп, кемдер кемне көтеп торганга шулай аталган дип аңлату — намуссызлык. Ул юл белән китсәң, эш бик асат: Сикертән авылы чокырга урнашкан. «Ай, шуны сикереп узарга иде»,— дигән берәү. Менә сиңа аңлатма. Борбаш дигән авылда аучылар яшәгән, алар бүре башын капкаларына элгәннәр. Арбаш дигән авылда арба ясаганнар. Мәскәүдәге Арбат урамыннан атлы арбалар узган, шуңа шулай исемләнгән. Болай аңлату — халыкны алдау.

Алдарак мин ни өчен Казан артындагы авылларның исемен ачыклаганда җир өсте күренешләрен нигез итеп алырга кирәк дигән идем? Бу — зур тарихи мәсьәлә. Бик борынгы заманнарда бабаларыбызның зур-зур дала киңлекләрендә яшәгән, күчмә халыклар булганын да онытмыйк. Дала ул диңгез кебек, көн барасың, өч көн, бер атна, ай барасың. Анда гел бертөрлелек. Инде дә килеп шул далада бер кое, бер таш, бер түмгәк очрадымы — күчмә халык өчен бу зур вакыйга. Аңа исем бирелми калмый. Менә шул ландшафт үзгәрешенең кадерен белгән борынгы бабалар кан, рух буенча тапшыра-тапшыра бер сыйфатны саклаганнар. Ул — чишмәгә, елгага, калкулыкка, тугайга, үзәнгә, чокырга, урманга үтеп, чүлгә, терлек-хайванга, киек кошка, кешегә караган кебек карарга, аларны хәтергә шигъри бер рух белән беркетергә һәм сакларга.

Казан артының ифрат бай табигате эченә килеп ил-йорт коручы бабаларыбыз, тегә, күчмә заманнардагы бабаларның кан буенча тапшырылган әнә шул сыйфатларын эшкә җиккәннәр. Бер авылның да исеме очраклы тумаган, моны аксиома буларак кабул итәргә кирәк.

Ниһаять, тагын бер мәсьәлә. Казан арты авыллары рәсми документларда берничә тапкыр исемнәрен үзгәрткәннәр. Моңа йә алпавыт җирбиләүчелеге, йә патша администрациясенең кайбер җир-оештыру чаралары, кайвакытта сыйнфый көрәш моментлары тәэсир иткән. Урындагы энтузиастлар, ни өчендер, әнә шул вариантларны өйрәнмиләр. Хәтта кызыксынмыйлар да. Әйтик, Арча районы Гөберчәк авылы утыз бишенче елларда «Кече Му» дип йөртелә иде. Күршедә Сеҗе авылының да өстәмә исеме бар иде — Мурья Мусич. Каян бу? Казанбаш авылы да ике исемле. Аның төп исеме — Кармыш. Аның янындагы рус авылы ике исемле.— «Четыре двора; татарларда — Өстеял — (анда Постоялый двор булган). Аның янындагы Тыңламас авылының да икенче исеме — Александровка.

Арча районы Чиканас авылыннан сугыш ветераны, Казан университетының рус филологиясе бүлеген тәмамлаган Госман Әхмәтов яза: «Безнең Чиканас авылын элек Алич Тархан дип тә йөрткәннәр. Латин хәрефләре белән язылган бу штемпель басылган кәгазьне үземнең күргәнем бар. Авылның тагын бер исеме бар иде, ачыклагач та хәбәр итәрмен». Менә бу инде — тарихка керергә омтылу, мондый кызыксынуда мин авыл исеменә грамоталы мөнәсәбәт сизәм. Бу инде Курса сүзен чабата ясый торган курыска кайтарып калдыру түгел. Югарыда сөйләгәннәрдән бары тик бер генә нәтиҗә ясарга мөмкин: авылларыбызның исемнәрен ачыклаганда бик сак булырга, аларны ачканда нейрохирург кебек эшләргә кирәк. Шул ук вакытта бәхәссез нәтиҗәләргә дәгъва кылмаска, версияләр белән күбрәк эшләргә кирәк. Бу фараздан нәтиҗә ясау, аларны документлар белән беркетү — монысы инде шул өлкәдә хезмәт итүче галимнәр эше.

**Динә Вәлиева,**
сәнгать фәннәре кандидаты

# ШӘМАИЛЛӘР

Болгар-татар сәнгате һәм культурасы гасырлар дәвамында бик тә үзенчәлекле үскән. Көнчыгыш белән Көнбатыш кисешкән төбәктә урнашканлыктан борын-борыннан алар, бер яктан — Иран, Кытай, Урта Азия белән, ә икенче яктан — Борынгы Русь, Әрмәнстан, Византия белән тыгыз экономик һәм культура бәйләнешләре урнаштырганнар. Көнчыгыш һәм Көнбатыш культурасы, сәнгате төрле вакытларда татар халкы культурасы һәм сәнгатенә теге яки бу дәрәҗәдә йогынты ясаган.

Татар халкының культурасы тикшеренүчеләр игътибарын инде үткән гасырдан башлап ук җәлеп итә. Шулардан бүгенгәчә халыкның гореф-гадәтләре һәм көнкүреше, һөнәре турында төрле хезмәтләр язылә. Әмма аларның берсендә дә, халык сәнгатенең мөстәкыйль төре буларак, шәмаилләргә анализ ясалмый. Бу хакта өстән-өстән генә әйтеп узу, шәмаилләрнең татар өйләрендә этнографик җиһаз булуын искә алу бар. Әмма шәмаилләрнең сәнгать әсәре булуы турында берни дә әйтелми. Фәкать С. Червонная гына, Татарстан дәүләт музее җыелмаларыннан өч шәмаилне игълан итеп, аларны сәнгать әсәрләре рәтенә кертте, шәмаилләр белән татар профессиональ рәсем сәнгате арасында уртаклык күрде.

Илебездәге халыкларның сәнгатен һәм һөнәрләрен өйрәнүгә зур әһәмият бирелгән хәзерге вакытта шәмаилләрне татар халык гамәли-көнкүреш сәнгатенең бер төре буларак тикшерү зарурлыгы көн тәртибенә килеп баса.

Шәмаил — гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә, рам-кыса эченә язып куелган дини текст, рәсем дигән сүз. Бу, нигездә, матур итеп бизәлгән, каллиграфик текст — Коръәннән өзекләр. Текст чәчәк-үсемлек белән бизәлә. Кайвакыт композициядә пейзаж яки архитектура төзелешләре (Мәккә һәм Мәдинә күренешләре) фрагментлары сурәтләнә.

Татар шәмаилләре шундый художество әсәрләре ки, аларда зур осталык белән язылган каллиграфик текст та, матур бизәкләр белән янәшә бик гади генә предметлар да, табигать күренешләре дә сурәтләнә. Моны татар халкының XIX гасыр ахырындагы социаль һәм культура тормышы белән аңлатып була.

Революциягә кадәр татарларда укый-яза белү дәрәҗәсе шактый югары була. Казанда гына түгел, авылларда да бөтен ир-ат диярлек укый-яза белә, күпләр мәдрәсәдә укыган гарәп һәм фарсы телендәге дини һәм дөньяви әдәбият белән таныш. Халык арасында кульъязма китаплар күп таралган. Шунлыктан шәмаилләрнең югары профессиональ дәрәҗәдә язылуына һич тә гаҗәпләнәсе юк. Бу урында шунысын да әйтик, узган гасырның 30 нчы елларында Казан университетында гарәп каллиграфиясен атаклы галим Гали Мәхмүдов укыткан.

Аерым очракларны исәпләмәгәндә моңарчы шәмаилләргә бары тик дин культы предметлары итеп кенә карадылар. Картларның сөйләвенчә, утызынчы елларда бик күп шәмаилләр махсус рәвештә юк ителгән. Шәмаилләр чынлап торып беркайда да җыелмады, теркәлмәде. Кызганычка каршы, әлегә аларны комплекста карау мөмкинлеге юк. Хәтта Татарстан дәүләт берләштерелгән музеенда да алар бик аз, өстәвенә булганнары да уникаль, бердәнбер данә түгел, ә литография ысулы белән басылганнары гына.

Эчтәлекләре, төзелешләре, башкару техникасы буенча шәмаилләр берничә төркемгә бүленә. Эчтәлекләре буенча алар танып-белү ягыннан әһәмиятле текстлы, поэтик, дини, үгет-нәсихәтле, мәкальле, танышу һәм үз-үзеңне тоту кагыйдәләре язылганнарга бүленәләр. Композиция сюжетлары буенча исә — үсемлек ясалган, табигать һәм архитектура күренешле, геометрик бизәклеләр. Башкару техникасы буенча шәмаилләр рәсемле (буяулар, кара тушь һәм фольга кулланып пыялага төшерелгән) һәм график (литография ысулы белән эшләнгәннәр) була.

Литография ысулы белән эшләнгән шәмаилләрне алыйк. Алар XIX гасыр ахырында — XX гасыр башларында Казандагы дәүләт һәм хосусый типографияләрдә цензура рөхсәте белән басылганнар. Кайчак литография текстлары астында «Габдрахман Абдуллин» дигән исем-фамилия дә очрый. Кем ул? Текстны басучымы, әллә төзүчеме? Әлегә моны ачыклап булмады.

Безнең өчен аеруча игътибарны җәлеп итүчеләре — төрле фәннәрдән элементар мәгълүмат биргәннәре. Мәсәлән, Болгарның архитектура һәйкәлләре төшерелгән шамаил: анда болгар мәчетләренең, палаталарының, иң зур мәчет хәрабәләренең фоторәсемнәре бирелгән. Текстта болгарның дине турында мәгълүмат та бар.

Икенче бер шәмаилдә җирдәге бар нәрсәгә тормыш бирүче кояш нурлары турындагы сүзләр язылган. Шунда ук ал чәчәкләргә һәм яшел яфракларга күмелгән куак рәсеме. Аңа кояш нурлары төшә. Ә композициянең астагы сул почмагында — кояш нуры төшмәгәнлектән сулган агач сурәте.

«Сакланганны ходай саклар» дип язылган, ваба авыруыннан ничек сакланырга кирәклеген өйрәткән шәмаил дә бар. Тагын бер шәмаилнең тексты кызыклы: анда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, дөньяда әйбәт итеп яшәү өчен ни эшләргә кирәклеге әйтелә. Игелекле булырга, ярлыларга булышырга, ата-анага хөрмәт күрсәтергә өйрәтелгән анда. Шулай итеп, тематикалары белән шәмаилләр төрле: алар тарих, табигать белеме, медицина, үз-үзеңне тоту буенча мәгълүмат бирә.

Шәмаилләр гадәттән тыш бай һәм төрле композицияләре белән аерылып торалар, ритмик яктан алар тигәл, күбесенчә аерым өлешләренең симметрияле булуы хас. Композицияләрдә шулай ук бизәк һәм сурәт төрләре дә файдаланыла. Каллиграфия турында махсус әйтмәсәң дә аңлашыла: чөнки ул, сүзләре нинди генә булса да, теләсә кайсы шәмаилнең аерылгысыз һәм төп өлеше.

Үсемлек-чәчәк темасы төп урынны билгәгән шәмаилләр дә бар. Ул бөтен текстны уратып ала, юллар арасын, почмакларны, рамны бизи. Кайчак композиция күпләгән детальләр, элементлар белән күмелеп бетә. Еш кына лалә чәчәге яки бәйләме очрый.

Кайбер шәмаилләрдә, текстка бәйсез рәвештә, алтын алмалар асылынып торган тормыш агачы сурәтләнә; кайчакта Болгарны, ә кайчак Урта Азия төсмерләрен хәтерләткән, үтә дә катлаулы үсемлек-чәчәктән генә торган бизәкләр дә бар.

Шәһәр архитектурасы, үсемлекләр, тау пейзажын сурәтләгән шәмаилләр дә үзенчәлекле. Алар үсемлек-чәчәк бизәкләре белән урап алынган. Ә текст композициянең сул һәм уң ягындагы кечкенә медальләргә урнаштырылган.

Икенче бер төр шәмаилләр геометрик бизәкле. Аларда композиция тулысынча геометрик фигураларның: йолдызларның, түгәрәк, ярымпочмак һәм квадратларның берберсенә үрелүенә, кушылуына корыла. Сүзләр я әлеге фигураларның эченә, я булмаса алар тирәсенә урнаштырыла. Бер фигура эченә икенчеләре дә ясалырга мөмкин.

Ниһаять, литографияләнгән шәмаилләрнең каллиграфик тексттан гына торганнары да бар. Андыйларда рәссамның игътибары язуның матурлыгына һәм мәгънәсенә юнәлтелә. Тамашачы күңелен башка берни дә җәлеп итми, матур гарәп язуы үзе искиткеч бизәк булып кабул ителә. Мондый шәмаилләрдә, кагыйдә буларак, сүзләр, бизәк, язу — барбөтен, бердәм композиция булып кабул ителә.

Пыялага язылган, рәсемле, уникаль шәмаилләргә мөрәҗәгать итик. Аларны да композицияләре буенча каллиграфик язулы, архитектура пейзажлы, геометрик һәм үсемлек-чәчәкле бизәк белән эшләнгәннәргә аерып була.

Шәмаилләрдә иң мөһиме — сүзләргә лаеклы урын табу, аларны матур итеп урнаштыру. Ә төрле сурәтләр — сүзләрнең мөһимлеген ассызыклау өчен кулланылган бизәкләр генә. Тикшереп үткән шәмаилләрдә без сүзләрнең төрлечә: геометрик фигуралар эчендә яки ирекле рәвештә урнаштырылуын күрдек. Еш кына шәмаилләрдәге текст төрле үсемлек бизәкләре белән чуарланган рамда диагональ буенча да урнаштырыла. Ул кызыл төстәге фонга языла һәм композициянең үзәген тәшкил итә. Ә күпчелек шәмаилләрнең фоны зәңгәр төстә. Үсемлекләр, алмагач чәчәкләре исә аларга бәйрәм рухы өсти. Композицияләр зәвык белән эшләнгән, аларда китап битләре башларындагы бизәкләрдән дә, профессиональ сәнгатьтән дә нидер бар.

Ниһаять, чын халыкча эшләнүе белән игътибарны җәлеп иткән шәмаилләр очрый. Менә аларның берсе: ачык зәңгәр фон, аның уртасына текст шигъри юллар итеп урнаштырылган, ул бай һәм ачык шрифт белән язылган. Текст тирәсендә — сары көнбагышлар, ал мәкләр. Композициянең өске өлешендә — матурлык һәм мәхәббәт символы булган ике күгәрчен сурәте. Бу сурәтләр халык картиналары яки стенага эленә торган чигүле келәмнәр рухында башкарылган. Аларда халык сәнгатендә, мәсәлән, чигүдә яки күн мозаикасында яратып кулланыла торган алым — катгый симметрия сакланган.

XX гасыр башында, бөек шагыйрь Габдулла Тукай үлгәннән соң, Коръәннән алынган сүзләр урынына матур хәрефләр белән Тукай шигырьләре, аеруча «Туган тел» язылган күпләгән шәмаил барлыкка килгән.

Татар шәмаилләренең үсеш юлын төгәл әйтү читен. Ихтимал, аның рухи башлангычы Көнчыгыш миниатюрасы булгандыр. Миниатюраның төп өлешен каллиграфия һәм күп урынын бизәк алып торган рәсем сәнгате тәшкил иткән. Урта Азиядә исә Коръәннән алынган сүзләр, җөмләләр язылган аерым битләр гамәлдә булган. Шәмаилләрнең бар-

лыкка килүендә нәкъ менә шулар билгеле роль уйнагандыр да. Чөнки элекке заманнарда күп кенә татарлар Урта Азия мәдрәсәләрендә укыган бит. Урта Азиядән «изге кәгазь»ләрне әнә шул шәкертләр алып кайтканнардыр, һәм ул аерым битләр, тора-бара төрлечә үзгәреп, без сүз алып бара торган шәмаилләргә әверелгәндер.

Шәмаилләрнең икенче бер чыганагы дип гарәп халык картиналарын һәм аларга якын булган, шулай ук XIX гасыр уртасында һәм ахырында киң таралган төрек лубокларын санарга мөмкин. Алар пыялага төшерелгән рәсемнәрдән һәм басма гравюрадән гыйбарәт. Анда каллиграфик текст, бизәк һәм лубок стилендә эшләнгән гади рәсемнәр, халык тормышын сурәтләгән күренешләр табигый төстә бергә берләшә. Шулай итеп, поэзиянең югары классик стиле белән халык такмаклары бергә катнашкандай, ниндидер гадәти, типик түгел жанрлар кушылмасы хасил була.

Шәмаилләр — нәкъ менә шундый кушылма үрнәге, каллиграфия дә, лубок та булмаган жанр. Алар үзләренең төзелешләре, характерлары, тышкы сыйфатлары, ә еш кына эчтәлекләре һәм йорт бизәлешендә тоткан рольләре белән, гарәп халык картинкаларына барып тоташа, безнең якның Гарәбстан белән үзара мөнәсәбәтләрендәге тарихи тамырларны күрсәтәләр.

Шәмаил өйдә ишек өстендә торган. Моның белән аның явыз көчләрдән саклау кебек символик әһәмияте басым ясап күрсәтелгән. Шәмаил хуҗаларга имин тормыш, йорттан чыгып китүчеләргә хәерле юл һәм изге эшләр «теләгән», биргә килүчене «сәламләгән». Монда инде шәмаилләрнең аерым, рухи асылы, аларның кешеләр кәефен тудырудагы әһәмияте ачыла. Алардагы конкрет текст әллә ни зур роль уйнамый, күргәнебезчә, бу сүзләр гап-гади, популяр текст булырга да мөмкин, хәтта бүгенге лозунгларны да хәтерләтә. Иң мөһиме, алар өйгә нидйдер бер тулылык, бөтенлек бирел торганнар.

Шәмаилләрне XX гасыр башы татар өеннән аерып карарга ярамый. Туку әйберләре һәм гади мебель, савыт-саба, тәрәз төпләрендәге гөлләр кебек ук, шәмаилләр дә өйне бизәгәннәр һәм тулыландырганнар, аның мәҗбүри бер өлеше булып торганнар. Шул ук вакытта, күпмедер дәрәҗәдә кешеләрнең үз өйләрендә художество әсәре, картина булдырырга теләве кебек эстетик ихтыяҗларын да канәгатьләндергәннәр. Аларны аталар үз улларына гаиләнең изге бер нәрсәсе итеп тапшырганнар, аларга хөрмәт белән караганнар.

Дөнья сәнгате фонында шәмаилләр Урта Азия һәм Гарәбстан сынлы сәнгатенә якын торсалар, милли культура фонында аларда Болгар балчык чынаяклары, аеруча татарларның борынгы кабер ташлары белән охшашлык табарга була.

Композицияләрнең төп структурасында: төгәл, оста, матур итеп язылган һәм төп урынны алып торган текстлары, текстның геометрик яки үсемлек бизәкләре белән рамга алынулары ягыннан ташъязмалар һәм шәмаилләр бер-берсенә бик тә якын тора. Бәлкем әле бу һәйкәлләр татар шәмаилләренә турыдан-туры йогынты да ясаганнардыр.

Шәмаилләрнең татар китабы, аеруча кульъязма китап графикасы белән дә якынлыгы күзгә ташлана. Шрифт, каллиграфия, текст башларының үзенчәлекле бизәлүе җәһәтеннән татар китабы һәм шәмаилләре композицияләрендәге билгеле бер охшашлыкны күрү кыен түгел.

Шәмаилләрнең художество үзенчәлекләре аларны «күчеш» жанрына кертергә нигез бирә. Бер яктан, бу — өйне бизәүче җиһаз буларак файдаланылган чын халык сәнгате әсәре. Әмма, икенче яктан, алар — әһәмиятләре белән китапка якын торучы, билгеле бер гыйлем бирүче, сынлы сәнгатькә, якын торучы рухи әсәрләр. Шулай итеп, шәмаилләрне гамәли-кәнкүреш сәнгатеннән профессиональ сәнгатькә, аеруча китап графикасына күчү жанры дип билгеләргә мөмкин. Күп кенә бүгенге милли рәссамнарның — Б. Урманче, Ф. Әминев, Т. Хаҗиәхмәтов һ. б. ларның иҗатында шәмаилләргә хас аерым сыйфатларны күрергә мөмкин.

Хәзерге көндә, милли сәнгать төре, жанры буларак, шәмаилләр яшәүдән туктады. Алар урынына квартираларга чын картиналар, аларның репродукцияләрен кую мөмкинлеге туды. Шәмаилләр исә хәзер татар культурасы ядкарьләре буларак кына игътибарны җәлеп итә.

Әмма, шулай да, шәмаилләрнең кайбер типик булмаган йогынтыларын бүгенге татар сәнгатендә дә очратырга була: профессиональ рәссамнар, сирәк булса да, шәмаилләр язалар, аларга бүгенге эчтәлек бирәләр, аерым алганда, Тукай шигырьләрен урнаштыралар. Б. Урманче, К. Нәфыйковның шундый шәмаилләре бар.

Татарстан рәссамнары әсәрләреннән Г. Тукайның тууына 100 ел тулуга багышлап оештырылган күргәзмәдә Р. Харисовның «Ак калфак» дигән картинасы игътибарны җәлеп иткән иде. Композициясе, эчтәлеге (анда милли киемле татар кызы гәүдәләндерелгән) белән бик үк туры килмәсә дә, ул үзенең рухы белән шәмаилне нык хәтерләтә иде.

Әлеге фактларда халык художество культурасына күп гасырларның һәм традицияләрнең «хәтер»ен сеңдергән, үлемсез сыйфатлар күренә.

# ҖҮКӘТАУ

Ашыкмыйча, чал дулкыннарын салмак кына уйнатып, мәһабәт Кама ага... Күпне күргән, күпне кичергән тарихи елга ул. Аның ярына болгар бабаларыбыз төзегән шәһәр һәм авыллар сыенып утырган. Даны еракларга таралган, Җүкәтау исемен йөрткән шәһәр дә Кама якасында урнашкан булган.

Җүкәтау шәһәре монгол яуларына кадәрге чорларда, археолог Т. А. Хлебникова фикеренчә, XI гасырның икенче яртысында төзелә башлаган һәм заманында Идел-Кама болгарларының кечерәк князьлеге башкаласы вазифасын үтәгән. Җүкәтауда башка болгар калаларындагы кебек сәүдә, культура, фән һ. б. зур үсеш алган. Бу чорда ук Җүкәтау Каманың түбән агымы тирәләрендә экономика һәм культура үзәге була. Соңгы вакытларга кадәр бу якларда табыла торган бик күп матди культура ядкарьләренең Җүкәтау шәһәрләренә караган археологик исталекләргә тартым булуы әнә шул турыда сөйли. Җүкәтау халык тормышының мул һәм әйбәтлеге белән билгеле булган. Аның байлыгы ушкуйникларның да игътибарын үзенә җәлеп иткән һәм бу шәһәр алар тарафыннан даими таланып торган.

Җүкәтау шәһәре ныгытылган үзәк өлештән, шәһәр яны бистәсе һәм зираттан торган. Шәһәрнең үзәк өлеше — элек Җүкәтау дип аталган, ә хәзер Кили дип йөртелә башлаган суның Камага кушылган урынында барлыкка килгән биек тау башында. Вакытлар үтү белән суның Җүкәтау дигән исеме бары тик тарихи чыганакларда гына сакланып калган. Җүкәтау каласы кыр ягыннан 2 метр ярымнан да биегрәк булган өч кат вал һәм әлеге валлар арасында казылган, тирәнлеге 2,5 метрдан да артып киткән чокырлар белән ныгытылган. Тауның текә бите һәм кыр ягының көчле ныгытмалары шәһәрне дошманнардан саклаган.

Кили суының сул ягында, Каманың сөзәк ярында Җүкәтау каласының бистәсе урнашкан. Шәһәрнең үсүе һәм зураюы бистә хисабына барган. Бистәдә яши торган халык сәүдә, игенчелек, һөнәрчелек, Кама һәм Җүкәтау суларыннан балык тоту һ. б. белән шөгыльләнгән. Җүкәтау зираты бистәнең көньяк һәм көньяк-көнбатыш ягында урнашкан. Бистә зурайган саен зират чигенә торган. Анда табылган язулы кабер ташлары, галимнәр фикеренчә, үзләренә генә хас үзенчәлекләре белән аерылып тора.

Җүкәтау шәһәрлеге урынында монгол яуларына кадәрге чорга мөнәсәбәтле утыз тугыз корылма калдыклары табылган. Бу корылмалар үзләренең төрле-төрле булуы белән аерылып тора. 1236 ел вакыйгалары вакытында алар бөтенләй янып беткәннәр. Корылмалар төзү бирегә монгол яулары килер алдыннан аеруча зур үсеш алган. Җүкәтау шәһәрлеге урыныннан табылган әйберләр арасында шушы чорга караганнары гаҗәп тә күп төрле. Болар арасында балчыктан эшләнгән савыт-саба, хайван сөякләре, шлак һәм кирпеч калдыклары бар.

Җүкәтау шәһәренең политик аренага чыгуы монгол яуларына кадәрге чорларда башланган. Кама суы буйларында яшәгән болгарларның XII йөз ахырларына кадәр әле рус князьлекләре белән мөнәсәбәтләре дустанә була. XII гасыр ахырында һәм XIII йөз башларында Нократ суы аркылы Кама-

ның түбән агымына таба барып, анда ныгып алырга теләгән рус князьләре белән булган бәрелешләрдә Җукәтау кешеләре башка болгар шәһәрләре һәм авыллары халкы белән берләшкән. Рус феодалларының Түбән Кама буйларына кул сузуы, алар җибәргән гаскәрләрнең бу тирәләрдә яшәгән болгар халкын борчуы болгарларны яу белән килүчеләргә каршы тору, туган җирне саклау өчен көрәшкә күтәрелергә мәҗбүр итә.

Җукәтау шәһәре 1236 елда монголлар тарафыннан тар-мар ителә һәм яндырыла. Ләкин ул тиз арада торгызыла һәм ул Алтын Урда чорында үсүен дәвам итә. Үсү генә түгел, үзенең чәчәк ату чорын кичерә. Шәһәр яны бистәсенең мәйданы бу чорда, мәсәлән, элекке белән чагыштырганда өч тапкырга арта. Зур Совет Энциклопедиясендә Җукәтау каласы турында сөйләгәндә XIV гасырның уртасында ул Болгар илендә шәһре Болгардан кала иң бай, төп шәһәрләрнең берсе булган дип искә алына. 1359, 1391 һәм 1409 елларда Новгород, Вятка һәм Устюг ушкуйникларының төп һөҗүме Җукәтау каласына юнәлдерелә. Чөнки ул көчәя, ныгый һәм дәүләт иминлеген саклауга зур өлеш кертә башлаган була. Гомерен болгар тарихын өйрәнүгә багышлаган Мәскәү галиме А. П. Смирнов Җукәтау шәһәрен Болгар иленең көнчыгыш төбәкләренең үзәге дип атый. Җукәтау җирләрендә XIII-XVI йөзләргә караган тәңкәләр, төрле эш кораллары, керамика һ. б. матди культура истәлекләре, бик нәфис итеп алтыннан эшләнгән бизәнү әйберләре табылган.

Җукәтау шәһәре урыны Кама суының сулъяк ярында хәзерге вакытта Данауровка дип аталган рус авылыннан (Чистай районы) бер чакрым чамасы ераклыкта урнашкан. Казан өязе писцовая кенәгәләрен җентекләп өйрәнгән С. М. Шпилевский Җукәтау шәһәрлеге хәрабәләре янында шушындый исемдәге географик атамаларның бөтен бер җыелмасын таба. Әйтик, Җукәтау шәһәрлеге урынына яисә шул тирәләргә соңыннан килеп урнашкан рус авыллары Никольский һәм Данауровканы да халык Җукәтау дип атаган. Җукәтау суы, Җукәтау шәһәрлегеннән 9 чакрым ераклыктагы Берсут дип аталган суда кечү урыны — Җукәтау кечүе, Җукәтаудан 8 чакрым ераклыкта урнашкан борынгы болгар шәһәрлеге Еланлы (Змеевский городок) шулай ук Җукәтау дип аталган. Еланлы шәһәрлеге каршында гына Камадагы бер утрау Җукәтау дигән исем алган. Нугай юлы өстендә урнашкан Җукәтау авылының Казан ханлыгы чорында булганлыгы мәгълүм.

Җукәтау атамасы җукә (юкә) һәм тау сүзләре кушылып ясалган. Димәк, әлеге сүзләр болгар чорында ук халкыбызның тел җәүһәрләре булган. Болгар шәһәрләре Җукәтау һәм Тубылгытау исемендә очрый торган «тау» сүзе белән хәзерге татар авыл атамаларының бөтен бер типологик комплексы бар. Биектау; Тау иле — Зеленодольск, Питрәч, Мамадыш; Калатау, Явлаштау — Саба; Ялтау — Лениногорск; Яктытау — Чирмешән; Күктау — Сарман; Кызылтау — Тукай, Аксубай, Апас һәм Печмәнтау — Арча районнарындагы авыллар. Хәзерге вакытта төрки халыклар яши торган төбәкләрдә һәм кайчандыр алар яшәгән урыннарда да тау сүзе кергән төрки атамалар күп. Мәсәлән, Сарытау (Саратов), Имәнтау, Янгантау, Кызылтау, Кырыктау һ. б.

Кайчандыр шаулап тормыш иткән Җукәтау шәһәре хәзер җир белән тигезләнгән, урыны сөреләә. Ләкин шәһәрнең исеме халкыбыз тарихында мәңге онытылмаслык булып уелып калган.

Фирдәүс ГАРИПОВА,
филология фәннәре кандидаты

# УТЛЫ ЕЛЛАР АВАЗЫ

Сугыш чорында Татарстанда чыккан матбугат белән якыннан танышканда, утлы еллар авазын алып килгән ул хәбәрләр халкыбызның тиңдәшсез батырлыгына мәдхия булып та, яңа сугыш уты кабызырга маташучыларга кисәтү булып та яңгырый.

«Бөтенесе дә фронтка, дошманны җиңүгә!» — ул көннәрнең ялкынлы чакыруы шундый. Татарстан язучылары да сугышның беренче көннәреннән үк алгы сызыкка — каләм белән дә, штык белән дә дошманны кыйнау һәм җиңү өчен көрәшкә күтәрелә. Язучылар союзының 53 әгъзасыннан сугышның беренче елында ук инде 25 кеше фронтка китә. Алар арасында М. Җәлил, Ф. Кәрим, Н. Баян, С. Хәким, Ә. Исхак һәм башкалар бар.

Халкыбызның данлы улы, Ватаныбыз азатлыгы өчен гомерен биргән Гадел Кутуй хәрби комиссариатка язган гаризасында болай ди: «Барлык совет халкы социалистик Ватаныбызны дошманнан саклау өчен кузгалган бу авыр көннәрдә мин өйдә кала алмыйм. Мине хәрәкәттәге Кызыл Армия сафларына кабул итүегезне сорыйм. Каләмем һәм штыгым белән дошманны кыйнаячакмын, тормышымны партия эше өчен бирәчәкмен».

Әйе, сугыш тормышның барлык тармакларын үзгәртеп коруны таләп иткән. Шул исәптән язучылар эшчәнлеген дә. Ул чор мәкаләләре кыска, үткен тел белән, вакыйгаларның кайнар эзеннән язылулары белән аерылып тора.

Фронттан әдипләребез язган публицистик мәкаләләр дә, фронтка барып кайткан каләм осталарының чыгышлары да әледән-әле «Кызыл Татарстан» газетасы битләрендә күренә. Вакыт узу белән саргайган сәхифәләрдә — шул кырыс чорның сулышы, сынауларда сынатмаган халкыбызның батырлыгы.

Менә Әхмәт Исхакның «Кызыл Татарстан» газетасының 1942 ел, 10 сентябрь санында басылган «Бер адым да артка чигенмәскә!» дигән шигыре. Патриотик хис белән сугарылган ул әсәр тылда калган газиз аналарның, сөйгән ярларның яу кырына киткән ир-егетләргә наказы булып яңгырый:

*Ышанычын баглый сезгә халык!*
*Дошманнарга нәфрәт белән янып,*
*Алыгыз сез туганнарның үчен,*
*Кызганмагыз җанны Ватан өчен.*

Якташларыбыз бу сүзләрне ничек үтәгәннәр соң? Йөзгә кызыллык китермәгәннәрме? Бу сорауларга фронтовик шагыйрьләр язган шигъри юллар белән җавап бирергә мөмкин. Төньяк-Көнбатыш фронттан Шәрәф Мөдәррис болай дип яза:

*... Таң аткач та һөҗүм башланачак,*
*Ярсый йөрәк бүген шуңарга!*
*Күп тә үтмәс, илнең тугай-кырын*
*Нурга биләп таң да яктырыр...*
*Шул вакыт ул, уйчан курайчыбыз,*
*Пулеметлар җырын яудырыр!*

«Кызыл Татарстан»ның 1942 ел, 23 октябрь санында басылып чыккан «Атака алдыннан» дигән әлеге шигырь Минзәлә егете курайчы Зөфәрнең землянкада, якташлары арасында моң сузуы, аларны һөҗүм алдыннан дәртләндерүе, Ватан-ана турындагы изге уйларга салуы турында.

Вакыт узган саен теге яки бу вакыйганың мәгънәсе һәм әһәмияте кими, тоныклана. Бөек Ватан сугышы елларындагы каһарманлык еллар узган саен яңа төсмерләре белән ачыла гына бара.

Шул чорның кайнар сулышын алып килгән бер язма игътибарны үзенә җәлеп итә. Ул «Кызыл Татарстан» газетасының 1942 ел, 25 октябрь санында басылган һәм «Язучыларның барлык иҗат көчләрен фронтка ярдәмгә» дип атала. Татарстан совет язучыларының гомуми җыелышыннан язылган ул отчетта мондый юллар бар: «...Сугыш башлангач язучыларның патриотик иҗат көчләре дөрес юналеш алган. Язучыларның иң зур күпчелеге үзенең иҗатын совет халкының гитлерчы бандитларга каршы изге көрәшен чагылдыруга багышлаган. Т. Гыйззәт, Ш. Маннур, К. Нәҗми, Ә. Исхак, Г. Разин, А. Шамов, М. Әмир, Н. Баян, Ф. Хөсни, Р. Ишморат һ. б. иптәшләрнең төрле жанрдагы әсәрләре моны бик ачык күрсәтәләр». Шушы эшлекле сөйләшүдә Татарстан язучылары алдында торган кичекмәстән хәл ителергә тиешле бурычлар да ачыклана. Әйтик, герой якташларыбыз Илдар Маннанов, Салават Кәримов, Виктор Григорьев, Фәрит Фәтхуллин, Геннадий Гобәйдуллин һәм башкалар турында киң полотнолы әсәрләр тудыру кебек сугышчан бурыч тора, дип билгеләп үтелә җыелышта. Вакыйгаларны узып булса да әйтик, язучыларыбыз бу бурычны намус белән үти. Каһарман якташ-

ларыбыз турында шактый гына очерклар, поэмалар иҗат ителә, ә 1945 елда Татарстан китап нәшрияты «Батырлар китабы»н бастырып чыгара. Бөек Ватан сугышы тарихын өйрәнүчеләр өчен ул бүген дә хезмәт итә, чөнки әлеге әсәрләр вакыйгаларның кайнар эзеннән язылган булулары белән үзенчәлекле.

Сугыш елларында фронтовиклар белән тыл хезмәтчәннәре арасында ачык хатлар алмашу матур гадәтләрнең берсенә әверелә. Менә шундый хатларның берсе. Аны иҗат итешүгә язучыларның кулы кергәнлекне чамалавы читен түгел. Хат «Кызыл Татарстан» газетасында 1943 елның 6 мартында басылган. Аңа 1511137 кеше кул куйган. Арада Кави Нәҗми, Таҗи Гыйззәт кебек күренекле әдипләребезнең исемнәрен дә очратабыз. Хат публицистик осталык белән, гыйбрәтле мисаллар аша, СССР халыкларының дуслыгын гәүдәләндереп иҗат ителгән.

«Татар халкының күз нуры кебек кадерле уллары! Сөйгән ярларыгызның Сезне фронтка озатканда:

*Куркак хатыны булып яшәгәнче,*
*Батырдан тол калу яхшырак,—*

дип җырлап, Сезне батырларча көрәшергә өндәгән наказларын намус белән үтәвегез өчен сөенеп бетә алмыйбыз. «Куркак егет ир булмас», «Курыкканга куш, койрыгы белән биш», дип, куркаклыкка нәфрәт белән караучы татар халкы Сезгә, бабаларыгызның сугышчан традицияләрен саклавыгыз өчен иксез-чиксез рәхмәт укый». Күренгәнчә, хатның эмоциональ көч-тәэсирен арттыру өчен авторлар халык иҗатын киң файдаланган.

«Идел-йортның ирекле шәһәрләрендә, авылларында син үзеңнең сәләтеңә тиң хезмәт, талантыңа тиң профессия, мәхәббәтеңә тиң яр сайлап алдың.

Кайчандыр синең бабаларың:

— Дус-иш кирәк дөнья көтәргә... — дип җырлаганнар. Ул тугрылыклы дусларны син совет халыкларының тату семьясында таптың.

Кайчандыр синең бабаларың:

— Очар идем юк канатым... — дип моңаеп җырлаганнар. Совет власте сиңа болытлардан югары очарлык, кешелек культурасының иң биек тауларын күтәрерлек көчле канатлар үстерде».

Хатта фашистларга ачы нәфрәт хисе конкрет мисаллар аша тәрбияләнә.

Бу хатта шулай ук шагыйрьләребез әсәрләре дә оста һәм белеп файдаланылган. Ә нигә бүгенге үзгәртеп корулар чорында да әдипләребезгә, журналистларга халык белән аралашуның шундый формасын кабатламаска соң әле?!

Ул чордагы татар матбугаты фронтовик шагыйрьләр иҗатына киң урын бирә, алар эшчәнлеген даими күзәтеп тора, дөрес юнәлеш бирергә омтыла.

1943 елның 13 мартында «Кызыл Татарстан» тәнкыйтьче Хәсән Хәйринең «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында шигырьләр» дигән күләмле мәкаләсен бастырып чыгара. Автор анда сүзне орденлы шагыйрь Шәйхи Маннур иҗатына юнәлдерә. Мәгълүм булганча, Бөек Ватан сугышы барган көннәрдә Ш. Маннурның «Җиңүчеләргә сәлам» исемле җыентыгы басылып чыга, аңа фронтовик шагыйрьнең окоплардан язган 19 шигыре туплана.

«Маннур бүгенге хәлләрне, һәр яңалыкны, сугыш чорында туган вакыйга, фактларны күрә һәм шагыйрь йөрәге белән сизә. Ул үзенең шигырьләрен фашистлар кулына эләкмәс өчен гранатасы белән үзен дә, дошманнарны да шартлаткан батыр старшина Курмаевка, сугышчы-шофер Ибраһим Сабитовларга («Халык улы», «Шофер һәм малай» һ. б.) багышлый. Ленинград халкының, Москваны саклаучы каһарманнарның батырлыкларын, совет халыкларының бердәмлеген, ышанычын, дошманга ачы нәфрәтен җырлый»,— дип яза Х. Хәйри.

Озак та үтми, газета фронтовик шагыйрьнең танылган «Гайҗан бабай самолеты» әсәрен бастырып чыгара. Фатих Кәримнең сугыш елларында иҗат ителгән һәм бүген дә дәреслекләребезнең йөзек кашы булып йөргән «Пионерка Гөлчәчәккә хат»ы һәм башка күп әсәрләре әнә шулай кайнар вакыйгалар эченнән алып язылган булулары белән әһәмиятле.

Язучыларыбызның көрәшче иҗатлары турында аерым-аерым сөйләргә мөмкин. Аларның агитация-пропаганда һәм оештыру эшендә кылган игелекләре, кулларына корал тотып дошманга каршы атакага күтәрелүләре, Муса Җәлил, Абдулла Алиш кебек каһарманнарыбызның дошман тылында аяусыз көрәш алып барулары һәм палач балтасы алдында да сынатмаулары үзләре бер дастан.

Шунда ук Габдрахман Әпсәләмов, Нәби Дәүли, Шәрәф Мөдәррис, Әмирхан Еники, Мөхәммәт Садри, Сибгат Хәким һәм башкалар сугыш елларының төрле чорын, төрле төбәкләрен, төрле вакыйгаларын чагылдырган гүзәл әсәрләр иҗат иттеләр. Аларның данлы традицияләре бүген Хисам Камалов, Шамил Рәкыйпов, Мөхәммәт Мәһдиев, Самат Шакир һәм башкаларның иҗатларында дәвам итә. Димәк, батырлык онытылмый. Димәк, ул еллардагы каһарманлык әле бик озак вакыт буена әдипләребезгә илһам чыганагы булып хезмәт итәчәк.

**Сәмигулла ХӘЙРЕТДИНОВ**

# КАЛƏМДƏШЕМ ТУРЫНДА

## НУР ГЫЙЗЗƏТУЛЛИНГА 60 ЯШЬ



Сугыштан соң Г. Кашшаф, Г. Халит һəм Х. Хəйри кебек өлкəн буын тəнкыйтьчелəргə кечкенə бер төркем яшь тəнкыйтьчелəр өстəлде. Арада бүген алтмышын тутырган Нур да бар иде (ай бу гомер дигəнең!) Студентлар идек əле, соңрак аспирант булдык. Түгəрəклəргə йөри, иҗат секциялəренə чаба идек, Язучылар союзында булган бер җыелышны да калдырмый идек. Тамак ягы такы-токы, өс-баш ташкүлчим, кеше почмагында яшибез. Шулай да күңел күр, килəчəккə ышаныч зур. Бəхəслəшəбез, кычкырышып та алабыз. Тик шунысы бар: алга карап яшəгəнгəме, əдəбият мəнфəгатен бар нəрсəдəн өстен куйгангамы, бер-беребезне өнəмəү, күпсенү, үчлəшү кебек нəрсəлəр юк иде.

Менə бүген калəмдəшемнең «ташка басылган» хезмəтлəрен күздəн кичерəм дə җиңел сулап куям: бəрəкəтле гомер кичергəн икəн бит ул. Дөрес, китаплары күп түгел: Кави Нəҗми турында ике монография дə «Əдəбият белеме сүзлеге». Аның каравы республиканың барлык газета һəм журналларында, төрле җыентык һəм басмаларда йөзлəгəн мəкалə һəм рецензия! Шунысы да күзгə ташлана: яшьрəк чагында ул һəммəбезгə караганда да өлгеррəк булган икəн. Əдəбияттагы һəр яңалыкка карата дип əйтерлек үзенең тавышын ишеттерə килгəн. Менə мəкалə һəм рецензиялəренең язылуына сəбəп булган язучыларның кыскартылган исемлеге: Г. Ибраһимов, Ф. Хөсни, И. Гази, Г. Толымбай, М. Максуд, Ə. Еники, Г. Əпсəлəмов, Г. Галиев, А. Шамов, А. Расих, Р. Төхфəтуллин. Берсен юри ахырга калдырдым. Кави Нəҗми бу, Нур Гыйззəтуллинның «үз» язучысы. Кави Нəҗми прозасы буенча ул диссертация яклады, мəкалəлəренең күп өлешен аңа багышлады, əдипнең дүрт томлык əсəрлəр җыелмасын гыйльми нигездə əзерлəп чыгарды. «Татар совет əдəбияты тарихы» (1960) һəм «История татарской литературы» («Наука», М., 1965) исемле калын-калын ике китаптагы К. Нəҗми турындагы монографик бүлеклəрне ул язды.

Укучы игътибар иткəндер: Н. Гыйззəтуллин калəменə «элəккəн» язучыларның барысы да прозаиклар. Əдəби тəнкыйтьтə дə үзенчəлекле хезмəт бүленеше яшəп килə бит. Безнең Нур исə, Кави Нəҗмидəн этелеп китеп, проза буенча белгеч булып үсте. Югарыда телгə алынган кирпеч калынлыгы китапларда, 20-елларны исəплəмəгəндə, проза турындагы барлык бүлеклəр дə Н. Гыйззəтуллин тарафыннан язылган. «История советской многонациональной литературы» («Наука», М.) дигəн күптомлы хезмəттə татар прозасына караган бүлеклəр шулай ук аның калəменнəн чыкты. Прозаның илле еллык тарихын бер системага салу, аны бербөтен итеп күрсəтү, катлаулы һəм каршылыклы үсеш-үзгəреш юлын билгелəү — Гыйззəтуллин башкарган эшлəрнең менə икенчесе.

Калəмдəшебезнең əдəбиятка керткəн өлешен тəкъдир итү белəн бергə, əйдəгез, аңа яңадан-яңа иҗат уңышлары телик.

Ибраһим НУРУЛЛИН.

## МАКСИМ ГОРЬКИЙГА БАГЫШЛАП

Казанда А. М. Горькийның тууына 120 ел тулуга багышланган тантаналар булды. 29 мартта В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында А. М. Горький иҗатына багышланган юбилей конференциясе үткәрелде. Татарстан Художниклар союзының Күргәзмәләр залында «А. М. Горький сынлы сәнгатьтә» дигән күргәзмә ачылды.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында узган юбилей кичәсенә йөзләрчә казанлылар һәм кунаклар килгән иде. Президиумда — КПСС өлкә комитеты беренче секретаре Г. И. Усманов, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ш. Ә. Мустаев, ТАССР Министрлар Советы Председателе М. Ш. Шәймиев, иҗат союзлары җитәкчеләре, хезмәт коллективлары, партия, совет, профсоюз, комсомол оешмалары вәкилләре, Польшаның Ломжа воеводалыгыннан килгән делегация членнары.

Юбилей кичәсен КПСС өлкә комитеты секретаре Н. Х. Кадерматов ачты. А. М. Горькийның тормыш һәм иҗат юлы турында доклад белән ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары, филология фәннәре докторы М. Х. Хәсәнов чыкты.

Тантаналы өлештән соң Татарстан сәнгать осталарының зур концерты булды.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

18 февральдә Әлмәт язучылар оешмасының әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышы булды. Поэзия буенча Э. Мөэминова, проза буенча Ф. Гыйльми доклад ясады.

Фикер алышуларда язучылар А. Хәсәнов, К. Булатова, Җ. Рәхимов, Сарман, Азнакай, Лениногорск, Бөгелмә әдәби берләшмәләре вәкилләре катнашты. Оешманың җаваплы секретаре Н. Әхмәдиев йомгаклау сүзе белән чыкты.

Җыелышта Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Г. Рәхим, Чаллы язучылар оешмасының җаваплы секретаре Г. Кашапов, «Казан утлары» журналының әдәби тәнкыйть бүлеге мөдире М. Вәлиев катнашты һәм чыгыш ясады.

19 февральдә Лениногорск шәһәренең М. И. Калинин исемендәге Техника йортында язучы Шамил Бикчуринның тууына 60 ел тулуга багышланган кичә булды.

Юбилярның иҗат юлы турында язучы Җ. Рәхимов сөйләде. Кичәдә катнашкан язучылар, партия һәм совет оешмалары җитәкчеләре, нефтьчеләр, төзүчеләр юбилярны кайнар котладылар.

Соңыннан Ш. Бикчурин оештырып җибәргән «Чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсе членнары һәм шәһәрнең үзешчән артистлары катнашында зур концерт күрсәтелде.

23 мартта Әлмәттә төзүчеләрнең Техника йортында язучылар оешмасының 25 еллыгына багышланган әдәбият-сәнгать кичәсе булды. Аны КПССның шәһәр комитеты секретаре А. П. Никифоркин ачты.

Кичәдә оешманың элеккеге җитәкчеләре Г. Ахунов, Ә. Маликов, Ә. Гаффар чыгыш ясады. Каракалпак АССР иҗат оешмалары вәкиле К. Җуманиязов, КПССның Азнакай шәһәр комитеты секретаре З. Мөхәммәдьярова, язучылар: Чаллыдан Г. Кашапов, Я. Игәнәй, Зеленодольскидан М. Хәсәнов, Мөслимнән Ф. Садриев, Минзәлә драма театры режиссеры Л. Садриев, Әлмәт драма театрының баш режиссеры Р. Абдуллаев һ. б. язучыларны җылы тәбрикләде.

## ТУГАНДАШ БАШКОРТСТАН ҖИРЕНДӘ

25 мартта Башкортстан дәүләт университетында «Казан утлары» журналының укучылар конференциясе үткәрелде. Очрашуны университет проректоры, профессор М. Ф. Гайнуллин ачып җибәрде. Журналның баш редакторы Р. Харис «Казан утлары»ның тарихы, эшчәнлеге, киләчәккә планнары турында сөйләде, тыңлаучыларның күпсанлы сорауларына җавап бирде. Проза бүлеге мөдире Р. Низамиев якындагы саннарда басылачак роман һәм повестьларга тукталды.

Конференциядә БДУның татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире вазифаларын башкаручы С. Поварисов, «Агыйдел» журналының баш редакторы урынбасары прозаик Р. Солтангәрәев, шагыйрь Р. Бикбаев һәм «Акчарлак» әдәбият-иҗат берләшмәсе членнары да чыгыш ясады.

Халыклар дуслыгын тагын да ныгытуны күздә тотып, Уфа резина-техник әйберләр заводы культура сарае каршында татар мәдәниятен сөючеләрнең Г. Ибраһимов исемендәге клубы ачылган иде.

24 марттагы очрашуга клуб членнары «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харисны чакырдылар. Р. Харис журналның эшчәнлеге, әдәбият-сәнгать яңалыклары турында сөйләде, сорауларга җавап бирде. Очрашуда журналның проза бүлеге мөдире Р. Низамиев та катнашты.

Кичәнең икенче өлешендә Кушнаренко

районы үзешчәннәре концерт күрсәтте. БАССРның атказанган культура работнигы М. Гыйләҗев үзе язган көйләрне башкарды. Соңыннан башкорт шагыйрьләре А. Хәлим, Р. Шаммазов, Ф. Габдрахманов, Р. Идиятуллин үзләренең шигырьләрен укыды.

Февраль аенда Уфада башкорт шагыйре Ә. Атнабаевка 60 яшь тулу уңае белән уздырылган иҗат кичәсендә Татарстаннан шагыйрь Р. Гатауллин катнашты. Ул юбилярны Татарстан Язучылар союзы исеменнән котлап, истәлекле бүләк тапшырды.

## ҮЗЕШЧӘН КОМПОЗИТОРЛАР КИЧӘСЕ

31 мартта Татар дәүләт академия театрының М. Горький урамындагы бинасында үзешчән композиторлар кичәсе булды. Мәсгут Имашев, Илгиз Закиров, Фирзәр Мортазин, Ренат Гобәйдуллин, Вәсим Әхмәтшин, Хәлил Сәлимов, Разим Вәлиуллин, Рәйсә Имамиева, Валерий Әхмәтшин, Фәрит Хатыйпов җырларын һәм инструменталь әсәрләрен төрле шәһәрләрдән, районнардан килгән үзешчән җырчылар, оркестрлар, эстрада ансамбльләре башкарды. Гали Исхаков, Сафьян Ибраһимов, Сания Әхмәтова, Һашим Салихов, читт өлкәләрдә яшәп иҗат итүче авторлар: Мәскәүдән Фирдәвес Вафин, Робес Зарипов, Чиләбедән Рафаэль Бакиров һәм Нил Миңязов көйләренә язылган җырлар да матур тәэсир калдырды. Соңыннан алар иҗаты турында сөйләшү булды.

## САЛИХ СӘЙДӘШЕВНЕҢ МИРАС КОМИССИЯСЕ

1990 елда композитор Салих Сәйдәшевнең тууына 90 ел тула. Шул уңайдан Татарстан Культура министрлыгы һәм Татарстан Композиторлар союзы каршында С. Сәйдәшев мирасын җыю, пропагандалау буенча республика даими комиссиясе төзелде. Комиссия председателе — РСФСРның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе композитор Ә. Бакиров. Комиссия бөек композиторның күпкырлы иҗатын яңабаштан барлау, өйрәнү, аларны бастырып чыгару, тормыш юлын өйрәнү, истәлекләр җыю һәм аның исемен мәңгеләштерү буенча күп төрле практик эшләр башкаруны үзенә бурыч итеп куйды. Комиссия С. Сәйдәшевка Казан шәһәрендә һәйкәл кую мәсьәләсе буенча тиешле оешмаларга мөрәҗәгать итәчәк.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет әдәбияты, театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы Рөстәм Мингалимовка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1988 ел, 2 март Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татар дәүләт драма һәм комедия театры артистлары Хәлил Мәхмүтовка һәм Ренат Мифтаховка Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1988 ел, 1 апрель Указы белән, «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татар дәүләт драма һәм комедия театры артистлары Әнәс Галиуллинга, Зөләйха Хәкимҗановага һәм Зөфәр Харисовка Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1988 ел, 1 апрель Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

## ХЕЗМӘТЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет театр сәнгате өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисткасы Рауза Хәйретдинова, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1988 ел, 18 февраль Указы нигезендә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

## КОТЛЫЙБЫЗ

Әдәбият белгече һәм тәнкыйтьче, журналыбызның редколлегия әгъзасы Азат Әхмәдуллин Алма-Атада Казахстан ССР Фәннәр академиясенең М. Әуэзов исемендәге Әдәбият һәм сәнгать институтында «Татар драматургиясендә социалистик реализмның формалашуы» дигән темага докторлык диссертациясе яклады.

Оппонентлар — СССР Педагогия Фәннәре академиясенең член-корреспонденты, Казахстан ССРның атказанган фән эшлеклесе профессор С. Кирабаев, РСФСРның һәм БАССРның атказанган фән эшлеклесе профессор М. Гайнуллин, профессор Т. Галиуллин.

Фәнни дәрәҗәнең раслануы турында 12 февральдә хәбәр килде.

Галимне югары фәнни дәрәҗә алуы белән кайнар котлыйбыз һәм иҗади уңышлар телибез.

# УКАЛЫ КАЛФАК

Халык аны элек-электән телдә тибрәткән, җырларына керткән:

*Ак калфагың, әй, укалы чук,*
*Укаларын алсам — яме юк.*
*Син сылудан башка чибәрләр күп,*
*Синнән башка торыр хәлем юк...*

Калфак — төрки халыклар көнкүрешендә киң таралган баш киеме. XVIII—XIX гасырларда «маңгайлык» рәвешен алган калфакның юл башы болгар чорында, аннан да элегрәк елларда кулланылган гади һәм йомшак баш киемнәренә барып тоташа.

Борынгыдан килгән бизәк-төсмерләрне калфакның түбәнге, каты өлеше ныграк саклаган. Мондагы нәкыш-чигешләр, үсемлекләр дөньясын сурәтләү белән беррәттән, хәрефләр һәм сүзләр язылышын хәтерләтә. Элегрәк бу бизәкләр урынына төрле теләкнамәләр, хатын-кызны күз тию ише нәрсәләрдән, яман көчләрдән саклаучы тылсымлы сүзләр язылган булса кирәк. Халык телендә «маңгайга язылган» дигән тәгъбир дә, мөгаен, нәкъ менә шуңа ишарәли.

Төрле төстәге бәрхеткә алтын һәм көмеш җепләр чигеп ясалган калфак XIX гасыр урталарында бизәнү әйберенә әверелә башлый, хатын-кызның башка төрдәге баш киемнәре арасында нәкъ менә шул сыйфат та өстенлек итә. Калфак җыйнаклана, камилләшә, күркәмрәк була бара. Аның килеш-килбәте, укалап чигелгән бизәк-гөлләре калфак иясенең күңел рухын, эчке кичерешләрен, хис-тойгыларын чагылдыра. Бәрхет өстенә яткан чигешләргә игътибар итсәк, анда күбесенчә чәчәк бәйләмнәрен, ай-йолдыз балкышларын, урман кошларын, үлән яфракларын, үсемлек сабакларын күрербез. Болар барысы да табигатьнең яшәү сулышын, яшәү көчен зурлый. Аларда тормышның гади һәм бөек фәлсәфәсе — туу-яңару, чәчәк ату, саргаю һәм шиңү, яңа үсентеләр, яңа бөреләр калкып чыгу кебек мәгънәләр сурәтләнә.

Шунысы игътибарга лаек: калфакта төп кыйммәт тукыманың яки җепләрнең ни дәрәҗәдә кыйбатлы булуында түгел, ә бәлки бизәк-сурәтләргә салынган мәгънәнең, хис-тойгыларның юнәлешендә һәм үзенчәлегендә. Әйтик, төнге күк йөзен хәтерләткән бәрхеткә чигеп ясалган ярымтүгәрәк ай, балкып-җемелдәп торган йолдызлар — ай-йолдызлы төннең серле һәм сихри матурлыгын сөйли, яшьлек хисләрен, яшьлек хатирәләрен чагылдыра.

Әле XIX гасыр башларында калфактагы бизәкләрдә җирнең уңдырышлылыгын, табигать байлыгын олылау кебек гомумирәк символлар киң таралган булса, соңрак инде төрледән-төрле киная-символларның бер бизәккә, аерым бер сурәткә — катлаулы композициягә тупланыуы күзәтелә.

Егерменче гасыр башында инде калфаклар кечерәя, алардагы бизәкләрдә табигатьнең, хатын-кызның матурлыгына шигъри мәдхия, эчке кичерешләргә киная ясаган төсмерләр киңрәк урын ала. Шулай итеп, калфак көнкүрештә кулланылган баш киеме булудан бигрәк, затлылык, нәфислек, хәтта күпмедер дәрәҗәдә көязлек билгесе булып әверелә.

Гомумән, калфак баш киеме буларак та, бизәнү әйбере буларак та, татар хатын-кызларының рухи матурлыгын, күңел байлыгын, тегү-чигү эшенә осталыгын, дөньяны танып-белүдә нечкә сизгерлеген, зәвыгын чагылдырган сәнгать җәүһәре ул.

**Р. ШАҺИЕВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музее
гыйльми хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Татарстан Рәссамнар союзының күргәзмәләр залы.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)